Рәмзи Вәлиев

Өзелгән дога



РӘМЗИ
ВӘЛИЕВ

ӨЗЕЛГӘН ДОГА

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2007

УДК 94 (47)
ББК 63.3 (2 Рос=Тат)
В 97

Вәлиев Р.К.

В 97 Өзелгән дога / Рәмзи Вәлиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 270 б. — 2000 д. — ISBN 978-5-298-01486-1

Октябрь инкыйлабыннан соң большевиклар илдә астыртын рәвештә репрессияләрне башлап җибәрделәр. Яңа хакимият төрле юллар белән татар халкын үзенең мәнфәгатьләреннән ваз кичеп, дәүләтсез, телсез халык итү өчен барын да эшләде. Нәтиҗәдә тарихи вакыйгалар, шәхесләрнең язмышлары өйрәнелмәде. Бу вәисиләр хәрәкәте, «Болак арты республикасы» вакыйгаларында һәм татар халкының күренекле зыялыларының язмышларында чагыла. Шәхесләр онытылды, вакыйгалар бозып язылды.

Китап татар халкының яңа чордагы фаҗигале тарихын моңа кадәр өйрәнелмәгән материалларга нигезләнеп язылган. Урындагы хакимият, партия, аерым шәхесләрнең үзара мөгамәләләре — яңача яшәүнең үзенчәлекләре тасвирлана. Автор үзенең хезмәтен архив материалларына нигезләнеп язган һәм әлегә кадәр аңлаешсыз яисә бөтенләй тарихта өйрәнелмәгән проблемаларны укучыга җиткерә. Китапның асылы менә шунда.

Китап киң җәмәгатьчелеккә һәм Татарстан тарихы белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-298-01486-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Вәлиев Р.К., 2007

АВТОРДАН

XX гасырның 80 нче еллар азагында ук архивларда эшләгәндә, мин шактый үзенчәлекле чыганакларга тап булдым. Миңа кайбер танышларым: *«Рәмзи, син бу «Алтын жилка»ны ничек таптың»*, — диделәр. Чыннан да, бертуган Шәрәфләр турында Казан, Оренбург, Ташкент һәм Петербург архивларында сакланган чыганаклар Татарстан тарихын өйрәнүчеләр өчен бик тә әһәмиятле урын алып торалар. Галимҗан Шәрәф өйрәнелмәгән бер шәхес кенә түгел, үзе бер феномен. Ул шагыйрь дә, дәүләт эшлеклесе дә, милли дәүләтчелекнең теоретигы да, чын көрәшче дә. Татар телен саклап калу буенча ул, 20–30 нчы елларда партиясезләрнең юлбашчысы булып, җиң сызганып, тоталитар режим белән көрәшә. Ул чорда И.Сталинга язган бөтен хатлар аның мөхбирлеге астында эшләнелә. Күпләр Гаяз Исхакыйдан баш тарткан чорда: *«Киләчәктә яшьләр аны укыячак, чөнки Гаяз кебек татар халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, тормышын классик буларак Октябрь инкыйлабына кадәрге чорны берсе дә тулы килеш күрсәтә алмады»*, — ди Г.Шәрәф. 1917–1918 елларда бәйсез «Идел-Урал штаты»н төзү өчен бөтен көчен биргән Галимҗан Шәрәфетдинович Шәрәф 30 нчы елларда авыр хәлдә кала. Аңа милләтче, халык дошманы ярлыгын тагып каторгага җибәрәләр. Аның язмышы — «халык язмышы», ә җыеп әйткәндә, бу безнең барыбызның да фаҗигабез. Ул дәвердә татар халкын дәүләтсез, телсез калдыру өчен барысы да эшләнелә. 30 нчы еллар башында ГПУшниклар бу өлкәдә шактый уңышка ирешәләр. Алар төрле контрреволюцион «оешмаларны фаш итеп», милләтнең «каймагын» җыеп юк итәләр. Мондый эшләр Кандыбин тарафыннан төзелгән һәм *«Обвинительное заключение о контрреволюционной деятельности одной из групп кадров филиала Султан-Галеевской организации в Татарии, объединившего буржуазно-националистические элементы в г.Казани. Справка составлена по материалам объвинения следственного дела СПО ОГПУ Татарской АССР 1931 г. за № 161»*дип аталган. 160 биттән торган гаепнамәдә йөзләгән татар зыялыларының исем-фамилияләре теркәлгән: Җамал Вәлиди, Гали Рәхим, Каюм Мостакаев, Садри Вәлидов (Садри Җәләл), Шиһаб Әхмәров, Хәбибрахман Зәбиров, Ибраһим Аитов, Әхмәт Хөсәенов, Лотфулла Вахитов, Котдус Фәхретдинов, Бакый Сөләйманов, Гали Ихсанов, Абдулла Әхмәдуллин, Габбас Хөснетдинов, Йосыф Латыйпов, Шәех Али Әскәр, Сәләхетдин Вафин һ.б. Чыннан да, бу шәхесләр тирәсендә тагын кемнәр генә булмаган... Менә шуларның язмышы турында мәгълүмат җиткерү теләге белән «Гаепнамә,

[illegible] «Татар контрреволюциясе» дип аталган тарихи очерклар [illegible] да иде.

1923 елда Мәскәүдә 9–12 июньдә узган яшерен киңәшмәдә Мирсәет Солтангалиев эшен карап, «солтангалиевчелек» дигән [illegible] оешма «тудырып», тоталитар режим бу сәяси провокациянe зур осталык белән башкара. Шуның нигезендә сталинчылар «контрреволюцион оешманың Казандагы солтангалиевчеләр филиалы» дигән «оешма»ны уйлап чыгаралар. «Оешма»-да искә алынган зыялыларның барысына да «контрреволюционерлар» дигән ярлык тагалар. Гаепнамәдә алар турында: *«Все они были квалифицированы как основные кадры буржуазно-националистического движения в противовес власти Советов в национальных областях вообще и, в частности, в Татарии. Это во-первых. И во-вторых, эти основные кадры буржуазно-националистического движения, в противовес власти Советов, активно, в борьбе с Советами, добивались утверждения буржуазно-демократического правопорядка на территории нынешнего Татарстана, ведя борьбу за создание так называемого «Идел-Уральского штата»*, — дип язылган. Билгеле булганча, 1918 елда Солтангалиев үзе II Мөселман съезды әгъзаларын «Идел-Урал штаты»н төзергә теләгәннәрe өчен кулга алып куып тараткан иде. 1923 елда аның инде үзен кулга алып, Татарстанда солтангалиевчеләрне эзәрлекләргә керештеләр.

Бу очеркта шулай ук «Яңа китап» нәшриятына кагылган материаллар да дөнья күрделәр. Әлегә кадәр тарихнамәбездә бу турыда мәгълүматлар бөтенләй диярлек юк иде. Шушы елларда Татиздатта булган вакыйгалар да тулысынча өйрәнелмәгән.

Китапның «Өзелгән дога» дип аталган өлешендә сүз 1862 елда башланып киткән *вәисиләр хәрәкәте* турында бара. Бу хәрәкәт әле өйрәнелә генә башлады. Аңа багышланган язмалар революциягә кадәр үк шактый язылганнар иде, ә тоталитар режим чорында бездә М.Сәгыйдуллинның язмасыннан башка 60 нчы елларга кадәр бер материал да булмады. Булмады гына түгел, аны искә алу да куркыныч иде. Бары тик француз тарихчыларыннан Келькеже һәм Беннигсен гына бу турыда яздылар.

Әлеге хәрәкәткә кагылышлы документлар белән мин 1965–1968 елларда аспирантурада уку чорында таныштым. Шушы елларда архивта эшләгәндә, Мидхәт Вәисев белән таныштым. Ул Гайнан Вәисев турында җәмәгатьчелеккә аңлатырга тырышкан иде. Шул вакытта ул үзе дә шактый материалларны белми иде. Соңрак ул «Габдулла Тукай һәм Сәрдар Гайнан Вәисев» (1979) исемендәге кулъязмасын тәкъдим итте. Әмма аны нәшер итәргә рөхсәт итмәделәр. Ахыр чиктә ул А.Сусловка, М.Горбачевка, ҮКка, Татарстан өлкә комитеты секретаре Г.Усмановка мөрәҗәгать итә. М.Вәисев Баһави, Гайнан Вәисевләр хакын-

да дөрес итеп язуны таләп итә, үзе дә, төрле мәкаләләр язып, тарихчыларны, әдәбиятчыларны дөрес юлга басарга өнди. Аның хатлары белән сез Татарстан Милли архивында таныша аласыз.

Мин үзем дә бу хакта 40 ел элек кандидатлык диссертациясендә, ә аннан соң 1972, 1979 елларда нәшер ителгән монографияләремдә язып уңай бәя биргән идем. М. Вәисев бер язмасында, француз тарихчыларыннан Беннигсен һәм совет тарихчысы Р.К.Вәлиев *вәисиләр хәрәкәтенә* уңай бәя бирәләр, дип язган иде. Шулай итеп, М. Вәисев ул вакыт миңа «медвежью услугу» ясады. Мине куркыныч астына куеп, антикоммунистлар белән бер рәткә бастырды. 70 нче еллар өчен бу бик куркыныч хәл иде.

Моның файдасы зур булды — әзер эш белән докторлык диссертациясен яклау өчен 10 еллык гомеремне сарыф иттем. Шул вакытта декан вазифаларын үтәгән И.Р.Таһировка зур рәхмәт белдерәсем килә. Ул һәрвакыт миңа рухи көч биреп торды. Бүгенге көндә бу темага язучы шактый кыю авторлар пәйда булып, *вәисиләр хәрәкәтенә* уңай караш булуларын күрсәтәләр. Моның белән бергә 20 нче һәм шуннан соңгы чорда бу теманы күтәргән авторларны да онытырга ярамый. Шундыйларның берсе — профессор, фәлсәфә фәннәре докторы Котдус Дәүләтшин, вәисиләр кемнәр алар дигән сорауга дөрес җавап бирергә омтылыш ясавы тоталитар режимга ошамады, аны Мәскәүдәге ҮК каршындагы диннәр буенча комитетындагы эшеннән азат итәләр. М.Вәисев тә Халыкара икътисад институтыннан (Институт международной экономики) куыла. Шулай итеп, *вәисиләр хәрәкәтен* өйрәнүгә каршы киртәләр күп булды. Ниһаять, бүген бу турыда иркен фикер йөртү мөмкинлеге бар. Шуңа күрә бу очеркларда без аның өйрәнелмәгән өлешләренә күбрәк урын бирергә тырыштык. Аларның программалары тулы килеш бирелә. Ләкин бу очерк *вәисиләр хәрәкәтен* тулысынча яктырта дип әйтә алмыйбыз. Яңадан-яңа чыганаклар табыла, һәм бу хәрәкәткә булган карашлар да үзгәрә. Бу — табигый хәл. Әйтеп үтелгән очерклар белән турыдан-туры бәйләнгән вакыйгалар «Милли тайпылыш», «Гаепсездән гаепләнгәннәр» дип аталган кисәкләрдә дә чагылыш табалар. Тоталитар режимының каты кулы йөзләгән татар зыялылары-коммунистларының гомерен кисте. Шуны да искә төшереп китми ярамый, бернинди «милли тайпылыш» булмаган ул вакытта бары тик милләт мәсьәләсендә генә төрле карашлар яшәгән. Үзәк татар коммунистларын уңнарга, сулларга бүлеп, аларның фикерен бозып күрсәтеп үз сәясәтен генә алга сөрә. Үзәкнең сәясәтенә туры килмәгән фәлсәфә соңрак юк ителә. Уңнар һәм суллар бары тик лагерьларда гына «бер» булалар. Бу очеркларда шулай ук беренче суверенитетка да бәя бирелә.

Галимҗан Шәрәфкә һәм Әгъдәс Борһановка багышланган очерклар да үзенчәлекле. Галимнәрнең язмышы — халык яз-

мыны, алар фаҗигасе — ул безнең дә фаҗига. Аларның тормыш юллары төрле чорга туры килсә дә, язмышлары — уртак.

Галимҗан Шәрәфнең «Миллиятне ничек аңлыйсыз?» дип аталган язмасы бүген дә бик актуаль проблеманы алга куя.

«Болак арты республикасы» дип аталган бүлек Татарстанның дәүләтчелек яулап алган чорындагы вакыйгаларга багышлана. «Болак арты республикасы» нәрсә соң ул? Без менә шушы сорауга җавап эзләдек.

Һәммәсен дә җыеп әйткәндә, без Татарстан тарихын, XX гасыр башындагы вакыйгаларны дөресрәк итеп күрсәтергә тырыштык.

Тормыш иптәшем Люция Әбүзәрова-Вәлиеваның якты истәлегенә багышлана

ГАЕПНАМӘ, ЯИСӘ «ТАТАР КОНТРРЕВОЛЮЦИЯСЕ»

1932 елның салкын гыйнвар ае иде. Дзержинский урамындагы Иминлек идарәсе йорты янына җиңел машина килеп туктады.

Гадәттә, мондый салкын көндә урамда кешеләр аз була. Берәүләр гыйнвар салкыныннан шүрләсә, икенчеләре исә бу бинаны гына түгел, хәтта урамын да әйләнеп узу хәерлерәк дип санлыйлар булса кирәк.

Машинадан бер хәрби чыгып, тиз генә идарәнең имән ишекләре артына чумды. Бары тик ишектән чыккан җылы пар гына, өерелеп, түбәгә үрмәләде. Машина да ике йорт арасына кереп юкка чыкты. Әйтерсең лә икесен дә җир йотты.

— Күрдеңме? — диде каракүл бүреген баса төшеп кигән кыска тунлы кеше.

Киң җилкәле, кара кашлы, күзлекле, фетр итеклесе дәшмәде. Ул идарә ягын күзәтә иде. Үзен кемдер сагалап торгандай тоелды аңа.

— Өч хәреф, — диде ул, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп.

— Кандыбин бу, Шомбай! Кандыбин! — диде тегесе сүзсез катып калган иптәшенә.

— Кем соң ул Кандыбин? — диде каракүл бүреклесе, һаман да акрын, сак тавыш белән. Хәер, Гали Рәхим инде күптән кычкырып сөйләшми башлаган иде. Хәзер мондый хәл гадәткә кереп бара инде.

— Кандыбин ул, Гали, уполномоченный председатель ОГПУ Татарской АССР, ә безнеңчә әйткәндә, өч хәрефтән торган идарәнең хуҗасы, диктатураның кан кою буенча вәкиле, — диде ул, сагаюын саклап.

— Без бит филологлар, ә син — фольклорист. ГПУга синең дә, минем дә нигә керәге бар икән? — диде Гали.

Галимҗан аның сүзен бүлде:

— Рәхим, син бит җүләр түгел. Эш синдә дә, миндә дә түгел.

— Ә кемдә соң?

— Кемдәме? — диде ул, бүреген баса төшеп. — Хакимияттә. Хакимият үзе өчен курка. Шуңа күрә ул карап тормый — язучымы, рәссаммы, сәясәтчеме, тарихчымы, фольклористмы. Син хакимияткә зарарлы кеше дип табылсаң, сиңа «Өч хәреф» килә инде. Менә шул, ә син әйтәсең...

[illegible], — диде Гали, Галимҗанның җиңеннән тартып. — Киттек, соңга калабыз...

Ул үзе дә Кандыбинны кайдадыр күргән иде. Бәлки, обкомдадыр, әмма тиз генә хәтеренә төшерә алмады. Шуңа күрә сүз дә куертмады. «Шәрәфиләр барын да беләләр, чамалыйлар» дигән уй уады аның башыннан, әмма ул бер сүз дә дәшмәде. Икесенең дә күңелләре борчулы иде. Казанда кулга алулар дәвам итә. Көн саен диярлек кешеләр югалалар.

Казан педагогия институтына әле күптән түгел генә (1931) «контрреволюционерлар оясы» дигән кара ярлык тагылды, гаепләмә әвәләп, тарихчыларны, филологларны кулга алдылар: Н.К.Будде, Е.И.Чернышев, С.П.Шестаков, В.А.Анучин, В.Ф.Смолин һ.б. Педагогия институтының директорлары Кудояровка, Йосыповка, Касыймовка, Быковка «халык дошманы» дигән ярлык тактылар. КДПИның 1936—1937 елгы отчетында мондый юллар бар иде: *«Истекший учебный год прошел в атмосфере весьма напряженного состояния. Перед институтом стояла трудная и ответственная задача перестройки всей его работы в соответствии с историческим постановлением Совнаркома СССР и ЦИВИПИ «О работе высших учебных заведений и о руководстве высшей школы» от 23 июня 1936 г.*

Потеря и притупление бдительности и затем критики и самокритики в организации, в коллективе института, возглавление института с 1930 г. по 1 января 1937 г. ныне разоблаченными врагами народа (бывшие директора — Кудояров, Юсупов, Биктагиров, Касымов, Быков) создали обстановку, благоприятствавшую в течение ряда лет вредительской подрывной работе... И даже в 1935—1937 гг. были разоблачены Юсупов, Касымов, Биктагиров, Быков, Эльвов, Грачев, Фаридова, Сайфи, Демашев, Нигмат Хаким, Атнагулов, Тагиров, Сафин, Вахитов, Столбова, Яфаев, Еналеев, были исключены более 20 студентов» (НАРТ, ф. 1487, оп. 1, ед. 4623, л.1).

1937 елга кадәр әле биш ел, биш ел гомер барын онытмыйк.

— Тарихчыларның эшләре мөшкел, — диде акрын гына Гали, Галимҗанга сораулы караш ташлап.

Таеп егылудан куркып, Галимҗанны терсәгеннән кысып тотты.

— Ә син хәтерлисеңме, Гали, — диде Галимҗан, җитди йөз белән аңа карап. — Мин әле 1921 елда ук Яңа икътисади сәясәт (НЭП) кертелгәч тә сезгә әйткән идем бит, хәтерлисеңме? — диде ул, көлемсерәп.

— Ә, ничек әле, юк, хәтердә калмаган, акчам юк, склерозым бар. Икътисади сәясәт капитализмга юл тотса да, ул әле Октябрь инкыйлабының нәтиҗәләре бөтенләй бетү турында сөйләми. Ул бетмәячәк. Тартып алынган йортлар, фабрикалар хуҗаларына кайтарылмаячак. Кәримовларның, Крестовниковларның, Стахеевларның фабрикалары кайтарып бирелмәячәк. Фуад Туктаров губернатор булса да, безне кулга алачаклар... Әйе, искә төште. Ун ел

узган бит инде. Хәзер 1932 ел. Каян шәйләдең син моны, ә, Буа мишәре? — дип шаяртты Гали Рәхим. — Карале, Җамал Вәлиди әйтмешли, серле елмаясың син. Күләсең инде миннән.

— Кызганычка каршы, — дип дәвам итте Галимҗан, — ә менә социализм юлында да барыбызны төрмә яисә лагерьлар көтә инде, чөнки без бит демократлар, ә диктатура өчен без зарарлы кешеләр, җитмәсә, татар демократлары.

Алар Болак буена җитәләр иде инде. Гали Рәхим, артына күз кырые белән генә карап, анда «койрык»ны шәйләп алды.

Ике доцент сүзсез генә Шәрык педагогия институты ягына борылдылар. Салкын әче җил биткә, яңакка ябышты.

Кандыбинның кабинеты иркен, җылы һәм чиста иде. Бүлмәнең уртасында диярлек зур өстәл, урындыклар, ә өстәл өстендә папкалар өелеп куелган. Аларның һәрберсендә кешеләр язмышы, татар халкының канлы тарихы...

Ул өстәл артына утырырга ашыкмады. Ашыкмыйча гына чишенеп, тунын, бүреген, җылы шарфын, перчаткаларын гадәттәгечә шкафка урнаштыргач, шифоньердагы көзге каршына басып галстугын төзәтте, чәчен тарады. Галифе кесәсеннән «Беломор» папиросы алып, тәмәкесен көйрәтеп, өстәл өстендәге папкаларга күз салды. Барысы да ул калдырган килеш урынында ята иде. Өстәл кырыена якынлашып, зур папканы аерып алды. Папканың өске өлешендә, уң якта — *«Совершенно секретно»*, ә урта өлешендә — *«Обвинительное заключение о контрреволюционной деятельности одной из групп кадров филиала Султан-галеевской организации в Татарии, объединившего буржуазно-националистические элементы в г. Казани. Справка составлена по материалам обвинения следственного дела СПО ОГПУ Татарской АССР 1931 г. за № 161»* дип язылган. Бу папканың соңгы 160 нчы битен ачып, ул анда коллегиягә җибәрүне сорап кул куйгач, Янунинның, Зюгановның, Неверовның имзаларын күрде[1].

— Поработали, начальнички, — диде ул, шактый көр тавыш белән. — Молодцы...

Документларны тагын бер кат карап чыккач, ул да папканың өске сул ягына «Уполномоченный председатель ОГПУ Татарской АССР г. Казани» дип язылган урынга «Кандыбин» имзасын куйды. Татар зыялыларына карата «Гаепнамә» шулай итеп закон төсен алды. Әмма формаль яктан булса да, әле бу материалларны Татарстан өлкә комитеты сәркатибенә дә күрсәтү кирәк иде. Бу турыда ул борчылмый иде, чөнки Разумов та, Лепа да бервакытта да ГПУның карарларына каршы сүз әйтә алмадылар. Киресенчә, репрессияләр дәвам итсен өчен барысын да эшләделәр.

Уполномоченныйның бүген эше шактый күп иде. Идарәдә киңәшмә, ә кичен партия җыелышы, һәр ай ахырында гадәткә кергән бу җыелышларны, башка коммунистлар кебек үк, Кан-

дыбин да яратмый иде. Бу уйларыннан аны телефон шылтыравы бүлде.

— Да, да, — диде ул, ашыкмыйча гына.

Җавап ишетелмәгәч, ул, трубканы урынына куеп, телефон аппаратын селкеткәләп алды. Салкында телефоннар да саташа, ахрысы, дип уйлап куйды Кандыбин. Әмма телефон янә озынрак итеп шылтырады бу юлы.

— Әйе, әйе, так, — дип куйды ул, хатын-кыз тавышын ишетеп. «Обком партиясеннән» дигән өлешен яхшы ук ишетте.

— Яхшы, яхшы ишетәм, нәрсә анда?

— Хәзер үк килеп җитегез, — диде хатын-кыз. — Сезне «үзе»нең күрәсе килә.

«Үзе» дигәне обкомның беренче секретаре Разумов иде. Ул Татарстанда үзен бары тик тискәре яктан күрсәтә алган обком сәркатибе Хатаевич урынына килгән кеше. Разумов та башкалардан әллә ни аерылып тормады. Ул да Татарстандагы террорны хуплады һәм соңрак үзе дә репрессиянең корбаны булды. *«Кешегә кое казысаң, үзең егылырсың»* дигән әйтемне аның үзенә дә татырга туры килде. М.Разумов[2], А.Лепа[3], Г.Мөхәммәтҗанов[4] кебек җитәкчеләрнең булышлыгы белән провокатор Кандыбиннар 1938 елның ахырында Татарстан партия оешмасының 11 %ын партиядән кудылар, ә 1,5 мең әгъзаны, «халык дошманы» дигән кара мөһер сугып, репрессияләргә дучар иттеләр (Литвин А. Запрет на жизнь. — Казань, 1993. — С.21).

«Бусы әле баласы, мичтә аның анасы» булуын аңладымы икән Разумов ул вакытта.

— Аңладым, ясно хәзер, — диде дә Кандыбин трубкасын телефон аппаратына ташлады.

Яңадан тиз генә киенде дә ишегалдына чыкты. Машина, гадәттәгечә, үз урынында иде. Ул баскычтан аска атлауга, машина йөртүче егет, оста итеп машинасын аның янына ук китереп, ишеген дә ачып җибәрде.

Кандыбин машинага кереп лап итеп утырды да, башын артка салып, өске төймәсен чишеп җибәрде.

— Уф! Ничек итеп киенергә дә белмисең: то салкын, то кызу, — дип уфылдавын дәвам итте.

Шефның кәефе әйбәт дип уйлады шофер егет. Ул хуҗасын яхшы белә: эшләре уңса, аның шулай уфылдый торган гадәте бар. «Ярый, көн начар башланмады кебек, кичен ничек булыр, ә ОК секретарена керсә, ярты көн салкын кабинада йокларгамы?» Шундый фикерләр белән ул каты итеп газга басты. Машина азрак каушап алган кебек булды да алга ыргылды. Урамда тагын кеше юк диярлек иде. Шофер егет рульне обком ягына борды.

«Татар контрреволюциясе» менә шулай канат җәйгән. Кара әле син аларны: революциягә кадәр патша хакимияте белән көрәшеп, аннан соң Вакытлы хөкүмәт белән, ә 1918—1920 елларда Совет хакимияте белән көрәштә чыныгып, татар зыялылары үзләренә

солтангалиевчеләрнең филиалын төзеп тә куйганнар бит, каһәр төшкерләре. Шулай булмый ни! Мирсәет Солтангалиевне «фаш иткәннән» соң ун ел узып киткән бит. Йокламаганнар бу бәндәләр. Хәзер инде алар Совет хакимияте белән дә тартышырга җиң сызганып керешкәннәр. Керешмәгәннәр дип кем әйтә ала? Әйдә, әйтегез, иптәш зыялылар! Онытмагыз: *«Кемдә көч, шунда дөреслек!»*

Култык астындагы саллы папканы тагы да катырак кыса төшеп, шулай уйлады Кандыбин.

Разумов кабинетына кергәч тә, бу фикерләрен дәвам итеп:

— Менә, иптәш секретарь, бу — татар зыялыларының милләтче, «халык дошманнары» икәнлекләрен исбат итүче чыганаклар, — диде ул, папканы Разумовның өстәленә ташлап. — Монда 18 кеше күрсәтелгән — барысы да татарлар[5].

Разумов, күзлеген рәтләп, шул биткә күз салды. Бу бишенче биттә иде. Анда «Личный состав КАЭР (к.р.) группы и социально-политическая характеристика членов ее», шунда ук *«По настоящему делу из деятелей «Организующего центра» к.р. буржуазно-националистического движения привлекаются в качестве обвиняемых... 18 человек, представляющих из себя более активную группу по своей контрреволюционной деятельности»* дип язылган иде. Исемлектә беренче булып Бикколов Ибраһим Җамалетдинович күрсәтелгән.

— Яхшы, иптәш Кандыбин, — диде секретарь, исемлекне алырга курыккан кеше кебек. — Ярый, — диде ул, тыныч кына.

Кандыбин дәшмәде. Куллары белән башта борын тирәсен, ә аннан колагын капшап куйды. Гомумән алганда, ул үзенең хезмәттәшләре эшләгән эш белән бик тә канәгать иде. Монда бит йөзләп фамилия узачак — барча татар зыялылары: Бикколов Ибраһимнан соң Җамал Вәлиди, Гали Рәхим, Мостакаев Каюм, Вәлидов Садри (Садри Җәләл), Әхмәров Шиһаб, Зәбиров Хәбибрахман, Аитов Ибраһим, Хәсәнов Әхмәт, Вахитов Лотфулла, Фәхретдинов Котдус, Сөләйманов Бакый, Ихсанов Гали, Әхмәдуллин Абдулла, Хөснетдинов Габбас, Латыйпов Йосыф, Шәех Али Әскәр, Вафин Сәлахетдин. Кандыбин да, обком секретаре Хатаевич та исемлектә күрсәтелгәннәрнең шактые белән яхшы таныш лар иде, әмма ни эшлисең?..

— Бездә генә түгел, бөтен ил буенча дошман безгә пычак кайрый, иптәш Кандыбин, — диде секретарь, папканы тагы да үзенә тартып. — Рәсәйгә кара син: «Союз марксистов-ленинцев», «Мәскәү к.р. оешмасы», «Рабочая оппозиция» төркеме, «Ленинград к.р. зиновьевчыл Сафронов төркеме», «Московский центр» һәм башка шундый группалар бар.

Ничек инде Татарстанда гына мондый группалар булмасын ди. Булмаса булдырабыз аны дигән кебек, Кандыбин, кулын кулга кушырып, секретарь янына сыенды.

Икесенең дә уйлары бер иде — фаш итәргә к.р. милләтче солтангалиевчеләрне, «халык дошманнары»н фаш итәргә...

Эшнең асылы нәрсәдә соң? Гаепнамәдән күренгәнчә, югарыда күрсәтелгән зыялылар массалар белән эшләү рәвешләрен яхшы белеп эш иткәннәр. Язучылар, журналистлар, муллалар, укытучылар буларак аларның тарихи процессның кайда баруын шәйләп алулары ачык күренә.

Яңа икътисади сәясәт чорында алар шактый гына изге эшләр эшләп хәл алганнан соң, дәүләттәге башбаштаклыкларны шәйләп алган зыялылар кебек, аларның уй-фикерләре Кандыбин-Разумов калыпларына сыймыйча ташып торалар. Алар бердәм рәвештә диярлек гарәп алфавитын саклап калу өчен көрәш җәелдерәләр, бердәм рәвештә «латинлаштыру»га каршы чыгалар. Әле 1926 елда ук «Яңа китап» нәшриятын төзеп, татар классикларының әсәрләрен нәшер итүне җайга салмакчы булалар. Бигрәк тә Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Дәрдемәнд әсәрләрен, Коръәнне, Әфтиякне нәшер итү теләге белән йөриләр.

Әлбәттә, болар барысы да махсус ачык җыелышларда эшләнмиләр. Мөмкинлекләр дә булмый. Ачык рәсми җыелышларда бары тик сәяси мәсьәләләр, коммунистларча гына эшләр карала.

Шуңа күрә очрашулар, сөйләшүләр урамда, эштә яисә чакырылган «мәҗлесләр»дә генә мөзакәрә ителә. Бу — татар зыялылары өчен табигый хәл. Совет хакимияте аларны башка мөмкинлекләрдән мәхрүм итте.

Югарыдагы әйтеп үтелгән унсигез милләтче, «халык дошманнары» Татарстан Республикасындагы солтангалиевчеләрдән Мохтаров, Бөдәйли, Борындыков һәм Енбаевлар белән дә тыгыз элемтәдә торганнар, имеш. Менә үзегез Кандыбин гаепнамәсенә күз ташлагыз: *«...выполняя... директиву Султан-Галеева... Хафизов Сафа начинает развертывать работу среди контрреволюционной буржуазно-националистической татарской интеллигенции, в лице Валидова Замалетдина, Бикколова Ибрагима, Мустакаева Касыма, Валидова Садри, Абдрахимова Галея, Шарафа Галимзяна, Галеева Мухамета, Халитова Касима и др.».*

Гаепнамәдән күренгәнчә, сораулар алу дәверендә бу эш аша күп татар зыялыларының исем-фамилияләре атала һәм алар соңрак (1933—1939) җавапка тартылалар. Шулардан Галимҗан Шәрәфне, Мәхмүт Галәүне, Вәлидхан Таначевны һ.б. бик күп зыялыларны санап китеп булыр иде. Җавапка тартылган зыялылар белән урамда очраклы рәвештә очрашып сөйләшү дә кулга алыну, репрессияләү белән тәмамлана. Урамда хәтта бер-береңә сәлам ирештерү дә шпионлык итү кебек бәяләнә.

Менә шулай «материал җыелып», гаепләре фаш ителә һәм аларның Солтангалиев белән бәйләнештә торулары да ачыклана. *«Обвиняемые по настоящему делу в лице Бикколова, Валидова Садри, Забирова Хабибрахмана, Валидова Замалетдина, Ахмерова Шигаба, Мустакаева Каюма, Шейх-Али Асгара, Абдрахимова Галея, постоянно находились как в организационной связи,*

так и в полном идейном родстве с главными деятелями султан-галеевщины, с самим Султан-Галеевым и основным ядром его к.р. организации, активными деятелями по Татарии — Будайли, Бурундуковым, Мухтаровым, Хафизовым, Урманчеевым и другими»[6].

Ни рәвешле бу «к.р. милләтчелек хәрәкәте» үзенең көчләрен оештырган һәм ныгыткан икән соң? Гаепнамәдән күренгәнчә, бу хәрәкәт гражданнар сугышы тәмамлангач, бигрәк тә Татарстан Республикасы төзелгәннән соң, хакимияткә «уңнар» килгәннән соң активлаша, имеш. Гаепнамәдә бу турыда түбәндәге юллар бар:

«Возникновение группы, вернее возобновление, по примеру прошлого, каэр деятельности ее главных руководителей, относится к периоду занятия руководящего положения представителями так называемой правой группы партийной организации Татарии в лице Валидова, Мухтарова, Будайли, Бурундукова и Енбаева, впоследствии, за исключением умершего в 1925 году Енбаева, — перекочевавшими в лагерь контрреволюции и как одни из главных деятелей образованной Султан-Галеевым контрреволюционной организации (осужденные вместе с последним Коллегией ОГПУ на разные сроки наказания), т.е. примерно к 1922—1923 годам, когда часть татарской интеллигенции, до того времени остававшаяся в плену своих контрреволюционных буржуазно-националистических идей и поэтому не шедшая работать в Советские учреждения Татарстана, стала устраиваться в социально-культурные и преимущественно в литературно-педагогические учреждения по своей специальности, инстинктивно поняв создавшиеся для них благоприятные условия к их дальнейшей каэр[7] *деятельности.*

Каэр группа, находясь в идейно-организационной связи с султан-галеевщиной, в соответствии своим контрреволюционным буржуазно-националистическим воззрениям и в целях осуществления поставленных ими перед собой политических задач, програмно-политических устремлений Султан-галеевской организации по существу, на всем протяжении времени, вплоть до последних лет, до момента ликвидации, планомерно проводила свою каэр деятельность и практически в этом отношении проделала следующее:

1. В первое время, перейдя к тактике захвата своим влиянием социально-культурных и иных учреждений, главные деятели этой каэр группы затем перешли к методу стягивания в Татарию антисоветских сил, части той буржуазно-националистической интеллигенции, которая до образования ТАССР активно боролась против Советской власти на стороне белых банд и в разных каэр организациях.

Наряду с выполнением этой задачи, деятельность их одновременно была направлена по сплочению этих каэр сил и на

выращивание кадров буржуазно-националистического движения, в том числе и султан-галеевщины.

2. В этом отношении ими была использована частно-предпринимательская кредитная организация «Казанское Общество Взаимного Кредита» и в тех же целях ими было создано в марте месяце 1926 года кооперативное издательство «Янга Китаб». Ими преследовалась цель создания такого «организующего центра», в котором можно было бы, да еще в легальной форме, в лучшей степени консолидировать свои антисоветские силы и через который пропускать в свет, в целях популяризации и пропаганды програмно-политических установок своего буржуазно-националистического мировозрения, соответствующего характера издания печати.

Фактически же созданием кооперативного издательства «Янга Китаб» ими была организационно закреплена предварительная и вся их последующая контрреволюционная буржуазно-националистическая деятельность, а использованием «Общества Взаимного Кредита» ими была подведена материальная база для этой каэр деятельности.

3. Распространяя среди татарского населения буржуазно-националистические идеи и истолковывая национальную политику компартии и Советской власти как «неорусификаторскую», разжигали тем самым национальный антагонизм, что особенно резко проявилось в выступлениях по вопросу перехода татарской (арабской) письменности на латинский алфавит (яналиф).

В этом отношении «Янга Китаб», как «организующий центр» буржуазно-националистического движения Татарии, в том числе и султан-галеевщины, развил широкую кампанию антилатинского движения и из этого «центра» вышел в свет известный исторический документ протеста «82-х».

4. Захватывая под свое влияние и технические средства — учреждения печати, в частности книжную фабрику Татиздата «Камиль Якуб» и фабрику по производству пишущих машин имени «Агамали-Оглы», использовали эти учреждения в своих каэр целях вообще, в том числе и против яналифа, в частности же — они организовали на фабрике «Камиль Якуб» ряд контрреволюционных и вредительских актов.

5. Распространяя свое буржуазно-националистическое влияние и на крестьянство, каэр группа противодействовала проведению в жизнь хозяйственно-политических кампаний Партии и Советской власти на селе и в частности успешному ходу коллективизации; увязываясь в этой своей деятельности с кулацко-мулльскими авторитетами, содействовала организации массовых выступлений на селе, подготовляла террористические действия над активными советскими работниками...»[8]

Тарихи белешмә

«Уңнар» хакимияте өч ел дәвамында республика белән җитәкчелек итә (1921—1923). Совнарком рәисе итеп Кәшшаф Мохтаров, ТатЦИК рәисе итеп Рәүф Сабиров, мәгариф министры итеп Микъдәт Борындыков сайланалар, Авыл хуҗалыгы комиссариатына Юныс Вәлидов һ.б. керәләр.

«Уңнар» икътисади һәм сәяси проблемалар белән бергә татар теле мәсьәләсен һәм аның бердәнбер дәүләт теленә әверелүен хуп күрәләр. Татар халкының чын тарихын язу мәсьәләсен дә уртага куялар. Шул исәптән татар халкының цивилизация үсеше дәверендәге урынын объектив бәяләү омтылышы да уяна. Нәкъ менә шушы вакытларда Галимҗан Шәрәфнең, Михаил Худяковларның хезмәтләре языла.

Шушы елларда Юныс Вәлидов инициативасы белән Казан янындагы авылларны торгызу мәсьәләсе дә күтәрелә. Бу периодта ТР картасында Чыңгыз (Нагорный пос.), Кызы́л Байрак, Нариман, Яңа Болгар һәм Бакчасарай поселоклары барлыкка килә.

Иң кызыгы шунда: «уңнар» хакимиятен Үзәк тә хуплый, Казанга махсус комиссия килсә дә, бернинди дә гаеп тапмый.

Үзәк Комитетның оештыру бүлеге 1923 елның 13 августында Татарстан Республикасы секретареның һәм Үзәк Комитет вәкиленең докладларын тыңлаганнан соң кабул ителгән карарында *«Татарстан өлкә комитеты урындагы халыкны Совет хакимиятенә тарту, татар телен дәүләт теле итү эшенең гомуми юнәлеше дөрес»* диелә, анда татар нәшриятын үстерүгә әһәмият бирелергә тиешлеге әйтелә[9].

«Уңнар» турындагы беренче доносны Ленинга Кырымнан Сәетгалиев җибәргән. В.И.Ленин бу сәясәтне дәвам гына итә.

Тиздән ачык рәвештә урыннардагы милли җитәкчеләргә киртә куела башлый. Троцкий әйтмешли, «багана» утыртыла, «багана»дан узарга беркемгә дә ярамый. Узсаң, син — «халык дошманы». Мондый җиңүгә И.Сталин 1923 елның 9—12 июнендә яшерен киңәшмә оештыру нәтиҗәсендә ирешә. Аның материаллары 1992 елда гына дөнья күрделәр. (Кара: Тайны национальной политики ЦРКП. — Казань, 1992.) Киңәшмәдә көн тәртибенә беренче урынга «ҮКның Солтангалиев турында доклады» куела. Доклад шундый итеп оештырылган була ки, анда кабул иткән карар нигезендә Солтангалиев партиядән чыгарылып, эш урыныннан куыла, кулга алына һәм 1940 елда атарга хөкем ителә.

Шулай итеп, әлеге киңәшмә «солтангалиевчелек»не СССРда Совет властена каршы оешып, киң таралыш алган сәяси агым дип таба. ГПУ һәм башка хакимият органнары бу сәяси провокацияне зур осталык белән башкарып чыгалар.

Шул нигездә сталинчылар «контрреволюцион оешманың Казандагы солтангалиевчеләр филиалы» дигән уйдырма оешманы

да уйлап чыгаралар. Шул «оешма»да күрсәтелгән яки искә алынган бөтен зыялыларның барысына да «контрреволюционерлар» дигән ярлык тагалар. Гаепнамәдә: *«Все они были квалифицированы как основные кадры буржуазно-националистического движения ради татарской интеллигенции и торгово-промышленной буржуазии, которые вели активную борьбу за недопущение установления власти Советов в национальных областях вообще и в частности в Татарии. Это во-первых. И во-вторых, эти основные кадры буржуазно-националистического движения, в противовес власти Советов, активно, в борьбе с Советами, добивались утверждения буржуазно-демократического правопорядка на территории нынешнего Татарстана, ведя борьбу за создание так называемого «Идель-Уральского штата».*

В этом отношении ими уже был заготовлен проект Средневолжского и Южно-Уральского штата и воззвание, и универсал 1 марта 1918 года, провозглашение которых было сорвано Казанским Советом и большевиками путем ареста И. Алкина, Д. Алкина, Ю.Музафарова и других, а 28 марта силой матросов был ликвидирован мусульманский батальон, избранный II съездом воинов мусульман для реализации проекта «Идель-Уральского штата», — дип язылган.

НКВД сотрудниклары, шулай итеп, «иске костюм»ны «яңа контрреволюцион (алга таба. — *К.Р.*) милләтчеләр»гә үлчәп, үзләре үк уйлап чыгарган «солтангалиевчеләр филиалы»на кидертергә тырышалар. Шул рәвешчә алар тарихи фактлар белән бөтенләй исәпләшеп тә тормыйлар. Ә бит чынлыкта 1918 елның мартында М. Солтангалиев үз кулы белән «Болак арты республикасы»н, II мөселман хәрбиләре съезды тарафыннан төзелгән Мөселман халык комиссариатын һәм башка булачак хакимият органнарын куып тараттыра, кулга алдырта[10]. Шулай итеп, Солтангалиев үзе үк «Идел-Урал штаты»н төзүгә киртә куя. Ул вакытта үзәккә бу эш бик ошый, Солтангалиев тә бу «хезмәте» өчен Совет хакимияте органнарына хезмәткә урнаштырыла. 1932 елда исә, 14 елдан соң, ОГПУ хезмәткәрләре II мөселман гаскәрләрен һәм «солтангалиевчелек»не бергә укмаштырып, «туфракчылар» итеп карыйлар. Гаепнамәдә болай диелә: *«Будучи окончательно разгромленными в открытой борьбе против Советской власти — создание «Идель-Уральского штата» и потерпев окончательный разгром в момент ликвидации «Забулачной Республики», часть руководителей буржуазно-националистического движения, из числа татарской интеллигенции и буржуазии, эмигрировала потом за границу, а оставшаяся же на территории Татарской АССР часть руководителей и активных деятелей этого буржуазно-националистического движения, в том числе и разгромленных, перечисленных выше, контрреволюционных буржуазно-националистических организаций, в частности и в лице обвиняемых по настоящему делу Бикколова Ибрагима, Вали-*

дова Замалетдина, Забирова Хабибрахмана, Валидова Садри, Мустакаева Каюма, Ахмерова Шигаба и других, уже в условиях Советского Татарстана, перешла к нелегальной контрреволюционной деятельности к Советской власти, постепенно начала проникать в социально-культурные и иные учреждения, что с особой четкостью и ясностью подтверждается следующей выдержкой из показания одного из обвиняемого:

«После того, как организовалась Татарская Республика и заняли руководящие посты представители правой группы татарской партийной организации в лице Мухтарова, Сабирова, Валидова, Будайли, Бурундукова и Енбаева — началась борьба правых и левых групп коммунистов татарской организации и в этот момент, та часть татарской интеллигенции, которая оставалась в своем реакционном лагере, которые до этого не шли активно работать в советские организации, стали устраиваться в литературные, педагогические и другие области по своей специальности, инстинктивно поняв создавшиеся для них благоприятные условия к их дальнейшей работе.

Одновременно они сознательно или не сознательно становятся связующим звеном между остальной частью беспартийного населения и правой группой как близко стоящая по своему политическому убеждению к правой группе, чем к левой».

Таким образом, исторически последующая и нижеприводимая контрреволюционная деятельность ликвидированной контрреволюционной группы берет свое начало и заимствована ими из прошлой их активной контрреволюционной деятельности против Советов; оттуда же ими были перенесены формы и средства борьбы с Советской властью, в условиях Советского Татарстана, как, например, «Казанское Общество Взаимного Кредита» и коопиздательства «Янга китап»[11].

Дөреслектә исә болар чын татар зыялылары була. Алар татар халкының киләчәген кайгыртып, Совет хакимиятенең кимчелекләрен күреп, аңлап, Совет хакимияте алып барган сәясәт белән килешмәүләрен ачык рәвештә белдергәннәр. Дөреслектә аларның күбесен, хәтта ачык рәвештә тәнкыйть итүчеләрен дә, Совет хакимиятенең «дошманы» дип әйтеп булмый. Күпчелек очракта алар фәкать Советларны яңадан сайлап,' анда татар вәкилләрен дә кертүне генә күздә тоталар. «Идел-Урал штаты» да федератив Рәсәйнең бер өлеше дип кенә карала. Аерылып чыгу турында бер сүз дә юк. Моның шулай икәнлегенә «Идел-Урал штаты» универсалы[12], II мөселман хәрбиләре съезды төзегән Мөселман халык комиссариатының мөселманнарга мөрәҗәгате кебек рәсми документлар дәлил булып тора. Алар «уңнар» белән солтангалиевчеләрнең бәйләнешләрен М.Солтангалиевнең үз сүзләре белән расларга маташалар. Гаепнамәдән күренгәнчә, алар аның сорау алу вакытында әйтелгән сүзләрен китерәләр. Бу хәл 1929 елның 27 февралендә була: «*...встреча моя с работ-*

никами Казанского кружка произошла вечером в первый день моего приезда в Казань на квартире у студента, быв. партийца Хади Урманчеева (ул. Вознесенская, № 1 или 2). Присутствовали на нем Бакиев, Хади Урманчеев, бывший анархист-журналист Хафизов, студент с/х института Файзуллин... и я»[13].

Имеш, менә шушы очрашудан соң Сафа Хафизов җитәкчелеге астында Солтангалиевнең к.р. директивалары нигезендә контрреволюцион буржуаз-милләтче татар зыялылары арасында актив рәвештә эш җәелдерелә. Бу эшкә Вәлиди Җамал, Бикколов Ибраһим, Мостакаев Каюм, Вәлидов Садри, Абдрахимов Гали, Галимҗан Шәрәф, Галиев Мөхәммәт, Халидов Касыйм һ.б.лар тартыла. Аларны һәм башка татар зыялыларын гаепләү өчен очраклы рәвештә урамда сөйләшеп торулары да җитә. Шуның өчен генә дә алар «солтангалиевче», «халык дошманы», «буржуаз-милләтче» булып китәләр. Шул ук «нигездә» мондый кара исемлеккә Рәүф Алмаев, Сабир Бәширов, Фатыйх Сәйфи, Шиһаб Әхмәровны һ.б.ларны да кертәләр. Әхмәровның 1918 елда, Казанны аклар һәм чехлар алгач, Солтангалиевне, Маметов Ибраһимны һәм тагы ике кызылармиячене үз квартирасында качырып калдыру факты да ОГПУга тәэсир итми. Ул да, кулга алынып, «халык дошманы»на әйләнә. Әмма М. Солтангалиев үзе хәтта Ш. Әхмәровның кайда эшләгәнен дә белми[14].

«Уңнар», хакимияткә килгәч тә, большевикларның үзбилгеләнү программасына таянып эш башкаралар, чөнки башкача эшләү ул бары тик татар халкын алдау гына икәнлекләрен Кәшшаф Мохтаров хакимияте төптән аңлый. Бу фикерне 1924 елның 8 маенда Мәскәүгә «39 лар» тарафыннан җибәрелгән хат та ачык күрсәтә. *«В период военного коммунизма в ТАССР,* — диелә анда, — *на стороне некоторых русских товарищей, не вполне изживших дух господствующей нации — делались попытки выявлять свои привилегии, игнорируя фактически самоопределение национальностей, признавая его лишь формально, что выразилось в обструкции дела привлечения татарских масс в партию, в советское строительство, причем создавшаяся объективная обстановка, требующая чрезвычайного напряжения сил, не давала возможность практически поставить вопрос о широком вовлечении татарских трудовых масс в партийную, советскую и профессиональную работу, в результате чего создание ТАССР сводилось в этот период к простому переименованию учреждений* (кара: Эхо веков. — 1998. — № 3/4. — С.67). К. Мохтаров хакимияте моның белән килешми һәм, үзбилгеләнү программасы белән эш итеп, милли, мәдәни, икътисади һәм сәяси проблемаларны чишү өстендә хезмәт итә. Республиканың күпчелек зыялылары, бу сәясәтне җылы кабул итеп, җиң сызганып эшләүләрен дәвам итәләр. К.Мохтаров һәм аның хакимиятенә бәя биреп, И.Сталин үзенең В.И.Ленинга җибәрелгән яшертен хатында: *«Сформировалась целая группа руководителей, всерь-*

ез воспринимающих партийные лозунги их национальному вопросу и пытавшихся реализовать их на практике», — дип яза. (*Султанбеков Б.* Письмо обреченных // Эхо веков. — 1996. — № 3/4.— С.63.)

«Уңнар» хакимиятенең сәясәте 30 нчы еллар башында инде киресенчә бәяләнә: Совет хакимиятенә каршы гамәл итеп карала. *«С занятием последней (*уңнар. — *Р.В.) руководящего положения в Татарской республике, перешла к оживлению своей прошлой контрреволюционной деятельности на первых порах осуществляя тактику захвата своим антисоветским влиянием социально-культурных органов Татарстана вообще, и литературно-педагогических учреждений, в частности. Затем, в целях объединения разрозненных сил буржуазно-националистического движения под единое организующее руководство, ставят перед собой задачу, по примеру прошлых лет, создание таких учреждений, как например, «Казанское Общество Взаимного Кредита», кооперативное издательство «Янга Китап», из которых первое, объединяя буржуазно-националистические элементы торгово-промышленной буржуазии, использовалась ими в качестве базы, а второе, «Янга Китап», представляло из себя «организующий центр» их руководства к.р. буржуазно-националистической деятельности вообще... формируя, таким образом, свои силы и кадры и в своей к.р. деятельности организационно увязываясь с султангалеевщиной... одновременно использовали и нелегальные подпольные формы борьбы с Советской властью.*

Одной и основной формой нелегально-подпольной к.р. деятельности их являлись так называемые «меджелисы»[15].

ОГПУ тикшерүчеләренең фикере буенча, 32 мәҗлестә 100 дән артык кеше булган һәм алар бу эшкә тартылганнар.

· *Тарихи белешмә*

Бикколов Ибраһим Җамалетдин улы 1885 елда туган. Ул Идел-Урал буенда гына түгел, хәтта Урта Азиядә дә танылган әдәбиятчы, укытучы, нәшриятчы була. Милли хәрәкәттә революциягә кадәр үк актив катнашкан зыялы. 1923 елда Ульяновскидан Казанга күчеп килә, ә алты елдан соң (1929) Сәмәркандка китәргә мәҗбүр була, чөнки Казанда, гомумән Татарстанда, кулга алулар киң җәелә. Сәмәркандта ул беренче номерлы тире фабрикасында тәрҗемәче булып хезмәт итә. 1929 елда Бикколов «82 ләр хаты»на үз имзасын куя. Нәтиҗәдә, «яңалиф»кә каршы көрәшче буларак, укыту эшеннән куыла. Менә шушы вакыйгалардан соң инде Бикколов Урта Азиягә юл тота. Аны революциядән соң да буржуаз-милләтчелек хәрәкәтендә гаепли-

лар. Бу гаепнамәне раслау өчен Ульяновск өлкәсе мөселманнар җәмгыятенең Бикколовка юлланган рәхмәт хаты да файдаланыла. Менә ул хат:

«Дорогой господин Ибрагим! С появлением в России Солнца-свободы Вы, разбив основы рабства, приложили все силы для создания национальных организаций и объединения всех разрозненных тюрко-татар и возглавили твердое руководство по их объединению в г. Симбирске.

Мы выражаем свою уверенность, что и в дальнейшем вы положите все свои силы на осуществление политического и культурного идеала всей Российской тюрко-татарской нации.

Выражая вам глубокую благодарность от имени Симбирских мусульман и мусульманок, преподносим вам настоящий адрес.

Симбирское мусульманское общество.
18 февраля 1918 года».

Гаепнамәдә, И. Бикколов «оештыру үзәге»нең җитәкчесе булган, диелә. Имеш, ул «мәҗлесләр»дә милли сәясәтнең дөрес түгеллеген исбат иткән һәм «солтангалиевче контрреволюцион оешма» белән бәйләнеш тоткан. Шуның өчен ул Мәскәүдә 1927 елда ук Солтангалиев белән Агиев Фәхрелислам фатирында күрешкән һәм 1928 елда шул ук Агиев белән ике мәртәбә Казан оешмасы әгъзалары белән бергә Кызыл Байрак поселогында очрашкан.

«Яңа китап» нәшрияты аркылы ул Хәсәнов Әхмәтгәрәй белән бергә, «Русча-татарча сүзлек»не файдаланып, буржуаз-милләтчелек идеяләрен пропагандалаган, кайбер сәяси әсәрләрнең эчтәлеген махсус үзгәрткән.

1929 елда ук Әхмәров Шиһаб белән Буа кантонына барган һәм анда к.р. кулак авторитетлары белән «идән асты» җыелышларында катнашып, аларга Совет хакимиятенә каршы булган директивалар биргән. Мондый «эшчәнлек» өчен ул РСФСР ҮКның 58—10, 58—11 статьялары буенча җавапка тартыла.

Сорау алу вакытындагы күрсәтмәләрендә ул бернинди дә к.р. эш алып бармаганлыгын, ә бары тик милләтне агарту өлкәсендә хезмәт итүен ассызыклый: *«1924—1925 елларда Солтан Габәши, Заһид Нуркин, Кәрим Тинчурин, Сәгыйд Кәрим, Шиһаб Әхмәров, Ибраһим Аитовлар белән бергә Фатих Әмирханнарда җыелышып карта уйный идек. Бу җыелулар Ф.Әмирханның авырып яткан чагында иде, һәм нәкъ менә шул очрашулар вакытында (партиялеләр һәм партиясезләр) без, татар зыялылары, бер нәшрият төзеп, фәнни-популяр һәм беллетристик әдәбиятны чыгару өчен нәшрият төзү кирәклеге турындагы уртак бер фикергә килдек. Мин үзем дә бу фикерне хуп күрдем һәм нәшриятның төзелүен теләдем»*. Моның сәбәпләре дә булганлыгын әйтеп уза: *«Беренчедән,* — ди ул, — *Татиздат кирәк әдәбиятны нәшер итеп өлгерә алмады. Бу турыда мин мөмкин-*

лек булганда Нуркинга һәм Измайловка һ.б.ларга әйттем. Бу эшкә Ибнеәмин Әхмәтов, Аитовлар[16] *да катнаштылар. Соңрак Шиһаб Әхмәров һ.б. үз өлешләрен керттелә*р». Нәтиҗәдә 1923 елда «Общество Взаимного Кредита», ә 1926 елда «Яңа китап» кооперативы төзелә.

Яңа икътисади сәясәт тормышка ашырылган чорда бу бик табигый хәл. Ул чорда яңадан-яңа оешмалар, трестлар, нәшриятлар барлыкка киләләр. Муллагали Якушев, Ибраһим Ильясов, Әхмәтҗан Даутов, Мулланур Усмановларның сүзләренә караганда, СССРдан килгән берәүнең: *«СССРда да начар яшәмиләр»*, — дип әйтүенә ышанып, туган илләренә кайту фикеренә киләләр. Илгә башка чит җирләрдән дә кайта башлыйлар. Бу тарихи процессны Совет дәүләтенең Яңа икътисади сәясәте (НЭП) нәтиҗәсе дип карау дөрес булыр. Әмма бу сәясәт алдавыч агитация-пропагандага корылмагандыр дип кем әйтә ала. Шулай булгач, Харбинга барып, кемнәр: *«СССРда да яшәп була»*, — дип йөргәннәр икән соң?

1922 елда бу процесслар дәүләт тарафыннан хуплансалар, 1932 елда алар инде, киресенчә, тискәре бәя алалар.

Белгәнебезчә, 1921 елдан башлап бөтен ил буенча төрле-төрле оешмалар, җәмгыятьләр, компанияләр оештырылып эшкә керешәләр, һәм тиз арада җимерелеп бара торган ил үсеш юлына баса. Бу Яңа икътисади сәясәтнең халыкларга киң мөмкинлекләр бирүе белән дә бәйле. «Яңа китап» нәшрияты да нәкъ менә шундый сәясәтнең нәтиҗәсе. Ул — татар зыялыларының аруталуны белмәс хезмәтләре нәтиҗәсе. Ул күп сөйләшүләр, киңәшмәләр нәтиҗәсендә туа. С. Вәлидов сүзләренә караганда, беренче очрашып сөйләшүләр Ш. Әхмәров фатирында була. Шунда ук рәсми рәвештә оештыру мәҗлесе уздырыла. Шулай итеп, «Яңа китап» нәшрияты кооперациясе төзелә. 1930—1931 елларда сорау алу вакытында язучы М. Галәү: *«Яңа китап» Казанда НЭПның чәчәк аткан чорында татар зыялылары тарафыннан төзелде. Нәшриятны оештыру эшләрен башлап йөрүчеләр Ибраһим Бикколов белән Ибнеәмин Әхмәтовлар иде»*, — ди. Бу эштә Бөдәйли, Борындыков һәм башкаларның катнашуын да әйтеп уза. «Яңа китап»ны оештырып йөргәндә, И. Бикколов һәм Ш. Әхмәровлар нәшрият төзелүенең татар зыялылары өчен кирәклеген әйтәләр: *«Фатих Әмирхан әсәрләрен Совет нәшрияты оешмаларында бастырмаячаклар. Әгәр дә без үз нәшриятыбызны булдырсак, аның сайланма әсәрләрен дә чыгара алачакбыз»*.

Әлбәттә, нәшрият эшчәнлеге моның белән генә чикләнми. Ул башка язучыларның да әсәрләрен бастырып чыгарырга җыена һәм чыгара да.

Ш. Әхмәровның күрсәтүләренә караганда, «Яңа китап» түбәндәге әсәрләрне чыгарган: «Исән дә түгел, үлмәгән дә» (рус теленнән тәрҗемә, фәнни-фантастик хикәя), «Мостафа Кәмал па-

шаның биографиясе» (рус теленнән Харис Фәйзи тәрҗемәсе), «Балдызкай» (Г.Кутуй комедиясе), «Чегәннәр» (М.Горький әсәреннән тәрҗемә), «Шигырьләр җыентыгы» (Октябрь революциясенең 10 еллыгына багышланган), «Русча-татарча сүзлек» (Гәрәй Хәсәнов, Абдулла Сөләйманов, Ибраһим Бикколовлар төзегән), «Театральный альбом» (артистларның фоторәсемнәре белән К.Тинчурин), «Макар Чудра» (М.Горький әсәреннән тәрҗемә), «Рахит» (доктор Басырова), «Татар халык җырлары» җыентыгы.

Ул тагын 5—6 китапның атамаларын хәтерләми (ЦГАИПД РТ. — Ф. 8239. — Арх. 2-10024. — Т.2. — С. 169).

Редакция коллегиясе составына Гомәр Галиев, Зыя Насыйров, Садри Җәләл, Ибраһим Бикколовлар керәләр. «Яңа китап»-та китап басу эшендә Исмәгыйль Рәмиев, нәшер итүдә Мохтаровлар да булышканнар. Соңгысы үзенең «Татарстан» исемле типографиясен файдалана.

«Мәҗлесләр»гә килгәндә шуны әйтергә кирәк: татар халкында, һич югында, елга бер мәртәбә кунак җыю изге эш дип саналган һәм санала да. Хәтта мәкаль дә бар: *«Кунак ашы — кара-каршы»*. Кунак була беләсең икән, үзең дә кунак кабул итә бел. Бу — мөселман халыкларында киң таралган традиция. Кунакта ашап-эчү генә түгел, ә иң мөһиме — бер-береңне хөрмәт итү, аңлашу. Партиялеләрнең партия җыелышлары булса, ә партиягә кермәгәннәрнең җыелу урыннары — кунакта, урамда, чәйханәләрдә. Гомумән, очрашып сөйләшү өчен бар да ярый. Монда бернинди дә к.р. дигән нәрсә юк. Аны эшләгәннәр җыелып та тормаганнар. Кирәк икән — үтергәннәр, кирәк икән — ут төрткәннәр h.б.

Шуңа да карамастан ОГПУ тикшерүчеләре бу «мәҗлесләр»-не «контрреволюцион җыелышлар», милләтчеләрнең «оештыру үзәкләре» итеп бәяләгәннәр. Гаепнамәдә бу турыдан-туры: *«Установлено, что, во-первых, руководители к.р. буржуазно-националистического движения в РТ, в том числе привлеченные в качестве обвиняемых по настоящему делу члены ликвидированной группы, в лице «Янга китап», создав организующий центр руководства буржуазно-националистическим движением, свою к.р. деятельность проводили при помощи татарской торгово-промышленной буржуазии, превратив в основной источник финансирования своей к.р. работы, организованное еще в 1923 году татарского буржуазного «Общества Взаимного Кредита»*, — диелә. Түбәндәрәк бу турыда тагын болай әйтелә: *«Во-вторых, идея об организации как «Казанского Общества Взаимного Кредита», так и издательства «Янга китап» создавалась на тех же «меджлисах»... В-третьих, идейно-организованная и финансовая связанность двух к.р. организаций... обусловливалась со стороны их руководителей необходимостью консолидации активных разрозненных к.р. буржуазно-националисти-*

ческих сил татарской интеллигенции и торгово-промышленной буржуазии, т.е. создания единого фронта для борьбы с Советской властью».

«Общество Взаимного Кредита» тарафыннан Кызыл Байрак поселогына һәм ТРның мәктәпләренә матди ярдәм итү Совет хакимиятенә каршы көрәш дип бәяләнә. Янәсе, алар татар авылларын түгел, ә буржуаз татар авылларын үстергәннәр. Шулай булгач, мондый авыл мәктәпләре дә шул рәткә баса инде.

Ә бит чынлыкта бу ярдәм халык һәм урыннардагы Совет органнары соравы белән эшләнә. Нәкъ менә шушы елларда ук Буа өязенең Кишер Аксуында да бертуган Шәрәфләр төзегән «Урман» компаниясе зур татар мәктәбе төзи. Бу мәктәп бүгенге көндә дә эшләп килә. 1996 елның 2 октябрендә Галимҗан Шәрәфнең 100 еллык юбилеена багышланган фәнни конференция Буада башланып, Аксу урта мәктәбендә дәвам итеп, 3–4 октябрьләрдә Казанда тәмамланды. Шушы көннәрдә Галимжан Шәрәф истәлегенә Жуковский урамындагы йортка мемориаль такта да куелды. Кишер Аксуы урта мәктәбенә Галимҗан Шәрәф исеме бирелде. 1997 елда бу конференциянең материаллары дөнья күрде. Ул «Интеллигенция Татарстана в период реформ и революции первой трети XX века» дип атала. Бу — интеллигенциягә багышланган беренче җыентык. Шулай итеп, 90 нчы еллар башында ук күренекле зыялыларыбыз хакында дөрес сүз әйтү, язу мөмкинлеге туды. Зур ачык мәҗлесләр, конференцияләр уздырыла башлады.

«Уңнар» чоры ачлык елларына туры килә. Ачлыкның төп сәбәбе корылык булу белән бәйләнгән булса да, 1920 елдан башлап хакимияткә килгән «суллар» һәм аларның юлбашчысы Сәетгалиевнең булдыксызлыгы республикадагы хәлне тагы да авырайта төшә. Сәетгалиев азык-төлекне Татарстаннан үзәккә һәм башка регионнарга җибәрү өчен барысын да эшли. 20 нче елның башында ук Татарстаннан 10 млн. поттан артык ашлык, 500 мең поттан аз гына ким ит, 2 млн. пот чамасы бәрәңге, 30 млн. данә йомырка, 25 мең пот май һәм башка азык-төлек читкә озатыла.

Республиканы ризыксыз калдыруның тагын бер юлы табыла: крестьяннарга базарда азык-төлек сату тыела, бары тик кибетләргә тапшыру рөхсәт ителә.

Шулай итеп, Татарстан халкы, Сәетгалиевнең Совет хөкүмәтенә күрсәткән тырышлыгы нәтиҗәсендә, 1921 елгы корылык алдыннан бөтенләй диярлек азык-төлексез калдырыла[17].

Өлкә комитетының VII конференциясендәге чыгышында Расыйм Мансуров, бу чорга бәя биреп: *«Эпоху работы Саид-Галеева надо считать самой бездарной и притом кошмарной в смысле не умения работать вообще в условиях ТССР, в частности, и в особенности, в смысле понимания национального вопроса... в результате этого в этот период создание ТССР сводилось к прос-*

тому переименованию учреждений...»[18]. Бу чорда халык азыктөлексез генә түгел, китапсыз да кала. 1922 елда Татарстан нәшрияты бер татар китабы да чыгармаган[19].

Сәетгалиевнең сүзләренә караганда, аны республикадан 24 сәгать эчендә куып җибәрәләр. Бу хәлнең төп сәбәбен күрсәтеп: *«Эшкә сәләте булмаганлыктан Сәетгалиевне башка берәү белән алмаштырдык, ул астыртын эшләр эшли башлагач, өлкә комитеты Казаннан чыгып китүне катгый рәвештә таләп итте»*, — ди К. Мохтаров.

Нәтиҗәдә 1921 елда республикада коточкыч ачлык башлана. Йөзләрчә мең кеше ачтан үлә. 1922 елның язында Татарстанда 410 меңләп кеше үлә, шуларның 224 меңе ирләр. Иң күбесе Тәтеш кантонында — 66 мең, Спаста — 48 мең, Зөядә — 36 мең, гомумән алганда, Татарстанда 500 меңнән артык кеше һәлак була. Идел буе шәһәрләрендәге кебек, Татарстанда да халык арасында хәтта үз балаларын, гомумән, кеше ашау — ганнибализм фактлары да фаш ителә. Сарман районындагы Өчиле-Саклау авылыннан Мөкәррәмә абыстай Ихсанова бу дәһшәтле еллар турында болай дип сөйләп калдырган: *«...1921 елның апреле июнь ае кебек җылы килде. Май аеннан башлап җәй буена бер тамчы да яңгыр яумады. Тары гына бераз күтәрелде, җирдә бары алабута уңды. Аның орлыгын күп итеп җыеп, тары белән кушып тарттык. Алдагы җәйгә кадәр калган көннәрне санап, бар азыкны нормага салып, бүлеп куйдык та, көнгә ике тапкыр ашау белән чикләндек. Малларны, кош-кортларны суеп, итләрен тозлап куйдык. Мал-туардан атны гына калдырдык һәм киләсе елга дигән чәчүлек орлыкка кагылмаска булдык. Булганны нормага салып яшәгәннәр язга барып чыктылар. «Хөкүмәт үләргә бирмәс, ярдәм итәр әле» дип, болай да аз булган азыкларны ашап бетергән кешеләр ноябрь аенда гүр иясе булды. Кайберәүләр, хөкүмәт ярдәменә ышанып, түйлар ясадылар. Аларның берсе дә исән калмады. Ачтан үлү безнең авылда октябрь аеннан ук башланды. Ирем Мәхүбрахман мулла халыкка 2—3 өйгә 1 ат, 2—3 сарык калдырырга, сыерларны суймаска киңәш итте.*

1921 елның кышы бик салкын килде. Ашарга эзләп чыгучыларның күбесе туңып үлде. Юлда үлеп ятучылар санап бетергесез иде.

Авылдагы этләр, мәчеләр дә ашалып бетте... Хәтта үз балаларын суеп ашаучылар да булды. Үлгәннәрне күмәр өчен кабер казырга кешеләрнең көче җитмәде, бер кабер казысалар, шунда барысын да күмәләр иде. Мәетләрне юу да, кәфенләү дә булмады.

Хатыннар бәбәй тапмады, балалар укытылмады, кыш буе урамга чыкмады. Мәчеткә йөрүчеләрнең саны да нык кимеде. Шулай да хәле булганнар җомга намазына киләләр иде.

Ике йөз хуҗалыктан торган авыл халкының яртысы 1922 елның язына хәтле җир куенына юл алды.

Авылдагы ике зур көтүдән икеме-өчме сыер калды, алар түбәгә ябылган саламны ашап кыш чыкты. Кош-корттан авылда түбән оч Шәрәфетдиннәрнең бер әтәче һәм берничә тавыгы гына калды.

Без гаиләдә биш җан идек. Балалар бик кечкенә, Фаикка — 5, Мөсәллиягә 3 яшь иде. Аларга көз аенда туган Фаиз өстәлде. Ашарга булмагач, күкрәк сөте бетте, аңа, алабута ипиен бал белән изеп, имезлек бирә идек.

Бервакыт салкын ямьсез көннәрнең берсендә, кичкә таба, коры сөяккә калган бер кыз бала кереп ишек янагына сөялде. Бу Мәһрүзә исемле 10 яшьлек чамасындагы беркеме дә калмаган ятимә бала иде. Мин савыт-саба юа идем, ул бала: «Абыстай, ул суыңны түкмә әле, миңа бирсәң, эчәр идем»,— диде. Әтиебез аңа алабуталы он болгатып эчертте. Без ул баланы урамга чыгарып җибәрә алмадык. Шулай итеп, без алты җан булдык. Ул бик тыңлаучан, эшчән бала иде. Аны үстереп кияүгә бирдек. Алар ире белән Ленинградта яшәделәр. Безне онытмыйча, посылкалар салып тордылар. Сугыш вакытында блокадада калып юкка чыктылар. Күрәсең, балачактан сагалап килгән ачлык аларны шунда куып җитеп юк итте. Озак та үтми, Ибраһим исемле тагын бер баланы гаиләбезгә алдык. Аны да үстереп, өйләндереп, кеше иттек.

Америкадан килгән ярдәм безнең авылга март аенда гына килеп җитте. 1922 елның мартында авылга бер олау өшегән бәрәңге китерделәр. Ач халык чаналарга ташланды һәм, капчыкларны ертып, булдыра алган кадәр бәрәңге алды. Бу ач карынга ашалган өшегән бәрәңгедән бик күп кеше якты дөнья белән хушлашты.

Ярдәм бар авылларга да килеп җитмәде»[20].

Шулай булуга да карамастан, Үзәк һәм урындагы кайбер оешмалар, идарәләр сүлпән яисә бөтенләй начар эшлиләр. Казан—Мәскәү тимерьюлчылары бары тик ришвәт биргәнне көтеп торалар. Күп очракта Казанга килә торган азык-төлек яисә башка хуҗалык товарлары төялгән составлар башка җирләргә җибәреләләр яки юлда тоткарлана. Болар — махсус эшләнгән эшләр. Бу эшне бары тик Наркомзем комиссары Юныс Вәлидов кына җайга салырга тырыша. Моның өчен ул махсус фонд төзи һәм шул фондтан тимерьюлчыларга ришвәт биреп, бөтен республиканы беркадәр азык-төлек белән тәэмин итә. Шуның нәтиҗәсендә бик күп халык исән кала.

Алар Солтангалиев белән бер очрашу вакытында фонд төзү һәм башка мәсьәләләр турында да фикер алышалар.

«— Кемгә ришвәт бирдең? — дип сорый аннан Солтангалиев.

— Казаннан Мәскәүгә кадәр бөтен тимер юлны мин ашатып тордым, — ди Юныс Вәлидов. — Бары да мин төзегән фонд хисабына, — ди ул, кыза төшеп. — Атсалар атарлар, үзем җа-

вап бирәчәкмен. Татар интеллигенциясенә, студентларга гына түгел, минә сезнең кебек эштән куылганнарга да ярап куячак. Бу фонд турысында әле беркем дә белми, син кешегә сөйләмә, — ди ул Солтангалиевкә».

Әлбәттә, мондый каһарманлыкны фәкать бик булдыклы, кыю һәм үз халкы өчен үлемгә барырга да әзер торган зыялы гына эшли аладыр. Америка газитләре бу хикмәтле, гайрәтле кешене «Идел буен ачтан коткаручы» дип язып чыгалар. Әмма Юныс Вәлидовны 1924 елны эшеннән азат итеп, партиядән дә куалар, һәм ул озакламый Семашко больницасында вафат була[21].

Идел буендагы 1921—1922 еллардагы ачлык вакытында татар зыялыларына, милләткә хезмәт итүчеләргә татар җәмгыятьләре дә ярдәм кулын суза. Әдәбиятта моңа кадәр билгеле булмаган бер гыйбрәтле вакыйгага күз салсак, без үзебезнең мондый хәлләрдән бихәбәр булуыбызга шаккатырбыз. Сүз мөһаҗирлектә яшәргә мәҗбүр булган Харбин шәһәрендә гомер итүче татарлар турында. Моны аз булса да күзаллау өчен архивта сакланып калган Газизов Абдулла Сакмари тарафыннан 1922 елның 27 мартында Риза Фәхретдиновка язылган хатының бер өлешен китерү дә җитәдер. Дөньяга беренче тапкыр тәкъдим ителгәнлектән, хатны тулы килеш (сакланган кадәрен. — *Р.В.*) бирергә булдык. Татарча тексты сакланмаган, ә бу өлеше тикшерү эшеннән алынды.

«С получением Вашего письма, тотчас, через Центрсоюз начали направляться вам посылки. Такие посылки направлялись с маршрутами продовольственных поездов. Потом, когда стало известно, где в Уфе имеется склад «Ара», то стали высылать через него. Отправленную вам первую посылку через Центрсоюз — это был господин Агишев Гумер (торговец из Пензенской губернии, в Харбине имеет дома). Этот же человек был первый, который послал через «Ара». Он написал своему сыну в Америку, Агишеву Загидулле о том, чтобы тот послал посылку вам и Мухлисе Бубинской. После прочтения Вашего письма, под влиянием этого письма он (Агишев Гумер) написал еще, где велел ему ежемесячно послать Вам, Мухлисе Бубинской, Фатиху Каримову. Затем «Харбинский мусульманский комитет помощи голодающим» решил посылать через «Ара» по одной посылке Вам, Мухлисе Бубинской, Бигееву, К.Бигяшеву и за все это первый отправил в Америку деньги на ваше имя одну посылку через ту же «Ара» человек, происходящий из Троицка по имени Идиатулла Дузеев. По получению вашего письма обратились к человекам двум, которые приняли наше обращение с великим удовольствием. Апанаев Вали, дочь господина Усманова Габдуллы, мадам Гульсум Хабирова по одной посылке через «Ара» и происходящий из Тамбовской губернии д. Янгуразовой торговец из Урчи Амин Абузов должны послать из Читы. Один по имени Мулланур Камаев уплатил деньги для посылки Вам через «Ара»

одной посылки. А также я читал в нескольких листах письма Мухлисы абыстай (Бубинской), полученное на имя господина Нияза. На ее имя должны послать ежемесячно Гумер Агишев и «Комитет помощи голодающим». Кроме этого, должна послать одну посылку дочь господина Усманова Габдуллы, мадам Мархаба Юзикеева, через «Ара». Гайния Яушева дала деньги на две посылки, которые мы отослали в Нью-Йорк — «Ара». Вали Апанаев послал через Читу одну посылку. Читинская посылка состоит из 30 фунтов муки, 7 фунтов крупы и одного плиточного чая. Надеемся, что в скором будущем ваш продовольственный вопрос наладится и свою остроту потеряет и Вам представится возможность в эту историческую эпоху продолжать вашу священную ответственную работу. Здешние братья-мусульмане очень быстро и положительно отозвались на те продовольственные затруднения, в которые попали там деятели науки, общества и просвещения. Приняты меры, чтобы посылать всем тем, которые в прошлом служили народу, нации, адрес коих нам известен.

«Харбинский комитет голодающих» при национальном управлении, кроме перечисленных, 6 мая старается посылать и другим, адреса которых известны.

На днях, с получением Вашего письма, я передал еще нижеследующих: Сангатулла Бикбулатов, Бурган Шараф, Ямалетдин Велиди (Җамал Вәлиди. — *Р.В.*), *Фатих Амирханов, Хади Максудов, Закария Садретдинов, Мухутдин Курбангалеев, Губайдуллин Буби, Абдулла Сулейманов, Ибрагим Терегулов, Джангир Абзгильдин посылаются посылки с 2-х сторон.*

Очень хотели посылать также Троицким хазратам, но ввиду отсутствия там склада «Ара», сделать это невозможно. Через Центрсоюз, кажется, не берут. С 5—6 ранее посланных известий нет.

Господину Ниязу я написал о вашем привете, а также послал копию Вашего письма. И он имеет большой интерес к новостям из России. Он напишет Вам сам. Адрес послал. По нашей мысли, очень хорошо сделали, что послали благодарственное письмо «Ара». Такого рода письмо очень влияет на американцев, копию его я послал в Японию. Может быть, там японские и английские газеты напечатают на русском языке. Собираюсь напечатать в Харбинских газетах. С большой просьбой написал письмо господину Ниязу о том, чтобы он собрал и выслал все Ваши вещи, которые написаны о Национальном управлении, которые было бы возможно опубликовать в Америке»[22].

Хатның башы да, ахыры да сакланмаган. Архив папкасында мөфти Р. Фәхретдиновка килгән я үзе җибәргән хатларның буш конвертлары гына сакланып калган. Бу хат Мөселман Диния нәзарәте үзәге (МДНҮ) хезмәткәрләрен хөкем итү 2300 һәм 2301 нче тикшерү эшләрендә бик ачык күренә. Анда 21 кеше хөкемгә

тартыла. Алар барысы да Япониядә, Маньчжуриядә һәм Кытайда яшәүче контрреволюцион төркем белән бәйләнештә булуда, Совет хакимиятенә каршы җимерү эше алып баруда гаепләнәләр. 2300 нче архив-тикшерү эше буенча Д.Абызгилдин, М.Камалетдинов, Ш.Шәрәф, Х.Әхтәмов, Г.Ханисламов, З.Мөҗавиров, М.Усманов, Г.Хәбиров, А.Мостафиннар үтә. Әмма бу 1938 елның 7—11 гыйнварында гына була әле. Архивта табылган бер чыганакта бу хакта: *«В Уфе существует ЦДУМ, которое возглавляли муфти Фахруддинов и его помощник Таржеманов Кашаф. Между Харбинской мусульманской общиной и ЦДУМ существовала нелегальная связь через специально приезжающих из Харбина...»* Бу тикшерүгә килеп эләккән Риза Фәхретдиновның улы Габдрахманнан да башта 1936 елның 16 июлендә, ә соңрак 8 октябрендә каты сораулар алына. Ул, этисенең сөйләгәннәрен искә төшереп, Газизов Абдулла Сакмариның Мәскәүгә барышлый Уфага килүе, эмиграциядән Россиягә кайткач, беркадәр Владивосток шәһәрендә диңгезчеләр әзерләү мәктәбендә инглиз телен укытканлыгы турында хәбәр итә.

Таякның икенче башы икенче МДНҮндә хезмәт иткән Шәһәр Шәрәфнең башына төшә. 1936 елның 14 декабрендә Башкортстан УГБсы лейтенанты Нуретдинов, сорау алу вакытында бу мәсьәләгә тагын әйләнеп кайтып, Шәһәргә төрле сораулар бирә:

«— Сез мөфти Фәхретдиновның татар ак эмиграциясе белән язышып торуы хакында белә идегезме?

— Әйе, мөфти Фәхретдиновның брошюра итеп җыелган берничә томнан гыйбарәт хатларын караштыргалаган идем. Алар арасында ак эмигрант Зәки Вәлиди, Газизов Абдулла Сакмари хатлары да бар иде.

— Шулай итеп, сез татар ак эмиграциясенең чит илдәге эше һәм соңгы мөфтинең күрсәтмәләре белән таныш идегез?

— Әйе, ак эмиграциянең эше һәм Фәхретдиновның күрсәтмәләре белән таныш идем, әмма аларның эчтәлеген мин хәтерләмим.

— Газизов Абдулла Сакмариның күрсәтмәләрен искә төшерегез!

— Хәтерләмим.

— Әйтегез әле, сез кайчан укыдыгыз Газизов Абдулла хатларын?

— Ак эмигрантлар хатларын, аерым алганда Газизов Абдулла хатларын, мин 1933 елның июль аенда укыдым.

— Сезнең тарафтан төзелгән (программный) документ ак эмигрант Газизов Абдулла Сакмари күрсәтмәсенә таянып эшләнелдеме? Газизов Абдулла Сакмари күрсәтмәләренә таянып, к.р. документ төзүдә гаебегезне таныйсызмы?

— Мин гаебемне таныйм. Минем тарафтан төзелгән к.р. характердагы документ ак эмигрант Газизов Абдулла Сакма-

ри күрсәтмәләренә таянып эшләнелде. Әмма документны мин үземнең ышанычлыгыма, үз фикерләремә таянып кына эшләдем.

— 1934 елны чит илдән кайтып, Газизов Абдулланың мөфти Фәхретдинов янына килгәнен беләсезме?

— Әйе, беләм.

— Мөфти Фәхретдиновның Япониядәге Ибраһимов Габдерәшит белән язышкан язмалары белән сез танышмы?

— Әйе, таныш.

Протокол минем сүзләрдән язылды, мин укып чыктым — дөрес. Бу турына кулымны куям. Шәрәф»[23].

Шулай итеп, заманалар үзгәрү белән бәяләр дә үзгәрә. Ачлык чорындагы ярдәм килүгә ун елдан соң «контрреволюцион атака», «террор», «национализм», «антисоветизм» кебек ярлыклар тагыла. НЭПтан «тырнаклар һәм мөгезләр» генә калган чорда, «немец», «япон», «кытай шымчылары» кебек терминнар да татар зыялыларына сылана. Индустриализация һәм коллективизация чорларында инде бөтенләй диярлек Совет хөкүмәте, партия органнары «Кызыл Байрак» поселогын төзү һәм киңәйтүне Солтангалиев резиденциясен төзү дип бәяләсә, Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы буенча комиссары Ю. Вәлидов бу үзәкнең оештыручысы диелә. Гаепнамәдә *«Следствием установлено, что данному поселку «Кызыл Байрак» «Общество Взаимного Кредита» под видом «шефства» оказывало в громадных размерах материальную помощь, создавая, таким образом, кулацкую базу для борьбы с Советской властью...»* дип әйтелә.

Чынлыкта өч ел эчендә бары тик 6 мең сум җибәрелгән икән. Бу һәр дворга 120 сум туры килә дигән сүз. ГПУ тикшерүчеләре «Кызыл Байрак»ка күрсәтелгән ярдәмне ун елдан соң «татар кулаклары поселогы»н төзү дип бәяли. Агроном, соңрак фәнни хезмәткәр, «Идел-Кама авыл хуҗалыгы станциясе»нең мөдире Ходжаев Калыр ЦКТКП вәкиле итеп, профессор Чаянов СК тарафыннан вербовать ителгән дип бәяләнә.

ГПУшниклар фикеренчә, милләтчелек хәрәкәте Татарстанда дәүләтчелек туганнан соң, чама белән 1925—1926 елларда сәяси-оештыру эшләрен ныгытып, бер к.р. оешма астына җыелалар. Бу оешманың «Яңа китап» икәнлеге көн кебек ачык. *«Одновременно с политической обработкой своих кадров на так называемых «меджелисах», по существу нелегальных, совещаниях, руководство «организующего центра» планомерно развертывало и вело свою к.р. работу и по другим направлениям, в частности, его деятельность особенно выделялась на идеологическом фронте, где оно по линии печати переходило на явные вредительские методы борьбы с Советской властью, а контрреволюционное влияние руководства этого «организующего центра» на крестьянство выражалось вплоть до организаций повстанческих и террористических действий на селе»*[24].

Шулай итеп, гомумән алганда, «Общество Взаимного Кредита» һәм «Яңа китап» нәшрияты ОГПУ тикшерүчеләре тарафыннан бирелгән бәяләмәгә караганда, буржуаз милләтчеләрнең «Оештыру үзәге» дип танылa. Имеш, шушы үзәк аркылы «халык дошманнары» солтангалиевчеләр белән тыгыз элемтәдә торганнар. Шулай итеп, кечкенә генә «эшләр»не, зур «эшләр»гә әйләндереп, йөзләгән, меңләгән зыялыларны хөкем итәләр.

«ОЕШТЫРУ ҮЗӘГЕ» ЛАТИНЧЫЛЫККА КАРШЫ

Билгеле булганча, 1926 елда ук «гарәп графикасы», «латин хәрефләре» турында кызу бәхәсләр башлана, татар орфографиясе һәм фонетикасы тирән итеп өйрәнелә. «Гарәпчеләр» һәм «латинчылар» арасындагы көрәш тюркологларның 1926 елның февраль-март айларында Баку шәһәрендә үткәрелгән I Бөтенсоюз корылтаендагы югары ноктасына җитә. Монда Г.Шәрәф берничә мәртәбә чыгыш ясый. Аның «Татарларда һәм төрки халыкларда гарәп һәм латин хәрефләре системасын файдалану мәсьәләләре» дип аталган докладны бик хуплап кабул итеlә, аның тезислары чит ил матбугатында да басылып чыга. Аерым алганда, ул катгый рәвештә: *«Гарәп хәрефләре уку һәм язу өчен латин әлифбасына караганда күпкә җайлырак... Төрки халыкларның хәзер кулланыла торган гарәп әлифбасыннан латинга күчүләре чынбарлыкта ул халыкларны язма әлифбасы булмаган өммәтләр дәрәҗәсенә төшерәчәк... Бу адым төрки халыкларның мәдәни үсешен бик нык тоткарлаячак»*, — дип белдерә. Гомумән, Г.Шәрәф фикерләре Партия өлкә комитеты биргән күрсәтмәгә каршы килми. *«Латин хәрефләренә күчүгә принципиаль каршы төшмәскә, ә гамәлдә Татарстан өчен яңа әлифбага күчү әлегә мөмкин түгел дип исәпләргә»* дигән күрсәтмә бирелгән була. Әмма корылтайдан соң да «гарәпчеләр» белән «латинчылар» арасындагы көрәш сүрелми. «Суллар» тарафыннан оештырылган «Латин әлифбасы дуслары җәмгыяте» («Яңалиф») гарәп хәрефләреннән латинчага күчү өчен көрәшне көчәйтә бара: «Яңалиф» төркемнәре һәм түгәрәкләре барлыкка килә, матбугат битләрендә шау-шулы кампания алып барыла. Шуның тәэсирендә ВКП(б)ның өлкә комитеты әлифба мәсьәләсендә үзенең элеккеге карашын үзгәртә. 1927 елның 3 маенда Партия өлкә комитетының «Яңалиф» җәмгыяте эше турындагы мәсьәләсен тикшерә һәм махсус карар кабул итә. Анда гарәп хәрефләреннән баш тарту һәм латинчага күчү кирәклеге әйтелә, партиянең район оешмаларына, матбугат органнарына, мәгариф буенча халык комиссариаты тәшкиләтләренә латинчага күчүне көнүзәк мәсьәлә дип карарга дигән күрсәтмә бирелә.

Ниһаять, Г.Шәрәф бу мәсьәлә буенча И.Сталинга да хат юллый[25]. Бу — И.Сталинның Троцкий, Каменев, Зиновьев, Буха-

рин, Рыковлар һ.б.ларны эшләреннән алып ташлар өчен әзерләгән чак. Г.Шәрәф тә «юлбашчы»га ышаныч баглый әле: фикерләрен ачыктан-ачык итеп аңлата, өй адресларын яза, җавап көтә. Күп тә үтмәс, «халыклар атасы» тәмам ныгыгач, шул адрес белән килерләр дә төн уртасында Галимҗанның ишеген кагарлар, менә сиңа татар әлифбасы, диярләр. Ә төрмәдә әлифба бер генә: кириллица да түгел, латинча да түгел, ул — диварга шаку, ул — бәйнәлмиләл әлифба.

Күрше республикаларда да хәрәкәт җәелә: «Башкортстан» гәзите битләрендә «преподаватель» псевдонимы астындагы зур мәкаләдә латин шрифтын кертмәү теләге белдерелә. *«Мы, преподаватели, не даем полномочий национально-тюркским республикам и их преподавателям, едущим в Баку, выносить постановления о принятии латинских букв и даже не даем полномочий говорить об этом на съезде. Также не берем на себя ответственности за недоразумения (восстания), могущих быть в связи с латинскими буквами, вместе с тем советуем ВКП(б) и правительству СССР успокоить массу»*[26].

Шул ук вакытта Мамадыш кантонының Вахитов волостеның Рабпросместкомы исеменә килгән мөрәҗәгатендә дә шул ук мәсьәлә куела.

Бакудан кайткач, Г. Рәхим дә «Беренче тюркология съезды» исемле брошюра нәшер итә. Бу эш Академцентр җитәкчесе Г.Ибраһимов киңәше белән эшләнә.

Г.Шәрәфнең дә шактый саллы фәнни хезмәте дөнья күрә. Ул хәтта Төркиядә нәшер ителә.

Алар «латин»га күчүнең күпме, ничек зыян китерәчәген исбатлыйлар. Әмма мондый демократия, 1927 елның май аенда булып узган ВКП(б)ның өлкә комитеты карары буенча «Кызыл Татарстан» гәзите битләрендә чыккач тыела. Бу карарда латин әлифбасына күчү кирәклеге әйтелә: *«Полезен и необходим переход к латинскому алфавиту. Вместе с тем ОК в категорической форме предлагает издать соответствующее постановление, отпускать средства из бюджета, ввести латинский алфавит в часть учебных заведений и т.п.»*.

Казан матбугатында мондый карарның чыгуы беркадәр көтелмәгән хәл кебек кабул ителгәне мәгълүм. *«Опубликование в печати подобного, больше чем резкого, постановления парторганом РТ, делающее вопрос латинизма делом партийной дисциплины и всякое обратное мнение и действия как бы делом контрреволюционным, было совершенно неожиданно для рабоче-крестьянской массы и трудовой интеллигенции.*

Это было тем более неожиданным, ибо всего 2—3 месяца назад съезд Советов Татарской Республики на выступление латиниста Векслина и Сайфи ответил только единодушным осмеиванием несерьезность их выступлений: наоборот, съезд Советов РТ своим, почти единогласным постановлением предло-

жил Наркомпросу РТ торопить практическое массовое проведение идущей реформы татарского типографического шрифта.

Мы, нижеподписавшиеся, обращаем внимание ЦКВКП(б) и ОКВКП(б) Татарской Республики на необходимость освобождения татарского населения от подобной жертвы как фактический отказ от своей письменной культуры...» диелә «82 ләр хаты»нда. Билгеле булганча, гаепләнүчеләрнең бу хатта имзалары бар.

Бу татар зыялыларының И.Сталинга, партиянең Татарстан өлкә комитеты пленумына һәм ВКП(б) үзәге комитеты инструкторы Пшеничныйга 82 имза куйган хаттан бер өзек кенә. Хатта бәян ителгән төп фикер — гарәп графикасыннан латин язуына күчмәскә, чөнки ашык-пошык әлифба алыштыру татар халкын күп гасырлар гамәлдә булган бай мәдәнияттән аерачак, күп өлкәләрдә торгынлыкка китерәчәк. Әмма тиздән ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты «82 ләр хаты» буенча махсус карар кабул итә. Анда мондый юллар бар:

«1) Төрки әлифбадан латин хәрефләренә күчүнең асылы буенча мәсьәлә хәл ителгән дип санарга һәм бу хакта бәхәс кузгатмаска;

2) бу мөрәҗәгатьнең язылуы ВКП(б)га каршы юнәлтелгән буржуаз милләтчел элементларның активлашуын күрсәтә;

3) өлкә комитет бюросына бу фактган тиешле нәтиҗәләр ясарга, кирәкле дип табылган иҗтимагый-оештыру чараларын күрергә һәм аңлату эшләрен үткәрергә кушарга»[27].

Оештыру чаралары да күрелә, аңлату эшләре дә алып барыла. Нәтиҗәдә хат авторларының күбесе үз имзаларыннан баш тартырга мәҗбүр булалар. Хат авторларын астыртын эзәрлекләүләр дә киң тарала.

Гаепнамәнең авторлары «82 ләр хаты»ның тууын «Оештыру үзәге»нә, «Яңа китап» нәшриятының тырышлыгына бәйлиләр. Чөнки «82 ләр» арасында И.Бикколов, Җ.Вәлиди, М.Гали һәм башкаларның куллары куелган диелә.

Әлеге хатның төп текстын редакцияләп язып бирүче Галимҗан Шәрәф була. Моның өчен аның фатирына Хәсән Исхаков белән Садри Вәлидов киләләр һәм язып бирүне үтенәләр. *«Бу безнең үтенеч кенә түгел, бәлки бөтен татар зыялыларның үтенече»*, — диләр алар.

«82 ләр хаты»ның ике данәсе Бикколовң фатирында тентү вакытында табыла. 1932 елда бу хат икенче яңгыраш ала. Хәзер инде хакимияткә каршы мондый эшнең «солтангалиевчелек» белән бәйләнгәнлеген, Татарстан Республикасында «Оештыру үзәге» булуын дәлиллиләр. Гаепнамәдә мондый юллар бар: *«Про-*

тест 82-х вышел в свет по существу от кадров султангалиевской организации в Татарской Республике»[28].

Шәех Али Әскәр, Бөдәйли, Максудов, Бикколов һ.б. *«Совет власте милли сәясәтне боза, ә латинлаштыру ул — Мәскәү эше... Совет хакимиятенең сәясәте татар милли мәдәниятен бетерүгә китерәчәк»* диюләре өчен дә гаепләнәләр.

С. Хафизов «82 ләр хаты» буенча имзалар җыюда гаепләнгән.

Соңрак, җавапка тартылган «82 ләр»не үз имзаларыннан баш тарттыру сәясәте башлангач, бер өлешенең, чыннан да, үз имзаларын кире алганлыгы билгеле. Шушы гаепнамә буенча хөкемгә тартылган И. Бикколовка имзасыннан баш тартуны таләп иткәч, ул: *«Мин моны эшли алмыйм, чөнки бу принциплардан баш тарту булыр иде, ә минем өчен принциплардан баш тарту — үлем белән бер»*[29], — ди. Бу турыда аңа С. Җәләл, И. Әхтәмов, З. Нуркин һ.б.лар белән дә сөйләшергә туры килә.

Шулай ук алар Совет хакимиятенә каршы булган әдәбиятны таратуда да гаепләнәләр. Алар үзләренең кибетләрен Совет властена каршы булган идеяләрне тарату үзәкләренә әйләндергәннәр, имеш. «Яңа китап» кибетләрендә Газиз Гобәйдуллинның 1918 елда нәшер ителгән «Милләтчелекнең кайсыбер нигезләре» (Некоторые основы национализма) исемле китабын тараткannar. Бу китабында ул: *«Төрки халыклар бер милләт хасил итәләр, төрек-татарлар Азия һәм Себер халыклары арасында Европа мәдәниятен тарату ролен Болгар һәм Хазар ханлыкларыннан башлап киләләр. Тарих тарафыннан Урта Россия төрекләренә мактаулы урын бирелде (почетное место), аларны чыннан да культегерларга әйләндерде. Татарларның роле мәдәният өлкәсендә генә түгел, алар тагын да зуррак мәсьәләләрне икътисад өлкәсендә дә эшләргә тиешләр»*, — ди. *«Ввиду географической и культурной близости волжских тюрок к тюркам-мусульманам Востока, понимания их и своей высококультурности — они должны помочь Европе научить одну часть этой великой нации — восточную тюркскую народность»*. Моннан башка «Яңа китап»ны Г. Исхакыйның әдәби хезмәтләрен таратуда, М. Галәү, Галимҗан Шәрәф, С. Хафизов һ.б.ларны Совет хакимиятенә каршы әдәбият нәшер итүдә гаеплиләр. Мәсәлән, Галимҗан Шәрәф 1926 елда Константинопольдә яңалифкә каршы багышланган брошюрасын ак эмигрант Бари Батталның кереш сүзе белән нәшер иткән. Моннан гайре тагын Галимҗан Шәрәф, Г.Рәхим, Җ.Вәлиди укыту процессында «яңа китапчылар» буларак Г.Исхакыйның хезмәтләрен файдалануда гаепләнәләр. Г.Рәхим Шәрык педагогия институтында әдәбият, ә Галимҗан Шәрәф һәм Җ.Вәлидиләр татар телен укытканнар.

Г.Рәхимнең сүзләренә караганда, Галимҗан Шәрәф укыту программасына Г.Исхакыйның әсәрләрен анализлауны керткән. Алай гына түгел, ул «Гаяз Исхакыйның иҗатын өйрәнү кирәкме?» дигән махсус доклад белән заман хезмәттәшләре алдында татар теле һәм әдәбият кафедрасында чыгыш ясый. *«Гаязның иҗатын өйрәнүгә берьяклы гына килергә ярамый,* — ди ул. — *Бу мәсьәләдә киң карашлык булырга тиеш. Аның әсәрләрен бүтән татар язучы-шагыйрьләрнең рухи мираслары белән бергә тикшерү һәм бәяләү зарури. Олуг әдипнең исемен дәреслекләрдән һәм матур әдәбият тарихыннан алып атуны хуплау һич тә мөмкин түгел».*

Моңа каршы С.Габдрахманов һәм кафедра әгъзасы Яфаров: *«Институтта Г.Исхакый әсәрләре бөтенләй дә өйрәнелергә тиеш түгел, уку-укыту процессында без алардан файдаланмаска тиешбез»,* — диделәр.

«Исхакый иҗаты мәсьәләсенә килгәндә, барыбызга да яхшы мәгълүм булганча, — ди Г.Шәрәф, — *ул — Галимҗан Ибраһимов белән бергә Октябрьгә кадәрге татар әдәбиятының иң күренекле шәхесе. Әгәр тәнкыйтьчеләр, революциягә кадәрге татар әдәбиятына чынбарлыкны һәм көндәлек тормышны реаль тасвирлау хас дип бәялиләр икән, Исхакый иҗатында бу төсмерләр аеруча тулы чагылалар. Өстәвенә әле Исхакыйның күпсанлы әсәрләре буржуаз дәвердәге татар әдәбиятындагы иң кыйммәтле вә нәфасәт ягыннан иң камил саналган әсәрләрнең яртысы ук булмаса да, иң кимендә өчтән бер өлешен тәшкил итәләр. Без әдәбиятка җәмгыяви продукт дип карыйбыз, димәк, аңардагы кыйммәтле дип исәпләнгән һәрнәрсә иҗтимагый казаныш дип каралырга тиеш. Әдипләрне һәм шагыйрьләрне матди яки рухи шәкелдә дәфен итсәк тә, аның әсәрләрен барыбер югалтмыйбыз, саклыйбыз»*[30].

Күренә ки, Галимҗан Шәрәф татар кешеләренең Октябрь инкыйлабына кадәрге тормышын Г. Исхакыйдан башка берәүнең дә хакыйкый төгәллек белән дөрес тасвирлый алмавын бик яхшы аңлый. Чынлап та, татар мәдрәсәләренең эчке тормышы, авыл кешеләренең уй-фикерләре, шәһәр байлары балаларының әхлакый түбәнлекләре кем иҗатында шундый үтемле образлар аша тасвирлана соң? Әдәбияттан шундый югары нәфасәтле әсәрләрне сызып ташлау аны ярым-йорты хәлдә калдырмыймы? Исхакыйның иҗатын тирәнтен өйрәнми торып, бер әдипнең генә түгел, ә бәлки татар әдәбияты тарихын, гомумән, тулы килеш күз алдына китерү мөмкин түгел.

Ләкин ул Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗатына тукталмый һәм бәя дә бирми. Бу, бердән, «тимер чаршау» сәясәте нәтиҗәсендә аның соңгы әсәрләре Ватанында мәгълүм булмау белән аңлатылса, икенчедән, Шәрәф үзе дә, илдә хөкем сөргән

шушы (Кандыбинның «Совершенно секретно» графасы астындагы «гаепнамә» әзерләгән көннәр) көннәрдәге сәяси вазгыятьне истә тотып, «кырмыска оясына таяк тыгу»ны урынсыз дип санагандыр, күрәсең. Шулай да, утырыштагы чыгышларга бәя биреп, Галимҗан үзенең Исхакый иҗатына булган карашын имеш-мимешләргә урын калдырмаслык итеп өзеп әйтә: *«Иртәме-соңмы безнең тәрбиячеләребез һәм тәрбияләнүчеләребез Исхакыйны укыячаклар. Әгәр дә без аның иҗатын тиешенчә тикшермәсәк һәм ясалма рәвештә эндәшмәү юлына бассак, «тәвә кошы» сәясәте булмасмы? Минемчә, бу — җитди мәсьәлә»*[31].

Гаепнамәдә Г.Рәхимнең дә һәм башкаларның да карашы чагылдырыла. Ул да Исхакыйның әсәрләрен искә алмау илгә зыян китерү белән бер дип карый.

Имеш, шушы һәм башка көчләп алынган күрсәтмәләр нигезендә педагогия институты 1928—1929 елларда Шәрәф һәм Вәлидовларның тырышлыгы белән к.р. солтангалиевчеләр «оясына» әйләнгән, алар тарафыннан янә «солтангалиевчеләрнең студент оешмасы» да төзелгән. Анда студентлардан Гали Галиев, Хаҗи Москов, Мотыйгый Курамшин, Нигъмәт Еникеев, Измаил Асанович, Хөсәен Җаффаров, Хөсәен Ширин һәм Батыршиннар кергәннәр.

Милләтчеләр һәм Совет хакимиятен җимерергә теләүчеләрдән Главлит рәисе Кәримов, З. Гыймранов, «Яңа китап» нәшрияты әгъзасы И.Рәмиев исем-фамилияләре дә аталган. Алар, төрле нәшриятларның әгъзалары буларак, к.р. әдәбиятын чыгарганнар. Андый әсәрләрдән «Халык җырлары» җыентыгын, «Толковый словарь»ны, дини әдәбияттан Коръәнне күрсәтергә кирәк. Шулай ук Җ.Вәлидинең «Очерки истории образованности и литературы Волжских татар», Г.Рәхимнең «Идел» романы, Г.Гобәйдуллин тарафыннан төзелгән «Татар тарихы» к.р. әдәбият рәтенә кертелә. Берсе архибуржуаз булса, соңгысында марксистик идеология бөтенләй юк диелә. Алар арасында иң куркынычы Җ.Вәлидинең хезмәте икән. Гаепнамәдә: *«Один из ярких представителей сторонников пантюркизма по вопросам татарской литературы — редактор контрреволюционной газеты «Алтай». В своей послереволюционной литературной деятельности продолжал проповедовать идею буржуазного национализма. Его книга «Очерки истории образованности...» на русском языке, вышедшая в 1923 году, является до конца буржуазно-националистическим, контрреволюционным произведением. В этой книге Валидов Д. умышленно популяризирует контрреволюционных эмигрантов, таких, как Г.Исхаков..., умалчивает о революционном движении среди татарских рабочих и крестьян, выдвигая на первый план как прогрессивных представите-*

лей татарского общества самых махровых пантюркистов, контрреволюционеров... Эта книга ничего общего не имеет с Октябрьской революцией, с марксизмом». «Толковый словарь»-ны бәяләп, Кандыбинның эштәшләре: *«Без анда элеккеге буржуаз милләтчелекне саклап, махсус рәвештә к.р. эмигрант Исхаковның әсәрләрен популяризовать иттек»,* — диләр. Гомумән, Җ.Вәлиди китабындагы әдәбиятчыларга хас нәрсә — хәзерге заманга кагылган мәсьәләләрдән баш тартып, узган заманны мактау, икенче төрле итеп әйткәндә, «тарихның чүп-чар әрҗәләрендә казыну». Төп ният шунда: Совет чынбарлыгын күрмәмешкә салышу. Бу эштә аңа Г.Шәрәф зур булышлык күрсәтте диелә. *«Именно благодаря Шарафу мы получили такой сборник в предисловии которого открыто преподносится султангалиевская концепция развития татарской культуры и литературы».*

Гаепнамәне әзерләү дәверендә 18 кешелек исемлеккә тагын Фәхрелислам Агиев, Һади Атласов, Һади Максудов (Әхмәтһади Максудов, Әхмәтһади Максуди), Микъдәт Борындыков, Нургали Һадиев, Нәсих Мохтаров, Хәдичә Ямашева, Кәрим Мөшәрриев, Гаяз Максудов, Фатих Әмирханов, Габдулла Шунаси, Гомәр Әмирханов, Фәтхи Борнашев, Мостафа Пименов, Риза Газизов, Вафа Сафин, Хуҗа Бадыйгов, Хәбибрахман Зәбиров, Хәсән Исхаков, Гыйлем Шәрәф, Борһан Шәрәф, Галимҗан Шәрәф, Салих Вафиннар өстәлә.

ОГПУның санауларына караганда, барлыгы 43 кеше хөкемгә тартылган. Аның монысы да ялган, чөнки хөкем ителүчеләр арасында тагын түбәндәге фамилияләр дә бар: Абдулла Әхмәдуллин, Әкрам Әхмәров, Габдул Әхмәров, Гали Биковский, Рәшит Бикбаев, Хәйретдин Бикчәнтәев, Шәрәф Баһаутдинов, Сәләхетдин Вафин, Гариф Галиев, Самат Зәйнетдинов, Хәбибрахман Закиров, Шәрифҗан Кәримов, Иосиф Лившин, Яков Ментин, Галимҗан Нигъмәтуллин, Халит Сәйфуллин, Рагиз Фәсхаков, А.С.Хәсәнов[32].

Алар барысы да диярлек үзләрен гаепсез хөкемгә тартылуларын исбат итәләр. Бу кешеләрнең гаепләре бары тик көчләп тагылган күрсәтмәләргә генә нигезләнгән. Бары тик Габбас Хөснетдинов, Гали Исхаков, Лотфулла Закиров үзләрен беркадәр гаепле дип саныйлар.

14 кешенең эше «особое производство»га бүленеп чыгарыла. Бу исемлеккә З.Нуркин, В.Таначев, И.Әхтәмов, Ә.-Һ.Максудов, Н.Надеев, Н.Мохтаров, Х.Ямашева, И.Кулиев, К.Тинчурин, Г.Максудов, Р.Газизов, Х.Бадыйгов, Х.Исхаков, Г.Шәрәф кертелә.

Солтангалиевчелекнең ул елларда Татарстан авылларына да барып җиткән икәнлеген дә ОГПУ хезмәткәрләре җиң сызганып исбат итә башлыйлар. Аларның фикеренчә, Чүпрәле һәм Буа

районнарында җиде авылда кулак һәм муллалар җитәкләгән к.р. төркемнәр табылган. Гаепнамәдә түбәндәге 7 төркем санала:

«1. Ново-Чукальская, под руководством и активным участием Галлямова Шакира и других в числе 2—7 человек кулацко-муллского элемента;

2. Старо-Чукальская, под руководством и активным участием Айнуллина Саната, Айнуллина Арифа, Алкаева Нурмухамета, Айнуллина Сафиуллы, ишана Бикулова Сафи, Усманова Гаяза, Велишева Сафи, Бикколова Касыма, Бикколова Хамита и др. 14 человек кулацко-муллского элемента;

3. Старо-Шаймурзинская, которая объединяла селения Ст. Шаймурзино, Нов. Шаймурзино, Мал. Цильна, Бол. Цильна под руководством и активным участием Сабитова Закира, Абдуллина Идиата, братьев Вахреевых и других в числе 9 человек кулацко-муллского элемента;

4. Тат. Санлыкская, под руководством и активным участием Самирханова Сафиуллы, Абитова Шарифзяна, Мушарапова Хабира и др., в числе 11-ти человек кулацко-муллского элемента;

5. Нижне-Чекурская, под руководством Дунаева Шарифа, Сулейманова Идиатуллы и других в числе 8-ми человек кулацко-муллского элемента;

6. Ново-Ишлинская, под руководством Мардеева Зарифа и др., в числе 10-ти человек кулацко-муллского элемента;

7. Каракитянская под руководством Ямашева Карима, Хисамутдинова Нуретдина и других в числе 7-ми человек кулацко-муллского элемента».

Бу «эшләр» буенча 86 кеше к.р. эштә гаепләнәләр. Шакир Галләмов, Халит Бикколов, Ибраһим Бикколов, Санат Айнуллиннар «солтангалиевчелек төркемнәре»нең җитәкчеләре сыйфатында каралалар: *«В основном деятельность каждой кулацко-муллской к.р. группировки, по совокупности вся их контрреволюционнан деятельность, под руководством ишана Бикколова и других, была направлена на свержение Советской власти и конкретно на селе она велась в направлениях:*

а) Организованного сопротивления проведению хозяйственно-политических мероприятий партии и Советской власти на селе;

б) территоризирования местного бедняцко-батрацкого и колхозного актива и представителей партии и комсомола;

в) организации массовых эксцессов и выступлений и проч.;

г) распространения в этих целях к.р. листовок с призывом к восстанию.

О том, как руководитель вышепоименованных кулацко-муллских к.р. группировок ишан Бикколов Ахметсафа пропагандиро-

вал «свой актив» и направлял его к контрреволюционной деятельности свидетельствуют данные, приведенные на стр. 3 обвинительного заключения по следделам вышеуказанных кулацко-муллских к.р. группировок, из которых видно, что на одном из еженедельных «меджелисов» в доме ишана Бикколова Ахметсафы, последний перед собравшимися муллами и кулаками держал следующую речь: «Пришло время, когда мусульманская религия лишена всякой свободы. За последнее время мы наблюдаем отказ в открытии школ и закрытие существующих, бесчисленные аресты преданных делу религии лиц, черезмерное обложение налогом как сельскохозяйственным, так и подоходным, отбирание насильственным путем хлеба и насильственное навязывание облигаций. Спрашивается, сделали ли мы что-нибудь для защиты религии от таких частых нападений? — Нужно сказать нет, мы спали. Можем ли мы терпеть, как до сего времени, конечно, это невозможно, поэтому нужно нам будить друг друга, а в первую очередь приходские советы и взяться за дело, за религию. Если мы будем бояться Советской власти — это равносильно тому, что отказываемся от Бога, мы должны объяснить прихожанам о насилиях на религию со стороны власти, внедрить в сознание каждого необходимость бороться против гонений, а для этого должны объединиться вместе с прихожанами всех приходов»[33].

Аларны Буа районында крестьян восстаниесе оештыруда, ОГПУ хезмәткәрләрен коралсызландыруда, «яңалиф»кә каршылык күрсәтүдә, Солтангалиев белән бәйләнештә торуда — «туранчылык»та гаеплиләр.

Тарихи белешмә

Солтангалиев Туран дәүләтен төзүнең сәбәпләрен күрсәтә: «1) киләчәктә Россиянең таркалу очрагын искә алып; 2) киләчәктә СССР төрки халыкларының һәм шәрык халыкларының берләшүе котылгысыз... бу берләшү СССРның һәм аның янындагы көньяк-көнчыгыш илләрдәге халыкларның берләшүе социалистик революция файдасына булсын өчен; 3) көчле төрки халыклар федерациясен төзү... Шушы өч факторны искә алып, мин Туран дәүләтен төзүне әзерләүнең кирәклеген күтәреп чыктым. Туран дәүләте ул — Советлар Союзы составындагы Совет Федератив Социалистик Республикасы, революциянең җиңелү очрагында — халык демократик республика. Соңгы очракта бөтен Туран дәүләте, минем уйлавымча, атакалаучы реакциягә каршы киң халык массаларын восстаниегә күтәрү өчен кирәк»[34], — ди.

Буа районында «туранизм» татар белән башкортны берләштерүдә чагылдырыла. Әлеге дә баягы шул «Идел-Урал штаты» белән бәйлиләр. Шулай итеп, юк эшне бар итеп, зур масштаблы итеп күрсәтәләр.

Бу «эш» өч ел дәверендә каралып, 31 дән артык кеше 1935 елның 15 маенда төрле срокларга ГУЛАГка озатылалар. Бары тик Закир Битковский, Шәрифҗан Кәримов, Галимҗан Нигъмәтуллин, Вәгыйз Фәсханов хөкемгә тартылмыйлар. Кайберләрен 1936—1939 елларда хөкемгә тарталар, ә калганнарын күбесенчә бишәр елга хөкем итәләр[35]. Аитов, икенче тапкыр 1940 елның 25 декабрендә кулга алынып, 14 елга хөкем ителә. Аның эше бары тик 1959 елда гына туктала.

1932 елның декабрь аенда № 5949449 «эш» буенча тагын 30 «Крестьян иттифагы» (союзы)нда «катнашучылар»ны кулга алалар. Имеш, алар, кораллы көч кулланып, Совет хакимиятен җимерергә теләгәннәр. Болар исемлегендә Г.Баймбәтов, Г.Алимов, М.Сәгыйдуллин, Д.Ханзафаров, Х.Габбасов, Ә.Мостаев, Ю.Якубов, С.Шәрәфетдинов, В.Хәбибуллин, М.Шаһиәхмәтов, В.Юлдашев, Х.Радиков, А.Мөслимов, Г.Садретдинов, Г.Кудояров, Х.Тарпищев, Х.Сәлимов, Ф.Ишбулдин, С.Салихов, Ш.Абдрафиков, А.Халикова, Х.Баймбәтов, М.Мортазин, М.Бакиров, С.Абдуллин, Х.Каипов, Г.Габбасов һ.б. була[36]. 1929 һәм 1937 елларда Туран дәүләтенең идеяләрен пропагандалаган өчен кулга алынып, 1938 елда Һади Атласов атылуга дучар ителә[37].

Шулай итеп, тоталитар режим шәһәр һәм авыл зыялыларына, аңлы эшче-крестьяннарга гына түгел, яшьләргә дә тоталь һөҗүм ясый. Моның шулай булачагын М. Солтангалиев алдан ук әйтеп калдырган булган. Ул 1924 елның 8 сентябрендә РКП(б)-ның үзәк контроль комитетына үзен партиягә яңадан кайтару мәсьәләсен куйган гаризасында: *«Туранизм»нан соң реакциянең атакасы нәтиҗәсендә 80—90 процент татар интеллигенциясе кырылып бетерелер иде»*, — ди. *«Это было бы равносильно скальпированию мозга общественного организма нацраионов. И это было бы на руку этой же реакции*[38]. *В итоге наступление тоталитарного режима* (Солтангалиев әйткән реакция турында. — *Р.В.*) *и репрессии оказались на руку режиму И.Сталина»*. Бу уңайдан шуны әйтергә мөмкин: барлык татар зыялылары да җинаятьчел Сталин режимына һәм үз-үзләренә карата борынгы заманның бөек шагыйре Гомәр Хәйям сүзләре белән бәя бирергә хаклылар. Алар иректә дә, каторга-концлагерьларда да үз акылларын, рухларын саклап кала алганнар.

Акыллы, шик тә юк, ... синнән,
Мәй эчсәк тә аек без, ... синнән.
Сусын безгә йөзем суы, сиңа кан,
Димәк, син ул явыз — ил канын имгән.

НӘШРИЯТ МАШИНАЛАРЫН КЕМ ВАТКАН?

Кандыбинның хәтере хәтәр иде шул. Секретарь кабинетында болай озак утыру ялыктырса да, алда әле эш күп булса да, үзенең эшеннән канәгать булганлыктан артык хафаланмады. *«Кайда йөрисең?»* — дисәләр, ул гадәттәгечә: *«Беренчедә»*, — дип кенә җибәрәчәк. Шулай уйланып, ул, Разумовның бик дикъкать белән укуыннан канәгатьләнеп, узган 1931 елның яз айларын исенә төшерде. Кызу иде ул язда. *«Бүген ничек салкын, анда шулай кызу иде»*, — диде ул үз-үзенә. Хәтердә, 1931 елның 1 мартында Татиздатта эшләүче 20 солтангалиевчене кулга алалар. Алар арасында Сафиулла Нигъмәтуллин, Андрей Исаев, Бакый Сөләйманов, Измаил Ибраһимов, Мазанова, Сәлах Габетдинов, Фәйзрахман Булатов, Шәрәф Баһаутдинов, Яков Максимов, Нәкыйп Бәхтияров һ.б.лар да бар иде.

Директорларын Шәрәфетдинов дигәннәр иде булса кирәк. Исемен хәтерләми иде: *«Кара әле, тел очында гына тора бит, шайтан алгыры... Ә, Самат,* — диде ул, шатланып, — *Самат Шәрәфетдинов»*. Нинди зур һәлакәттән коткарды бит Кандыбин Совет хакимиятен...

Бу вакытта нәкъ менә «зыян китерүчеләр»не эзләү киң җәелдерелгән иде шул. Шундыйларның бер төркемен Кандыбиннар әле 1931 елда ук Татиздатта «тапканнар» иде бит. Зур җыелышлар булып алды, анда «дошманнар»ны фаш итү күңелле узды. 1931 елның 27 февралендә Камил Якубов типографиясендә эшчеләр һәм служащийлар бер мәсьәләне мөзакәрә кылалар: Татиздат директоры Шәрәфетдинов «зыян китерүчеләр» мәсьәләсе буенча доклад ясый: *«Безнең белүебез буенча, типографиядә 13 кеше кулга алынды. Социаль положениеләре буенча барысы да служащийлар һәм эшчеләр. Бу безнең типографиядәге «зыян китерүчелек» белән бәйләнгән: кәгазь, инструментлар урлау һ.б. Иң әһәмиятлесе, шул «зыян китерүчелек» — корректорлар бүлегендә. Ул отделда мулла малайлары, исерекләр һ.б. Сәяси хаталар китүе шулар белән бәйле»*, — ди. Җыелышта 180 кеше катнашкан. Гаепнамәдән күренгәнчә: *«Җыю цехында эшләнеп бетмәгән брошюралар производствога җибәрелми яталар... бер брошюраны бетерми, икенчесен башлыйлар. Шулай итеп, эш торкарлана, эшкә зыян китерелә»*. Аннан соң махсус рәвештә машиналарның ватылуын дә әйтеп уза. Доклад ясаучыдан башка тагы 19 кеше чыгыш ясый. Шуны да әйтергә кирәк, соңыннан аларның һәрберсеннән диярлек ГПУ тарафыннан сорау алына. Чыгыш ясаучылар чыннан да кайбер җитешсезлекләрне фаш итәләр: прогуллар, эчүчелек, утынның булмавы күрсәтелә. Чыгыш ясаучылардан Шакировның әйтүенә караганда, машинаның ватылу сәбәбе — аның искерүендә. Аның шулай бу-

лачагын ул инде берничә мәртәбә кисәткән дә. Аннан соң чыгыш ясаган Али Битковский исә: *«Мин монда бернинди дә зыян китерүне (вредительство) күрмим, ә бу бары тик гади аңлашылмаучылык кына»*, — ди. Ул чыгыш ясаганда ук ГПУ вәкиле А.З.Битковский фамилиясе янына: *«Срочно подвергнуть к аресту»*, — дип язып та куя.

Нәтиҗәдә җыелыш ГПУдан ашыгыч рәвештә чаралар күреп, гаеплеләрне хөкемгә тартып, китап фабрикасы эшчеләре алдында ачык (показательный) суд уздыруны таләп итә.

С.Шәрәфетдинов докладын тыңлап, аның буенча мөзакәрә кылганнан соң, махсус карар кабул ителә. Ул тугыз пункттан тора. Без аны тулы килеш бирәбез: *«Заслушав информацию тов. Шарафутдинова о вредительстве на фабрике, мы, рабочие и служащие книжной ф-ки имени «Камиль Якуб», требуем строгих мер наказания над вредителями и требуем органы ГПУ сделать показательный суд перед рабочими книжной фабрики. На основе этого постанавливаем:*

1. Факт вредительства признать правильным;

2. Мобилизировать рабочие массы вокруг производства для выявления остальных исполнителей вредительства;

3. Предложить дирекции фабрики поставить точный учет на фабрике и довести промфинплан до станка, в течение 10-ти дней и для этого мобилизировать рабочие массы;

4. Отмечая недопустимо плохую постановку учета поступления и процесса печатных книг, собрание поручает дирекции типографии и правлению Татиздата немедленно упорядочить этот учет, введя персональную ответственность за своевременный выход книг в свет;

5. Предложить фабкому, дирекции типографии и Татиздата принять решительные меры к оживлению массовой и профсоюзной работы, через чего добиться мобилизации рабочих и служащих вокруг задач выполнения промфинплана, борьбы и окончательного выявления корней вредительства, поднять производительность труда трудовой дисциплины, соцсоревнования и ударничества;

6. Категорически предложить правлению Татиздата и дирекции фабрики наладить поступление авторской корректуры и своевременно изжить залежи авторской корректуры у автора;

7. Предложить дирекции типографии, правлению Татиздата принять срочные меры к комплектованию состава рабочих и корректоров типографии и подготовки кадров как для типографии, так и для Татиздата;

8. Собрание целиком и полностью присоединяется к решению рабочих типографии «Кызыл Татарстан» и поручает фаб-

кому типографии в срочном порядке обсудить это решение на общем собрании рабочих фабрики;

9. Провести на фабрике субботник для разборки мусора в цехах. За своевременное раскрытие акта вредительства на нашей фабрике шлем большевистский привет органу ГПУ».

Бу «эш» буенча Татарстан китап нәшриятының бөтен хезмәткәрләре узалар. «Эш» акрын гына әзерләнә. Бу «эш»тән урындагы, хәтта үзәктәге матбугат та файдалана. Мәсәлән, 1929 елның 9 мартында «Кызыл яшьләр» гәзите битләрендә «Татиздат букеты» исемле мәкалә пәйда булды. Соңрак шул ук гәзит битләрендә «Юбилей» дигән мәкалә чыга. Бу мәкаләләр барысы да Татарстан китап нәшриятын тәнкыйть итүгә багышланганнар. Анда: *«Татар нәшрияты акгвардеецлар һәм безгә каршы элементлардан тора»*, — диелә.

Үз чиратында бу мәсьәлә Татиздатның месткомында һәм ячейкасында да карала. Аннан соң эш НК РКИ һәм ОККИ коллегияләрендә дә каралып, мәкаләнең авторы Н.Бәхтияровка кисәтү ясала. Дәүләт учреждениеләре хакында андый тупас рәвештә тәнкыйть ясалырга тиеш түгел диелә. Нәтиҗәдә шулай да Рязанов һәм И. Кулиевлар эштән азат ителәләр. Әмма эш моның белән тәмамланмый, киресенчә, кыза гына.

Нәшрият директоры С.Шәрәфетдиновка атака дәвам итә. Директорга Россия мөселман капиталистларының вәкиле дигән ярлык тагалар. Аның җиде ата-бабасына да барып җитәләр. Янәсе, аның әтисе — ахун. Имеш, аның ике дисәтинә җире булган.

С.Шәрәфетдиновның 1917—1918 елларда «Тормыш» гәзитендә чыгарылган мәкаләләренә анализ ясап, үзенең кем икәнлеген исенә төшерәләр. Аның «Тормыш» гәзите (1918, № 898) битләрендә чыгарган бер материалы китерелә. Ул анда: *«Октябрь инкыйлабы безнең милли хәрәкәтебезгә зур һәм үтергеч сугу булды. Бу эшләрне күреп үз-үзеңә сорау бирәсең: ирек игълан ителүгә бер ел узды, ә ул безгә нәрсә бирде соң?*

Чынлыкта ул безгә бернәрсә дә бирмәде. Халыклар тигезлеге, туганлыгы безнең төшебезгә генә керә. Без бүген язарга, сөйләргә дә куркабыз, ә төрле милли хәрәкәтләр бары тик буржуаз хәрәкәтләр диеп бәяләнәләр һәм тамыры белән йолкып алыналар», — ди. Аңа карата тагын әллә нинди материаллар табалар.

Шулай итеп, ГПУ тикшерүчеләре, үзләренә кирәк нәтиҗәне ясап: *«Шарафутдинов Самат в течение пяти лет существования Татиздата свил себе теплое гнездо и вокруг этого гнезда сконцентрировал всю белогвардейско-вредительскую сволочь начиная снизу до верха»*, — дигән кара мөһер сугалар[39].

Татиздатта зыян китерүчеләр исемлегенә 19 кеше кертелә: Т.Девятов, Фәрхи Әхмәтов, Фатих Әмирханов, Габдулла Әхмә-

тов, Гомәр Әмирханов, Сергей Ефимов, Абдулла Әхмәдуллин, Мейтин, Ибраһим Кулиев, Кыям Юлдашев, Мөхәммәт Муллинов, Кузьма Смолов, Хафиз Мозаффаров, Лев Бунаков, Якуб Рязанов, Петр Сахаров, Лотфи Вахитов, Владимир Яровинский, Харис Фәйзуллин.

Алар мулла малайлары, акгвардияче һәм миллионер уллары дип бәяләнәләр. Лотфи Вахитов 1906 елда Габдулла Апанаев тарафыннан нәшер ителгән «Азат» гәзите хезмәткәре булуында гаепләнә. Аннан гайре ул чехословаклар бандасында катнашкан, имеш. И. Кулиев — латинизация дошманы, «82 ләр»не яклаучы сыйфатында бәяләнә. Шактый зыялылар — язучылар, журналистлар эшләмичә гонорар алганнар, имеш. Бу исемлектә С.Шәрәфетдинов, Ф.Әмирханов, Ф.Йосыф, М.Сәгыйдуллин, Ю.Даут, Х.Гайнан, Г.Нигъмәти, Фәридова, Ш.Маннуров һ.б. була.

Ф.Әмирхановка карата гаепнамәдә болай язылган: *«Этот скрытый, как черепаха — тихий элемент долгое время был секретарем «Кзыл Татарстан», состоял активным членом правления кооперативного издательства «Янга китап»... много очень пишет и переводит по заказу кондратьевщины. Книга Короткова — активного участника контрреволюционной организации «партии трудового крестьянства», — кондратьевщины — «Лен и его возделывание» переведена и отпечатана только благодаря доверчивому отношению главного редактора и халатному отношению редактора с/х отдела Ханзафарова. Книга напечатана летом 1930 года и уже распространена почти полностью... Ясно, что к таким лжесоветским интеллигентам издатотдел Татиздата относится примиренчески, а в результате книжный рынок наводняется книгами, являющимися выразителями творчества чуждого нам класса, а хорошо выдержанные по содержанию книги лежат не напечатанными годами».*

Шактый кыска вакыт эчендә Кандыбиннар кампаниясе менә шулай итеп тагын бер «эш» әвәлиләр. Бу провокацион «эш» Татарстанда яшәгән татар зыялыларына гына түгел, СССРда, бөтен дөньяда яшәүчеләргә дә кагыла. Иң гаеплесе булып М. Солтангалиев санала, шул ук вакытта аның тирәсендәге барлык татар-башкорт зыялылары да, хәтта руслар, яһүдләр һ.б.лар да гаепләнә. Гаепнамәдә күренгәнчә, иң куркынычлысы татар зыялылары икән...

Биш елдан соң да партиянең контроль органнары Татиздатны тикшерәләр. 1937 елның 11 сентябрендә «җаваплы контролер» ВКП(б) каршындагы партконтроль комиссиясенең ТР буенча уполномоченные Зайцевка Татиздатта зыян китерүчеләр хакындагы хәбәрендә болай диелә: *«Как известно, в Татгосиз-*

дате в течение десятилетия орудовали контрреволюционные националистические и бухаринские элементы, где на руководящих постах сменились одни вредители другими. Например, с 1925 г. до II половины 37 года управляющими Татгосиздата работали: Альми, Атнагулов, Шарафутдинов, Гумеров, Башкиров, Юнусов, Мухсинов, а главредактором С.Бурган, Ф.Ахметов, М.Гумеров. Эти вредители насаждали на ответственных постах в качестве старших редакторов и зав.секторами контрреволюционных националистов и близких им лиц. Например, старшими редакторами работали: в секторе учебно-методической литературы — М.Гумеров (националист), с 1932 года до лета 1937 года Бакиров (в июле исключен из партии, к сожалению, еще работает в издательстве), который был в близких отношениях с ныне разоблаченными националистами; в секторе художественной литературы работали Нигмати, Гумер Галеев, Шарифуллин, Тулумбайский и др.

Эти враги народа в качестве авторов-переводчиков и нештатных редакторов привлекали близких им людей из националистов или им сочувствующих (Атнагулов, Ф.Сайфи, К.Наджми, Г.Тулумбайский, А.Ахметов, Мансуров, Ф.Карим, Х.Туфан, Г.Нигмати, С.Гильфанов, А.Кутуй, М.Галеев, Исанбетов и многих других), в руках которых монопольно находилось составление, переводы и редактирование политической, художественной и учебно-пед. литературы. Молодых кадров умышленно не привлекали, а ... задерживали и тормозили их рост.

Вредительство их заключалось еще и в том, что они систематически срывали выполнение плана издательства, особенно трудов классиков марксизма-ленинизма...»[40].

Шулай итеп, тоталитар режим зыялыларны эзәрлекләүне дәвам итә. Монда инде яңа этап: 1937—1938 еллар тарихы. Ул махсус өйрәнүне сорый.

Разумов, сүзсез генә өстәл артыннан торып:

— Уф, иптәш Кандыбин, башым авырта, — дип, ике кулы белән маңгаен каты итеп уып алды.

Кандыбин дәшмәде. Ул папканы үз ягына тартып китерде. Әйтерсең лә секретарь аны аңа бирмәс...

Разумов өстәлдәге графиннан стаканга салкын су салып, бөтенләй диярлек эчеп куйды да янә урынына утырды. Икесе дә сүзсез калдылар. Бу килешү билгесе иде.

Кандыбин җитез генә өстәл артыннан чыгып киенә дә башлады.

Өстәлдә телефон бертуктаусыз шылтыраса да, Разумов алмады. Аның, бәлкем, Кандыбин алдында сөйләшәсе килмәгәндер...

Кандыбин ничек килсә, шулай ук бик тиз китеп тә барды. Бу минутларда Разумовның да шактый чәчләре агару юлына бастылар. Күңелдә шик туды. Ничек эшләргә бу Татарстанда?

Бу хәл 1932 елның гыйнвар аенда булды. «Солтангалиевчеләр филиалы», «Оештыру үзәге», контрреволюцион «Яңа китап» — дөреслектә бу бит ГПУ тарафыннан уйлап чыгарылган уйдырмалар гына. Күпме язмышлар өзелгән, ә күпме өзеләчәк... Тарих моңа ничек карый? Разумов ул кадәресен күз алдына китерә алмаса да, үзенең баш очында болытларның куеруын сизенә иде. Ни эшләргә соң?

Моңа җавап бирергә аның көче дә, теләге дә юк иде. Ә җавап бирергә туры киләчәк — ул моны яхшы аңлый. Тарихның кулы каты һәм коры. Ул сине юлбашчы яисә секретарь дип тормый, үз вакыты белән барысын да үз урынына куя. Бу — закон.

Әмма алда ГПУның тагы 5 еллык планын үтисе бар иде әле, ә аннан соң... акыллы «ил атасы» күпме кан коячак.

30 нчы елларның ахырына таба тоталитар режим зинданнарында бу очеркта аталган зыялылар гына түгел, башка бик күп галимнәребез, язучыларыбыз, муллаларыбыз, эшче-крестьяннарыбыз газап чиктеләр, юкка һәлак булдылар. Аларның язмышлары безгә, хәтер булып кайтып, кисәтү дә ясыйлар: бер-берегезне аңлап эш итегез, аерылмагыз, үзегезнең киләчәгегез өчен көрәшүдә безнең хаталарыбызны кабатламагыз. Бу хаталар 1939 елның 1 гыйнварында 24 894 татарны зиндан-лагерьларга озатырга мөмкинлек тудыра. ГУЛАГтан исән-сау кайткан Хәмит Хәкимовның сүзләре әле хәзер дә йөрәкләрне сыкрандыра: *«Я иногда сам себе задаю вопрос, как я уцелел, ведь я провел 18 лет, а ведь по сути дела не за что...»*

Башкалар өчен реабилитация 1956 елдан ук башланган булса, М.Солтангалиевнең акланган исеме 1988—1990 елларда гына безгә кабат әйләнеп кайта алды.

1992 елда Татарстанның киң җәмәгатьчелеге аның 100 еллык юбилеен уздырды. Анда аның туганнары, якыннары катнаштылар. Соңыннан, булачак һәйкәл урынына зур таш куеп, митинг уздырылды. Бу Солтангалиевнең туганнары өчен генә түгел, безнең барыбыз өчен дә зур бәйрәм булды. Анда Төркиядән, Гарәбстаннан, Америкадан килгән татарлар актив катнаштылар.

Тарихтан нәтиҗә ясау бик зарури. Бу хәлләр барысы да революциягә ышанып, үзара аңлашмый, бер-береңне гауга, тавыш, кирәкмәгән гамәлләр белән харап итүнең бер нәтиҗәсе генә.

Безнең көннәрдә дә татар-башкортның — бер төрки туганның — берсен берсе аңлый алмавы безне борчый. Онытмагыз,

җәмәгать, алда авыр көрәш еллары — бу көн кебек ачык. Моны беләк белән йөрәк кенә хәл итә алмый, баш кирәк. Безнең чорыбыз — үзаң чоры. Моның өчен без барын да эшләргә тиешбез.

Массаларның алга бару процессында башта абстракт рәвештә күзәтү, үзеңчә аңлау булса, икенчесе исә активлык этабы. Бу этапта массалар, митингларда, җыелышларда актив катнашып, үз көчләрен күрсәтәләр. Менә шушы вакытта төрле яктан әзер булган партияләр, аерым шәхесләр өскә чыгалар. Алар иске лозунглардан, иске халәттән, башкалардан аерылып, тиз күтәреләләр һәм шуңа күрә җитәкче дә булып китәләр. Өченче, соңгы этабы — үзаң этабы. Ул озак дәвам итә. Бу чорда төрле шәхесләр, партияләр, халыклар, милләтләр көрәшне киң җәелдереп җибәрәләр; күбрәк тәрбия, уку, укыту, тарихны тирәннән өйрәнү кебек мәсьәләләр калкып чыга, чөнки милли үзаң бары тик чын, дөрес тарихыбызны барлап, аны халыкларга җиткерү белән бик нык бәйләнгән. Үз чиратында бу мәсьәлә тарихи хәтер, фикер, сүз белән үзара тыгыз бәйләнгән. Боларны җимерү халыкны төшенкелеккә китерә, аның рухи көчен зәгыйфьләндерә. Ахыр чиктә ул золмәт чылбырларын, явызлыкны җиңә алмас хәлгә, яңарышка өметне өзүгә китерә. Халыкның милләт булып яшәве дә куркыныч астына куела. Үзаң чоры, икенче төрле итеп әйткәндә, фикер, хәтер, сүз, тарих чоры ул. Бары тик иректе, фикерле, хәтерле, үз әйтер сүзе булган халыкның гына, яңарыш этабын узып, бәйсезлек баскычының иң югары басмасына күтәрелә алуы көн кебек ачык.

«Список осужденных по делу «Казанский филиал Султангалеевского центра. 11 мая 1932 г.[41]

1. Абдрахимов Гали Шакирович — 5 лет концлагеря

2. Аитов Ибрагим Сулейманович — 3 года концлагеря

3. Ахмедов Шигаб Шарафутдинович — 5 лет концлагеря

4. Ахмадуллин Абдулла Валеевич выслать на 3 года в Северный район

5. Биккулов Ибрагим Замалетдинович — 5 лет концлагеря

6. Садри Джалял — 5 лет концлагеря

7. Вахитов Лутфулла Шагабутдинович — 5 лет концлагеря

8. Вафин С. — 5 лет концлагеря

9. Закиров Хабибрахман Валеевич — 5 лет концлагеря

10. Исхаков Гани Исхакович выслать на 3 года в Северный район

11. Латыпов Шун Салихович — 5 лет концлагеря

12. Мустакаев Каюм Рахимович — 5 лет концлагеря

13. Сулейманов Баки Ш. выслать на 3 года в Северный район

14. Фахрутдинов Кутдус выслать на 3 года в Северный район
15. Хасанов Ахмет Гарай — 3 года концлагеря
16. Хуснутдинов Гайбас — 3 года концлагеря
17. Шейх-Али Асгар — 5 лет концлагеря
18. Валидов Заялетдин — 5 лет концлагеря».

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] ЦГАИПДРТ. — Ф.8239. — Арх. 2-10024.

[2] Разумов Михаил Осипович (Арханцев Арон) (1894—1937) — Партия эшлеклесе. Петроградта Октябрь революциясендә катнашучы. 1919—1920 елларда Одесса хәрби округының сәяси идарә башлыгы. Соңрак ВКП(б)ның Орел (1922—23), Башкортстан (1923—27) һәм Татарстан (1928—33) өлкә комитетларында беренче секретарь. 1933 елдан Көнчыгыш Себер край һәм Иркутск өлкә комитетларының беренче секретаре. Репрессияләр чоры корбаны.

[3] Лепа Альфред Карлович (1896—1937) — 1933—1937 елларда Татарстан ОКВКП(б)ның беренче сәркатибе. Гаепсезгә репрессияләнә. ВКП(б)ның өлкә комитеты секретарьлыгыннан азат ителә, партиядән 1937 елның август пленумы чыгара, шул ук вакытта республиканың эчке эшләр комиссары П.Г.Рудьны, Совнарком рәисе К.Абрамовны, шәһәр башкарма комитеты рәисе В.А.Фомичевны, шәһәр комитеты секретаре В.А.Баскинны, оештыру бүлеге җитәкчесе В.Х.Андерсонны, прокурор Е.М.Лейбовичны, Г.Г.Байчуринны, Вольфовичны, Г.П.Тикны партиядән чыгаралар. (Кара: *Султанбеков Б., Лепа А.* Штрихи к политическому портрету // Коммунист Татарии. — 1988. — № 6. — С. 87.

[4] Галим Мөхәммәтҗанов (1908—1938) Казан губернасы Буа өязендә Бездна авылында туган. Комсомол эшләрендә актив катнаша. 1936 елның гыйнварында ул өлкә комитетының икенче секретаре итеп сайлана, ә 1937 елның 24 октябрендә кулга алына. Ул «Татар яшьләренең террор оештыру оешмасы»н төзүдә гаепләнә. Аны диверсия оештыруда да гаеплиләр. Нәтиҗәдә 1938 елның 10 маенда СССРның Югары хәрби суды коллегиясе ябык утырышында РСФСР УКның 58—2, 58—7, 58—8, 58—11 маддәләре нигезендә югары җәзага — атарга хөкем ителә, ул шул ук көнне атыла. 1957 елны реабилитацияләнгән.

[5] Соңрак бу исемлек тагын да киңәйтелә.

[6] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8239. — 2-10024. — С.33—43.

[7] Каэр — контрреволюцион.

[8] Шунда ук.

[9] Кара: ЦГАИПДРТ. — Ф.15. — Арх. 843. — Оп. 1. — С.50.

[10] *Вәлиев Р.* Болак арты республикасы. — Казан, 1999.

[11] Шунда ук.

[12] *Султанбеков Б.* Сталин и «татарский след». — Казань, 1995. — С. 30.

[13] Мирсаид Султан-Галеев. Статьи, выступления, документы. — Казань, 1992. — С. 421.

[14] *Султан-Галеев М.* Избранные труды. — Казань, 1998. — С. 539.

[15] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8239. — Арх. 2-10024. — С. 35—36.

[16] И.С.Аитовның әйтүенә караганда, ул 7 ел дәверендә «Казанское Общество Взаимного Кредита»ның рәисе булып тора, ә «Яңа китап» Облисполком һәм СНК, ЦИК РТның булышлыгы белән эшли.

[17] *Сәйфуллин Х.* Алтын-көмеш таш иде — алабута аш иде // Шәһри Казан. — 2000. — 14 март.

[18] ЦГАИПДРТ. — Ф.15. — Оп.1. — Ед. хр. 1098. — С. 160.

[19] Тайны национальной политики ЦКРКП. Стенографический отчет Секретного Совещания ЦКРКП. 1923. — Казань, 1992. — С. 28, 30, 60.

[20] *Сәйфуллин Х.* Алтын-көмеш таш иде — алабута аш иде // Шәһри Казан. — 2000. — 14 март

[21] Беренче милли фонд 1917 елда төзелә. «Милли сармая» 1918 елда бетерелә. Моны Үзәк мөселман социалистлары комитеты эшли. 70 меңнән артык алтын акчаны алалар. Аның башында М.Вахитов тора. Икенче тапкыр бу мәсьәләне — фонд төзүне — Мостафа Сәбхи күтәреп чыга. Революция җиңелгән очракта рус коммунистлары оешкан төстә подпольега китә алачаклар, ә шәрык коммунистларының мондый мөмкинлекләре юк, ди. Менә шуның өчен фонд төзеп, аның акчасын чит ил банкында саклау мәсьәләсен куя. Аның тавышын бер кеше дә ишетми. Өченче тапкыр бу мәсьәләне Баймбәтов күтәрә. Ул моны «татар-башкорт» проектының хәле белән бәйли. Подпольега китәргә туры килер, ди. Дүртенче мәртәбә бу мәсьәләне М.Солтангалиев үзе күтәреп чыга. Бу хәл Советларның X съездында фракциянең җиңелүеннән соң була. Бишенчесе, әйтеп узганыбызча, Ю.Вәлидов төзегәне — «Фонд помощи голодающим Поволжья». (Кара: *Солтангалиев М.* Сайланма әсәрләр. — Казан, 1998. — 576—577 б.

[22] Архивно-следственное дело 2301. — Врем. фонд 2238. Архивно-следственное дело. — 853459; Врем.фонд 2238. — Т. 3 (Уфа. ОГПУ) — С. 99.

[23] Шунда ук. — 222 б.

[24] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8239. — Арх. 2-10024. — С. 63—69.

[25] *Вәлиев Р.* Фаҗига. — Казан, 1996. — 32—34 б.

[26] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8239. — Арх. 2-10024. — С. 73.

[27] *Вәлиев Р.* Фаҗига — 36 б.

[28] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8239. — Арх. 2-10024. — С. 77.

[29] Шунда ук. — 78—80 б.

[30] *Вәлиев Р.* Фаҗига — 42 б.

[31] Шунда ук. — 43 б.

[32] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8239. — Арх. 2-10024. — Т. 9. — С. 3—4.

[33] Шунда ук. — Т. 1. — 355 б.

[34] Мирсаид Султан-Галеев. Статьи... — С. 468—489.

[35] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8239. — Арх. 2-10024. — С. 4.

[36] ЦГАИПДРТ. — Арх. 6851. — С. 40.

[37] *Гайнетдинов Р.Б.* Тюрко-татарская политическая эмиграция: начало XX века — 30-е годы. — Набережные Челны, 1997. — С. 126.

[38] Мирсаид Султан-Галеев. Статьи... — С. 489.

[39] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8239. — Арх. 2-10024. — Т. 7. — С. 210.

[40] ЦГАИПДРТ. — Ф. 292. — Оп. 2. — Арх. 464. — С. 1—2.

[41] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8233. — Оп.1. — Д. 2-10024. — Т. 4. — Л.3.

ӨЗЕЛГӘН ДОГА

Тарихи һәм әдәби әсәрләрдә шактый урын алган, әмма аңлашылып бетмәгән, капма-каршы бәяләмәләр алган *вәисиләр хәрәкәте* XXI гасыр башында, бөтен Җир шарында демократиянең үсеп, таралып, ныгып барган чорында, дөрес һәм гадел бәяләүне таләп итә. Бүген моңа бөтен мөмкинлекләр дә бар.

XIX һәм XX гасырларда бу хәрәкәткә карата төрле-төрле карашлар булды, уртак фикергә килә алмадылар, ә СССР яшәгән дәвердә моңа мөмкинлекләр дә булмады.

Вәисиләр турында күпсанлы мәкаләләр язып, китаплар нәшер иттеләр. Шулардан Н.Е.Федосеев, А.Я.Аросев, А.Молоствов, Н.Ф.Катанов, А. һәм М.Сәйдәшевләр, А.Килдишев, Л.Н.Толстой, И.Наживин, Г.Тукайларның хезмәтләре һәм әсәрләре җитди урын алып тора.

Октябрь инкыйлабыннан соң бу хәрәкәт турында В.Тихомиров, Я.Шейнкман, Г.Гордеев, Л.Климович, Н.Смирнов, М.Сәгыйдуллин, К.Нәҗми, З.Ишмөхәммәтов, К.Дәүләтшин, И.Нуруллин, Р.К.Вәлиев, М.Мөлеков, С.Алишев, И.Ионенко, И.Таһиров, Ф.Нуретдинов һ.б.ларның хезмәтләре дөнья күрде. Бу исемлеккә С.Малышеваның, Д.Усманованың һәм алман галиме М.Кемпернең мәкаләләре дә килеп кушыла.

Бу хәрәкәтне өйрәнүгә чит ил галимнәреннән Ш.Келькеже, Р.Гароди, А.Беннигсен да үзләреннән зур өлеш керттеләр. Алар хәрәкәткә тоталитар режим чорында да дөрес бәя бирергә тырыштылар.

Гомумән алганда, *вәисиләр хәрәкәтенә* өч дәвердә: Октябрь инкыйлабына кадәр, тоталитар режим чорында һәм хәзерге демократиягә омтылу чорында төрлечә бәя бирелде. Беренче ике чорда әлеге хәрәкәткә «община», «секта», «шайка», «ишанизм», «мюридизм» кебек ярлыклар тактылар. Алгарак китеп әйтсәк, әле бүген дә аларга «вахабизм» кебек ярлыкны тагарга әзер торучылар да юк түгел.

Кайберәүләр аны «крестьяннар хәрәкәте» яисә дин байрагы астында барган милли азатлык хәрәкәте дип тә атыйлар. Мидхәт Вәисев исә үзе соңгы фикерне хуплады. XIX гасырның 60 нчы еллар башында ук әйтелгән бу фикер, гомуми алганда, дөрес булса да, ул социаль гаделлек өчен дә көрәшкән *вәисиләр хәрәкәтенә* берьяклы караш булыр иде. Аяныч ки, әмма М.Вәисев бу хәрәкәтнең йөзьеллыгы көннәрендә, тоталитар режимның кабат котыра башлаган чорында, аңа башкача бәя бирә дә алмый иде шул. Ул елларда *вәисиләр хәрәкәтеннән* хәтта демократик эчтәлек табу да коммунистик идеологиягә, Совет хакими-

ятенә каршы «көрәш» булып бәяләнде. Шуңа күрә тарихчы-галимнәрнең күбесе бу хәрәкәтне әйләнеп узуны кулай күрде, икенчеләре исә хәрәкәтнең асылын белми торып тәнкыйть кенә иттеләр. Фәкать шулай эшләгәнгә генә тарихчыларның, әдәбиятчыларның күңелендә, эшендә, гаиләсендә тынычлык булды.

Әмма шәхес культы фаш ителгәннән соң, сәяси дөньяда беразйомшаклык туган елларда, *вәисиләр хәрәкәте* тарихчыларны, әдәбиятчыларны яңадан кызыксындыра башлый[1].

«Октябрь Казанда» монографиясе авторларының фикерләренә караганда, икенче рус революциясе чорында демократик позициядә булган *вәисиләр хәрәкәте* халыкларның гомум демократик хәрәкәтенә кушылып китә. Тарихчы-галимнәр Р.Вәлиев, М.Мөлековлар да, шул ук фикерне куәтләп, *вәисиләр хәрәкәтен* өйрәнүгә үзләренең өлешләрен керттеләр[2].

Архивларның да тиз арада яңадан ябыла башлавы фикерне үзгәртә алмады — йөк үз урынында кала бирде.

Республика партия архивында кандидатлык диссертациясен язу өчен материаллар җыйнап йөргән көннәрнең берсендә (1966 ел булырга тиеш) мин Вәисевләрнең берсе — М. Вәисевнең үзе белән дә танышкан идем. Кызганычка каршы, мин ул вакытта әле эшли генә башлаганлыктан, вәисиләр хакында бөтенләй диярлек хәбәрсез идем. Шуңа күрә бу хакта аңардан сораша да алмадым. Хәер, хәзер инде аларга кагылышлы бөтен язмаларны укып танышып була, теләгең һәм вакытың гына булсын.

М.Вәисев ул вакытта «Габдулла Тукай һәм Сәрдар Гайнан Вәисев» исемендәге китабын язу өчен материаллар җыя иде. Шул танышудан соң берничә көн узгач, мин аны очраклы рәвештә Ленин урамындагы Лобачевский һәйкәле урнашкан бакчада очраттым. Бу соңгы күрешүебез булды. Без беркадәр сөйләшеп тә утырдык. Ул Мәскәү хәлләрен сөйләде, ә мин аспирант тормышыннан зарландым. Шулай сөйләшә торгач, ул, миңа төбәп карап:

— Рәмзи, син ничек уйлыйсың, әгәр дә мин Нуруллинны судка бирсәм?— диде.

Минем өчен бу һич тә көтелмәгән, сәер сорау иде. Мин, аптырап китеп:

— Кайсы Нуруллинны? — дидем берни дә аңламыйча. Мин Ибраһим Нуруллинның мәкаләсен укымаган идем шул...

Ул күзлеген сөртә-сөртә, киң җилкәләрен уйнатып, миңа ышанмыйчарак:

— Ибраһим Нуруллинны, — диде. — Ул Баһаветдин, Гайнанетдин Вәисевләргә пычрак ата, «шайка Ваисова» дип, хәрәкәтне бозып күрсәтә, — дип, тагы әлләниләр сөйләп китте.

Ибраһим абый белән мин һәрвакыт дус, аңлашып, хәл-әхвәл сорашып, университетта бергә эшләдек. Шуңа күрәдер инде, мин дә, шактый кызып китеп, Ибраһим абыйны бу бәладән коткарырга тырыштым.

— Менә, Мидхәт абый, безнең татар шулай инде ул — берсен берсе мактыйсы урында сүгә яисә судка бирә. Ярамый, кирәкми, Мидхәт абый, — дидем. Минем белән килешкән кебек булган иде ул, әмма бүген, архивлардагы документлар белән танышкач, мин эшнең башкачарак булганын аңладым[3].

Ничек аерылып китүебез төгәл генә истә калмаган, әмма М.Вәисев кыю, көчле, гадел кеше буларак хәтердә саклана. Шушы очрашудан соң ул үзенең язган хезмәтләрендә, хатларында, мәкаләләрендә мине буржуаз (ул вакытта шулай әйтелә иде. — *Р.В.*) тарихчылар белән бер рәткә куйса да, вәисиләргә карата бирелгән минем бәяләмәне хуп күргән иде. Ул вакытларда Ш.Келькеже, А.Беннигсен яисә Гародилар белән бер фикердә булу ничек куркыныч булганлыгын үзебез генә беләбез. 70 нче елларда боларның үземә һәм гаиләмә «файдасы» булмады дип әйтә алмыйм.

М.Вәисев урта буйлы, киң җилкәле, кара чәчле, гайрәтле кеше иде. Ул вакытта аңа 60 яшьләр булгандыр. Әлеге чорда вәисиләр турында мәгълүматыбыз бик ярлы булды, чөнки аларга «сектантлар», «Совет хакимияте дошманнары» дигән ярлыклар тагып өлгергәннәр иде инде.

Тәҗрибәле, өлкән яшьтәге тарихчылар да вәисиләр хакындагы материалларны әйләнеп узарга, китапларга, диссертацияләргә кертмәскә киңәш итәләр иде. Хәер, әле бүген дә, хәл башкачарак булса да, татарның үзәктәге бу кайнар тарихын өйрәнергә теләүчеләр бик аз...

Совет чорына караган өлеше бөтенләй өйрәнелмәгән килеш кала бирде, чөнки чын тарих яшерелде яки бик яшерен фондларда атом бомбасыннан да катырак саклandылар.

Мидхәт һәм Хаҗәр Вәисевләрнең М.Сусловка, М.Горбачевка, Г.Усмановка, XXVII съезд исеменә язган хатлары да моңа дәлил булып торалар. Алар *вәисиләр хәрәкәтен* дөрес итеп язуны таләп иттеләр. Бөтен теләкләре фәкать шул иде.

Мәгълүм булганча, *вәисиләр хәрәкәте* XIX гасырның 60 нчы елларында башланып китә. Бу хәрәкәткә хәзерге Яшел Үзән районының Мулла Иле (Молвино) авылының күренекле кешесе Баһаветдин Вәисев[4] нигез сала. Ул, Аллага, Коръәнгә таянып, татар халкының яшәешенә туры килердәй яңа «дөреслек»кә корылган чын мөселман дәүләте концепциясен төзи һәм «Фирка-и Наҗия» исемендәге коткару партиясен дә оештыра. Б.Вәисев һәм аның иптәшләренең патшага, хакимият органнарына язган «изге аңлатмалары», мөрәҗәгатьләре сакланып калган. Бу тарихи документлар әлеге хәрәкәтнең үсешен аңларга мөмкинлек бирәләр. 1874 елда аларның «Тарих-и хөҗҗәтин» (Хаҗилар юлы), 1907 елда «Җаваһиру хикмәти дәрвишан» (Дәрвишләр хикмәте җәүһәрләре) исемле әсәрләре басылып чыга. Шушы хезмәтләрендә вәисиләрнең җитәкчеләре бу хәрәкәткә нигез салалар. Б.Вәисев үзен «Алла сугышчысы» дип атый һәм «Вәисиләр

иланн полклары» (Божьи полки) төзү эшен җайга сала. Аның төп фикере үзбилгеләнүгә, бөтен халыклар өчен тигезлеккә, шәхесләрнең хокукларын һәм милкен саклауга юнәлдерелгән була. Бу мәсьәләне хәл итү өчен Болгар дәүләтен, шул замандагы яшәешне торгызу да җитә дип раслый. Ул татарларның Идел буе болгарларының дәвамы булуларын һәм шуңа күрә шушы җирдә үз дәүләтләрен төзергә хаклы икәнлекләрен исбат итә. Вәисев патша хөкүмәтенә түли торган салымнардан бары тик Болгар ханлыгын (Казанны. — *Р.В.*) яулап алынгач кертелгән җир налогын гына түләргә чакыра, чөнки без болгарлар, ди ул[5]. Калган налогларны түләмәскә, патша армиясендә хезмәт итмәскә өнди. Уфа Диния нәзарәтенең указлары белән санашмаска чакыра, чөнки алар патшага сатылганнар. Татарлар болгарларның дәвамы, шуңа күрә аларның Идел буе болгарларының җирләрен кире кайтарырга һәм шушы җирләрдә бәйсез дәүләт — Болгарстанны төзергә хаклары барлыгын исбат итә. Мәсьәләнең шулай куелышы аның тарихны яхшы белгәнлеген күрсәтә. Чыннан да, татар халкы элек-электән үз дәүләтен төзегән, көрәшкән, тормыш иткән. Шулай итеп, М. Вәисев беренчеләрдән булып, бөтен Русия алдында татар халкы өчен үзбилгеләнү, дәүләтчелек мәсьәләсен күтәреп чыга, шуның өчен көрәш җәелдерә. Бу максатны ул Ислам дине байрагы астында гына тормышка ашырып булачагын кисәтеп куя.

Вәисиләрнең руханиларга мөнәсәбәте дә билгеле. Б. Вәисев, үзенең оешмасын төзегәнче үк, руханиларны, хакимияткә тәлинкә тотучы муллаларны көчлеләр алдында баш игәннәре, изелгәннәрне якламаганнары, Ислам диненең чисталыгы хакында онытулары өчен тәнкыйть итә. Шуңа күрә аларга баш имичә, бары тик «Вәисиләр илаһи полкы» җитәкчесенә, аның җитәкче органнарына гына буйсынуны таләп итә. Мәсьәләне болай кую мөселман руханилары тарафыннан вәисиләрне эзәрлекләүләргә, мыскыл итүләргә китерә. Б.Вәисев урамнан узганда аңа хәтта таш ату, көлү гадәткә кереп бара. Менә шундый мөгамәләләрдән соң, үз сүзендә тора торган көрәшче буларак, Б.Вәисев үзенең «Вәисиләр илаһи полкы»н төзеп, бу оешмага кабул итү тәртипләрен дә җайга сала. «Илаһи полк»ка кабул ителүче һәрбер вәисигә махсус «Изге присяжный лист»лар бирелә. 1908 елда нәшер ителгән «Изге присяжной лист»та «Илаһи полк»ның әгъзасы *«отделяется от светских народов и общества, светских властей и от человеческих уставов и законов, а именно, обязан исполнять природный духовный, божьего издания святой закон Коран-илмизит и шаригата Мухаммед (т.е. науку о Коране и законоустановления Мухаммеда. — Л.К.) и признавать во всех отношениях и обязательствах»*[6] диелә. «Присяжной лист»ның эчтәлеге түбәндәгечә:

«Всего мира государственный молитвенный дом мяктяб-гирфан, т.е. мусульманская академия и автономное духовное уп-

равление и канцелярия сотрудника всего мира духовного отца Сардара староверского о-ва мусульман ваисовского божьего полка, в городе Казани, по 5-й части. Существует с 1862 года. № 33078.

Автономного духовного правления сотрудник всего мира, начальник ваисовского божьего полка староверского мусульманского общества — Сардар Ваисов извещает... губернии ... области ... страница ... уезда ... волостному правлению ... деревни, член ваисовского божьего полка староверского общества мусульман ... эль-Бургари (т.е. «ал-Булгари» — потомок и наследник поволжских булгар. — Л.К.) из ... сословных списков выключить в звание, согласно его титулу особы, а именно: «не татарин, не крестьянин, не мещанин, не дворянин и не потомственный гражданин, «а ... исполнитель природного духовного лица староверского общества мусульман, ваисовского божьего полка и имеющий миллет Ибрагим Халиулла (т.е. принадлежащий к вере Авраама, друга божьего. — Л.К.), имеющий веру святого Ислама мухаммеданской религии Ханафии Имам Агзамский, секта Агли-Сюннет Вельджемогет суннитский (т.е. принадлежащий к суннитам ханифитского толка. — Л.К.) обряда как есть мухаммеданский, по сословию турки, Эльмисагдан Берли мусульман, из древни беспрепятственно молящиеся только одной святой молитвой, святой веры ислам, на своих собственных устах, по правилам святого Корана, на основании святого шаригата и согласно святому отечеству, повелевающий указам бога и царя, не повинующийся ни в каком отношении Оренбургскому татарскому собранию, муфтию, мулле и ахуну. Староверское общество мусульман, ваисовского божьего полка, точно так же отделяются от татар-крестьян, как небо от земли и вода от огня, и точно так же не подчиняющиеся ни в каком отношении светским гражданским властям, кроме духовной верховной власти, на основании... святого божьего издания текста Корана...

Ввиду изложенного объяснения, согласно божьего издания святого закона, автономное духовное правление, канцелярия сотрудника всего мира — Сардар духовный отец Ваисов, «Божьего полка», староверского мусульманского общества, нашел нужным дать сведения и заявления, необходимые для того, чтобы над верноподданным членом нашего ваисовского «Божьего полка», мусульманином-старовером не допускать ни в каком-либо отношении насилие и произвол со стороны ... администрации, не узнавшей достаточного его убеждения, и точно так же со стороны татар и прочих национальностей не должно допускаться никакого насилия административной власти-начальства. Ввиду этого данного фактического обстоятельства вместе — одновременно сего святого сведения и заявления возвращается выданный ... документ, паспорт и после этого ни в каком списке и

в бумаге не называть звания, кроме вышеизложенных званий, подпись члена ваисовского «Божьего полка»: ...

С подлинным верно: подпись начальника — сотрудника всего мира ваисовского «Божьего полка», староверского общества...».

Абдулла Килдишев, өч ел дәвамында Гайнан Вәисев һәм аның иярченнәре белән якыннан аралашып яшәгән вәиси буларак, «Гайнан Вәисевнең тозагы» исеме астында нәшер ителгән китабында «илаһи полк»ка кабул ителгәннәргә үзләрен ничек тотарга кирәклеге хакында түбәндәгеләрне күрсәтә:

«1) Если вас будут звать в какое-либо правительственное учреждение, то повесток не принимайте и не подписывайте, потому что для сношения с правительственными учреждениями у нас имеется собственная канцелярия, в которой нужные сведения можете получить от своего духовного отца-руководителя (Сардара).

2) Если по крайней необходимости вам придется посетить правительственные учреждения, то шапки там не снимайте; войдя же, громко троекратно произнести славославие божие. Если вас будут допрашивать, какое это учреждение, кто вы, что делаете, какой вы веры или секты, или сословия, то громко ответьте: «Я не татарин, не крестьянин, не раскольник, не идолопоклонник, а от татар мы отличаемся так, как небо от земли или как огонь от воды, ибо мы, дескать, не смешиваемся с ними ни в чем и ничего с ними не имеем общего ни в уме, ни в думах. Мы между собою образуем, дескать, староверческое общество мусульман, ваисовский «Божий полк». Я — веры мухаммеданской, религии по уложению имама Агзама Ханифы, исповедания суннитского, обряда как есть мухаммеданского со времени завета с Богом и повинуюсь только начальству одной верховной духовной власти, а не гражданской власти».

3) Против постановления вы протестуйте, говоря: «Мы не подведомственны начальству гражданской власти, и вы не имеете права постановлять против нас решение». Хотя бы не принимали ваших протестов, вы твердо стойте на своем, и вам ничего не сделают. Вы не можете браниться, напр., так: «Вы — антихристические собаки и религиозные разбойники, достойные всех тысяч проклятий и анафем».

4) Кто не следует за нами, тех мы именуем татарами и приравниваем их к язычникам, вроде огнепоклонников-татар Монголии; крещеных же татар и татар, не имеющих никакой религии, мы мусульманами не называем.

5) Если будут спрашивать, почему не посещаете мечетей, то отвечайте им: «Ваши мечети — мечети вреда, а в мечеть вреда Бог Всевышний ходить не велел. У нас нет никакого желания пускать в ваших мечетях на ветер, точно пыль, наши молитвы. Мы жалеем вас, что вы обольщаетесь, говоря: «У нас есть свои мечети и медресе, и вы — мусульмане». Многого не-

достает вам, чтобы быть настоящими мусульманами: во-первых, у вас на руках — русские паспорта; во-вторых, вы отдаете своих сыновей в солдаты, а в-третьих, вы повинуетесь каждому правительственному учреждению. Что же касается нас, паспорта у нас — свои собственные, солдат мы не даем и налогов мы не платим. Если вы не придете к нашему Сардару, т.е. главарю, и не присягнете ему, не возьмете у него паспорта и не станете ему повиноваться, — то ни один из вас не мусульманин. Хотя бы вы без крыльев летали по воздуху и без лодки ходили по воде, — не будет вам спасения. Время еще есть, если вы им не воспользуетесь, придет время, когда правительство закроет ваши мечети и медресе, и тогда Сардар вас к себе уже не примет; впрочем, он может принять, если вы внесете все свои суммы в кассу, себя сделаете его рабами, а жен — его служанками. В недалеком будущем последует о нас от царя указ, и тогда выяснится разница между исламом и неверием, мусульманами окажутся тогда лишь те, кто присягнул на верность службы главарю спасительного отряда».

«Тем из ваисовцев, которые подлежали призыву в армию, давалось такое наставление:

«Придя на прием, шапки не снимай, не раздевайся, на стан не поднимайся и никаких законов и инструкций не признавай. Когда все-таки возьмут, то не принимай ни солдатских одежд, ни оружий, не ешь солдатской пищи; всему противься, — и под конец тебя отпустят: «На одну лошадь двух хомутов не надевают: мы служим царю своими молитвами, мы — друзья его друзей и враги его врагам. Если бы не было на свете нас, спасительного отряда ваисовского «Божьего полка», то не существовать бы миру. Благодаря нашим благословленным молитвам, живут все от мала до велика, от простого человека до царя»[7].

Шулай итеп, ул үзенең дингә, хакимияткә булган мөнәсәбәтен ачык итеп әйтә, аңлата.

Вәисиләр үзләре турында *«Без татар да, крестьян да, расколчылар да, потка табынучылар да түгел, ә татарлардан без, җир күктән, су уттан ничек аерылса, шулай аерылабыз... без үзара искечә мөселман ышанучылар җәмгыятен барлыкка китерүчеләр — «Вәисиләр илаһи полкы»... Приемга килсәң, бүрегеңне салма, чишенмә... бернинди законнарга, инструкцияләргә буйсынма»*[8] диләр.

Шулай итеп, ирекле, гадел, чиста динле Болгарстан төзү мәсьәләсе акрын гына патша хөкүмәте белән көрәш юлына күчә. Вәисиләр бүрекне салуны, баш июне Алла алдында, Коръән каршында гына кирәк диеп саныйлар. Бу хәрәкәт, феодализм чорындагы башка хәрәкәтләр кебек үк, дингә реформа ясап, динне «чистартып», аны хакимияткә ышанмый, буйсынмый торган, Алла тарафыннан җибәрелгән идеология итеп карап, хокуксызлык,

гаделсезлекләр белән көрәшкә чакыра, аны «дереслек һәм гаделлек патшалыгы» дип атый.

Тарихта моңа беркадәр охшашлы хәрәкәт XV гасырның беренче яртысында Чехиядә һәм Словакиядә дә була. Бу хәрәкәт гуситлар исемен йөртә. Аның җитәкчеләре Ян Гус, Иероним Пражский, Ян Жижка һ.б.лар була. Алар, католиклар чиркәвенә, феодализм чорындагы көчләү һәм изүләргә каршы көрәшеп, реформалар уздырырга телиләр, ләкин 1437 елны җиңеләләр. Реформаның идеологы — католик чиркәү дошманы, немец көчләүләренә каршы көрәшкән Ян Гус бүген Чехиянең милли герое.

Күренекле көнчыгыш белгече Л.Н.Климович, вәисиләргә бәя биреп: *«Все требования ваисовцев имели вполне земные корни... содержание... заключалось не в вопросах догматических, в которых ваисовцы ... не выходили за рамки ортодоксального суннитского Ислама, а в их политической платформе. Последняя была отражением чаяний зажатого в помещичьи и государственные тиски пореформенного крестьянина (и ремесленника-кустаря), который стремился к своему действительному освобождению. Видел он его в отказе от всего того, что было для него кошмаром, т.е. в отрицании податей, продажного суда, воинской повинности, казенного духовенства с его поборами и т.п. ... Отражая недовольство широких крестьянских ремесленнических масс существующим режимом, движение ... всегда находилось в зависимости от данного состояния этих масс».*

Икенче рус тарихчысы, Шәрык белгече Е.В.Молоствова Б.Вәисев хакында түбәндәгене яза: *«По отзывам всех лиц, еще помнящих старика Багаутдина, это был человек очень высоких нравственных качеств и большой эрудит. Первоначальное образование он получил при медресе в Казани, затем ездил на Восток... не пропуская случая пополнить свое образование беседами с учеными единоверцами и покупкой редких книг и рукописей»*[9].

Б.Вәисев җитәкчелегендәге хәрәкәт Мулла Иле авылында һәм тирә-як авыл халкы арасында башланып китә. Яшел Үзән районы Карашәм авылында вәисиләр зираты Түбән Чалу дигән җирдә урнашкан. Анда әле бүген дә каберләр өстендә ташлар саклана. Соңгы елларда кемдер үзенең бабасы кабере өстенә чардуган да куйган иде. Үзем бу авылда туып үскәнлектән, бу турыда кайбер хәбәрләрне олылардан ишетеп белә идем. Озак еллар дәверендә указлы мулла булып, колхозда күп тир түккән бабам — Нәбиулла Вәлиевнең (1878—1967) — алар хакында сөйләгәннәрен хәтерлим. Ул Вәисев идеяләре белән янып йөргән Шиһабетдин Ибәтуллин һәм тагын (хәтеремдә калмаган. — *Р.В.*) әллә кемнәрнең исем-фамилияләрен атаган иде. Аның авылда вәисиләр белән авыл халкы арасында булган бәрелешләр турында сөйләгәнен хәтерлим.

— Әнә аларның зиратлары да бар, — диеп, кулы белән Түбән Чалу ягын күрсәтә иде бабай.

Хәер, ул үзе дә шул Түбән Чалу ягында күмелгән. Аның кабере елганың уң ягында булса, вәисиләрнеке — сул ягында. Шунысы да кызык: 1881 елда, бабама дүрт яшь чагында, вәисиләр үзләренә каберлек өчен урын бирүне таләп итәләр. Күрәсең, алар моңа ирешкәннәр дә. Патша хөкүмәте дәүләтчелекне бирмәсә дә, зират урынын бирергә җәлләмәгән. 1881—1882, 1889—1890 елларда булып узган бәрелешләрдә карашәмлеләрдән Г.Ибатуллин, Г.Бикчәнтәев, Җ.Галиуллин, Ш.Рәхмәтуллин, М.Вәлидов, Г.Сәйфетдин, М.Мөхәммәдъяров һ.б.лар актив катнашканнар.

Б.Вәисев үзен XIV гасырда яшәгән суфи Нәкшбәндинең варисы дип игълан итә. Нәкшбәндинең тәгълиматы Кавказда, Төркиядә һәм Көньяк Азиядә киң тарала. Бу хәрәкәтнең әгъзалары эре җир хуҗаларына каршы көрәшәләр. Вәисиләр дә Русиядә феодалларга һәм югары дин әһелләренә каршы көрәштә үз иярченнәрен табалар. **Алар, чын мөселман кешесе өчен иң кадерле байлык — рухи байлык, диләр.** Шуңа күрә калыкны агарту, укыту кирәклеген аңлап, мәдрәсә ачу мәсьәләсен дә күтәреп чыгалар. 1881 елның 12 августында мәдрәсә ачу хакында Вәисев гариза яза, әмма, төрле сәбәпләр табылып, моңа рөхсәт бирелми. Янәсе, ул гаризасында «российский» диясе урынга «всей России» дип язган, «Государь милоствейший» дигән фраза төшеп калган, ә имзасы, татарча язылып, русчага тәрҗемә ителмәгән икән. Нәтиҗәдә, тагын әллә нинди сәбәпләр табып, гаризага тискәре җавап бирелә. Әмма Вәисев моның белән генә туктап калмый, әлбәттә, 1862 елда Казанда рөхсәтсез «Мөселман академиясе»н (Всего государства молитвенный дом, мяктябе гирфан), автоном (мөстәкыйль) Диния нәзарәтен ачып җибәрә. Аның яшел байрагында ярым ай һәм биш кырлы йолдыз балкый. Монда урта мәктәп, югары уку йорты (мәдрәсә), типография, нәшрият, Диния нәзарәтенең идарәсе, бөтендөнья хезмәткәре — Ислам диненең ышанычлы атасы Сәрдар Вәисев Баһаветдиннең канцеляриясе эшли башлый. 1552 елдан соң татар халкы тарихында бу беренче мәртәбә Русиядә бәйсез автономия игълан итү факты була. Бу бәйсез туфракта (территориядә) ярым ай һәм йолдыз белән бизәлгән яшел байрак та күтәрелгән.

XIX гасыр башында Казан губернасындагы крестьян восстаниеләренең *вәисиләр хәрәкәте* тәэсирендә оешканлыгы хәзер инде күпләргә мәгълүм. Нәтиҗәдә хәрәкәт үзе дә яңа үрләргә менә, ныгый. Шул чорда Петербургта нәшер ителә торган «Слово» газитендәге мәкаләгә караганда, вәисиләрнең саны 1908 елда 15 меңнән артык була. Казан жандарм идарәсенең полиция департаментына җибәрелгән хәбәрендә вәисиләрнең бигрәк тә Казан, Оренбург шәһәрләрендә күп булулары әйтелә. Алар шулай ук Урта Азиядә дә булганнар[10]. Аларның «Фирка-и Наҗия» исемле партиясе үз заманында мөселманнар арасында иң көчле партия-

нең берсе булган дисәк тә дөрестер. Ә Идел буе халыкларының сәяси оешмалары бары тик февраль инкыйлабыннан соң гына оештырылганлыгы мәгълүм.

1884 елдан соң вәисиләр Россиянең төрле зинданнарында, каторгаларында җәфа чигәләр. Николай Евграфович Федосеев Забуддинов дигән крестьян белән Санкт-Петербургның «Кресты» зинданында очрашканын һәм аның белән сөйләшкәнен искә ала. Забуддиновның сүзләре буенча, ул крестьяннар хәрәкәтенең җитәкчесе булган, иярченнәре белән бергә налог түләүдән баш тарткан. Шул чорның вакытлы матбугатында да бу турыда шактый материал тупланган.

«Каһарман бабайлар» исемле китапның авторы Сәлам Алишев Идел буе татарлары белән хакимият арасындагы каршылыкның көннән-көн үскәнен исбат итте. Бу вакытта *вәисиләр хәрәкәте* бигрәк тә Свияжск, Тәтеш өязләрендә киң таралган була. Нәкъ менә шушы хәрәкәтләр һәм хакимияткә буйсынмау сәясәте Б.Вәисевне «юләрләр йорты»на ябуга бер сәбәп була да инде. Ул елларда 300 дән артык гаиләне Себергә — каторгага куалар.

Патша хөкүмәтенең урындагы һәм үзәктәге органнары бу хәрәкәтне бастыру, нәтиҗәдә юкка чыгару эшләрен акрын гына, сыналган алымнар белән әзерлиләр.

1882 елның август-сентябрь айларында ул «Казанская окружная лечебница во имя божьей матери», кыскасы, «юләрләр йорты»на килеп эләгә. Монда аның сәламәтлеген Карпов фамилияле врач тикшерә.

Вәисевнең күрсәтмәләренә караганда, аны монда китерү алдыннан төнлә белән сәгать дүрттә кемнәрдер ул яшәгән йортның ишекләрен кагып, ватып киткәнлекләрен әйтә. Шушы вакыйгадан соң ул полициягә мөрәҗәгать итеп, аларны кисәтә. Әгәр дә тагы шулай кылансалар, мин корал кулланачакмын, ди. Моңа җавап итеп, иртәгесен берничә кеше ияртеп полицейский килә һәм әшәке сүзләр белән сүгенәләр. Ул губернаторга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Губернаторга очрашуга килгәч, кабул итү бүлмәсендә ул Мосолов фамилияле полицейский начальнигы белән бәрелешә.

Мосолов, аны күргәч:

— Ага, Ваисов, тебя давно пора убить, — ди, ә Б.Вәисев, аңа карап:

— Господин полицейский, мин сине инде 20 ел беләм. Син ничә кеше үтердең?— ди.

Мосолов кылычын чыгарырга маташа, кылана, куркыта... Менә шуннан соң Вәисев урамга чыгып бераз көтеп тора, чөнки кабул итү бүлмәсендә бер татар карты Вәисевнең хәлен күреп елап җибәрә. Ул чыкмый, һәм Б.Вәисев китеп бара.

Шушы вакыйгалардан соң аны психбольницага көчләп озаталар. Тикшерү вакытында аның исән-сау икәнлеге раслана һәм аны «дөреслек һәм Ислам» өчен көрәшкәненә әзәрлекләүләрен дә ачыклыйлар.

Врачлар язып калдырган чыганакта түбәндәге юллар бар: *«Он спокойный, приветливый, держится с достоинством... говорит по-русски плохо, но спокойно, вразумительно, сознанием человека знающего цену своим словам»*. Ул азрак больницада булуга каршы килми, әмма нигә монда китерүләренә гаҗәпләнә, чөнки аны бернинди сәбәпсез урамда барганда полицейскийлар тотып, көчләп алып киләләр. Монда ул үз бүлмәсендә күбрәк вакытны дини китаплар укып уздыра, прогулкага чыга. Табиб Карпов белән әңгәмә вакытында ул үзе турында: *«Минем төп вазифам гаделлек һәм дөреслекне, Исламга ышануны саклау, Алла законнарын саклау, аңлату һәм ялганчылык белән көрәшү... мин дәрвиш, табигый якты фикер иясе, Алла сугышчысы, миңа үлгәнче отставка юк»*, — ди.

Нәтиҗәдә 1882 елның 23 сентябрендә табиб В.Карпов аны исән-сау дип таба, һәм больницадан чыгара. Әмма урындагы хакимият органнары аның артыннан күзәтүне дәвам итәләр һәм аны яңадан «божья лечебница»га озату юлларын әзерлиләр. Моңа ике ел вакыт җитә. Билгеле булганча, 1884 елда Б.Вәисевнең академиясе, штабы урнашкан йортның югалган иске хуҗасын җылы яклардан табып кайталар. Тиздән йортны хуҗасына кайтару файдасына суд карары да чыгарыла. Менә шуннан соң инде бу карарны тормышка ашыру нияте белән суд приставы бернечә кеше белән Б.Вәисев йортына килгәч, аларны ишегалдына да кертмиләр. Б.Вәисевнең шәкерте Г.Халидов аңлашу теләге белән чыккач, алар аны этеп, калитканы ачып, ишегалдына бәреп керәләр. Бер полицейский Г.Халидовны аягыннан чалып еккач, ачуы чыккан Б.Вәисев үзенең шәкертләре белән ишегалдына чыгып, бер полицейскийны башына таяк белән сугып ега, ә шәкертләр полицейскийларны артларына типкәләп, капкадан чыгарып аталар. Шуннан соң капканы ябып, анда баррикада ясыйлар, эчке яктан ныгыталар. Имән баганалар белән әйләндереп алынган академияне туздыру бик үк җиңел булмый. Полицейскиларга ярдәмгә хәрби наряд та килә.

КӨРӘШТӘШЕ ШИҺАБЕТДИН БАБА

XIX гасырның 80 нче елларында, Б.Вәисев вафат булганнан соң, аның эшен Гыйззәтулла Хәмидуллин, Габдуллатыйф Хәмит улы (хатынының этисе), Сәетбаттал Хәбибулла улы, Нәҗметдин Ишмөхәммәт улы Ижбаев, Шиһабетдин Сәйфетдиновлар дәвам итәләр[11]. Алар барысы да хакимият органнары тарафыннан бертуктаусыз эзәрлекләнеп киләләр. Аларның кайберләренә хәтта психбольница тирәсендәге квартирага керү дә тыела. Күрәсең, хакимият органнары аларны Б.Вәисев белән контактка керерләр дип уйлаганнардыр. Б.Вәисевнең эшен дәвам итүчеләрдән иң күренеклесе, мөгаен, Карашәм авылы крестьяны (хәзерге Яшел

Үзән районы) Шиһабетдин Сәйфетдинов булгандыр. Шушы авылның Зюмагуловның улы Ш.Сәйфетдинов 1861 елның 19 декабрендә туган.

XIX гасырның 90 нчы елларында Ш.Сәйфетдинов зур активлык күрсәтә. Бу турыда «Волжский вестник» һәм «Московский вестник» гәзитләрендә кызык материаллар нәшер ителгән. 1891 елның 16 июнендә чыккан «Московские ведомости» гәзите битендә урнаштырылган хәбәрдән без шул ук елның 15 июнендә суд булганлыгын беләбез. Ш.Сәйфетдиновның эшен суд палатасы карый. Гәзитнең язуына караганда, ул вәисиләр сектасының *«вредный учение»*сен таратуда гаепләнә. Ул моны хатлар тарату юлы белән эшли. Бу хатларда ул налог түләмәскә, судның карарлары белән санашмаска, төрле хакимият карарларына буйсынмаска киңәшләр бирә, аларны хакимиятнең чын вәкилләре дип санамый. Суд вакытында ул, суд рәисенә мөрәҗәгать итеп: *«Мине кем хөкемгә тарта? Нинди диндә?»* Җавап алгач, ул, кычкырып: *«Мин мондый судка буйсынмыйм, инкарь итәм»*, — ди[12]. Ул бары тик Аллага, аның вәкиле Мөхәммәдкә, Коръәнгә, «Илаһи полк» җитәкчесе Б.Вәисевкә генә буйсынганлыгын раслый.

Нәтиҗәдә суд аны, бөтен хокукларыннан мәхрүм итеп, Себергә сөргенгә җибәрү хакында карар кабул итә. Моңа кадәр Ш.Сәйфетдинов берничә мәртәбә судка хөкемгә тартылган була. 1889—1890 елларда ул губернаторга, мировой судьяга, Казан психбольницасының директорларына һәм башка хакимият органнары әгъзаларына төрле тупас сүзләр әйткән өчен башта ике айга, аннан соң дүрт айга хөкем ителә. Шуннан соң аны Себергә җибәрү турында карар кабул ителә. Ул аннан 1894 елның августында качып, туган ягына кайта. Беркадәр Мулла Илендә торганнан соң, ул Казанга килә һәм яңадан хакимият органнары белән бәрелешә. Нәтиҗәдә 1894 елның октябрендә ул Н.Ижбаев һәм М.Бәйрәмгалиевләр белән хөкемгә тартылып, башта 25 тапкыр таяк белән сугуга хөкем ителеп, өстәвенә каторгадан качканлыгын искә алып, аңа тагын өч ел каторга өстиләр. Аны туган ягына кайтудан мәхрүм итеп, Сахалин утравына озаталар[13].

Ш.Сәйфетдиновның язуына караганда, аны 1895 елның сентябрендә Казаннан Мәскәүгә, ә 1896 елның февралендә Сахалин утравына җибәрәләр, һәм ул анда 29 апрельдә генә барып җитә. Монда да ул пропаганда эшләрен туктатмый, киресенчә, актив рәвештә дәвам итә. Мәскәүдә һәм урындагы хакимият органнарына үзенең «изге гаризалары»н җибәреп тора. Ул анда үзенең гаепсезгә газап чиккәнлеген, Б.Вәисевнең идеяләренә тугрылыклы булып калганлыгын гына түгел, Вәисев башлап җибәргән изге хәрәкәтнең дәвам итүчесе икәнлеген исбат итә. Сәйфетдинов үзенең бу эшкә Вәисев тарафыннан «җаваплы наместник» һәм бөтен «Илаһи полк»ның вакытлыча җитәкчесе дип игълан итә. Безнең фикеребезчә, ул Гайнан Вәисевнең әле яшүсмер икән-

леген дә искә алып шулай эшләгәндер. Соңрак, Гайнан һәм Газизҗаннар да үсеп өлгергәч, ул алар белән кулга-кул тотышып, Б.Вәисев ... өчен көрәшә. Сахалинда чагында аның тырышлыгы нәтиҗәсендә Петр Морозов гаиләсе белән Исламны һәм вәисиләрнең идеологиясен кабул итә. Сахалин утравының руханиена язган «Изге аңлатма»сында аның П.Морозовка юкка бәйләнгәне хакында ассызыклый. Ул Исламны кабул итеп дөрес юлга чыкты, ә сез *«и ваш христианский народ табак курят, водки пьет, свинина мяса ест и чожими бабами на пасха цолоется и голяет, и рука дают, и миста пляшут и всякий поген делает. А вы им же по домам ходете и собираете коски их. А это не видите? Ведь Морозов тебе ничего не говорил и не заскарбил вас: и даже здоровался, дал вам чисть. А вы как скот начинаете заскарбить среди улица, без факта особенно в настоящий время слобод вера религое по указа Его Императорского величества...»*[14]. 163 тән артык «Изге заявление»ләрендә ул, тагы башка мәсьәләгә дә кагылып, үз заманының кыю фикерле көрәшче икәнлеген күрсәтә.

1906 елны ул, Казанга кайтып, сәүдә белән шөгыльләнә. 1909 елда тагын хөкемгә тартыла. 1910 елның 28 гыйнварында икенче хатыны янына барып яши башлый. 1911 елны янә ел ярымга хөкем ителә.

Октябрь инкыйлабыннан соң ул, Гайнан Вәисев, Хуҗиәхмәт Гыймадетдин һәм башка вәисиләр белән берлектә, Идел буе мөселманнарының хәрби полкларын төзүдә актив катнаша. 1920 елның 4 гыйнварында алар М.В.Фрунзенең сорауларына җавап бирәләр. Бу интервью Самарада чыга торган «Коммуна» газитендә «Пробуждение Востока» исеме астында дөнья күргән[15].

ГАЙНАН ВӘИСЕВ ҺӘМ ЛЕВ НИКОЛАЕВИЧ ТОЛСТОЙ

XX гасыр башында хәрәкәтне Гайнан Вәисев җитәкли башлый. Ул 15 яшендә үк крестьяннарның кораллы чыгышларында актив катнаша, шуңа күрә аны 1894 елда Себергә, ә 1895 елда Сахалин утравына сөргенгә сөрәләр. Казанга ул 1904 елда гына кайтып төшә[16].

Гайнан Вәисев тиз арада хәрәкәт белән җитәкчелек итүне яңадан үз кулына ала һәм аның эшчәнлеген тагын да көчәйтүгә ирешә. 1907 елда ул «Дәрвишләр хикмәте җәүһәрләре» исемле китап нәшер итеп чыгара — әтисенең мирасын татар халкына кайтара. Бу китапта *вәисиләр хәрәкәтенең* концепциясе бәян ителә. Аның фикеренчә, бөтен бозыклыклар «бозык тормыштан» килә. Моңа бары тик урындагы хакимият органнары, сатучылар, администрация һәм мәчет гаепле. Болар белән көрәшү өчен бары тик Коръәнне һәм аның тәгълиматын корал итеп алырга кирәк, ди. Урындагы начальствоны ул «дәҗҗал булышчыла-

ры» дип атый. Шуңа күрә ахырзаман килер, ди. Гайнан Вәисев үзен Сәрдар-коткаручы — «Алла сугышчысы» дип игълан итә. *«Минем сүземә ышанмаучыларны үлем көтә, тәүбә итәргә соң булачак»*, — ди. Гомумән алганда, ул үзен Алла тарафыннан җибәрелгән сугышчы, коткаручы дип атый[17].

XX гасыр башы татар халкы өчен киеренкелекнең артуы һәм демократик көрәшнең яңа үрләргә менеп, патша хөкүмәтен дер селкеткән чоры дип исәпләргә була. Шуңа күрә 1906 елның 12 августында Министрлар Советы рәисе Столыпин бөтен тәртипсезлекләр һәм либераль реформаларга каршы көрәшне төп мәсьәлә итеп куя.

Мәгариф министры Толстой да демократиягә каршы һөҗүмен көчәйтә: *«Инородецларны укытуның соңгы нәтиҗәсе... аларны урыслаштыру һәм рус халкына кушу»*[18], — ди.

П.А.Столыпин мөселманнарның хәтта дин иреге өчен көрәшен дә патша хөкүмәтенә каршы көрәш дип тамгалый. Шуңа күрә ул аеруча Идел буенда барган вакыйгаларны күзәтү астына алып, татар халкының азатлык өчен алып барган көрәшен бастыруга бөтен көчен биреп эшли. Шул мәкерле ниятен тормышка ашыру һәм ахырынача җиткерү өчен ул әледән-әле махсус киңәшмәләр уздырып тора. Алар яшертен рәвештә уздырыла. 60 нчы елларда ук бу киңәшмәләр турында тарихчы-галим Рәфикъ Нәфыйгов үзенең монографиясендә язып чыга, тик моңа тарихчылар гына игътибар бирмәде. Дөрес, алар Столыпинның аграр сәясәтен тәнкыйтьләде, ә менә реакцион милли сәясәте фаш ителмәде. Югыйсә бит шул киңәшмәләрнең берсендә: *«Возвращаясь к Поволжью, в частности, к Казанскому краю, я не могу не отметить, что к этой местности, местности с инородческим населением, колеблющимся, как сказано, между русско-православным и татарско-мусульманским влиянием, должны быть направлены серьезные усилия к пресечению национально-татарского натиска. Отказаться от этой борьбы значило бы отказаться от своих вековых исторических задач, отрицательные последствия чего неисчислимы... не подлежит сомнению, что в настоящем деле все правительственные силы должны быть мобилизованы, так как важность государственных задач очевидна»*[19].

Нәтиҗәдә 1910 елның 12—19 гыйнварында яңа «махсус киңәшмә» уздырыла. Аның исеме дә җисеменә туры килә: «Идел буендагы татар-мөселман тәэсиренә каршы чаралар әзерләү буенча махсус киңәшмә». Монда *вәисиләр хәрәкәте* турында махсус сөйләнмәсә дә, урыслаштыру һәм татар-мөселман хәрәкәтенә каршы көрәшү төп мәсьәлә була.

Столыпинның башка өлкәләрдәге сәясәте дә киң халык массалары, бигрәк тә алдынгы интеллигенция тарафыннан кискен рәвештә тәнкыйть ителә. Аңа тагылган «Асучы-премьер», «Столыпин галстуклары» кебек кушаматлар шул турыда сөйли.

Л.Н.Толстой да аңа карата үз бәясен биргән. Мәгълүм булганча, Толстой Кырым кампаниясе вакытында Севастопольдә, булачак премьерның этисе А.Д.Столыпин белән танышып, дуслашып китә, һәм аларның бу дуслыклары 1899 елга кадәр — аның үлеменә кадәр дәвам итә. Шуңа күрә Л.Н.Толстой аның улы П.Столыпин хакимияткә килгәч тә, аңа дусларча хат язарга да теләге була, әмма төрле сәбәпләр аркасында хат язылмый кала. Ниһаять, Столыпинның нинди сәясәт алып барганын күргәч, Л.Н.Толстой түзми, аңа 1909 елда хат яза. Анда мондый юллар бар: *«Пишу вам об очень жалком человеке, самом жалком из всех, кого я знаю теперь в России — человек этот вы сами. Давно уж хотел писать вам и даже начал письмо писать вам не только как брату по человечеству, но как исключительно близкому мне человеку, как к сыну любимого друга*[20]*. Но я не успел окончить письмо, как деятельность ваша все более и более дурная, преступная, но теперешней вашей деятельностью вы уже завершили ту ужасную славу, при которой всегда, покуда будет история, имя ваше будет повторяться как образец грубости, жестокости и лжи»*[21].

Ул шулай ук чиркәүне дә тәнкыйть итә. *«Гоголь ищет бога в церковной вере, там, где он извращен»*, — ди. 1909 елның 7 мартында ул: *«Безнең тормыш, безнең бай классларның туктаусыз урлау һәм талау белән яшәүләре хакында язсаң яхшы булыр иде»*[22], — дип язып куйган. Л.Н.Толстой эзәрлекләүләр, асу, үтерү сәясәтен алып баручы Столыпин хакимиятенә карата фикерен ачык итеп әйткән. Заманында аның фикерләрен күпләр белеп торганнар һәм шуңа күрә Россиянең төрле-төрле төбәкләреннән аңа киңәшләр сорап язганнар. Чөнки ул дөреслек, гаделлек ягында була һәм, Русия сәясәтчеләреннән аермалы буларак, халыкларның азатлык, гаделлек өчен көрәшләрен, чыгышларын зур кызыксыну белән күзәтә. Мәсәлән, Мөбарәкша Гаделшинның хәрби хезмәттән баш тартуы анда һәм аның фикердәше И.Ф.Наживинда зур кызыксыну уята. Нәкъ менә шушы чорда ул *вәисиләр хәрәкәте* белән дә бик нык кызыксына һәм аның җитәкчесе Гайнан әл-Болгари белән очрашу мөмкинлекләрен эзли. Сәрдар Гайнан Вәисев белән очрашу турында сөйләшү өчен, рус язучысы И.Ф.Наживин 1908 елны Казанга махсус рәвештә килә. Нәтиҗәдә Иван Наживин һәм Гайнан Вәисев күрешеп аңлашалар. Бу очрашу турында Наживин болай диеп искә ала: *«Через несколько мгновений в сени вышел Сардар. Это был еще молодой мужчина в зеленом полосатом халате и белой чалме. Лицо его, украшенное темной, аккуратно подстриженной бородкой и длинными, висящими вниз усами, было спокойно и красиво: особенно хороши были большие серьезные глаза. Во всей его живописной фигуре чувствовалось какое-то особенное благообразие — результат глубокой внутренней работы над собой»*[23].

Менә шушы очрашу вакытында Гайнан Вәисев тә бөек рус язучысы — «бөек проповедник» белән күрешеп сөйләшәсе килгәнен белдереп: *«Мөмкин булса, мин үзем Ясная Полянага барып чыгар идем»*, — дигән фикерен әйтә.

И.Ф.Наживинның Л.Н.Толстойга язган хаты 1909 елның 15 гыйнварында килеп җитә. Шул ук конвертта Вәисев тарафыннан 1909 елның 7 гыйнварында Л.Н.Толстойга язган хаты да була. Ике хатта да Вәисевнең Толстой белән күрешеп фикер алышасы килгәнлеге хәбәр ителә. Хатларны укыгач, шул ук көнне Л.Н.Толстой аңа хат язып җибәрә. Ул анда:

*«Любезный брат Ходжа Мухаммед Гайнанутдинов Ваисов. Очень рад был получить письмо от И.Ф.Наживина о вашем желании приехать ко мне. Я уже давно желал узнать подробности о том, как вы понимаете Бога и жизнь человека на Земле. Потому, что слышал о вас, надеюсь, **что наши взгляды будут одинаковыми**. Если бы люди держались только истины, то все бы было едино. Будем же и мы стараться держаться только истины и потому быть едиными с теми, которые держатся ее.*

Очень рад буду видеть вас у себя. Приезжайте, когда хотите; я никуда не уезжаю»[24].

Шулай итеп, Л.Н.Толстой һәм Гайнан Вәисиев арасында дустанә бәйләнешкә юл ачыла. 1909 елның 11 февралендә алар Ачык Аланда (Ясная Полянада) очрашалар. *«Шушы көнне монда Сергеенко, Чертков, Андрей Львович дигән әһелләр белән берәттән Казан татары Вәисев тә килгән иде»*, — дип язып калдырган Л.Н.Толстойның секретаре. Гайнан Вәисевкә характеристика биреп: *«Бик гади, әмма оялчан түгел, иркен сөйли, әмма хаталар белән... Лев Николаевич, мин сине көттем, шатмын, ди. Ул Казанны искә алды, шәрык факультетында гарәпчә укыдым»*, ди.

Очрашудан соң икенче көнне, барлыгы алар өч көн сөйләшеп утыралар, Л.Н.Толстой үзенең көндәлегендә: *«12 февраль, 1909. Ясная Поляна. Бүген хатлар төзәткәләдем. Берсе материалист, бик үк начар булмады кебек. Кичә һәм бүген Вәисев, Сергеенко, Трегубовлар килделәр. Әйе, кичә үлеп баручы кешенең сүзләре тәэсирчән була икән дип уйладым. Бу нәрсәдән? Бу үлә торган кешенең әлеге дөнья турында уйлавыннан. Без бит бөтенебез дә үлә торганнардан. Дөнья турында уйлама — шулай ук синең дә сүзләрең тәэсирчән булырлар, әгәр дә сине тыңлаучылар синең дөньяви хәлләрдән ваз кичкәнеңне сизеп торсалар... Менә нинди боҗра: мәрхәмәтле тормыш, яхшы эшләр ышануны арттыра, ышану эшләр эшли. Моннан аңлашыла инде: ышану булмаганда аңа охшаганы — иң куркынычы ялганчылык — хакимиятләрдә, хәрбиләрдә, каракларда, судьяларда, ялган укытучыларда»*[25]. Очрашу барышында язылган бу фикерләргә Гайнан Вәисевнең дөреслек, гаделлек, мәрхәмәтлелек тарафдары булуы; саф ышанулары; хакимияткә, хәрби хезмәткә тискәре карашла-

ры тәэсир ясамый калмагандыр дип әйтеп булмый. П.Бирюковның сүзләренә караганда, вәисиләрнең хәрби хезмәткә карата булган мөнәсәбәтләре дә кызыксындырган иде, ди[26]. Ул *вәисиләр хәрәкәтенең* рухи нигезләре, тамырлары белән кызыксына. Алар Ислам дине хакында фикер алышалар. Л.Толстойның Коръәнне яхшы белгәнлеге күренеп тора. Аның китапханәсендә Парижда нәшер ителгән Коръән саклана. Нәтиҗәдә ул *вәисиләр хәрәкәтен* дини-реформаторлар хәрәкәте генә түгел, бәлки самодержавиегә, хакимияткә каршы сәяси, икътисади һәм милли азатлык хәрәкәте икәнен белеп кабул итә. Шуны да әйтергә кирәк, ул бу хәрәкәт белән соңгы көннәренә кадәр кызыксынып, сорашып тора, Вәисевнең язмышы өчен чын күңеленнән борчыла. Нигә дигәндә, бу чорда Казанда *вәисиләр хәрәкәтенә* каршы төрле яклап һөҗүмнәр оештырыла. Аеруча татар карагруһчылары чаң кага. Рус шовинистлары исә, учакка «керосин сибеп», янгын сүндерергә телиләр. Алар, вәисиләр сафыннан куылган «аферист» Кильдишевнең «Гайнан Вәисев тозагында» исеме астында нәшер ителгән язманы файдаланып, Вәисев һәм аның тарафдарларын судка тарталар. Нәтиҗәдә Гайнан Вәисев 1 мартта төрмәгә ябыла.

Шушы чорда да Л.Н.Толстой «Алла сугышчыларының» сәрдары (юлбашчысы. — *Р.В.*) Гайнан Вәисевкә рухи көч биреп тора. Ул 1909 елның 18 маенда язган хатында болай ди:

«Дорогой мой милый брат Ваисов.

Письмо ваше... порадовало и огорчило меня. Огорчило меня за тяжелое положение в котором вы находитесь, но порадовало более, чем огорчило. ***Порадовало тем, что из письма Вашего я почувствовал, что братство с Вами, к которому идут и придут все народы по вере в единый, общий для всех закон Бога: любви к нему и ко всем людям без различия.*** *Помогай Вам Бог и ваша вера в него перенести всю тяжесть Вашего положения. Пишите мне, не могу ли чем служить вам. Был бы рад.*

Любящий вас брат»[27].

Бөтен дөньяга танылган әдип, сүз остасы Л.Н.Толстойның һәрбер сүзе тирәннән уйланып язылган. Монда очраклы бер сүз яисә фикер дә юк. *«Сезне яратучы туганың, кирәк булса сезгә хезмәт итүгә дә шатмын»* дигән сүзләре Гайнан Вәисевне һәм аның хәрәкәтен якын итеп кабул иткәнлеген күрсәтә.

Шик юк, бу рус һәм татар халкының берсен берсе аңлап, бигрәк тә рухи яктан иң югары биеклеккә менә алган сәгатьләре, минутларыдыр.

Чыннан да, Л.Н.Толстойның *вәисиләр хәрәкәтенә* биргән бәяләмәсеннән чыгып фикер йөртсәк, ул халыкларның туганлыгын бер Алланы ярату белән бәйләп караган һәм *вәисиләрнең хәрәкәте* Г.Вәисевнең тәэсире нәтиҗәсе икәнлегендә шик юк. Ике проповедникның икесе ике яктан бер таякны тотып, берберсе белән аңлашканнары көн кебек ачык. Толстойны шул шат-

ландырган да. Башка диннәрне дә бик яхшы белгән Л.Н.Толстой Ислам диненең бөтен халыклар өчен дә уртак бер юл икәнлеген ассызыклап язган. Бу бит тарихи факт. Моның чыннан да шулай икәнлеген тагын бер факт раслый. Эш шунда ки, 1909 елның февраль ахырында булса кирәк, Тифлистә (Тбилиси) яшәүче Елена Ефимовна Векилева дигән бер хатын Л.Н.Толстойга киңәш сорап хат язган. Аның язуына караганда, аның ике улы да, берсе — Петербург технология институтының студенты, ә икенчесе — Мәскәү хәрби училищесында укчы юнкер, Ислам диненә күчәргә әниләреннән рөхсәт сораганнар. Ни әйтергә белмәгән Елена Ефимовна, күрәсең, Толстойның фикерен беләсе килгән. Балаларының татар халкына кушылып, аңа булышырга теләкләре барлыгын да язган, әмма моңа дин комачаулый, дигән ул[28].

Л.Н.Толстой, бөтен эшләрен ташлап, аңа шактый саллы хат язып җибәрә. Зыялы кеше буларак, туп-туры күчсеннәр яисә күчмәсеннәр дип язмый, әлбәттә, фәкать кирәкле информацияне генә бирә. Ул анда: «*Не знаю, известно ли вам и вашим сыновьям о двух известных мне учениях в магометанстве, которые стремятся к этой самой цели: освобождение высших основных истин от скрывающих их заблуждений и суеверий. Оба эти учения подвергались и подвергаются за это гонениям. Одно из этих учений — это учение бабистов, зародившихся в Персии, перешедшее в Турцию, где также терпело гонения и теперь сосредоточилось в сыне Багаулле, живущем в Анкаре. Учение это не признает никаких внешних форм богопочитания, считает всех людей братьями и признает только одну религию любви*[29]. *Другое учение возникло в Казани. Последователи его называют себя «Божьим полком» или «ваисовцами», по имени своего основателя. Эти люди также полагают сущность веры в делах любви и потому воздерживаются от участия во всех делах, противных любви, как-то податях, которые употребляются во зло, и от солдатства. Секта эта тоже гонима, и на днях только руководитель их был посажен в тюрьму.*

Очень буду рад, если мои советы пригодятся хоть на что-нибудь и вы или сыновья ваши известят меня о своем решении и своей дальнейшей деятельности»[30].

Әгәр дә чиркәү Л.Н.Толстойны бүген дә гафу итми икән (анафемасыннан ваз кичми. — *Р.В.*), моңа тагы да әле безгә билгеле булмаган сәбәпләр юктыр. Кем әйтә ала?

XX гасыр башы — төрле идеяләрнең, милли һәм гомум үзаңның үскән чоры. Русиядә генә түгел, Германия, Англия, Франция кебек илләрдә дә төрле-төрле очрашулар, конференцияләр, съездлар булып уза. Шуларның берсендә — Берлинда булып узган конференциядә — мөселманнардан Садретдин Максудов, Дәүләт Думасы депутаты буларак, бөтен Җир шарында гомумсолых, гомумкилешүләр төзү хакында сөйләргә тели. Ул үзе бу

турыда: *«Берлинга барыш. Англия сәяхәтеннән максатлар да башка иде,* — ди. —*Русия депутатларының анда торткан урыннары да башка. Мин анда нотык сөйләргә әзерләнгән идем. Хәзерге заманда дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә ИСЛАМНЫ файдаланып бөтен дөньяда «бердәм килешү», «гомумхәлне ныгыту» өчен моңа карата христиан диненең өлеше дә кертелергә тиеш кебек уйларымны сөйләргә теләгән идем. Аннан соң дәлилләр итеп Төркиядәге кансыз революцияне, Иран хәлләрен китермәкче идем, әмма күңелсез хәл килеп чыкты, сүзләремне әйтә алмадым. Нотыкны сөйләргә рөхсәт итмәделәр. Милюков миңа «Садри әфәнде, сез үзегезнең Русиядән килгәнегезне онытмагыз. Монда бәйнәлмиләл мәсьәләсен кую кирәкмидер, сез Истанбулдан, йә Тәһраннан килмәдегез» кебек сүзләр сөйләде. Тагын да төрле сылтаулар таптылар»*[31].

Дөреслек, гаделлек эзләү шулай итеп дөньяның төрле почмакларында дәвам итә, әмма аның дошманнары әле көчле, гайрәтле. Ислам илләрендәге революцияләр дә киләчәктә килешүләр, аңлашулар кирәклеген исбат итәләр, әмма аларны рус шовинистлары күрмәмешкә генә салышалар; күрергә, аңлатырга теләүчеләрне эзәрлеклиләр. Европа мөнбәрләрендә прогрессив фикерләр тыелган чорда Казанда, Казан Печән базары маклерларыннан, Килдишев, Сәйдәшевләрдән ни көтәргә икәнлеген чамалау бик үк авыр түгел.

Казан карагруһчылары Гайнан Вәисевкә һөҗүм оештыралар. Вәисевне кеше хатынын урлауда гаеплиләр. Аның турында төрле ялганнар тараталар. Хәтта махсус китаплар нәшер итәләр. Патша хөкүмәтенең эксперты Катанов, бу хәрәкәт хакында материаллар җыеп, аны бары тик «сектантлар» хәрәкәте итеп бәяли. Вәисиләр арасыннан төрле бозыклыклары өчен куылган Килдишевның да китабы аңа каршы язылган. Болар барысы да Столыпин, Милюков һәм татар карагруһчыларының татар-мөселман хәрәкәтен тыю сәясәтенең бер нәтиҗәсе икәнлеге билгеле. Чыннан да, вәисиләрне судка тарткач, анда шаһитлар булып Катанов, Разумов, мулла Садыйк Иманкулов, Килдишев, Сәйдәшевләр киләләр.

«Печән базары» һәм «Бәянелхак» идеологлары, шул исәптән Килдишев, Камаллар тәэсирендә туган Г.Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасындагы Дию образындагы Гайнан Вәисев, яисә Б.Вәисевкә генә юнәлдерелмичә, киресенчә, «хатынны урлады»лар, сату иттем, кичен зина кылып, көндез изге булып йөрүче сәүдәгәр «мөселман башын» тәнкыйтьли. Бу Башның соңгы зары — аның хатынын Дию урлап киткән икән. Кисекбаш татар сәүдәгәре булса, Дию образында Г.Тукай Гайнан Вәисевне күз алдында тота. Бөтен бәлаләрдән коткаручы — цирк көрәшчесе Карәхмәт. Шулай итеп, шагыйрь кызыклы һәм гыйбрәтле образлар тудыра. Моңа беркадәр Г.Тукайның әнисенең вәисигә кияүгә чыгуы һәм ул «мөрит»нең ша-

гыйрьгә карата ихтирам күрсәтмәгәнлеге дә тәэсир ясамый калмагандыр, мөгаен. Бу ир кеше — вәиси — әнисенә Г.Тукай белән очрашуны тыйган. Ул Газизә апасына язган хатында (1908, 27 март): *«Ул мөрит мине намәхрәм ят кеше дип бычылдап, мине әни белән күрештермәскә карар биргән икән»*[32], — ди. Соңрак алар арасында да җылылык урнаша. Бу эш шагыйрьнең тырышлыгы белән эшләнелгән. Менә шушы вакыйгалардан соң булса кирәк, 1908 елның 5 ноябрендә Г.Тукай «Кисекбашка гыйлавә» яза[33].

Рәт-рәт итеп гаскәрен куйгач тезеп
Һәм дә җиткезгәч аякка торгызып,

Шунда Сәргаскәр үзенчә бер горур
Берлә гаскәргә карап читтә торыр.

Бу «Кисекбаш»ны язып, мин дә шулай,
Аз гына мәгърурланып тордым бугай.

Буш вакытта рәткә тезгән җырларым
Булса, сафланды, димен, гаскәрләрем.

Көлкеле чыкты: ярарлык ул ягы,
Әмма бик яхшы түгел гармонь ягы.

Сарт китабыннан алынган үрнәге,
Назмы шуннан бик мөкәммәл булмады.

Мөнтазам булсынмыни соң гаскәрең,
Алгач үрнәккә Бохара гаскәрен!

1906 елның октябрь-ноябрь айларында «Бәянелхак» гәзите битләрендәге (№ 74, 78, 79, 81, 82) Гайнан Вәисев һәм Әхмәтҗан Сәйдәшевләрнең дискуссияләре моңа тәэсир ясаганлыгы билгеле. Ә.Сәйдәшев Гайнан Вәисевкә «Мөселман союзы» белән бергә кушылып хәрәкәт итәргә чакыра, әмма ул үз максатына ирешә алмый. Гайнан Вәисев баш тарта. Менә шушы вакыйгалардан соң Гайнан Вәисевкә карата мөгамәлә үзгәрә. Аңа һәм аның хәрәкәтенә пычрак ату кампаниясе киң итеп җәелдерелә.

Беренчедән, Гайнан Вәисев мөселманнарны бүлүдә гаепләнсә, икенчедән, «старовер», «автономное духовное управление» кебек терминнарны рус телендә файдалануда гаеп табалар.

«Старовер», «нестаровер» терминнарын реакцион руханилардан аерылуны гына аңлатса, терминнарның русча язылуы, Гайнан Вәисевнең фикеренчә, болгар халкының 400 елдан артык дәүләтчелек коронасын аларның башыннан каерып алып, аларны рус дәүләте поданныйларына әйләндергәнлектән икәнлеген әйтә. Шулай булгач, без бәйсезлеккә бару теләкләребезне, әлбәттә, рус телендә әйтергә мәҗбүрбез, ди. (Кара: *Вәи-*

сев М. Габдулла Тукай һәм Сәрдар Гайнан Вәисев. — М., 1979. — 44—53 б.)

Шагыйрь, «Кисекбаш»ка бәя биреп: *«Поэма көлке булып чыкса да, «әмма яхшы түгел гармонь ягы»,* — ди. Әлбәттә, монда гармонь дигәндә, сүз музыка турында түгел, ә аның эчтәлеге турында бара. Шагыйрьнең фикеренчә, монда чынбарлык дөрес итеп чагылдырылмаган. М.Вәисевнең фикеренә караганда, шагыйрь Гайнан Вәисевтән, вәисиләрдән генә, сатирик поэманың объекты булсалар да, көлгән дигән фикер тулы килеш дөреслеккә туры килми. Бу фикер белән дә килешми булмый, чөнки Г.Тукай үзе дә әсәре белән канәгать булмаганлыгы һәм аның фикере 1909—1910 елларда үзгәргәнлеге билгеле. Бу сәяси тормышның, милли хәрәкәтнең дә үзгәрүе белән бәйләнгән. Менә шуларның нәтиҗәсендә 1909 елда аның «Тәрәддәд вә шөбһә»се нәшер ителә. Бу икеләнү һәм шикләнү турында:

> Нәрсә күрдем бу җиһанда? Ни бетердем? Уйласам:
> Алдыма чын эз вә юлдан читкә тайганым килә.

Тагы үзенә-үзе риза булмыйча:

> Шигъреми яздым, басылды, мин тагын зур кайгыда:
> Фикеремә юк-бар белән исememне игълань килә.
>
> Һич риза булмыйм үземнән язганымнан соңра мин;[34]
> Һәр заман күз алдыма кимлек вә noksanым[35] килә.

Әле шул ук «Кисекбаш» өстәмәсендә дә:

> Шунда Сәргаскәр үзенә бер горур
> Берлә гаскәргә карап читтә торыр[36], —

ди.

Монда Сәргаскәр, икенче төрле итеп әйткәндә, гаскәр башлыгы — Сәрдар турында сүз бара. Сәрдар җитәкчене, командирны, юлбашчыны аңлата. Барыбызга да билгеле булганча, бу чорда Гайнан Вәисев үзе Сәрдар була бит инде.

Поэманың ни өчен уңышсызрак чыкканына да Г.Тукай, үзе ишарә ясап, бөтен бәла Бохарадан үрнәк алудан, ди. Поэманың үрнәге Сарт китабыннан булса, гаскәрнең дә үрнәге Бохара икәнлеге ап-ачык итеп әйтелгән: *«Тәртипле булырмыни соң гаскәрең, алгач үрнәккә Бохара гаскәрен».* Менә боларны искә алу Г.Тукайның вәисиләргә булган карашын дөрес итеп анализларга мөмкинлек тудыра. Күрәсең, бу үзгәрешләр Гайнан Вәисевнең бөек рус язучысы, дөреслек, гаделлек эзләүче Л.Н.Толстой белән очрашулар вакытына туры килә. Бу очрашу шул чорда нәшер ителгән китапларда да язылган. Шуңа күрә бу турыда Г.Тукай хәбәрдар булмагандыр дип әйтеп булмый. Шагыйрьнең Л.Н.Толстойга булган хөрмәте, ихтирамы билгеле. Л.Н.Толстойның үлеме шагыйрьне кайгыга сала. «Мөбарәк тәсбих өзелде» мәкаләсендә:

Ушбу яздырды нәсрән вөҗданымның көчләве,
мәсьәлә бик зур сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве, —

дигән фикер әйтә шагыйрь. Ул *«быел табигатьнең бөтенләй үзгәрүен, көзнең килә алмавын, җылы якка кошларның китмәвен — аларның нәрсәдер «табигатькә ят бер» хәл буласын белгән кебек»*, ди. *«Толстой вафат булды. Кояш йөзен чытты. Агалды. Инде көлми. Агар сулар дәфгатән бозландылар... караңгы, күңелсез, салкын»*[37].

Әдәбиятчылар һәм тарихчылар да, бу фактларга игътибар итмичә, вәисиләргә беркадәр объектив булмаган фикерләр тудырдылар. Шуңа күрә бу хәрәкәтне өйрәнгәндә, Л.Н.Толстойның һәм Гайнан Вәисевнең мөгамәләләрен өйрәнү кирәктер. Шулай ук Г.Тукайның да карашларын, фикерләрен искә алып кына аларга объектив бәя биреп була. Бу тарихи хәтерне яңарта һәм тарихи хәрәкәтләргә, аерым шәхесләргә, соңгы чиктә милли азатлык хәрәкәтенә дөрес итеп бәя бирергә мөмкинлек тудыра.

ИСЛАМ СОЦИАЛИЗМЫ

1917 елгы февраль инкыйлабы төрле сәяси һәм сәяси булмаган хәрәкәтләргә киң юл ача.

Каторга, ссылка, төрмәләрдә җәфа чигүчеләр ирекккә чыгарыла һәм аларның күбесе, туган якларына кайтып, яңадан көрәш юлына баса.

Гайнан Вәисев тә, тиз арада Казанга кайтып, *вәисиләр хәрәкәтен* җанландырып җибәрә. Ул большевиклар белән аралаша һәм алар белән бергә хәрәкәт итә башлый. Большевиклар да үзләрен гаделлек, ирек өчен көрәш тарафдарлары дип атыйлар. Алар шулай ук вак милләтләргә үзбилгеләнү хокукын да вәгъдә итәләр. Әлбәттә, бу лозунглар Гайнан Вәисевне һәм аның тарафдарларын большевиклар белән бердәм хәрәкәт итүгә китерә. Алар большевикларның лозунгларына чын күңелдән ышанып хәрәкәт итәләр, башка оешмалар белән дә тыгыз бәйләнештә торалар. Мөселман социалистлары комитеты (МСК) — шундый оешмаларның берсе. Аның белән ул чорда Һади Маликов тыгыз элемтә урнаштыра. Шунысы да кызык, Мулланур Вахитов үзе дә папахасында вәисиләр тамгаларын — биш кырлы йолдыз һәм ай сурәтен йөртә. Әлеге истәлекләрне М.Солтангалиев зинданда утырганда «О ваисовцах» исемендәге 18 битле язма-күрсәтмәсендә шактый кызыклы итеп тасвирлаган. *«В программной декларации,* — дип яза ул, — *ваисовцев после Февральской революции, т.е. еще до Октябрьской революции, наряду с лозунгами установления братства и солидарности между народами всего мира, без различия рас и национальностей, выставлялись также требования свержения царей и королей во всем мире, и не только коронованных, но и не коронованных королей золотого*

мешка, иначе говоря «ваисовцы» именуя себя «божьими воинами» и исходя из материалистического понимания и толкования учения Ислама, открыто заявляли себя сторонниками социальной революции».

М.Солтангалиев Сәрдар Гайнан Вәисевне, Газизҗан Вәисевне, И.Зәйнуллинны яхшы хәтерли. Гайнан Вәисевне ул беренче тапкыр II Бөтенрусия Мөселман хәрби съезды алдыннан булган фронтовиклар җыелышында очрата. Бу очрашу турында искә алып, *«Ул безнең чыгышлардан соң бик көчле, ялкынлы чыгыш ясады. Шул чыгышы вакытында ул, кесәсеннән Коръән чыгарып: «Менә мин кем исеменнән хәрәкәт итәм, менә кем исеме белән сезне гаделлек дәүләте* (Болгарстан. — *Р.В.*) *өчен көрәшкә чакырам...»* — диде. *«Бу кеше безнең тирмәнгә су койса да,* — дип дәвам итә тоткын Мирсәет: *Вакыты җиткәч, үз хәрәкәтенә татарның дини фанатикларын үз ягына тартачагын һәм киләчәктә аның безнең өчен куркыныч кешегә әйләнәчәген күрдем, чөнки вакыты җиткәч, үзен көчле итеп сизгәч, Коръәнне безгә каршы куячак. Аның белән сак булырга кирәклеген мин аның чыгышын тыңлау дәверендә күрдем, күренгәнчә,* **бу кеше зур рухи көчкә ия, тимердәй энергияле, курку белмәс, иң әһәмиятлесе — үзенең дөреслегенә көчле ышанучы — фанатик.** *Төрмәдә озак утырганлыктан, агарынган йөзе белән ул тарихи шәхесләрдән Маратны хәтерләтә һәм бу кеше каннан курыкмый, әгәр кирәк булса, теләсә нинди куркыныч белән санашмыйча аңа ташланачак».* Шушы вакыйгалардан соң Вәисев Петроградка бара, һәм аны анда В.И.Ленин кабул итә. Шул вакытта, аның большевиклар белән бергә хәрәкәт итәргә теләвен истә тотып, аңа бар эшләрендә булышлык күрсәтергә кирәк дип язылган «Записка» да алып кайта.

Бәлкем, шушы «Записка»ны истә тотып, аның тәэсирендә Карл Грасис, милли-хәрәкәтнең кара дошманы, хәтта Казан губернасын Сәрдар җитәкчелегендә ханлык итеп игълан итәргә кирәклеген әйткән иде, ди М.Солтангалиев. Шулай итеп, К.Грасис вәисиләрне Казанның, Уфаның, Оренбургның татар-башкорт милләтчеләренә каршы куеп сугыштырырга теләмәгәндер дип әйтми булмый. Грасисның мондый уйдырмаларга бик мастер булганлыгы да билгеле. «Болак арты республикасы» авантюрасы да аның тәэсире астында эшләнгәне барыбызга да мәгълүм.

Солтангалиевнең күрсәтмәсе буенча, К.Грасисның бу тәкъдименә ул каршы төшә, чөнки Сәрдар Вәисев хан итеп игълан ителә калса, аның кулыннан «җиңел эләккән хакимият»не кире алуы авыр булачак. Әмма вәисиләрне файдалану сәясәте дәвам итә, һәм аларны шушы вакыттан башлап коралландыра да башлыйлар. Бу хезмәттәшлеккә Казан демократиясе үзенең канәгатьсезлеген белдерә. Мөселман социалистлары, бигрәк тә эсерләр, бу эшкә каршы төшәләр һәм алар Я.С.Шейнкманнан вәисиләрне коралсызландыруны таләп итәләр. Шулай ук алар вәиси-

ләрне нинди сәбәпләр белән коралландыруларын аңлатуны сорыйлар. Шуны да истә тотарга кирәк, бу — Казанда II Мөселман съезды эшләгән көннәр. Билгеле булганча, 1918 елның 8 гыйнварыннан башлап съезд эшли башлый. Анда «Идел-Урал өлкәсе»н төзү мәсьәләсе дә карала. 1917 елда башланып киткән бердәмлек шул көннәрдә большевикларга зур булышлык күрсәтә — «Идел-Урал өлкәсе» игълан ителми кала[38]. Вәисиләрнең булышлыгына таянып, большевиклар шушы татар-башкорт халыкларының язмышын хәл иткән көннәрдә съездның җитәкчеләреннән И.Алкинны, Җ.Алкинны, Г.Токымбетовны кулга алалар. Сукыр ышану белән большевиклар җырын җырлый башлаган Гайнан Вәисевнең дә эшләре хөртиләнә. Ул ике ут арасында кала. Беренчедән, большевиклар аңа вакытлы «иярчен» итеп кенә карыйлар, ә икенче яктан, милләтчеләр һәм чын демократия өчен көрәшүчеләр, Гайнан Вәисевнең хәрәкәтенә каршы чыгып, аның белән көрәшәләр.

Большевиклар белән якынлык, бер яктан, «сәяси сукырлык» булса, икенче яктан, аларның ялган лозунгларына ышану *вәисиләр хәрәкәтен* үлемгә дучар итүе бары тик вакыт факторына гына бәйләнгәнлеге көн кебек ачык. Менә шулай итеп, большевик-шовинистлар, аеру, бүлү, алдау сәясәтенә таянып, милли хәрәкәтләрнең һәлакәтен әзерлиләр.

Вәисиләр, большевикларның үзбилгеләнү лозунгысына ышанып, «Идел-Урал республикасы»н түгел, «Болгарстан» дәүләтен булдырырга телиләр. Болгарстан идеологына булышлык күрсәткән булып кыланган большевикларга аларның икесенең дә кирәкмәгәнлеге инде хәзер барыбызга да мәгълүм.

1917 елга әйләнеп кайтсак, монда бик кызыклы материаллар бар. Бигрәк тә гомуммилли кризис өлгереп килгән чорда, *вәисиләр хәрәкәте*, көчле хәрәкәткә әйләнеп, анархиягә каршы протест йөзеннән бөтен изелгән халыкларны колонизаторлар сәясәтенә каршы тынычлык һәм үзбилгеләнү өчен көрәшкә чакыра. Большевиклар да бу хәрәкәткә зур игътибар биреп, алар белән аралашып, 1919 елга кадәр аны үз сәясәтләре өчен файдаланалар.

Октябрь революциясе алдыннан Гайнан Вәисев «Керенскийга протест» җибәрә. Бу протестны 1917 елның 10 августында большевикларның «Рабочий» гәзите тулы килеш нәшер итә. Анда түбәндәге юллар бар:

«1) мы, ваисовские воины — Волжско-булгарских мусульман, протестуем против войны до победного конца и до полного разгрома врага;

2) мы требуем немедленного прекращения кровавой братоубийственной бойни, требуем немедленного мира без аннексий и контрибуций;

3) требуем созыва конференции из представителей всех разграбленных империалистами, капиталистами народов для

восстановления их законных прав на началах самоопределения;

4) требуем освободить захваченные империалистами Англии, Италии, Германии, Америки и прочими земли: Индостана, Африки, Азии и др»[39]. Протест шундый сүзләр белән тәгәлләнә: *«Должен быть конец зверству, царству фараонов»*.

Большевик Милх, гомуми бәя биреп, вәисиләр, Октябрь революциясе алдыннан үзләрен Вакытлы хөкүмәткә каршы куеп, аларның фронтларын җимерүдә, какшатуда актив булдылар, ди. Я.С.Шейнкманның тормыш иптәше дә, Гайнан Вәисевне искә алып: *«Ул бик кыю рәвештә июль вакыйгаларыннан соң Керенскийга хат белән мөрәҗәгать итте һәм анда: «Сезне хакимият исертте; сез изелгән эшчеләрнең һәм социализмның дошманына әвереледегез; Иске Романовлар заманындагы хокуксызлык калды»*, — дигән сүзләренә игътибар итә. Ул шулай ук иренең Гайнанны хөрмәт иткәнлеген яза, исполкомда бергә сөйләшеп утыруларын искә төшерә: *«Гайнан Вәисев безнең юлдан бара иде. Ул буржуазия белән көрәште, төрмәләрдә утырды, ссылкада булды. Шулай ук мөселман буржуазиясен фаш итте, Кызыл гвардиягә булышу өчен Яшел гвардия төзеде»*[40].

Чыннан да, аларның хәрәкәте гомуммилли кризис чорында үзен хакимияткә каршы куеп, милли һәм сәяси хәрәкәтнең үсешенә, Вакытлы хөкүмәтнең тагы да хәлсезләнүенә үз өлешен керткән.

Гайнан Вәисев, кызганычка каршы, бөтен хәрәкәте белән чын күңеленнән революциягә, социализмның матур лозунгларына ышанып, үзенең булачак дошманнары (аңа кабер казучылар. — *Р.В.*) белән кулга-кул тотынып хәрәкәт итә. Большевиклар исә аңа бары тик вакытлыча иярчен итеп кенә карыйлар, файдаланалар.

Чыннан да, большевиклар, хәйләкәр сәясәтчеләр буларак, аннан һәм башкалардан бик оста файдаланалар. Авыр минутлар, сәгатьләр артта кала барган саен, аларның вәисиләргә карашы да үзгәрә. Вакыты җиткәч, барысына да богау салыначагын алар яхшы беләләр.

Октябрь инкыйлабы җиңгәннән соң да бу аралашу дәвам итә. Шунысы кызык: Гайнан Вәисев үзе актив рәвештә социализм идеясен пропагандалый. Бу эшне дә ул Коръән һәм Аллаһы Тәгаләгә таянып эшли. 1918 елның 24 гыйнварында ул «Знамя революции» гәзитендә «Значение социализма и к чему он приведет» дигән мәкаләсен бастыра. Ул анда: *«Хәзерге инкыйлаб Аллаһ кушуы белән үсә. Туганнар, зур кыюлык һәм түземлек белән социаль реформаларны тормышка ашырыгыз һәм советлар хакимиятен төзегез! Әгәр дә сез, туганнар, социализмга каршы барсагыз, моның белән сез Аллага каршы барасыз. Бөтен көчегез белән социализм өчен көрәшүчеләргә булышыгыз, чөнки киләчәктә котылу юлы шул гына»*, — дип язып чыга. Нәкъ

менә шушы вакытларда Гайнан Вәисев үзен «Ислам социалисты» дип игълан итә һәм эшче, солдатлар, крестьяннарны саботажниклар, алдакчылар белән көрәшеп, Совет хакимиятен ныгытырга чакыра. Ул Совет хакимиятен «Батыр» дип атый һәм вәисиләрнең аның яклы икәнлеген ачык итеп әйтә[41].

Бу сәясәт 28 февральгә — Гайнан Вәисевнең үтерелгән көненә кадәр дәвам итә.

* * *

1918 елның 28 февраль төнендә, югарыда күрсәтелгән II Мөселман съездының җитәкчеләре кулга алынганнан соң, Казан чынлап кайный башлый. *«28 февраль иртәсендә,* — дип яза «Йолдыз» гәзите, — *Казан мөселманнары мәйданга вә окружной хәрби комитеты тарафына җыелдылар. Бу җыелышта кулга алынган кешеләрне азат итү таләбе куелган. Әгәр азат итмәсәләр, бөтен Казан мөселманнары мәхбүсләр янына барып, үзләре азат итәргә әзер торганнар. Бу вакытта Екатеринская урамына 10 меңләп кеше җыелган, мөселман штабы, мәхбүсләрне азат итүне сорап, Советка вәкилләр дә җибәргән. Шулай итеп, Казан мөселманнары арасында зур ризасызлык, гауга куба. Астыртын эш иткән көчләр, киеренкелекне тагы да көчәйтү теләге белән, Совет хакимияте белән көрәшергә теләмәгән, битарафлык саклаган вәисиләргә каршы коткы таратуны дәвам итәләр»*[42].

Бу вакытта вәисиләр штабы Нариман урамындагы йортта урнашкан була. (Кайбер мәкаләләргә караганда, Г.Тукай урамындагы бу 92 нче йортта хәзер 22 нче почта бүлекчәсе эшли.)[43]

Оешманың җитәкчесе Гайнан Вәисев яңа төзеләчәк җөмһүриятне «Татарстан» дип түгел, «Болгарстан» дип игълан итә. Ниһаять, Б.Вәисевнең хыялы тормышка ашачак. «Дөреслек һәм гаделлек» фиркасе җитәкчесенең уй-фикерләре һаман шул кулга алынган милләттәшләре тирәсендә чуала. Бу аның өчен көтелмәгән хәл була. Ул үзе башкачарак уйлаган, ничек булса да аңлашу, берләшү, динебезне саклау турында хыялланган. Килеп туган вазгыятьтән нинди юлны сайларга кебек сорауларга җавап эзли. Шулай ук Хәрби Шураның төбәк комитеты вәкиле Садретдин Йосыпов та *«Сез бу очракта нәрсә эшләячәксез?»* дигән соравына аннан җавап көткән.

— Һәрхәлдә, без Советларга каршы көрәштә катнашмаячакбыз, — дигән Вәисев.

Йосыпов киткәннән соң озак та үтми, Гайнан Вәисев янына Хәйретдин Вәлиев килә. Ул хәрби шурачыларны кулга алу сәбәпле оештырылган фетнә күтәрелешенең башлануын хәбәр итә. *«Советка каршы көрәшергә теләмәгәнегез өчен сезгә карата да янаулар ишетелә»,* — дип кисәтә ул. Аның сүзләрен раслап, тиз арада йорт янына фетнәчеләр дә җыйнала. Кычкырыш, хәтта ату тавышлары да яңгырый. Гайнан, ярсыган халыкны тыныч-

ландырырга теләп тәрәзәсен ача һәм урамдагы төркемгә мөрәҗәгать итеп:

«Милләттәшләр, кардәшләр! Кемнәрдер сезне хата юлга кертергә маташа. Тынычланыгыз, өйләрегезгә таралыгыз. Мин хәзер үк Советка барам һәм кулга алынганнарны азат итү чарасын күрәчәкмен...» — ди.

Гайнан сүзләрен әйтеп бетерә алмый, берничә җирдән аңа төбәп атып җибәрәләр. Гайнан Вәисев, күкрәген тотып, диванга ава. Аңа И.Зәйнуллин ярдәм итә. Бераздан ул яраланган хәлдә залга уза, әмма аның авызыннан кан агып чыга, ул аңын югалтып егыла һәм шунда җан бирә. Шуннан соң И.Зәйнуллин үзе дә җәрәхәтләнгән хәлдә тәрәзә янына килеп: *«Сәрдар үлде, без биреләбез, теләсә нәрсә эшләгез!»* — дип кычкыра.

Халык өйгә бәреп керә һәм мәетне штыклар белән кадый башлыйлар. И.Зәйнуллин һәм башкалар үлек өстеннән мәсхәрә кылмаска чакыралар, әмма аларның үзләрен дә кыйнап, 600 сум акчаларын, 6 револьверларын, 4 кылычын алалар. Ибраһимны кулга алып, комитетка алып китәләр.

Вәисиләр Совет хакимиятеннән үтерүчеләрне табуны таләп итәләр. Нәтиҗәдә бу эш белән Ревтрибунал һәм аның җитәкчесе А.Бочков, ЧКдан Жестянниковлар шөгыльләнә башлыйлар. Тикшерү комиссиясенең комиссары Родионов район милициясе начальнигы А.Ибраһимовтан 1918 елның 2 мартында сорау ала. Аның күрсәтмәләренә караганда, 28 февраль көнне, сәгать 11 белән 12 ләр арасында Вәисев квартирасы янына (А.Ибраһимов үзе дә шул ук йортта яшәгән) килеп, аннан корал бирүне таләп иткәннәр. Халыкны тарату теләге белән Вәисев квартирасыннан атып җибәрә, җыелган халык арасыннан да аталар. Бөтенесе 5—10 минут эчендә була. Ул шулай ук И.Зәйнуллинның яралану фактын да күрсәтә. Соңыннан, халыктан саклап калу нияте белән, аларны милициягә алып киткәнлеген дә әйтә. И.Зәйнуллин да күрсәтмәләрен бирә. *«Безнең өчен аның күрсәтмәләре бик кадерле, чөнки алар дөрес күрсәтмәләр иде»*, — ди. Мәсәлән, Гайнан Вәисевнең тәрәзә ачуы, ату турында бер сүз дә әйтми. Зәйнуллин үзенең җитәкчесе турында: *«Ул чыннан да «ялкынлы социалист» һәм изелгән халыкларның яклаучысы иде»*, — ди. 5 март көнне Родионов, Арзаянов, Богданов составындагы тикшерү комиссиясе И.Зәйнуллиннан һәм Мөбарәкшин Болгарилардан янә сорау алалар. Зәйнуллин янә үзенең Сәрдар янына беренче булып килүен, ә аннан соң Хәйретдин Вәлиуллинның килүен сөйли. Сәрдар аларга бу эштән читтәрәк калуны кирәклеген әйтә. Тиздән Окружной комитет әгъзасы Йосыпов килеп Сәрдардан: *«Шура әгъзаларының кулга алынуларына ничек карыйсыз?»* — дип сорады ди. Гайнан Вәисев Советка каршы бармаячагын әйтә. Халык йорт янына килеп җиткәнче, Гайнан секретаре Майстерны арткы ишектән Советка барып хәлне сөйләр өчен чыгарып өлгерә. Тиздән төркем килеп, тәрәзәләрне ватарга

керешә... Менә шунда ул, кулына револьверын алып, тәрәзә янына килә...

Милиционер Киселевның күрсәтмәләренә караганда, аны мөселманнар йорт яныннан синең монда эшең юк дип куып җибәрәләр, икенче көнне дә шул ук хәл кабатланды, ди. Аның фикеренчә, төркем Яшел гвардия өчен әзерләнгән коралны алырга теләгән, ә Вәисев аларны кире кага. Вәисевкә карата мөселман халкы да ачулы иде, чөнки ул мәчетләрне бетерү ягында иде.

Гайнан Вәисев үтерелгәннән соң, 2 мартта тикшерү комиссиясе һәм мөселман комиссариаты делегатлары Ибраһим Галиев, Измаил Рәхмәтуллин, 5 нче район милиция начальнигы А.Ибраһимов Сәрдарның квартирасында булалар. Алар анда тәрәзәдә пуля тишекләрен табалар, ә икенче бүлмәдә кан эзләре була. Бөтен бүлмәләрдә тәртипсезлек, таралган кәгазьләр, туздырылган урын-җир, китаплар идәндә яталар. 1918 елның 4 мартында комиссия агент Козловка бөтен кәгазьләрне Вәисев квартирасыннан алып китәргә боера.

Шаһитларның берсе — Төхфәтуллин Насыйбулланың сүзләренә караганда, Вәисевкә атучы кеше кара-кучкыл, урта буйлы, каракүл бүрекле, пальтодан иде дигән мәгълүмат бирә.

1918 елның 1 апрелендә З.Ибраһимов Родионовка бирелгән гаризасында Вәисевнең Әхмәтҗан Мөхәммәтҗанов тарафыннан үтерелгәнен күрсәтә. Нәтиҗәдә Мөхәммәтҗанов фатирында 10 апрельдә тентү була, һәм анда бик күп патроннар да табыла. Мөхәммәтҗанов кулга алына. Әмма ул: *«Мин Вәисевне үтермәдем»*, — ди. Аны зинданнан ireккә чыгаралар. Шулай итеп, бу «эш» тукталып кала. 1920 елның 14 июлендә бу «эш» амнистия нәтиҗәсендә бөтенләй ябыла.

Сәрдар Гайнан Вәисев әл-Болгари вафат булган көн матәм көне итеп игълан ителә. Аны Сөембикә манарасы янына күмәләр. «Знамя революции» гәзите зур некрологлар бастыра. Гайнан Вәисевкә шундый хөрмәт күрсәтелгән икән, бу — чираттагы мәкер; ул милли хәрәкәтне таркатуга юнәлдерелгән. Рәсми хакимият милли дәүләт төзергә, әлеге ниятне тормышка ашырырга теләүчеләрнең бер йодрык булып каршы чыгуыннан шүрли. Күмү вакытында яңгыраган залп тавышлары ераkларга ишетелсә дә, Гайнан Вәисев җитәкләгән хәрәкәт тиз арада Совет хакимияте тарафыннан тар-мар ителә.

Шуны да әйтергә кирәк: аклар, Казанны алгач, аның мәетен яңадан чыгаралар. Казанны аклардан азат иткәннән соң, аны Совет хакимияте өчен шәһит булганнар зиратына (хәзерге Үзәк мәдәният һәм ял итү паркы янындагы «Братская» каберлеге) күмәләр. 70—80 нче елларда *вәисиләр хәрәкәтен* яңадан оештырып җибәргән яңа төркем тырышлыгы белән аның каберенә таш куела.

Бу хәлләр вакытында Вәисев штабының кәгазьләре таралып, ертылып беткәнлектән, вәисиләр яңадан теркәлү үтәләр.

Гайнан Вәисев эл-Болгари вафатыннан соң бөтен эшләрне аның бертуган энесе Мөхәммәт Газизҗан эл-Болгари Вәисев (1884—1963) үз кулына ала, һәм хәрәкәт яңа сулыш ала башлый. 1919 елның гыйнварында булып узган II съездларында партиянең яңа атамасы «Партия ваисовцев и коммунистов Востока (Ислама)» кабул ителә. Анда шулай ук аның уставы, программасы да раслана. Программада предприятиеләрне национализацияләү, крестьян хуҗалыкларын кооперацияләү кирәклеге дә күрсәтелә. Хәрәкәтнең III съездында (1919 елның июль ае) илне тышкы һәм эчке контрреволюциядән саклау, мәдәни һәм икътисади үсешлеш хакында да карарлар кабул ителәләр. Нәкъ менә шушы вакытларда вәисиләр Фрунзе җитәкләгән Төркестан фронтында зур активлык күрсәтәләр.

Әмма ВЧКның урындагы эштәшләре Газизҗанның бу тырышлыкларын яратмыйлар. Мәсәлән, Көнбатыш фронты армиясенең махсус бүлеге җитәкчесенең әйтүенә караганда, Газизҗан җитәкчелегендә *вәисиләр хәрәкәте* «башкачарак» эшкә керешкән, ди. Янәсе, ул — «үз-үзен», хакимиятне (властьны. — *Р.В.*) бик яратучы, дәүләтчелек акылы белән эш итә алмый торган җитәкче. Ул, бернинди кагыйдәләр белән санашмыйча, уңга һәм сулга, кем тели шуңа хәрәкәтнең әгъза билетларын бирде, ди. Аңа барыбер — спекулянтмы, кара йөзлеме, дезертирмы, контрреволюционермы. Фронтка китәсе килмәгән эшче-крестьяннар, чыннан да, бик рәхәтләнеп вәисиләргә килеп, аларның Газизҗанга «Аллага шөкер»не генә әйтәсе көн кебек ачык, ә ЧК әһелләренә бу хәл контрреволюциянең активлашуы булып күренә. Аларга каршы булганнар — барысы да дезертир, контрреволюционер, милләтче... Вәисев хәрәкәте үсә, ныгый. Оештыру эшләре алга бара. Моңа 1919 елның 29 гыйнварында эшче һәм крестьяннар Яшел армиясе уполномоченныйларының гомуми җыелышларында вәисиләрнең ислам сугышчылары азатлык төркеме тарафыннан бердәм кабул ителгән программасы яхшы дәлил. Бу чыганак фәндә беренче тапкыр китерелгәнгә, без аны тулы килеш бирергә булдык.

«Угнетенные братья, стремитесь выбраться из пути угнетателей и предателей. Спешите, братья. Соединяйтесь в пути славном. Истинный путь, путь до нации (выше национализма. — прим. переводчика). Освободительная группа.

ПРОГРАММА

Воинов Ислама — ваисовцев 1337 года Хиджри (От переселения Мухаммеда из Мекки).

Во имя милосердного Бога.

Освободительная группа.

Программа Волжско-Булгарских мусульман — Божьих воинов «Ваисовцев».

Чему верят братья-ваисовцы, перенесшие с 1862 года жертвы в борьбе с угнетателями за правду и справедливость. К чему призывают (учат) братья, борющиеся за правду и справедливость.

1. Освободительная группа «Ваисовцев» признает, что Бог един, что Вселенная — творение единого бога.

2. Все люди — рабы божьи. Рабство и подчинение присущи только одному Богу.

3. Всему человечеству предписано жить в правде и справедливости. Все люди — братья.

4. Цари, императоры и капиталисты — суть поправшие законы Всевышнего Бога. Духовенство же (эти сатаны) — приспешники царей, богатей — предатели, заставлявшие людей пасть ниц перед законом.

5. Пророки же, последователи истинного пути Божьих законов, а так же проповедники истинного пути Ислама, ведущего к освобождению угнетенных народов от гнета угнетателей. Пророки — истинные социалисты Ислама, перенесшие много тяжестей на своем пути.

6. Восхваленный пророк Мухаммед есть великий пророк проповедник пути истины, проповедник уничтожения гнета и несправедливости —торжества равенства и миролюбия на земле.

7. Коранулмазид (Коран) есть книга Бога (Божьи законы) данного богом Мухаммеду-Мустафе на проповедование народу мира о братстве всех народов, о справедливой и братской жизни на основе мирного и справедливого труда.

8. Последователи пророков, Мухаммед, а также наследники пророков — уважаемые братья, проповедники пути истины народам мира.

9. Дердмент-дервиш Багаутдин Эмир-ханзаде Оглы Ваиси-ханзаде эль-Булгари — проповедник истинного пути Великого пророка и последователь его по Корану к объединению всего человечества по пути истины Пророк, составитель программы мирному братскому сожительству. Великий проповедник последнего века.

10. Сардар (Гайнанетдин) Ваиси-ханзаде, истинный социалист Ислама, героически стремящийся к согласию в указанной программе, к защите угнетенных от угнетателей.

11. Освободительная группа братьев-ваисовцев по смыслу стихи из Корана: «Все мусульмане-братья должны жить в мире по-братски», являются между собой братьями, т.е. братство ваисовцев предсказано Всевышним. Поэтому братья-ваисовцы всегда будут помогать друг другу. Сильные слабым, богатые бедным будут помогать и, в результате, братья будут жить в равенстве и справедливости, как одно тело и душа.

12. До поступления в освободительную группу «Ваисовцев» необходимо: 1) Каждый должен по своему мышлению и совести

находить истинный путь, проповедуемый ваисовцами; 2) Исповедоваться в своих проделках и грехах; 3) Дать клятвенное обещание.

13. Братья-ваисовцы получают от Духовного собрания за подписью председателя удостоверение в принадлежности к ваисовцам, последователям истинного пути. И везде (во всех частях света) куда бы они ни попали, братья имеют указанные удостоверения.

14. Братья-ваисовцы во всех делах подчиняются управлению ваисовцев — Духовному собранию.

15. Духовное же собрание подчиняется только Богу, Пророку и Корану.

16. Ввиду того, что великий проповедник пути братьев-ваисовцев — Дердмент-дервиш Багаутдин Эмир-ханзаде Оглы Ваиси-ханзаде — потомок булгарских ханов (князей), а также ради сохранения доброго имени известных в истории мира своей культурой, наукой наших предков — булгарских рабочих и в ознаменование места в начале нашей священной работы по внедрению справедливости на земле братьям-ваисовцам присваивается звание «эль-Булгари» (булгарец).

17. Духовное собрание — управление освободительной группы воинов Ислама братьев-ваисовцев состоит из 12 уполномоченных. Председатель этих уполномоченных — начальник освободительной группы.

18. Председатель выбирается братьями освободительной группы «Ваисовцев» всего мира — лицо умное, развитое и просвещенное.

19. Уполномоченные же назначаются председателем освободительной группы и большинством братьев-ваисовцев.

20. Управление Духовным собранием, а также ответственные дела воинов Ислама — братьев-ваисовцев возлагается на 12 уполномоченных.

21. В введении уполномоченных нижеуказанные отделы: 1) отдел просвещения; 2) земледелия; 3) рабочих; 4) зеленая армия; 5) здравоохранения; 6) контроля; 7) юстиции; 8) агитации и организации; 9) помощи; 10) казначейства; 11) кооперации; 12) связи с братьями далеких стран (внешняя связь). Члены вышеуказанных Отделов назначаются общим собранием.

Обязательные правила братьям-ваисовцам — воинам Ислама.

22. Обязательное учение для всех братьев: мужчинам, женщинам, старикам и молодым, согласно изречения Мухаммеда: «Науки обязательны всем мусульманам и мусульманкам».

23. Начальные школы — воспитательницы человека. Мальчики и девочки от 7 до 16 лет должны обучаться под руководством опытных и знакомых с педагогикой учителей и учительниц необходимым для трудовой жизни грамоте и ремеслу.

24. Для братьев, не получивших в молодости образования, будут открыты школы для взрослых, где будут обучаться во внеурочные часы.

25. Признавая за основу всех наук культуру и искусство — Коран и изречения Мухаммеда, ваисовцы обязаны просвещаться и изучать все науки, ибо это необходимо для справедливой, трудовой и братской жизни.

26. Для вступления в супружество по Шариату мужчинам должно быть не менее 18 лет, а женщинам — 16 лет.

27. Вступающие в брак предварительно извещают Духовное собрание. После подтверждения согласия сторон Духовное собрание утверждает, и брак заносится в брачную книжку.

28. Братья-ваисовцы, как в жизни вообще, так и в совместной жизни в частности, должны избегать угнетения и несправедливости.

29. Все братья-ваисовцы, как мужчины так и женщины, должны правдиво трудиться и жить только своим трудом.

30. Братья-ваисовцы должны избегать злоупотребления, расточительности и всех неблагодарных поступков.

31. Братья-ваисовцы должны быть правдивыми, справедливыми и отзывчивыми.

32. Братья-ваисовцы как сами, так и их семейства и дети должны быть воспитанны и весьма нравственны.

33. Нетрудоспособные братья-ваисовцы: ойроты, калеки и престарелые будут воспитываться управлением братьев-ваисовцев в общих домах воспитания.

34. Имея всегда в виду, что братья-ваисовцы — братья по крови, по мышлению, не будут между собой враждовать и чинить козни, так как у них единый путь, единое мышление и единое воспитание.

35. Братья-ваисовцы должны избегать пустословия, т.е. не тратить время на пустые слова, также избегать вредных дел. Ибо должны помнить, что лучше много делать, чем много говорить.

36. Братьям-ваисовцам строго запрещается игра в карты и употребление одурманивающих средств (спиртные напитки и опиум).

37. Братья-ваисовцы должны соблюдать обряды, указанные в Коране и изречениях Мухаммеда.

38. Братья-ваисовцы, подчиняясь изречению Мухаммеда: «чистота есть часть веры» — строго и очень внимательно должны соблюдать чистоту. Как в семейной жизни, так и вообще должны жить чисто и опрятно.

39. Братья-ваисовцы по отношению к другим также должны быть по-братски справедливы и отзывчивы, как к своим братьям.

40. Братья-ваисовцы должны всеми силами стремиться к

защите всех угнетенных без различия религии и нации, в особенности, рабочих и бедных от угнетателей.

41. Братья-ваисовцы должны быть готовы ко всяким самоотвержениям в борьбе за защиту угнетенных и идти рука об руку с социалистическими партиями, которые наиболее самоотверженны в борьбе с угнетателями, защищая угнетенных и которые наиболее близки социалистам.

О земле

42. Все братья-ваисовцы: мужчины и женщины, старики и молодые являются наемниками земли. Все они должны пользоваться ею равно и одинаково.

43. Земледельцы-ваисовцы (крестьяне) будут пользоваться землею настолько, насколько сумеют по-справедливому обрабатывать (трудовая норма).

44. Братья-ваисовцы не будут хозяйничать в земельных делах и не будут заниматься куплей и продажей земли.

45. Всем земледельцам братьям-ваисовцам земля будет предоставлена исключительно управлением ваисовцев в таком количестве, каковое они могут обрабатывать сами.

46. И если после распределения между земледельцами в распоряжении управления окажется излишек земли, то таковой будет обрабатываться артелями братьев-рабочих, работающих и живущих в городах и заводах. Во время земледельческих работ из них будут составляться группы, артели, коммуны. Они будут обрабатываться на коммунальных началах, ровно и одинаково распределять работу; другими словами, будет истинная Коммуна Ислама, основанная на правде и справедливости.

47. Хлеб, заготовленный артелью или Коммуной Ислама братьев-ваисовцев, поступит на удовлетворение неработоспособных братьев-ваисовцев, содержащимися братьями-ваисовцами по необходимости.

О рабочих

48. Управлением братьев-ваисовцев организуется кооператив под названием «Фидакарь» (Герой, самоотверженец).

49. В разных отделах «Фидакарь» братья-ремесленники будут вместе работать по своим специальностям.

50. Братья, воины Ислама, работающие на фабриках, заводах, мельницах и других отделах «Фидакарь», все будут из рабочих.

51. Все братья-рабочие в своем деле должны быть аккуратными и должны работать честно и геройски.

52. Норма работы братьев-ваисовцев не будет превышать 8 часов.

53. Отдел земледелия и отдел труда у братьев-ваисовцев будет честно и справедливо обмениваться продуктами своего производства и оба будут в согласии.

6. С-107

54. В Сибири, в Туркестане будут отделы «Фидакарь». Сырье, находящееся у сибирских и туркестанских братьев, будут направлены ими для обработки. По справедливой обработке не будут направляться обратно.

55. Все братья-ваисовцы — Божьи воины, т. е. воины Ислама, подчиняются только Богу, посланнику его (Мухаммеду) и Корану.

56. Братья-ваисовцы борятся против угнетателей, злодеев, преступников и отступников от истинного пути. И будут стремиться направить их на истинный путь.

57. Братья-ваисовцы никогда не будут в войсках (в рядах войск.— прим. переводчика) в подчинении правительства, проливающего кровь, т.е. не будут вмешиваться в дела кровопролития (кровопролитные).

О войне

59. По верованию (понятию) братьев-ваисовцев эти великие сражения и кровопролития — ниспосланные Богом несчастья. Но виновниками этих несчастий являются цари, правительства, императоры и называемые капиталистами грязные лица духовенства, которые живут среди нас. Господь Бог сотворил людей наследниками Земли и указал жить правдивым и справедливым трудом — по-братски. Отступившие от указания Бога люди начали угнетать своих братьев и властвовать над ними, поработили людей и свели их с истинного пути. Те духовенства же, ради личных интересов, заставили всех угнетенных под клятвою перед священными книгами Бога подчиняться этим грязным угнетателям. Весь народ благодаря этим лжецам был порабощен империалистами и капиталистами. Для того, чтобы заблуждающие люди раскаялись и скорее нашли путь истины — путь Бога и пророка — Богом ниспосланы все эти несчастья и войны. Когда будут уничтожены виновники несчастий — империалисты и капиталисты и продавшиеся им лжецы духовенства, а также распространяемые ими разные ложные верования, вот только тогда должна кончиться война.

Всеобщий мир

60. Уничтожение империалистов, капиталистов и лжецов духовенства, мир еще скоро не наступит, ибо еще долго придется бороться с грязной и черной силой, оставленной ими, в особенности, нациям. На спасение же от этой ужасной борьбы есть единственный путь, путь, по которому шли люди от сотворения мира — путь, по которому шли до национализма. Этот путь предуказан Богом человечеству — путь правды, справедливости, равенства и мира — путь Ислама. По этому пути пошли сначала Адам, Мухаммед и все бывшие до него пророки,

последователи этого пути, воевали и, погибая, стремились вывести людей на этот путь, ибо на этом пути нет империалистов, капиталистов и продавшихся им. Этот путь Ислама, признающий и подчиняющийся только одному Богу, есть путь истины, ведущий все человечество к братству, равенству, справедливости и одинаковой жизни. Когда человечество найдет этот истинный путь, только тогда наступит всеобщий мир и спокойная жизнь.

Стремитесь же, угнетенные братья, заблужденные угнетателями. Соединяйтесь с братьями-ваисовцами — воинами Ислама, последователями истинного пути Бога и его пророка.

Братья, с божьей помощью сегодня нам удалось написать и предложить Вам, Братьям, тот путь, по которому идут воины Ислама — ваисовцы. 60 лет жертвуя жизнью, средствами, проповедовали этот путь истины, лишились родителей и родных. Принуждались к каторге, тюрьмам и Сибири. Отрываясь от родины, были вынуждены скитаться по горам и среди камней. Около 100 воинов Ислама пали жертвою на этом пути. За что? За правду и справедливость, за Бога и его пророков. Самыми беспощадными последователями и нашими угнетателями были Романовы и продавшиеся им за личные интересы наши братья-муллы. Они проливали нашу кровь за то, что мы звали народ к пути истины. О священный Ислам! О чистая совесть! О чистое дарование! О священный Коран!

Мы, воины Ислама, — ваисовцы, столько героизма проявили и, слава Богу, терпели. Братья, угнетатели нападали на нас со всех сторон, не давали возможности писать, говорить и объяснить Вам правду. Вы же, братья, к сожалению, находились в гнете и ваши угнетатели морочили вам голову и до сего времени Вы не могли понять истину. Но великие угнетатели, противники правды и справедливости уничтожены и уничтожаются. Мы же воины Ислама — ваисовцы, слава богу, еще существуем. Восторжествует правда и справедливость на Земле и мы будем существовать. Поэтому люди говорят, что правда не будет останавливаться — будет двигаться и искать себе место. Говоря иначе, если и погибли Мустахид Багаутдин Эмирханзаде Оглы эль-Булгари и Сардар (Хуза Мухаммед Гайнан) Ваиси-ханзаде — но правда осталась и есть, и всегда будет. Правда двигается... благодаря стараниям воинов Ислама — ваисовцев, она распространяется уже в Сибири, Туркестане, Казахстане, Киргизии, даже в горах Тянь-Шаня и до Афганистана. И с каждым днем сгущаются ряды братьев освободительной группы.

Братья, образумьтесь. И вам нужна правда и справедливость. Не оставайтесь и стремитесь освободитсья из тумана. «Старание мужчины разрубает горы», — так говорят арабы. Умному достаточно показать.

Временный председатель освободительной группы ваисовцев: Хуза Мухаммед-Газизян Эль-Фахрутдин Мустахид Багаутдин Оглы, Ваиси-ханзада эль-Булгари.

Привет тем, кто идет к истине. 1919 год 12 февраля. Волго-Булгарские мусульмане[44].

Программа үзе 6 бүлектән тора. Беренче өлешендә, нигездә, өч әһәмиятле факторга урын бирә. Вәисиләрнең азат итү группасы бары тик бер Алланы гына бар дип белә, ә бөтен дөнья аның тарафыннан барлыкка китерелгән. Бөтен адәм балалары аның коллары, алар бары тик аңа гына буйсыналар. Аның тарафыннан бөтен адәм балаларына — кешелек дөньясына — дөреслектә һәм гаделлектә яшәргә кушылган. Бөтен кешеләр — бертуганнар (братья). Аннан кала вәисиләр өчен бары тик Коръән һәм Мөхәммәд, Алланың илчесен тыңлау, аның күрсәтмәләрен үтәүдер. Бу программага нигез салучы — Б.Вәисев, Ислам социализмына нигез салучы Сәрдар Гайнан Вәисев икәнлеге дә күрсәтелгән. Күрәсең, вәисиләр бу хәрәкәтнең үсүен, аның үзгәрүен яхшы белеп эш иткәннәр.

Шушы ук бүлектә *вәисиләр хәрәкәтенең* оештыру эшләре тәртибе дә бик аңлаешлы итеп язылган. Үзләренең төп идарә органнары итеп Дини идарә һәм аның рәисе күрсәтелгән. Вәисиләр Дини идарәгә буйсыналар, ә Дини идарә бары тик Аллага гына буйсына. Дини идарә үзе 12 уполномоченныйдан тора. Уполномоченныйларга бүлекләр буйсына. Монда мәгариф, җир эшләре, эшчеләр, яшел армия, исәнлек саклау, контроль, юстиция, агитация һәм оештыру бүлеге, казна, кооперация, башка илләрдәге туганнар белән элемтә бүлекләре күрсәтелгән. Алар барысы да гомуми җыелышта хәл ителәләр.

Шушы ук бүлектә вәисиләрнең шәхси таныклыкларын алу тәртибе дә күрсәтелгән. Моны алу өчен башта кылган яман эшләреңне сөйләп тәүбәгә килергә, аннары вәисиләрнең идеологиясен кабул итәргә кирәк. Башка оешма, партияләрдәге кебек, взнос һ.б. нәрсәләр кирәкми.

Программаның икенче өлеше шактый зур, эчтәлекле. Ул «Бертуган вәиси сугышчыларының мәҗбүри кагыйдәләре» дигән исем астында бирелгән.

Программада вәисиләргә уку һәм белемнең кирәклеге, 7 яшьтән башлап 16 яшькә кадәр булган һәрбер баланың тормышта хезмәт итү һәм яшәү өчен һөнәргә өйрәнергә, укый-яза белергә тиешлеге ассызыклап әйтелгән. Өлкәннәргә карата да: «*Яшь чагында белем ала алмаган олы яшьтәгеләргә махсус мәктәпләр булдырырга. Вакытны юк-бар белән бушка уздырмаска. Иң яхшысы — күп эшләп, азрак сөйләнергә. Карта уйнау, опиум, спиртлы эчемлекләр эчү дә тыела. Гомумән алганда, алар пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)нең «Чисталык — дингә ышануның бер өлеше» дигән хәдисен истә тотып, чиста, пөхтә һәм матур итеп яшәргә тиешләр*» дигән җитди таләпләр куйганнар.

Вәисиләр, диннең һәм милләтнең аерылуына карамастан, кешеләргә мәрхәмәтле, гадел булуны таләп итәләр. Изелгәннәрне социалистик партияләр белән кулга-кул тотышып, бергә көрәшкә чакыралар.

Программаның өченче өлеше «Җир турында» дип атала. Ул алты өлештән тора. Анда әйтелгәнчә, вәисиләр: ирләр һәм хатын-кызлар, картлар һәм яшьләр — барысы да җирдән файдалану хокукына ия булулары, әмма үз көчләре белән эшкәртә алган кадәр җиргә генә хуҗа була алулары, ә артып калган җирләрне бары тик күмәкләшеп, коммуналар төзеп бергә эшкәртергә тиеш икәнлекләре күрсәтелә. Шул рәвешчә монда вәисиләрнең беренче тапкыр чын Ислам коммунасы өчен көрәшләре бәян ителә. Шул ук вакытта анда барлык әзерләнгән икмәк һәм башка әйберләрнең хезмәттә эшли алмый торган яраксыз милләттәшләргә һәм зәгыйфьләргә бүлеп бирелергә тиеш икәнлеге дә әйтелә.

Программаның дүртенче өлеше «Эшчеләр турында» дигән 10 бүлекчәдән торган кагыйдәләрдән гыйбарәт. Монда вәисиләрнең идарәсе тарафыннан «Фидакарь» дип аталган кооператив төзергә кирәклеге әйтелеп, түбәндәгеләргә игътибар итүне таләп итә: *«Бөтен вәиси-эшчеләр намуслы һәм батырларча эшләргә тиеш. Эш вакыты — 8 сәгать. Себердә, Төркестанда «Фидакарь»-нең филиалларын булдырырга кирәк. Алар бары тик Аллага һәм Мөхәммәдкә генә буйсыналар; изүчеләргә, усаллыкка, дөрес юлдан адаштыручы явызларга каршы көрәшәләр, армиядә хезмәт итмиләр һәм хакимиятнең кан кою эшләрендә катнашмыйлар».*

«Сугыш» дип аталган бүлектә кан кою өчен генә барган сугышлар Алла тарафыннан җибәрелгән бәхетсезлекләр дип бәяләнә. Бу бәхетсезлекләрдә патшалар, хакимнәр, капиталистлар дип аталучы империалистлар һәм алар алдында тәлинкә тотып торучы руханилар гаепләнә. Соңгылары, изелгәннәрне алдалап, аларны үзләренең изүчеләренә буйсындырганнар. Болардан котылу юлы бер генә — Алла юлы. Бу бәхетсезлекләрне тудыручы империалистларны бетерми торып, сугыш бетмәячәк. Алар бетерелгәндә генә сугыш бетәчәк.

Программаның соңгы — алтынчы бүлегендә «гомум тынычлык» турында сүз бара. *«Империалист-капиталистларны әле тиз арада гына бетереп булмый һәм шуңа күрә бу кара көчләр белән көрәшергә туры килә. Тынычлык юлы — Ислам юлы. Бары тик шушы юл гына гаделлеккә, дөреслеккә, туганлыкка, бертөрле яшәүгә китерәчәк. Менә шушы юлны тапкан очракта «гомум тынычлык» булачак, әмма тынычлык үзе килмәячәк, аның өчен көрәшергә кирәк. Дөреслек Ислам сугышчылары тарафында булачак; көн саен диярлек Шәрык илләрендә азат итү группасының тарафдарлары арта, үсә, ныгый. Туганнар, акылыгызга килегез...»* — диелә анда.

Программадан күренгәнчә, хәрәкәт җитәкчеләренең Исламны социаль революция белән бәйләп карау сәясәтен алып барганлыгы күренә. Шул исәптән социалистик партияләрне файдалану да күздә тотыла. Болай хәрәкәт итү үзенең нәтиҗәләрен дә бирә. Мәсәлән, Русиянең төрле регионнарында, бигрәк тә Төркестан, Казакъстан һәм Кыргызстанда вәисиләр тарафдарларының саны арта, сафлары ныгый. Бу эш Газизҗан һәм аның иптәшләренең фидакарь хезмәте белән бәйле була. Аларның эшчәнлеге Идел буендагы шәһәрләрдә башланып китә. Бигрәк тә 1919—1920 елларда алар «Илаһи полк»ларны төзү өлкәсендә эшне киң җәелдерәләр, төрле шәһәрләрдә агитация эшләре алып баралар. Хәер, Идел буенда гына түгел, Төркестанда да эшне оештыралар. Хәтта Мәскәүгә — М. Солтангалиевкә дә мөрәҗәгать итеп, аның да булышуын сорыйлар. Шул максаттан чыгып, Төркестан хәрби штабы каршында махсус вәисил‹›р группасын төзүне таләп итәләр. М.Солтангалиев бу хакта: *«Нәкъ менә шушы мәсьәлә белән аларның миңа мөрәҗәгать иткәннәрен хәтерлим, әмма мин аларга «дипломатик җавап бирдем»,* — дип яза. Менә шуннан соң ул республиканың Реввоенсоветка биргән запискасында: *«Мин бу формированиеләрне төзүгә каршы булуымны әйттем, чөнки мин ахыр чиктә бу формированиеләрнең кем кулына килеп эләгәсен белмәдем. Аннан соң моңа кадәр үк Казандагы Центрмусвоенколлегия бу мәсьәлә буенча тискәре фикердә иде, һәм мин аңа каршы баруны уңайлы дип санамадым. Бәлкем, мин бу мәсьәләдә хата җибәргәнмендер»,* — дип искәрмә ясый.

Соңга калып булса да (1941. — *Р.В.*), ул халыкара сәясәт өчен, бигрәк тә Шәрык илләрендә бу хәрәкәтнең уңай фактор булуы мөмкинлеген дә әйтә. Кызганычка каршы, ул елларда бу хәрәкәтне большевиклардан бары тик бер кешенең — М.В.Фрунзенең генә уңай хәрәкәт дип бәяләвен күрсәтә.

Вәисиләрнең 1918 елның гыйнварында «О мерах по защите от внешней и внутренней контрреволюции» исемендәге карарлары кабул ителгәнлеген дә онытырга ярамый, чөнки 5—8 августта Казанның аклар тарафыннан алынганлыгын искә төшерсәк, аның нинди әһәмияткә ия булуы үзеннән-үзе аңлашыла.

1919 елның 9—14 июлендә, II съездан соң нибары биш ай узуга, вәисиләрнең III съезды да шул ук программа нигезендә эш итә башлый. Анда 12 кешедән торган сәяси бюро (политбюро), Үзәк Комитет (ЦК) төзелә. Казан эшче-солдатлар советына И.Зәйнуллин һәм Ә.Гыймадетдиновлар депутат итеп сайланалар. Съезд шулай ук Идел буе болгарларының советын төзү турында да карар кабул итә. Программада шулай ук икътисади хәл, социаль-тәэминат, мәгариф, кооперация һ.б. мәсьәләләр дә карала[45].

Болгар советы үзенең эшен тиз арада киң рәвештә җәелдереп җибәрә. Ул шәрык коммунистларының Үзәк бюросы, Бөтенру-

сия Үзәк хәрби штабы, Төркестан Реввоенсоветы рөхсәте белән мөселманнардан гына торган хәрби частьлар төзүне җәелдереп җибәрә. Шул исәптән вәисиләрдән генә торган 3 нче укчы пехота полкы төзелә, һәм аның командиры итеп Сәрдар Газизҗан Вәисев әл-Болгари куела. Идел буе болгарларының «изелгән халыкларны тираннардан» коткару, яклау эшләрен Газизҗан, съезд кушканча, армый-талмый башкара. Ул бер ел эчендә 500 меңлек вәисиләр армиясен төзү эшенә керешә, төрле шәһәрләргә командировкаларга барып, анда лекцияләр укый, аңлату эшләрен алып бара. Ул шулай ук эшне Обь-Иртыш бассейнында, Тобольск-Томск губернасында, Алтайда, Төрекмәнстанның Мерв, Юлтан, Ашхабад, Үзбәкстанның Әндиҗан, Нәмәнган шәһәрләрендә дә киң җәелдереп җибәрә, хәтта Урта Азиядә, ә 1923 елда Әфганстанда да була. Газизҗан һәм аның тарафдарлары кыргызлар, төрекмәннәр һәм башка халыклар белән дә эш алып баралар[46].

Мондый зур эшне башкарып чыгу Үзәкнең дә вәисиләргә булышуын таләп итә. Бигрәк тә матди ярдәм кирәк була. Газизҗан Вәисев ярдәм сорап телеграммалар да суга. Шуларның берсендә ул: *«Әгәр дә ярдәм булса,өч ай эчендә 40 меңнән артык хәрбиләрне туплар идем»*[47], — дип хәбәр итә. Тиздән аңа Мәскәү һәм Самарадан «хәрби оештырулар» эше буенча доклад ясау өчен чакыру телеграммалары җибәрәләр. Шәрыктә хәрби эшләрне оештыру турындагы мәсьәләне тикшерү өчен Идел буе болгар-мөселман шурасы президиумы Газизҗан Вәисевне һәм Ә.Гыймадетдиновны шул максаттан җибәрүне сорап, Төркестан фронты штабына да телеграмма җибәрәләр[48].

Шулай итеп, Шәрык экспедициясе шактый уңай юнәлеш ала. Төрле шәһәрләрдән телеграммалар, хатлар килү дәвам итә. Аларның күбесе нәкъ менә вәисиләрнең хәрби частьларында хезмәт итәсе килүләре хакында язалар. Менә шундыйларның берсе әле 1917 елда Мөселман социалистлары комитеты һәм вәисиләр белән аралашуда зур роль уйнаган Һади Маликовтан килә. Ул үзенең шушы частьларда хезмәт итү теләге барлыгын белдерә. Әмма аңа партиянең Үзәк бюросы һәм Центрмусвоенколлегия рөхсәте кирәклеген дә искә төшерәләр. Бу эшне бары тик Газизҗан Вәисевнең генә башкара алуына инанганга күрә, ул аннан кирәкле телеграмманы Мәскәүгә юллавын сорый. Тиз арада Газизҗан Маликовны Шәрык экспедициясендә катнаштыру өчен аны эшеннән азат итүләрен сорап партиянең Үзәк Комитетына һәм Центрвоенколлегиягә мөрәҗәгать итә. *«Шушы арада минем җитәкчелегем астында бер группа экскурсантлар Шәрыкка шәрыкчеләрне оештыру эшләрен башкару өчен китәчәк»*, — диелә телеграммада.

Шулай итеп, 1919 елның ахырында оештыру эшләре кызу темплар белән бара. Үзәк белән Вәисев арасында шактый тыгыз элемтә урнаша, аның Үзәк белән аңлашып эш итәргә тырышканлыгы сизелеп тора. Мәсәлән, аның 1919 елның 7 декабрендә

Бөтенрусия советларының VII съездына җибәргән телеграммасында мондый юллар бар: *«В лице Вас приветствую представителей VII съезда Советов восстановителей справедливости за освобождение народов всего мира. Да поможет Бог героям правды. Веками существовавшие кумиры, высасывающие народную кровь и достояние рухнули навсегда»*. Вәисиләр VII съезд тарафыннан кумирларны булдырмау өчен көрәшкә чакырып, дин, милләт аерымлыкларына карамыйча, бөтен изелгәннәр файдасына резолюция кабул итүләрен сорыйлар[49].

«Идел буе мөселманнары, — диелә телеграммада, — *диктатура, диктаторлар белән* (кумирлар. — *Р.В.*) *көрәшергә, аларга баш имәскә, бернидән дә курыкмыйча алга барырга тиешләр, ә вәисиләр сезгә бу эштә булышлык күрсәтәчәкләр».*

1919 елның 16 гыйнварында Төркестан фронты һәм Идел буе болгар-мөселман шурасы Президиумы карарлары, шулай ук вәисиләр ревштабының беренче номерлы приказы нигезендә мобилизация игълан ителә[50]. Мобилизация эшләре Сембер, Самара губерналарында уңышлы башланып китә. Бу вәисиләрнең фидакарь эшчәнлеге нәтиҗәсе була. Вәисиләр яңадан-яңа теләктәшләр табу өчен бөтенесен эшлиләр. Алар төрле коллективларда, шәһәрләрдә лекцияләр укыйлар, чыгышлар ясыйлар, урыннардагы вакытлы матбугаттан да киң файдаланалар. Мобилизация игълан ителеп 10 көн чамасы узгач, Самара шәһәрендә нәшер ителә торган «Коммуна» гәзитендә Газизҗан Вәисев әл-Болгари, Сәйфетдин әл-Болгари, Әхмәт Гыймадетдин әл-Болгарилар белән Төркестан фронты башкомандующие Фрунзеның сорауларына җавап бирәләр. Бу интервью «Пробуждение Востока» исеме астында нәшер ителә. Без аны, фәнгә беренче тапкыр кертелгәнлектән, тәрҗемәсез, тулы килеш бирергә булдык.

«Пробуждение Востока

Пролетариат Востока проснулся, его нужно только растормошить, ряды начинают пополняться сынами великого Востока, где борьба за победу трудящихся во всем мире поставлена на повестку дня. Это борьба за освобождение порабощенных народов Востока от ига капитала звучит в унисон с грозными призывами заказного пролетариата. «Но знамя это — Зеленое знамя вождя Ислама, находящихся ныне в руках буржуазии, мы хотим вырвать из рук богачей и продавшихся им мулл и поставить рядом с Красным знаменем всемирного пролетариата». Так отвечают на заданные вопросы командующим Н-го фронта т. Фрунзе Волжско-Булгарские мусульмане, ответ которых приводится полностью.

Я, Сардар Х.М.Газизян Ваисов и нижеподписавшиеся уполномоченные Совета Волжских Булгарских мусульман ваисовцы Шигабутдин Сайфутдин Оглы Булгари и Хузиахмед Гимазетдин Оглы Булгари в ответ на поставленные нам командующим Н-м фронтом т. Фрунзе Михаилом вопросы заявляем:

1. Общество Волжско-Булгарских мусульман (Ваисовских божьих воинов) стремится к водворению на земле царства братства, равенства, любви и справедливости, что достижимо, по нашему мнению, лишь с уничтожением на земле господства капитализма и передачи всех средств производства и земли в руки трудящихся. В этом отношении наши цели вполне совпадают с целями Российской коммунистической партии большевиков и задачами Советской власти. Отличие лишь в признании нами религиозного начала, на почве которого мы и ведем пропаганду наших идей.

2. Мы всегда являлись и являемся врагами всякого буржуазно-капиталистического правительства и признаем Советскую форму правления единственной государственной организацией, соответствующей интересам угнетенных трудящихся масс.

3. Мы защищаем Российскую Рабоче-Крестьянскую Советскую власть и будем защищать ее всегда всеми нашими силами, средствами и разумением.

4. Нашим символом является Зеленое знамя вождя Ислама, пророка Магомета, но знамя это, находящееся ныне в руках буржуазии, мы хотим вырвать из рук богачей и продавшихся им мулл и поставить рядом с Красным знаменем всемирного пролетариата.

5. Мы считаем всех трудящихся братьями друг другу, независимо от расы, национальности, религии и языка и считаем себя одним из отрядов всемирного пролетариата.

6. Спрашивая разрешение на формирование части Ваисовских божьих воинов, мы заявляем о полной обязательности для нас всех начал, лежащих в основе Российской Рабоче-Крестьянской Красной Армии. Мы будем поддерживать и строго выполнять все приказания и распоряжения соответствующего военного командования.

7. Священной задачей наших воинов-ваисовцев в Красной Армии мы считаем борьбу за победу трудящихся во всем мире и, в частности, в первую очередь борьбу за освобождение порабощенных народов Востока от ига западноевропейского капитализма.

8. В правдивости всего изложенного даем торжественную клятву перед лицом народов всего мира.

1. Сардар Х.М.Газизян Ваисов (подпись по-мусульмански)

2. Шихабутдин Сайфутдин Оглы Булгари (подпись по-мусульмански)

3. Хузя-Ахмет Гимазетдин Оглы Булгари (подпись по-мусульмански)»[5].

Җаваплардан күренгәнчә, Идел буе болгар мөселманнары, аларның җәмгыяте җирдә дуслык, гаделлек, тигезлек урнаштыру өчен көрәшә. Моның өчен хосусый милекне бетереп бөтен җирләрне, производствоны хезмәт ияләре кулына тапшырырга кирәк, диләр. Менә бу өлкәдә вәисиләрнең һәм коммунистлар-

ның теләкләре тәңгәл килә. Аерма бары шунда: вәисиләрнең бөтен эшләрендә Аллага ышану тора. Шул нигездә алар пропаганда алып барганнар һәм бу турыда ачык итеп җавабын да биргәннәр. *«Бу — беренчедән, ә икенчедән, без һәрвакыт буржуаз-капиталистик хакимияткә каршы булдык һәм аңа каршы көрәшәбез. Без бары тик Совет хакимиятен изелгән халыклар теләген яклаучы хакимият итеп кабул иттек. Өченчедән, без бөтен көчебез белән Русия эшче-крестьян советы хакимиятен саклыйбыз. Дүртенчедән, безнең Яшел байрагыбыз — Ислам җитәкчесе Мөхәммәд байрагы, әмма бүгенге көнне ул байрак буржуазия кулында. Без ул байракны, байлар һәм байлыкка сатылган муллалар кулыннан тартып алып, бөтендөнья эшчеләренең байрагы белән бер сафка куярга телибез. Бишенчедән, без бөтен хезмәт ияләрен расага, диннәренә, телләренә карамыйча бертуганнар итеп карап, үзебезне бөтендөнья эшчеләренең бер отряды дип карыйбыз. Алтынчыдан, «Илаһи полк»ларны төзүне сорап, без шул ук вакытта Совет Кызыл Армиясенең таләпләренә, хәрби командованиесенең приказларына, боерыкларына буйсынабыз. Җиденчедән, Кызыл Армия сафларындагы бурычыбыз — бөтен дөньяда хезмәт халкының җиңүе өчен көрәшү, изелгән халыкларны Көнбатыш Европа капитализмыннан коткару»*[52], — дип белдерәләр.

Шулай итеп, Газизҗан Вәисев һәм аның тарафдарлары тулысынча диярлек большевиклар позициясе белән килешәләр һәм аның өчен көрәшергә әзер икәнлекләрен ачык итеп игълан да итәләр. Аерма бары тик рухи өлкәдә генә. Вәисиләр Исламга тугрылыклы булып калалар һәм бөтен көрәш, изге эшләр башында Аллага ышану, Ислам дине булырга тиешлеген дә ачык итеп әйтәләр.

Совет хакимияте, коммунистлар партиясе, соңгысы белән бөтенләй санашырга теләми һәм нәтиҗәдә тиз арада *вәисиләр хәрәкәтенә* киртәләр корыла башлый. 1920 елның февралендә алынган телеграммадан күренгәнчә, «хәрәкәтне җәелдермәскә» дигән кисәтү алына, ә икенче телеграммада турыдан-туры «Илаһи полк»ларны төзүне туктатырга дигән боерык бирелә. Политбюро М.В.Фрунзе тарафыннан вәисиләрнең хәрби частьларын төзергә биргән рөхсәтен юкка чыгарырга тырышалар. Мондый телеграмма Фрунзеның үзенә дә килә. Нәтиҗәдә вәисиләргә акрын гына каршы хәрәкәт башлана. Бу хәрәкәтне тиз генә, боерык белән генә туктатып булмаганлыкны аңлаган Совет хакимияте җитәкчеләре төрле юллар белән милли полкларны таратыралар, тараталар. Мобилизацияләнгән вәисиләрне Самарада оештырыла торган Кызыл Армиянең укчы полкларына җибәрә башлыйлар. Шулай ук башка частьларга да тараталар, төрле фетнәләрне бастыруда, Красный Кут, Александров-Гай тимер юлларын төзүдә файдаланалар. Ул Мәскәүне Каспий диңгезе бассейны белән тоташтыру линиясе булып хезмәт итә.

1920 елның 19 гыйнварында Газизҗан Вәисев Идел буе болгарларының советы каршындагы армияне оештыру штабының 2 нче номерлы приказына кул куя. Бу приказ нигезендә полк командиры итеп Газизҗан Вәисхан-задә (Вәисев), аның ярдәмчесе итеп Ш.Хәлиулла улы (Фәйзуллин) әл-Болгари, полкның адъюданты итеп Г.Галәветдин улы әл-Болгари, адъютантның ярдәмчесе итеп С.Хәкимҗан улы әл-Болгарилар билгеләнә. Полкның хуҗалык өлкәсендәге җитәкчесе итеп Әхмәт Гыймадетдин әл-Болгари куела; казначей, нотариус һ.б. эшләр буенча да җитәкчеләр тәкъдим ителә. Шушы приказ чыккан көннән башлап вәисиләр үз вазифаларын тагын да зуррак тырышлык белән башкарырга керешәләр[53]. Приказ үзе дә вәисиләрнең эшләре уңышлы барганлыгын күрсәтә. Оешканлык, бердәмлек, фидакарьлек үз җимешләрен бирә. Аларның хәрәкәте күзгә күренеп үсә һәм киңәя бара. Менә шушы хәл Совет хакимиятенең җитәкчеләрендә канәгатьсезлек тудыра да инде. Бигрәк тә Мәскәү борчыла. Шушы приказ чыгып ике ай узуга Махсус (Особый. — *Р.В.*) бүлек вәисиләр хакындагы хәбәрендә *«...из агентурных данных наблюдений можно сказать одно, что в данное время ваисовцы не только совершенно уклоняются от революционной работы, но превращаются в очаг контрреволюционного движения среди мусульман Поволжья и всего Востока, так как великолепная связь с Восточными республиками и хорошая выводка дает им возможность проводить в жизнь организационные задачи»*[54], — диелә.

Шушындый ялаларга карамыйча, Газизҗан Вәисев эшен уңышлы дәвам итә һәм 1923 елга кадәр Төркестан фронты штабында утыра, ә икенче улы — Габделәхәт Вәисев — 1920 елда аерым Фарсы Интернационал отрядының командиры булып хезмәт итә.

Вәисиләрне тарату эшләре шушы елларда тагы да активрак дәвам итә. Вәисиләрне Харьков губернасының Кунянск һәм Змеевск өязләренә җибәрәләр. Алар ачлыктан интеккән Мәскәү, Петроград, Казан шәһәрләренә 41 эшелон икмәк төяп озаталар[55]. Соңга таба бу отрядлар таркалалар. Вәисиләрнең башкалары да шул хәлдә калалар. Врангельне җиңгәннән соң, алар демобилизацияләнәләр һәм төрле өлкәләрдә хезмәт итәләр. Күбесе эшчекрестьян хезмәтен үти, ә кайберәүләре, ВКБда әгъза булып, зур урыннарда эшләп, 60—70 нче елларга кадәр яшиләр. Шулардан Х.Субаев белән Г.Шәрәфетдиновны атап була.

М.Вәисев бу хәрәкәткә тискәре тәэсирне Татарстан Республикасының төзелүе ясады дигән фикерне әйтә. Әлбәттә, бу бер яктан *вәисиләр хәрәкәтенең* кризиска дучар булганын күрсәтә, әмма һәлакәтнең башы 1917 елдан ук башлангандыр диясе килә. Бу процесс вәисиләрнең дә большевикларның ялган лозунгларына ышанып эш иткәннәреннән килә. Калганы исә фәкать вакыт факторына гына бәйле булуы көн кебек ачык. Ахыр чиктә больше-

викларга Ислам да, Ислам социализмы да, Болгарстан да кирәк булмаган. Аларга бары тик диктатура кирәк булган, ә диктатура булганда демократиягә урын юк. Чыннан да, большевиклар диктатурасы башка партияләрне һәм демократик хәрәкәтләрнең барысын да «тарих чокырына» чыгарып атарга теләде һәм бу өлкәдә шактый уңышларга да иреште.

Вәисиләр фаҗигасенең большевиклар белән килешеп хәрәкәт итүдән башланганлыгы күптөрле тарихи чыганаклар һәм фактлар белән тәмам расланганлыгы күпләргә мәгълүм. Шунысын да искәртик, большевиклар аларны 1918 елның гыйнвар-март айларында II Мөселман хәрбиләре съезды тарафыннан Казанда «Идел-Урал штаты»н төзүне тормышка ашырмауда да бик оста файдаланалар. Чыннан да, Гайнан Вәисев, большевикларга ышанып, Казан мөселман демократиясенә каршы чыга. Бу чорда, М.Солтангалиевнең әйтүенә караганда, Казан Советының хәрби көчләре бик зәгыйфь була. Гайнан Вәисевнең II Мөселман съездының карарларына карата булган каршылыгы большевикларга бик кулай була. Шуннан файдаланып, алар Үзәк булышлыгына таянып көч туплыйлар һәм, вакыты җиткәч, чаралар да күрәләр. Республиканың Көнбатыш армия ВЧКсы идарә җитәкчесенең вәисиләр хакындагы тарихи мәгълүматы моны шулай ук бик яхшы дәлилли: *«Когда совершился Октябрьский переворот, то Ваисов телеграфировал т. Ленину, что он всецело за рабоче-крестьянскую революцию и предложил свои услуги Совнаркому.*

В феврале 1918 года, когда была провозглашена Идель-Уральская республика (Забулачная республика)[56]*, Ваисову, с согласия Совнаркома, Казанским Советом было отпущено 7000 винтовок и деньги на организацию «Зеленой гвардии» для защиты Советской власти от контрреволюционных войск Всероссийского Военного Шуро. Его штаб помещался на Сенной площади в номерах «Болгар». Мусульманская буржуазия, увидя в нем опасного противника, решилась на отчаянный шаг... и вот громадная толпа народа, приведенная в исступление агитаторами Шуро, с оружием в руках бросилась на штаб «Зеленой гвардии», разгромила его и зверски растерзала Сардара Ваисова. «Зеленая гвардия» была разоружена и разошлась, а все оружие попало в руки Шуро и было направлено против Советской власти»*[57].

Гайнан Вәисев үтерелгәннән соң, нәкъ бер ай дигәндә, 28 март көнне (1918), II Мөселман хәрбиләре съезды да куып таратыла. Шулай ук аның ревштабының һәм мөселман халык комиссариаты әгъзаларының бер өлеше кулга алына, икенчеләре исә качып китәргә мәҗбүр булалар. Казан Советы тарафыннан төзелгән ревштаб эшен дәвам итә. Аның составына Ефремов, Северов һәм Солтангалиев керә. 31 мартта яңа Вакытлы революцион штаб төзелә. Анда Мөселман комиссариаты әгъзаларыннан Садыйк

Әхтәмов, Шәһид Әхмәдиев, Харис Юмагулов, Исмәгыйль Рәхмәтуллин һәм Ибраһим Галиевләр керә. Ревштабның төп максаты II Мөселман съездын һәм аның тарафыннан сайланып куелган 15 әгъзадан торган Мөселман халык комиссариатын куып тарату һәм, гомумән, милли хәрәкәтне туктату була. Солтангалиев һәм Милх тарафыннан кул куелган документ «Знамя революции» гәзитендә нәшер дә ителә[58].

Милли хәрәкәтне, шул исәптән вәисиләрне дә бары тик шул чорда нәшер ителгән меньшевикларның «Рабочее дело» гәзите генә яклап мәкаләләр бастырып чыгара. 28 март вакыйгаларына бәя биреп, *«Тагын пулеметлар, тагын кан кою. Бөек Русия демократиясенең балалары берсе берсенә ярсып ташлана»* диелә анда.

«Анда нинди атулар бара соң?» дип сораучыларга большевик Милх, мыскыл итеп: *«Болак арты республикасы»н бетерү бара»,* — ди. Менә шуннан инде фәнгә «Болак арты республикасы» дигән термин кереп тә кала. Җ.Вәлиди бу хакта: *«Андый республика булмады, шуңа күрә без аны һәрвакытта кавычкаларда яздык»,* — ди. Чынлыкта Болак артында, хәзерге Казан Ратушасында (Ирек мәйданы), тантаналы рәвештә башланган II Мөселман хәрбиләре съездының дәвамы Болак артында була, чөнки 28 февральгә каршы төндә съездның җитәкчеләре кулга алына. Съезд «Идел-Урал өлкәсе»н төзү өчен көрәшә һәм 15 кешедән торган халык комиссариатын да сайлый, әмма хәрби көч җыеп өлгергән Казан Советы Үзәктән килгән 300 матрос булышлыгы белән, пулемет-броневикларны кулланып, хулиганнарча кыйланып, бөтенесен туздырып ата. Менә шуңа күрә безгә «Рабочее дело» һәм «Идел-Урал өлкәсе» гәзитләренең материаллары бик тә кыйммәтле. Бары тик андагы язмалар гына шул чордагы көрәшне дөрес итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Шул ук «Рабочее дело» гәзите, үзбилгеләнү мәсьәләсенә кагылып: *«Үзбилгеләнү бары тик большевиклар рецепты белән генә уздырылырга тиеш булып чыга, кем дә кем алар символын кабул итми һәм үзенең эчке тормышын үзе оештырырга тели, аңа анафема-пулеметлар»,* — дип яза. Мөселманнарның хәрәкәте акрынлап тыныч кына үсте... ул, татар пролетариатыннан һәм вак буржуаз демократиясеннән торган көчле хәрәкәт булып, шушы социаль нигезгә таяна иде. Булдыксыз Шейнкманнар, Грасислар, Милхлар һ.б. компанияләре тарафыннан урнаштырылган хулиганлык атмосферасы бик күп көчләрне милли хәрәкәткә китерде, аны нык көчәйтте. Хәрәкәтнең җитәкчеләре тарафыннан эшләнгән милли-мәдәни мөхтәрият проекты (шактый гына җитешсезлекләре булса да), гомумән алганда, милләтнең саф теләкләрен чагылдырып, шовинизмга каршы чыгып, күршеләр белән дустанә мөнәсәбәттә калуны таләп итә.

Үзенең хәрби көчләренә таянып, Хәрби Шура да берничә тапкыр үз халкын большевикларның бу оятсыз тыкшынуларыннан

якларга тырышып карый, әмма шул ук большевиклар тарафыннан алдана.

Эчке фронтта җиңүләр арткан саен, хакимиятнең кыюлыгы да көчәя бара, һәм алар: *«Үзбилгеләнү хокукы бары тик Советка гына бирелгән, ә милли оешмалар берсүзсез господин Грасисның Самоопредилительный операцияләрен күзәтеп кенә торырга тиешләр»*, — диләр. Шулай итеп, милли оешмаларга каршы ачыктан-ачык көрәш башлана. *«Татарлар ачык сугыш кырында көч сынашырга теләмәделәр һәм милли гаскәри частьларны һәм Шураны тарату декретына буйсындылар. Шушы вакыттан башлап милли хәрәкәтне бастырылган дип санарга мөмкин»*[59].

28 февраль һәм 28 март көннәренең серләре ачыкланмады инде дип әйтеп булмый. Алар бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнгәннәр. Большевикларга «Идел Болгарстаны»н, «Идел-Урал штаты»н төзүчеләрнең дә кирәге булмый. Шуңа күрә алар белән яисә демократия белән исәпләшү Казан большевикларының планына кертелмиләр. Шул ук «Рабочее дело»: *«Большевикларның бетмәс-төкәнмәс җинаятьләренә тагын берсе өстәлде. Бу эш халык исеменнән эшләнде. Килер бер заман, халык исемен файдаланып кан коюны һәм халыкларны бер-берсенә бәрелештерүнең эчке серен аңлап, аларны җирәнеп искә алырлар»*[60], — дип белдерә бу оппозицион матбугат.

Царизмны бәреп төшереп, революция сөреме белән исергән халыкның зур өлеше, большевикларның вәгъдәләренә ышанып, «социализм» сукмагыннан барабыз дип уйлады һәм Кызыл байрак астына җыелды. Аның кая китереп чыгарачагын аңламыйча, алар юлыннан киттеләр. Бу юлда Гайнан, Газизҗан Вәисевләр, Мулланур Вахитов, Мирсәет Солтангалиев, Камил Якубов һ.б. да бар иде. Кызганычка каршы, алар революциягә ышанып, милли хәрәкәтләргә бик зур комачаулыклар тудырып, аның туктап калуына китерделәр. Тиз арада Совет хакимияте үзләрен дә бетерү юлына басты. Әгәр дә милли хәрәкәткә беренче куркыныч удар 1918 елның 28 февралендә ясалган булса, М.Солтангалиевкә шундый ук удар бары тик биш елдан соң — 1923 елда ясала[61]. Калганнарына һөҗүм XX гасырның 80 нче еллар ахырына кадәр дәвам итә.

Кабат *вәисиләр хәрәкәтенә* әйләнеп кайтсак, монда да шул ук сәясәт дәвам итә, әллә ни аерма юк: эзәрлекләү, бүлгәләү, тарату. Нәтиҗәдә барысын да юк итеп, бары тик коммунистик идеологияне тантана иттерү. Казан губернасының агентура бүлеге начальнигы 1919 елның 18 ноябрендә үк Ахметовка биргән нарядында *«Вәисевнең һәрбер адымын тикшереп, күзәтеп торырга»* диелә. Аны күзәтүне Самарадан Казанга агитация эшләре белән килгән көннәрдә дә дәвам ителә. ЧК агентлары аның һәрбер адымын эзәрлекләп, тиешле урынга хәбәр итеп торалар. Менә шулардан күренгәнчә, Газизҗан 1922 елның гыйнварында

Казанда Зур театр залында лекция укый. Нәтиҗәдә «Илаһи полк»ка 475 кеше языла. Шул килүендә үк ул дезертирлар комитетында да була һәм аларны үзенең полкына җибәрүләрен сорый. Шушы эшләрен башкарып, ул 1920 елның гыйнварында кабат Самарага юнәлә. Монда аны көтеп кенә торганнар икән. Аны Көнбатыш армиянең махсус бүлегенә чакырып, «Илаһи полк»ны төзүгә рөхсәт кәгазен кайтарып бирүне таләп итәләр. Эшләр уңышлы гына барганда мондый мөгамәлә Газизҗан Вәисевне беркадәр шикләндерсә дә, ул бирешми, чөнки *вәисиләр хәрәкәтенә* каршылыкларны әле ул Казанга киткәнче үк сизенгән була. Самара шәһәре районының мөселман секциясендә, 11 гыйнварда ук, шактый дискуссияләрдән соң вәисиләр оешмасын контрреволюцион оешма буларак юк итү чараларын тормышка ашыру фикере кабул ителә. 1920 елның 3 февралендәге яшертен телеграммада *«...Политбюро постановило предложить тов. Фрунзе отменить его при нем о разрешении ваисовцам производить самореально формирование... ЦКА Крестинский»*. Политбюроның сәясәт бүлеге вәисиләр полкын төзүгә фронт командиры Орвизов тарафыннан бирелгән рөхсәт-мандатын юк итүне дә таләп итә. Шулай итеп, Фрунзеның 1919 елның декабрендәге приказын юк итүне көн тәртибенә куялар. Күренгәнчә, тиз арада вәисиләргә карата булган яшертен һәм ачык рәвештә атака дәвам итә[62].

Менә шушы вакыттан вәисиләр өчен яңа этап башлана.

Тарихчы-галим Л.Климович *вәисиләр хәрәкәтен* 1862—1905, 1905—1917 һәм 1917—1918 елларны чагылдырган өч чорга бүлеп өйрәнә[63]. Шулай да мондый бүленеш әлеге хәрәкәтнең тарихын тулы итеп чагылдыра алмый, чөнки анда 20 нче еллар исәпкә алынмый. Мәгълүм булганча, вәисиләр 1919—1920 елларда да Газизҗан Вәисев җитәкчелегендә милли хәрби частьлар төзиләр, көрәшләрен дәвам итәләр.

Шуннан чыгып, без *вәисиләр хәрәкәтен* 1862—1917, 1917—1919 һәм 1919—1930 елларга бүлеп өйрәнү тарихи дөреслекне тулырак чагылдырадыр дип уйлыйбыз.

Беренче этап ул — хәрәкәтнең тууы, оештырылуы һәм эшчәнлеген башлап җибәрү этабы. Бу хәрәкәтнең идеологы Б.Вәисев аның гомум юлына да нигез салган. Аерым алганда аның дәүләтчелегебезне кору турындагы концепциясе татар халкы өчен бүген дә бик актуаль. Ул, беренчеләрдән булып, Болгар дәүләтенең җирләре, дәүләтчелеге татар халкының да байлыгы икәнлеген аңлата, исбат итә һәм патша хакимияте алдында «Болгарстан»ны кире кайтару мәсьәләсен катгый рәвештә куя. Татар халкының моңа хакы барлыгын исбатлый. Романовлар династиясенә каршы башланып киткән көрәшне ул үзенчә, үзенә генә хас алымнар белән оештыра һәм, тарафдарлары белән берлектә, шактый уңышка ирешә. *Вәисиләр хәрәкәте* турында Сахалин, Япон утрауларында, Урта Азиядә, Европа илләрендә дә ишетеп

болалар. Бу хәрәкәткә хәтта рус милләте вәкилләренең дә катнашын киткәнлеге мәгълүм, чөнки Б.Вәисев хәрәкәте, Коръәнгә нигезләнеп, бер Алланы гына Алла дип белеп, дөреслек, гаделлек, дуслык, тынычлык өчен көрәшкә чакыра.

Икенче этапта *вәисиләр хәрәкәте* чын-чынлап яңа үрләргә күтәрелә. Әгәр дә Б.Вәисев дәүләтчелек, бәйсез дәүләт концепциясен төзегән булса, ***Гайнан Вәисев исә «Ислам социализмы» концепциясен барлыкка китерә.*** Бу фактор милли хәрәкәтне бер яктан күтәрсә, икенче яктан аны һәлакәткә дә дучар итә, чөнки большевиклар хакимияткә килеп бераз ныгып алуга, башка партияләргә, оешмаларга һәм хәрәкәтләргә каршы көрәш башлап җибәрәләр һәм тора-бара аларны берәм-берәм юк итүгә ирешәләр. *Вәисиләр хәрәкәте* дә шул ук язмышка дучар була.

Соңгы өченче этапны *вәисиләр хәрәкәтенең* бетерелү этабы дисәк, дөресрәк булыр. Политбюро вәисиләрнең хәрби частьларын төзүне тыя, һәм шунлыктан хәрәкәт тиз арада таркала башлый. Хәрәкәт демократик характерда булганлыктан, диктатура чорында аңа урын калмый. 20 нче елларда башланып киткән эзәрлекләүләрнең 80 нче еллар ахырына кадәр дәвам иткәнлеге хәзер күпләргә мәгълүм инде. Төгәлрәк әйткәндә, вәисиләрне махсус тикшерү, эзәрлекләүләр 1926 елда башланып китә һәм Газизҗан Вәисевне кулга алганчыга кадәр дәвам итә. Билгеле булганча, аны 1926 елда кулга алып Себергә озаталар, һәм ул аннан бары тик 1934 елда гына Буа шәһәренә кайтып урнаша. Шул вакытта ул Польшада яшәүче туганы Гаян Вәисев белән элемтәгә керә: хатлар алышалар, хәл белешеп яшиләр. 30 нчы еллар ахырында ул кабат күзәтү астына эләгә: бөтен туган-тумачаларын, хәтта алар белән бәйләнештә булган кешеләрне дә эзәрлекләүләр башлана. Хәбәрләргә караганда, Төрекмәнстанда да вәисиләрнең барлыгы әйтелә. Менә шул елларда Мәскәү, Свердловск, Казан һәм Төрекмәнстан чекистлары арасында тыгыз элемтәләр урнаша. Алар оешкан рәвештә вәисиләрне эзлиләр. Әмма бу юлы Газизҗан Вәисевне тиз генә таба алмыйлар. Аны эзләү озак вакыт дәвам итә.

Ниһаять, 1940 елның 20 ноябрендә Газизҗан Вәисев Ташкент янындагы бер станциядә кулга алына. Аны 1918 елдан башлап Совет хакимиятенә каршы көрәшүдә, алай гына да түгел, бу эшне җитәкләүдә һәм Болгарстан дәүләтен төзергә омтылуда гаеплиләр. 1926 елда Әфганстан полковнигы белән булган әңгәмәсен дә исенә төшерәләр. Нинди генә ялалар яксалар да, төрле җәзага тартсалар да, Газизҗан Вәисев фидакарь вәиси буларак үзенең «Алла сугышчысы» икәнлеген кыю рәвештә исбат итә. Ул үзен гаепсез дип саный һәм алдан чекистлар әзерләгән документларга имзасын да куймый.

Ахыр чиктә аны, кабат 8 елга хөкем итеп, лагерьларга озаталар. Ул аларны узып, әйләнеп кайта һәм 1963 елда вафат була. Аның көрәштәшләре С.Якупов белән А.Шәфигуллин 1942 елда

ук төрмәдә вафат булалар, ә Шәйдуллин белән Фәхретдинов, фактлар җитмәү сәбәпле, ирекkә чыгарылалар.

Шулай итеп, 1862 елда башланган дога өзелде дисәк тә була. Хәзер алар турында тарихи истәлекләр генә калды. Тәсбих та таралды.

Соңгы сүз. XX гасырның 50—60 нчы елларында да вәисиләрнең улларын һәм оныкларын эзәрлекләүләр дәвам итә. 60 нчы елларда, беркадәр «җылылык» туган чорда, Гайнан Вәисевнең улы Мидхәт Вәисев бу хәрәкәткә кагылышлы материалларны җыю эшләрен башлап җибәрә һәм хәрәкәтне бозып язганнарга каршы көрәш башлый. Төрле архивларда, китапханәләрдә мәгълүмат туплаганнан соң, ул 1979 елда рус телендә Габдулла Тукай һәм Сәрдар Гайнан Вәисев турында китап яза. Монда ул Г.Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» исемендәге поэмасындагы образларның, татар әдәбиятчылары тарафыннан Вәисевкә карата булган язмаларын тәнкыйть итә. Гомумән алганда, ул *вәисиләр хәрәкәте* һәм Гайнан Вәисев образы турында объектив язуны таләп итә. Шушы ук мәсьәләгә багышлап, «Кемнәр соң алар вәисиләр?» дигән гыйбрәтле мәкалә дә яза. Әмма ул аны «Социалистик Татарстан», «Казан утлары»нда чыгарырга теләп редакцияләргә мөрәҗәгать итсә дә, аны тыңлаучы булмый — бөтен җирдә дә кире кагалар. Соңрак ул, сеңлесе белән берлектә, Партиянең Үзәк Комитетына — Михаил Сусловка һәм Михаил Горбачевка да мөрәҗәгать итә. «Гадел җавап» озак көттерми, барысы да большевикларча хәл ителә: Халыкара икътисад институтының өлкән хезмәткәрен, фән кандидатын — М.Вәисевне — эшеннән куып чыгаралар. 1987 елның 28 октябрендә Вәисева Хаҗәр Гайнан кызының Г.Усманов һәм М.Горбачевка язган хатында: *«Хождение по мукам» ветерана Отечественной войны, старшего научного сотрудника института международных отношении АН СССР, умышленно забаллотированного и выгнанного с работы только лишь потому, что он был большим правдолюбом, не терпящим несправедливости и лжи — следовательно, бывшим «неудобным человеком» для администрации института, который более 20 лет своей жизни потратил на поиск правды и справедливости, чтобы восстановить поруганную честь и доброе имя погибших революционеров, закончилось для него трагически — он рано ушел из жизни, раздавленный социальной несправедливостью»*[64], — дигән юллар бар.

«Дөреслек һәм гаделлек» өчен көрәшкән Вәисевләр хакында әле бүген дә шактый саллы хезмәтләрдә дә бер сүз язылмый, әйләнеп узыла. Моның сере бер генә — тыныч яшәү. Киресен эшләгәндә, шул ук Баһаветдин, Гайнан, Газизҗан, Мидхәт Вәисевләрнең язмышы көтелми дип кем әйтә ала? Шул ук вакытта тарихи дөреслекне белү, бабаларыбызның көрәш тарихын дөрес аңлау халкыбызның үзаңы, үсүе белән бәйләнгәнлеген истән чыгармаска кирәк. Бу уңайдан М.Вәисев сүзләре гыйбрәтле:

«Непременным условием существования самосознания народа является, как известно, Историческая память. Ее разрушение вносит в самосознание народа болезненные чувства своей неполноценности и обреченности, приводит его к пагубному самоотождествлению своей личности и всего народа с данным мгновением их бытия. Разрушение Исторической памяти убивает в народе духовную тягу к полноте личной и общественной жизни, национального самосознания, калечит его нравственно, уничтожает веру и надежду на возрождение, и, в конечнем счете, приводит к гибели народа как нации. Для этого не нужно его полного физического уничтожения — довольно лишь отнять у народа память, мысль, слово — и нация будет убита. А расцвет нации — это необходимая историческая ступень развития человечества в процессе его становления как властелина над силами природы. Замалчивание или искажение реальных исторических фактов и событий служат лишь недоброму делу разрушения исторической правды»[65].

Бу хәрәкәтне ничек кенә атасаң да, ул дөреслек, гаделлек, рухи чисталык өчен көрәш. Алар йөз ел дәверендә диктаторлар белән көрәштеләр. «Сектант»лар хәрәкәте кебек башланып киткән бу хәрәкәт акрын гына зур сәяси көрәшкә әверелде. Гайнан Вәисев беренчеләрдән булып Ислам социализмы концепциясен төзеде. Икътисад, сәясәт, мәдәният өлкәсендә дә большевиклар программасын тулы килеш диярлек үз программаларына керттеләр. Большевиклар бөтен мәсьәләләрне сыйныфлар көрәшенә таянып хәл итсәләр, вәисиләр Аллага — Исламга таяндылар.

Вәисиләр хәрәкәтенең көчәеп үсүенең төп сәбәбе — хезмәт ияләренең мәнфәгатьләрен чагылдыруда, программаларының эшче-крестьян һәм изелгән халыкларның «телләрен» искә алып төзелгәнлегендә. Чыннан да, большевиклар икътисади, сәяси, мәдәни мәсьәләләрне сыйныфлар көрәшенә таянып хәл итәргә теләсәләр, вәисиләр исә бөтен мәсьәләләрне Аллага, Коръәнгә таянып гамәлгә ашырырга омтылалар. *«Безнең бердәнбер бурычыбыз,* — ди Гайнан Вәисев, — *изге Коръәндә язылганны үтәү, ә моның өчен без ирекле булырга тиешбез, бер атка ике камыт кидермиләр. Патшаны хөрмәт итеп дога кылсак та, тик аның дәүләте безгә кирәкми»*[66], — ди. 1905 елның 17 октябреннән соң Гайнан Дәүләт Думасының да файдасыз икәнлеген ачык итеп әйтә.

Хәрәкәтнең көче, абруе аның җитәкчеләренең фидакарь хезмәтләре белән бәйләнгәнлеге көн кебек ачык. Алар, Коръәнгә таянып, Алла исеменнән хәрәкәт итсәләр дә, көндәлек сәясәтне аңлап, татар халкының киләчәге өчен борчылып, патша хөкүмәтеннән, төрле кумирлардан (диктаторлардан. — *Р.В.*), гомумән алганда, халыкларны барлык изүләрдән азат итү өчен программа төзүгә ирешәләр. Программалары тормышчан булганлыктан һәм халык мәнфәгатьләрен яклап көрәшүләрен күреп, массалар-

ның күп өлеше аларның идеологиясен кабул итә һәм көрәш юлына баса. Нәтиҗәдә вәисиләр 1917 елда большевикларга хакимияткә килергә, Россияне гомуммилли кризистан чыгаруга, аны бөтенләй таркалудан, анархиядән коткарып калуга да зур өлеш кертәләр. Совет хакимияте, авыр минутларда аларның көченнән оста файдаланып, вакыты җиткәч, дөресрәге, диктатураның ныгу этабы башлангач, хәрәкәтне, аның җитәкче органнарын, Газизҗан Вәисевне һ.б.ларны эзәрлекли башлый. Соңрак исә барысын да репрессияли. Шулай итеп, иң авыр чорларны кичеп, 20 нче елларда «Ислам социализмы» концепциясен тудыра алган көчле милли хәрәкәтнең бер агымы җимерелә һәм озак еллар дәвамында төрле эзәрлекләүләргә дучар ителә. Диктатура әлеге демократик хәрәкәтне дә юк итү белән генә чикләнмичә, бөтенләй тарихтан ук сызып ташлауны максат итеп куя. Шунысы аянычлы, әгәр демократия җиңеп чыккан булса, бу хәрәкәт әле бүген дә колониализм, фашизм, терроризм һ.б. негатив «измнар»га каршы көрәшләрдә үзенең лаеклы өлешен кертә алган булыр иде. Кызганычка каршы, 20 нче елларда, М.Солтангалиев әйтүенчә, бу хәрәкәткә фәкать бер генә кеше, ул да булса Фрунзе дөрес, уңай бәя бирә алган.

Чыннан да, аның рөхсәте белән 1919—1920 елларда Самара шәһәрендә «Илаһи полк»лар төзелә башлый. Хәрәкәт тиз арада үсә һәм ныгый башлагач, Совет хакимияте аларның юлына киртәләр кора, төрле юллар белән милли полкларны таратырга керешә. Нәтиҗәдә гомуммилли хәрәкәт 1918 елның 28 мартында туктала, *вәисиләр хәрәкәте* исә 1923 еллар тирәсендә бөтенләй таркала.

Вәисиләр хәрәкәтенең уңай яклары белән бергә кимчелекләре дә була. Борынгы Болгар дәүләтен торгызу, территориаль автономияне төзү омтылышлары белән бергә татарларны «болгарлар» дип атау хәзер инде мөмкин түгел, чөнки гасырлар дәвамында күп үзгәрешләр булды[67], тарих көпчәген кире борып булмый. Бүген дә бу фикер тирәсендә төрлечә сүзләр йөри, әмма нәрсә генә эшләсәк тә, ничек кенә уйласак та, тарихны кире кайтарып булмый. Шуңа күрә без, үзебезнең бабаларыбыз белән горурланып, аларга охшарга тырышып, татар милләтенең якты киләчәге өчен бердәм булып барын эшләргә тиешбез. Моның өчен безнең барыбызга да тарихыбызны дөрес аңлап, бер фикергә килүебез кирәктер. Төрлебез төрле якка тартсак, уңай нәтиҗәләр булмас: гадәттәгечә, көрәш түгел, ызгышу, талашу, бер-береңә ярлыклар тагу гына булыр. Шайтанга шул гына кирәк...

Вәисиләрнең руханиларга карата булган мөнәсәбәтләре дә катлаулы, чөнки бөтен дин әһелләрен дә хөкүмәткә сатылганнар дигән нәтиҗә ясау да дөреслеккә туры килми. Бу очракта сүз «хакимият тарафыннан сайлап куелган муллалар» хакында гына барырга мөмкин. Казан губернасының жандарм идарәсе полковнигы 1908 елның 28 августындагы доносында: «*Вәисев ха-*

кимиятнең берсенә дә буйсынмаска өнди, хакимият тарафыннан куелган муллаларны танымаска чакыра. Вәисевнең «Илаһи полк» сугышчылары гражданнар хакимиятенә бөтенләй буйсынмыйлар»[68], — дип яза. Нәтиҗәдә алар, мәчетләрнең, муллаларның эшләрен тәнкыйть утына тотып, «юынтык суы белән бергә баланы да чыгарып аталар». Шуның нәтиҗәсендә мөселманнар арасында (бигрәк тә 1918 елны. — *Р.В.*) тагы өстәмә рәвештә аңлашылмаучылык арта, бердәмлек булмый кала. Татарлар төрле партияләргә, оешмаларга, группаларга китеп таралалар, көчсезләнәләр. М.Вахитов, М.Солтангалиев, Г.Ибраһимов кебек сәяси көрәшчеләр дә, большевикларның кызыл «лозунг»ларына ышанып, революциягә алданып һәлак булалар. *Вәисиләр хәрәкәте* дә шундый ук язмышка дучар булды дисәк, дөреслеккә туры килә.

Гомумән алганда, *вәисиләр хәрәкәте* безнең тарихыбызда бик зур әһәмияткә ия. Чөнки XIX гасырның 60 нчы елларында башланып XX гасырның 17—20 нче елларында сәяси һәм милли-азатлык көрәшләренең аеруча киң колач алган чорында тагын да югарырак баскычларга менә алган бу хәрәкәт үзе эзәрлекләнеп юкка чыгу дәрәҗәсенә китереп җиткерелгән булса да, аның дәвамын без Африка, Азия илләре халыкларының бәйсезлек өчен алып барган көрәшләрендә ачык күрдек. Ислам диненә таянып хәрәкәт итүнең уңай нәтиҗәләре XX гасырның 70 нче елларында да ачык күренде. Мәсәлән, 1979 елда Ирандагы Ислам революциясе зур җиңү белән тәмамланды. Нәтиҗәдә Ислам революциясе Советы һәм Хәрби трибуналы төзелде. Рухулло Хомейни — тарафдарлары Аллага таянып һәм Ислам лозунгысы астында хәрәкәт итеп җиңүгә ирештеләр. Мәһди Сафариның сүзләре белән әйткәндә: *«Рухулло Хомейни Ислам революциясенең җиңәчәген исбат итте һәм аны тормышка ашырды»*[69]. Бу — тарихи факт. Рухулло Хомейни — шигыйлар, ә Б.Вәисов сөнниләр мәзһәбе вәкилләре булсалар да, алар икесе дә бер Аллага һәм Коръәнгә таянып хәрәкәт итү нәтиҗәсендә зур уңышларга ирештеләр. Гомумән, Ислам диненә таянып хәрәкәт итүче көчләр реакция, диктатурага каршы көрәштә әһәмиятле нәтиҗәләргә ирешәләр. Фашизмга, экстремизмга, радикализмга һәм башка шундый авантюраларга каршы көрәшләргә дөрес дини юнәлеш бирү шулай ук җитди әһәмияткә ия. Моңа бүген дә байтак дәлилләр китереп була. Амин!

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] *Ионенко И., Тагиров И.* Октябрь в Казани. — 1967.— С. 87.

[2] *Валеев Р.* Революционное движение в Среднем Поволжье (июль—октябрь 1917 г.).— Казань, 1979.

[3] Архив документларыннан караганда, монда сүз Ибраһим Нуруллинның 1965 елда нәшер ителгән «Дию» исемле мәкаләсе, 1966 елда чыккан Г.Тукай турындагы хикәяләре, 1986 елда дөнья күргән «Напевы мятежного саза» исемендәге хезмәтләре турында бара.

[4] Мәсгуд Гайнетдиновның язуына караганда, «секта»га нигез салучы Ягъфәр Салихов — Иске Кулаткада мәдрәсә тотучы билгеле бер ишан. Чыннан да, Салихов үзенең шәкертләренә «яхшы патша», «саф дин» булганда гына җәмгыятьтә дөреслек, гаделлек булачак кебек идеяләрне сеңдерә. Ул шулай ук Төркиягә таянмаска чакыра, чөнки ул башка дәүләт, ди. Кара: *Гайнетдинов М.* Прошение возвратить Б.Ваисову, а дело кончить // Гасырлар авазы (Эхо веков). — 1996. — 3/4; *Кемпер М., Усманова Д.* Ваисовское движение в зеркале собственных прошений и поэм // Эхо веков (Гасырлар авазы). — 2001. — 3/4.

[5] *Кемпер М., Усманова Д.* Ваисовское движение в зеркале собственных прошений и поэм // Эхо веков (Гасырлар авазы). —2001. — № 3/4. — С. 86—104.

[6] *Климович Л.* Ислам в царской России. Очерки. — М., 1936. — С. 158—159.

[7] *Климович Л.* Ислам в царской России. Очерки. — М., 1936. — С. 158—159; *Килдишев А.* Гайнан Вәисевнең тозагы — Казан, 1908.

[8] *Катанов Н.Ф.* Новые данные о мусульманской секте ваисовцев.— Казань, 1903.— С. 105.

[9] *Климович Л.* Ислам в царской России. Очерки. — М., 1936.— С. 161.

[10] Шунда ук. — 167—168 б.

[11] Гасырлар авазы (Эхо веков). — 2001. — № 3/4. — 93, 105 б.

[12] *Климович Л.* Ислам... — С. 152.

[13] Гасырлар авазы (Эхо веков). — 2001. — № 3/4.— 105 б.

[14] Шунда ук. — 118—121 б.

[15] ЦГАИПДРТ. — Ф. 823. — Оп. 2. — Д. 2. — С. 24, 57—58.

[16] Мидхәт Вәисев 1904 елны күрсәтә, ә кайбер хезмәтләрендә 1906 ел диелә.

[17] *Кемпер М., Усманова Д.* Ваисовское движение. — С. 90— 91.

[18] *Махмутова А.* Направить серьезные усилия к пресечению национально-татарского натиска // Эхо веков (Гасырлар авазы). — 1998. — № 3/4. — С. 69.

[19] Шунда ук.— 72 б.

[20] *Толстой Л.Н.* Избранные соч.— Т. 22.— С. 674.

[21] Шунда ук.— 308, 314, 466 б.

[22] Шунда ук.— 466 б.

[23] *Нурутдинов Ф.* Жизнь Сардара // Комсомолец Татарии.— 1989. — 9 июль.

[24] *Толстой Л.Н.* Полн. собр. соч. — Т. 79.— С. 30.

[25] *Толстой Л.Н.* Полн. собр. соч. — Т. 57.— С. 25—26.

[26] *Бирюков П.* Толстой и Восток // Мир Ислама. — № 6. — С. 399-400; *Молоствова Е. В.* «Божий полк». — СПб., 1912.— С. 149.

[27] *Толстой Л.Н.* Полн. собр. соч. — Т. 79.— С. 29—30.

[28] Шунда ук. — 120 б.

[29] *Толстой Л.Н.* 1909 елның 14—16 мартында М.М.Крымбаевка язган хатында *«...основа всех религий одна и та же: Любовь к Богу, т.е. к всевышнему совершенству, и к ближнему»*.

[30] *Толстой Л.Н.* Полн. собр. соч. — Т. 79.— С. 120.

[31] *Вәлиев Р. К.* Фаҗига. — Казан, 1996. — 77 б.

[32] *Тукай Г.* Сайланма әсәрләр. — Казан, 1956. — Т. 4.— 211 б.

[33] Шунда ук. — 214 б.

[34] *Тукай Г.* Произведения в 4-х томах.— Казань, 1955.— Т. 2. — С. 7—8.

[35] Ноксаным — җитешсезлегем, кимчелегем.

[36] *Тукай Г.* Сайланма әсәрләр. — Т. 1. — 214 б.

[37] *Тукай Г.* Шунда ук. — 211 б.
[38] *Вәлиев Р. К.* Болак арты республикасы. — Казан, 1999.
[39] *Валеев Р. К.* Революционное движение в Среднем Поволжье.— Казань, 1972. — С. 144—145.
[40] ЦГАРТ.— Ф.7080. — Ед. хр. — 114. — Л. 172; *Валеев Р.К.* Революционное... — С. 145.
[41] Шунда ук... — 144 б.
[42] *Вәлиев Р. К.* Болак арты республикасы... — 29 б.
[43] *Рәхимов М.* Сәрдар Вәисев Толстой янында // ВТ.
[44] НАРТ. — Ф. 823. — Оп. 2. — Д. 2.— С. 4—7. (Перевод Алмаева. — *Р.В.*)
[45] *Ваисов М. С.* Кто же все-таки ваисовцы?.. — С. 26. Копия статьи хранится в архиве автора. ГАОР СССР. — Ф 1318. — Оп. 11. — Ед. хр. 655.
[46] НАРТ. — Ф. 823. — Оп. 2. — Д. 2.— С. 14.
[47] Шунда ук.— 16 б.
[48] Шунда ук.— 17 б.
[49] Шунда ук. 48 нче телеграмма.
[50] Шунда ук. 33 нче телеграмма.
[51] НАРТ. — Ф. 823. — Оп. 1. — Д. 2.— С. 65—66.
[52] Шунда ук.
[53] Шунда ук.— 68 б.
[54] НАРТ. — Ф. 823. — Оп. 2. — Д. 2.— С. 1—3.
[55] *Вәисов М.* Габдулла Тукай. — С. 115.
[56] Большевикларның каршылыгы нәтиҗәсендә ике республиканың да төзелүе игълан ителмичә кала.
[57] Алдагы вакыйгалардан күренгәнчә, бу акт белән генә *вәисиләр хәрәкәтен* туктату мөмкин булмый. НАРТ. — Ф. 823. — Оп. 2. — С. 2.
[58] Знамя революции. — 1918. — 6 апр. Чынлыкта Болак артында «Идел-Урал өлкәсе»н игълан итүгә каршы көрәш бара.
[59] Рабочее дело. — 1918. — 17 (30) марта.
[60] Шунда ук.
[61] Тайны национальной политики РСДРП. Стенографический отчет секретного IV Совещания ЦКРКП. 1923 г. — М.: Инсан, 1922.
[62] НАРТ. — Ф. 823. — Оп. 2. 28 нче телеграмма.
[63] *Климович Л.* Ислам... — С. 149.
[64] НАИПДРТ. — Ф. 824. — Оп. 2. — Д. 2. — С. 5.
[65] *Ваисов М.* Г.Тукай и Сардар Гайнан Ваисов.— М., 1979. — С. 69.
[66] *Климович Л.* Ислам ... — С. 156.
[67] Искәндәр Измайлов бу турыда *«бүген яшәүче халыкларның берсе дә урта гасырлардагы этносларның турыдан-туры нәселе түгел»* икәнлеген әйтә. Кара: *Измайлов И.* Татар милләтен бергә туплауда тарихи үткәннең факторы // Мирас. — 2002. — № 9. — 96 б.
[68] *Климович Л.* Ислам... — С. 163.
[69] *Хомейни Имам.* Путь к свободе.— М., 1999.— С. 10.

«МИЛЛИ ТАЙПЫЛЫШ»

Казан коммунистларының үзләре арасындагы аңлашмау бигрәк тә Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының Мәскәүдә булып узган беренче җыенында күренә. Монда төп мәсьәлә булып Шәрык һәм милли проблемалар була. Беренче төркемнәр 1918 елда ук күренә башлый.

М.Солтангалиевнең язуына караганда, *«Первая группа, состоявшая из так называемых «вахитовцев» и руководимая после смерти М.Вахитова мной, в национальном вопросе стояла на точке зрения, которая затем, в 1919 году, была проведена на VIII партийном съезде и на которую встал сейчас окончательно товарищ Сталин. По восточному или, скорее, колониальному вопросу мы еще тогда развивали, правда, не в таких ясных формах, как сейчас, ту точку зрения, на которую встал в этом вопросе II съезд коммунистов Востока в 1919 году, затем и II Конгресс Коминтерна. В этой группе кроме меня были товарищи Фирдевс и турецкие коммунисты во главе с Мустафой Субхи»*[1].

«Уңнар» һәм «суллар» шушы вакыттан соң милли мәсьәлә буенча үзара көрәшә башлыйлар. Алар турында сүз барганда Үзәкне дә онытырга ярамый, чөнки «уңнар», «суллар»ның барлыкка килүе дә Үзәкнең сәясәтенә, дөресрәге, аның астыртын сәясәтенә турыдан-туры бәйләнгән. Материаллардан күренүенчә, гадәттә Үзәк аларның үзара мөнәсәбәтләрен «керосин сибеп» сүндерергә тырыша. Шуның нәтиҗәсендә 20—30 нчы елларда Татарстанда милли мәсьәлә, Совет органнарына җирле халыкны тарту, колхозлаштыру, индустрияләштерү һәм башка мәсьәләләр хакында да алар, бәхәскә кереп кенә калмыйча, шактый гаугалы көрәш җәелдерәләр.

Шунысын да истән чыгарырга ярамый: «уңнар» өчен төп мәсьәлә — милли проблема, колониаль мәсьәлә булса, «суллар» исә андый мәсьәләне күтәреп чыкмый, алар уйлавынча бу хәл ителгән мәсьәлә дип санала. Болар фәкать хакимиятне яулап алу, ничек кенә булса да аны «уңнар»га бирмәүне кайгырта, бу эшләрен «чын интернационализм»га таянып эшлиләр.

Бәйнәлмиләлчеләр Шәрык коммунистлары съездында үзләрен «сул коммунист-бухаринчылар» дип атыйлар. Бухаринга килгәндә, шуны әйтергә кирәк: ул автономияне «кой-кому» — кайберәүләргә бирергә ярый, ди. «Кой-кому» дигәнгә ул һиндстанлы, бушменнар, готенготларны гына кертә. Башкача әйткәндә,

татарларга автономия бирүне ул кирәк дип санамый. В.И.Ленин, аны тәнкыйть итеп, без автономияне башкортларга бирдек һәм шул ук сәясәтне Шәрык регионнарында дәвам итәчәкбез, ди. Бу карашлардан чыгып эш иткәндә «суллар» һәм «уңнар»га бүленүләрне Үзәк китереп чыгарганлыгы күренеп тора. 1920 елның 14 октябрендә РКП(б) Үзәк Комитетында М.Солтангалиев сөйләгән докладта «суллар»дан Исмәгыйль Рәхмәтуллинны, Исхак Рәхмәтуллинны, Камал Каспранскийны, Дәүләт Али Мәхмүт, Хәсият Гайнуллиннарны атап китә һәм аларга карата тискәре бәяләмә бирә. «Суллар»дан тагы Галиулла Касыймовны, Ибраһим Галиевне, Каюм Саттаровны, Шәһид Әхмәдиевне, Урмановны, Әминә Мөхетдинованы һәм башкаларны да саный. Алар белән Казанда Сәетгалиев җитәкчелек иткәнлегенә дә басым ясый.

Шәрык коммунистларының II съездында үзара көрәш тагын да кискенләшә төшә. М.Солтангалиевнең сүзләренә караганда, «суллар» «уңнар»га өч юнәлештә басым ясый: *«а) Со стороны противников идеи Татаро-Башкирской республики. Тут соединились два противоположных течения: Шамигулов и подпавший под влияние башкирских националистов Каспранский... б) Со стороны «левой группы гумметистов» в лице Нариманова и Исрафилбекова... в) Саид-Галиева, который старался доказать, что мы в сущности будто бы ничем не отличаемся от наших националистов»*[2]. Соңгы пунктка игътибарсыз калу дөрес булмастыр, чөнки 1918 елдагы милләтчеләр һәм ул еллардагы «суллар», милли мәсьәләләрдә бердәм була алмыйча, үзара каты бәрелешәләр. Милләтчеләр бердәм административ берәмлек өчен көрәшсә, «суллар» Совет хакимиятен ныгыту юнәлешендә эш алып баралар. Миңгәрәй Сәгыйдуллинның күрсәтмәләренә караганда әлеге «суллар» 1918 елгы кораллы алыш вакытында, ягъни «Болак арты республикасы»на каршы көрәш чорында Казан Советы яклы булдылар, съездларда алар сул фракцияләр оештырдылар. Бу чорда М.Солтангалиев үзе дә «сул» булып гамәл кылды, милләтчеләргә каршы торып, Советны яклады. Әлеге вакытта рус коммунистлары да «суллар» яклы иде.

Шулай итеп, Шәрык коммунистларының II съезды бу өлкәдәге үзгәрешләрне яхшы чагылдырды. Монда М.Солтангалиев, 1918 елдагы Ильяс Алкин кебек, татар-башкорт бердәмлеге өчен көрәшә. Әмма инде хәзер, табигый рәвештә, Алкин роленә дучар булган Солтангалиевнең дошманы — «суллар» җитәкчесе Сәетгалиев үзен иркен тота, чөнки аңа астыртын һәм ачык рәвештә Үзәк булышлык күрсәтеп бара. Безгә 1918 елда Солтангалиевкә Үзәк һәм Казан Советының булышып торганлыгы билгеле. Татар әйтмешли, дөнья куласа — бер әйләнә, бер баса. Үз тирәсендә менә шундый хәлләр килеп чыкмаслыгы хакына бердәм хәрәкәт итү кирәклеген аңлаган Солтангалиев, татар коммунист-

лары арасындагы бүленүне тагын да тирәнгәрәк җибәрмәс өчен килешенеп, Шәрык коммунистларының Үзәк бюросына Сәетгалиевне кертергә карар кылынгач, ул сайлау вакытында күпчелекне алганнан соң, әлеге бүленүне көчәйтеп кенә җибәрә. Нәтиҗәдә Үзәк бюро рәислеген Сәетгалиевкә бирергә мәҗбүр булалар. Солтангалиев үзе моның турында: *«Сделал я это и по тому соображению, что в это время из-за различных интриг против меня РКП(б) ко мне питал скрытое недоверие. Мне было известно, что за мной установлен надзор особого отдела ВЧК.*

Произошло это потому, что II съезд коммунистических организаций Востока, которым я руководил, происходил в условиях полной провокации, связанных со стечением целого ряда обстоятельств и без малейшей вины с нашей стороны. Центральный Комитет почему-то не захотел объективно разобраться во всем этом, но я ошибся. Дальнейшее поведение тов. Саид-Галиева ясно показало, что, добиваясь места председателя Цебюро комнарвостока, а затем председателя Татревкома, он имел совершенно другие задачи», — ди[3].

1920 елның 10 июнендә ТАССР ревкомы составы хакындагы карар кабул ителә. Ул 7 кешедән тора. Аның рәисе итеп Сәхипгәрәй Сәетгалиев куела. Комитетка шулай ук Исхак Казаков, Кәрим Хәкимов, Кәшшаф Мохтаров, Ходоровский, Бочков, Гольдберг һәм Гольдбергның урынбасары итеп Жарко кертелә[4]. Рәис булып алганнан соң ул, Солтангалиев әйтмешли, үзен «ликвидатор» итеп күрсәтә. Сәетгалиев Татарстанда чын «суллар»ча, милли мәнфәгатьләр хакына көрәшүчеләрдән котылу өчен барысын да эшли. Шул сәясәтне тормышка ашыруда аңа рус коммунистлары, автономиягә каршы булган Казан губкомы, Баймбетов, Атнагулов һәм башкалар зур булышлык күрсәтәләр. Г.Касыймовның фикеренчә, *«В Казани образовалась группа твердых коммунистов для решительной чистки Татарской республики от татарских националистических коммунистов»* («уңнар». — *Р.В.*)[5]. Нәтиҗәдә кыска гына вакыт арасында милли коммунистлардан И.Фирдевс, Ш.Усманов, Г.Мансуров, О.Мамин, И.Казаков, Р.Алмаев, К.Хәйруллин, А.Алимбәкова, Кадриков, М.Борындыков, Н.Вахитов, А.Енбаев, А.Ганиев, Сөләйманов, Ф.Бурнашевлар Татарстаннан чыгып китәргә мәҗбүр булалар. Моннан кала Сәетгалиев тырышлыгы белән РКП(б)ның татар секцияләре бетерелә, Казаннан татар полклары чыгарыла. Матбугат битләрендә «суллар» тарафыннан махсус әзерләнгән мәкаләләр дөнья күрә. Боларның барысы да Үзәк мөселман коллегиясенә һәм башка милли оешмаларга да яла ягу эшләрен җәелдерүгә юл ача, «Кызыл Армия» гәзитенә дә «эләгә». Имеш, әлеге басма дөрес сәясәт алып бармый. Моның хакыйкатькә туры килмәгәнлеге бу гәзитне укуга ук аңлашыла. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе органы буларак, «Кызыл Армия»дә ТАССР төзелү көннәрендә,

аннан соң да милли мәсьәләләр хакында бик кызык мәкаләләр чыккан. Шулардан бер-икесен генә атап китик. 1920 елның 16 июнендә Галимҗан Шәрәфнең «Республика мөнәсәбәте белән», ә соңрак «Татар җөмһүрияте татар баласына нәрсә бирә ала?» дигән бик тә кызыклы мәкаләләре дөнья күргән. Мондый язмалар, чыгышлар ревком рәисен бик борчый, чөнки алар суны «уңнар» ягына агызалар. Бу чорда «уңнар» башында М.Солтангалиев торганлыгын искә алсак, бу бик җиңел аңлашыладыр. Ул гына да түгел, республиканың хакимият оешмаларында «чехарда» бара. Ике ай дигәндә Юстиция халык комиссариатында 5 җитәкче алышына, Татарстан Хәрби комиссариатында — 4, Эчке эшләр халык комиссариатында — 3. Акрынлап Татарстанда Сәетгалиев һәм аның иптәшләренең кылган гамәлләре халык арасында зур канәгатьсезлек уята башлый.

Шулай итеп, илдә тәртипсезлек, эшсезлек киң таралганда, Сәетгалиев үзенең халык арасында, шулай ук татар коммунистлары арасында да бик тә кыйммәтле зат икәнен күрсәтү өчендер инде, Сталин кушуы белән үзенә «һөҗүм» оештыра[6]. М.Солтангалиев фараз кылганча, әлеге һөҗүм Үзәк мөселман коллегиясе җитәкчеләрен кулга алу өчен сылтау рәвешендә генә оештырылган, чөнки татар коммунистлары, эсерлардан, большевиклардан аермалы буларак, шәхесләргә карата террорны баштан ук кире кагалар. Сәетгалиевкә «һөҗүм» ясауның ихтыяҗы юк, чөнки һөҗүм контрреволюцияне активлаштыруга гына сәбәп бирер иде. Ә моңа «уңнар» гына түгел, ә бәлки «суллар» да каршы. Әгәр дә һөҗүм чыннан да оештырылган булса, Сәетгалиев бәләкәй тырналу белән генә котылып кала алмас иде. Чынлыкта бу Сәетгалиев һәм аның иптәшләре Борһан, Конов, Яруллин, Гайнуллин һәм башкалар оештырган сәяси бер спектакль генә булган. Шулай эшләгәндә оппозицияне дә юк итәргә мөмкинлек булачак. Шулай итеп, «бүре дә тук, сарыклар да исән». Солтангалиевнең язуы буенча, *«Этим трюком, очевидно, Саид-Галиев хотел убить двух зайцев: оклеветать и загрязнить навсегда и убрать с политической сцены «конкурентов» в лице той группы, против которой он боролся, а во-вторых, поднять его поколебавшийся «авторитет» в глазах народных масс, разыгрывая из себя «татарского Ленина»*[7].

Бу вакытта Сәетгалиевкә һәм аның эштәшләренә Атнагулов белән Баймбетовлар булышалар. Алар Казаковны, Усмановны һәм Борындыковны тәнкыйть итәләр. Шулай итеп, бу иптәшләр «уңнар»ны эзәрлекләүләрдә катнашып, «сул бәйнәлмиләлчеләр» булып китәләр. Аларның элеккеге сул эсерлыклары һәм шәхсән үпкәләре дә тәэсир итмәгәндер дип әйтеп булмый.

Шулай итеп, «суллар» үзләрен сул интернационалистлар дип санап, татарист «уңнар»га киң рәвештә һөҗүм оештырырга телиләр. Алар, «уңнар»ны шуристларга тиңләгән сурәттә тәнкыйть итеп, ахыр чиктә Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең дә абру-

ен төшерергә телиләр. М.Борындыков бу турыда, «суллар»га татар-башкорт сул эсерлары булыштылар, ди. *«Они клеймили татаризм, называя его алкинизмом. Татарскую республику называли «Забулачной республикой»*. М.Борындыковның фикеренчә, ул вакытта (1919) Казанда «уңнар»ны Исхак Казаков, Нәби Вахитов, Шамил Усманов, Гали Ганиевлар, «суллар»ны бертуган Рәхмәтуллиннар, Касыймов, Галимҗан Ибраһимов, Гыйлемдар Баймбетов, Сәлах Атнагулов, Әхмәтҗан Алмаев, Фатыйх Сәйфи, Хаҗи Габидуллин, Әминә Мөхетдиновалар җитәкләгән. Борындыковның сүзләре буенча, «сул»дан «уң»га күчү табигый хәл, чөнки алар икесе дә бер медальнең ике ягы, ди.

Бер мәсьәлә дигәне — милләт мәсьәләсе. Бу күчешләр Солтангалиевнең үзенә, Борындыковка һәм башкаларга да кагыла. Иң кызыгы, бәлкем, шундадыр: 1918 елда II Мөселман съезды эшләгән көннәрдә, «сул» була торып, «уң»нар белән көрәшеп йөргән Солтангалиев 1919—1920 елларда үзе дә «уң» булып китә, II Мөселман съезды идеологлары белән тыгыз элемтә урнаштыру мәсьәләсе килеп чыга. *«Ул вакытта «уңнар» платформасы нигезендә Татар республикасын, элеккеге сул эсерлар Татар-Башкорт республикасын төзүне алга сөрделәр»*, — ди М.Борындыков. *«Суллар» исә икесен дә инкарь итәләр. «Правыми» националистами и левыми эсерами одновременно фактически руководил Султан-Галиев (эсеры и правые, главным образом, работали в Военной коллегии), а левыми — Саид-Галиев... С приездом Фирдевс и Валидова правая группа значительно усилилась. С согласия губернского бюро коммунистов-татар в помещении Военной коллегии собрали совещания актива коммунистов-татар, куда преимущественно были приглашены правые, где я сделал сообщение о своевременности постановки вопроса о Татарской республике и созыве II съезда Комвостока. Совещание после долгих прений в общем одобрило мои тезисы и поручило мне, Енбаеву, Казакову, Фирдевсу и Шамилю Усманову подготовить к конференции коммунистов-татар Казанской губернии проект положения о будущей республике и географическую карту. Комиссия... привлекла к этой работе Идел-Уралиста Галимджана Шарафа... надо было еще завоевать симпатии виднейших представителей татарской интеллигенции, которые еще играли роль в создании общественного мнения... таковыми в то время являлись братья (Гильми, Бурган, Галимджан) Шараф, писатель Фатих Амирхан, историк Газиз Губайдуллин, Ибрагим Биккулов, Хадича Ямашева, Джамал Валиди, Мухутдин Корбангалиев, Фатих Мухамадьяров»*[8]. Нәтиҗәдә татар коммунистларының губерна конференциясендә Татар республикасына каршы булган фәкать өч кенә делегат сайлыйлар. Алар — Гасыйм Мансуров, ирле-хатынлы Баймбетовлар. (Соңрак Г. Мансуров үзе дә «уңнар» ягына күчә.)

Шәрык коммунистлары оешмаларының 1919 елның декабрендә булып узган съездында республика мәсьәләсендә өч фракция хәрәкәт итеп, шуннан шактый тавыш-гауга килеп чыга. *«Второй съезд Комвостока распался на три группы (фракции): татаристов, татаро-башкиристов и антиреспубликанцев. Татаристов возглавлял Микдат Борындыков, татаро-башкирцев — Салах Атнагулов и Галимджан Ибрагимов. Присутствовал беспартийный Галимджан Шараф как докладчик по вопросу о Татарской республике»*[9]. Солтангалиев татаристларны һәм татар-башкортчыларны бергә хәрәкәт итәргә өнди. Ул Башкорт, Татар республикалары булсын, ә соңыннан без аларны берләштерербез, ди. Татар республикасына Төркестаннан Ибраһимов, азәрбайҗанлылардан Нариман Нариманов һәм Әфәндиевләр каршы чыгалар. Нәтиҗәдә, ике проектның да узмаслыгы билгеле булгач, күпчелек Татар-Башкорт республикасын сайларга карар кыла.

Әлбәттә, мондый хәлнең килеп чыгуы очраклы гына булмаган, чөнки съезд делегатларына, бигрәк тә антиреспубликачыларга һәм аларның җитәкчесе Сәетгалиевкә Сталинның тәэсире булганлыгы көн кебек ачык.

Соңрак, 1919 елның 13 декабрендә, Политбюро Татар-Башкорт Социалистик Республикасы турындагы декретны юкка чыгару хакында карар кабул итә. Шулай булса да, Үзәк Комитеты каршында Татар республикасы мәсьәләсен карау мөмкинлеге кала. Менә шушы вакытта Сәетгалиев үз-үзен күрсәтә дә инде. Күргәнебезчә, Татарстан революцион комитетына Солтангалиев, М.Борындыковлар да кертелми. Бу — әйтелгән фикеремне исбат итә торган дәлилләрнең берседер. М.Борындыков бу хакта: *«Мы с одобрения Султангалиева решили саботировать Ревком во главе с Саид-Галиевым и как можно скорее провалить его. На II съезде Советов... правым действительно удалось провалить левых, причем правые играли на самых больных струнах населения; они распространяли слухи о том, что голод в Татарии ужасающие размеры принял потому, что Саид-Галиев, желая выслужиться перед Москвой, весь хлеб из нее (Татарии) выкачал в другие области»*[10]. Турыдан-туры «уңнар»ны бу вакытта Кәшшаф Мохтаров, Юныс Вәлидов, Исхак Казаков, Шамил Усманов, Фирдевс һәм Енбаевлар җитәклиләр. Нәтиҗәдә көрәш «уңнар» файдасына була һәм 1921—1923 елларда аларның хакимияте уңышлы гына эшли. Халык Комиссарлары Советы рәисе итеп Кәшшаф Мохтаров, Татарстан Үзәк башкарма комитеты рәисе итеп Рәуф Сабиров, мәгариф халык комиссары итеп М.Борындыков сайлана. Кайбер тарихи хезмәтләрдә бу хакимиятне «Кәшшаф Мохтаров хакимияте» дип атыйлар.

«КӘШШАФ МОХТАРОВ ХАКИМИЯТЕ»

Хакимияткә килгәч, «уңнар» икътисади һәм сәяси проблемалар белән бергә татар теле мәсьәләсен һәм аның бердәнбер дәүләт теленә әверелергә тиешлеген хуп күрәләр. Татар халкының хакыйкый тарихын язу мәсьәләсе дә көн тәртибенә куела, М.Худяков, Г.Шәрәф һәм башкаларның хезмәтләре шушы чорда нәшер ителә. 1552 елдан соң Казан тирәсеннән куып җибәрелгән татарларны туган якларына кайтару мәсьәләләре дә күтәрелә. Шушы елларда Кызыл Байрак, Нариман, Яңа Болгар һәм Бакчасарай бистәләре төзелә. Казанда Чыңгыз бистәсенә (Нагорный) нигез салына.

Башта «уңнар» сәясәтен Үзәк тә хуплый. Казанга килгән махсус комиссия дә гаеп тапмый, әмма хәл 1923 елның 9—12 июнендә РКП(б)ның махсус яшертен уздырылган киңәшмәсеннән соң, «солтангалиевчелек»кә каршы көрәш башланганнан соң, әлеге дә баягы «уңнар»ның хәле авырая. Ә соңрак исә хәлләр башкача рәвеш ала. Монда инде «суллар» да әллә ни кора алмый. Шушы вакыттан башлап «уңнар» һәм «суллар» көрәшендә яңа чор башлана.

«Уңнар» хакимияте, аның нигезе хакында М.Борындыковның язмасында шактый кызык расланма тупланып калган. Ул 1922 елны Татарстанга эшкә кайта. Ул вакытта «уңнар»ның үзәгенә түбәндәге кешеләр кертелгән була: Кәшшаф Мохтаров, Гасыйм Мансуров, Ариф Енбаев, Микъдәт Борындыков, Гали Ганиев, Гыймаз Баһаветдинов, Шамил Усманов, Гыйлаҗ Фәсхетдинов (Фәсхи), Рәүф Сабиров, Юныс Вәлидов.

«Правые» в то время были у власти и все вопросы партийного и советского порядка, прежде чем они поступали на рассмотрение соответствующих официальных организаций, подвергались обсуждению в вышеуказанном центре правых националов.

На заседания центра очень часто приглашались еще Николай Петров, Ахняф Шакиров (тогдашние секретари Татцика), Исхак Казаков, Абдулла Валеев, Хафиз Сайфи, Саттар Еникеев, Ахмед Умеров... Максудов, братья Балтановы и др. В более важных случаях созывался весь актив «правых».

М.Борындыковның язганнарына караганда, «уңнар»ның платформасы түбәндәгечә билгеләнгән булган:

«1. Форсированное переселение татар без разделения их на кулаков и трудящихся на свободные земельные участки по берегам больших рек у трактовых дорог и вблизи от железных дорог;

2. Вовлечение в средние и высшие учебные заведения максимального количества татарской молодежи, без разбора ее классовой принадлежности;

3. Форсированная татаризация учреждений и форсированная реализация татарского языка в них;

4. Особые налоговые и кредитные льготы татарским селениям;

5. Форсирование роста количества татарского пролетариата;

6. Создание татарского капитала (Татбанк)»[11].

Зинданда язылган бу язмаларның дөреслеккә туры килүе шик уятмый, әмма «уңнар» платформасының татар халкына түгел, ә бәлки буржуазия өчен файдалы дип күрсәтелүе НКВД хезмәткәрләренә ошарга теләүдән икәнлеге дә мәгълүм. Әйтергә кирәк, шушы платформаның татар теленә генә кагылган өлеше тормышка ашырылган булса да, бүгенге көнге бик күп мәсьәләләр җиңел хәл ителгән булыр иде. Ул вакытта мәктәпләрдә укыган руслар әле бүген дә рәхәтләнеп, безне шаккатырып татарча сөйләшәләр. *«Телне ничек шулай яхшы беләсез?»* — дип сорагач, алар: *«Ә безне егерменче елларда мәктәптә яхшы укыткан нар иде»*, — диләр. Әлбәттә, бу хәл татар халкы белән рус халкын дус итә. Шуңа күрә М.Борындыковның бу платформа русларга каршы дип нәтиҗә ясавы НКВД үзенә шәфкать күрсәтмәсме дигән өмете икәнлеге ачык. Ике телне дә яхшы белү ул — бергә тигез, матур яшәүнең бер чарасы гына бит.

«Уңнар» эшчәнлегенең бер нәтиҗәсе буларак, 1921 елның 3 декабрендә Мәгариф халык комиссариаты коллегиясендә Академүзәк оештыру хакында карар кабул итүне дә күрсәтеп китү бик тә урынлы[12]. Аның беренче рәисе итеп Гаяз Максудов билгеләнә. Шул ук вакытта ул «Мәгариф» журналы мөхбире дә булып тора. 1921—1924 еллар — Академүзәкнең оештыру еллары, һәм бу эшләрне «уңнар» бик тә уңышлы башкаралар. К.Мохтаров — Халык Комиссарлары Советы рәисе — Академүзәккә бик зур игътибар биреп, аңа шактый зур матди ярдәм күрсәтеп тора[13]. Беренче көннәрдән үк Академүзәк фән, мәгариф, нәшрият үзәгенә әйләнеп, хәтта «Мохтаров хакимияте»н туздырганнан соң да бик уңышлы эшләп бара. Әмма 20 нче еллар азагында һәм 30 нчы елларда аның эшенә тыкшынулар арта. Татар белеме бүлеген һәм шулай ук музейлар, тарихи истәлекләрне саклау, ә торабара башка бүлекләрне дә ябу Академүзәккә идеологик басымның артуын күрсәтә. Нәкъ менә шуның нәтиҗәсендә Татарстан тарихын өйрәнүдә уңышлы гына башланган эшкә чикләр куела башлый, ә тора-бара бу эш бөтенләй туктатыла. Өйрәнелгән очракта да вакыйгаларны бозып күрсәтү кебек фактлар күбәя. Н.Н.Фирсовның раславына караганда, Татарстан тарихын өйрәнү бөтенләй бетү хәлендә була.

Мондый эшләрне Совет хакимияте, партия оешмалары, бигрәк тә Сталин җитәкләгән Үзәк алдан уйлап башкара. Бу кара гамәлләрне кылуда 1923 елда әле беренче тапкыр милли хәрәкәтнең җитәкчесен, ә бу елларда Сталин хакимиятенең бер әгъзасын кулга алып, аны төрле-төрле контрреволюцион эшләрдә гаепләп партиядән дә кугач, икенче төрле итеп әйткәндә, «сол-

тангалиевчелек» тә барлыкка килгәч, татар зыялыларына да каршы кара сәясәт җәелдерелә.

К.Мохтаровның үзенә 1923 елда бирелгән бәяләмә белән танышу, аның хезмәтләренә дә беркадәр ачыклык керту булырдыр.

«Характеристика на Мухтарова К. Г.

5 ноябрь,1923 г.

Тов. Мухтаров К.Г., как партийный и советский работник, является безусловно весьма крупной величиной. Работа его в условиях национальной республики, при необходимости быть чутким в проведении национальной политики, является безусловно весьма ответственной. Тов. Мухтаров является одним из лиц, кои призваны проводить корабль по опасным руинам, по путям, намеченным ЦК РКП(б), и со своей работой справляется вполне успешно. Если принять во внимание те условия, в которых ему приходится вести руководство партийной и советской работой при наличии различных течений и оттенков в вопросе национальной политики, то приходится констатировать, что партийная линия и директивы ЦК им проводятся твердо и неуклонно. Что же касается Советской административной, хозяйственной и финансовой работы, то здесь тов. Мухтаров является почти фактически их руководителем. Среди деловых, финансовых и хозяйственных кругов тов. Мухтаров является неоспоримым авторитетом и его мнение в этих вопросах является выражением мнения большинства. Как человек с высшим образованием и законченной марксистской подготовкой, будучи чрезвычайно компетентным во всех отраслях работ, тов. Мухтаров является безусловно незаменимым работником на занимаемом им посту председателя Совнаркома.

Единственная у него имеется слабая сторона, это страсть к спорту вообще и к футбольной игре в частности, однако и здесь тов. Мухтаров как человек практический извлекает несомненную пользу, ибо последняя является укрепляющей его физическое состояние, дает бодрость духу и служит неисчерпаемым источником его энергии.

Тов. Мухтаров к подчиненным является наилучшим товарищем, отзывчив на их нужды и запросы и во всех начинаниях, направленных на сторону улучшения быта и положения, всегда идет первым навстречу. В отношении соблюдения коммунистической этики тов. Мухтаров также является примерным членом ВКП(б).

Зам. председателя Совнаркома И. Казаков»[14].

К.Мохтаров хакында Америка миссиясе составында Россиягә килеп ике ел ярым эшләп киткән Канзас шәһәре вәкиле Джон К.Бонд та, үз иленә кайткач, Мохтаров, Сабиров һәм аларның иптәшләре хакында: *«Алар ягымлы, көчләре ташып торган зы-*

илы һәм эшчән кешеләр иде. Бөлгенлеккә төшергән сугыштан соң аларның төбәкне аякка бастыру өчен кылган гамәлләре инде һәм азык-төлеккә бай булган Франция өчен дә дәрәҗә саналыр иде. Аларның америкалыларга мөнәсәбәте мәрхәмәтле иде», — дип язган[15]. Чыннан да, аның бердәнбер «җитешсезлеге» — футбол уйнау. Ул бит бу өлкәдә дә гади шар тибүче генә түгел, ә оста уенчы булган. Ул Пермь шәһәренең беренче командасында, Казанда эшләгәндә Идел буе командасында, шулай ук «Серп и молот», Сәламәтлек халык комиссариаты командаларында да уйнаган.

Шулмы гаеп? Бу нәрсә аның «гаебе» икән, монда мантыйк кайда соң?

СОЛТАНГАЛИЕВ, «УҢНАР» ҺӘМ «СУЛЛАР»

Яшерен киңәшмә җыелыр алдыннан Солтангалиев, төркемнәр арасындагы аңлашылмаучанлыкны бетерергә тырышып, партияне сәламәтләндерү турында хыялланып эш итә: «*Давайте оздоровим нашу среду, давайте прекратим всякую групповую борьбу твердым установлением внутри себя нормальной партийной дисциплины и решительной борьбой с каким бы то ни было уклонением как в сторону мелкобуржуазной стихии, так и анархосиндикализма... мы можем начать организованное привлечение в нашу среду татаро-башкирских рабочих. Иначе мы их будем только развращать, заражая их своими болезнями, и от этого кроме вреда никому пользы не будет...*»[16]. Бу беренчедән. Икенчесе: советларның 1922 елда булып узган X съездында СССРның төзелеше хакында да Солтангалиев, Сталинның фикеренә баш имичә, үз фикерен әйтә. РКП(б) фракциясе утырышындагы чыгышында ул СССРны төзүдә ике төрле юл барлыгын әйтә. «*Первый путь, который определяется докладом Сталина, именно объединение в Союз четырех республик: РСФСР, Украины и Белорусии и создание ЦИКа и СНК. Второй путь, который по нашему мнению являлся бы более правильным, — это путь прямого вхождения отдельных республик в Союз и не в составе федеративных образований. Мы находим, что форма слияния независимых республик лишь в составе федерации, которая выставляется в докладе т. Сталина, создает только лишнюю проволочку, лишнюю инстанцию...*»[17].

М.Солтангалиев 1923 елның 25 апрелендә РКП(б)ның XII съезды секциясендәге чыгышында: «*Постановка вопроса, которая предлагается Сталиным, не разрешает национального вопроса, и мы принуждены будем опять возвращаться к этому вопросу, если не поставим его кардинально*», — ди[18]. Төп фикер СССРга турыдан-туры керү, ә Сталин фикеренчә, бары тик РСФСР

аркылы керү. Бу мәсьәләдә Солтангалиев, Грузия вәкиле Мдивани фикерен хуплап, СССРга турыдан-туры бөтен милли республикалар керергә тиеш, чөнки милләтләрне сортларга бүлеп, берсенә керергә ярый, ә икенчеләренә ярамый дип әйтү дөрес түгеллеген ачык итеп әйтә. *«Если мы внутри Союза Советских Республик сохраняем принцип федерирования отдельных национальных частей этого союза, т.е. допускаем для Закавказья, почему мы не должны допустить это в отношении других частей, допустим, Туркестана, Киргизии, Башкирии, Бухары и т.д.»*[19]. Солтангалиев РКП(б)ның милли сәясәте хакындагы тезисларында, И.Сталинның 1923 елның 4 маенда төзелгән милли мәсьәләләрдәге карашына бәя биреп, бу сәясәт ленинизмнан баш тарту, артка чигенү, чынлыкта милли сәясәтне юкка чыгару дип бәяли. Ул башка республикалар белән беррәттән рус республикасын төзү мәсьәләсен дә күтәреп чыга[20].

Бүген инде кайсы сәясәтнең дөрес икәнлеген тарих үзе исбат итте. Шулай итеп, Солтангалиев милли мәсьәләдә үзе дә, «милли тайпылышчы» булып, И.Сталин белән бәхәскә кереп китә. В.Ленин исән чагында мондый бәхәсләр эзәрлекләү белән тәмамланмыйлар. Әмма 1920—1922 еллардагы дискуссияләрнең барысы да М.Солтангалиев һәм «уңнар», ахыр чиктә «суллар» өчен дә фаҗигале төстә бетә. Милли сәясәт тиздән үзәкләштерү сәясәтенә әйләндерелеп бөтенләй башка төс ала да, киләчәктә бер милләтне генә милләт дип белеп, калганнары турында сүз дә булырга тиеш түгеллеге алга сөрелә. Имеш, социализм чорында милләтләр чәчәк атып, бөтенләй якынаеп бетәләр. Шулай итеп, бары тик бер милләт кенә — рус милләте кала. Бу әкиятләрне безгә фәлсәфәчеләр, социологлар, тарихчылар да шактый күп сөйләделәр, шул хакта докторлык диссертацияләре язарга тырышучылар да бар иде бит.

1923 елның 4 маенда М.Солтангалиев кулга алына. 9—12 июньдә ул ышерен киңәшмәнең карары нигезендә җаваплы эшләреннән куылып, партиядән чыгарыла. Киңәшмәдә 60 кеше катнаша. Төп докладны В.Куйбышев сөйли. Монда И.Сталин, Л.Троцкий, Г.Зиновьев, К.Мохтаров, А.Енбаев, Сәетгалиев һ.б.лар чыгыш ясыйлар.

Сәетгалиев, үзенең Казаннан фәкать «уңнар»га ярарга тырышмаганлыгы өчен генә куылганын ышандырырга тырышып, аларның җитәкчесе, инде зинданга ябылган Солтангалиевкә, Совет хакимиятенә хыянәт кылуда гаепләп, «табигый милләтче», «пантюркист» ярлыкларын тага. Аннан соң чыгыш ясаган Ибраһимов һәм Шамигуловлар да, аның фикеренә кушылып, Солтангалиевкә карата каты чаралар күрүне тәкъдим итәләр. А.Енбаев белән К.Мохтаров, Р.Сабиров килеп чыккан хәлне йомшартырга тырышып карыйлар. К.Мохтаров Солтангалиевнең эшләрендә революциягә каршылык беркайчан да булганы юк, ә җитешсезлекләре булса, алар урындагы үзенчәлекләр һәм РКП(б)ның

Х съезд белән XII съездлар арасындагы үзенчәлекләргә бәйле икәнлеген исбат итә. Татарстан коммунистларын революциягә каршы булуда гаепләү мөмкин дә түгеллеген әйтә. Әгәр инде Үзәк Комитет җитешсезлекләрне белергә, тәнкыйть итәргә тели икән, башта безнең эшләр белән танышырга тиешлеген дә әйтә. Татарстан «уңнар»ын «солтангалиевчелек»тә гаепләүчеләргә ишарә ясап, әлеге кайбер иптәшләр үз чыгышларында бик еракка китәләр, бөтенесен бер өемгә җыялар. Мәсәлән, алар «суллар» белән «уңнар»ның үзара тартышын Солтангалиев белән бәйләргә тырышалар[21]. Партиядә, чыннан да, төрле төркемнәр бар, әмма алар контрреволюция белән һичнинди бәйләнештә тормыйлар, диләр. Республикадагы хәлләргә объектив анализ ясап, ул: *«Наши расхождения в условиях Татарской республики углубились до Х съезда партии, когда «левые» не различали никаких особенностей в национально-экономическом состоянии разных национальностей. Мы же говорили о необходимости учета стадии национально-экономического развития. Х съезд партии правильность такого взгляда подчеркнул особенно точно... и только после этого «левые» внешне признали свои ошибки и признали необходимость отказа от идеалистического уклона»*[22].

Зиновьев үз чыгышында, Сәетгалиевкә карата ишарәләр ясап, аның чыгышында бары тик Ленин хатының укылган өлеше генә эшкә яраклы дип, «суллар»ны гомумән тәнкыйть итеп чыга. Алар милли мәсьәләне юк дип саныйлар. *«Это было бы правильно, если бы десятки миллионов рабочих это уже понимали. Но дело в том, что рабочие не понимают этого — в силу предыдущего развития. И тот, кто подходит к ним с таким лозунгом, хочет попасть в одну дверь, а попадает в другую. Никогда мы не сможем стать массовой партией в тех областях, где национальный вопрос играет крупную роль, если мы будем так ставить национальный вопрос»*[23].

Милли мәсьәләне, урындагы үзенчәлекләрне искә алмаганда «суллык авыруы» көчәя, ә киресенчә, «уңнар»ча эшләгәндә, ул тантана итә алмый. Менә шуңа күрә дә инде киңәшмәдә «уңнар»ны «солтангалиевчелек» белән бәйләргә тырышсалар да, алар монда үз позицияләрен саклап кала алалар. Кызганычка каршы, IV киңәшмәдән соңгы вакыйгалар моның вакытлыча гына икәнлеген күрсәтәләр. Киңәшмәдән соң булып узган җыелышларда әкертен генә «уңнар»ны, ә соңрак «суллар»ны да «солтангалиевчелек»тә гаепләп, халык дошманнары исемен биреп, лагерьларга озату гадәткә кереп китә. Бу Үзәкнең төптән уйлап әзерләгән сәясәте була. Шулай итеп, IV киңәшмә «милли тайпылышка» яңа сулыш өрә.

КАЗАН КИҢӘШМӘСЕ

Мәскәүдәге яшерен киңәшмә ябылганнан соң, 1923 елның 19—21 июлендә РКП(б) өлкә комитетының, өлкә контроль комиссиясенең милли мәсьәлә буенча җаваплы хезмәткәрләре катнашында киңәшмә уза. Мәскәү киңәшмәсе һәм аның карарлары хакында Татарстан өлкә комитеты сәркатибе сөйли. *«Султан-Галиев почти всего лишился... исключен ЦКК из партии за антипартийную и антигосударственную работу, причем Постановление ЦКК подтверждено Оргбюро и Политбюро и наконец нашим совещанием»*[24]. Ул М.Солтангалиевкә карата кабул ителгән резолюцияне игълан итә. Шактый озак мөзакәрәдән соң бу резолюция үзгәртүләрсез диярлек күпчелек тарафыннан кабул ителә. Без аны тулы килеш китерербез, әмма аңа кадәр бу киңәшмәдәге чыгышларга тукталып китик.

«Секретарь обкома довел до сведения присутствующих, что на местах недостаточно проводятся решения X и XII съездов партии по национальному вопросу. Он довольно четко изложил взгляды И.Сталина по вопросу групповой борьбы. Хотя Сталин одинаково критиковал борьбу левых и правых, в целом групповую борьбу, однако, на деле он поддерживал левых. Он говорил: «...в борьбе против национализма правые слабы, потому что заражены некоторым скептицизмом по отношению к партии и легко поддаются влиянию национализма. «Левые» более или менее свободны от скептического отношения к партии от податливости и воздействия национализма, но даже левые упрощенно подходят к национальному вопросу — отрицают его значение, не хотят или вернее не умеют маневрировать, переносить формы и методы работы из центра на окраины и не хотят или не умеют понять ту обстановку, в которой они работают, поэтому если правое крыло более способно... выделять из своей среды отдельные элементы, которые забывают, где кончается партия и где начинаются ее враги. Если правые могут замедлить или затруднить сближение пролетариата бывшей державной нации с крестьянством ранее угнетенных национальностей, то левые своим нигилизмом в национальном вопросе могут оторвать от нас крестьянство и тем самым сыграть на руку нашим врагам. Поэтому наша линия должна быть определенной и твердой. Надо, как говорил тов. Сталин, подстегнуть правых для того, чтобы заставить их научиться бороться с национализмом на предмет выковки настоящих коммунистических кадров из местных людей, но надо также подхлестнуть и левых для того, чтобы научить их гибкости и умелому маневрированию на предмет овладения широкими массами населения.

Необходимо все это подавлять потому, что истина лежит посередине между правыми и левыми»[25].

Әйтелгәннәрдән күренгәнчә, Сталин «маневрирование»ләрнең асылын үзе күрсәтте. Әгәр дә бөтен хәрәкәтләр Үзәкнең хәлен ныгыта икән, бу — яхшы. Дөреслек уңда, сулда яисә уртада торуга карамый. Мәскәү киңәшмәсе моның шулай икәнлеген ачыклый. Әгәр дә дөреслек Политбюро ягында саналган икән, бу һичшиксез шулай диган сүз түгел, ә бәлки Политбюроның бар куәтне яулап алганлыгыннан гына килеп чыга. Чынлыкта хакыйкать М.Солтангалиев ягында булганлыгы бүген көн кебек ачык. Әмма әле 1923 ел гына. Тоталитар режимның ныгый башлаган чоры, ул көчле һәм тагын да көчлерәк булырга омтыла. Аның бар белгәне — Үзәкне ныгыту, аңа ярамаучылар барысы да дошман.

Казан киңәшмәсенә килгәндә, 30 дан артык кеше чыгыш ясап, күпчелек Солтангалиевне фаш итү резолюциясен хуплый. Беренчеләрдән булып сүз алган Мөслимов: *«Солтангалиев — армиясез генерал, ул Сталин белән милли мәсьәлә хакында әрләште һәм аның беренче корбаны булды»*, — ди. Ул «солтангалиевчелек»не кемализм һәм фашизм белән чагыштыра. Бу фикерне Үзәк Комитет вәкиле Струппе, Ибраһимов, Бикчәнтәевләр яклый. Соңгысы Усманов белән Ганиевне «солтангаливчелек»тә гаепли. Чыгыш ясаучылардан А.Енбаев, Николаев, Галл, Шәймәрдәнев, Р.Сабиров һәм башкалар Мәскәүдә узган киңәшмәнең үзенчәлекле икәнлеген белдерәләр, ә Ендаков аның «фәкать тикшерү рәвешендә» булуын ассызыклап әйтә. Николаев та: *«Мин үзем шундый нәтиҗәгә килдем, безгә «җирле юнәлеш»не табарга кирәк, ә «уңнар»га килгәндә ул: әлеге «канат» дип аталган юнәлеш гамәли эштә тулаем алганда партия күрсәтмәләрен тормышка ашыра, әмма асылда ул читтә, коммунистлар партиясеннән, безнең юлыбыздан «суллар»га караганда да читтәрәк тора»*, — ди[26]. Шәймәрдәнев, Р.Сабиров, Галл бердәм диярлек Татарстанда «солтангалиевчелек» юк дип баралар, ә Сабиров, киңәшмәгә бәя биреп, аның төп вазифасы ике агымны да «кысу» дип белдерә. Буадан килгән вәкил Бәширов, Солтангалиев гаепле булса, шелтә бирергә кирәк, әмма Мохтаров, Сабиров, Енбаевлар тарафыннан андый эшләр эшләнмәде, дип раслый. Үзенең беркадәр нәтиҗә ясаган сыман чыгышында Камалетдинов фамилияле коммунист: *«Монда Солтангалиев һәм солтангалиевчелек хакында бик күп сөйләнде. Бу сорау белән бик күп сәүдә иттеләр... Милли мәсьәләнең тормышка ашырылуы хакында бик аз сөйләнде»*, — ди[27]. Менә шушы чыгышлардан соң Живов, нәтиҗә ясап, *«Солтангалиевчелекне юк итү өчен көрәш яңа юлны тудырмый, бу көрәш иске юлның дәвамы гына булырга тиеш»*легенә басым ясап, Мәскәүдә тәкъдим ителгән резолюцияне кабул итәргә чакыра. Нәтиҗәдә ул үзгәрешсез килеш кабул ителә.

Мәскәү киңәшмәсенең карарына түбәндәге өстәмәләр кертелә: *«...отметить особую ценность материалов ЦК РКП(б) для*

нашей организации и считать необходимым, чтобы ОК принял меры к ознакомлению тем или иным путем всех ответработников материалами с одновременной широкой популяризацией постановления XII съезда РКП(б) по национальному вопросу.

Целиком присоединиться к постановлениям совещания, осудить преступную работу Султан-Галиева и призвать всех коммунистов в ТССР к изживанию остатков султангалеевщины и к более решительной борьбе с возможными уклонами к национализму.

Обратить особое внимание на выращивание подлинно интернациональных кадров из пролетарских и полупролетарских элементов достаточно гибких для того, чтобы привлекать к советской работе все сколь-нибудь лояльные элементы местной интеллигенции, завоевать поддержку трудящихся масс местного населения и применять к этим особенностям соответствующие методы работы, а также достаточно стойких для того, чтобы устоять против меньшевистско-буржуазного национального влияния и повести решительную борьбу с уклоном национализма и за уничтожение пережитков национального неравенства.

При осуществлении этой задачи поручить ОК принять все меры к усилению партийно-воспитательной работы, укреплению РКСМ выдержанными партработниками, борясь против перенесения групповой грызни внутри союза в ущерб коммунистическому воспитанию и обратить внимание на систематическое поднятие квалификации татарских рабочих путем втягивания их в фабзавучи и профтехнические школы.

Принимая во внимание важность практического твердого осуществления постановлений Совещания и XII съезда, считать необходимой немедленную разработку их применительно к организации, для чего создать специальную комиссию в составе Шварца, Мухтарова, Ахмадеева, Борындыкова, Сагидуллина и Ахметшина под председательством Шварца с предварительным рассмотрением результатов работы в этой комиссии очередным Совещанием секретарей канткомов и райкомов и со следующим утверждением ОК»[28].

Киңәшмә исеменнән Ленинның «данлыклы булышчысы ип. Сталинга» телеграмма җибәрелә һәм анда: *«Бүгеннән башлап Татарстанда «уңнар» да, «суллар» да булмаячак, бары тик бердәм әгъзалар гына булачаклар»*, — дип язылган була.

Өлкә комитеты секретаре Живов Сталинның Татарстандагы «крамоланы» бетерү киңәшләрен уңышлы үти. Булат Солтанбеков әйткәнчә, *«Дальнейшее было делом техники. Бюро обкома партии осудило действия К. Мухтарова и нескольких членов обкома, обратившихся в ЦК после ареста Султан-Галиева в мае 1923 года с предложением взять его на поруки и выразивших сомнение в обвинениях, предъявленных тому»*[29].

Әмма моны утны керосин сибеп сүндерергә тырышу белән генә чагыштырырга мөмкин. Эш «К.Мохтаров эше» оештыру белән төгәлләнә. Моңа бераз соңрак «39 лар хаты»да өстәлә.

Бу хатта сүз Татарстандагы милли сәясәтнең үзенчәлекле шартларда тормышка ашырыла башлануы хакында бара. Татарстан Республикасын төзү һәм аның соңгы чорда, бигрәк тә 1920—1921 елларда, Сәетгалиев хакимияте, партиянең өлкә комитеты үзбилгеләнү сәясәтеннән бөтенләй баш тартып, республикага бары тик ТАССР исемен бирү белән генә чикләнергә тырышалар. Әлбәттә, үзбилгеләнүгә моның ише үтә карау татар халкының күпчелегендә табигый рәвештә ризасызлык уята. Бигрәк тә үзбилгеләнүгә каршы булган рус коммунистларының шовинистик сәясәте күпләрне канәгатьсезләндерә. *«Нам, русским коммунистам, в высшей степени не нравится то, что вы (татары) занялись реализацией языка в русском городе»* яки *«нам надо равняться на запад, а не культивировать отсталую культуру»* дип барылган булган рус сәясәте. Үзәк тә шул фикердә торып, татар халкына каршы булган сәясәт чынга аша башлый. Шушы һәм башка сәбәпләр татар коммунистлары арасында да төрле-төрле төркемнәр хасил булуга сәбәп була. Нәтиҗәдә Сәетгалиев хакимияте, өлкә комитеты шовинизм, бөек хакимиятлек сәясәтенә юл тотып, республикадагы каршылыкларны көчәйтеп, ары таба җәелдереп торалар. Алар Татарстандагы үзенчәлекләрне санга сукмыйча, аларга карата хак бәя биреп, сәясәт алып барасы урынга, киресенчә, татар коммунистларын «милләтчеләр»гә, «интернационалистлар»га бүлеп, гомуми эшне алып баруда өстәмә комачаулыклар китереп чыгарып, бигрәк тә руслар һәм татарлар арасында каршылыкларны уйлап табып, хакимияттәге кискенлекне көчәйтәләр. Сәетгалиев хакимияте кыска гына вакыт арасында кризиска дучар ителгән икән, аның сере фәкать республиканың икътисади, сәяси, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен искә алмыйча торып, ә бары тик Үзәк күрсәтмәләрен генә үтәп, өстәмә кыенлыклар уйлап торудадыр, Гасыйм Мансуров РКП(б)ның Татарстан Республикасы өлкә комитетының партия конференциясендәге чыгышында: *«Эпоху работы Саид-Галиева надо считать самой бездарной и при том самой кошмарной в смысле неумения работать вообще в условиях ТССР, в частности, особенно в смысле непонимания и неправильного подхода к разрешению национального вопроса... В результате этого в этот период создание ТССР сводилось к простому переименованию учреждений»*, — дип белдергән чыгыш ясый[30]. М. Сәгыйдуллин да үз сүзендә Үзәкнең сәясәтен һәм Г.Мансуровны тәнкыйть итеп: *«Коммунистлар партиясенең милли сәясәте бик яхшы*, — дип белдерә, — *әйе, бик яхшы һәм бөтенесе дә аңа буйсынырга тиеш»*[31]. Ул милли үзенчәлекләрне онытырга ярамаганлыкны мисаллар китереп аңлата. Мәсәлән, Азәрбайҗанда квартира мәсьәләсе дин белән бәйләнгән — анда гарем бар, ә

Кыргызстанда коммунист партия җыелышыннан соң намаз укырга китәргә мөмкин. Менә шуңа күрә урыннардагы үзенчәлекләрне искә алып эш итәргә, милли каршылыклар белән халыкларны куркытып торырга ярамаганлыгын да кисәтә. *«Татар һәм рус хезмәт ияләре арасында бернинди каршылык юк, һәм без бары тик милли дошманлык тудыручы тупаслыкка гына каршыбыз»*, — ди. Коммунистлар арасында каршылыклар китереп чыгаруда бигрәк тә Бажанов, Шварц, Жуков, Ивановлар, ә татарлардан Гафуров, Касыймов, Габидуллин, Х.Гайнуллин һәм Гыймрановларны атап китү урынлыдыр. Нәтиҗәдә, әлеге хаттан күренгәнчә, иң күренекле һәм үзләрен эштә оста җитәкчеләр итеп таныткан коммунистлардан А.Енбаев, Фәсхи, Саттаров, З.Булушов, Еникеев, Саттар, К.Хәйруллин, Үзәк башкарма комитеты рәисе Р.Сабиров, шәһәр башкарма комитеты рәисе Ратехин, аның урынбасары Ганиев, Халык Комиссарлары Советы рәисе Г.Мансуровлар эшсез калалар, җитәкчелек органнарына бөтән сайланмыйлар.

Шулай итеп, партия һәм совет органнарының абруен төшерү өчен бөтенесе эшләнә. Бу өлкәдә Татарстан Республикасы советларының IV съездында Гафуров, Габидуллин һәм Пинсоннар үзләрен шул тарафтан күрсәтәләр. Гомумән алганда, алар Үзәкнең сәясәтен хуплап, «К.Мохтаров хакимияте» чорында зур активлык күрсәткән һәм татарларны хакимияткә тартуда зур уңышларга ирешкән зыялыларны яңа чорда ээзәрлекләп, аларны эш урыннарыннан алып аталар. Күрәсең, берәүләр большевикларның үзбилгеләнү шигаренә ышанып чын күңелдән эш алып барса, икенчеләре — «суллар» һәм Үзәк — бу хакта уйламыйлар да. И.Сталинның Ленинга яшерен грифы белән җибәрелгән хатында кайбер төбәкләрдә партиянең үзбилгеләү шигарен чынлап торып тормышка ашырырга теләүче төркемнәр барлыкка килүе турында әйтелә[32]. Анда алар әлеге өндәмәне чынлап торып тормышка ашырмакчылар, диелә. Әлбәттә, бу турыдан-туры «К.Мохтаров хакимияте»нә карый. Әле 1922 елда ук бу хакимиятнең эше нәтиҗәсендә хәтта рус коммунистлары арасында да милли сәясәтне аңлап эшләү теләге туып, татар коммунистларын «национал», «интернационалист»ларга бүлүдән баш тарталар. Менә шушындый уңай агым Үзәкне борчый һәм ул «урыннарга» һөҗүмен көчәйтеп җибәрә. Тиз арада аларны эзәрлекләүләр, эштән алу, башка вазифаларга күчерү, гомумән, юлга салынган милли сәясәтне, суверенлыкны җимерү эше җәелдерелеп җибәрелә.

Менә шундый авыр хәл килеп чыкканнан соң, Сталинга, Молотовка икенче хат та языла. Тарихи әдәбиятка беренче тапкыр кертелгәнгә күрә без аны тулысынча тәкъдим итәбез.

«В ЦК РКП(б)
Тов. Сталину
Тов. Молотову
Тов. (текстта шулай. — *Р.В.)*

В дополнение к поданному в ЦК обращению за подписью 39 ответственных работников татар мы считаем необходимым обрисовать происшедший за самое последнее время ряд событий, еще больше усложнивших политическое и хозяйственное положение в ТССР. Являясь результатом неумелого руководства большинством ОК и его секретарем т. Морозовым, это положение для организации не гарантирует правильное проведение национального вопроса в духе постановления съездов партий и ЦК и безусловно способствует углублению розни, групповой борьбы и склоки. Интриги и бесшабашная травля, ведущаяся, не считаясь с пределами рамок, партии против испытанных и заслуженных в революции товарищей-коммунистов-татар, за последнее время настолько углубились, что грозят окончательно превратить организацию в арену склоки.

Обращение в ЦК работников-татар, ведущих в известный период колоссальную работу в партии и органах сов. власти путем правильного разрешения нацвопроса в условиях Татреспублики, было результатом партийно-политической обстановки после 8-й партконференции, каковая, по глубокому нашему убеждению, ставила нашу партию и соввласть в ТССР перед трудными переживаниями. Заявив об этом на 8-й партконференции и последующих заседаниях ОК в своих предложениях, мы считали своим партийным долгом обратить внимание ЦК на допускавшиеся отклонения от правильной партлинии в нашей организации и полагали, что разрешение данного вопроса необходимо представить авторитетной компетенции ЦК. Мы и сейчас остаемся при мысли, что именно такой порядок действий и по форме и тем более по существу являлся единственно правильным партийным и выдержанным.

Между тем бесконечная травля и провоцирование со стороны руководителей ОК по отношению к подписавшим это обращение и разделяющим их оценки явились прямым ответом на это обращение. При этом исступленном преследовании и терроризировании была утеряна всякая граница внутрипартийности и элементарной разумности.

Не ограничиваясь резко осуждающими, необоснованными резолюциями и наклеиванием разных ярлыков, руководители ОК и ОКК практикуют и меры физических воздействий по отношению к означенным товарищам к деятельности. За последнее время можно проследить достаточно большое количество факторов, свидетельствующих об этом. Достаточно указать на отстранение без каких-либо деловых причин от занимаемых должностей целого ряда товарищей (напр. зам. НКРКИ Хайруллина, зам. НКП Будайли, члена бюро ОКРКСМ т.Рамзи, зав. обл. совпартшколы Рафикова, а затем Ф. Сайфи, заворготдела Саттарова, секретаря СНК Беганского, секретаря Елабужского канткома Колесникова, Бондюжского райкома Усачева и др.),

если не считать подписавших настоящее заявление т. Мухтарова, Мансурова и Енбаева. Или практикуются еще такие вещи, как полное игнорирование подписавших товарищей в партработе. Например, ОК ни одного из этих товарищей не счел возможным использовать при подготовке партконференции. На самой партконференции ни одному из товарищей не дали выступить по докладу ОК. Подчас не только игнорировали, но применяли метод механического исключения из списков избранных на партконференцию, не стесняясь официальными заявлениями, что это делается за подписание заявления в ЦК (выборы в горрай... лишение мандатов части Елабужской делегации). Или актами проведения решений об исключении из партии тех товарищей, кои не согласятся снять свои подписи с обращения.

Характерно, что такие действия распространяются уже не только на отдельных товарищей, но и на целые организации, посмевшие сказать руководителям ОК их ошибки. С сожалением приходится констатировать несправедливое и бесцеремонное обращение с редким в Татреспублике и по качеству и по количеству пролетариата центром (парторганизации Бондюжского и Кокшанского заводов).

Эти заводы являются единственным центром, где сосредоточена самая крупная и организованная масса татар. За время своего существования пролетарии этих заводов не раз доказывали свою преданность революции, и за эти годы выдвинули из своих рядов немало видных работников в партии, в Советах и профдвижении.

По отношению к этим рабочим, организациям руководители во главе с т. Морозовым допустили самые вредные политические деморализующие эти парторганизации и ярко пристрастные действия. Так, например, в целях дискредитации этих пролетарских организаций т. Морозов, выступая, характеризовал истинно рабочие массы Бондюжских и Кокшанских заводов как мелкобуржуазный элемент. Одновременно умаляя политический удельный вес этих пролетарских масс своей грубой формулировкой — что они вовсе не являются центрами внимания тат. организации. Кроме того, на конференции т. Морозовым было проведено решение, выражения недоверия и исключения из состава ОК представителей Бондюжского и Кокшанского организаций тт. Колесникова, Валиуллина и Хабибуллина (последний был несколько недель назад взят от станка) — все товарищи рабочие.

Или еще, например, без согласия местных организаций были сняты секретари Бондюжского райкома и Елабужского кантокома по тем же группировочным мотивам. На самой конференции представителям этих же организаций не дали слова для ответов по существу сделанных против тех ложных выпадов со стороны т. Морозова. В обстановке такого режима т. Моро-

лотым была проведена резолюция на партконференции о Елабужской организации, которая гласила о группировочности в этой организации. А между тем только до этого бывшая Елабужская кантонная конференция единогласно констатировала полное здоровье организации и правильность руководства верхушки местной парт. организации. Характерно, что присутствовавший на Елабужской конференции т. Морозов сам голосовал за такое предложение.

Все вышеприведенное неопровержимо свидетельствует, что линия ОК была направлена не к изживанию группировок, а затруднила работу и осложнила взаимоотношения в рядах организаций благодаря игнорированию директив ЦК по вопросу о татарской организации.

Татарскую организацию, как известно, в недавнем прошлом лихорадило в полосе дискуссии. Тогда упадочно оппозиционные настроения и нездоровые отклонения имели в ней место. Такое обстоятельство не учитывалось и не учитывается т. Морозовым, а, наоборот, его поведение импонировало этим настроениям. Конечно, такое руководство не гарантирует здоровую жизнь в организации и в будущем.

И проявление этих настроений мы можем наблюдать даже в напечатанной в газете резолюции 9-й областной партконференции по докладу обкома, где т. Морозов и руководители обкома вместо проведения в жизнь постановлений Оргбюро от 6 мая 1924 года становятся на путь подрыва авторитетности принятых ЦК решений и противопоставляют свою линию директивам ЦК.

И характерно, что т. Морозов, будучи кандидатом в члены ЦК, в своих речах на конференции, пленума обкома и на совещании делегаций допускал выступления в духе, что ЦК заблуждается, что организация должна провести свое собственное решение, что ЦК это делает из дипломатических соображений перед восточными работниками.

Благодаря этому у значительной части делегатов конференции создалось мнение, якобы в ЦК о татарской организации, в частности, о т. Мухтарове создалось формально одно, а в действительности другое мнение, которое выражается устами кандидата в члены ЦК т. Морозова.

Результаты нездорового руководства сказались и в ряде конкретных решений обкома по практическому проведению национального вопроса. Не говоря уже о том, что вместо директивы ЦК об изживании группировок путем вовлечения в деловую работу, явился в жизнь загон большого количества работников татар, стали практиковаться замена серьезно подготовленных работников татар явно неспособными и неделовыми. В результате чего несомненно складывается подрыв самой идеи вовлечения на государственную и партработу работников из

татар, ибо их проблемы в работе получают объяснения как общая неспособность работников.

Важным политическим моментом является и то, что секретарем ОК в его выступлениях отрицается факт великодержавнических, русотяпствующих тенденций в татарской организации. Такое же поведение наблюдается и в постановлении ОК о Чистопольской организации, когда отменяются решения старого обкома о снятии из Чистополя ряда зарекомендованных русотяпов. Или когда руководители ОК становятся на защиту работников с явно выраженным великодержавничеством, как Бажанов, Жуков и Шварц (несмотря на имеющиеся решения ЦК об отзыве Шварца).

Кроме того, ряд решений практического порядка имеют непосредственный отказ учета особенностей Татарской Республики. Для примера можно указать на резкое снижение %та отпускаемых средств на нужды НКПроса из местных средств с 32% прежних до 20%, тогда как за этот счет увеличивается % для милиции и внудела. Ликвидация татарского издательства по с/хозяйству, затор землеустроительных мероприятий, чистка в первую очередь НКЗема и НКПроса, тогда как эти органы являются наиболее татаризованными, а наряду с этими оставляются без чистки заполненные черносотенными и нелояльными русскими элементами целый ряд учреждений, призванных соприкасаться с туземной крестьянской массой и не приспособленных к ней. Имеются и такие явления, когда проходит передача хлебозаготовительных функций по Бугульминскому кантону в ведение Самарск. конторы хлебопродукта. А отказ от регулирования этой важной отрасли в хозяйстве нац. республик является недопустимым фактом.

Таким образом, можно привести целый ряд примеров из деятельности за этот короткий период, которые являются практическим выяснением занятой линии поведения руководителей обкома.

При таком подходе к вопросу безусловно является лицемерием заявление т. Морозова о том, что якобы линия поведения в нац. вопросе у старых руководителей была робкой и нерешительной.

Касаясь национального вопроса в программной его постановке на 9-й партконференции в докладе от бюро ОК следует констатировать ряд недочетов. Вся постановка вопроса отличается чрезмерной теоретичной расплывчатостью без конкретных практических предложений или с боязливым подходом к ним. Такой же теоретичностью страдал и план ОК по нац. вопросу, против чего в свое время приходилось вносить возражение в бюро. Левствующая тенденция доклада внесла неверное освещение многих исторических фактов и условий. Кроме того, совершенно отсутствует освещение исторического важного фак-

тора, что Казань в прошлом являлась центром русского миссионерства и оголтелой черной сотни, наследие которых и по сию пору представляют ряд опасностей в работе. Кроме того, наличие демагогических моментов в заключении доклада безусловно вредны в смысле разжигания разногласий между туземными коммунистами.

Обвинение нас со стороны Морозова и других руководителей нынешнего состава ОК в отрыве от партийной периферии и от масс, в противопоставлении организации и группировочности, в противопоставлении сов. аппарата партийному является тоже абсолютно необоснованными и неверными. Достаточно сослаться на постоянную тесную связь старого состава татарских работников с крупнейшими пролетарскими центрами Бондюж. и Кокшанск. заводов и на то доверие этих районов, которое имело место и на последней Елабужской партконференции. Можно указать и на выборы на последнюю конференцию в самом городе, где низовая партмасса в ячейках избрала ряд наших товарищей из старого состава (хотя райком механически исключал из списков подписавших обращение 39-ти). Все это опровергает ложное обвинение в отрыве от партмасс, которое некоторые товарищи наклеивают нам за выступление в период дискуссии с защитой положений ЦК против разных нездоровых искажений.

Подачу нами заявления в ЦК, наши выступления с теми или другими партийными предложениями в самом обкоме преследовали цель отвращения неделовых и явно группировочных постановок вопросов некоторыми руководителями ОК, могущих привести к нарушению равновесия и смычки в трудовых слоях населения Татреспублики, рассматривать как группировочность и противопоставление неверно и ошибочно.

Неправильным является и обвинение нас в отрыве от аппарата партийного. В действительности имел место не отрыв, а искусственное отталкивание сов. аппарата от партруководства. Ряд фактов убеждают в этом...

Во-первых, часть планов обкома по сов. строительству была составлена без всякого участия и уведомления руководителей СНКома и ЦИКа. завед. орг. отдела ОК т. Бажановым и, несмотря на вопиющие недочеты и несоответствия с фактическим положением вещей и несмотря на протест члена бюро т. Мухтарова, этот план был утвержден бюро ОК. Кроме того, ряд вопросов совет. деятельности, внесенный в ОК и не терпящий никакого отлагательства (вроде плана посевной компании), залеживался там целыми неделями. Рассуждения же о том, что якобы бюджет ТССР имел недостаточное обсуждение по партлинии, является тоже огульным, ибо над бюджетом все время работала парткомиссия обкома из т. Мухтарова, Гордеева и Злобина, и все вопросы бюджета проходили через нас. А попутно также скла-

дывают вину за дефицитность бюджета на нас, это тоже необдуманно. Достаточно на этот случай сослаться на мнение с приезжавшего специально для обследования нашего бюджета из Москвы т. Беленького, который (в Известиях ТССР за № 98) говорит, что в активности и в творческих достижениях по местному хозяйству и бюджету Татреспублика занимает высокое место в ряду других республик и областей РСФСР, особенно если принять во внимание все пережитое ею: Гражданская война, разгромы и исключительный голод. Последние причины и крайнее обнищание населения и являются величайшим препятствием к разрешению задач экономического развития. Татарская Республика нуждается в поддержке и заслуживает самого широкого содействия и внимания со стороны центра.

Обвинение нас в робости и нерешительности в проведении национальной политики является безусловно лицемерным и противоречивым, так как иногда обвинявшие нас товарищи не стеснялись, смотря по обстановке, обвинять нас в противном, т.е. обвиняли нас в чрезмерности нажима по линии татаризации. Три года нашей работы по реализации Тат. Республики с огромными достижениями в этом направлении и при постоянном сохранении полной смычки между трудящимися всех национальностей без единого конфликта служит критерием для фактической оценки нашего участия в работе парторганизации за то время.

Таким образом, в результате вышеприведенных соображений и фактов мы считаем, что такая линия обкома не может способствовать здоровому росту организации и не преодолеет сложную политическую и хозяйственную работу в условиях национальной республики. В самом составе ОК в настоящем мы видим с одной стороны элементы, противодействующие решениям нац. вопроса, в особенности путем углубления розни среди коммунистов татар, с другой — левствующих татар. Наряду с этим лучшие силы из татар с сравнительно большим партийным стажем, с практическим опытом, с активным и заслуженным прошлым в периоды Гражданской войны, вышедшие из недр рабочих, совершенно изолированы от работы или используются нерационально, третируются, терпят гонения (т. Хайруллин Кариб, Фасхи, Еникеев С.Х., Сайфи, Ганеев, Сабиров, Борындыков, Булушов, Исхаков, Рафиков, Бурнашев, Рамзи и др.).

Взамен выдвигаются для активной партийно-политической работы кадры, идеологически требующие испытаний как выходцы из иных партий или недавно пришедшие в РКП, товарищи со слабым деловым и теоретическим стажем и известные невыдержанными и недисциплинированными выходками, беспринципные и ненадежные для ответственных участков партийно-советской и хозяйственной жизни. Считаем необходимым подчеркнуть, что выдвинутые в настоящем, а также и в предыдущем обращении положения, полностью подтверждаются настроения-

ми и переживаниями, которыми охвачена лучшая часть татарских коммунистов, комсомольцев-активистов, беспартийных рабочих и крестьян и трудовой интеллигенции ТССР.

Доводя обо всем вышеизложенном до сведения ЦК нашей партии, мы просим ЦК реагировать на создавшуюся обстановку в Татарской Республике.

Нам думается, что необходимо:

1. Отозвать из татар. организаций товарищей, сильно зараженных русотяпской тенденцией;

2. Прекратить травлю и преследования по отношению к товарищам, подписавшим обращение в ЦК и им сочувствующим и использовать их как в руководящей, так и в низовой парт. сов. и проф. работах;

3. Провести чистку под руководством представителя ЦК и ЦКК в городском районе, в вузовских ячейках и в Чистопольской организации;

4. Привлечь к партийной ответственности виновников, способствовавших неправильностям в организации (т. Шварц, Пинсон, Бажанов);

5. Реагировать со стороны ЦК на поведение кандидата в ЦК т. Морозова;

6. Дать ряд конкретных директив для работы организации по исправлению допущенных отклонений от правильной партлинии;

7. Предложить обкому прекратить третирование и погромный режим по отношению к Елабужск., Бондюжск. и Кокшанск. пролетарских организаций.

Москва.

22 мая, 1924 год. Мухтаров, Енбаев, Мансуров»[33].

Чыннан да, Казан киңәшмәсеннән соң «уңнар»га турыдан-туры һөҗүм башланып китә. Хат ияләренең сүзләренә бераз дәлилләр китерик. Казанлыларны «төзәтү» өчен Үзәк Комитет Мәскәүдән Казанга В.Измайлов, Сибгат Гафуров, Гатаулла Касыймов һәм башкаларны җибәрә. Алар Татарстанда партия оешмасының тоткан юлын төзәтергә һәм РКП(б)ның XII съездының милли мәсьәләләр буенча карарларын тормышка ашырырга тиешлеген максат итеп куялар. Имеш, Татарстанда бер төркем татар коммунист җитәкчеләре милләтчелеккә бирелгәннәр.

1923 елның 17 декабрендә Татарстан Республикасы советларының IV съездында «уңнар»га һөҗүм дәвам итә. Үзәк вәкилләре, «суллар» һәм шовинистлар төп «атака»ны К.Мохтаровка юнәлдерәләр. Үзәк вәкиле С.Гафуров, К.Мохтаровны тәнкыйть итеп: *«Аның хакимияте казна акчасын үзләштергән Ю.Вәлидов, А.Енбаев, И.Казаков кебек «җинаятьчеләр»дән тора, ә К.Мохтаров үзе эшче гаиләсеннән чыкмаган, студент елларында Пермьдәге күзәтү бүлегендә цензор булып хезмәт иткән»*, — ди. *«Мне еще в Москве было известно о шифрованной перепис-*

ке между Мухтаровым и недавно исключенным из партии контрреволюционным Султан-Галиевым. Я располагаю бесспорными документальными доказательствами, что глава нынешнего правительства Татарии Кашаф Мухтаров в 1915—1916 годах служил военным цензором в Пермском жандармском управлении. Я настаиваю на том, чтобы отказать в доверии»[34]. Залда тавыш күтәрелә. К.Мохтаров бөтен фактларны биографиясендә күрсәткән. Алай гына да түгел, Солтангалиев кулга алынгач, алар, 12 кеше, Солтангалиевне ирекка чыгаруны сорап Үзәк Комитетка махсус хат та юллыйлар. Әмма хатка җавап килми. Гафуровка «артык тырышканлыгы» өчен катгый кисәтү бирәләр, съездан куалар.

Тарихи белешмә

Гафуров Сибгатулла Садыйк улы (1888 — 1938) 1918 — 1920 елларда РКП(б) Сембер губерна комитетындагы мөселман секциясен җитәкли. 1925—1929 елларда — Татарстан партколлегиясе контроль комиссиясенең икенче секретаре. 1929 елны ул партия тарихы бүлеген җитәкли. 1937 елда кулга алына, 1956 елның 3 октябрендә аклана.

Әмма Казан «уңнар»ын, К.Мохтаровны мондый провокацияләр белән генә җиңә алу мөмкин булмый. Чөнки 1552 елдан соң беренче мәртәбә Татарстан чын автономияле, суверенлы республика сурәтендә дөньяга танылa башлаганлыктан, аны шул дәрәҗәдә татарлар гына түгел, руслар һәм башка милләт вәкилләре дә таный. Шуңа күрә Мохтаров хакимиятен бетерү, юкка чыгару һәм эзәрлекләү вакыт таләп итә. Моны съезд һәм андагы вакыйгалар да исбатлый. Нәтиҗәдә Гафуров съездан куыла, ә аның эше Үзәк Комитетка һәм Үзәк контроль комиссиясенә җибәрелә. 1924 елның февралендә урындагы контроль комиссиясе С.Гафуровка шелтә дә белдерә. Шулай итеп, «уңнар» хакимияттә калалар, К.Мохтаров та хакимияттә кала. Бары тик 1924 елның мартында гына ул Халык Комиссарлары Советы рәислегеннән алына, һәм аның урынына Хаҗи Габидуллин сайлана. Живов урынына өлкә комитеты секретаре итеп И.Морозов куела.

Менә шушы вакыттан башлап Татарстан тарихында янә бер чор башланып китә дисәк тә дөрес булыр. Бу тоталитар режимның ныгый барып, репрессия, эзәрлекләүләрне киңрәк җәелдереп, Үзәкне тәнкыйть итүчеләрне һәм урыннарда гадел, дөрес сәясәт алып баручыларны юк итү эшен башлап җибәрү чоры дисәк тә урынлы һәм хактыр.

К.Мохтаров бу этапта, югарыдагы хатлар һәм башка чыганаклардан күренгәнчә, бөтен көчен, талантын «уңнар»ны, 1921—1923 еллардагы сәясәтне яклауга багышлый. Бу аның үз-үзен яклавы түгел, ә бәлки татар халкын һәм аның күренекле вәкилләренең революциядән соң беренче тапкыр гадел милли сәясәтен бердән-

бер дөрес сәясәт икәнлеген исбатлавы гына. Хәзер инде моның шулай икәнлеген кем инкарь итә ала — итсеннәр! Дөреслек барыбер тантана итә, әмма аның шулай икәнлеген күрү өчен бер кешенең яисә бер буынның гына гомере җитми — монысы да аяныч. Татарстанның 10 ел дәвамында суверен республика булып яшәвен күреп, К.Мохтаров тантаналы хис кичерер иде.

1924 елның февраленнән соң Партия өлкә комитеты актив рәвештә «уңнар»ны эзәрлекләү, куу сәясәтен уздыра. Тиз арада бу эшкә прокуратура да үз өлешен кертә. Төрле сәбәпләр табып, юк-барга бәйләнеп, эштән куулар кагыйдә булып китә. Беренчеләрдән булып Г.Мансуровны җибәрәләр. Аннан соң К.Мохтаров, А.Енбаев, Р.Сабировлар Мәскәүгә артык әһәмиятле булмаган вазифаларга эшкә алына. К.Мохтаров белән бераз уңайсызлык килеп чыга. Казаннан ике эшче Сталинга җибәргән хатларында аны эш урыныннан алуны сорыйлар. Әле беркадәр демократия белән уйнаган Сталинга язган хатында, аларга ярарга тырышып, без аны Мәскәүдә җитәкчелек урынында файдаланачакбыз, ди[35].

34 татар эшчесенең хаты да бик зур әһәмиятә ия. Без аны тулы килеш китерәбез:

«Секретарю комитета Российской Коммунистической Партии (б), дорогому товарищу Сталину, всем членам Центрального комитета.

от рабочих и работниц, работающих на фабриках и заводах центра Татарской Республики г. Казани, от делегатов в фабрично-заводских комитетах.

заявление

Вместе в настоящем заявлении доводим до сведения ответственного секретаря Центрального Комитета — дорогого нашего товарища Сталина о нашем горе.

В 20—21-х годах (несмо.) (Алга таба җәя эчендәге сүзләрне сызылган дип укыйсы. — *Р.В.), хотя был большой голод, промышленность улучшалась и (рабочие) увеличивались рабочие силы. Заработная плата уплачивалась вовремя, неграмотность (понизилась) понижалась. С (ростом) улучшением промышленности и (подни) прояснением сознания рабочих и крестьян, укреплялась достаточно и дружба рабочих с крестьянством. Когда из нашей среды были (взяты) оторваны те товарищи, которые т. Мухтаров и другие трудившиеся вместе с ним товарищи, т.е. работники, которые много истратили энергии во всем этом деле, показали большую работоспособность в этом деле и дали совершили дост. доб. показали ряд достиж. добились. Показали ряд достижений те товарищи, работавшие в этом (направлении) т. Мухтаров и трудившиеся вместе с ним работники, отдавшие очень много сил и энергии всему этому делу и добившиеся (немалых достижений) очень многих достижений в этом направлении, то промышленность и сельское хозяйство*

Татарской Республике (страшно упали уж сильно, сильно ухуд. стр.) и в настоящее время (про произво) и очень сильно сократилось производство фабрик и заводов. (В результате) начались сокращения на фабриках и заводах и других промышленных предприятиях, (в результате) и выброшены на улицу тысячи рабочих. Вместе с этим участились случаи закрытия заводов и фабрик. Между тем раньше у нас даже в голодные годы не было сокращений и не закрывались заводы и фабрики.

Если коснемся вопроса о школах, то и здесь (очень сильное) видим очень сильное сокращение (школ). Осталось по одной школе на 5—6 аулов. Тысячи школ без движения стоят, которые до этого довольно хорошо функционировали, давая (просвещение) свет и знания тысячам рабочих и крестьянских детей, теперь они остаются без знаний. Эти дети, эти звезды будущей нашей жизни, остаются без знаний и в невежестве.

Если же обратим внимание на положение крестьян, то оно еще хуже. Нынешний Наркомзем не проводит в жизнь тех серьезных начинаний, которые проводились раньше со стороны старого Наркомзема (примеры). Так, например, ничего не предпринимается для увеличения в республике лошадей и сельскохозяйственных орудий, составляющих «сердце» сельского хозяйства. Вообще, все крестьянское хозяйство в настоящее время находится в крайне тяжелом положении и, весьма возможно, что если не будут приняты (своевременно) меры, то наша республика опять попадет в положение голодного года и вопросы просвещения, поднятия (сельском) крестьянского хозяйства и усиления промышленности останутся совсем позади.

Если коснемся вопроса кооперации, то в аулах и в волостях во главе большинства кооперативов сидят кулаки и мироеды (от них). Поэтому от них не только мало пользы крестьянству, но часто они бывают ему совершенно бесполезны. Вообще положение крестьянства, ввиду необращения на него (на над) должного внимания на местах, становится все хуже и хуже.

Мы просим вас вернуть к нам в нашу среду (т. Мухтарова и работавших вместе с ним товарищей) нужного и ценного для нашей республики т. Мухтарова и работавших вместе с ним товарищей, которые (работа) не покладая рук, работали среди нас, спасли нас от голода, подняли нашу промышленность и (сделали крупные услуги потратили крупные силы для) много сделали в поднятии крестьянского хозяйства, и тем самым... вывели нас из нашего теперешнего (этого такого) трудного положения. Из этого положения мы (сумеем выйти) выйдем лишь при указанных товарищах и при их умелой (соответств.) и соответствующей действительным условиям нашей республике работе.

Сейчас, не знаем почему, крайне сильно сократилось число детских домов и яслей, в результате чего выброшены на улицу голодными и холодными тысячи пролетарских детей (взгля-

ды). Их взгляды на будущее сейчас темны. Они скитаются по улицам (протягивая, принужденные протягивать руки за подаяниям), протягивая руки прохожим за подаянием.

Заявление это свое здесь на месте мы не подаем. Мы посылаем его непосредственно к Вам, так как у нас вера в Вас большая (великая). Думаем и надеемся, что вы поймете нас, войдете в наше трудное положение, удовлетворите нашу просьбу и тем обеспечите наше будущее.

(Следуют следующие подписи).

На подлиннике (следующие) подписи рабочих Порохового, Алафузовского, Пугачевского и др. (заводов)

1. Мухаметзянов
2. Авходиев
3. Сафиуллин
4. Валиуллин — делегат завкома
5. Валиуллин
6. Хайбуллин
7. Хайретдинов
8. Мухаметим (Мухаметов?)
9. Миннулин
10. (Неразборчиво)
11. Сагидов
12. Халимов
13. Мусина — делегатка
14. Нурлу-Банат Хаждуллина — делегатка
15. Марфуга Габдрахманова — делегатка
16. Рашитова — делегатка
17. Махи-Кемаль — делегатка
18. Марьям Сафарова
19. Хадича Туктарова
20. Ходича Халфеева
21. Абдуллина
22. Хатмуллина
23. Шаютоллина
24. ...(подп. неразб.) — *завком*
25. Шакиров — чл. завкома
26. Фаткуллин
27. Кадиров
28. Хабибуллин
29. Данвараева
30. Галиокбаров
31. Байрамов
32. Сафиуллин
33. Гашуллин
34. Давлекиши(н?)

(Хатның копиясе ЦГАИПДРТ да саклана. К.Мохтаровның шәхси эше.)

Әмма булачак «халыклар атасы», эшче-крестьяннар исеменнән эш йөртсә дә, Казандагы фабрика-завод эшчеләренең фикерләре белән санашмыйча, К.Мохтаровны, Татарстаннан куалап, Мәскәүгә озаттыра, ә калганнарын төрле җиргә таратып, җайга салынган эшләрне тарката.

К. Мохтаров үзе 1924 елның 10 октябреннән Сәламәтлек халык комиссариаты коллегиясенең әгъзасы булып эшкә керешә. Бу турыда соңрак... Әлегә «уңнар»га һөҗүм турында тагын бераз сүз алып барыйк. «Уңнар»ны юк итү, шовинизмның үзеннән-үзе алга таба үсеп, ачык рәвештә хәрәкәт итүе «суллар»га да кагыла. Үзәккә ярарга тырышып, Мохтаров хакимиятенә каршы көрәшкән «суллар» үзләре дә тиз арада авыр хәлдә кала. Бу инде хыянәт итүнең бер нәтиҗәседер, дисәң дә дөрестер.

Шулай итеп,. Татарстанда 1924 елда һәм аннан соңгы чорда Сталин сәясәтенең ятьмәсенә урындагы хакимият һәм партия органнарының да килеп эләгү факты күренә. Чын-чынлап халык мәнфәгатен яклап хезмәт иткән бик күп зыялыларыбыз эшсез калып, инде бары тик Үзәк Комитетка язып, эшләгән эшләренә анализ ясарга гына кала, әмма инде алар бары тик милләтчеләр, сәләтсез җитәкчеләр итеп каралып эзәрлекләнәләр. Рәсми рәвештә эшкә алынсалар да, аларның киләчәге билгеле — «халыклар атасы» моны үзе генә белә.

КАЛДЫКЛАР БЕЛӘН КӨРӘШ

1925—1927 елларда «милли тайпылыш»ның яңа формалары туа. Төптән алганда, бу көрәш өлкә комитеты һәм Үзәкнең сәясәтеннән канәгать булмаучылар арасында бара. Әгәр дә өлкә комитеты 1924 елга кадәр урындагы үзенчәлекләр белән санлашкан булса, хәзер алар өчен бары тик Үзәк Комитетның, Сталинның гына күрсәтмәләре өстен куела, шовинистлар тантана итә. Үзәк, «суллар» һәм «уңнар» белән көрәшкән булып, татар коммунистларына басым ясый.

1929 елда кулга алынганга кадәр, Мохтаров, Мансуров, Енбаев Дәүләт политик идарә күзәтүе астында торалар. Шушы елның 22 июлендә алар өчесе дә Редус Зенкович җитәкләгән комиссиягә чакырылалар һәм анда аларны Петерс, Васильев, ОГПУ хезмәткәрләре төрле бозыклыкларда гаеплиләр. Мондый чакырулар, гаепләүләр кабатлана тора. Бу вакыйгалар турында Мохтаров һәм аның эштәшләре тарафыннан язылган шактый саллы кульязма сакланып калган. Гомәр Белялов аны 25 июльдә язылган, ди, ә документның үзендә 7 август датасы күрсәтелгән. Хаттан күренгәнчә, аларны түбәндәгеләрдә гаеплиләр: *«...участие в антипартийной группировке, которая ставила задачу скрыть от партии директивы работникам национальных республик, связь с пантюркистским движением, связь с Султангалиевым и участие с ним в создании программы отдель-*

ной мусульманской коммунистической партии, участие в разработке раздела национального вопроса в программе оппозиции и даже связь с Крымской контрреволюцией»[36].

Хаттан күренгәнчә, аның иялəре гаепләүнең бөтен пунктлары буенча төгәл һәм аңлаешлы аңлатмалар бирә. Бу чыганак һәм башкалары белән дә танышканнан соң, Татарстан Республикасы нинди талантлы дәүләт эшлеклеләрен югалтканлыгын, ә алар тикшерүчеләрнең надан, формалист ялчылар ролен уйнаганын аңлый башлыйсың. Сталин үзе дә милли мәсьәләдә чеп-чи наданлыгын ачык итеп күрсәтә. Әгәр дә ул һәм аның хакимияте Мохтаров хакимиятенә таянып эш кылган булса, СССР, бәлкем, әле бүген дә чын суверен, икътисади яктан да бай булыр иде. Бу, һичшиксез, шулай. Кызганычка каршы, Сталин һәм аның эштәшләре дә объектив анализлардан ваз кичеп, субъектив факторларны алга сөрделәр. Бу үз чиратында илдә көчләү, куркыту, талантлы зыялылардан арыну сәясәтен революция тарафыннан салынган нигезне җимерү урынына үстерде, ныгытты.

Хат авторларына килгәндә, алар, чыннан да, үзләренең бердәнбер гаепләре итеп Солтангалиев белән шәхси бәйләнештә булуларын аңлыйлар. Бу вакытта әле Сталин үзе дә, аның белән йомшак сөйләшүләр алып барып, аны партиягә кабаттан алу турында сөйли. Пантюркизм мәсьәләсендә дә хат иялəре үзләренең уяу фикерле һәм җәмгыятьтәге хәрәкәтләргә, үзгәрешләргә фәнни бәя бирә алганлыкларын ачык итеп күрсәткәннәр. *«В современных условиях, когда Октябрьская революция в корне изменила в СССР межнациональные отношения, а буржуазная Кемалистская революция в Турции окончательно ликвидировала дореволюционные отношения тюрков-османлы и Турции к тюркским народностям Советского Союза, можно ли серьезно думать о пантюркизме?»* Алар, аңгыра солдафоннар белән эш иткәннәнәрен аңлап, үзләре үк төпле җавап бирәләр. Алар фикеренчә: *«Органам, разбирающим и изучающим политические группировки в тюркском мире, известна азбучная истина, что еще в дореволюционное время, перед империалистической войной, пантюркизм уже изживал себя и уступал свое место национализму, как в свое время панисламизм сменился пантюркизмом. Всем известно, что в результате Октябрьской революции, образованием национальных советских республик национальное самосознание отдельных народностей были разбужены настолько, что даже такие общепринятые термины, как «татаро-башкирин» получили уточнения как: «татарин» и «башкирин». Носителями этой дифференциации у ряда тюркских национальностей (казах, узбек, башкир, крымчак) стали не только буржуазная интеллигенция, которая строила свои отношения на основе старых обид и конкуренции с Казанской татарской буржуазией и мусульманским духовенством, которые недружелюбно относились к казанским татарским работникам, но что*

особенно характерно, такое же отношение нередко приходилось встречать даже со стороны коммунистов этих народностей. При таких фактических отношениях можно ли серьезно думать об объединении тюркских народностей. Ведь в дореволюционное время пантюркисты представляли объединение тюркских народностей во главе с Турцией на основе общности интересов, претворение которых в жизнь требовало общей борьбы против русского царизма и Европейского интернационализма в целом и осуществление пантюркизма мыслилось путем создания общетюркского литературного языка. Октябрьская революция постепенно ликвидировала внедренный вместе с восточной культурой язык «тюрк» и способствовало развитию языков каждой национальности в отдельности»[37]. Чыннан да, нәтиҗәдә революциягә кадәр бер-берсен аңлаган төрки халыклар, бер-берсеннән ераклашып, берсен берсе аңламаслык булдылар бит. Менә инде бу — «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» дигән шигарнең чынга ашырылудагы классик мисалыдыр. ГПУшниклар моны аңлап эш итмәгәндер дигән фикер йөртсәк тә, Сталин турында алай ук әйтү дөрес булмастыр. СССРда бөтен халыклар да рус теленә, рус культурасына тартылалар. Шуңа күрә пантюркизм хәрәкәтен оештыру турындагы фикерләр безнең башыбызга да килмәде. Күренгәнчә, ГПУ аны бик оста файдалана, әмма бу барыбер үзең утырган ботакны кискән белән бер бит. Хат авторлары, үзләренең өстенлекләрен сизеп булса кирәк, *«заманчивые идеи пантюркизма не дают покоя лишь отдельным эмигрантам, но и они, по-видимому, не верят в осуществление когда бы то ни было в жизнь этих идей, а лишь используют по мере возможности исключительно для самовнушения против советской действительности. Вот если такая авантюра была допущена каким-то фантазером, так при чем же мы? Или кто-то серьезно может допустить такую мысль, чтобы эмиграция ориентировалась на нас, партийных татарских работников, активных строителей советской власти? Это же сплошной абсурд...»*[38].

Оппозициягә кагылган гаепнамәләр дә шулай ук бары тик аңлашылмаучылык нәтиҗәсе, чөнки чынлыкта Казан партия оешмасында Үзәк Комитет юнәлешен яклаучылар «уңнар» була. Оппозициянең чәчәк аткан чорында, хәтта өлкә комитеты секретаре Пинсон оппозицияне яклаганда, «уңнар» аның белән көрәшә. Моның да ясалма гаепнамә икәнлеген исбат итәләр.

Хатның соңгы өлешендә безне шаккатырган һәм иң гаҗәпләндергән нәрсә: *«ОГПУ органнары берничә ел дәвамында безнең турыда төрле мәгълүмат җыйганнар, әмма бер тапкыр да безне чакырмадылар, хаталарыбыз хакында кисәтмәделәр. Хаталарыбыз булган булса, без аларны төзәткән дә булыр идек».*

Бу хат хуҗасына барып җиткәнмедер, безгә мәгълүм түгел, әмма «Мансуров эше»ндә Емельян Ярославскийның 1929 елның 5 августындагы белешмәсе бар. Аннан күренгәнчә, 1929 елның

23 августында аларны партиядән чыгаралар, ә Сабировка катгый кисәтү бирелә. Шул ук елның декабрендә Г. Мансуров кулга алына, ә 1931 елның гыйнварында атарга дигән карар чыгарыла. Соңрак «эш» яңадан каралып, ул 10 елга хөкем ителә. Соловки лагерьларын узып, соңрак Москва-Волга су каналын төзүдә катнаша. Сугыш алдыннан иреккә чыгарылса да, илебезнең үзәктәге шәһәрләрендә яшәү аңа катгый рәвештә тыела. Ул 1955 елда вафат була.

К.Мохтаровка килгәндә, 1929 елның 16 августында РСФСР Халык Комиссариаты һәм РСФСР икътисади советларының берләштерелгән утырышында аны РСФСР Сәламәтлек саклау буенча халык комиссариаты коллегия әгъзасыннан алу хакында карар кабул ителә. Шул ук елның 8 гыйнварында К.Мохтаров нацменьшинстволарга хезмәт итү өчен төзелгән бюроның рәисе итеп билгеләнә, әмма сентябрь аенда ул бу эшеннән дә азат ителә. Ул да Соловки лагерьларын узып, атып үтерелергә дип хөкем ителә. 1927 елда Л.Троцкий, Г.Зиновьев һәм башкалардан торган оппозицияне фаш итү процессы киңәйгән, тирәнәйгән саен, корбаннарның саны да арта, чөнки Сталин турыдан-туры аларны урыннардагы «милли тайпылышлар» белән бәйли.

Бу уңайдан Татарстан коммунистларының IV пленумы нәтиҗәләре хакында доклад тыңлаганнан соң, Верхне-Городской партактивы түбәндәге карарны кабул итә:

«1. Развернуть в предсъездовской дискуссии свободное обсуждение всех спорных вопросов, как это всегда было при Ленине, предоставив не согласным по тем или иным пунктам с линией ЦК и ОК возможность отстаивать свои взгляды перед всей партией как в печати, так и устно на собраниях партячеек;

2. Прекратить травлю как сторонников всесоюзной оппозиции, так и тех т.т. националов, кои осмеливаются прямо заявить об ошибках ОК в национальном вопросе;

3. Поставить своей задачей добиться сплочения в рядах татарского партактива сближения его с русской частью организации на почве последовательного проведения подлинной внутрипартийной демократии;

4. Оказывать решительный отпор поднимающим голову великодержавным настроениям в аппарате наших советских органов, не ослабляя борьбы с представителями местного национализма из кулацко-поповских кругов»[39].

Өлкә комитетының IV пленумы карарларын мөзакәрә кылу дәверендә милли сәясәтнең дөрес алып барылмаганлыгы да тәнкыйть ителә. Шәһәр активында чыгыш ясаучы Борындыков: *«В отношении национального вопроса, то тут-то, благодаря неправильному подходу к вопросу латинизации и татаризации, стали насчитываться и группировки»*, — ди.

Икенче сөйләүче, Исхаковны тәнкыйть итеп, җыелышларда «уңнар»ны сатлыкҗаннар дип атый. Левин фамилияле коммунист, туп-туры итеп: *«Мы имеем дело с представителями Сталинской линии в области разрешения национального вопроса. Два года работал т. Хатаевич над сколачиванием татактива, но не пришел ни к чему. В разногласиях на Бюро ОК Хатаевич оказался в меньшинстве, это уже можно сказать, что имеется кризис секретарского усмотрения»*, — ди.

Шуны да әйтеп узарга кирәк, кагыйдә буларак, союз оппозиционерлары белән «уңнар» бергә хәрәкәт итәләр, чөнки алар оппозиция ленинчыл дөрес сәясәт алып бара дигән фикердә торалар һәм Сталин сәясәтен тәнкыйтьлиләр. Әмма бу өлкәдә дә бердәм фикер булмый. Мәсәлән, Бөгелмә шәһәр активы, киресенчә, Үзәк юнәлешен хуплап, оппозициягә, аның белән якын мөнәсәбәттә булучыларга каршы көрәшүне һәм хөкемгә тартуны таләп итә. Казандагы Заречьеда узган гомуми җыелышта президиумга җибәрелгән язмалар арасында оппозиция һәм Үзәкнең сәясәтенә төрле карашлар булганлыгы ачык күренә. *«Бер язмада ни өчен оппозициянең документларын нәшер итмиләр, ә икенчесендә бөтен җирдә диярлек оппозиция дөрес юнәлештә бармый, ленинизм юлыннан тайпылган, диләр. Алай булгач, ни өчен соң нәшриятта аларның программаларын чыгармыйлар. Оппозициянең тәкъдимнәре нинди? Ни өчен соң оппозициягә кагылган бөтен материаллар яшертен рәвештә коммунистлар арасында гына таратылалар, ә оппозицияне яклаучыларны эшләреннән куалар. Күрәсең, җитәкчеләрнең башлыклары оппозициядән куркадыр»*.

Кагыйдә буларак, мондый язмаларны төркемнәр яза. Заречье ВКП(б) әгъзаларыннан торган бер төркем, югарыдагы фикерләрне дәвам итеп, *«главное, на всех партийных собраниях не дают высказываться не только оппозиционерам, но и остальным партийцам, которые выражают лишь только мысли оппозиции. Этим самым только доказывается трусость со стороны руководящей головки, и почему того товарища, который выразит мысли оппозиции, снимают с работы. Ведь сам же областной комитет ВКП(б) писал, что не нужно говорить за углом, а говорить на собраниях, а в жизни, как видно, проводится наоборот»*[40].

Югары уку йортларының партактивында да пленум материаллары хакында фикер алышу вакытында бик кызыклы сүзләр әйтелә. Левин консенсусның булмавында Сталинны гаепли, ә «Правда» гәзитендә бастырылган Емельян Ярославскийның мәкаләсендә килешү бозыла. Тормыш оппозициянең дөрес юлда торганлыгын исбат итә: *«Оппозиция права... Ленин за нас, оппозиция идет по ленинскому пути»*.

Ганиев, гомумән алганда, пленум карарларын хуплап, уйландырырлык фикерләр әйтә: *«В условиях нашей парторганизации мы имеем ряд ненормальных моментов. Взять хотя бы вопрос о сплочении татактива. Вместо сплочения мы имеем большое разд-*

роблсние. Если раньше партработников разделяли на две части, сейчас, безусловно, делят на три и даже на четыре. Бюрократические извращения в деле руководства партактивом... у нас в Татарии имеет особенно болезненный характер. Если с одной стороны имеется мелкая опека Обкома над советскими учреждениями, в ущерб работе и руководству основных и более серьезных вопросов, то, с другой стороны, всякая мало-мальская критика и по тому и другому вопросу, направленная против постановок т. Хатаевича, называется безответственной, групповщиной, уклоном и т.д. Хатаевич доходит до такой истеричности, что заявляет, чуть ли не публично, что, мол, Исхакова и Борындыкова и других за их выступления на собраниях сотру в порошок»[41].

Борындыков белән Ефимов та, оппозицияне яклап, аның дөрес юнәлештә хәрәкәт иткәнлеген төгәл дәлилләр белән исбат итәләр. Пленум карарларын тормышка ашыруның кирәклеген, әмма моның өчен Татреспубликаның парторганизациясендә кирәкле шартлар юклыгын басым ясап әйтә Борындыков: *«Хатаевич мине үзенә чакыра да: «Сез нәрсә, собраниеләрдә Исхаков белән миңа каршы сөйлисез, әгәр дә шулай дәвам итсәгез, мин сездән порошок ясаячакмын»*. Шулай итеп, болай да зур авырлыклар белән ачлыкны узып, милли проблемаларны бергәләп аңлашып хәл итәсе урынга ызгыш-талаш, куркыту, коткы чыгару партоешманың эшенә әйләнеп, яңадан-яңа авырлыклар гына тудырып торалар. Оппозиция белән көрәш тиз арада «солтангалиевчелек» белән бәйләнешеп, яңартылып, тирәнәйтелеп бара. Бу өлкәдә Үзәк зур тырышлык күрсәтә.

1928 елны яңадан «Солтангалиев эше» кузгатыла, «солтангалиевчелек»кә каршы көрәш киң җәелдерелә. Бу һөҗүмнәргә берләшеп каршылык күрсәтү Үзәк Комитет тоткан юлга каршы көрәшү дип карала. Урындагы матбугат битләрендә «солтангалиевчелек» белән көрәшкә чакырган мәкаләләр пәйда була.

Шулай ук Р.Сабиров, И.Фирдевс, О.Дерен Айрлы, А.Енбаев хөкемгә тартылалар. Ноябрь аенда Мәскәүгә килгән М.Борындыковны кулга алалар. Шунысы кызык: аны да «Мәскәү үзәге» әгъзасы дип игълан итәләр.

ОККга бик яшертен гриф белән җибәрелгән документта Борындыковның Солтангалиев белән мөнәсәбәтен ачыклауны таләп иткән боерыкта түбәндәге юллар бар: *«...лидер так называемой «правой» группировки 1917 г., подпоручик, с 1918 г. член партии, родился в 1896 г. в семье крестьянина. В 1924 г. ОКК ВКП(б) объявил строгий выговор за «групповую борьбу»*. Аның «Мәскәү үзәге» белән аралашуын да ачыклыйлар. Янәсе, ул «үзәк» белән берлектә сәяси мәсьәләләр буенча фикер алышуда һәм оештыру эшләрендә актив катнашкан. «Уңнар», Солтангалиев белән бергә эшләгән. Казанга килгәч, Мөхәммәдъяров, Ганиев, Бөдәйлиләр белән әңгәмә корган. М.Борындыков 1918 елда сөйгәне Фәйзуллина Мәчтүрәгә язган хатын да үзенә каршы

файдаланалар. Ул анда «большевиклар турында большевикларча шаяртмаган икән»[42]. Солтангалиевнең киләчәк турындагы уйфикерен мин ул кафедрада сөйләгәндә ишеткән идем, ди. Эчке эшләр комиссарына язган язмасында ул: *«Московский центр» все больше и больше склонялся к давнишней мысли Султан-Галиева о неизбежном крахе Советской власти и о необходимости создания кадров на этот случай»*, — ди[43].

1927—1929 елларда «көрәшчеләрнең» кайберләре, шул исәптән Г.Кутуй, Терегулов, режиссер Л.Солтанов һәм педагог Фазлуллин өлкә комитеты секретаре Разумовка язган язмаларында: *«Солтангалиевчелек тамырлары партиясез зыялыларга тирәнгә керде»*, — диләр[44]. Өлкә комитеты әгъзаларыннан Г.Байкиев, Ш.Рамазанов, Ф.Бурнаш, С.Шангареев һәм башкалар Солтангалиевкә каршы икәнлекләре турындагы гаризаларын өлкә комитетына тапшыралар. Рахманкуловның язмасында квартирларда булган җыелышып сөйләшүләр хакында сүз бара. Имеш, Борындыков, Бөдәйли, Ганиевлар өлкә комитеты сәркатибенә һәм «уңнар»га карата нинди мөнәсәбәттә булырга кирәклеге хакында мөзакәрә кылалар, ә Мохтаров, Енбаев, Сабиров, Мансуровлар кулга алынгач, алар тарафыннан Мәскәүгә командировкага Ф.Бурнашны җибәрергә булалар. Төп мәсьәлә — аларның язмышын белү. Ф.Бурнашның гафу үтенеп язган хатлары 1929 елның 18 ноябренә, 15 гыйнварына, 1930 елның 1 июненә, 24 ноябренә карый. Соңгы хатында ул: *«Я порываю все нити от своих литературных ограниченностей и решительно переключаюсь отображению в своем творчестве героических мотивов строительства социализма, социалистической переделки сельского хозяйства, ликвидации кулака как класса на основе сплошной коллективизации.*

Я отмежевываюсь от всех своих ошибок, совершенных мною принадлежностью и примиренчеством к «правой» группировке, и обещаю честно служить генеральным лозунгам партии во всех звеньях своей работы...» — ди[45].

Г.Әминев, «Положить конец султангалеевщине!» дигән лозунг белән чыгып, «уңнар»ны төп сәясәткә каршы булуда гаепли. Солтангалиевчеләр, индустриализациягә, күмәкләштерүгә каршы чыгып, Совет хакимиятен, *«эшчеләр диктатурасын эчтән җимерергә телиләр»* ди[46]. Ул «уңнар»ны «солтангалиевчелек» белән бутарга ярамый икәнлеген дә искә төшерә, чөнки солтангалиевчеләргә Башкортстанда — «вәлидовчылык»ны, Бохарада — «гарифовчылык»ны, Кырымда — «ибраһимовчылык»ны, Казакъстанда «вафкасовчылык»ны китереп кушалар. Шулай эшләүнең сере Солтангалиевне Туран мөселман дәүләтен төзүдә гаепләү өчен кирәк була.

Сентябрь, октябрь айларында кулга алулар башлана. Педагогика институты укытучысы Максудов, Бөдәйли буржуаз милләтчеләр буларак кулга алыналар. Шулай ук партиядән Ганиев тә чыгарыла. Борындыков һәм Максудовның ачык хөкем ителүләре дә була.

Шул ук вакытта «суллар» белән көрәш тә яңа сулыш ала.

«Суллар»ның җитәкчесе, теоретигы булып М. Сәгыйдуллин сайлана. Әдәбиятта аны «татарский Бухарин» дип йөртәләр. *«У нас есть т. Сагидуллин, парень весьма грамотный, теоретик левых. Несколько лет назад за ученость его прозвали «татарским Бухариным». С тех пор вконец испортился самомнением и стал путать еще более безбожно... написал статью «О подхалимах и обывателях»*. Монда ул, ялагайларны, үз мәнфәгатьләре хакына гына яшәүчеләрне «уң»нан да, «сул»дан да эзләмәгез, алар уртада, ди. Солтангалиевчелек ул милли сәясәт дөрес булмауның нәтиҗәсе икәнлеген ассызыклап яза. М.Сәгыйдуллинның партиядәге хәле бик күп татар коммунистларының язмышына охшаган. Кыю фикер йөрткәне өчен ул шактый газаплар чигә. 1927 елда ук аны февраль пленумы карары белән эшеннән куалар. Төп сәбәп — өлкә комитетын тәнкыйть итү. Татарстан өлкә комитетына язган гаризасында ул: *«Өлкә комитет тарафыннан төркемнәргә карата булган мөнәсәбәтне тәнкыйть иткән идем, 15 айлык тәҗрибә һәм XII конференция минем дөрес фикер йөртмәгәнемне күрсәттеләр»*, — ди. Шулай итеп, ул үзен эшкә алуларын сорый. 1927 елның 9 маенда аңа карата өлкә комитеты секретариаты уңай җавап бирә. Әмма эшкә алганда аңа махсус шартлар куялар: төркемнәрдә, фракцияләрдә катнашмаска һәм партиянең бердәмлеге өчен көрәшергә[47]. М. Хатаевич өлкә комитетының III пленумында М.Сәгыйдуллинны Татарстанга кайтару хакында: *«Безгә Сәетгалиев кебекләр кирәкми, ә М.Сәгыйдуллин кебек белемле татар коммунистлары бездә бик аз»*, — ди. Бу әле 1927 елның май ае гына була. Республикадагы хәлләр көннән-көн авырая бара, чөнки төркемнәр яши, алар бетерелмәгән. Өлкә комитеты бюросының һәм ВКП(б)ның өлкә контроль комиссиясе президиумының берләштерелгән утырышында махсус рәвештә Шәймәрдәнев, Әхмәтшиннәрнең өлкә комитеты секретаре М.Хатаевичка шикаятьнамәләре карала.

Тарихи белешмә

Миңлегәрәй Әхмәт улы Әхмәтшин (1889—1938) — дәүләт эшлеклесе, 1921—1922 елларда Татарстан Республикасының эчке эшләр халык комиссары, 1926—1927 елларда җир эшләре халык комиссары, 1927—1929 елларда ТАССР Үзәк башкарма комитеты президиумы рәисе. 1930 елда хуҗалык эшләрендә хезмәт итә, репрессияләнә, соңыннан аклана.

Шәймәрдәнев Шәйгәрдән Шәймәрдән улы (1890—1939) — дәүләт эшлеклесе, 1824—1927 елларда Үзәк башкарма комитеты президиумы рәисе урынбасарының җаваплы инструкторы, 1930—1931 елларда РСФСРның финанс халык комиссариаты коллегиясе әгъзасы. Репрессияләнгән, соңыннан акланган.

Әхмәтшин әлеге утырышта: *«Өченче пленумнан бирле (*май, 1927. — *Р.В.) партия җитәкчеләре арасында аяусыз көрәш бара, төркемнәрдән инде өченче төркем — Хатаевич төркеме хасил була. Бу төркем актив коммунистларны үзеннән читләштерә. «Уңнар» да бетерелми. Әмма бу төркемнәрнең көрәше Татарстанга, коммунистларга каршы булмасын иде. Өлкә комитетының сәркәтибенә төркемнәр белән көрәш ысулы XI, XII партконференцияләрнең карарларына туры килмиләр»,* — ди.

Моңа карата ул дәлилләр дә китерә. Мәсәлән, Хатаевич: *«Мондыйларны беркая да сайламаска кирәк»,* — ди, русларны төркемнәр белән куркыта. Шуңа күрә Әхмәтшин җитәкчелек эшендә бердәмлеккә, үзара аңлашып хәрәкәт итүгә басым ясап әйтә. Ул коллектив белән эшли белми, ә миңа Татарстан Үзәк башкарма комитеты рәисе булып эшли башлаганда ук яла яга башлады, ди. Моның нәкъ шулай булганлыгын исбат итү өчен бер архив чыганагына тукталу да җитә. 1927 елның ноябрь-декабрь айларында Әхмәтшингә каршы провокацияләр оештырыла. Шәймәрдәневнең дошманнары Чаллы кантоны комитеты секретаре Яһудин һәм Чаллы кантоны комитеты буенча өлкә контроль комиссиясе вәкиле Баев Хатаевичның «үз кулына гадәттән тыш ышанычлы» дип җибәрелгән хатында: *«Сезгә крестьян Искәндәревнең Сәгыйдуллин тарафыннан әйтеп торып яздырган язмасын җибәрәбез. Имеш, Искәндәрев Казанда чагында аның фатирында булган. Менә монда килгәч, ул тагын Якуповны, Шәймәрдәневне дә күргән»,* — дип яза. Архивта бу хатның татарчага күчерелмәсе сакланмаган. Бусы да шик тудыра. Бу — беренче, ә икенчесе, янәсе, Искәндәрев Баевка: *«Мин сөйлим, сез языгыз»,* — дигән. Шулай итеп, бу Искәндәрев хаты түгел, ә бәлки Баев хаты булып чыга инде. Бик уңай бит: крестьян Искәндәрев исеменнән ни язсаң да була. Бу хатта: *«Искандеров говорил: мне в период Всетатарского съезда Советов пришлось быть в Казани и по приглашению Сагидуллина после съезда я с членом ВКП(б) Мухаметзяновым пришел на квартиру Сагидуллина. Цель моего посещения тов. Сагидуллина увести в дер. к его родителям обещанные им деньги... там же я застал Якупова, Шаймарданова и еще двоих неизвестных. Они сказали (Шаймарданов и Якупов): «Как только придешь в деревню, после деятельной агитации среди крестьян, соберите подписи от них об оставлении Сагидуллина и Якупова на своих местах, их отстранили от должности, скажите крестьянам, что эти товарищи много принесли пользы народу, ты это заявление крестьян пошли нам, мы их отправим Сталину, только к этим заявлениям сам не подписывайся, пусть подписываются крестьяне, имей в виду, чтобы ОГПУ не узнало и потом, чтоб за это не попало, но все это сделай». Я сказал, что этого я не сумею сделать и таких дел я боюсь».* Искәндәрев искә алган Суыксу авылы крестьяны Фәхрулла Гыйззәтуллин һәм коммунист Мөхәммәтҗановка күзәтү

оештырыла. Мөхәммәтҗановны Шәймәрдәнев, Сәгыйдуллин һәм башкалар белән очрашу вакытында тагын нәрсәләр булганын белү өчен махсус чакыртачакбыз, диелгән[48].

Бу мәсьәлә өлкә комитетының ябык утырышында Үзәк Комитет вәкиле Мехлис катнашында карала. Монда Ибраһимов, Мехлис, Шәймәрдәнев, Хатаевич, Гыймрановлар чыгыш ясыйлар һәм Шәймәрдәневкә сораулар да бирәләр. Ибраһимов үз чыгышында өлкә контроль комиссиясе президиумы әгъзасы Чаллыдан килгән гаризаларны гына карый дип әйтә. Ул шулай ук Искәндәревкә Казаннан беркем дә материал җыю хакында махсус бурыч бирмәгәнлеген әйтә. Шәймәрдәнев үз чыгышында: «*Нельзя так относиться ко мне, не доверять мне и думать, что я не член партии, и не понимаю, как себя вести. Почему какому-то Искандерову, который выгнан из партии чуть ли не за казнокрадство, больше доверяют, чем другим членам партии.... Мухаметзянова и Искандерова я совершенно не знаю и они ко мне не приходили. Я категорически отрицаю то, что они мне приписывают... записок и денег... никому не давал, приглашений на съезд не давал. Что касается Искандерова, он сказал, что он меня дискредитирует, может быть, он как раз получил указание из Казани, но я это не могу доказать. Мое заявление не разбирают*».

Үзәк Комитет вәкиленең «*Сез нәрсә тәкъдим итәсез?*» дигән соравына «*Яһудинны партиядән чыгарырга*» дип җавап бирә.

Съездда үз чыгышында җаваплы секретарь Мендель Хатаевич: «*Якубовка кул чабуларны һәм партиясезләр тарафыннан Хатаевич, Гыймранов кандидатураларыннан баш тартуны кем оештырган икәнлеген белмим, әмма Яһудиннар хатында Шәймәрдәнев тә катнашканлыгы әйтелә*», — ди. «*Әлбәттә, Баев, Р.В.Яһудин арттырып җибәрәләр*», — ди секретарь.

Гыймранов жалобщикларны хуплап чыкса да, нәтиҗәдә Шәймәрдәнев өчен уңай карар кабул ителә. Анда:

«*1. Указать на Ягудина, Баева на неправильный их поступок;*

2. Письмо Шаймарданова, разосланное членам бюро ОК 13 мая, писалось им в обстановке раздраженности... письмо принять к сведению.

3. Просить президиума ОКК пересмотреть свое решение в отношении Шаймарданова»[49].

Шулай итеп, Халык Комиссарлары Советы рәисе булып эшләгән Шәймәрдәнев тә авыр хәлдә кала. 1927 елның 22 декабрендә Татарстан Халык Комиссарлары Советы рәисе Шәймәрдәневне эш урыныннан алу хакында карар чыгарылып, аның урынына Исмаев тәкъдим ителә. Ул шул ук көнне Сталинга хат юллый: «*Мин Хатаевич белән бәхәсләшә идем, кайбер мәсьәләләрдә мин дә дөрес фикердә булмаганмындыр, әмма ул милли республикаларда эшли ала торган җитәкче түгел. Ул кадрларны бик еш алмаштыра. Башта Габидуллинны куйды, аннан мине. Инде менә хәзер өченчесен куя. Тиз арада Татарстанда*

эш урыннарыннан мәгариф комиссары Мөхетдинев, хезмәт наркомы Измайлов, зам. ТСНХ Кудояров, Госбанк управляющие Тарпищев, Республика прокуроры Палютин, кайсыбер секретарьлар алыныпрлар. Сәгыйдуллин һәм Чаллы кантоны секретаре эшләреннән алындылар да инде», — ди[50]. *«Кстати, месяцев шесть назад сняли с ответственных постов Мухамета Тагирова, Еникеева Исхака, Гимранова. Тагиров критиковал татотдел ГПУ, который вместо того, чтобы бороться с к.р., собирает грязь на татарских коммунистов. У нас в Татарской партийной организации не найдется ни одного активиста, который бы не пострадал в том смысле, как я, за исключением некоторых «барабанщиков», «плясунов» под дирижерскую палку. Обычно у нас принято понимать так: когда выступаешь с критикой, говорят, что тебе полагается по штату, что он пострадавший»*[51].

Болар барысы да совет органнарында, бер сүз белән әйткәндә, Татарстан хакимиятендә, татарларның санын азайту сәясәтенең нәтиҗәседер. Шәймәрдәнев бу сәясәт белән ачыктан-ачык көрәшә һәм өлкә бюросында күпчелек аны яклый, хәтта Мәскәү вәкиле дә аның дәлилләре белән килешә. 1926 елның 1 декабрендә «Татар теле һәм совет органнарын җирләштерү (коренизация) мәсьәләләре» хакындагы докладында бөтен инстанцияләрдә җаваплы эшләрдә татарларның саны азайганы конкрет мисаллар белән исбатлана. Мәсәлән, бер ел эчендә (1926) җаваплы хезмәткәрләрнең саны 3,24% техник персонал, кантон оешмаларында 1924 елда 29% булса, 1926 елда — 24,4% , ә техник хезмәткәрләр 19% тан 14,8% ка, КИК әгъзалары 53,3% тан 52,3% ка, Үзәк башкарма комитеты әгъзалары 58, 9% тан 55,1% ка кимегән. Үзәк Комитет инструкторы Мехлис, совет хакимиятенә татарларның санын арттыру мәсьәләсенә анализ ясаганнан соң, бу процесска бәя биреп: *«Когда начинаешь глубже изучать качество работы, то, оказывается, что в целях достижения заданных процессов по плану некоторые учреждения привлекают в аппарат татар в качестве дворников, сторожей, кучеров и т.д.* ***Получается не татаризация, а кучеризация...*** *Если мы хотим сделать Советскую власть понятной для основного населения, необходимо на деле принимать меры по реализации татарского языка как по линии обучения татарскому языку, письменности работников не татар, так и по линии привлечения трудящихся масс татар в государственные аппараты и в аппараты профессионального и партстроительства»*[52]. Г.Ганиев һәм В.Исхаковларның өлкә комитет бюросы адресына язылган хатының эчтәлегеннән чыгып, тагын шуны әйтергә була: Хатаевич һәм аның яклылар оппозиция белән милли буржуазия арасында аерманы күрмәмешкә салышалар. Әлбәттә, оппозиция белән милли буржуазия бер түгел, һәм алар арасында тигезлек билгесе кую — турыдан-туры провокация. Мондый эшләрне Мендель оста башкара. Шуңа күрә хат ияләре өлкә комитетыннан катгый рәвеш-

тә түбәндәге таләпләрне тормышка ашыруны таләп итәләр. *«Во-первых, срочно обсудить настоящее наше заявление и брошенное на нас т. Хатаевичем необоснованное обвинение в том, что в своих выступлениях на пленуме Областном (*IV. *— Р.В.) мы выразили заявление и настроение национальной буржуазии, и опубликовать это в парторганизации; во-вторых, отменить директиву БЮРО ОК, принятую по настоянию т. Хатаевича и фактически означающую недопущение бывших т.н. «правых» и «левых» в выборные парторганы, в корне отменяющие постановление ЦК по вопросу о срабатывании; в-третьих, перенести вопрос на разрешение в ЦК партии в случае непринятия наших предложений»*[53].

Татар крестьяннарының хәленә дә кагылып, аларның бик тә авыр хәлдә икәнлекләре әйтелә. Кагыйдә буларак, татар авыллары зур шәһәрләрдән, базарлардан, тимер юллардан ерак урнашкан, җир сөрү артта калган ысуллар белән эшләнә, 40% тан артык хуҗалыклар — атсыз. Шундый вакытта дәүләт ягыннан ярдәмне азайту шәһәр белән авыл арасындагы бәйләнешне өзү ихтималлыгы да искә алына. Болар һәм башка сәбәпләр татар авылларын зәгыйфьләндерә генә. Аларның барысына да киртә салучы Мендель Хатаевич һәм аның кыланышлары милли сәясәт линиясендә Татарстан хезмәт ияләренең яулап алган җимешләрен бетерүче дип бәялиләр[54].

Әхмәтшиннән соң сүз алган Щербенин үз чыгышында: *«Причина сегодняшнего собрания — это разобрать ту неправильную политику, которую ведет большинство ЦК ВКП(б) и, в частности, областной комитет. Ошибка местных националов в том, что они вину за создавшееся положение переносят персонально на Хатаевича, в этом я с ними не согласен, он выполняет общую линию, которую ему дал Сталин»*, — ди.

Төркемнәр мәсьәләсендә ул: *«Татарский актив сознательно сталкивают лбами, чтобы секретарю лучше было командовать. Вы, товарищ Хатаевич, командуете и будете иметь подобные заседания»*, — дип өсти[55]. Милли мәсьәләләрне хәл итәргә теләү һәрвакытта төркемлектә гаепләнә һәм алар *«еще очень наивны и верят, что ЦК проводит правильную линию, а вот на местах искажают. Это не совсем так. ЦК партии искажают в целом ряде вопросов решения предыдущих съездов, а в частности по национальному вопросу»*. Куянов, Щербенинны тәнкыйть итеп: *«Вы, тов. Щербенин... пользуясь трудностями в работе нашей организации, раздуваете страсти, натравливаете одних на других. Все равно вам номер не пройдет. Вы — человек конченый»*[56]. Шәймәрдәнев, Исмаев, Петров, Шәфигуллиннар — барысы да тәнкыйть утына эләгәләр. Шәймәрдәневне «ультрасуллар» белән блокка керүдә гаеплиләр.

Шул чор өчен үзенчәлекле чыгышны М.Сәгыйдуллин да ясарга мәҗбүр була. Гариза язып, тынычлыкны бозмаска сүз биреп,

Татарстанга эшкә кайткан М.Сәгыйдуллинның чыгышы бик тә кызыклы. *«Мин монда Сәгыйдуллин турында сөйләргә килдем, чөнки минем өчен башка темалар «табу» билгесе астында торалар. Мин инде ике ел беркайда да чыгышлар ясамадым, әмма минем исемемне «везде и всюду склоняют по всем падежам». Минем гаризамны беләсез: мин барысын да үтим, әмма мин протест белдерәм, чөнки минем гаризам озынлыкка һәм киңлеккә үсә. Минем гаризама иптәшләр яңа пунктлар, яңа бурычлар өстиләр. Минем гаризамны договорга әйләндереп, мине «договорной коммунист»ка әверелдерәләр. Менә бу инде активистны пленда тотуның яңа методикасы». «Молчу, не выступаю — говорят, договор нарушается, надо, видите ли, выступать против т. Шаймарданова, еду в отпуск на родину — говорят, что это нарушение обязательства и т.д.»*[57].

Менә шушындый ысуллар белән татар коммунистларын маңгайга-маңгай бәрдерү сәясәтенә ул түзми — протест белдерә. Сүзен дәвам итеп, ул: *«Я на этом пути не один, в наших условиях каждый выдвиженец повторяет этот путь, доходя до обкома, доходя до руководящей работы — аккуратненько получает ярлык групповщика, это ненормальная обстановка, которую необходимо ликвидировать... документ доверия превращается в «бессрочный паспорт», при помощи которого хотят держать в плену. Я вынужден буду бороться за партийное равноправие»*[58].

Үзсүзле булганы һәм кыю фикерләр өчен «татарский Бухарин» исемен йөртүче М.Сәгыйдуллин шул ук вакытта «Татар эшчеләре Октябрь юлында», «Вәисиләр хәрәкәте тарихына» исемле тарихи хезмәтләр дә нәшер итә. Соңрак ул «Кызыл Татарстан» гәзите битләрендә «Ялагай Куштановлар кабиләсе» исемендәге шактый зур памфлет белән чыга. Ул монда ялагайлар, дәшмәүчеләр, тәлинкә тотучылар хакында яза. *«Куштанлыкның чишмәсе — коллар хуҗалыгы, крепостнойлык тәртипләре, Шәрыктә сарай хезмәте, ишанга мөритлек, колонизаторларга яраклы булу мәҗбүрлеге... Урыс тарихында крепостнойлык чоры, түбәнчелек белән буйсынуга нигезләнгән монастырь тәртипләре, аннан илне идарә итүдә губернаторлык системасы, түрәләрнең халыкка түгел, бер-берсенә буйсыну рәвешләре... болар иске Русияне Молчалиннар иле ясадылар»*. Үзе яшәгән чорга күз салып, М.Сәгыйдуллин, «молчалин»нарның хәзер телләре ачылды, ди. *«Грибоедовның телсез «Молчалин»ы сөйләргә өйрәнеп китте: ревизия, тазарту вакытларында тасма телләнеп, түрәсен мактап чыга башлады. Чацкий «хәзер сүзләләрне яраталар» дип зарлана торган булса, заман бюрократлары тиешле җирдә түрәсен яклап речь сөйләгән егетләрне ярата башладылар.*

...Түрә дә бит кабыктан ясалмаган: аңар сүз тыңлаучан кешеләр кирәк, «Ни боерасыз?» дип тора торган типлар, «Баш өсте» дип тора торган көянтә билле чиновниклар кирәк. Андыйлар белән эшләү җиңел була». «Куштаннар бүген ни эшли?»

дигән сорауга җавап биреп, ул: *«Ул бүген гадәттәге эшләреннән башка бюрократка тәнкыйтьне арканлап куярга ярдәм итә, демократчылар белән көрәшә, тазарту эшләренә комачаулык итә. Прение ачмаска дигән тәкъдим кертә. Гомумән алганда, канәгатьләнерлек дигән карарларга башлап тавыш бирә. Аппаратны үзгәртми, тазартмый сакларга, үзенә файдалы булган кешеләрне партия эчендә — совет аппаратында саклап калырга тырыша. Ул үзенең хезмәтен «эшлеклелек» эләме астында алып бара»*[59].

Татарстан өлкә комитеты тарафыннан Шәймәрдәневкә һәм башкаларга каршы оештырылган кампаниядә катнашудан баш тарткан Сәгыйдуллинның чыгыш ясамавының сәбәбе билгеле. Үзәккә ярарга тырышып хезмәт иткән Хатаевич, Морозовлар һәм Татарстан «суллар»ы шушы кабиләдәндер дисәк, ялгыш булмастыр. Аларның барысын да үз заманында яхшы күзаллаган М.Солтангалиев үзенең «Записная книжка»сында *«Суллар» кемнәр алар?»* дигән сорауга җавап бирә: *«Группа «левых»: а) саидгалеевцы; б) левые эсеры; в) шамигуловщина; г) ибрагимовцы (к буржуазии не пристал, от пролетариата отстал, самые беспринципные, карьеристы (Крым), наиболее трусливые, шкурнические элементы... противоречивость, мягкотелость, трусливость (зачем кричать о колонизаторстве). А в это время Смирнов проводит колонизаторскую политику. Есть национализм в русской организации? Есть. Это подтверждает и постановление Коминтерна (речь Молотова об уклонах в русской организации): «Восстановление Москвы, Китайск. город, Собор Блаженного, Троицкие ворота.*

Зачем же воспитывать в духе самоотвержения и ограничения во имя революции? Одни лишь окраины. Почему не всегда в том же духе и русских...»[60].

Бу җыелыштан соң икенче көнне Әхмәтшин, Шәймәрдәнев, Петров, Гафуров, Измайлов, Кудояров, Палютин Мәскәүгә китеп баралар, ә Хатаевич, өлкә комитеты бюросының һәм өлкә контроль комиссиясе президиумының җыелышын җыеп, өлкә комитеты әгъзаларының рөхсәтсез килеш Мәскәүгә китүләрен тикшерә[61].

Шулай итеп, татар коммунистларын кулга алу һәм аларны эштән куу өчен бөтен мөмкинлекләр тудырыла. Өлкә комитетындагы ыгы-зыгы, Хатаевичның булдыксызлыгы, Үзәкнең басым ясавы — болар барысы да бергә төп юнәлештә киң мөмкинлекләр ача. Партия өлкә комитеты элмәккә эләгә. Хәтта Хатаевич та өлкә бюросында аздан гына урынсыз калмый. Аны бары тик Исмаев һәм Гарифуллин гына үз итәләр. Нәтиҗәдә авыр хәлдә калган өлкә комитеты секретаре М.Хатаевич, Үзәк Комитетка язган хатында тиз арада үзен башка җиргә алуларын үтенеп, Татарстанга Ежовны җибәрсәгез иде, ди[62].

Үзәк Комитетка Молотов, Янсон исеменә юнәлгән хатында ул, *«миңа каршы Шәймәрдәнев белән Әхмәтшин эш алып баралар»*, ди. Казан татарлары, Кырым татарлары кебек, партиянең

өлкә сәркатибен куарга телиләр. Алар, *«ни эшләп әле без үзебезне берәм-берәм кыйнатабыз, әйдәгез берләшик һәм җитәкчеләрне бәреп чыгарыйк, ә чыгара алмасак, җитәкчесеннән котылырбыз»*, диләр. Бөтен оешмаларда, җыелышларда өлкә комитетын сүгәләр. Бу эшне «әүвәлгеләр» һәм «уңнар» эшли. *«Үзем турында шуны гына әйтәм: мин монда 5—6 айдан артык утыра алмамын, арыдым»*, ди.

К.Мохтаровның фикерләренә караганда, бу очраклы хәл булмаган, ә бары тик өлкә комитеты һәм Үзәк тарафыннан алып барылган сәясәтнең бер нәтиҗәсе генә. *«У нас на месте не потрудились оценить, а какова же у нас в ТССР борьба левизны и правизны.*

У нас была такая картина: 1) Великодержавная сильно выпяченного не было, а, стало быть, и реакции к нему; 2) А по выпячиванию в партаппарат рабочих татар мы можем судить, что руководящая часть и в целом организация вообще была чиста от мешающей этому правизны.

В общем оказалось, что постановления XII съезда сходят насмарку. Цель совещания не понятна. Идет линия искривления этих решений (тянут не к партии, а к левизне... всех без исключения работников татар разделили на правых и левых, наклеили им ярлыки... и во всем ярко проступило, что только русские правы, и эта тенденция, очень аналогичная «разделяй и властвуй», привела к тому, что фактически постановления XII съезда о великодержавничестве стали в большинстве случаев считаться декларацией).»

Татар коммунистлары кебек үк, Татреспубликаның үзенчәлекләрен аңлап эш иткән рус коммунистлары да татаризмда гаепләнәләр. Нәтиҗәдә бөекдержавачылык башын күтәрә. 1921—1924 еллардагы халыклар арасындагы тигезлек әкрен генә югала бара — бөекдержавачылык калкып чыга. Җитәкчелек органнарында «уңнар» сәясәткә зур тәэсир ясый алырлык хәлдә түгел инде, чөнки партия әгъзаларының саны татарлардан күбәйсә дә, аның «сыйфаты» түбән кала бирә. Партия өлкә комитетының эш рәвеше дә бөек державачылык «суллар» ягында. Шулай да төп гаеп өлкә комитеты бюросына төшә. *«Бюро не видит части работ, каковые захватываются секретариатом, особые мнения, отказ от использования правых, деловым экономическим предложениям противопоставляются неделовые. Все это имеет очень вредное отражение в массах и низах партии. В аппарате ОК почти никого нет. Они разжигают антагонизм среди татар. Создают группировки»*. Нәтиҗәдә рус халкының күплегеннән файдаланып, үзгә фикерләр уздырыла, көнүзәк өлгергән милли мәсьәләләр юк дип санала. Караса да, аны бюро түгел, ә бары тик секретариат кына хәл итә. Анда инде, чыннан да, милли мәсьәләне караучы бер генә татар да юк икәнлеге көн кебек ачык. Моңа бер генә мисал китерү дә җитә.

Мәсәлән, «39 лар хаты»нда өлкә комитетында уздырылган тавыш бирү нәтиҗәсе бик тә гыйбрәтле. Морозов-Жуковлар резолюциясен хуплыйлар: өлкә комитеты әгъзаларыннан — 15, кандидатлардан — 10, ОКК — 8.

«За резолюцию Мухтарова из членов ОК — 2, кандидатов — 2, ОКК— 0, воздержались: член ОК — 1 канд. — 1». Бондюг һәм Кокшайск районы вәкилләре бөтенесе К.Мохтаров резолюциясе өчен сайлыйлар. Шуны да әйтми ярамый, хәтта шушы вакытта Бикмуллин үзен «39 лар» исемлегенә кертүләрен сорый, әмма, кызганычка каршы, өлкә комитетында да татарлар бик аз булалар, алары да йә «сул», йә «уң» булып хәрәкәт итәләр[63].

Менә шушы ыгы-зыгылар Казанда кулга алулар белән бергә бара. Татар коммунистларын бу чорда, күбрәк төркемнәргә бүлеп, милләтче яисә бәйнәлмиләлче ярлыкларын асып, Русия буйлап төрле эшләрдә файдаланалар (Казанда калсалар, берләшүләре бар). Татарстанның күренекле зыялыларын төрмә, лагерьларга озату арта, чөнки алар эшнең кая барганын алдан күреп, вакыйгаларга анализ ясап торалар. 1927 елда Г.Шәрәф, Ш.Шәрәф, кулга алынып, лагерьларга озатыла. Аларны «буржуаз милләтчеләр», «Совет хакимиятенең дошманнары» дип игълан итәләр. Шулай ук аның эше һөҗүмнәр башка татар зыялыларына каршы да көчәйтелә. Бу эшне 1927 елда ОГПУның Татарстан бүлеге буенча башлыгы Кандыбин башлап җибәрә. Шул ук елны аның тикшерүе нәтиҗәсендә Бөгелмә кантонында «Совет хакимиятенә каршы хәрәкәт иткән» милләтчеләр төркеме «табыла». Аның җитәкчесе күренекле татар тарихчысы мөгаллим Һади Атласи була, имеш. Анда тагын җиде кеше җавапка тартыла. Һ.Атласи тирәсендә булган сексотлар аның сүзләрен ОГПУга җиткереп торалар. Аның шуңа сәбәпче фикерләреннән берсе: *«Ленинның тәгълиматы дөрес түгел, ул тарихта «сикереш» ясый. Тарих — көчле фән, аның кануннарын сикереп узып булмый»*, — диюдән гыйбарәт. Нәтиҗәдә ул 10 елга хөкем ителә. Кызганычка каршы, «уңнар» һәм «суллар» бу кара эштә коммунистлар буларак актив катнашалар. Матбугат битләрендә «шарафизм» белән көрәшергә кирәклеге әйтелә. Билгеле булганча, бу чорда татар зыялылары ныклы рәвештә татар халкының мәдәнияте, аның киләчәге хакында мөзакәрә кыла. Әлбәттә, татар коммунистлары да бу үзара бәхәсләрдә кайнар рәвештә катнаша[64]. Билгеле булганча, берничә ел дәвамында гарәп, латин шрифтларын саклау-сакламау хакында кызу фикерләр булганнан соң, нәтиҗәдә әйләнешкә кириллица кертелә. Монда да эш бөтен мәсьәләне халык фикерен искә алып түгел, ә Үзәкнең күрсәтмәсе белән генә хәл ителә. Менә шуңа күрә әле бүген дә бу өлкәдә шактый саллы бәхәсләр бара. Татар конгрессы тарафыннан уртага куелган латинлаштыру мәсьәләсе Русия Дәүләт Думасы тарафыннан тискәре якка хәл ителде. Шулай итеп, монда да, XX гасырның 20 нче елларындагы кебек, эшне Үзәк үзенчә хәл итеп куйды.

Мәгълүм булганча, 1927 ел — Сталин тарафыннан эштәшләрен: Троцкийны, Каменев, Зиновьев, Бухарин, Рыков һәм башкаларны алып ташлар өчен мәкерле ниятләр әзерләгән вакыт. Күренекле язучы, дәүләт эшлеклесе Г. Ибраһимовны эзәрлекләү көчәя. Аның һәрбер адымын тикшереп торалар. 1927 ел — Октябрь инкыйлабына 10 ел. Г.Ибраһимов та бу бәйрәмгә «Каким путем пойдет татарская культура?» дигән хезмәтен нәшер итә. Ул шовинизм һәм милләтчелек турындагы үз фикерләрен ап-ачык итеп әйтеп бирә. Хакимият органнарын аның түбәндәге фикере кызыксындыра: *«Народы, говорящие на татарском языке, где бы они не жили, считаются частями одного культурного коллектива. Поэтому вопрос о постоянном контакте с татарами, живущими вне Татарской Республики, должен занимать особое место в развитии и усилении татарской культуры, и моменты обмена культурными и научными опытами с другими тюркскими народами должны иметься в виду»*[65]. Беренче һөҗүмне Г.Ибраһимовка Ходорович 1927 елны 16—19 маенда узган ВКП(б) өлкә комитетының III пленумында ясый. Ходорович үзенең «Милли мәдәният һәм латинлаштыру мәсьәләләре» дип аталган докладында, *«Г.Ибраһимов әлеге хезмәтен өлкә комитеты рөхсәтеннән башка нәшер иткән, һәм аның бу брошюрасында зарарлы фикерләр бар, аның фикерләре партия фикерләреннән ерак»*, ди. *«Проводя директивы партии по национальному вопросу, в частности, в области обслуживания масс на родном языке, когда мы всячески стремимся и добиваемся, чтобы культурно-бытовые условия и навыки данной национальности полностью учитывались, то в проведении всей этой работы мы должны более четко выпячивать задачу борьбы с реакционно-буржуазными попытками обособить трудящиеся массы данной нации от трудящихся других народов СССР, от пролетарской идеологии, носителем которой является пролетариат СССР и наша ВКП(б). Между тем в тезисах Ибрагимова такое выпячивание пролетарского содержания национальной культуры на продолжении всей книги отсутствует. Поэтому когда появилась его книга, наиболее горячий прием и ходкую аудиторию она нашла среди беспартийной буржуазной интеллигенции. В книге тов. Ибрагимова совершенно отсутствует борьба направо...»*[66].

«Начальник III отделения сообщил в Обком партии о том, что «наибольшую популярность получила книга Г.Ибрагимова. Она развила национальные страсти интеллигенции и послужила объектом оживленных разговоров. Интеллигенция типа Галимджана Шарафа, Али Рахима, Садри Джаляла, И.Кулиева, М.Галеева и других высказала к ней положительное отношение, так же отнеслись бывшие правые татарские коммунисты М.Будайли, Ганеев, Борындыков, Г.Мансуров и др.»[67]. 1927 елның

февралендә булып узган киңәшмәдә бу мәсьәлә хакында егермедән артык татар коммунисты чыгыш ясый: Рәфыйков, Таһиров, Казаков, Атнагулов, Әлмөхәммәдов, Сәйфи, Борындыков, Мөслимов, Бәдәйли, Сәгыев, Хуҗиев, Насыйров, Толымбайский, Мөкминова, Гыйлемдаров, Рәхмәтуллин, Гомәров, Садриев, Солтанбек, Максудов, Мөхетдинов һ.б.

Нәкъ менә шушы елларда татар зыялыларының абруен төшерер өчен махсус сәясәткә юл салына. Хатаевичка җибәрелгән бер документта бу турыда: *«Необходимо по возможности устранить из руководящих постов лиц, вредящих нашей идеологии, вроде Шарафа Г., Биккулова Ибрагима, Норкина Загида, используя их лишь в техническом направлении»*[68]. ОГПУ башлыгы Кадушин да «милли интеллигенция» совет органнарында татарларның азчылыгында, Татарстан Республикасының автономиясен кимсетүдә, гомумән, татарларга каршы сәясәттә партиянең өлкә комитетын гаепләү барлыгын яшертен язмасында җаваплы секретарь Мендель Хатаевичка җиткерә[69].

Шул ук мәсьәлә 1927 елның 31 маенда өлкә комитеты бюросында тикшерелеп, анда шактый зур карар да кабул ителә. Бу юлы Г.Ибраһимов милли мәдәниятне мөстәкыйль мәдәният итеп карауда һәм аны югарыга күтәрүдә гаепләнә. Имеш, ул эшче сыйныфның ролен түбәнәйтеп, милли зыялыларның ролен өскә чөя. Г. Ибраһимовның брошюрасы бары тик партия хезмәткәрләренең хаталарына гына суга һәм нәтиҗәдә аны буржуаз милләтчеләр үз итәләр, имеш. Карарның дүртенче һәм бишенче пунктларын тулы килеш китерәбез, чөнки алар хәлнең нинди куркыныч төс алганын яхшы күрсәтә: *«Недопустимые приемы партийной дискуссии, выразившиеся в сравнении ряда партийных и честных советски настроенных беспартийных работников с мурзами, царскими чиновниками, проводниками насильственной обрусительной политики, воспоминание о которой в широких трудящихся массах татар вызывает чувство отвращения. Поскольку этот тон господствует во всей брошюре, естественно, что он не только мог сочувствовать уяснению вопроса ошибавшимся товарищам, но и вызвал обострение дискуссии, углубление разногласий и некоторые признаки опасности перенесения старых группировочных споров в новую плоскость борьбы по вопросам идеологического характера.*

Ввиду этих обстоятельств, ОК считает необходимым высказать свое отрицательное отношение к брошюре Г.Ибрагимова... Вместе с тем ОК считает, что дальнейшее продолжение дискуссии в той плоскости, в которой она протекала (куда идет татарская культура?), является нерациональной затратой партийной энергии и отвлечения внимания партийной организации от более актуальных задач, вызываемых политической и хозяйственной обстановкой».

Бу «тайпылыштан» арынып, советларча гына мәдәниятне үстерү хакында кайбер сүзләр булса да, аларның бары тик И.Сталин формуласына гына буйсынырга тиешлеге туры итеп әйтелгән: *«Вся установка в вопросе о национальной культуре укладывается в формулу тов. Сталина о том, что эта культура должна быть пролетарской по содержанию, национальной по форме»*[70].

С. Атнагулов, киресенчә, татар мәдәниятен ассимиляция юлына кертеп җибәреп, аны рус культурасы белән кушылдыру карашында тора. Ул, шулай итеп, «суллар» карашын яклый. Әйтергә кирәк, өлкә комитеты үзенең җыелыш-утырышларында аларның икесен дә тәнкыйть итә, әмма «уңнар»га, кагыйдә буларак, катырак сугыла, аларны еш кына буржуаз милләтчеләр белән бер итеп карыйлар. Күрәсең, бу «уңнар» һәм милли зыялыларның мәсьәләне тирәннән аңлап эш иткәннәрен аңлата. Алар, бер таякның ике башыннан тотып, уртага килеп очрашалар. Бу — табигый процесс. Алар икесе дә, «суллар»дан аерылып, көннән-көн үсеп барган бөекдержавачылык шовинизмы белән дә актив көрәшәләр.

1927 елның 14 июнендә партия өлкә комитетының карары белән Г.Ибраһимовка шелтә белдерелә. Аның татар халкының үз мәдәнияте үсәргә тиеш дигән тезисы тәнкыйть ителә. Имеш, ул социалистик мәдәният социализм төзүгә булышлык итә алмый дип бара. Шулай итеп, бу елларда табигый рәвештә «уң» булып хәрәкәт иткән Г.Ибраһимов та ут астында кала. Махсус органнар да тик ятмый: эзәрлекләү, җитешсезлекләр эзләү, провокацияләр дәвам итә. Хәтта аның шәхси тормышына да тыкшыналар.

1928 елның гыйнвар аенда Татарстан чекистларына, Д.Кандыбин исеменә килгән хәбәрдә *«Г.Ибраһимовның юбилеена әзерлек бара һәм бу юбилейны милләтчеләр тантанасына әйләндермәсеннәр, латинлаштыруга каршы комачауламасыннар»* диелә. Чыннан да, ул елның ноябрь аенда ук өлкә комитеты хәтта махсус юбилей уздыру буенча бер комиссия төзегән була. Анда мәгариф халык комиссары Нәсих Мөхетдинов (рәис), Шәриф Камал, Фәтхи Бурнаш, Галимҗан Нигъмәти, Сафа Борһан кертелә. Мәскәүдән мәгариф халык комиссары А.В.Луначарский да *«бу бәйрәмне юбилей итеп түгел, ә бары тик язучылар кичәсе итеп уздырыгыз»* дигән хәбәр җибәрә. Әмма хакимият органнарының ниятләре җимерелә. Юбилей зур тантана белән бөтен Русиядә билгеләнеп уза, Г.Ибраһимовка хәтта Хезмәт Герое дәрәҗәсе дә бирелә. Моңа да карамастан язучының хәле көннән-көн авырая бара. Провокацияләр, эләкләү, шымчылык дәвам итә[71].

ГПУның татар бүлеге башлыгы Кадушин ВКП(б) өлкә комитеты сәркатибе Хатаевичка «бик тә яшертен», «фәкать Хатаевичның үзенә генә» дигән хат юллый. Анда татарлар арасында милләтчелекнең көчәюе, бу тенденциянең Ф.Әмирхан,

Н.Хәким кебек язучыларның китапларын бастырып чыгарырга омтылышта сизелүе, аеруча бертуган Шәрәфләрнең халыкка тәэсире зур булуы, татар зыялылары белән динчеләр арасындагы гади мулладан алып мөфти Р. Фәхретдиновка кадәр — элемтәнең бертуган Шәрәфләр аша алып барылуы әйтелә. Бер уңайдан «Кызыл Татарстан» гәзите дә гаепләнә: янәсе, ул буржуаз шагыйрь Габдулла Тукаевка һәйкәл кую кирәклеген күрсәтә.

Татар интеллигенциясенең хәле «82 ләр хаты» белән дә катлауланып китә. Монда әлифба алыштыру мәсьәләсе турында бер төркем партиясез зыялылар И.Сталинга хат юллый. Тиздән ВКП(б) өлкә комитетының да карары кабул ителә. Анда мондый юллар бар: *«1. Төрки әлифбадан латин хәрефләренә күчүнең асылы буенча мәсьәлә хәл ителгән дип санарга, һәм бу хакта бәхәс кузгатмаска. 2. Бу мөрәҗәгатьнең язылуы ВКП(б)га каршы юнәлтелгәне буржуаз милләтчел элементларның активлашуын күрсәтә. 3. Өлкә комитеты бюросына бу факттан тиешле нәтиҗәләр ясарга, кирәкле дип табылган иҗтимагый-оештыру чараларын күрергә һәм аңлату эшләрен үткәрергә кушарга»*[72]. Тиздән «аңлату эшләре», эзәрлекләү, кулга алулар башлана. Ачык җыелышларда тәүбә итүгә, имзалардан баш тартуга керешәләр. Татар коммунистлары һәм партиясезләр — барысы да бик авыр хәлдә калып, Үзәкнең сәясәтен тормышка ашырырга мәҗбүр булып, әкрен генә бер якка «тайпылу»га әзерләнәләр.

1937 елның 31 мартында тоткын М.Сәгыйдуллин үзенең «уңнар» хакындагы күрсәтмәсендә: *«Правые в ходе своей борьбы с партией и политикой Советской власти в последующие годы не раз искали пути сближения с левыми, заключили блоки по отдельным вопросам, а в конечном счете стали параллельно действующими отрядами контрреволюции»*, — дип шаһадәтнамә бирә[73].

Менә шулай итеп, «милли тайпылыш», «буржуаз милләтчеләр» белән киләчәктә бергә кушылганнан соң көрәш тагын да югарырак баскычка күтәрелеп китә. «Милләтчеләр», «уңнар» һәм «суллар» хакында хөкем карарлары бер-бер артлы кабул ителеп тора. Мондый сәясәт Татарстанда гына түгел, ә бәлки бөтен СССРда уздырыла. «Дошман» эзләү, аны «фаш итү» кагыйдәгә әверелә.

СССРның җимерелүе, бик тиз юкка чыгуы икътисади яисә иҗтимагый-сәяси сәбәпләр аркасында түгел, ә бәлки илдә дөрес, гадел милли сәясәтнең булмаганлыгыннан килә. Бүген дә Русиядә көчле дәүләтчелек өлкәсендә зур эш алып барыла. Бу дәүләтчелек тә, әгәр милли мәсьәләне алга куеп, дөрес сәясәт алып барылмаса, җимереләчәк. Бу аның өчен сызлаган теш кебек. Милли мәсьәләгә мөнәсәбәтеннән аның нинди хакимият икәнлеге күренеп тора.

Бары тик ирекле, инициативага ия булган, иҗади рухлы халык кына гадел дәүләтчелек төзи һәм күпчелек мәсьәләләрне

хәл итә ала. Халык иҗаты — фәкать берүзе кризистан чыгу чарасыдыр, бай илне бөлгенлектән коткару юлыдыр. ***Татарстан дигән дөньякүләм феномен — моңа тагын бер дәлил.***

Узган гасырның 90 нчы елларында халыкның тормыш-көнкүреше, иҗтимагый-сәяси мохитендә беркадәр иреккә ирешү ихтималына ирешкән Татарстан җөмһүрияте тиз арада бөтен Русиядә һәм дөньяда танылып өлгерде. ***Моның төп нигезе Республикабыз Президенты М.Ш.Шәймиев җитәкчелегендәге хакимиятнең, үз төбәге үзенчәлекләрен искә алып, иң беренче нәүбәттә торган милли мәсьәләне хәл итү аркасында гына икътисад, иҗтимагый-сәяси проблемалар да дөрес, хакыйкый хәл ителде.***

Республикада барча төбәкләргә үрнәк булырдай урталыктагы, иминлектәге бар нәрсә дә уңай икән, монда, һичшиксез, халкыбызның һәм Президент М.Шәймиевнең өлеше зур.

Татарстан бәйсезлегенең 20 нче еллардагы беренче адымнарыннан соң дәвам иткән, дәвам ителә торган һәрбер маягы бөтен дөньяга мәгълүм инде. Моны кем инкарь итә ала? Итсеннәр соң!

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] *Солтангалиев М.* Сайланма әсәрләр. — Казан, 1998. — 285 б.
[2] Шунда ук. — 286 б.
[3] Шунда ук. — 287 б.
[4] Образование Татарской АССР. — Казань, 1963. — С. 246.
[5] *Солтангалиев М.* Сайланма әсәрләре. — Казан, 1998. — 288 б.
[6] *Султанбеков Б.* С грифом «Совершенно секретно»: Драматические страницы истории Татарстана. — Казань, 1993. — С. 4—12; Выстрел у Лядского сада. Версия // Эхо веков (Гасырлар авазы). — 1995. — № пробный. — С. 107—111, 285, 445.
[7] Шунда ук. — 293 б.
[8] *Султанбеков Б., Малышева С.* Трагические судьбы. — Казань, 1996. — С. 194—195.
[9] Шунда ук. — 196 б.
[10] Шунда ук. — 199 б.
[11] Шунда ук. — 202—203 б.
[12] *Фаттахова Г., Валеев Р.* Академический центр Татарии в 1920 годы. — Казан, 2002.
[13] Шунда ук. — 17 б.
[14] ЦГАИПДРТ. — Ф. 15. — Оп.1. — Ед.хр. 962. — С.73.
[15] НАРТ. — Ф. 732. — Оп. 1. — Ед.хр. 475. — С. 13—15.
[16] *Солтангалиев М.* Сайланма әсәрләр. — Казан, 1998. — 378 б.
[17] Шунда ук. — 409 б.
[18] Шунда ук. — 435 б.
[19] Шунда ук. — 436 б.
[20] *Солтангалиев М.* Сайланма әсәрләр. — Казан, 1998. — 438 б.
[21] Тайны национальной политики РСДРП. Стенографический отчет секретного IV Совещания ЦКРКП. — М.: Инсан, 1922. — С. 60.
[22] Шунда ук.
[23] Шунда ук. — 225 б.
[24] ЦГАИПДРТ. — Ф.15. — Оп. 1. — Д. 857. — С.4.
[25] Шунда ук. — 11 б.

[26] Шунда ук. — 122 б.
[27] Шунда ук. — 222 б.
[28] Шунда ук.
[29] *Султанбеков Б.* Письмо обреченных // Эхо веков (Гасырлар авазы). — 1996. — № 3/4 — С. 63.
[30] ЦГАИПДРТ — Ф. 15. — Оп. 1. — Ед. хр. 1098.
[31] Шунда ук. — 168 б.
[32] *Султанбеков Б.* Письмо обреченных // Эхо веков (Гасырлар авазы). — 1996. — № 3/4. — С. 98.
[33] Татарстан Республикасы Милли архивы, Р. Мохтаровның шәхси эше.
[34] *Литвин А.* Запрет на жизнь. — Казань, 1993. — С. 77.
[35] *Солтанбеков Б.* Письмо обреченных // Эхо веков (Гасырлар авазы). — 1996. — № 3/4. — С. 64.
[36] ЦГАИПДРТ К.Мохтаровның шәхси архивы. (нөсхәсе миндә. — *Р.В.*)
[37] Шунда ук.
[38] Шунда ук.
[39] ЦГАИПДРТ. — Ф. 15. — Оп. 2. — Ед. хр. 316. — Л. 62.
[40] Шунда ук. — 140 б.
[41] Шунда ук. — 19 б.
[42] ЦГАИПДРТ. — Ф. 15. — Оп. 2. — Ед. хр. 67. — С.10.
[43] *Султанбеков Б., Малышева С.* Трагические судьбы. — Казань, 1996. — С.210.
[44] ЦГАИПДРТ. — Д. 672. — Оп. 2. — С.12.
[45] Шунда ук.
[46] Шунда ук. — 26 б.
[47] ЦГАИПДРТ. — Ф. 15. — Оп. 1. — Ед.хр. 844. — С.15.
[48] ЦГАИПДРТ. — Ф. 15. — Оп. 2. — Ед. хр. 292. — С. 37—38.
[49] Шунда ук. — 44 — 47 б.
[50] ЦГАИПДРТ. — Ф. 15. — Оп. 1. — Ед. хр. 299. — С. 73—74.
[51] Шунда ук. — Ед. хр. 494. — С. 45.
[52] ЦГАИПДРТ. — Ф. 15. — Оп. 2. — Ед. хр. 292.
[53] Шунда ук. — 43 б.
[54] Шунда ук.
[55] ЦГАИПДРТ. — Ф.15. — Ед. хр. 268. — С. 96—99.
[56] Шунда ук. — 103 б.
[57] Шунда ук. — 115 б.
[58] Шунда ук. — 116 б.
[59] *Сәгыйдуллин М.* Ялагай Куштановлар кабиләсе // Кызыл Татарстан. — 1929. — 10 авг.
[60] *Солтангалиев М.* Сайланма әсәрләр. — Казан, 1998. — 439 — 440 б.
[61] Шунда ук. — 126 б.
[62] ЦГАИПДРТ. — Ф.15. — Оп 2. — Ед. хр. 292.
[63] ЦГАИПДРТ. К.Мохтаровның шәхси эше.
[64] *Вәлиев Р.* Фаҗига. — Казан, 1996.
[65] *Литвин А.* Запрет на жизнь. — Казань, 1993. — С. 114.
[66] ЦГАИПДРТ. — Ф.15. — Оп.1. — Ед. хр. 494. — С. 26—27.
[67] ЦГАИПДРТ. — Ф. 15. — Оп. 2. — Ед. хр. 344. — С. 84.
[68] ЦГАИПДРТ. — Ф. 15. — Оп. 2. — Ед. хр. 290. — Л. 86.
[69] Шунда ук. — 137 б.
[70] ЦГАИПДРТ. — Ф.15. — Оп.2. — Ед. хр. 267. — С. 89.
[71] *Литвин А.* Запрет на жизнь. — Казань, 1993. — С.116—117.
[72] *Вәлиев Р.* Фаҗига. — 36 б.
[73] ЦГАИПДРТ. — Арх. 2-7090. — Д. 15745. — С. 104.

ТУРЫ СҮЗЛЕ, БАШ БИРМӘС ШӘХЕС

1965 елда Казан дәүләт университетына аспирантурага кергәч, партия тарихы кафедрасы җитәкчесе профессор Рәфикъ Измайлович Нәфыйгов, мине үзенә чакырып:

— Сезнең тема буенча бездә бер генә кеше эшли, ул Әгъдәс Хөсәенович Борһанов, — диде.

Шуннан соң мин булачак җитәкчемне эзләп таптым. Ул Казанның Горький урамында Татар дәүләт академия театры янындагы йортта яши иде. Беренче очрашуыбыз аның фатирында шактый рәсми төстә узды, әллә ни озакка да сузылмады. Минем өчен иң мөһиме — җитәкчелек итәргә аның ризалыгын алдым.

Безнең алга таба фәнни эшчәнлегебез-хезмәттәшлегебез ул Мәскәүгә киткәнгә кадәр бергә барды. Хәер, ул Мәскәүдә яшәгәндә дә бер-беребезнең хәл-әхвәлен белешеп, сирәк булса да очрашып торабыз. Әйтергә кирәк, хәзер мин үзем дә аспирантлар белән җитәкчелек итәм һәм бу эштә остазымның карашларына таянам. Алар шуннан гыйбарәт: кыюлык, дөреслек, намусыңа хыянәт итмәү.

Хакыйкать, намус дигәннән, аның белән булган бер сөйләшү колагымда яңгырый кебек. 1966 елның октябрь ае. Борһановның докторлык диссертациясен якларга әзерләнеп йөргән көннәре иде. Диссертация темасы — «Октябрь революциясе һәм вак буржуаз партияләр. 1917 ел, март—ноябрь айлары». Зур күләмле, саллы хезмәт. Һәрберсе 600 битлек 2 томлык бу хезмәтнең кайбер битләрендә саннар-даталарны ачыклауда аңа булышырга алындым. Бу эш белән шактый утырдык без. Диссертациянең тарихи хезмәтләргә күзәтү-анализ бүлегендә Ә.Борһанов Мәскәү тарихчылары — Иҗтимагый фәннәр академиясе кафедрасы мөдире И.Ф.Петровны, КПСС Үзәк Комитетының бүлек мөдире С.П.Трапезниковны һәм шулай ук П.Н.Соболев, Д.Коваленко кебек галимнәрне, әлбәттә, И.Сталинны да шактый нык тәнкыйть иткән иде.

Бераз шүрләп:

— Әгъдәс Хөсәенович, болай ук тәнкыйтьләгәч, сезнең эшегезне расламаулары мөмкин бит, — дип әйткәнемне сизми дә калдым. (Хәер, шөбһәләнеп әйткән сүзләрем, кызганыч ки, рас килде. Чыннан да, аның эшен 25 ел дәвамында Югары аттестация комиссиясе (ВАК) расламый тинтерәтте.)

Әмма фәнни җитәкчем, бераз уйланып:

— Юк, үзгәртмим, язылганча калдырачакмын, — диде.

— Нигә инде алай үзегезне удар астына куясыз? — дип сорадым.

— Башкача эшләргә минем фәнни намусым кушмый, — дип сүзен тәгәлләде Әгъдәс Хөсәенович.

Әйтергә кирәк, аның кайберәүләр тарафыннан гади үҗәтлек дип бәяләнгән фәнни намуслылыгы диссертациясен яклау вакытында да һәм тагын 25 елга сузылган көрәшендә дә ачык расланды.

Дөрес, аның диссертациясе университет гыйльми советында зур алкышлар белән якланды. Әмма шуннан соң ул шактый гыйбрәтле хәлләргә сәбәп булды. Өнәмәүчелек җиле аның диссертациясе язмышын хәл итү белән генә чикләнмәде, Ә.Х.Борһановның аспирантларына да кагылып узды. Аны без 1967 елның сентябрендә үк сизә башладык. Аз гына алданрак яклаганлыктан, минем диссертациям андый каһәрләнүгә эләкми калды. Ә инде М.А.Мөлеков, М.Х.Хәйдәров, В.Н.Николаевка кыенга туры килде. Алар Казанда яклаган кандидатлык диссертацияләрен раслату өчен ике ел Мәскәү юлын таптадылар. ВАКка барып, һәркайсы диссертациясен тагын бер тапкыр якларга мәҗбүр булды. Безнең фәнни җитәкчебездән намуслылыгы өчен менә шулай үч ала башладылар...

Тиздән «Коммунист» журналында җимергеч мәкалә пәйда булды. Конкрет атап әйтмәсәләр дә, «кайбер» галимнәргә «троцкист» һәм башка ярлыклар тага башладылар. Шәхес культы шаукымы кабат уяна, баш калкыта башлады. Күп тарихчылар тындылар, көтеп тору позициясенә күчтеләр... Әмма Әгъдәс Хөсәенович, чын галим буларак, фәнни эзләнүләрен туктатмады, яңа аспирантлар туплады (ул барысы 10 фән кандидаты әзерләде, шулардан икесе инде фән докторы, өчесенең докторлык диссертациясе әзер), студентлар аның артыннан көтү-көтү булып йөри, аның лекцияләре тирән эчтәлекле һәм кыю фикерләргә бай була иде.

ВАК шулай ук үз эше белән мәшгуль: фәнни этиканың иң гади нормаларын да бозып, Ә.Борһановның диссертациясен рецензияләү өчен ул тәнкыйтьләгән галимнәргә тапшыра! Алардан фикер туплау-җыю өчен 16 ай вакыт кирәк була. Большевиклар революция вакытында үзләренә якын торган вак буржуаз партияләр белән хезмәттәшлек итәргә мөмкин иде дигән ленинчыл положение катып калган сталинчы тарихчыларга ошамый. Үзгәртеп кору чорында Ә.Борһанов бу хакта «Вопросы истории» журналында болай дип язды: *«Рецензентлар тәнкыйтенең бөтен пафосы хезмәтемдәге шәхес культына каршы ориентациягә юнәлдерелгән иде. Алар Сталинның төп ударны демократик партияләргә юнәлдерүен кагылгысыз итеп калдырырга теләделәр»*. «Озакка сузылган эш» дигән бу мәкаләсендә ул үз хезмәтенә карата гаделсез тәнкыйтьне тулысынча кире кага.

Хәер, ул аны 1967 елда ВАКның эксперт комиссиясендә дә кире кагучы, ВАКның ул вакыттагы рәисе В.П.Елютинга диссертациясен ВАК пленумында карауны сорап мөрәҗәгать иткән. В.П.Елютин, аны кабул итеп: *«Диссертациягез Казан университеты ректорына кире соратып алырга тәкъдим ителде»,* — дип белдергән. Иҗтимагый Фәннәр академиясе галимнәренең аңа каршы кампания оештырулары уңаеннан Ә.Борһанов Брежневка да мөрәҗәгать итә. Моның нинди файдасы булды дисезме? Шул ук 1967 елда басарга дип кул куелган монографиясенең наборы таратыла. Университет нәшриятында Әгъдәс Хөсәенович үтенече белән бу китапның корректурасын берничә көн үзем укыдым. Ул үз заманы өчен бик кызык һәм хәтәр язма иде. Сталинга, Троцкийга кагылышлы урыннары һич тә гадәттәгечә түгел, тәнкыйть күзлегеннән чыгып яңача язылган иде. Большевикларга, меньшевикларга карата фикер үзгә иде. Авылдагы крестьян инкыйлабы да коммунистлар һәм Сталин язганча түгел, ә Ленин язганчарак иде. Кыскача гына әйткәндә, авылда инкыйлаб 1917 елда түгел, ә бары тик 1918 елда гына булды, диелгән иде.

Университетның ректоры М.Нужин чын галим-профессор иде. Ул тыныч, сабыр холыклы. Ул һәркемне дикъкать белән тыңлый, кулыннан килгәнчә булышырга әзер тора, күп вакытта бәлагә тарыган галимнәрне коткарырга көчен, вакытын кызганмый иде. Аның Ә.Борһановка мөнәсәбәте дә шулайрак булды. Ул аның белән даими аралашып торды. Әлбәттә, моңа Ә.Борһановның берара партиянең өлкә комитетында вузлар бүлеге мөдире булып эшләве дә тәэсир иткәндер. Фикер ияләре буларак, алар икесе дә партиянең тар кануннары белән бик үк санашмаска тырыштылар. Докторлык диссертациясен яклау алдыннан ректор Ә.Борһановка журналистлар кафедрасының мөдире урынын тәкъдим итә, әмма Борһанов моннан баш тарта.

Кайбер көннәрне алар сәгатьләр буена фикер алышып утыралар. Коммунистлар партиясенең тарих кафедрасы доцентының башкалардан аерылып торган фикерләре ректор өчен, әлбәттә, кызыклы була. Математика галиме М.Нужин Ә.Борһановның яңача карашларын тиз шәйләп ала. Шулай бер сөйләшеп утырганда ректор аңа:

— Әгъдәс Хөсәенович, лекцияләрегезне бик иркен укыйсыз, артык кыю фикерләр ычкындырасыз, дип сөйлиләр. Сөйләгәннәрегезне язып алып, тиешле оешмаларга да җиткерәләр икән, — ди.

Әгъдәс Борһанов болай җавап бирә:

— Мин Советка каршы сүз сөйләмим, бары тик партияне һәм социализмны ленинча яхшыртырга гына телим.

Бу чорда Ә.Борһанов аларны яхшыртып булмаячагын аңлау дәрәҗәсенә җитмәгән була әле. Ул моны соңрак аңлаячак. Бу үзсүзле татар доцентының кыю җавабын тыңлап утырган ректор, тагын да җитдирәк төс белән:

Шуны көннәрдә генә миңа өлкә комитеты секретаре янында булырга туры килде, — дип сүзен дәвам итә. Үзсүзле татар егетен тикшергән сымак, тукталып калып, әйтер сүзен әйтми тора да кырт итеп:

— Сез ул троцкист Борһановны кайчан эштән куарсыз? — дип сорады секретарь.

Ректор, гадәтенчә тамак төбен кыра-кыра, коры йөткерү белән йөткереп ала. Дулкынланганда йөткереп җәфалана иде мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын.

— Ә сез нәрсә дип җавап бирдегез соң? — дип сорау бирә Борһанов, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән.

— Минме? — дип, аның сүзен бүлә Нужин. Ул, кесәсеннән кулъяулыгы алып, маңгаен, битен сөрткәләп, тагын йөткергәләп куя. — «Сез үзегез куалагыз, ул бит сезнең кадр!» дидем мин аңа.

Икесе дә сүзсез тынып калалар. Тынлыкны тагын ректор боза:

— Мин аңа әйттем: «Без аны бер мәртәбә срогы җитми торып сайлау уздыру юлы белән 1964 елны эшеннән куган идек — барып чыкмады. Лекцияләрендә, укыту эшләрендә җитешсезлекләре булмаганлыктан, Мәскәү яңадан кайтарды», — дидем.

Өлкә комитеты җитәкчеләре, Ә.Борһановны болай да җиңә алмагач, соңрак башка институтларга «ычкындыру» турында уйлана башлыйлар. Башта аны финанс-икътисад институтына күчермәкче булып маташалар, әмма андагы кафедра хуҗасы: *«Без аны ала алмыйбыз, чөнки коллектив каршы»*, — ди. Консерватория ректоры Нәҗип Җиһанов: *«Без дә ала алмыйбыз, безнең уку йорты иҗади, махсус вуз»*, — дип кире кага.

1968 елда КПСС Үзәк Комитетының фән бүлеге мөдире С.П.Трапезников «Борһанов эше» белән үзе җиң сызганып шөгыльләнә башлый. Бу турыда Ә.Борһанов болай сөйли: *«1968 елның ахырында КПСС ҮК фән бүлеге мөдире С.П.Трапезников Ә.Х.Борһановның докторлык диссертациясенә багышланган киңәшмә үткәрде. Киңәшмәдә академик И.И.Минц, СССР Фәннәр академиясенең тарих бүлеге академик-сәркатибе Е.М.Жуков, КПСС ҮКның фән бүлеге секторы мөдире В.Т.Долгих, СССР Фәннәр академиясенең СССР тарихы институты парткомы сәркатибе П.В.Волобуев, диссертациянең оппоненты профессор Ф.Т.Константинов катнашты. Күрдегезме, нинди тузлар! Һәм... мин бер «кечкенә шөреп», диссертант Ә.Борһанов... Трапезников башта Константинов, Минц һәм Волобуев фикерләрен тыңлады. Иң сәере шул: болар һәр өчесе Ә.Х.Борһановның диссертациясенә КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясенең кайбер профессорлары гадел булмаган тәнкыйть белән чыкканнар, шуның аркасында Ә.Х.Борһановның фән докторы дәрәҗәсе алуы ВАКта тоткарлана, дип сөйләде.*

Шуннан соң Трапезников минем диссертациянең ВАК аша үтүен үзе тикшерәчәген әйтте һәм минем... киңәшмәдән чы-

гып китүемне үтенде. Мин чыктым, киңәшмә тагын бер ярты сәгать дәвам итте шикелле. Соңыннан Константинов белән Волобуев миңа сөйләделәр: Трапезников, бу Борһановка башта докторлыгын якларга кирәк булган, аннары инде бүтән галимнәрне тәнкыйтьь итсә дә ярар иде, дигәнрәк фикер әйткән икән».

Бу урында шуны да өстәп куярга кирәк: Ә.Борһановның диссертациясендә С.П.Трапезниковның икетомлык хезмәтенә дә «эләгә». Октябрь инкыйлабы чорындагы аграр мәсьәләләрне сталинчыл карашлардан торып бәяләгән хезмәт була ул. Әлбәттә, Ә.Борһанов аны «сүтеп» ташлый.

КПСС ҮКның фән бүлегендә гаделлек эзләүче галимгә менә шулай «ярдәм» итәләр.

Бу авыр чорда без Әгъдәс Хөсәенович белән тагын да якыная төштек. Һәр кич очрашып, бәхәсләшә, мәсьәләләрне уртаклаша идек. Өстәвенә бер үк вакытта икебезнең дә хатыннарыбыз авырып китте. Тиздән Әгъдәс Хөсәеновичның хатыны вафат булды. Бәла дигән нәрсә кешегә бер килсә, бер-бер артлы килә икән ул...

— 70 нче еллар азагында, — дип искә ала Әгъдәс Хөсәенович, —диссертациядәге аеруча бәхәсле дип саналган мәсьәләләр теге яки бу формада расланганнан соң, фәнни хезмәтемне яңадан карауларын үтенеп, кабат ВАКка мөрәҗәгать иттем. ВАК диссертацияне яклау материалларын Казаннан соратып караган иде, аларны таба алмадылар. Шуннан соң КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Партия контроле комиссиясенә апелляция бирдем. Яклау материаллары «табылды», ул КПССның Татарстан өлкә комитеты секретарьларының берсенең өстәл тартмасында яткан. Аны ВАКка җибәрделәр, тик диссертация үзе «югалган» булып чыкты. Шунлыктан ВАК аны яңадан карау мөмкин түгел дип тапты.

Ниһаять, Әгъдәс Борһанов көткән чор җитә.

1988 ел. СССР Фәннәр академиясенең фәнни советы Октябрь инкыйлабының комплекслы проблемаларын өйрәнү буенча мәсьәлә күтәрә. Бераз соңрак Мәскәү тарих-архив институты белән Казан университеты гыйльми советлары да бу мәсьәләне кузгата. Бу юлы университетның бер бүлегендә «Для служебного пользования» дигән гриф белән «ябылып» яткан диссертация дә «табыла». Әйе, Ә.Борһанов диссертациясе.

1998 ел. Безнең гыйльми советтан Ә.Борһановның үзе һәм аның хезмәтләренә карата фикеребезне белдерүне сорадылар. Бу, әлбәттә, табигый хәл иде, чөнки ул диссертациясен бездә яклаган, байтак еллар бездә эшләгән, безнең кеше иде. 1998 елның 23 февралендә тарих факультеты гыйльми советы утырышында бу мәсьәләне карадык. Анда профессорлардан И.Р.Таһиров, Г.Н.Вульфсон, А.Л.Литвин, доцентлар Р.К.Вәлиев, Р.А.Шәйхиевләр чыгыш ясап, бертавыштан Борһановның «Бөек Октябрь революциясе һәм вак буржуаз партияләр» дигән докторлык дис-

сертациясе өчен аңа докторлык дәрәҗәсе бирү турындагы мәсьәләне Югары аттестация комиссиясе (ВАК) алдына яңадан куярга дигән фикергә килделәр. Шундый ук карар да кабул ителде. Бу карарны университет гыйльми советы да хуплады.

Ниһаять, Әгъдәс Хөсәенович Борһанов — тарих фәннәре доктоы! Җитмеш яшен тутырган көннәрдә аны Мәскәү тарих-архив институтында профессор итеп тә сайладылар.

Хәзер Әгъдәс Борһанов Мәскәүдә яши. Бер уйласаң, кызык бит: ни өчендер үз төбәгендә кыерсытылганнарга шул Мәскәүдә урын табыла. Әлбәттә, Ә.Борһановны Мәскәү махсус чакыртып алмады. Ул анда үзе китәргә мәҗбүр булды. «Телен тыя алмаган» яисә уйлаганын әйтергә батырчылыгы җиткән галим, үз Казанында тынычлык таба алмагач, ни эшләсен?!

Бу аның өчен бик авыр вакытлар иде. Хәләл җефетенең вафат булуы аның хәсрәтләрен тагы да арттырды. Мин укытучымның фатирыннан ерак тормый идем. Әгъдәс Хөсәенович һәр кич диярлек безнең тулай торакка килеп керә дә:

— Исәнмесез, Люция ханым! — дип елмаеп, хатыным белән озаклап сөйләшеп утыра иде.

Соңыннан, икәү генә калгач:

— Рәмзи, ай-һай акыллы хатының! — дип мактап та куя.

Мин аңа үзем ясаган эчемлекне тәкъдим итәм. Ул аз гына эчә.

— Әйдә, бакчага киттек, — ди.

Без өчәү Горький бакчасына барып һава сулыйбыз. Туктап-туктап һавадагы йолдызларны саныйбыз, сөйләшәбез, хыялланабыз. Әйтерсең лә берни булмаган... Әгъдәс Хөсәенович һәрвакыт тыныч йөзле, уяу фикерле булып калды. Бервакытта да зарланмады. Эче пошкан көннәрендә Фукс бакчасы янындагы чаңгы базасыннан Дәрвишләр бистәсенә кадәр чаңгыда йөреп кайта да:

— Менә, Дербоградка барып килдем әле, — ди. Үзенең бите алмадай кызыл, аркасы тирләгән...

Озакламый Ә.Борһанов Мәскәүдәге Гражданнар авиациясе институтына эшкә урнашты.

Монда эшкә урнашу да Казандагы кебегрәк каршылыклар белән бара. Ул үзе бу турыда, шаяртып:

— Казан мескеннәрен миңа эш табудан коткарырга булдым, жәлләдем, кызгандым үзләрен, — дип сөйли.

Мәскәүгә барып төшкәч тә институттан институтка йөгерә остазыбыз. Вакыт тиз уза, кесәсенең сайлыгын да искә алсаң, безнең галимебез бөтенләй авыр хәлдә кала. Бар ышаныч дусишләр, фикердәшләр, танышларда. Ә.Борһановны ул вакытта ук күпләр белә иде инде. 1999 елның март аенда Әгъдәс Хөсәенович Казан санаториенда ял иткән көннәрдә мин аннан Мәскәүгә китүе турында сөйләвен үтенгәч, ул:

— Ярый, мин сиңа язып бирермен, — диде.

Тиздән без аның белән минем эш урынымда, тарих факультетының декан кабинетында очраштык. Ул кызыклы гына язма алып килгән иде. Текст урысча язылган, без аны татарча китерәбез.

«...1973 елны мин Мәскәүгә китеп бардым.

Табигый ки, бөтенләй күченеп китәргә җыенганчы, иң әүвәл эш табарга кирәк иде. КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбенең читтән торып уку бүлегендә дустым В.Н. эшли иде. Ул кафедра мөдире белән мине эшкә алу турында сөйләште. Моны КПСС ҮКның фән бүлеге ризалыгы белән эшләргә кирәк булды. Мин, шундагы танышыма, оештыру бүлеге мөдиренең беренче урынбасары Н.К. га мөрәҗәгать итеп, аның Югары партия мәктәбенә шылтыратып алуын үтендем. Ул исә миңа болай дип җавап бирде: «Кадерле Әгъдәс Хөсәенович, син, безнең тәгълимат белән яраша алмаган хаталарыңны танып, бер мәртәбә дә матбугатта чыгыш ясамадың, төп коммунистик журнал булган «Коммунист» битләрендә сине тәнкыйть итеп чыккан күренекле галимнәребез фикере белән килешмәдең, инде хәзер Югары партия мәктәбендә эшләргә телисеңме? Синең оппортунист икәнеңне белмәгән берәр тынычрак пединститут яки техник вузда урын тап!»

Югары белем министрлыгында да танышларым бар иде, анда методика идарәсенә инспектор кирәк икән, мине шунда «кодаладылар». Бөтен кирәкле ишек-тишекләрне үттем, партком секретаре белән генә очрашасым калды, әмма ул авырый иде. Шулай да министрлык коллегиясендә мине эшкә раслау көне билгеләнде. Шунда килдем, партком секретаре да терелгән. Ул үзе башкорт, КПСС райкомы бюросының әгъзасы һәм алыштыргысыз партком секретаре икән, хәзер фамилиясен хәтерләмим инде. Коллегия утырышы алдыннан ул мине чакырып алды да: «Сез «Коммунист» журналы тәнкыйтьләгән Борһановмы?» — дип сорады. «Әйе, — дидем, — үзе». Аның башка сораулары юк иде. Коллегия утырышы булмый калды.

Шул ук таныш-белешләрем аннары мине Гражданнар авиациясе институтына тәкъдим иттеләр, кочак җәеп каршы алмасалар да, мин шунда эшли башладым».

1973 елны бу хәлләрне без белми идек шул. Ә.Борһановның Казанда калган шәкертләре М.Мөлеков, В.Бохараев белән без уңайсызлыклар сизсәк тә бирешмәдек, тавыш-тынсыз эшкә керештек.

Мин булачак докторлык диссертациямнең кулъязмасын 1976 елда университет нәшриятына тапшырдым, әмма ул анда дүрт ел ятты. Нәшриятның директоры Әскәр Хәйретдинов мине бик якын итә иде. Университетның комсомол комитетында үзем секретарь чагында ул идеология комиссиясенең җитәкчесе иде, ә университет бетергәч, нәшрият директоры булып китте. Монографиянең листажын да ул биргән иде. Тоткарлау мәсьәләсе аннан

тормады, киресенчә, ул булмаган булса, минем монографиям дөнья да күрмәгән булыр иде, бәлкем. Хезмәтем «Назревание общенационального кризиса и его проявление в Поволжье и на Урале в 1917 году» дип атала. Әлбәттә, ул елларда «кризис» сүзе хакимият башындагыларга һич ошамый иде. Бары тик 80 нче еллар ахырында гына бу мәсьәләләр актуаль булып китте, һәм мин, биш ел Мәскәү юлын таптаганнан соң, 1990 елда Екатеринбургта докторлык диссертациясен якладым. Менә шул вакытта тагын бер мәртәбә остазымны искә алдым, ә бит аның диссертациясен 25 ел буе расламадылар. Ничек түзгәнен Әгъдәс Хөсәенович үзе генә беләдер инде...

Шуны да әйтеп узарга кирәк: Ә.Борһанов диссертациясен сейфка салып куйгач, гәзит-журналларда аны тәнкыйтьләү башлангач, безнең факультет каршындагы докторлык диссертацияләрен яклау советын да яптылар. Эшләр авыраеганнан-авырая барды. 1980 елда язган хезмәтем 1990 елга кадәр портфелемдә йөрде. Хәтта «Рәмзидә кризис» кебек шаяртулар да булгалады. Чыннан да...

70 нче еллар азагында Бионика лабораториясендә уңышлы эшләп килгән хатыныма да уңайсызлыклар туа башлады. Физика факультеты деканы мәрхүм Поминов: *«Лаборатория җитәкчесе сезнең хатыныгыз өстеннән көн саен деканатка яза башлады»*, — дигән иде. Бу Люциянең кандидатлык диссертациясен яклап, докторлык диссертациясен эшләгән чаклары иде.

— Аның җитәкчесе белән ничек сөйләшергә соң? — дип сорадым.

— Иң яхшысы — бәйләнешмәскә... эштән китәргә кирәк... Ахыры начар булуы мөмкин, — диде декан.

Шулайрак булды да. Хатынымны, үзенә әйтми генә совет уздырып, эшеннән азат иттеләр. Ул шикаятьләр белән йөрмәде, мин дә киңәш итмәдем.

М.Нужин монда да безгә булышу юлларын эзләде. Ниһаять, хатынымны биология факультетына доцент итеп «Биофизика» курсын укырга чакырдылар. Бу инде аны аклау иде. Шулай итеп, «троцкист-оппортунист» Ә.Борһанов җилләре безне дә сыйпап узды. Кафедрабыз мөдире И.Ионенко хәлемне аңлады, артык борчымады. Дустым И.Таһиров һәр көн диярлек сораштырып торды. А.Литвин, Б.Солтанбеков, М.Мөлеков һәм башкалар рухи көч биреп, теләктәш булдылар. Ниһаять, 1990 елны китабым дөнья күрде. Әлбәттә, аңа чын күңелдән шатланган кеше Әгъдәс Хөсәенович Борһанов булды.

— Молодец, Рәмзи, булдыргансың! — диде ул.

Бу минем өчен барлык рецензияләрдән дә зур бәя иде инде. Шатландым.

— Эх! Сез монда булып, сезнең мәктәбегез тагын да үскән булса иде... — дидем.

Ул, елмаеп:

— Ерунда! Мәктәпсез дә әйбәт эшлисез бит, — диде. — Әнә Марат Мөлеков, Володя Бохараев эшли, Мурхан Хәйдәров... — дип санап китте. — Павел Васильевич Волобуев бик булыша, — диде ул. — Беләсең бит, ул — «Хлебная монополия» хезмәтен язган кеше. СССР тарихы институтының элекке директоры, академик...

Әйе, хәтерлим. Мин Мәскәү университетында аның янында булган идем. Ул анда Октябрь инкыйлабы темасына багышланган махсус курс укый иде. Лекциясе тәмамлангач, тәнәфес вакытында аның янына килеп:

— Павел Васильевич, исәнмесез! — дидем.

Ул, көрәк кебек кулын сузып:

— Сез каян, кем буласыз соң? — дип сорады.

— Мин Вәлиев Рәмзи, Әгъдәс Борһановның шәкерте. Казан университетыннан, — дигәч, көр тавыш белән, үз итебрәк:

— Ә-ә-ә, гафу итегез инде мине, теге вакытта сезнең авторефератыгызга отзыв җибәрә алмадым бит, — диде ул.

— Павел Васильевич, инде һәммәсе тәртиптә, ВАК минем эшне хуплады. Хәзер мин сездән булачак докторлык диссертациямнең консультанты булуыгызны сорарга килгән идем, — дидем.

— Мин риза, — диде Волобуев. Диссертациянең темасын да хуплады, ә аерылганда, кулын биреп: — Казанга киткәндә шылтыратыгыз, — диде.

Күпме вакыт узгандыр, хәтерләмим, П.Волобуевны эшеннән азат итеп, Табигать белеме институтына гади хезмәткәр итеп җибәрүләрен Ә.Борһанов аша белдем. Үзгәртеп кору елларына кадәр яңадан тавыш-тыны ишетелмәде. 1987 елда гына «Выбор путей общественного развития: теория, история, современность» дигән зур хезмәте дөнья күрде, һәм үзе дә яңадан Тарих институтында эшли башлады.

Хәзер инде ул вафат булды. Бу зур кайгы иде. Ул кешелекле кеше, зур галим иде. Ә.Х.Борһановка 70 яшь тулган көннәрнең берсендә академик П.В.Волобуев, шылтыратып:

— Әгъдәс Хөсәенович, сезнең докторлык диссертациясен раслау мәсьәләсен ВАКта яңадан кузгатсак, риза булырсызмы? — дип сорый ул.

— Риза, әйдә, бар гаделлек тантана итсен әле, — ди Ә.Борһанов. — Әмма үзем кыл да кыймылдатмыйм, туйдым.

— Безгә сезнең ризалыгыгыз гына кирәк, — ди академик Волобуев.

Менә шуннан соң боз кузгала — аклау процессы башлана.

1996 елны Ә.Борһановның «Кайлардан киләсең, кайларга барасың, Рәсәй?» дип аталган зур күләмле китабы дөнья күрде, ә 1998 елда ул татар телендә дә нәшер ителде. Бу китабында ул Октябрь инкыйлабыннан соңгы чордагы Россиянең хәле һәм аның киләчәге турында сүз алып бара.

Үз вакытында академик П.В.Волобуев, бу монографиягә бәя биреп: *«Аның яңа китабы Россиянең узганы һәм киләчәге турында тирән уйланулар нәтиҗәсендә туган. Ул Россиянең киләчәге өчен борчыла. Яңа китап — озак еллар дәвамында тормышта дөреслек эзләүнең нәтиҗәсе»*, — дип язган иде.

Ә.Борһанов орден-медальләр белән бүләкләнмәде, макталмады. Ул беркайчан да, беркем алдында да билен бөкмәде, башын имәде. Хәтта артык горуррак та булгандыр, дип әйтсәк тә ялгышмабыз.

Бу хезмәте барлык зыялылар тарафыннан да укылып, аңлашылып беткәндер, дип әйтү дөрес булмас. Әмма фикер алышулар булмады түгел, булды һәм дәвам итә.

Әйе, Ә.Борһанов үзен көчле фикер иясе, эзләнүче һәм тынгысыз галим, көрәшче итеп күрсәтте.

Аның «Үзәк һәрвакыт эгоист булды» (Комсомольская правда, 1992, 20 март), «Рус булмаган кешеләргә рус телендә сөйләшү мәҗбүри түгел» (Общая газета, 1993, № 19 (21), «Федерация милләтләр берлеге сыйфатында» (Утро России, 1995, № 17 (77), «Мин ни өчен татар?» (Идель, 1995, № 7 (8), «Россиядә татар диаспорасының киләчәге» (Панорама-форум, 1995, № 3), «Безне бөгү мөмкин түгел» (Татарские края, 1996, № 36 (37, 39, 40), «Европа Советына» (Татарские края, 1996, № 4), «К вопросу о национальной идее» (Татарские новости, 1997, № 7 (8, 41, 42), «Федерацияме? Юк ул!» (Идел, 1999, № 2). Үзгәртеп коруга багышланган «Борһанов публицистикасы» әле 90 нчы елда ук чит илдә дә дөнья күрде (*Burganov A.* Perestroika and the concert of Moscow. 1990).

«Татар халкының киләчәге нинди?» (Татарстан, 1999, № 12) дип аталган мәкаләсендә ул: *«...безгә, татар халкына, тарихи тупиктан чыгу юлын гамәлдәге системадан читтә эзләү зарур. Милләтнең үсешен, беренче чиратта аның икътисадының юнәлешен үзгәртергә кирәк»*, — дип яза. Татар халкы бу эшне бары тик үз көченә генә таянып эшләргә тиешлеген әйтә. Россиянең бу эшне эшләргә теләге дә, икътисади хәле дә юк. Цезарь сүзләрен үзгәртеп әйтсәк, үз-үзенә булыша алмаган Россия ничек итеп татар халкына булышсын? Бу эшне башкару өчен *«бөтен халыкны тату, кешеләрне бөтенләй яңа сыйфатка ия итеп, Татарстанның үсешенең үз стратегиясе һәм тактикасы булырга тиеш»*. Ә.Борһанов фикеренчә, эшләрне матди нигез төзүдән башларга кирәк. Шул чагында гына ул базар мөнәсәбәтләре объектыннан шул мөнәсәбәтләрнең субъектына әверелә һәм милли капиталны булдыруда реаль төстә катнаша ала.

«Халык байлыгының байтак өлеше дәүләт бюрократиясе инициативасы белән малкуарлар кулына... күчсә дә, төп милли байлык әлегә дәүләт карамагында кала бирә. Республика карамагындагы бөтен байлыкны исәпкә алырга, анда һәр гражданның өлешенә тигән көмешен билгеләргә, аннары кыйммәтле кә-

газь рәвешендә халыкка бирергә кирәк», — ди ул. Шулай итеп, ул хосусый милекчелек идеологиясен яклап чыга, хосусый милекчелек татар халкының киләчәгенә нык тәэсир итәчәген ышандырырлык итеп исбатлый, фәнни әдәбиятта мондый фикер яңа гына әйтелгән булса да, чынлыкта ул татар эшмәкәрләре тарафыннан әле гасыр башында ук тормышка ашырыла башлаган. Әмма бу мәсьәлә әле аз өйрәнелгән, билгеле тарихи фактлар да онытыла бара иде. Гасыр башында ук инде татар эшмәкәрләре үз кулларында шактый матди байлык туплап өлгерәләр. Бу байлык табигый рәвештә хезмәт итеп, көч түгеп туплана. Фәнни терминология теле белән әйткәндә, бу юл — эволюцион юл, иң ышанычлы юл.

Бу уңайдан Мәскәү тарихчысы М.Водолагинаның татар халкына карата әйтелгән сүзләре кызыклы. Бер студентның: *«Татар халкы нинди халык?»* — дигән соравына ул болай дип җавап бирә: *«Татармы? О, ул мәһабәт халык! Син аларның эшчәнлекләрен җәелдерергә мөмкинлек кенә бир, бөтен дөньяны камап алачаклар. Әгәр Ульянов, үз вакытында килеп өлгермичә, аз гына ун-утыз ел гына соңарган булса, бөтен хакимият өч йөз аек татар миллионеры кулында булыр иде. Чөнки алтын да, уран рудалары да, нефть тә, төрле кыйммәтле ташлар да — һәммәсе дә алар кулына күчеп бетәр иде.*

Газизов һәм Азимовлар, Рәмиев һәм Шәкүревләр, Скуратов һәм Строгановлар...

Урал, Кавказ, Себер... Ат, икмәк, җир асты байлыклары — һәммәсе дә, һәммәсе дә!

Акчуриннар, Хәйруллиннар, Мансуровлар, Ишморатовлар, Морозовлар, Дәгиловлар! Хәтәр бит!

Ә идеологияләре-инанулары нинди? Яшел! Тыйнаклык, гыйлемлек... Һәм шул ук вакытта — батырлык, курку белмәслек, егетлек, байлык, көч, тугрылык, чисталык. Аннары бу илнең ничек аталуы хакында да уйланырлар иде: Русияме, әллә Татарстанмы?!»

Ә.Борһанов борчылып болай яза: *«Мин атап киткән юл — кыскарак юл* (халыклар һәрвакыт кыскарак юл эзлиләр, әмма җиңел юллар юк. — *Р.В.*) *Татарстан үз байлыкларына хуҗа түгел дигән мәгънәдә әйтмим. Хикмәт шунда: байлык халык карамагында түгел һәм татар халкының (бөтен халыкның) МИЛЛИ МАЯСЫ формалашмаган. Бу җәһәттән дөнья күләмендә башкарасы эшләрнең исәбе-хисабы юк.*

Соңгы 10—15 ел эчендә татарның элек югалткан этник бердәмлеген торгызырга омтылышы, аның уянуы — халыкта, милли идея буларак, үз-үзен саклап калу хисе туның мөһим күрсәткече. Татарларның яшәешендә тел һәм милли мәдәниятне торгызу процессы бара. Аны татар милләтендәге гражданнарның акционерлык, кооператив, җитештерүче, сәүдә итүче һ.б. предприятиеләр, компанияләр, шулай ук шәхси-хосусый

гаилә предприятиеләре төзү юлы белән милекчеләргә әйләндерергә, ярдәм итеп ныгытырга һәм үстерергә кирәк. Гражданнарның һәм татар эшкуарларының байлыкларын махсус оештырылган Татарстан халык банкында туплап, татар МИЛЛИ МАЯСЫН формалаштыру өстендә эшлисе бар».

Үзгәртеп кору чоры башлангач, Ә.Борһановка да «кояш елмайды». Соңгы унөч ел эчендә генә дә аның ике йөздән артык хезмәте дөнья күрде. Шуларның җидесе — китаплар. Фәнни хезмәтләре өчен Россия гуманитар университеты аңа махсус академик стипендиясе билгеләде. Үзе шул ук гуманитар университетның социология кафедрасында «Философия и социология собственности» дигән темага махсус лекцияләр укый, аспирантлар белән җитәкчелек итә.

Казаннан «үз теләге» белән китәргә мәҗбүр булган Ә.Борһанов шушы елларда гына Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы итеп сайланды.

Әгъдәс Хөсәенович Борһанов һәрвакыт эштә: яза, Рәсәй буйлап лекцияләр укып йөри. Халык әйтмешли, *«карама беләккә, кара йөрәккә»*! Аллага шөкер, аның йөрәге әле нык. Фидакарь хезмәтендә яңа уңышларга ирешүен телик!

Октябрь, 2000

МИЛЛӘТ ҺӘМ ТӨРЕК-ТАТАР ТАРИХЫ

Билгеле булганча, XX гасыр башында татар зыялылары арасында «милләт» төшенчәсен аңлатучы өч төрле караш туа[1] .

Беренче караш вәкилләре «милләт» терминының бөтен мөселманнарны аңлатуын раслый, икенчеләр бу атама астында бөтен төрки халыкларны берләштерә. Өченче карашны «Галимҗан Шәрәф карашы» дип тә әйтергә була. Галимҗан Шәрәф — күпкырлы галим-педагог. Дөресрәге, энциклопедик галим, бик яшьли җәмәгать эшләрендә катнашып, төрле өлкәләрдә ачык итеп үз фикерен әйтә алган зыялы. Өченче караш ияләре «татарчылар» исемен дә йөртәләр, чөнки алар татар милләте хакында сүз алып баралар. «Аң» журналының 1914 елда чыккан бер санында, укучыларына мөрәҗәгать итеп, «Миллиятне ничек аңлыйсыз?» дигән сорау куя. Моңа җавап рәвешендә Галимҗан Шәрәф үз чиратында «Ничек аңларга?» исеме астында үзенең зур булмаган, әмма «милләт» атамасының нәрсә аңлатуын, нинди әһәмияткә ия булуын бәян иткән мәкаләсен бастыра. Монда ул милләтнең төп сыйфатларын атый.

«Миллиятне ничек аңлыйсыз?» дигән сорауга бүген дә җиңел генә җавап бирү мөмкин түгел. Элек без файдаланган «милләт» төшенчәсенең И.Сталин билгеләмәсе конкрет сәяси-идеологик максатлардан чыгып бирелгән. Ул исә бөтен милләтләрнең оешу тарихларын һәм чынбарлыкларын объектив рәвештә чагылдырмый, чөнки империячел идеология файдасына җайланган.

Галимҗан Шәрәф фикеренчә, тел, нәсел, тарихи кардәшлек, милли вөҗдан, бер-беренә якынлык тойгысы, бер-беренә бәйләнгәнлекне хис итү — милләтнең төп сыйфатлары.Галимҗан Шәрәф милләтнең дәүләтне барлыкка китерүдәге һәм аны ныгытудагы мөһим роленә игътибар итә. Ул милләт булып яшәр өчен тел охшашлыгының гына җитмәгәнлеген ассызыклап үтә.

Галимҗан Шәрәф раславынча, дин һәм ватанның бер булуы гына милләтне барлыкка китерми. Мәсәлән, татарларның руслар белән ватаннары бер, ләкин бу ике халык бер милләтне тәшкил итми. Дин берлеге белән дә шулай. Эфиопия мөселманнары һәм Идел-Урал мөселманнары бер милләт санала алмыйлар.

---

[1] Бу мәсьәлә бүген дә бик актуаль. «Милләт» төшенчәсенә карата кызыклы фикерләр матбугатыбыз битләрендә еш күренә. (Кара: *Ногмани Р.*«Милләт» төшенчәсенә карата фикер // Ватаным Татарстан. — 2001. — 9 нояб.)

Ул шулай ук милләт булып хәрәкәт итүнең кирәклеген дә күрсәтә. Башка халыклардан мәдәни, икътисади һәм сәяси яктан артта калмас өчен дә милләт кирәклеген яза.

«Без шималь төрекләрбез, без төрекләрбез, без Ислам динен кабул иткән урыс дәүләте кулы астына кергәнбез. Халыкларның якынлыклары дин вә ватан берлегеннән, алар белән бәйләнгәнлекләреннән дә тора. Шул тәртиптән караганда, Казан артындагы керәшеннәр безгә Гарәбстан мөселманнарыннан, Һиндстан мөэминнәреннән дә якынрак булулары күренә... Безнең моңа кадәр керәшеннәрне читтәрәк күреп, Гарәбстаннан килгән бәдәвиләрне шатлык белән каршы алуыбыз бездә милләт хисенең үсмәгәнлеген, дин фанатиклыгы астыннан чыга алмаганыбызны гына күрсәтә». Бу һич кенә дә татарның күңел хисе Гарәбстан төрекләре ягында булмау түгел, киресенчә, ватан, тел, тарихи янәшә яшәгән халык белән исәпләшү, хөрмәт итү турында сүз бара. *«Яхшы күрше туганыңнан якын» ди бит халык. Монда инде туган туфракны, «милләтнең җәгърафи шәкелен» дә истән чыгарырга ярамый. Без шималь төреге булсак, бер төрле була, гомуми төрек булсак, бөтенләй икенче шәкел ала»*, — ди Галимҗан Шәрәф.

Милләт булганда, безнең башта татар булуыбызны, аннан соң гына шималь төреге, ягъни төньяк төреге, аннан соң төрки булуыбызны, аңардан соң гына мөселман вә гомуми адәм баласы булуыбызны әйтә.

Милләт үсешенең, куәтенең аның милли әдәбияты, милли музыкасы, милли сәнгате, милли тарихына да бәйләнгәнен ачып сала. Бу фикер аның шушы чорда нәшер ителгән З.Вәлидинең «Төрек-татар тарихы» исемле хезмәтенә язган җентекләвендә (рецензиясендә) күренә. Галимҗан Шәрәфнең бу мәкаләсе дә озак еллар дәвамында тарихчылар тарафыннан файдаланылмады, чөнки бу фикерләр «халык дошманы» тарафыннан әйтелгән иде. Чынлыкта исә болар милли тарих өчен бик кыйммәтле. Галимҗан Шәрәф милли тарихның туып килүен һәм аның милләт өчен әһәмиятен ассызыклап әйтә. З.Вәлидинең хезмәтенә бәя биреп, ул аны *«татар тарихын бер системага китерү юлында беренче тәҗрибә»* дип бәяли, хезмәттәге ялгышлыкларга да туктала. Мәсәлән, китапта Чыңгыз ханга кадәр булган төрки дәүләтләргә тиешле күләмдә урын бирелмәвен әйтә. Угыз (Модэ), Этил (Атилла) кебек «каанлар»га күбрәк урын бирергә иде, борынгы төркиләрнең диннәрен тулырак тасвирларга иде, ди. Шулай ук Чыңгыз ханга карата булган тәнкыйди фикерләрен дә әйтә.

Бу рецензиянең фәнни һәм публицистик әһәмияте XXI гасыр башында да югалмаган, чөнки 1917 елдан соң татар халкының тарихы махсус рәвештә бозып язылды. XX гасыр башындагы кебек үк, XXI гасыр башында да күп проблемаларны яңабаштан

өйрәнү, аңлату таләп итеlә. Бу эш бигрәк тә яңа дәреслекләр булдыру өчен кирәк. Дөрес язылган дәреслек, шифалы дару шикелле, милләтнең үзаңын үстерә, ныгыта.

Үзаңның үсү тарихы хәтер белән бәйләнгән. Тарихи хәтерне җимерү милләтнең рухын, үзаңын җимерүгә китерә. Ә милли үзаңның җимерелүе үз чиратында милләтнең бетүенә алып бара. Шуңа күрә милләтне җимерергә теләгән хакимият ул милләтнең хәтерен, фикер йөртү сәләтен, сүз әйтү мөмкинлеген бетерә. Тарихи мирасыбызны һәрьяклап өйрәнгәндә, тарихи хәтеребезне яңартып торганда гына татар милләте үсә, ныгый, алга бара ала.

Боларның барысын да истә тотканда, Галимҗан Шәрәфнең «Ничек аңларга?» һәм Зәки Вәлидинең «Төрек-татар тарихы»на язган рецензиясендәге фикерләре безнең татар милләте, аның бай тарихы өчен бик тә файдалы икәнлеге көн кебек ачык.

Укучылар игътибарына Галимҗан Шәрәф тарафыннан язылган әлеге ике мәкаләне тәкъдим итәбез.

Миллиятне ничек аңлыйсыз?

1. Нәселләре бер, тарихлары бәйләнгән, телләре якын халыклар бер милләт тәшкил итәләр. Шул халыклардагы бер-береңең якынлык тойгысы, бер-беренә бәйләнгәнлекләрен хис итүләре «миллият» дип атала.

Милләт әһелләрен нәсел, тел вә тарихлары берлә бәйләгәнгә, аларның гомуми гадәт вә йолалары берлә гомуми дога вә теләкләре була.

2. Миллиятнең хәзер дә халыкларның тормышында зур әһәмияте әүвәлдәге кеби тарихта да әһәмияте булган; дәүләтләрнең күтәрелү вә төшүләре күп вакытта миллият хисенең күтәрелү вә төшүеннән килгән. Германия урындагы аерым вакытта һичбер әһәмиятләре булмаган әллә ничә йөз вак хөкүмәтләрне берләштереп, хәзергә бүтән халыкларны үзенең кырыйдагы куәте берлә куркытып торган, фәнгә иң күп хадимнәр җитештергән, мәдәни вә икътисади тормыш берлә халыкларның иң алгы сафларында торган бер дәүләт, бер мәмләкәт ясаган нәрсә — миллият, әүвәлдәге кеби, Италияне берләштереп бу көндәге бөек дәүләтләр арасына керткән нәрсә дә — миллият хиседер. Миллиятнең бу көндәге халыкларның тормышындагы әһәмиятенә соңгы Балкан фаҗигаләре җитәрлек дәлил була алыр.

3. Миллиятнең әсаслары — тәгърифтә әйтелгәнчә — тел якынлыгы, нәсел якынлыгы вә тарихи кардәшлектер. Тел вә нәселләре безнекенә якын булмаган гарәп, рус, фарсылар Гарби Аурупа халыклары берлә бер милләт тәшкил итә алмаячаклары кеби, нәсел вә тарихлары безнекеннән башка булган, телләре генә туры килешкән Кырым вә Төркестандагы бәгъзе килме-

шәк халыклар да безнең берлә бер милләт була алмыйлар; шулай ук Дунай болгарлары хакында: кайберләре Идел болгарларыннан аерылган, алар берлә бер нәселдән дип, нәсел вә тарих якынлыгын күрсәтсәләр дә, хәзергә аларның телләре безнекенә бөтенләй охшамаган, имля вә телләре якынайган булганлыктан алар да безгә милләт җәһәтеннән кушыла алмыйлар. Гомуми бер милләт тәшкил итәр өчен тел, нәсел вә тарих кардәшлеге — һәр өчесе ләзүм нәрсәләрдер.

4. Миллиятнең дин вә ватан кеби җәмгыйләргә дә, икътисади хәл вә кәйфият берлеге кеби җәмгыйләргә дә һич мөнәсәбәте булмаска тиеш. Милләт үзе ватан вә дин кеби тулы хаклы бер җәмгъ. Ватаннарыбыз бер булганнан гына бездә русларга милли якынлык булуы мөмкин булмаганы кеби, диннәребез бер булганнан гына Хәбәшстан мөселманнары да безнең берлә бер милләт була алмыйлар. Милләт мәхкүме йә хакиме булуның да миллият хисенең куәтле йә азлыгына катышы юк; тик милләт мәхкүмнәрендә миллият тыштан караганда гына күбрәк күренә: милләт хакимнәре үзләренең милли теләкләренә, милли йомышларына ачыктан-ачык дәүләт вә мәмләкәт исеменнән дә эшли алалар, милләт мәхкүмнәре исә һәрбер милли эш вә йомышларны милләт исеменнән генә эшләргә мәҗбүр булалар.

5. Искедән калган тарихи язуларыбызда бабаларыбызның «төрек» булулары берлә мактанулары, Чыңгыз хан Гаребкә гаскәр җибәргәндә: «Бер төрек уты күрсәгез, аны башкалар кулы астыннан күтәрелдерми калмагыз!» — дип җибәрде. Гомумән, иске татар, магул, төрек хөкүмәтләрендә төрек-татар нәселеннән булган кешеләргә бөтенләй башка мөгамәлә булуы — безнең бабаларыбызда да миллияткә охшаш бер нәрсә булганыны күрсәтәләр; әмма диннәргә бертигез караулары, дин аермасы алар өчен әһәмиятле нәрсә булмаганын күрсәтә. Аннан соңгы гасырларда Ислам тәэсире астында халкыбыз дингә тиешеннән артык бирелеп китсәләр дә, соңгы вакытта милли шагыйрь, милли әдип, милли мөәррих, милли халык хадимнәребез җитешә башлауга безнең дә дин васыйлыгы астыннан чыгып, миллият буйсынуы астына керә башлаганыбызны күрсәтә.

6. Милли вөҗдан — үзеңне милләтнең бер кисәге итеп хис итү, милләтнең гомумән күтәрелү вә төшүенә үз шәхесе күтәрелү вә төшүеннән артыграк итеп, вә милләтнең һәр фәрденең күтәрелү вә төшүенә үз күтәрелү вә төшүенә мөсави итеп хис итүдән вә шулай хис итүгә тырышудан гыйбарәттер.

7. Миллият хис берлә тарих, тел вә нәсел якынлыгы булган халыкларга файда вә хезмәт итү бәйләнгәнгә, миллиятнең файдасын инкяр итәргә мөмкин түгел. Башка халыклар-

да шул миллият хисе булып торган мөддәттә, алардан мәдәни, икътисади вә сәяси җәһәтләрдә уздырмавыбыз, артта калмавыбыз өчен безгә дә миллияттән башка киченергә һич мөмкин түгел, миллиятнең эсаси кирәклеге йә кирәк түгеллеге исә башка мәсьәлә.

8. Без татарларбыз, без шималь төрекләрбез, без төрекләрбез, без Ислам динен кабул иткән вә урыс тәбәгалегенә кергәнбез. Халыкларның бер-беренә якынлыклары төрле дәрәҗәдә була; шуңа карап милләт җәмигын да киңәйтергә вә тарайтырга мөмкин. Бер җәмгыятьнең безгә якынлык вә ераклыклары түбәндәге фиркаләрнең кайсына каравына мәрбуттыр: а) татарлар; б) шималь төрекләре;в) төрек халыклары; г) дин вә ватан берлеге илә бәйләнгән халыклар; д) алар берлә бәйләнмәгән халыклар. Шул тәртиптән караганда, Казан артындагы керәшеннәр безгә Гарәбстан мөселманнарыннан да вә Һиндстан мөэминнәреннән дә якынрак булулары күренә. Соңгы вакытта чуаш вә керәшеннәр арасында да миллият хисе кузгала башлап, үзләренең татарларга якынлыкларын ачарга, күрсәтергә тырышучылар вә аларны татарларга якынайтырга теләүчеләр булуы да бу фикерне тәэкид итсә кирәк. Безнең моңа кадәр керәшеннәрне читрәк күреп, Гарәбстаннан килгән бәдәвиләрне шатлык берлә каршы алуыбыз бездә миллият хисе җитәрлек ипләнмәгән, дин тәгассыбы астыннан чыга алмаганыбызны гына күрсәтә. Алай да, хәзер Гарәбстан үзенә автономия алырга дип төрекләргә каршы сугыша башласа, мин һәрбер татарның хисе, мәхәббәте төрекләр тарафында булачагына ышанам. Гомуми миллият безне иң алдан татар, аннан соң шималь төреге, аннан соң төрек булырга, алардан соң гына мөселман булырга вә гомуми адәм баласы булырга мәҗбүр итәргә тиеш.

9. Милләтнең җәгърафи шәкеле дә шуңа карап үзгәрә. Без шималь төреге булсак, бер төрле була, гомуми төрек баласы булсак, бөтенләй икенче шәкел ала.

10. Үткән көннәребездә, тарихыбызда шатлыклы сәхифәләр дә, кайгы сәхифәләре дә бар: Чыңгызның дөньяны селкеткәндәге куәте, Аксак Тимернең бүтән тирә-яктагы мәмләкәтләргә, идарәләренә имля итеп торгандагы шәүкәте никадәр шатландырса, аларның хәләфләренең үзара сугышлары, бер-берен изүләре шулкадәр көендерә. Юлына бер алтын биреп Фирдәүси кеби даһилардан, фарсы эсатыйрларыннан зур поэмалар яздыручы Мәхмүд Газнәвиләребез, фән вә милли татарга хидмәт итеп бөтен гомерләрен үткәргән Олугбәк вә Әбелгази Баһадур ханнарыбызның, гарәп мәдәниятенең таҗында алмаз таштай ялтыраган Ибне Сина, Фарабиларыбызның исемнәрен ишеткәндә, эсәрләрен укыганда никадәр шатлансак та, үзебезнең төрек теле, төрек тарихы, иске төрек мәдәниятенә җитәрлек эһәмият бир-

ләп кешеләрнең чыкмавына, күбесенең төрек телендә язуны бер кимчелек санауларын күргәч кайгырмыйча, көенмичә дә китәргә мөмкин түгел.

11. Милләтебезнең соңгы 10—15 елда алган гыйлем вә мәгарифкә омтылу юлы, дин тәгассыбы астыннан чыгып миллият тәэсире астына керә башлавы, аның киләчәккә куәт җыя башлаганын вә мөстәкъбәле якты вә күңелле икәнен күрсәтә.

12. Әдәбиятта миллият — әдип вә шагыйрьләребез тарафыннан күбрәк милли телләрне күрсәтү, милли тормыштан алынган ләүхәләр бирүдә вә әсәрләренә милли тарихтан темалар (мәүзугъ) алу да булырга тиеш. Әдәбиятыбызда алгы икесе булса да, соңгысы күренми. Милли тарихтан алынып язылган кулга тотарлык бер әдәби әсәребез булмавы — әдәбиятыбызның иң зур кимчелекләреннән саналырга тиеш.

Мәктәптә миллият — милли тел, милли тарихка әһәмият бирелүдә, мәктәпләребездә милли көйләр берлә җыр дәресләре кертелү дә булырга тиеш. Моңа кадәр мәктәптә миллиятебез абыстайның әүвәл сыйныфларда имля яздыру, берәр кәррат китап укытып чыгарудан узмаса да, соңгы елларда зуррак мәдрәсәләребездә татар сарыфы вә нәхүе, татар тарихы, татар әдәбияты вә әдәбият тарихы укыла башлавы вә шуңа кирәкле дәрес китапларының акрын-акрын әзерләнә башлаулары — чынлап шатландырырлык эшләрдер.

Сәнгатьтә миллиятне исә милли рәсем, милли архитектураларыбыз булганчы, алар татар теләгенә, татар күңеленә муафыйк әсәрләр бирә башлаганчы күтәрергә туры килер. Милли музыкабыз матур, моңлы; үзенең йөрәкләребезгә тия торган хосусыятьләре дә бар, ләкин хәзерге музыкантларыбыз күп булса гитара йә мандолинага иске гармунчыларыбыздан күчереп уйнаудан узмаганга, милли музыкабызның да тәртипкә салынып, кеше рәтенә керүенә, тәртипле, милли оркестрлар ясалуына, яхшылап музыкальный образование алган кешеләребез өлгергәнче көтәргә кала. Казан вә Петербургтагы музыка мәктәпләрендә укучы туташ вә егетләребез берничә данә бар: өметтә калабыз.

13. Бабайлар «бәндә ни теләми, язык йибәрми» дигәннәр. Милләтебез өчен хәзергә иң беренче теләк, билгеле, мәдәни вә икътисади күтәрелү булырга тиеш. Моннан башка да милләт өчен матур, күңелле теләкләр күп, ләкин аларны... барыбер «язык җибәрмәс» дип язмый торырга, тик күңелдә сакларга мәҗбүрбез.

Төрек-татар тарихы

(Зәки әфәнде Вәлиди әсәре. 1915 елда Казанда басылган[1])

Татарларда милли рух күтәрелә башлау берлә милли тари-

хыбызны белергә кызыгучылар да арта башлады. Милли рух башта мәктәпләребезгә милли телне кертсә, инде милли тарихны да кертеп бара. Хәзер дә милли тарихның мәктәпләребезнең тарих берлә берникадәр таныш булуларына гына мәукуфдер[2].

Соңгы ун елга кадәр тарихыбыз берлә танышыр өчен телебездә җитдирәк бары ике мәнбәгъ бар иде: берсе Әбелгази Баһадур ханның «Тарихе шәҗәрә-и төрек» дигән китабының Казан төркисенә тәрҗемәсе (Габделгаллә м Фәезхан угылының тәрҗемәсе булып, 1891 елда Казанда басылган), икенчесе Шиһаб хәзрәт Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...»ы иде.

Алардан башка Казан төркисендә «Тәварихы Болгария», «Кыйссаи Чыңгыз вә Аксак Тимер», «Шәҗәрә», «Чыңгыз хан» вә «Җамигъ әт-тәварих тәрҗемәсе» кеби әсәрләр булса да, болар тарихи җәһәттән әһәмиятсез, күбесенчә хорафат вә хикәяләр берлә тулган, баштагы икесе генә халык арасында таралган иде.

Соңгы ун ел эчендә исә, милли тарихыбызга гаид әсәрләр байтак арттылар вә һаман да артмактадыр. Әсәрләрнең саны гына артып калмыйча, мөндәриҗәләре җәһәтеннән дә бик тиз тарикъ үтүләре, бу юлда эшләүчеләребезнең көннән-көн күбәюләре — шатлык, ләкин эшләнмәгән, тикшерелмәгән, өсте тузан вә пычрак берлә капланган тарихыбызның тиздән җанлану, аякка басуын вә читләр тарафыннан ташланган пычраклардан арулануын тиздән күрү өмиден бирә.

Хәсәнгата хәзрәт Габәши үзенең «Мөфассал тарихе кауме төрки» вә аннан соң чыккан «Мохтасары тарихы кауме төрки» вә «Төрек ыруглары» исемле әсәрләрендә төрек кавемнәренең элекке хәлләрен тәгаен итәргә теләсә, Ризаэтдин хәзрәт «Шура»дагы мәкаләләре вә кыйммәтле «Асар»ы илә элекке вә соңгы милли тарихыбызда әһәмиятле урын тоткан аерым шәхесләр вә аларның фәгалиятьләре илә таныштырды. Гайнетдин Әхмәревнең хезмәтләре Болгар вә Казан заманнарының күп якларын ачтылар. Һади әфәнде Атласи «Себер тарихы»н язды. Ләкин 1912 елга кадәр телебездә төрек халыкларының тарихын иске дәверләрдән алып соңгы вакытка кадәр китергән, фәндә мәкъбүл ысуллар илә бер җепкә тезгән, төрле дәверләрнең бер-бере илә мөнәсәбәтен тәгаен иткән әсәр юк иде. Бу хәл мәктәп вә мәдрәсәләргә милли тарихның кереп, урнашып китүе өчен бик зур манигъ булып тора иде.

Яшь мөәррихләребездән Зәки әфәнде Вәлидинең 1912 ел башында чыккан «Төрек вә татар тарихы» исемле «Милләт» көтепханәсе тарафыннан нәшер ителгән әсәре тарихыбызга гаид материалны фәнни ысуллар илә җыеп бер тәртипкә кую, бер системага китерү юлында беренче тәҗрибә иде. Зәки әфән-

де монда югарыдагы әсәрләрдә булган мәгълүматны бер җепкә тезү берлә генә калмый, аларда булмаган, татар укучылары өчен яңа булган байтак мәгълүматлар да керткән, тарихыбызга гаид Шәрык вә Гаребтә басылган бик күп әсәрләр вә мәкаләләр илә таныштырган иде.

Билгеле, беренче тәҗрибә булганлыктан, Зәки әфәнденең бу әсәрендә ялгыш юлдан киткән урыннары, дөрес булмаган карашлары да аз түгел. Ләкин, алай да булса, беренче адым булганлыктан, тарихыбызның үз телебездә эшләнү юлында бу әсәрнең әһәмияте игътираф ителергә тиештер.

Бу әсәр үзе артыннан озакламый Г.Баттал әфәнденең «Татар тарихы» дигән әсәрен тудырды. Г.Баттал әфәнденең әсәре төзелеш, тел вә бүксәме берлә мәктәптә укыту өчен Зәки әфәнденең югарыда мәзкүр әсәренә караганда уңайрак булса да, мөндәриҗәсе берлә татар матбугатында булмаган бер нәрсәне бирү түгел, Зәки әфәнде тарихыннан соң артка таба бер адым иде. Бу әсәрдә тарихыбызның бары бер кисәге — XII гасырдан башлап XVI гасырга кадәр булган бер кыйсеме генә күрсәтелә, бу ике арада да байтак әһәмиятле моментлар төшереләп калдырыла. Әсәр өчкә бүленгән: болгарлар хакында (күбрәк этнографияләренә гаид мәгълүмат) — 12 сәхифә, татарлар хөкүмәте — 45 вә Казан патшалыгы — 40 сәхифә. Бөтен әсәр гүя Болгар хөкүмәте төзелгәнчегә кадәр татарларның, бабаларыбызның тарихы булмаган, Казан ханлыгы беткәннән соң да аларның тарихы юк дигән тәэсирне калдыра. Әсәреннән күренгәнчә, мөәллиф тарихыбызга гаид әсәрләрдән татарчада чыкканнарын гына күреп, әсәрне шулар буенча гына язган булырга кирәк. Телебездә булган әсәрләрнең һәммәсендәге гаепләр Баттал әфәнденең тарихына да күчкәннәр. Чыңгызга кадәр тарихыбызның телебездә җитәрлек эшләнмәгән, татарча китапларда бу турыда мәгълүмат аз булуына карап мөәллиф туктап калмаган, тоткан да тарихыбызның ул кыйсемен ташлап калдырган. Болгар вә башка төрек-татар халыкларының нәселләре вә бер-беренә мөнәсәбәтләре турысындагы фикерләреннән дә, мөәллифнең бу хактагы фәнни агымнар берлә төпле рәвештә таныш түгеллеге күренә.

Г.Баттал әфәнде тарих мөтәхассыйсы булмаганлыктан, бу җитешсезлекләр өчен, билгеле, аны гаепләргә мөмкин түгел. Мәйданда мәктәпләрдә дәреслек урынында истигъмаль итәрлек бер китап та юк вакытта чыгарылганга, анысына да рәхмәт укырга гына туры килә. Баттал әфәнде тарихында бик зур җитешсезлекләр булганга, Зәки әфәнденең 1912 елда чыккан тарихы да дәреслек өслүбендә язылмый, тарих мөгаллимнәре файдаланырлык рәвештә язылганга, яхшырак төзелгән яңа бер милли тарих дәреслегенә зур ихтыяҗ бар иде. Шуны күзгә алып булса кирәк, Зәки әфәнде Вәлиди мәктәпләребез өчен «Кыскача

рәсемле төрек-татар тарихы» исемендә дәреслек нәшер итте. Безнең җентекләячәк әсәребез бу әсәрдер.

Әсәрнең тышына «Беренче җөзьә» дип куелган. Иншалла, башка җөзьәләре дә чыкса кирәк. Мөәллиф мөкаддимәсендә тарих өчен мөфассал харита да нәшер итәргә вәгъдә итә. Әсәр зур кулда, 136 битлек булып Казанда «Өмид» матбагасында басылган. Әсәр дүрткә бүленгән: 1) иске заманда төрек халкы — 13 сәхифә; 2) төрекләр вә исламият —17 сәхифә; 3) төрек илә магуллар шәүкәте дәверендә — 73 сәхифә; 4) вак ханлыклар һәм төрек иле шәүкәтенең төшүе — 31 сәхифә.

Әсәрдә әлегә чаклы чыккан тарихларыбызда булмаган берничә артыклык бар:

1. Милли җиһангирларыбызның иң зурларыннан берсе булган Аксак Тимернең шәхесенә, хөкүмәт төзүенә вә аның балалары гасырына зур әһәмият биреп тукталынган. Әлегә кадәр безнең тарихларыбызда аңа махсус туктап тормыйча, кырыйлап кына үтәләр иде.

Шиһаб хәзрәт «Мөстәфадел-әхбар...»да Тимергә махсус тукталмаган кеби, Ризаэтдин хәзрәт тә, үзенең «Шура»сында милли тарихтагы күренгән шәхесләребезнең тәрҗемәи хәлләрен язганда, Аксак Тимерне калдырып үткән, Зәки Вәлиди дә, беренче тарихында шулар артыннан барып булса кирәк, Тимернең тарихын төшереп калдырган иде[3]. Шул материаллар буенча дәреслеген төзегән Г.Баттал әфәнде дә, билгеле, тарихыбызның бу бүлеген төшереп калдырган иде. Һәммә тарихларыбызда Аксак Тимер, төзегән хөкүмәте вә балаларының тарихы булмавы зур бер китек вә җитешсезлек булып тора иде. Мөәррихләребезнең шундый бөек бер батыр, заманында дөньяны тетрәткән җиһангирыбыз яныннан ят күреп, тиешле сәламне бирми үтүләре ихтирамсызлык булуы кеби, башкалар берлә таныштырганда, балаларыбызны бу җиһангир берлә таныштырмый калдыру да күңелгә җинаять кеби тоела иде. Зәки әфәнденең соңгы тарихында бу бушлыкның тутырылуын шатлык берлә күрсәтеп китәбез.

2. Әсәрдә төрек халыкларында төрле дәверләрдә мәдәният дәрәҗәләрен күрсәтеп китүгә зур әһәмият бирелгән вә китапның бу бабларында бик күп материал кергән. Хосусан мөәллифнең уйгурлар вә магуллар дәверендәге мәдәният (мәгариф вә әдәбият) турысындагы фасыллары тулы вә яхшы язылган.

3. Әсәрнең «Вак ханлыклар һәм төрек иле шәүкәтенең төшүе» дигән бүлеге мөндәриҗәсе җәһәтеннән, беренче мәнбәгъләрдән алынып, татардагы тарихларда гына түгел, Аурупа мөәррихләрендә дә табылуы мөмкин булмаган байтак мәгълүматны бирә вә ханлыкларның төзелү, югалуларының шактый гына җанлы рәсемнәрен күз алдыннан үткәрә.

4. Утызлап, күбесенчә оста вә белеп сайланган рәсемнәр дә әсәргә зур бер камаләттерләр. Күп вакытта кечкенә бер рәсем берничә сәхифәләрдә язып белдерергә мөмкин булмаган тормышны һәммә тәфсыйльләре берлә күз алдына бастыра ала.

5. Һәр бүлекнең актыгында шул бүлектә кузгатылган мәсьәләләр хакында байтак мәнбәгъләр күрсәтелүе дә, һәм тарих мөгаллимнәребез өчен һәм тарихыбыз берлә шөгыльләнә башлаган яшьләребез өчен бәһасез бер материал икәнен әйтми үтә алмыйбыз.

Гомумән алганда, бу әсәр милли тарихтан язылган әсәрләребездән, үз бабында иң күп китап күреп язылгандыр, дисәк, мөбаләга иткән булмасак кирәк. Ләкин шулай да булса әсәрнең гаепләре, җитешмәгән яклары юк түгел, байтак бар. Инде аларга күчик:

1. Әсәрнең иң зур гаепләреннән берсе — Чыңгызга кадәр булып үткән төрек хөкүмәтләренә тиешле микъдарда урын бирелмәведер. Бу яктан Зәки әфәндедең беренче тарихы да, бу соңгысы да Хәсәнгата хәзрәт тарихыннан соң артка таба бер адымдыр. Төрекләрнең иң шәүкәтле заманнары, бөтен Азияне үзләреннән куркытып зур кыйсемен кулларында тоткан вә Аурупага да күп күз ачарга ирек бирмәгән заманнарыннан һуннар (хун-ну), төрекләр (түкю) дәверләренә мөәллиф бик аз урын биреп, ярты-чирек сәхифә берлә генә үткән.

Шәүкәт дәверләренең мәркәзләрендә торган Угыз (Модэ), Этил (Атилла) кеби һун кааннарына, Төмин, Муган, Шийгуй вә Шийби кеби шәркый вә гарби төрек кааннарына вә аларның дәверләренә озаграк тукталырга кирәк иде. Уйгур, болгар, хәзәр вә кыпчакларга кыска-кыска булса да аерым фасыллар бирелсә, алар турысында шәкертләрдә түгәрәк бер аңлаеш калдыру өчен файдалы булыр иде.

Мөәллиф күчмә төрек кабиләләрнең гомумән бер-беренә мөнәсәбәтләре, мәмләкәтләрендәге идарә рәвешләре турысында тулырак мәгълүмат бирсә, укучылар вә шәкертләргә бу гасырларда төрек хөкүмәтләренең берсе күтәрелеп, берсе төшү, кинәттән дөньяны тетрәткән хөкүмәтләр тууының сәбәбен аңлау өчен җиңелрәк булыр иде. Бу вакытлардагы төрек хөкүмәтләренең күршеләренә (кытай вә фарсыларга) сәяси мөнәсәбәтләре дә кыска вә буталчык язылып, күбесенчә гомуми сүзләр берлә генә үтелгән.

2. Шул ук беренче бүлектә мөәллиф иске төрек дине (шаманизм) турысында да берничә юл гына язып китә. Бердән, халыкның дингә ышану вә хорафатлары, аның музыкасы, әдәбияты кеби рухы берлә танышыр өчен иң яхшы мәнбәгъ, иң дөрес көзге булганга; икенчедән, ничә мең еллар бабаларыбыз өчен бердәнбер рухани азык булып килгәнгә, шаманизм турысында болай 5—6 юл берлә генә иктифа ителмәскә тиеш иде. Бу кыска

мәгълүматта да бик үк тугъры булып бетмәгәннәре бар. Иске төрекләр, мөәллиф әйткәнчә (7 нче сәхифәнең актыгы), «күкнең, җирнең, ут, су, агач вә мәгъдәннәрнең мәҗмугасы бер илаһтан гыйбарәт» дип ышанмаганнар, бәлки болар һәркайсы аерым илаһлар дип таныганнар. Тик болар арасында «Күк тәңре» (яхуд «Хан тәңре») халикы көлли итеп, илаһы вахидкә якын рәвештә башка илаһларның вә мәхлукатның өстендә саналган. Мөәллиф әйткәнчә, тауларны хөрмәтле санамаганнар, таудагы рухны хөрмәтләгәннәр. Сугыш, мөәллиф әйткәнчә, дин буенча хөрмәтле саналмаган, бәлки һәрвакыт сугышып торырга туры килгәнлектән, сугышны яшьтән өйрәнү лябид кенә нәрсә булып киткән (иске төрек динендә сугыш тәңресе булуы, билгеле, аларның сугышны тәкъдис итүләренә дәлил була алмый). Иске төрек дине турысында Зәки әфәнде берничә җирдә «мәгънәсез мәҗүсият» дигән сүзне куллана. Шактый тирән вә матур булган бу дин турысында «мәгънәсез» дигән сүз, безнеңчә, шәпләбрәк куллану тиеш булуы кеби, иске төрек диненең мәҗүсият булып, әле тәфтишләрдән соң гына өзелергә тиеш мәсьәләдер. Башка күп диннәр кеби, тәңре дине дә бик күп тәхрифләргә, үзгәрүләргә очраганлыктан, хәзерге шаманиларның дине иске төрек дине белә танышканда материал гына була алалар[4].

3. Мөәллиф төрек, манҗур, магул, фин-угорларга кардәш халыклар өчен гомуми исем итеп «туран» сүзен истигъмаль итә (2,4,31 һәм башка сәхифәләрдә), элегрәк «туран» исемен гарби мөәррих вә этнографлардан истигъмаль итүчеләр булгалаган, бәгъзеләр бу исемне төрек-магуллар хакында гына, бәгъзеләр төрек, магул вә манҗур, фин-угор вә арадагы башка кардәш халыкларга гомуми исем итеп кулланганнар. «Туран» исемен тагын да киңрәк мәгънәдә истигъмаль итүчеләр дә булган. Хәсәнгата хәзрәт тә «Тарихы кауме төрки»дә (20 нче сәхифә) югарыда күрсәтелгән һәммә халыклардан тыш кытайлар вә японнарны да әкъваме тураниядән саный.

Бердән, «туран» исеме, югарыда күрсәтелгәнчә, төрле галимнәр тарафыннан төрле киңлектә истигъмаль ителгәнлектән, аны алу фәнни җәһәттән уңайсыздыр. Икенчедән, хәзерге Туран инеше (низменность) мөәллифнең Туран дип атаган халыклары өчен характерный булмавы кеби, «Шаһнамә» бәетләрендәге вә фарсы ганганәләрендәге тураниларның төрек, магул, манҗур йә финнардан булуы дәлилләр белә сабит мәсьәлә түгелдер. Иран вә Туран сугышын, аклар белә сарылар сугышы булмаенча, кардәш халыкларның үзара тәхет вә өстенлек өчен генә сугышулары дип караучылар бар[5]. Шул уңайсызлыклардан котылыр өчен булса кирәк, соңрак Гареб галимнәре «Туран» истиляхын ташлаганнар, төрек-магулларга Алтай халыклары исемен, вә төрек, магул, манҗур, фин-угор вә башка арадагы ха-

лыкларны бергә «Урал-Алтай халыклары» истиляхын истигъмаль итәләр.

4. Мөәллиф «манҗур, магул, финнарга һәрвакыт төрекләр кулы астында, алар идарәсендә гомер итәргә туры килгән» ди (5, 31 нче сәхифә). Тарих башка Урал-Алтай халыклары берлә финнар арасында сәяси мөнәсәбәтнең бик аз булуын күрсәтә. Шуңа күрә, башкалар финнар кулы астында булмаган кеби, финнар да, гомумән алганда, ни төрекләр, ни башка Урал-Алтай халыклары кулы астында булмаганнар (тарих тик Әтил-Атилла кулы астында берникадәр фин-угор ыруглары булуын гына ачык күрсәтә). Манҗурлар илә магуллар хакында озак вакыт төрекләр идарәсендә булганнар дияргә мөмкин түгел: һун (хунну) вә төрекләр (түкю) дәверендә манҗур вә магуллар төрекләр кулы астында торган булсалар, Чыңгыз вә аның балалары вакытында манҗурлар да, төрекләр дә — һәммәсе магуллар кулы астында иделәр. Түкюләр берлә Чыңгызыйлар дәвере арасында исә һәм төрекләргә, һәм аларның магул бүлегенә күбесенчә Кытайда хөкүмәт сөргән манҗур сөләләләре кулы астында яшәргә туры килде. Шуңа күрә мөәллифнең югарыдагы фикере тугры булып бетмидер.

Мөәллиф үзе дә 9—10 нчы сәхифәләрдә берзаманны «асылы төрек булган сяньби вә җуҗаннарның бөтен төрек, магул вә манҗурларны үз кулларында тотулары» турында сөйли. (Әйтеп китәргә кирәк ки, һәм сяньби, һәм җуҗаннар турында бу сүзләр мөбаләгаледерләр. Аның өстенә сяньби вә җуҗаннарның асылы төрек булу-булмавы да хәзергә фән карашында узылмаган мәсьәләдер.)

Сүз туры килгәндә мөәллифнең магул вә төрекләрнең нәсел ягыннан бер-беренә мөнәсәбәтләренә карашына да бераз туктап китик. Мәгълүм ки, антропология галимнәре магуллар илә кыргыз вә якут, нугай вә башка төрек халыкларында күпчелеге арасында баш вә тән сөякләренең, чәчнең вә тән тиресенең төзелеше ягыннан аерма тапмыйлар. Шул ук халыкларның мәдәният ягыннан бер үк баскычта торганнарының йола, ышану вә гадәтләренең бердәй диярлек якын булуы күренә... Лисан галимнәренең арасында иң якыны магул теле икәнен күрсәтәләр. Магул шивәсен дә, төрек шивәләрен дә бик яхшы белгән галимнәр дә сүзләрнең төпләрен (корень) тикшергәндә, бу асыл магулча, бу асыл төрекчә дип аеру мөмкин түгел дәрәҗәсендә дип карыйлар. Мөтәхассыйслар бу телләрнең сарыф вә нәхү якларыннан да төзелеше бердәй булуын сөйлиләр. XII гасырдан мөкаддәм хәзерге магул халкының вә аның теленең булуы да әле ышанычлы дәлилләр берлә исбат ителгән бер мәсьәлә түгел. Амур мөнсабларыннан килеп, XI—XII гасырларда шимали Кытайны рәхәтсез иткән, манҗур халыкларыннан булган мэн-гу берлә Чыңгыз хан моголлары (мэн-гу) бер-берилә башкалардыр, соңгы-

лар мэн-гу (магул) исемен Чыңгыз каан булгач кына вә сәяси ихтыяҗлар буенча гына кабул иткәннәр[6] вә бу яңа исемле халыкның төбенә күбесенчә кераит, найман, татар, уйгурлар кеби асылы төрек булган[7] элементлар булса да, арага манҗур элементлары вә берникадәр кытай элементлары (әсирләр) да кергәнгә, кушмадан хасил булган яңа халыкның теленә алар да тәэсир иткәннәр. Манҗурлар, шәркый төрекләр вә кытайлар арасында борын-борыннан кыз алып, кыз биреп торулар булганы, бер ыруг икенче ыругтан булган гаиләләрне, хәтта кечерәк ыругларны бөтене берлә әсир итеп алып китүләр булганын күрсәтәләр. Билгеле, бу йотулар һәр ике тарафның теленә дә тәэсирсез калмаган. Чыңгыз вә балалары дәверендә җирле төрек кабиләләре берлә Шимальдән вә Шәрыктән килгән манҗур кабиләләрен бергә тоташтырган, бутаган. Шулай итеп, хәзерге Монголия өчен гомумирәк бер тел мәйданга килгән булса кирәк. Иске Кытай тарихлары үзләренең берсе тауларның уң ягындагы манҗурлар, икенчесе тауларның сул ягындагы халык; тауларның уң ягында да, сул ягында да һаман бер үк халыкларның алмашынып торуларын күрсәтәләр, магулларны да шул үк төптән вә халыктан, диләр[8]. Синолог вә монгологлардан Иакинф, Шмидт вә башкалар XIX гасырның беренче яртысында шул әсас буенча монда булып үткән халыкларның (хунну, түкю вә уйгурларның) һәммәсенең магулдан булуына дәгъва итteләр. Ләкин уйгурча язулар табылуы уйгурларның төректән булуын күрсәтәләр (хәзер дә төрекләрен бер дәрәҗә югалткан уйгурлар булса да, боларның төрле тәэсирләр астында гына үзгәргәнлекләре күренде). Урхун язуларының табылуы — түкюларның төрек икәнлекләрен вә «түкю» сүзе үзе «төрек» дигән сүзнең кытай хәрефләре берлә генә язган икәнен күрсәттеләр. Хуннулар да төрекләрнең бабалары булуын галимнәр кабул иттеләр[9]. Иакинф вә Шмидтларның фикерләре ялгыш булып чыгуы, Кытай тарихлары сүзенә ялгыш мәгънә биргәнлекләрен генә күрсәтәләр. Кытай мөәррихләрендә күрсәтелгәнчә, чыннан да, тауларның сул ягындагы халыклар, һаман бер төптән, бер нәселдән килгән халык булуы мөмкин, ләкин бу нәсел, бу асыл алар уйлаганча «магул» түгел, «төрек»тер. «Магул» үзе дә шул асылдан бер бүлек кенәдер. Болай караганда, Кытай мөәррихләренең фикере берлә мөселман мөәррихләренең фикере бергә киләләр. Чөнки мөселман мөәррихләре дә бу тарафларда торган угыз, уйгур, кыргыз, татар вә моголларны һәм мәсен бер асылдан, «төректән таралган» дип саныйлар. Магул ханнары сарайларында булган рәсми мөәррихләр дә тарихларында магулларны төрек кабиләләреннән берсе итеп кенә таныйлар[10]. Чыңгыз нәселеннән булган мөәррих Әбелгази Баһадур хан «Тарихы шәҗәрә-и төрек»тә магуллар төрекләрнең бер кыйсеме генә булуын тәэкид итә. Без кулыбызга төшкән башка

фарсы, гарәби вә кытайча әсәрләрдә дә моңа каршы булган бер фикер очратмадык.

Без, монда китерелгән дәлилләрнең XIX гасырның соңгы яртысында Аурупа галимнәре арасында мәшһүр булып киткән төрек берлә магулны аеру, вә магулны (монгол) фин, кытай, япон вә төрек кеби сары җенестәге төп асыллар арасына керту дәгъвасын тәнкыйть берлә карау өчен җитәрлек дип уйлаганыбыз кеби, магулны төрекнең бер фәргысе генә түгел диючеләрнең фәнни әсаслардан чыккан шөбһәсез дәлилләре булмаган мөддәттә дә, Ислам мөәррихләренең дә, кытай мөәррихләренең дә карашларына туры килгән вә югарыда күрсәтелгән әсаслары булган магулларны төрекнең фәргысе дип тану әсасын ташларга ихтыяҗ юк дип беләбез.

Зәки әфәнде исә әсәрендә магул берлә төрекләрне бөтенләй аерып куя (2, 4, 54 вә гайре сәхифәләр), хәтта тезгәндә, төрек, манҗур, магул дип санап (31 нче сәхифә), манҗурларны урта арадагы бер милләт итеп күрсәтә. Бу караш Гареб әсәрендә соңгы вакытка кадәр мәшһүр караш булганга, Зәки әфәндене бу карашка кушылуы өчен, билгеле, гаепләргә мөмкин түгел; ләкин бу карашны ихтыяр вә кабул итсә, мөәллиф әсәрендә баштан актыкка кадәр шул юлдан барырга тиеш иде. Әсәрдә исә бу күренми, ул магулларны төрек-татарлардан аерым, аларга ят милләт дип карый; ләкин үзе «Төрек-татар тарихы» дип исемләнгән китабының өчтән ике өлешен магуллар шәүкәте дәверенә хәсыр итә вә бу дәвер турысында: «Бу дәвер төрек халкы хәятында иң матур бер дәвер хисаплана. Бу дәвердәге хәятында төрек халкы чиксез зур кузгалышлар ясап үзенең кем икәнен дөньяга янә ачыграк танытты... Төрек халкы бу вакыт үзен җирнең күп өлешенә һәм җир йөзендәге күп милләтләргә чын мәгънәсе берлә хуҗа булып торганын, үзенең милли хәяты, милли көче берлә тереклек итә ала торган бер тау-таш икәнен ачык күрде», — ди (82—83 нче сәхифәләр). Бу сүзләр күрше килене пешергән ботка берлә мактану булыбрак чыгалар. Әгәр мөәллиф, югарыда әйткәнчә, магулларны төрекләргә ят халык дип караса, аларның тәсәллыт дәверенә төрекләр өчен шәүкәт дәвере дип түгел, төшкенлек дәвере дип карарга тиеш иде вә төрекләрнең иң зур шәүкәт дәверләре итеп һун, төрек (түкю), уйгур хөкүмәтләренең заманнары саналырга тиеш вә китапта иң күп урын шуларга бирелергә тиеш иде.

«Магуллар шәүкәте дәвере» дигән бүлектәге күзгә бәрелгән, әсәрнең гомуми агышы өчен әһәмиятле булган бәгъзе хаталарны да күрсәтеп китик:

1. Мөәллиф: «Кытайдагы император нәселе, Тимучинның саксызлыгыннан файдаланып, аны әсир итеп алды, Тимучин анда ун еллап гомер итте», — ди (33 нче сәхифә). Дөрес, Мэн-Хун дигән бер кытай сәйяхы шундый бер хәбәр яза[11]. Ләкин рәсми

Кытай тарихларында бу турыда һичнәрсә булмаганы кеби, фарсы вә гарәп мөәррихләрендә дә мондый хәбәр күренми.

2. Бөтенләй диярлек Чыңгызның Монголиядәге хәятына хәсыр ителгән «Алтын Тобчи» вә «Санан-Сецен» кеби магул истәлекләре Чыңгызның башыннан үткән һәм башка читенлекләргә туктап та, бу турыда һичбер сүз язмаганнар. «Чыңгыз йортының яшерен тарихы»нда да бу турыда бер хәбәр дә юк[12].

3. Мэн-Хун әйткәнчә, кытайлар арасында 10 елдан артык калу Чыңгызның табигатенә тәэсир итәргә, һич булмаганда, Чыңгыз бу вакыт эчендә кытайча сөйләшергә өйрәнергә тиеш иде. Ләкин Чыңгыз хәятының дәвамы моны күрсәтми. Рәшидеддин вә Җүвәйни Чыңгызның ана теленнән башка телне белмәвен язалар.

4. Чыңгызның бөтен хәяты дәлилләр берлә, сабит вакыйгалар берлә тулы булып, бу вакыйга өчен урын юктыр.

5. Мэн-Хун бер сәйях кына булганнан, аның тарихка гаид сүзләре башкаларга хилаф булмаганда, вә алар тарафыннан да тәэкид ителгәндә генә кабул ителергә тиеш. Шундый сәбәпләрдән булса кирәк, күп кенә гарәп мөәррихләре Мэн-Хунның бу сүзен кабул итмәгәннәр, Зәки әфәндене бу сүзне ни өчен генә кабул итүен без белә алмадык.

6. Мөәллиф: «...12 нче елларга кадәр ул (Чыңгыз) Байкал күле әтрафындагы Урхун-Онон буендагы һәммә кабиләләрне җыйды», — ди (33 нче сәхифә). Тарих исә Чыңгызның бу вакытка кадәр Онон буендагы кабиләләрне генә җыйганын күрсәтә. Мөәллиф үзе дә югарыда күрсәтелгән кераит, найман вә башкаларның 12 нче елдан байтак соң кушылганнарын яза (33 — 34 нче сәхифәләр).

7. Чыңгыз гасырында Харәзем мәмләкәтендә «Харәзем шаһы исемендә башта хәлифәнең валисе булып та, соңыннан аңа карышып истикълал игълан иткән бер нәсел идарә итә иде» диелгән (38 нче сәхифә). Тарих исә моны күрсәтми. Харәзем шаһларының төп бабалары Ануш Сәлчук ирләреннән Билгә тәкиннең сатып алган колы булган, соңрак моның бабалары Төркестанда урнашканнар. Истикълал игълан итүдән элек исә Мөхәммәднең бабасы Атсыздан башлап кара кытай гурханнары кулы астында аларның валие булып торганнар. Гурханнарның куәтләре кимегәч, Харәземшаһ Мөхәммәд вакытында гына ихтилал чыгарып, истикълал кәсеп иткәннәр. Димәк, бервакытта да Мөхәммәднең бабалары хәлифәнең валие булмаганнар[13].

8. Кангылылар Чыңгыз килгән вакытта Харәземшаһка «бик мотыйглар» иде диелгән (39 нчы сәхифә). Тарих бу вакытта кангылылар берлә Харәземшаһ Мөхәммәд арасы бозык булуын күрсәтә. Сәмаркандта кангылылар берьюлы кырык меңләп үз

ихтимирлары берлә Чыңгыз бирелгәннәрен мөәллиф үзе дә шул ук сәхифәдә яза.

Гомумән, Чыңгызның Төркестан сәфәренә 4—5 сәхифә бирелеп тә, магуллар шәүкәте өчен әһәмияте аннан да ким булмаган Кытай сәфәренә ярты сәхифә дә бирелмәгән.

9. Казан ханлыгының тарихын башка вак ханлыклар арасына гына кертеп, аерым тукталмаган. Бөтен Казан ханлыгына башкалар арасында берничә юл бирелеп, шуның берлә генә үтелгән. Әсәргә фәнни бер әсәр дип фәнни ноктадан гына караганда, мөәллифнең бу эшен бер дәрәҗә сөкүт илә үтәргә мөмкин булса да, милли ноктадан күз алдында тотылып язылуы тиеш булган бер дәреслек өчен бу да гаептән саналырга тиештер.

10. Әсәрдә карап бетермәүдән килгән ялгышлар да еш очрыйлар. Мәсәлән, маҗарлар бер җирдә финнардан, бер җирдә төрек кабиләләреннән (25 нче сәхифә), бер җирдә һәм төрекләргә, һәм финнарга аерым бер асыл итеп тәлкыйн ителә. Әсәрнең 2 нче сәхифәсендә венгр вә маҗарлар бер-беренә башка ике халык дип аңларга мөмкин (дөрестә бу ике исем фин-угорлардан булган бер үк халыкның ике исемедер. Күлтәгин бер җирдә (10 нчы сәхифә) Билге каанның агасы дип, бер җирдә (12 нче сәхифә) энесе дип йөртелә (дөрестә — соңгысыдыр). Чыңгызның икенче улы Чыгтай, өченче улы Үгәдәйдер (36 нчы сәхифәдә ялгыш тәртиптә куелган). 37 нче сәхифәдәге «Төрек-магул гаскәре сугыш киемендә» дигән рәсем ни йөзе, ни тәне, ни киемнәре берлә төрек гаскәре дә, магул гаскәре дә түгелдер. Әсәрнең һәр битендә диярлек 6—7 матбага хатасы булуы да әсәрнең күркен җибәрә. Әсәрдә баштан актыгына кадәр бер имля сакланып барылмаган.

11. Әсәрнең теле матур түгеллеге, иләмсез вә ялгыш төзелгән җөмләләрнең байтак очравы да сөкүт илә узылырга тиеш түгелдер. «Шундый дошман кешеләр, кабиләләр Тимучинга атасының, бабаларының дәүләтен кайтарып алырга кыенлык (?) истигъмальдән халкын бик нык тойды», «Чыңгыз фәкать шамани мәзһәбендә торды, мәмләкәт һәм фотухат (?) һичбер динне тотмады, Тимер исә шаманилык (мәҗүсилек) өстенә (?) бик нык мөселман иде» (75 нче сәхифә) кеби сәер генә җөмлә вә мәгънәләр, «Ул үзе күчмә терэклекне бик ярата, халкының шул күчмә мәгыйшәттә булулары берлә бергә гыйлем вә һөнәрдә шәп һәм бай булуын теләде» (44 нче сәхифә) җөмләсендәге кеби сәхифәләрне ялгыш истигъмаль итүләр дә очрый.

Әсәрдә «Әй, сез! Минем гаскәрем! Сез минем кәпәчемнең өстенә тезелгән асыл зиннәтләр төслесез» (35 нче сәхифә), «Минем башыма төшкән авырлыклар» (36 нчы сәхифә), «Минем аркамдагы кабыргаларым» (43 нче сәхифә) вә башка шундый

җөмләләрдә яңа әдәбиятыбызда мәкъбүл вә мәгъруф «минем» сүзе урынына «минең» истигъмаль итүне архаизммы, провинциализммы дияргә аптырап калдык.

Югарыдагы җөмләләр, «минең» дигән сүзләр бөтенләй төшерелеп калдырылса да, җөмләләрнең татарчалыгы артып, тәрҗемәлеге югала гына төшә вә мисалга зарар килми бугай.

Хәзергә шулкадәр берлә тәмам итик. Билгеле, һәр әсәрнең яхшы ягы да, ятышмаган ягы да була. Тарих язу җиңел эш түгел. Хосусан безнең — төрек халыкларының тарихы башкаларныкына караганда да эшләнмәгәнрәк булуы бу юлда хезмәтне тагын да авырлаштыра төшә. Зәки әфәндедең әсәре күрсәтелгән җитешсезлекләре берлә алганда да, мәктәпләребез өчен дә, гомуми тарих берлә шөгыльләнүчеләребез өчен дә бәһасез вә кадерле бер әсәрдер. Монда бәгъзе җитешсезлекләр күрсәтелсә дә, алар әсәрнең әһәмиятен төшерергә тиеш түгел. Әсәрләрнең күбрәгендә андый җитешсезлекләр монда күрсәтелгәнчә кечкенә гадәтләргә генә сыймыйлар, аларның хаталарын күрсәтергә керешсәк, бөтен әсәрне яңадан язып чыгарга кирәк була. Татар матбугатында, тарихтан язылган әсәрләр эчендә андыйлар юк түгелдер, һәммә тарих мөхибләренә вә тарих мөгаллимнәренә әсәрне тәүсыя итеп, мөәллифне әсәре өчен тәшәккер итәбез, милли тарихыбыз бабында тагын җитди әсәрләр көтеп калабыз.

ИСКӘРМӘЛӘР*

1. Бу җентекләү иптәшләр учагы өчен язылган иде. Быел 2—3 җирдә милли тарих имтиханнарында булуым бу мәкаләнең матбугатка чыгуы кирәклеген миңа күрсәткән иде. Яз көне милли тарихтан тагын дәреслек язучылар булуын ишеттем. Алар да, мөгаллимнәр дә, әсәрнең мөәллифе дә яңадан бастырганда, бәлки, файдаланыр өмиде илә, әсәр [19] 15 нче елда чыккан булса да, җентекләүне матбугатка чыгарырга тиеш күрдем.

2. Быел җәй Зыя әфәнде Камали тарафыннан ачылачак мөгаллимнәр курсларының матбугатка чыккан программасында милли тарих дәресләре булмауны тәэссеф берлә укыдык.

3. Ризаэтдин хәзрәт үткән елгы «Шура»лардан беренең тышына: «...әмир Тимер тәрҗемәсен салкын кан берлә язуыбызга ышанмаганыбыздан бу көнгә кадәр «Шура»да баса алмадык. Безнең аңа булган үпкәбезнең бетү вә ачуыбызның аз гына да йомшау ихтималы юк...» — дигән (1915, № 18).

4. Шаманизм берлә танышырга теләүчеләр өчен русчадагы әсәрләр: *Базаров*. Черная вера или Шаманизм. — СПб.,1891; *Михайловский*. Шаманство. — Изв. Имп. Общ. люб. ест. — М.,1892. — Т.75; *Трощанский*. Эволюция черной веры у якутов. — Казань, 1902; *Валиханов*. Следы Шаманства у киргизов (в собр. соч., СПб.,1904); *Малов С.* О Шаманстве у Соргутуров (Жив. ст.,1912); *Радлов В.* Мифология и миросозерцание жит. Алтая, (Вост. обозр., 1882—1883); *Васильев В.* Изобретения Долгано-Якутских духов как атрибуты Шаманства, (Жив. ст.,1909); *Васильев В.* Шаманский костюм и бубен у якутов (Сб. музея по антр. и этногр. при Акад. наук, VIII, СПб.,1910); *Хангалов*. Новые материалы о Шаманстве у бурят (Иркутск, 1890). Монда бу турыдагы әсәрләрнең әһәмиятлерәкләре вә яңа танышучылар өчен әһәмиятләре тәртибенчә язылды. Бу турыда Азия вә Себергә сәяхәтнамәләрдә байтак мәгълүмат бар. Радловның «Төрек кавемнәренең халык әдәбияты нәмунәләре» вә Тамбуевның «Иске магул гадәт вә ышанулары» дигән әсәрләрендә шаманиларның бәгъзе догалары бар.

5. Иностранцевның «Һуннар — хуннулар» дигән әсәре каралсын (Жив. стар.,1900. — Вып. 3—4).

6. Труды Вост. Отд. Р. Арх. общ-ның 17 җилдендә Васильевның әсәре вә «Чыңгыз йортының яшерен тарихы» дигән әсәр каралсын.

7. Бу халыкларның төп төректән булуларын ислам мөәррихләре сөйлиләр, Һовард кеби галимнәр исбат иттеләр, Урхун язулары күрсәтәләр, боларны Кытай мөәррихләре «ша-ту ту-кю»дан (дала төрекләреннән) санйилар.

8. Иакинфның иске Кытай әсәрләреннән җыеп тәрҗемә иткән «Урта Азиядә торган халыклар турысындагы хәбәрләр» дигән әсәренең мөкаддимәсе каралсын.

9. Хуннуларның асыллары турысында Иностранцевның югарыда мәзкүр әсәре каралсын. Башкаларның әсәрләре хакында «Живая старина» (1904), Аристов әсәре каралсын.

10. Фазлулла Рәшидеддиннең «Җамигытъ-тәварих»ка мәдхәле; Галәветдин Җүвәйнинең «Җиһангир тарихы» дигән әсәрләрдә бу мәсьәләгә караш бертөрледер.

11. Труды Вост. Р. Арх. общ., Т.IV, стр.218.

12. Галәветдин Җүвәйнинең «Җиһангир тарихы»; Бартольдның «Магул дәверендә Төркестан», 2 нче җилд, 346—350 б.

13. Ул вакыттагы Багдад хәлифәсе Насыйреддин берлә Харәземшаһ Мөхәммәд арасы яхшы чагында Харәзем мәсҗидләрендә хотбә Насыйр исеменә укылып та, аралары бозылгач, Харәземшаһ башка берәүне хәлифә итеп игълан итүе вә хотбәне аның исеменә укыта башлавы мәсьәләсенең сәяси истикълалга мөнәсәбәте юктыр.

---

* Галимҗан Шәрәф искәрмәләре.

СҮЗЛЕК

асыл — тамыр, нигез, төп
экъваме Турания — Туран халыклары, төрки халыклар
эсас — нигез
эсатыйр — мифлар, легендалар язучы
эсәр: Гареб эсәре — Көнбатыш тәэсире
баб — бүлек, төр
бәгъзе — кайбер
бәдәви — күчмә гарәп
бер-берилә — бер-берсе белән
бүксәм — форма
вали — дәүләтнең бер өлкә идарәчесе, губернатор
васый — опека
гаид — бәйле
ганганә — легенда
гарби — Көнбатыш халыклар
җәгърафи шәкел — географик форма
җенес — раса
җилд — том
җөзьә — кисәк
игътираф җәмгъ — биредә: берләштерүче фактор, категория
игътираф итү — тану
иктифа — канәгатьләнү
илаһы вахид — бердәнбер Алла
имля — орфография
истикълал — фетнә
истилях — атама, термин
каан — каган, хан
кәйфиять — бер әйбернең үзенчәлекле рәвеше
кәмаләт — камиллек, тулылык
кәррат — кат-кат
кыйсем — бүлек, өлеш
ләүхә — күренеш
лисан — тел
лөзүм — кирәклелек
лябид — котылгысыз
манигъ — кыенлык, киртә
мәгъдән — җир асты байлыгы
мәгъруф — мәшһүр, билгеле
мәгыйшәт — көнкүреш, тормыш
мәдхәл — кереш
мәзкүр — әйтеп узылган
мәзһәб — биредә: дин
мәҗмуга — җыентык
мәнбәгъ — чыганак
мәрбут — бәйләнгән
мәүкуф — бәйле
мәхкүм — хөкем ителгән
мәхлукат — җан ияләре
мотыйг — буйсынучы
мөбаләга — арттыру
мөәллиф — язучы
мөәррих — тарихчы
мөкаддәм — әүвәл, элек
мөндәриҗә — эчтәлек
мөнсаб — елга коя торган урын
мөсави — тигез

мостәкъбәл — киләчәк
мөтәхассыйс — белгеч
мофассал — тулы, җентекле
муафыйк — ярашлы
нәху — синтаксис
сабит — исбатланган, ачык
сарыф — морфология
сәйях — сәяхәтче
сөкүт илә — әйтелмичә
сөлялә — нәсел, династия
тарикъ — юл
тәгъриф — билгеләмә
тәэссеф — ачыну, кайгыру
тәкъдис — изге дип ышану, изгеләштерү
тәлкыйн итү — аңлату
тәүсыя итү — киңәш бирү
тәфтиш — тикшерү
тәхриф — язылган сүзләрне үзгәртү
тәэкид — раслау
тугъры — дөрес
учак: иптәшләр учагы — иптәшләр төркеме
фәгалиять — эшчәнлек
фәргъ — тармак
фәрд — аерым зат
фотухат — яулап алынган җир
хадим — хезмәткәр
халикы көлли — чынбарлыкны яратучы
характерный — хас
харита — географик карта
Хәбәшстан — Эфиопия
хәләф — берәүнең эшен үзеннән соң дәвам иттерүче
хәсыр итү — багышлау
хәят — тормыш
Шәрык вә Гареб — Көнчыгыш һәм Көнбатыш
шималь — төньяк
яхуд — яки

ЧЫН БӘЯНЕ ТАРИХ ҮЗЕ БИРӘ

Гомер ничек кыска булмасын,
әгәр күп уйлансак, без озак яшибез.

П.Бауст

Мисыр мөселман реформациясе идеологы Мөхәммәт Габдуһ (1849—1905) бервакыт болай дигән: *«Сәясәт катышкан нәрсә исән калмый»*[1].

Чыннан да, бигрәк тә матур әдәбиятка һәм сәнгатькә берәр сәяси партиянең идеологиясе тәэсир итсә, ул әдәбият, ул сәнгать үлемгә дучар ителә. Моны XX гасыр башындагы язучыларыбыз, тәнкыйтьчеләребез яхшы аңлаган. 1908 елда Ф.Кәриминең «Хыялмы, хакыйкатьме?» дигән китабы нәшер ителгәч, анда сәяси партияләргә мөнәсәбәт мәсьәләсе беренче планга куелганына Ф.Әмирхан игътибар итә.

Ф.Кәрими монда «Иттифакы мөслимин»нән аерылып чыккан «Трудовая группа» вәкилләреннән үч ала. Ф.Әмирханга бу ошамый. *Авторның,* — ди ул, — *эш эшләрлек халкымыз арасында партия тәгассыбы* (катып калганлык) *таратырга тырышуына тәгаҗҗеб итми* (гаҗәпләнми) *кала алмыйм».* Элеккеге проза әсәрләре белән укучылар арасында яхшы танылган Ф.Кәриминең бу әсәренә тәнкыйтьче каты хөкем чыгара: *«Хәзер Фатих әфәндене милли мөхәррирлек сыйфатын тар милли, сәясилек сыйфаты тәмамән мәху итеп* (югалтып, бетереп), *партия мөтәгасыйбы бер кеше ясап калдырганлыгын, мәгаттәәссеф* (үкенечкә каршы), *бу әсәрен укып чыккан һәркем икърар итәргә мәҗбүр буладыр»*[2].

Әйе, әдәбиятка сәясәт катыштымы, ул исән калмый. Безнең гасырның 30 нчы еллар татар әдәбиятының фаҗигасенә дә сәбәп әнә шул. Менә нәкъ шул елларда әдәбият, әдәби процесс белән ВКП(б) өлкә комитеты җитәкчелек итә башлый.

Сталин идарәгә килүнең беренче елларында ук ВКП(б) җитәкчелеге зыялыларны команда постларыннан мөмкин кадәр читләштерергә, ә ахырда физик яктан кырырга, бетерергә тотынды. ВКП(б)ның Үзәк Комитетының бюро составын, дәүләт җитәкчелеген карасаң, анда ярым-йорты белемле кешеләр халык алдында идеологик эш алып баралар (Сталин, Калинин, Ворошилов һ.б.). Болар, ике-өч класс белемнәре барлыгын «онытып», язучыларны ничек язарга, композиторларны ничек итеп көй иҗат итәргә өйрәтә башлыйлар. Зыялылардан Сталин чорында гына түгел, Хрущев заманында да курыктылар. Ярым-йорты белемле

бичара Хрущев, никадәр генә крестьянча акыллы булмасын, язучыларны, архитекторларны, скульпторларны вакыт-вакыт гел орышып, ничек иҗат итәргә икәнен гел өйрәтеп торды.

Коммунистлар партиясенең бөтен сәясәтен коррупциягә әйләндергән Брежнев та зыялылардан курка иде. Хәтерлисезме? 70 нче елларда партиягә кабул итүнең нормаларын билгеләделәр: 9 эшчене алгач кына райкомнар бик сыкранып партия сафына унынчы кеше — укымышлыны алалар иде. *«Партия сафларына — эшчеләрне!»* — лозунг шул иде. Эшченең станок янында басып торасы, машина йөртәсе, урман кисәсе, күмер чабасы бар. Идеологиягә катнашырга аның вакыты калмый — җитәкчелек өчен нәкъ менә шул кирәк тә...

«Әдәбиятта, язучы кадрлар арасында эшчеләр катламын көчәйтергә!» — 30 нчы елларда ВКП(б)ның Үзәк Комитеты әнә шундый «юл» күрсәтте. Татарстан өлкә комитеты җитәкчеләре исә бу көрәшкә җиң сызганып ташланды.

Шул максаттан чыгып 1930 елда «Атака» журналы чыгарыла башлады. Татар телендә чыккан бөтен гәзит-журналларга, матур әдәбиятка һөҗүм көчәйтелде. Бу өлкәдә бигрәк тә «Чаян» журналы активлык күрсәтте. Партия өлкә комитетының беренче секретаре Разумов матбугатта, пленум-конференцияләрдә даими рәвештә татар әдәбияты мәсьәләләрен кузгатып торды. Аның чыгышларында төп ике тезис ярылып ята иде: 1. Үткәндәге әдәби мирасны (Тукай, Дәрдмәнд һ.б.) бастырып чыгарганда марксистик күзлектән чыгып эш итәргә. 2. Татар язучылары арасында эшче-крестьян катлавыннан чыккан кешеләр санын күбәйтергә.

Һәр ике тезиста бик күп нәрсә ачылмаган көе кала иде: Тукай, Дәрдмәнд әсәрләрен бастырганда марксистик күзлектән карау конкрет нәрсә ул? Әдәбиятка эшчеләр, крестьяннар түгел, бары тик иҗат итәргә сәләте булган талантлы кешеләр генә килергә тиеш бит инде, Разумов анысына да кагылмый. *«Әдәбиятка — эшчеләр!»* лозунгы матбугат битләрендә үзен тиз сиздерә. Дәрдмәнд, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Ф.Кәрими, Г.Исхакыйлар тудырган нәфис әдәбият урынына тупаслык, гайбәт, сүгенү, аламалык, шапшаклык кереп тула. Шул атмосферада татар язучылары арасында яшерен контрреволюцион «Җидегән» оешмасы турында хәбәр тарала. Шуннан соң әләкләр, берберенне сатып, үзең исән калу турында кайгыртулар, җыелышлар, чистартулар кебек җәзалар комплексы эшкә кушыла.

«Җидегән» исеме, имеш, аның составында җиде язучы булганга күрә бирелгән. Ләкин канга сусаган журналистлар, партия эшлеклеләре, *«без — эшчедән чыккан»* дип күкрәк киереп, шигырь, роман язган булып йөргән талантсызлар җиде белән генә канәгатьләнергә теләмиләр. *«Без — пырлитар язучылары»* дип күкрәк сугып йөргән урта кул язучы Л.Гыйльми, мәсәлән, аларның санын тугызга җиткерә: Г.Рәхим, Н.Исәнбәт, Т.Ченә-

кәй (псевдонимы — Сәмави), М.Бөдәйли, Ф.Бурнаш, Г.Кутуй, Н.Гальгаф, Г.Минский, С.Агиш. Кайбер әләкләрдә бу исемлеккә журналист З.Галине дә кертәләр.

1930 елның 31 августында ТАПП (Татарская ассоциация пролетарских писателей — Пролетар язучыларының Татарстан ассоциациясе)ның гомуми җыелышы булып, анда бик иркенләп «җидегәнчелек» мәсьәләсе тикшерелә һәм «тиешле» карар кабул ителә. Төп докладчы Г.Гали була. Җыелышта Т.Ченәкәйнең «Башкортстан», Ф.Мөбарьнең «Кызыл Татарстан» гәзитләрендә чыккан мәкаләләре, Г.Кутуйларның аңлатма язулары тикшерелә.

Җыелыш түбәндәге резолюцияне кабул итә:[3]

«1. Идән асты әдәби оешмасы булган «Җидегән», чыннан да, 1929 елның җәендә Өфедә оешкан һәм үзенең тәэсирен Казанга тарата башлаган. «Җидегән»нең инициаторлары Ченәкәй, Н.Исәнбәт, Г.Кутуйлар булган.

2. Фаш ителгән «Җидегән» үзенең формасы һәм алдына куелган бурычлары буенча матур әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә турыдан-туры партия сәясәтенә каршы юнәлтелгән, пролетариат әдәбиятына ачыктан-ачык дошман оешмасы булып тора.

ТАПП һәм пролетар җәмәгатьчелек «Җидегән»гә рәхимсез, хәлиткеч отпор бирергә, бу оешма һәм аның әгъзаларының чын сәяси физиономияләрен бөтен совет җәмәгатьчелеге алдында фаш итәргә тиешләр.

3. «Җидегән»нең эшчәнлегендә сәяси төс булуны Кутуй һәм Минский инкяр итсәләр дә, боларның «Җидегән»дә эшләүләрен ТАПП констатацияли, бу мәсьәләдә Кутуйның сәяси икейөзлелеген аерым билгеләп үтә.

ТАППның гомуми җыелышы Кутуй һәм Минскийны татар пролетар язучыларының ассоциациясеннән чыгарырга кирәк дип таба.

4. ...ТАППның гомуми җыелышы аның эшендә соңгы вакытта байтак зур кимчелекләр булганын билгели. Бу бигрәк тә түбәндәгеләрдә күренә:

а) матур әдәбиятта «Җидегән»нең йогынтысына каршы эшнең йомшак булуы;

б) ТАППның төп составын яңа кадрлар, эшче яшьләр арасыннан выдвиженецлар белән көчәйтү буенча җитәрлек эшләмәү;

в) сугышчан пролетариат әдәбияты рухында язучы эшче яшьләрне тәрбияләүгә игътибарның җитәрлек булмавы;

г) ТАПП җитәкчелегенең татар язучыларының төп массасыннан аерылуы һәм үз эченә бикләнгәнлеге.

ТАППның гомуми җыелышы ТАППта партия җитәкчелеген көчәйтү кирәклеген билгели.

5. Җыелыш ТАПП составына предприятиеләрдән күбрәк эшче яшьләрне тартырга, эшчеләр массалары арасында «Җидегән»

турында докладлар укырга, ТАППның сафлары арасында «чистарту» уздырырга, «Җидегән» турында татар һәм рус матбугатында материаллар бастырырга кирәк дип таба.

6. Н.Исәнбәтнең БАППта учетта торганлыгы турында әйтеп язган гаризасын искә алып, гомуми җыелыш бу турыда Башкорт пролетар язучыларының ассоциациясенә җиткерергә кирәк дип таба»[4].

Җыелышта Г.Минскийның хаты нигезендә Сафа Борһанның да «Җидегән»гә мөнәсәбәте барлыгы ачыла. Җыелыш С.Борһанның бу эшен киләчәктә тикшерергә, ТАПП идарәсендә пассив эшләвен исәпкә алып, аны идарә составыннан чыгарырга дип карар кабул итә[5].

Нинди хат соң ул Г.Минский хаты? Нигә бик еш телгә алына ул? Бу хат «җидегәнчелек эше»нә байтак ачыклык һәм шуның кадәр үк буталчыклык та кертә. Партия архивында бу хат саклана. «Җидегәнчелек»кә кагылышлы документлар арасында ул иң озыны, шуңа күрә без аны бераз кыскартып бирергә мәҗбүрбез. Бу хат «Кызыл Татарстан» гәзитенең редакторы исеменә 1930 елның 20 августында язылган.

«1928 елда мин Г.Кутуй белән, әдәби сәяхәт ясап, Уфага барып кайттым. Уфада кичә уздырылды. Уфаның әдәби көчләре белән аерым иптәшләр, очрашу тәртибендә булган сөйләшү-фикер алышуларда сизелерлек булып сызылган бу фикер куәтләнде: ул да булса без язучыларның оешып җитә алмавыбыз, берберебез белән хәбәрләшеп тора алмаучылык кеби зарлар нәтиҗәсендә бу фикер үзенә күрә бер «приключенческий» төс алып, «Җидегән» дигән бер төркем төзүгә кадәр килеп җитте. Бигрәк тә бу эшкә шагыйрь Ченәкәй аерым бер дәрт, теләк белән тотынды, һичшиксез, бу «Җидегән»нең кирәклеген көчәйтте. Әнә шуннан башлап «Җидегән» төзелде. «Җидегән»гә мин белгән биш иптәш керде (Ченәкәй, Кутуй, Н.Исәнбәт, Г.Минский, С.Кудаш). Калган икесе турында шуңар лаеклы булган «Җидегән»гә ярарлык кешене табу дигән фикер кузгалды. Бу фикер буенча Уфа шагыйре С.Агишның кандидатурасы күрсәтелүен дә хәтерлим. С.Агишның «Җидегән»гә керүе, эшләве турында моңар кадәр бернәрсә дә белмим.

...Оештыру эше тәмамланды, без кире Казанга кайттык. Мәсьәләнең тарихи ягын чуалтмас өчен, Уфада уздырылган кичәдә Мәскәү язучысы Г.Ильяс катнашуын әйтеп китәргә кирәк. Ләкин Г.Ильясның «Җидегән»гә бертөрле дә катнашы булмады, һәм ул аның турында белә дә алмады».

Бу — яңалык. Без озак еллар буе С.Батыевның Татарстан урта мәктәпләрендә тарих фәне укытучыларының семинарында ясаган чыгышына ышанып яшәдек. Ул анда болай дип әйткән иде: *«Без тикшереп карадык, бернинди «Җидегән» булмаган, бу — уйдырма, бу — язучыларны кырыр өчен генә уйлап табылган бер легенда...»*

Г.Минскийның хаты исә моны, С.Батыев фикерен инкяр итә, 30 нчы елгы версияне раслый. Бу безне, тикшеренүчеләрне, бик кыен хәлгә куя. Г.Минский ул чорда «Кызыл яшьләр», «Авыл яшьләре» журналларында эшли. Бу журналларда Г.Кутуй, Н.Исәнбәт, С.Кудаш шигырьләре басыла. *«Болар,* — ди Г.Минский, — *«Җидегән» принцибында түгел, бәлки басарга яраклы шигырьләр булулары өчен басылганнардыр. Ләкин, моның нигезендә пассив хәлдә булса да, «җидегәнчелек» энергиясе булуын бу урында яшереп булмас».*

Г.Минский, ахыр нәтиҗәсен һич тә күз алдына китермичә, «Җидегән»нең фактта булуын раслый. Ә җәзага сусаган Сталин козгыннарына шул гына кирәк: «оешманың» де-юре һәм де-факто яшәвен тану. Дөрес, тәҗрибәсез Минский әйтергә тели: монда бернинди «анти» юк, бу — болай гына... Ләкин 30 нчы елларда акны кара итеп күрсәтү караны ак итеп күрсәтүгә караганда җиңелрәк иде. Г.Минский хаты нәтиҗәсендә әнә шундый сәяси платформасы бөтенләй булмаган, рәсми яктан да формалашмаган, ләкин инде матбугатта сәяси төс алган бу оешма турында сүз китә. *«Караңгы төн уртасында караңгы бүлмәдә кара мәчене тоту, бигрәк тә ул анда булмаса, бик кыен».* Кайсыдыр халыкта, гарәпләрдәме икән, шундый әйтем бар.

Ләкин шулай да... «Җидегән»нең бөтен трагедиясе Г.Минскийның хаты аркасында дип уйларга тулы нигез бар. Ул болай яза:

«Җидегән» оешмасы оештырылса да, ул мине үзенә якынлаштыра алмады. Киресенчә, мин ул вакыттагы яшьләр матбугатында күренә башлаган сәламәт булмаган күренешләрдән качарга һәм, сыйнфый тәрбия ала алмаганда, богемачылык күренешләренә кереп буталуларга да мөмкинлекләр бар иде. Шуңар күрә дә мин Кызыл гаскәр сафына китәргә ашыктым һәм шул ук елны өч айдан соң ук Кызыл гаскәр сафына алындым. Шуннан соң «Җидегән» турында моңар кадәр бернәрсә дә белми идем, хәтта оныткан да идем, чөнки «Җидегән» ул үз асасында (нигезендә) сәяси бер зур төс бирү аркасында түгел, бәлки җиңелчә генә әдәбият мәйданында була торган каләмдәшлек, дуслык группачылыгы тәртибендә оештырылган иде».

«Минем бер гаебем бар, — дип дәвам итә Г.Минский. — *Ул да булса «Җидегән» турында матбугатта аның йөзен ачып (димәк, идеологик диверсия булган!) ташламау. Бу урында укучылар, бәлки, гаҗәпләнерләр дә... Ни өчен соң «Җидегән» соңгы вакытта зур төс алды? Ул миңа болай: Ченәкәй совет язучыларының оешмасында член иде. «Чистарту» вакытында Ченәкәйне чыгардылар. Ни өчендер (бәлки, Ченәкәй матбугатта әйтер) Ченәкәй ул вакытта ук Кутуй белән ераклашкан иде һәм аерым бер дошманлык сакларга тырышкан кебек сизеләдер иде. Кутуй ТАПП члены, гомумән, Кутуйның ТАППта член булуы турында дәгъва күптән башланган иде. Ченәкәй дә, әнә шул дәгъвага кушылып, Кутуйга каршы бара башлады. Моның*

өчен, ул оештырган «Җидегән»нең оешмасын казып чыгарып, аңа нур төс бирергә тырышып, Уфада матбугатка хат белән чыкты. Бу Ченәкәйнең үзенә күрә бер тактикасы иде. Хат белән чыгуга кадәр Ченәкәй Уфада «Җидегән»нең яшәве турында татар пролетариат язучыларының берсенә сөйләгән.

«Җидегән»гә бүген ничек карарга кирәк?

Бу мәсьәлә — бик мөһим һәм мәсьүл мәсьәлә. Әгәр дә без «Җидегән» турында аңар бөтенләй юк дәрәҗәсендә бәя биреп йә аны «балалык» дип атасак, бу — сәяси хата. Без моның белән фәкать совет дөреслегеннән күз йому, партиянең сыйнфый көрәштәге юлын йомшарту... буржуазия тегермәненә су түгү булып чыгар иде. Шуңар күрә дә бу урында «пролетариат диктатурасы дошманнары гына ачыктан-ачык советларга каршы барырга мөмкинлек булмаганда гына яшерен рәвештә эшләргә керешәләр» дигән аргумент бик дөрес һәм мәсьәләгә большевикларча карау тәртибендә әйтелгән бер сүз дип табып, «Җидегән»дә булачак хөкемнең беренче нигез сүзе шул булырга тиеш, дибез. Хәзерге көндә «Җидегән» мәсьәләсе кузгалу·уңае белән аңар төс бирмәскә, аны бөтенләй йомшартырга теләүче иптәшләрнең барлыгы сизелә».

Кыскасы, Г.Минский җиде-сигез язучының муенын бүкәнгә салырга чакыра. Хәтта алга таба Татар театрындагы зарарлы идеология турында сөйли, театрның «тотнаксыз» әсәр «Пикүләй Шәрәфи»не куюын (Н.Исәнбәт) гаепли. *«Бу әсәрне репертуарга алуда Кутуйның катнашы булды»*. Алга таба Р.Ишморатның «Данлы чор» әсәрен сәхнәгә кую, аның тирәсендәге ыгы-зыгы, шул әсәргә Г.Кутуйның тискәре мөнәсәбәте һ.б. театр интригалары турында языла. Г.Кутуй өстенә байтак гаеп ташлана.

Хәтта чираттагы корбан — «Кызыл Татарстан»ның редакторы С.Борһан.

«Сафа иптәш Борһанның «Кызыл Татарстан»да редактор булып эшләгән вакыты иде. Бу вакытларда мин яшьләр мәсьәләсендәге булган күренешләрне безнең матбугат башындагы җитәкче иптәшләребезнең әһәмият бирмәүләреннән, шул ук вакытта матбугатта күренә башлаган күңелсез фактлар (шул ук вакытта мин Дәрдмәнднең яңа басылу өчен билгеләнгән принципка каршы булып) турында Сафа Борһан иптәшнең үзенә генә хас булган бер хат язган идем. Ни өчендер ул башта минем хатны гәзиттә басарга җыенган булган, басмыйча калдырып, язу машинкасы аркылы күбәйтеп, шуларга (җидегәнчеләргә?) таратканы турында ишеттем... Логика турыдан-туры Сафа Борһанның «Җидегән»гә якын торуын дөресли. «Җидегән» ачылды.

Ләкин бу юлы ныклы көрәш кирәк. Бу көрәш тар бер рамка эчендә булмыйча, моңар кадәрге начар фактларның барысын тикшереп законлату тәртибендә барырга тиеш...

Бүгенге сыйнфый көрәш дәверендә пролетариат җәмәгатьчелегенең социализм фронтында катнашып үскән бервакыт-

та бөтен булган яшеренлек, группачылык... рәхимсез корытылырга тиеш... Мин бу көрәштә катнашачак иптәшләргә үземнең бар булган мәгълүматым белән ярдәм итешергә һәм кирәк булган тәртиптә матбугатта да, ТАПП каршында да җавапка чыгарга хәзерлегемне белдерәм. Г.Минский. 20 август»[6].

Инде матбугат органнарына күз салыйк. Кайда, кем, нәрсә яза? Әмма өлгерлек: август ахырында ТАППта мәсьәлә тикшерелә. «Чаян»ның август-сентябрь санында инде җидегәнчеләргә карата коточкыч сатира сурәтләнгән. Дөресрәге, сатира түгел, ә шәхесне мәсхәрә итү. Бу — бары тик сталинизм системасында гына була торган хәл. «Чаян»ның тышлыгында күсе рәсеме. Аның авызында «Җидегән» уставы. Шунда ук шигырь сыман бер тезмә:

Җиде күсе идән астында оя корганнар,
Күп еллар урлап совет икмәген ашап торганнар.
Тел очларында чума микробы барын белгәннәр,
Сөтләргә тыгылып, шушы микробны ташып йөргәннәр.
Нәсел-нәсәпле, һәйбәт токымлы
Бу җиде күсе хәзер тотылды.

Журналның эчендә «Астрономнар фикере» (янәсе, Җидегән йолдыз турында) дигән исем астында Г.Иделле, М.Гали, Ф.Мөсәгыйть, «астроном-профессор» Такташ фикерләре урын алган. Субәтәй псевдонимлы берәү «Җидегән» бәетен бирә. «Астроном-шагыйрь» Туфан фикере:

Демокритлар фәнне «алдадылар»,
«Бер атом да бетми» диделәр.
Бу дөньяда нәселе бетә торган
Материядән икән «Җидегән».

Мөсәгыйть бу уңайдан үз телендә булган бөтен ямьсез сүзләрне файдалана: *«Җидегәнчелек»*, — дип яза ул, — *Гаяз Исхаковларның пролетариат әдәбиятын сасытыр өчен түкмиенчә, үзләре эмиграциягә качканда совет өенең бер почмагына яшереп калдырган тәрәт чүлмәге. Ә җидегәнчеләр — шуның эчендә үсеп җитешкән хәшәрәтләр»*[7]. Шул ук көннәрдә аның «Кызыл яшьләр»дә «Гегемонлык өчен көрәштә җимерелгән «Җидегән» исемле зур мәкаләсе чыга. Ул әлеге төркемнең исемлеген бирә. *«Боларның бер-икесе партия члены, комсомол булса да, калганнары ачыктан-ачык вак буржуа вәкилләре»*, — дип тамга суга ул. *«Болар,* — ди Ф.Мөсәгыйть, — *ничек итеп тирес башыннан, завод корымы эченнән күтәрелгән малайларга ирекле рәвештә матур әдәбиятта юл бирсен! Нәкый Исәнбәт, Кутуйлар менә шулай уйлыйлар, менә шуңа күрә дә «Җидегән» оештыралар. ...бу бәндәләрнең оешуына тагын бер сәбәп — аяклары астыннан зәминнең китә, шуа баруын сизенүләре. Пролетариат кадрлар үскән саен, бу бәндәләр эри, югала баралар. Шәһрәт чәчәкләре сула, корый башлый... Кутуйлар матур әдәбиятны үз кулла-*

рына алмакчылар, үзләре генә яшәмәкчеләр. Пролетариат әдәбияты фронтында үсеп килгән яшь каләмнәргә астыртын ут төртәләр... «Җидегән»нең эчтәлеге пролетариат әдәбиятына каршы көрәш, пролетариат идеологиясенә каршы буржуа идеологиясен кую, кыскасы, матур әдәбият фронтында пролетариат диктатурасына каршы барудан тора».

«Җидегән»не ТАППтан куу гына Ф.Мөсәгыйтьне канәгатьләндерми. *«Аларның, —* ди ул, *— ВАПП составында торганнары да бар, аларын да куарга кирәк»*[8].

Әйе, «пролетариат»ка монда кизәнергә мөмкинлекләр зур. Кем ул Н.Исәнбәт? Мулла малае, мәдрәсә шәкерте. Җитмәсә, сатирик. Кем ул Г.Кутуй? Аңа тамга бер генә, имеш, фабрикант малае. Дөрес инде, фабрикант ук булмаса да, кулында эш биеткән кешенең малае. Кем ул Т.Ченәкәй? Аның бит псевдонимы да пролетарча түгел — Сәмави. Ягъни күккә ашкан. Ул бит чүкеч, домна турында язмый. Әнә аның «Күзсенмәсен бу бала» шигыре Йрек турында.

Ике бите аның алсу алма,
Күзе яна, йөзе нурлана;
Кашы кыйгач аның, күзе кара,
Күзсенмәсен иде бу бала.
Әлли-бәлли итеп ул уйнаса,
Изге фәрештәләр ярала.
Тел тибрәтсә, мең-мең серләр ача,
Сер чишмәсе инде бу бала.
«Ирек» дигән исем бирик аңа,
«Ирек» атлы булсын бу бала;
Кул күтәрик, йәгез, без боларга,
Мәңге яши күрсен бу бала,
Кул күтәрик изге бер догага,
Җир йөзендә калсын бу бала[9].

Пролетариат мондый шигырьне ничек гафу итсен?

Менә пролетариат шагыйре Мансур Крыймов. Донбасс шахталарына барган да, яхшы ук төшереп алгач, койма буенда төн кичкән. Шул ук «Чаян» моны эләктергән: *«Шагыйрьнең аяклары ревматизмлы»* дип, ул аңа сатира биргән[10]. «Ударниклар» журналы да бик усал. М.Крыймовның бер «шигыре»еннән өзек китерә, дөрес, мактап түгел:

Шагыйрьлекне
Зурлык санаучылар
Борынын күтәрсеннәр йолдызга;
Үсү юлыбызга
Файда бирсә —
Безнең өчен иптәш дуңгыз да...

«Пролетариат әдәбияты» менә шулай ул. М.Крыймов җидегәнчеләргә карата да бик принципиаль. Г.Кутуйга ул мондый «шигырь» белән бәрә:

Син сволочь!
Вузлар үтеп
Кеше булдың безнең җилкәдә[11].

«Чаян» шатлана:

ТАППның сафлары тазара,
Көчләр арта баралар.
Көч өстенә көч өстәлә: Толымбайлар,
Мостафиннар.
К.Рәхимнәр, И.Газилар
Һәм башкалар — күп алар[12].

Ә Ченәкәйне үтерергә кирәк! Кутуйны бетерергә кирәк! Ф.Бурнашны әдәбияттан алып ташларга кирәк! Йә әле, Мансур Крыймов, пролетариат шагыйре, бу юнәлештә ниләр эшли аласың? «Ударниклар» (Мәскәүдә чыга) журналы, 1930 ел, 4—5 нче саннар. Шигырь. Авторы — М.Крыймов. Шигырьнең исеме — «Атака». Кыскартып бирәбез:

Төннәр саен
Хан сараен
Кемнәр сагына?
Кем чылатып
Күзен ата
Төннәр ягына?
Фәтхи Бурнаш
Катгый боргач
Артка көймәсен,
Тыгылмасын,
Легендасын
Атка сөйләсен.
Кемнең анда,
Җыр язганда,
Куллары тала?
Ярты юлда
Әрнеп җылап,
Уе бутала?
Ул — Ченәкәй,
Кечкенә, кәй,
Адашып калган.
Юкны җырлап,
Куллары талган.
Тынчып чыккан
Толчокчыга
Кем җанын сата?

Г.Кутуйның «Базарда җан сатам» дигән футуристик шигыренә төрттерә:

Урталыкта
Бар халыкка
Кем һәйкәл сала?
Кайда сыйныф?
Тамгасы юк
Нигә бутала?
Бывший буржуй
Гадел Кутуй,
Шулмы сыйныфташ?
Чит дөньядан
Безгә калган
Ярты сынык таш...

13. С-107

Вульгар социологизмның иң актив лидерларыннан берсе С.Мортазин «Яңалиф» журналының 1931 елгы 1 нче санында болай дип яза: *«Диния нәзарәте, сыраханә, лото, алимент һәм чүп чарлар шагыйре Төхфәт Ченәкәй (Сәмави)»*. Ченәкәйгә ышаргә урын калдырмый Мортазин! Ченәкәйгә өмет белән караган тәнкыйтьче Г.Нигъмәтине дә бәреп ега ул әлеге мәкаләсендә.

Мөхәммәт Парсин (1899—1963) — журналист. Сталиннанниләр күрәсен әле белми. Бичара! Менә болай ди ул: *«Җидегән» — 1928 елда Уфада оешкан татар язучылары оешмасы. Оештыручылары: фабрикант улы Кутуй, сәүдәгәр улы Минский һәм динче-милләтче шагыйрь Ченәкәй. Бу оешмага член булып мулла малае Нәкый Исәнбәт һәм мәгълүм Зыя Камалиның кияве Сәйфи Кудаш керәләр, Агишев. Әлегә тикшерелмәгән хәбәрләргә караганда, бу оешмага Сафа Борһан да керә, имеш»*[13].

Г.Тләшев — шул еллардагы иң актив әдәбиятчы, журналист. Бу кеше бөтен жанрларда да эшли, ул үзен «пролетариат әдәбияты»ның чын, алдынгы вәкиле дип исәпли, еш кына башкаларны ярышка чакыра, ничек язарга өйрәтә (таланты булмаган «язучы», гадәттә, кеше өйрәтә). Г.Тләшев әле шәхес культы елларын кичеп исән калгач та (ул Чиләбе өлкәсе Копейск шәһәрендә яши иде) татар әдәбиятына кабат керергә омтылып карады, урындагы татар район гәзите типографиясендә ниндидер китапчык та чыгарып маташты. Ләкин татар әдәбияты томаналыктан айнып килә иде инде. Менә шул Г.Тләшев җидегәнчеләр турында болай яза:

«Оешма төзүдән максат югарыда фамилияләре күрсәтелгән бәндәләр әдәбият мәйданын үз монополияләренә алырга, социализм төзергә хезмәт итүдән тайпылдырып, шәхси интригаларга буйсындырырга тырышканнар, гәзит-журналларда фәкать үз әсәрләрен генә бастырырга булганнар. Пролетариат сафыннан чыккан яшь язучы кадрлардан көлеп, аларның җитешлекле әсәрләрен дә тәнкыйть итеп килгәннәр һәм берберсен вакытлы матбугатта мактарга булганнар. Бу бурычларны Уфада һәм Казанда практик эштә дә башкарганнар»[14].

Мәкаләне Г.Тләшев үзенең шигыре белән тәмамлый. Әйдәгез, карыйк әле, шәп шагыйрьме икән ул?

Безнең кайгы — көрәш кайгысы,
Безнең тойгы — сыйныф тойгысы.
Бүгенгене һаман сөймәүче чит элемент
Бүре булып һаман боексын!

Журналист Мирза Даутовның мәкаләсе дә канлы. Аның *«Милләтче кодалар һәм аларның партбилетлы кодагыйлары турында»* дип аталган әлеге язмасы «Ударниклар» жур-

налының 1930 ел, 4—5 нче санында басылган. Мәкалә татар әдипләре дөньясын бик нык бутау максатында язылган. Монда байтак гайбәт тупланган. Әйтик, ул Г.Кутуйның әле дә булса туганнары белән яшерен рәвештә бәйләныш тотуын яза. Бу зур гаеп икән. *«Әлеге, — ди ул, — ике җидегәнче билгеле түгел. Әйттерергә кирәк, әйтмәсәләр, әйттерә торган юллар бар»*.

Әйе, М.Даутов тәкъдим иткән методны без беләбез: репрессияләр вакытында Сталин ОГПУ-НКВД органнарына, сорау алганда әгәр гаепләрен танымасалар, *«физик тәэсир ясау максатка ярашлы»* дигән күрсәтмә бирә һәм үзебезнең фашистлар моны зур канәгатьлек хисе белән башкаралар: тоткыннарны ач күселәр тулы салкын подвалларга ябалар, бармакларын ишеккә кысалар, тешләрен сугып сындыралар... Моны соңрак М.Даутов, шәт, үзе дә татыгандыр. Г.Галигә дә өлеш чыга: ул җидегәнче Кутуйга тел тидермәскә чакыра икән. Тагын кемнең гайбәтен сатарга? Әнә Ченәкәй бар бит әле. Әнә ул авырып ятканда, ТАПП аңа йөзәрләп акча биргән, ә менә С.Баттал авырганда, аңа бирмәгәннәр. Бу турыда С.Баттал «Эшче» редакциясенә ТАПП өстеннән жалоба язган, имеш, *«бәлки, мин инде тора да алмам, әйтеп калырга кирәк барысын да»* дигән. Гайбәт яратучы автор шунда һич кирәксезгә С.Батталның «ТАППка ачык хат»ын бастыра:

Такташ — капиталист.
Өйрәнгән ул
Безнең ышанычны таларга.
Шахтер хисен
Нинди срок белән
Арендага бирдең аңарга?

М.Даутов, бөтен гайбәтне болгатып чыкканнан соң, ТАПП җитәкчелегендәге Г.Галигә катгый хөкем чыгара: ул, ди, милләтче кодаларның партбилетлы кодагыйлары...

Мәкалә басылып чыкканнан соң, «Ударниклар» редакциясе үзенең хатасын аңлый һәм алдагы санында ук моның төзәтелми, тикшерелми басылуын ялгыш дип таба.

1930 елның 2 сентябрендә «Красная Татария» гәзитендә берьюлы ике мәкалә басыла: «Политические уроки» «джидегановщины» һәм «За большевистское руководство».

Беренче мәкаләнең авторы псевдоним белән имза куя. С. Ар. мәкаләсендә 31 августта узган язучылар җыелышына, анда культпроп мөдире Г.Касыймовның чыгышына туктала, җидегәнчеләрдән Н.Исәнбәтне аерып ала. Алга таба Г.Касыймов та Исәнбәткә бер гаеп өсти. Ул.Г.Ибраһимовны классик дип танымый, ә менә ак эмигрант Г.Исхакыйны һәм гомеренең ахырына кадәр Совет властеның дошманы булып калган Ф.Әмирханны классиклар дип исәпли.

«Исәнбәтнең бөтен иҗатын анализлаганда, аның иң явыз дошман, аның бөтен әсәрләре Совет властена, пролетариат диктатурасына каршы икәнен, үзен совет әдибе дип атарга мөмкин булсын өчен аның кайвакытта формаль-советча әсәрләр белән чыкканын аңларга тиешбез. Исәнбәт әсәрләрен иң яхшы теләктән чыгып караганда да, безнең төзелеш өчен аларда бернинди уңай сыйфатлар табып булмый. Исәнбәтнең пьесалары совет чынбарлыгыннан ачыктан-ачык көлү һәм тоташ мыскыл итүдән тора.

Бу пьесаларны берәр Берлин театрчыгында татар эмигрантлары рәхәтләнеп карарлар иде. Чөнки бу пьесаларда татар буржуаз милләтчеләрен тәнкыйть иткән бер генә фраза да юк. Исәнбәт идеологиясе ул үзенең тамырыннан ук Гаяз Исхакый һәм башка акгвардиячеләр өеренең тамырдан безгә дошман идеологиясе...»

Г.Касыймов әйтә: *«Уфадагы беренче утырышта беренче сүзне Кутуй нәкъ менә Исәнбәткә биргән. Ул болай дигән:*

— Беренче почетлы сүзне бөтенебез тарафыннан ихтирам ителгән Исәнбәт агага бирәбез...

...Исәнбәт органик рәвештә партиянең теләсә нинди өлкәдә җитәкчелеге белән килешә алмый (һәм беркайчан да килешмәячәк тә).

...Исәнбәт, кискен моментларда коммунистларның эшне партиясезләр җилкәсенә салырга тырышуларын, кеше кулы белән утлы күмер чүпләргә яратуларын әйтеп, «Алласызлар союзы»нда эшләүдән баш тартты...

...Кутуй да аерым урын алып тора. Без аны бик озак вакытлар үз кешебез дип, безнең белән чын күңелдән бергә эшләргә теләүче, партиягә һәм Совет властена ярдәм итәргә теләүче дип йөрдек... Бу шәхестә без ачыктан-ачык сәяси хаинне, Совет властена ябышкан оятсыз карьеристны күрәбез...»

«За большевистское руководство» дигән мәкаләдә «җидегәнчелек» белән көрәш татар әдәбияты тарихына сыйнфый көрәшнең бер моменты булып, ләкин пролетариат әдәбиятына дошман тарафыннан тылдан әйләнеп үтелгән моменты булып кереп калыр, диелә. Мондый тәкъдим дә кертелә: уң оппортунистик һәм буржуаз-милләтче «солтангалиевчелек» тенденцияләре белән кискен көрәш башларга. Тайпылыш һәм агымнар белән килешүчәнлеккә шулай ук отпор бирергә.

Матбугат бу турыда әле бик озак шаулый. Белешмиләр: Г.Касыймов та, язучылар да үз-үзләренә чокыр казыйлар. 1937 ел килгәч, бу чокырга бер-береңне төртеп төшерү иң ансат эш булачак. Ялгышалар: Кутуйның татар зыялылары арасында дингә каршы кампания алып баруы, мәчетләрне яптыру өчен татар укымышлылары арасында 90 имза җыюы да[15], Ф.Бурнашның «Җидегән» өстеннән өлкә комитетына язган хаты да — берсе дә

ярдәм итми: барысына да кара тамга сугыла һәм барысы да диярлек төрмәгә озатыла...

Ф.Бурнаш хаты дигәннән... Бу — аерым мәсьәлә, һәм катлаулы, һәм аңлавы авыр булган мәсьәлә. Әллә моның нигезендә шәхси мөнәсәбәтләр генә ятамы? Театр бит авторларны сугыштыру, талаштыру өчен иң уңайлы мәйдан. Чөнки әгәр репертуарда синең әсәрең барса — синең тамагың тук, өстең бөтен. Әгәр синеке барса, димәк, теге авторныкы бармый. Димәк, теге — ач, ялангач. Театр исә бөтен авторны да берьюлы туйдыра алмый, ул һәрвакыт бер йә ике автор белән генә эшли. Әсәреңне сәхнәгә меңгерү өчен көрәш — сәнгать дөньясындагы иң рәхимсез, имансыз көрәшләрнең берсе. Бу көрәштә нык нервлы, планлы, рәхимсез авторлар гына җиңеп чыга. Җиңелгән автор алга таба инде беркайчан да беренче планга чыга алмый. Язгы чон вакытында ата пошилар арасында «кәләш» өчен коточкыч бер сугыш булып ала икән. Шунда җиңелгән поши, имеш, ялгызлыкка дучар ителә, бер җиңелгәнне икенче язны көрәшкә дә кертмиләр, имеш.

Гаҗәп, «Җидегән»не сәяси яктан иң нык гаепләп чыккан кеше — Ф.Бурнаш. Кайчандыр партия архивына караган фондларда аның бу турыда хатлары саклана. «Җидегәнчелек»не ул Украинада, Белоруссиядә, Казакъстанда «табылган» милләтчелек хәрәкәтләре белән бер бәйләнештә бәяли. Бурнаш нәкъ Сталинча яза. Аның фикерләре түбәндәгеләргә кайтып кала: капитализмның тамырларын актару, кулакларны сыйныф буларак ликвидацияләү процессында социалистик һөҗүмнең уңышлары сыйнфый көрәшнең кискенләшүенә китерә. «Җидегәнчелек хәрәкәте»нең иң характерлы сыйфатларыннан берсе шунда ки, аның кайбер вәкилләре үзләренең чын йөзләрен революцион фразеология белән каплау хәйләсенә ирештеләр. РАПП оешмасы язучылар арасында оппортунизм урнаштырды.

«Җидегән» — безнең партиябез уздырган әдәби сәясәт кысаларына сыя алмаган татар язучыларының оешмасы. Бу оешма әгъзаларының кайберләре — Кутуй, Кудаш (ул ВКП(б) әгъзасы), Минский (комсомолец) — алсу төскә буяныл эш иттеләр, шуның белән пролетариат әдәбияты өчен бу оешманың хәвефе тагы да артты. Бу оешманың илдә һөҗүмчән социализм нигезендә сыйнфый бәрелешүләрнең кискенләшкән, партиядә уң, оппортунистик тенденцияләр көчәйгән, милли окраиналарда «солтангалиевчелек», «Сәгъде Ваккасчылык» һ.б.) милләтче-шовинистик хәрәкәте көчәйгән чорда барлыкка килүе игътибарны җәлеп итә.

«Җидегән» ул — китеп баручы капиталистлар сыйныфы оешмасы».

И Бурнаш, Бурнаш... Алданиләр көткәнен белсәң иде син...

Ләкин хатны укыйк әле: *«...«Җидегән» әдәбиятта гына түгел, үзен театрда да күрсәтте. Г.Кутуй, Г.Минский театрның репертуарын, актерлар составын, режиссерларны билгелиләр иде.*

Алар кулы белән театрдан Б.Тарханов, С.Байкина, Р.Кушловская, Ф.Ильская, К.Шамил читләштерелделәр. Алар (Г.Кутуй, Г.Минский) инициативасы белән театрга Тинчуринның художество җитәкчелеге урнаштырылды. Тинчурин — буржуаз рухи бозыклык, милли көнкүреш тарлыгының вәкиле.

Рецензияләр һәм контроль тулысынча Кутуй карамагында иде. Театр һәм сәнгать турында «Кызыл Татарстан», «Безнең юл» битләрендә Кутуйдан узып беркем дә берни дә бастыра алмый иде.

ТАПП һәм аның җитәкчелеге Кутуй йогынтысы астында, ә Гомәр Гали, Сафа Борһан кебекләр аны бернигә дә карамастан яклыйлар иде. Кутуй ТАППта череп таркалган буржуаз язучылар — Такташ, Минский кебекләрдән үзенә «ядро» төзегән иде.

«Җидегән»гә кемнәр ярдәм итте?

Аларны ачыктан-ачык яклаучылар, һичшиксез, Сафа Борһан, Гомәр Гали, Газыйм Касыймов. Г.Касыймов үзенең чыгышында (Кызыл Татарстан, 1930, 2 сентябрь), Кутуйны телгә алмыйча, бөтен гаепне Исәнбәткә аударып калдыра».

Архивта Сафа Борһаннан кергән хат саклана.

«ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетына ВКП(б) члены Сафа Борһанның гаризасы.

ТАППның 29—31 сентябрьдәге (1930) киңәйтелгән утырышында кайбер иптәшләр минем исемне «идән асты» сәяси-әдәби «Җидегән» оешмасы белән бәйләргә тырыштылар. Моннан тыш Казан, Уфа һәм Мәскәүдәге кайбер иптәшләр пролетариат әдәбиятына дошман булган бу оешма белән бәйләнешем турында бик тырышып хәбәр тараткannары миңа мәгълүм.

Мондый җавапсыз җирәнгеч гайбәт минем иҗтимагый журналист һәм партия әгъзасы буларак дәрәҗәмне төшерә.

Контроль комиссиясеннән минем эшемне тикшерүне һәм реабилитация ясавын сорыйм.

Коммунистларча сәлам белән С.Борһан, 5.IX».

Безнең кулда С.Борһанның хатыны Мәрзия Борһанның 1964 елның 25 декабрендә авторларның берсенә язган хаты.

С.Борһан 1898 елда Уралдагы алтын приискаларының берсендә шахтер гаиләсендә туган. Беренче белемне шундагы амбар сакчысы булып эшләүче татар картыннан алган. Алар анда барлыгы сигез малай грамотага өйрәнгәннәр. Сафа прииская коногон булып, соңыннан металл заводында эшләгән. Йөкче дә булып эшләргә туры килгән. 1916 елда аны Верхотурьега укытучылар курсына чакыралар. Курсны тәмамлап кайткач, ул завод янында башлангыч мәктәп ачтыруга ирешә, шунда татар эшчеләренең балаларын укыта.

1919 елда аны, кызылларга хезмәт иткән дип гаепләп, аклар кулга ала. Әтисе аны «порука»га ала, 20 нче елларда ул Башкортстан комсомолын оештыручылардан берсе була. 1920 ел-

ның 1 октябрендә Эстәрлетамакта Башкортстан комсомолының I съезды ачыла. Сафаны Комсомол өлкә комитетының бюро әгъзасы итеп сайлыйлар. 1919—1921 елларда ул Партия өлкә комитетының Эстәрлетамак шәһәрендә агитпроп мөдире булып тора, аннан КУТВ да (Коммунистический университет трудящихся Востока) укый. 1923—1926 елларда партиянең Башкортстан өлкә комитетында матбугат бүлеге мөдире булып эшли. 1926 елда партия аны Казанга күчерә.

Казанда ул «Кызыл Татарстан»ның баш редакторы, «Красная Татария»нең баш редактор урынбасары булып хезмәт итә. 1936 елда кулга алынганчы «Известия» гәзитенең Татарстан буенча махсус хәбәрчесе була. 1920 елдан бирле партия әгъзасы С.Борһан бик күп китаплар авторы. 1936 елда кулга алына һәм 1937 елда һәлак була. 1957 елда реабилитацияләнә. Псевдонимнары: С.Танай, Т., С.Б., бер мәртәбә — Лялин (кызының исеменә охшатып).

Менә шундый «кызыл киселгән» коммунистның исеменә Г.Минскийның хаты нигезендә тап төшә һәм обкомда «Сафа Борһан эше» барлыкка килә.

Өлкә комитетының яшерен бюро утырышында (23 сентябрь) «Җидегән» мәсьәләсе карала. Көн тәртибе буенча докладны обком секретаре Б.Абдуллин башлый.

Абдуллин. Партия оешмасы бу төркемне үз мөнәсәбәтләрендә берсен берсе яклап пролетариат тәнкыйтенә каршы оешкан антипролетар төркем дип бәяләргә тиеш.

Баһаветдинов. Башында партиец һәм комсомолец торган бу оешманы антипартийный кешеләрне үзенә туплаган групповщина дип бәяләргә һәм аларны җәзага лаек дип исәпләргә.

Мөэминов. «Җидегән» кебек хәлләр бүтән кабатланмасын өчен, ТАПП сафына түбәннән кешеләр алып, аның эшенә яңа агым бирдертергә кирәк. ТАППта партия җитәкчелеген көчәйтергә, анда квалификацияле җитәкчеләр идарә итәргә тиеш.

Разумов. Безгә сыланган Кутуй кебек карьеристларның шәхесен констатацияләп, шуны әйтергә кирәк: түбәндә торган эшлекле иптәшләрнең тәкъдимнәренә колак салырга. ТАППның эшчәнлеген моңа кадәргегә караганда югарырак дәрәҗәгә күтәрергә, партиясез язучылар арасында партия оешмасының җитәкчелеген көчәйтергә. Милли шартларда интеллигенция линиясе буенча партиялеләр һәм партиясезләр арасындагы смычкага юл куймаска, чөнки алар арасында бу очракта аерма бетә (мисал — язучылар).

Азанова. ТАППны үз эченә бикләнгәнлеген (эшчеләрдән язучыларны вербовать итми) һәм ТАПП белән йомшак җитәкчелек иткәнен исәпкә алып, культпроп ТАПП җитәкчесе ип. Галиевне алыштырсак әйбәт булыр иде.

Вульфсон. ТАППтагы рус секциясенең эше катастрофик хәлдә булганын истә тотып, рус секциясен аның алдында торган

хуҗалык һәм сәяси бурычларга якынайтырга кирәклеген аерым пункт итеп күрсәтергә кирәк.

Разумов. Бу мәсьәлә буенча резолюция бар.

(Ип. Абдуллин резолюцияне укый. Резолюция раслана. Өстәргә кирәк: ТАПП мәсьәләсен өлкә комитеты бюросына куярга кирәк)[16].

1930 елның 6 октябрендә өлкә комитетының бюро утырышында ТАПП мәсьәләсе тагын карала. Монда Разумов, Мөэминев, Галиев, Яһудин, Касыймов, Еникеевлар чыгыш ясый. ТАПП сафларында 60 әгъза икәнлеге, шуның 50 проценты эшчеләрдән икәнлеге, басылып чыккан әдәбиятның 80 проценты тәнкыйтьтә чагылыш тапмавы әйтелә. Чыгыш ясаучылар ТАПП җитәкчелегендәге төп ике кимчелекне күрсәтәләр: 1) эшчеләр массасы белән элемтәнең җитәрлек булмавы; 2) эштә сизгерлек булмавы.

Касыймов. Татар әдәбиятында соңгы вакытта без торгынлык сизәбез. Бездә җитди әсәрләр юк... Аларны тудыручыларны без предприятиеләрдән эзләргә тиешбез.

Разумов (протоколда аны «татарча белми һәм татарча укымый» дип күрсәткәннәр). Миңа Галиев, соңгы вакытта татар әдәбиятының йөзе үзгәрде, дип әйтә. Ләкин хәл башкачарак. Кем дә кем хәзер колхоз һ.б. тема белән шөгыльләнә — болар юлаучылар, ягъни күтәрелеп чыгарга теләүчеләр. Колхоз турында иң әйбәт пьеса язган Бурнашев — уң оппортунист...

Бюрода ТАППның эше канәгатьләнерлек түгел дип табыла. Яңа кадрлар үстерү, пролетариат язучыларын туплау буенча ул бөтенләй начар эшли. *«ТАПП шактый дәрәҗәдә йомык интеллигентлар оешмасына охшап кала»*[17].

1930 елның 14 октябрендә өлкә контроль комиссиясе С.Борһанның контрреволюцион «Җидегән» оешмасында эшләү мәсьәләсен карый. Комиссиянең рәисе Г.Кудояров, әгъзалар И.Еникеев, Сакаев түбәндәге документларны тикшерәләр.

1. Г.Минскийның хаты. Бу хатта безгә мәгълүм булган информациядән тыш Г.Минский тагын бер факт китерә: *«С.Борһан,* — ди ул, — *татар буржуаз язучыларының (Дәрдмәнд) әсәрләрен бастырды. С.Борһанның «Җидегән»гә якын торганын логика үзе раслап тора».*

2. М.Даутов мәкаләсеннән өзек: *«Казанда бу оешманың җиденче әгъзасы С.Борһан дип сөйлиләр. Ә бит җиденченең кем икәне Казанда билгеле».*

3. Ф.Бурнаш хаты: *«Җидегәнчелекне ачыктан-ачык яклаучы кешеләр Сафа Борһан, Гомәр Гали һәм Газыйм Касыймовлар булды. Бу шәхесләр Кутуй һәм аның фикердәшләренең корткычлык эшләренә хәерхаһлык юлында еллар буе эш алып бардылар, аларның эш урыннары бу өлкәдә үзләренә ошаган бөтен нәрсәне дә алып барырга мөмкинлек бирә иде».*

4. Г.Тләшев мәкаләсе («Җидегән»нең безгә мәгълүм исемлеген бирә).

5. М.Парсин мәкаләсе (автор С.Борһанны шушы исемлеккә кертә).

6. Ф.Мөсәгыйть мәкаләсе (шулай ук).

Бу мәгълүматларны комиссия җитәрлек түгел дип таба һәм иптәшләрне аерым-аерым комиссиягә чакырта.

Г.Минский. Логика С.Борһанны шул оешмада торган дип расларга мөмкинлек бирә. Чөнки С.Борһан Г.Кутуйга бик нык ышаныч белән карый иде. С.Борһан бервакыт Г.Кутуйның мәкаләсен «укып тормастан да басарга мөмкин» диде. Редакция аппаратында Г.Кашшаф, Ә.Айдар кебек чит элементлар эшләде. С.Борһан, Татиздат директоры булып эшләгәндә, пролетар яшьләрнең әсәрләрен бастыруга зыян китереп, татар буржуаз классикларын бастырды. (Әңгәмәнең ахырында Г.Минский шулай да С.Борһанны «Җидегән»дә торган дип раслый алмавын әйтә.)

Г.Тләшев. С.Борһанның бу оешмада торуын мин Г.Минскийга таянып әйттем. Шулай да С.Борһан объектив рәвештә «Җидегән»гә ярдәм итте дип исәплим. С.Борһан пролетар язучылары Г.Тләшкә, М.Сөндеклегә ярдәм һәм игътибар күрсәтмәде, редакциядә эшләү өчен Г.Кашшаф, Әхмәров, Айдар кебек чит элементларны җыйды.

Г.Гали Г.Минский һәм Г.Тләшев фикерен сүзгә-сүз кабатлый.

К.Нәҗми. ТАПП фракциясенең комиссиясе «Җидегән» оешмасы әгъзаларының 51 хатын һәм телеграммасын өйрәнде. Бу язышулар арасында С.Борһанның әлеге оешмада катнашканлыгын расларлык әйбер табылмады. Ләкин С.Борһан Г.Кутуйга карата гадәттән тыш ышаныч белән каравы аркасында «Кызыл Татарстан»да пролетар язучыларының әсәрләрен пычрата торган («Данлы чор» — Р.Ишморат, «Ут» — Ш.Камал) рецензияләр бастырды, шуның белән җидегәнчеләргә һәм Кутуйга татар мәдәниятенә каршы көрәшергә ярдәм итте. (К.Нәҗми «Кызыл Татарстан»да чит элементларны файдалану фактларын шулай ук раслый.)

Кушаев. Кутуйның «Данлы чор»га рецензиясе С.Борһан редакциядән киткәч басылды.

С.Борһан. Кутуйга булган ышанычымны тулысынча раслыйм... Кутуйны коммунист язучылардан артык күргәнемне инкяр итәм.

Нәтиҗә

Язылган мәкаләләр белән дә, телдән бирелгән күрсәтмәләр белән дә С.Борһанның контрреволюцион «Җидегән» оешмасында торганлыгы расланмады. Төп гаепләүче Г.Минский үзенең элеккеге күрсәтмәләреннән баш тартты һәм бөтен эшне «логик нәтиҗәгә» генә кайтарып калдырды. Башка барлык мәкаләләр, нигездә, Г.Минский күрсәтмәсе аркасында язылган булып чыкты... С.Борһанның идеологик яктан «җидегәнчелек»кә якын

булуы расланмады. С.Борһанның Кутуйга артык ышаныч күрсәтүенең сәбәбе исә редакторның газитне яхшырту максатында үткән репортажлар артыннан кууы булган. Шул ук вакытта газиттә, штатта тормасалар да, чит элементлар файдаланылмый.

Контроль комиссиясендә материал биргән һәм мәкалә язган язучылар арасында аерым иптәшләрдән (Г.Касыймов, Г.Гали, С.Борһаннан) шәхси үч алырга омтылу тенденциясе сизелде. Моның ачык мисалы — партиядән чыгарылган кара эчле солтангалиевче Фәтхи Бурнаш хаты... Мондый хатлар Татреспубликада партия җитәкчелеген дискредитацияләү максатында язылганнар[18].

Резолюция

1. С.Борһанны җидегәнчелектә гаепләргә нигез юк дип санарга.

2. Г.Кутуйга карата артык ышаныч күрсәтүен әйтеп үтәргә.

3. ВКП(б) әгъзасы Мирза Давыдовның (Даутовның) ишеткән сүзләргә нигезләнеп кенә «Эшче»дә республиканың партия оешмасын «Җидегән» әгъзаларын яшереп калдыруда бернинди дәлилсез гаепләргә тырышуын күрсәтергә. Бу турыда тиешле оешмаларга җиткерергә[19].

ТАППны чистарту йомгаклары

Карар кабул ителде:

1. ТАППның эшен үзгәртеп кору һәм чистарту комиссиясенең нәтиҗәләре белән килешергә.

2. ТАППның җаваплы секретаре итеп К.Нәҗмине рasларга. Урынбасары итеп — Имаметдиновны.

3. «Атака» журналының редколлегиясен К.Нәҗми, Толымбайский, Каратаевлар составында расларга»[20].

Хуш, «җидегәнчелек» белән көрәшү татар әдәбиятына нинди файда китерде? «Түбәннән» күтәрелгән кешеләр фабрикант, мулла малайлары Кутуйлар, Исәнбәтләрне сәхнәдән алып ташлагач ниләр яза башладылар соң? Татар әдәбияты пролетарлаштымы?

Әйе, пролетарлашты. Моңа ирешелде, әйтик, пролетар язучы Г.Ильясның «Штык» повесте басылып чыкты. Әсәрдә вакыйга икмәк пешерә торган җирдә (пекарняда) бара. Төп герое — Шәмгун. Ул тырыш егет. Аның тырышлыгын (ипине мичкә тыкканда) автор болай сурәтли:

Тизрәк, тизрәк, тизрәк...
Удар!
Удар!
Удар!
Һәр ударникның эче — ягылган мич,
Һәр мичтә каен утыны — ялкын,

Һәр ударникның бите — икмәк бите,
Кәрәзләнеп аккан икмәк мае.
Һәр ударникның күзләре — кызыл бөре җыры,
Һәр ударникның ирене —
Шалтырап төшкән алсу каен күмере.

Беткәнче шулай. Бичара авторны талантсызлыкта гаеплисе урында аңа... сәяси ярлык тагалар. «Штык» контрреволюцион әсәр икән. Матбугатта чиле-пешле бу әсәр турында зур сәяси кампания башлана. М.Җәлил, Г.Төхфәт, Алфади имзалары белән «Коммунист» гәзитендә өч санга сузылып «Матур әдәбиятта контрреволюцион троцкийчылыкка каршы» исемле зур мәкалә басыла. Тәнкыйть объекты — «Штык». Әсәрнең редакторы булган М.Максуд «артка таба хут» ясый. *«Штык» китабы, объектив алганда, Кызыл Армиягә контрреволюцион троцкизмча пычрак яла яга торган әсәр дип бәя бирүгә мин тулысынча һәм бөтенләе белән кушылам,* — дип белдерү ясый ул. — *Әсәрне басарга яраклы табуым белән тирән сәяси хата эшләвемне бөтен кискенлеге белән икърар итәм»*[21].

Бичара авторга шуннан соң ни кала?

«Минем «Штык» дигән әсәремдәге хаталар турында» дигән мәкалә белән матбугатка чыга ул. *«Кешеләр күрсәткән бөтен хаталарны таныйм,* — ди автор. — *Ләкин болар аңлы рәвештә түгел, аңламыйча шулай эшләнгән»*[22].

Тагын берничә мисал. Әдәбият кая таба бара? Менә мондый әсәрләргә таба:

Октябрьнең көчле дулкыннары
Байларның җирләрен киметте.
Власть төште байлар кулыннан,
Изүле көннәр күздән тиз үтте.
Власть күчте хезмәт ияләренә,
Завод-фабрик, җирне алдылар.
Заводлардан, киң-киң җирләрдән
Бай нэпманнар мәхрүм калдылар.

Д.Фәтхи[23]

Бригадир дус,
Таза йөрәккә
Металл гөлен элик эрәтләп.
Йөрәк типсен,
Шул ук минутта
Алсуланып тусын гигантлар.

Ә.Ихсан[24]

«М.Сатай» имзалы берәүнең «Орлыклар» хикәясе. Шаблон: кулаклар колхоз амбарына ут төртәләр. Тасвир:

Биш минуттан соң —
Сары,
Эре,
Тук.
Су,
Орлык, пожар[25].

С.Латыйповның «Гөлкәйгә хат» хикәясе. Кызылармеец яза: «*Үпкәләмә, бәгърем, кайвакытта синең шомырт күзләреңне дә айлар буенча онытырга туры килә. Чөнки винтовкама булган мәхәббәт синең мәхәббәтеңнән катырак*»[26].

Яки МАПП (Московская ассоциация пролетарских писателей — Пролетар язучыларының Мәскәү ассоциациясе) чыгарган «Көрәш еллары» җыентыгы, А.Таһировның «Беренче көннәр» хикәясендә «*анаңны...*»; Г.Ильясның «Вахта» хикәясендә шкивлар «*маңка тыгылган борын кебек лышкылдап эшлиләр*». Шунда ук: «*Анасын... дип ачы сүгенде*». Хәтта ни әдәпле А.Шамов та «Лазаретта» дигән хикәясендә болай яза: «*Кая керәсең, анаңны...*»

Ш.Шәһәретдиновның рецензиясе Ә.Айдарның «Барабызлар турында» исемле шигырь җыентыгы турында. Тәнкыйтьче монда «зур хата» таба. Шигырьдә «*кызны ак каен, ялгыз ай белән сөйләштерү ул табигатьтән тыш бер көч бар дип ышандырырга тырышу була*». Безнең кызлар «*клуб, кызыл почмак, уку өйләрендә комсомол уставын өйрәнәләр, гәзит-журнал, китаплар укыйлар, социализм төзелеше мәсьәләләрен тикшерәләр*»[27].

«*Революцион бәйрәмнәрне үткәрү кичәләрендә сөю-сөешү җырларын җырлау булгалады*», — дип яза С.Сәлманов дигән берәү[28].

Такташка да бәйләнәләр: «Югалган матурлык» та, «Мәхәббәт тәүбәсе» дә ошамый формалистларга.

«*Такташ бу әсәрендә, хатын-кызларга бәя бирүдә «хатын-кызның бөтен матурлыгы ана булуда» дип, бөтенләй пролетариатка чит карашны җырлап чыкты*, — дип яза Г.Толымбайский, үзе төзегән беренче томына Г.Гали тарафыннан язылган сүз башын тәнкыйтьләп. — *Гомәр ... шуңардан күзен йома. Такташ хатын-кыз образын бирде, бөтен специфик яклары белән бирде, нык уңышлы әсәр бирде, ди. Хатын-кыз мәсьәләсендә төп карашы ялгыш булгач, ничек инде ул хатын-кыз образын бөтен специфик яклары белән бирә, «нык уңышлы» итеп бирә?*»[29]

Уралдан торып шагыйрьгә Г.Тләшев һөҗүм итә. «Югалган матурлык» авторы Такташка» дип атаган ул үзенең эпиграммасын.

Бик биек шул шөһрәт тавы, ай-йай биек,
Менеп булмый аллы-гөлле баскыч куеп.
Такташ абзаң, инде менеп җиттем дигәч,
Саз эченә лерт иттереп төште килеп[30].

«*Шүрәле*», «*Су анасы*»н яңалифчә басып чыгару урынсызрак диясе килә, — дип яза С.Самадов дигән берәү. — *Бу китаплар балаларны эш белән, тормыш белән кызыксындырмыйлар*». Автор фикеренчә, балаларга завод-фабрика, ясле турында язарга кирәк[31].

«*Комсомол кулакларны тәрбияләргә тиешме?*» — «Авыл яшьләре» журналына Н.Кәлимуллин дигән кеше шундый сорау

бирә. — *Ни өчен кулак, мулла малайларын мәктәпләрдән, комсомолдан куабыз да Совет иленә дошман ясыйбыз?»*

Яшь Ф.Хөсни җавап бирә: *«Кулакларны комсомолдан күн бияләй белән алып ташларга, алар анда тәрбияләнү өчен кермиләр».*

«Кулак балаларын буарга кирәк... Кулак, мулла балаларын якын китермәскә, киресенчә, алар белән көрәшне көчәйтергә»[33].

«Нинди дә булса бер сыйныфка хезмәт итмәгән әдәбият булырга тиеш түгел. Без дә ул пролетариат сыйныфы белән бер юлдан барырга тиеш. Сыйнфый бурыч онытылырга тиеш түгел»[34].

«Яңа ел — юк нәрсә. Безнең Яңа ел октябрьдән башлана... Безнең йолдызлар бриллиант кебек янмыйлар; ай да алтын нурын сипми, күл өсләре дә көмеш кебек ялтырамыйлар»[35].

«Кызыл яшьләр» журналы ТАППның сыйнфый составын игълан итә: партия әгъзалары — 51,5%, комсомоллар — 20,3%, партиясезләр — 26,1%. Социаль яктан: эшчеләр — 34%, крестьяннар — 38,4%, хезмәткәрләр — 11,4%, башкалар — 16%[36].

Яшь язучы И.Гази хикәяләрен тикшерәләр. Ф.Мөсәгыйть доклад ясый, *«И.Газиның сурәтләүләре авылча»* ди. Һәм мисаллар китерә. «Көмеш сулы Нурминкә» әсәрендә мондый җөмләләр бар икән: *«Аккош кебек күкрәк киереп йөргән мамык болытлар»; «Әнә аякларын өскә күтәргән сыер кебеге кәҗә, сарык, бозауга охшаган болытларны айкап, таптап узып китте» һ.б.*

Җыелышта чыгыш ясаган Г.Тләшев тагын да тирәнгәрәк керә. И.Газиның әсәрендә *«кояш чыга», «кояш бата»* дигән гыйбарәләрне мисалга китереп, авторны ул идеализмда гаепли. *«Бу, —* ди И.Гази, — *бик авыр гаеп. Ләкин мин үзем «кояш чыга», «кояш бата» сүзләре өчен берәүне дә идеализмда гаепләмәс идем. Дөрес, «кояш чыга», «кояш бата» сүзләре абсолют мәгънәдә алганда дөрес түгелләр. Чөнки кояш йөрми, ә җир әйләнә. Ләкин бит татар әдәби телендә идеализмда гаепләнерлек сүзләр бик күп. Мәсәлән, «Гыймай урам уртасында һичбер хәрәкәтсез тора иде» дигән җөмләне берәү дә идеализмда гаепләмәс. Ләкин бит бу җөмлә дә дөрес түгел, Гыймай урамда һич хәрәкәтсез тора алмый. Ул үзе хәрәкәтләнмәсә дә, җир шары белән бергә әйләнә, хәрәкәтләнә. Шулай булгач, «Гыймай урам уртасында һич хәрәкәтсез басып тора иде» дип язган кешене дә идеализмда гаепләргә кирәк»*[37].

30 нчы еллар башында татар әдәбиятын «большевизацияләү» өчен аяусыз көрәш башлана. Әдәби әсәрдә төп герой булып ударник, пролетариат вәкиле, комсомол әгъзасы торырга тиеш дип раслана. Бу тенденция Г.Абдуллинның «Литературная газета»да басылган «Татарстан матур әдәбиятын большевиклаштыру өчен»[38], М.Җәлилнең «Комсомольская правда»да басылган «Яшьләр әдәбиятын югары баскычка»[39] исемле мәкаләләрендә ягы-

лып ята. Дөрес, М.Җәлил образ тудыру процессындагы формализмга да каршы чыга. Ул Ә.Ерикәйнең бер шигырен мисалга китерә:

Герой, герой.
Нинди матур сүз,
Герой булу нинди күңелле.
Герой, герой.
Нинди матур сүз,
Герой булу матур түгелме?

«Герой» сүзен коры кабатлау белән андый сурәтне тудырып булмый» дип бәяли М.Җәлил[40].

Авыр идеологик атмосферада бик күпләр сынала. Кимсетелгәннәр генә дәшми. Үзенә «җидегәнчелек» яки «солтангалиевчелек» янамаган язучылар иманнарын сата башлый. М.Максуд «Эшче» газитендә бик нык һөҗүм итеп «Матур әдәбиятта эшчеләрдән кадрлар җитештерү турында» исемле мәкалә бастыра[41]. Ул анда солтангалиевчеләрнең исемлеген бирә. Болар: Ф.Бурнаш, М.Бөдәйли, Ф.Агиев, Г.Касыймов. Игътибар итик: болар барысы да Сталин корбаннары була. М.Максуд хәтта Ф.Әмирхан мирасына да кара буяу сала. Б.Мансуровның (1889—1942) Ф.Әмирхан иҗаты турында әйткән уңай фикеренә һөҗүм итеп, ул болай ди: *«Шул ук Мансуровның Фатих Әмирхан кичәләре үткәреп, милләтче шәкертләрне күкләргә күтәрүе... солтангалиевчеләрнең матур әдәбият фронтына нык игътибар иткәнлекләрен күрсәтә»*[42]. Ә.Фәйзи дә фәрештә түгел: С.Сүнчәләйне ул солтангалиевче дип гаепләп матбугатта чыга. С.Сүнчәләйнең нинди гаебе булган соң? 1919 елда шагыйрь «Интернационал»-ны тәрҗемә иткәндә бик күп гарәп сүзләрен кулланган икән. М.Максуд хаклы:

Бу булыр иң ахыргы, иң каты зур җиһад,
Булыр һәм бәйнәлмиләл бәни инсан азат!

Ләкин бит моннан контрреволюция эзләргә ярамый. Мәкаләнең исеменә генә игътибар итик: «Мөселманнар, шәһитләр бәйнәлмиләле»ме, әллә «пролетариат интернационалы»мы?»

«Бу «тәрҗемә»не, — ди Ә.Фәйзи, — *революциянең беренче елларында атаклы солтангалиевче Сәгыйть Сүнчәләй ясаган. Дөресрәк әйткәндә, ул аны «мөселманчылык» һәм милли «мөхтәриятчелек» кухнясында үз вирусына карап «пешереп» чыгарган... Ул «Интернационал»ны баштанаяк гарәпчелек белән сугарып, гарәпчелек астына гимнның революцион пафосын яшерергә тырышкан... Кыскасы, «тәрҗемә» бозык һәм кичекмәстән ул яңадан төзелергә тиеш»*[43].

Онытмыйк, С.Сүнчәләй бераздан «халык дошманы» буларак төрмәдә атыла.

30 нчы еллар татар әдәбияты тарихы бездә өр-яңадан эшләп чыгуны көтеп ята. Монда бернинди «культ»лар ясамыйча, бер

талантка да табынмыйча, ничек булган, шулай күрсәтергә кирәк. Л.Гыйльми, М.Давыдов (Даутов), М.Крыймов, Г.Тләшев, М.Максуд, Ф.Мөбарь, Ф.Мөсәгыйть, Г.Толымбайский, Г.Гали, Ф.С.-Казанлы, З.Гали, С.Борһан кебек каләм әһелләренең «пролетариат әдәбияты» өчен көрәштә кайсының ялгышып, кайсының аңлы рәвештә корбаннар соравын, кан коярга чакыруын бүгенге буынга җиткерергә кирәк. Тарихны бүген без язмасак, киләчәк буыннар барыбер язар; гәзит-журнал төпләмәләре, архивлар исән бит. Тик инде киләчәк буыннар бу тарихны язганда, 30 нчы еллар әдипләреннән бигрәк, бүгенге әдәбият галимнәрен гаепләп язарлар. Кандидат та, доктор да булганнар, әмма татар халкыннан әдәбият тарихын яшереп яшәгәннәр, диячәкләр.

Бүген бик күп зыялы безне тарихта казынмаска чакыра. *«Җитәр инде, кара таплар эзләмәгез, ник хәзер генә акыллы булып кыланасыз?»* диләр. Болай диючеләрне аңлап була: доноcлар, обком өчен язылган рецензияләр, үч алу өчен язылган кәгазьләр соңгы елларда теркәлгән архивларда да байтак. Аларны ача башласаң, кайбер иптәшләрнең урамга чыгып безнең арада йөрергә мөмкинлеге дә калмас иде.

Ә инде *«Ник элек дәшмәдегез?»* дигәннәргә карата тарихи бер факт белән җавап биреп була. Н.С.Хрущев партиянең XX съездында шәхес культы турында докладын тәмамлагач, президиумга имзасыз бер сорау килә. Анда болай язылган була: *«Сталинның бу хәлләрен белгәч, ник аны үз вакытында әйтмәдегез?»*

Н.С.Хрущев сорауны укый да залга мөрәҗәгать итә:

— Моны кем язды?

Залда тынлык. Берәү дә «мин» дип әйтми. Һәм шуның белән сорауга җавап та бирелә. Русча әйткәндә, «этим сказано все».

Үткәндәге хаталар, ул хаталарны ясаган кешеләр турында бүген язу кирәкме, юкмы? Шул ук Хрущев СССР Язучыларының III съездында: *«Аерым шәхесләрнең үткәндәге хаталарына кагылып, аларга даими рәвештә бармак белән төртеп күрсәтмәскә, ләкин онытып бетерергә дә ярамас»*, — дигән иде.

«Солтангалиевчелек», «Җидегән эше», бераздан «черек либерализмга каршы көрәш» — болар барысы да киләчәк трагедиянең генераль репетициясе булдылар. Бу елларда пáлачлар һәм булачак корбаннар ачыкланды, билгеләнде.

Алда канлы 1937 ел тора иде. Татар әдәбияты, башка милли әдәбиятлар белән чагыштырганда, бу елда иң күп корбан биргән мәйдан булды.

«Җидегән» исемле спектакльнең генераль репетициясен Партия өлкә комитеты һәм башка хакимият органнары шундый «шәп» башкарганнар. Әйе, сәясәт катышкан әйбер исән калмый... Чын бәяне тарих үзе бирә.

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Шура. — 1915. — № 23. — 732 б.
[2] Кызыл яшьләр. — 1931. — № 2.
[3] Кайбер пунктлары кыскартылып бирелә.
[4] ЦГАИПДРТ. — Ф.292. — Оп.1. — Ед.хр.1009. — Л.53.
[5] Шунда ук. — 50 б.
[6] Шунда ук. — 27—30 б.
[7] Чаян. — 1930. — № 8—9.
[8] Кызыл яшьләр. —1930. —2 сент.
[9] Кызыл шәрык. — 1921. — № 7—8.
[10] Чаян. — 1931. — № 1.
[11] Эшче. — 1930. — № 102.
[12] Чаян. — 1931. — № 4.
[13] Ялчы. — 1930. — 6 сент.
[14] Кызыл Армеец. — 1930. — 2 сент.
[15] ЦГАИПДРТ. — Ф.292. — Оп.1. — Ед.хр.1009. — Л.9.
[16] ЦГАИПДРТ. — Ф. 15. — Арх.788. — Оп.2. — С.168—169.
[17] Шунда ук.
[18] ЦГАИПДРТ. — Ф.292. — Оп.1. — Ед.хр.1009. — С.10.
[19] Шунда ук. — 11 б. Кыскартып бирелә.
[20] ЦГАИПДРТ. — Ф.15. — Оп.2. — Ед.хр.788. — С. 137.
[21] Коммунист. — 1932. — № 122.
[22] Коммунист. — 1932. — № 259.
[23] Ударниклар. — 1931. — № 11.
[24] Яңалиф. — 1930. — № 3.
[25] Колхозчы. — 1930. — № 32 (Самара).
[26] Колхозчы. — 1930. — № 59.
[27] Эшче. — 1929. — № 141.
[28] Туку. — 1929. — № 3.
[29] Коммунист. — 1932. — № 85.
[30] Сабан һәм Чүкеч. — 1929. — № 15.
[31] Эшче. — 1930. — № 33.
[32] Авыл яшьләре. — 1930. — № 6.
[33] Авыл яшьләре. — 1930. — № 8.
[34] Авыл яшьләре. — 1929. — № 10.
[35] Шунда ук.
[36] Колхоз яшьләре. — 1931. — № 2.
[37] Колхоз яшьләре. — 1932. — №1.
[38] Литературная газета. — 1933. — № 16.
[39] Комсомольская правда. — 1931. — 25 нояб.
[40] Ударниклар. — 1932. — № 3.
[41] Эшче. — 1930. —№ 26.
[42] Шунда ук.
[43] Коммунист. — 1932. — № 149.

«БОЛАК АРТЫ РЕСПУБЛИКАСЫ»

...Төнге тынлыкны каты шаку тавышы бүлә. Хезмәтче хатын, сискәнеп-куркып, ишеккә килә:

— Кем ул анда?

— Ильяс Алкин өйдәме? Аңа пакет! — дип җавап бирәләр һәм, үрелеп, ишекнең өске пыяла өлеше аша кәгазь күрсәтәләр.

Бикне ычкындыруга, ялт итеп башта Л.Гомәрев, ә аның артыннан С.Сәетгалиев, С.Урманов, Касыймов һәм башкалар — беренче һәм икенче рота солдатлары, егермеләп коралллы кеше — ишекне каерып ачып килеп керәләр.

— Чыгып китегез! — ди хезмәтче хатын, коты алынып. — Мине эштән кудыртасыз бит!

Аның сәясәттә эше юк. Аның бурычы — йорт-җирне җыештырып тору һәм саклау.

Өлкән кешеләрнең йокысы сак була. Өстенә чапан киеп, залга, төнге «кунаклар» янына, башта гаилә башлыгы Сәетгәрәй Алкин чыга. Аннары — уллары.

Йокысы бүленгәнгә җен ачуы чыккан улы Ильяс:

— Әһә, кулга алыргамы? — ди.— Көндез ярамас идемени? Качар бу, дип уйладыгызмы? Мин качмас идем.

«Кунаклар»ның бәрәңге борынлысы теләр-теләмәс кенә җавап бирә:

— Көндез ничектер вакыт җитми шул.

— Йә, ярый,— ди Ильяс, тынычлана төшеп. — Бер стакан сөт эчәргә рөхсәт итәрсез бит? Әйе, акт төзегез һәм шунда күрсәтегез: физик көч кулланганга гына буйсынам.

Сәетгәрәй абзый ихтыярсыздан көлемсерәп куя: кара әле син аны, егерме ике яшен яңарак кына тутырган улы үзен ничек итеп ир-егетләрчә тота. Юридик мәсьәләләр буенча этисе әйткән-өйрәткәннәрне, шөкер, күңеленә салып барган икән егет... Хәер, хәзер кая монда юриспруденция? Кемдә көч — шул хаклы. Көчленеке хәзер замана — бөтен хокук менә шул.

Ильясның абыйсы Җиһангир түзеп тора алмый:

— Сез үзегезнең нәрсә эшләвегезне беләсезме? Гомуми эшкә, милләткә хыянәт итәсез ләбаса! — Ул гасабиланып телефонга үрелә башлый, ләкин аңа ирек бирмиләр.

— Мәшәкатьләнмә,— диләр аңа.— Телефон инде кичтән үк өзеп куелган.

Госман Токымбетовны, Йосыф Мозаффаровны шулай ук, шул ук төнне «Бристоль» кунакханәсендә кулга алалар. Ә менә Сәлах Атнагуловны, Гата Баһаветдин ахунны, полковник Әкрам

Бигловларны кулга алырга өлгерми калалар — таң ата. Ул чакта бик алай иркен кылана алмыйлар: «эләктерү группалары» көпә-көндез эш итәргә халыктан шикләнә[1].

Тагын шуны да истә тотарга кирәк, полковник Әкрам Биглов — II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды тарафыннан төзелгән хәрби коллегиянең (һәйәтнең) башлыгы. Ул — анда хәрбиләрнең киләчәген кайгыртучы. Аңа, бәлки, кагылырга да курыкканнардыр, чөнки аны кулга алу тагын да көчлерәк ыгы-зыгы тудырыр иде. Большевиклар, Казан Советының, Мөселман Комиссариатының җитәкчеләре бу факторны искә алмаганнардыр дип әйтүе кыен. Совет тарафыннан уннан артык кешене кулга алу планлаштырылган була. Шул исәптән Н.Еникеевне, Рәмиевне һәм башкаларны. Бу мәсьәлә буенча да Совет әгъзалары бәхәсләшәләр һәм нәтиҗәдә биш кешене генә кулга алырга булалар.

Кулга алынганнар төрмәгә озатыла. Бу хәбәр яшен тизлеге белән бөтен шәһәргә тарала.

* * *

Кулга алынучылар кемнәр соң? Алар ни өчен кулга алынган? Әлеге мәсьәләгә ачыклык кертеп узыйк.

1918 елдан башлап озак еллар дәвамында Татарстан җөмһүриятен төзү һәм аның белән бәйләнгән вакыйгалар бер тар калыпка салып кына каралдылар. Моны аңлау өчен төрле елларда дөнья күргән, Татарстан һәм партия тарихына багышланган очеркларга, Татарстан Республикасының төзелүе яктыртылган мәкаләләргә һәм китапларга күз ташлау да җитә.

20 нче елларда ук «Болак арты республикасы» (алга таба, кыскартып, «БАР» рәвешендә язарбыз. — *Р.В.*) махсус язмаларда телгә алынып, аны Украина Радасы, Кырымдагы Врангель хөкүмәте, Дондагы казак автономиясе, Кавказдагы муссаватчылар, Кече Башкортстан, Коканд автономиясе, Олаш Орда белән чагыштырулар гадәткә әверелеп китә. Барысы да «Забулачка»ны буржуаз республика яисә контрреволюция оясы итеп карый. Югарыда саналган республикаларның чыннан да үз хакимият органнары, дәүләтчелек атрибутлары була. «БАР»га килсәк, аның территориясе бар, ә башкаласы юк кебек. II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съездының карары белән төзелгән Мөселман Совнаркомы бары берничә номер гәзит чыгарып кала, Совет тарафыннан куып таратыла. Гомумән әйткәндә, беркадәр дәүләтчелек атрибутлары төзелеп өлгерсә дә, алар нәтиҗәдә кәгазьдә генә калалар. Шул чорда Казанда яшәгән Җ.Вәлиди 1931 елның 10 июнендә сорау алу вакытында милли мөхтәрият «Идел-Урал» һәм «Болак арты республикасы» турында болай ди: *«Хәрби Шура Казанда, шулай ук Совет Русиясе эчендә мөстәкыйль хәрби көч буларак сакланды әле. Моннан соң Казанда кинәт «Идел-Урал өлкәсе» игълан ителде. Мин хәтта кайсы съезд тарафыннан һәм ул кайчан игълан ителгәнен дә белмим,*

лəкин хəтерлим: бу актның бернинди дə эффекты булмады... Бу вакытта аның гəзитлəренең берничə саны чыкты... «Болак арты республикасы» бетерелгəннəн соң, мине кулга алдылар һəм штабка китерделəр. Анда Шəһит Əхмəдиев миңа күп кенə үгет-нəсихəтлəр, күрсəтмəлəр əйтте. Мин аңа: «Сез матбугат ирегеннан бозасыз»,— дидем. Моңа ул үпкəлəде һəм: «Нəкъ менə ирек өчен көрəшүче партия турында сез ничек болай əйтəсез?» — диде. Мин анда барлыгы 5 сəгать булдым, аннан соң мине иреккə чыгардылар. Əхмəдиев миңа: «Ну, хəзер бар, иртəгə үк яңа гəзит чыгара аласың»,— диде. Шулай итеп, «Корылтай» урынына без «Алтай»ны чыгара башладык. Шуңа күрə «Болак арты республикасы»ның көрəш планы һəм билгелəнгəн политик платформасы булган, дип, һəм аны большевиклар алу белəн боларның бөтенесе дə пыр туздырылган, һəм ниндидер зур кискен үзгəреш (переворот) булган, дип уйларга ярамый. Юк, андый эффект булмады. Мин үзем, һəрхəлдə, андый кичерешне тоймадым. Əле ул вакытта берəү дə большевизм ныгып калыр дип уйламады, əгəр ныгып калса да, сүз һəм матбугат иреге яшəр, буржуазия яшəр, билгеле чиклəүлəр генə булыр'дип уйладылар... Мин «Болак арты республикасы» сүзен куштырнаклар эченə алып яздым, чөнки чынлыкта андый республика булмады. Дөресен əйткəндə, ул дəүлəт оешмасы түгел иде һəм аның бернинди хөкүмəте дə булмады»[2]. Хəер, чынлыкта аны «Болак арты республикасы» дип түгел, ə бары тик II Бөтенрусия мөселман хəрбилəре съездының дəвамы дип кенə карарга да мөмкин, əмма «БАР»ның бөтенлəй хакимият органнары, платформасы да юк иде дип əйтү дөреслеккə туры килми. «БАР»ның программасы, платформасы ул — Миллəт Мəҗлесенең, II Мөселман хəрбилəре съездының платформасы, чөнки алар барысы да бер мəсьəлəне хəл итəргə тырышалар. Аларның максаты: «Идел-Урал штаты»н тормышка ашыру. Бу проект — тирəннəн уйланып, фəн күзлегеннəн уздырып эшлəнгəн программа. Ə инде «хөкүмəте дə юк» дип əйтү — бөтенлəй дөрес түгел, чөнки болай итү II съезд тарафыннан төзелгəн һəм 15 кешедəн торган Мөселман Совнаркомының барлыгын күрмəмешкə салыну булыр иде. Аның «Идел-Урал өлкəсе» дип аталган үз гəзитенең дə ике саны чыгып кала. Эш шунда ки, акрын гына, сабыр гына, тавыш-гаугасыз, демократик юл белəн төзелеп килə торган мөселман (татар) дəүлəтчелеге хəрби көч тарафыннан тар-мар ителə. Əлбəттə, ике-өч атна эчендə Мөселман Совнаркомы əллə ни эш күрсəтеп өлгерə алмый. Бу табигый хəл. Ниндидер нəтиҗəгə ирешү өчен вакыт кирəк. Г.Исхакый Миллəт Мəҗлесенең 20 еллыгына багышлап язган мəкалəсендə бу турыда: *«Идел-Урал җөмһүрияте һəйəте Гаскəри Шүрə (*Вошуро яки Хəрби Шура.— *Р.В.) берлə бергə берлəшеп, апрель башында Казанда Идел-Урал җөмһүриятен игълан итүне хəзерлəгəн булса да, большевиклар ул вакытларда куəтлəнеп киткəнгə, бу эшкə имкян*[3] *бирмəделəр. Һəйəтнең Гас-*

кәри Шурә әгъзаларының күбесен тәукыйф иттеләр (кулга алдылар). Шуннан соң Мәскәүдән Казанга күндерелгән матрослар, латышлар Идел-Урал җөмһүрияте һәйәтен вә Гаскәри Шурәне тәмамән көчтән төшерделәр»[4].

Совет тарихчылары әлеге мәсьәләгә карата башлыча тискәре фикердә булдылар. Тарихчы А.Тарасов уйлавынча, «Забулачная республика» — ул бары тик революциягә каршы булган милләтчеләр оясы[5]. Тарихчыларның кайберләре «БАР»ны Совет хакимиятенә каршы фетнә яисә восстание итеп тә карадылар. Кайбер язучылар да шундыйрак караштa иде. Аерым алганда, Галиәсгар Камалның «Бер ел элек» шигыренә күз салыйк:

Бер ел элек чистарттылар Болак артын,
Кашыдылар «милләтчеләр» колак артын;
Буржуйларның аһларына колак салып,
Ярдәм бирүче булмады һичбер яртын[6].

Әфитсәрләр ашап йөреп байлар ашын,
Күз чыгарды — төзәтәбез диеп кашын,
«Сезгә без җөмһүрият бирәбез»,— дип
Әйләндерде «милләт байлары»ның башын.

Урам чатларына өеп бүрәнәләр,
Сугышырга мылтык уены өйрәтәләр;
«Җөмһүрият»не йотарга бирмәбез», — дип,
Түр башында, аш янында сөйләнәләр.

Уйлаганнар иде бугай хан куярга,
Яшел төскә һәрбер флагны буярга;
Сизеп алгач Совет аларның уйларын,
Бирмәде ирек бай малайларына уйнарга[7].

Соңрак татар зыялыларын «Забулачка», «Идел-Урал штаты» белән куркыту гадәткә кереп китә. Бу эшне партиянең Татарстан өлкә комитеты, тарих-партия бүлеге үз өстенә ала. Нәтиҗәдә «БАР»ның тарихын өйрәнүчеләрне, аның белән кызыксынган шәхесләрне ачыктан-ачык эзәрлекләү киңрәк колач ала.

Мингәрәй Сәгыйдуллин «БАР» турында махсус хезмәт әзерли. Октябрь революциясенең 10 еллыгына багышлап нәшер ителгән «Татарские трудящиеся на путях Великого Октября» дип аталган китапта «Забулачная республика» дип исемләнгән бүлек бар. Шактый зур күләмле хезмәт шул чорда чыгып килгән «Корылтай», «Йолдыз», «Безнең тавыш» гәзитләрен файдаланып язылган. Автор шулай ук үз карашы өчен кулай булган кайбер истәлекләрдән дә файдаланган. Әмма «БАР» турында уңай фикердә булган татар һәм урыс гәзитләре игътибардан читтә калган, М.Сәгыйдуллин алар хакында искә дә алмый. Ул чор өчен бу табигый хәл. Әйтергә кирәк, монда Сәгыйдуллинны гаепләп тә булмый. Әлеге язма югарыдан кушу буенча әзерләнә. Максат рәвешендә «БАР»ның чын тарихын язу түгел, ә бары тик анда катнашкан зыялыларның исем-фамилияләрен барлау, больше-

викларның гамәлләренә югары бәя бирү, бөтен гаепне, җитешсезлекләрне «милләтчеләр»гә сылтау бурычы куела... «Тарих-партия бүлеге» авторы конкрет юнәлеш бирә. Брошюра Н.Еникеевнең «БАР» хәрәкәтендә катнашу фактын төгәл ачыкларга ярдәм итәргә тиеш була. Әлбәттә, Сәгыйдуллин моның белән үзе дә килешә алмый. Бу аның Татарстан өлкә комитетына язган хатыннан бик ачык күренә. Хатта түбәндәге юллар бар: *«Әгәр мәсьәлә шулай куела икән (шулай куелырга тиеш тә), әгәр ОКК миңа бу фактны ачыкларга ярдәм итәргә тәкъдим ясый икән, мин бик теләп бу йөкләмәне башкарырмын. Мин брошюраны төзү өчен кулда булган барлык материаллар һәм мәгълүматлар белән уртаклашырга әзер. Ләкин шуңа күрә дә миңа тикшерү церемониясе һәм чакыру кәгазьләре (повесткалар) системасы һәм башкалар өчләтә аңлашылмый башлый. Болар фәнни-тикшерену эше тәртибендә эшләнә. Бу эштә миңа башка роль бирүне мин дөрес түгел дип саныйм һәм моңа минем ышанычым камил. Фәнни-тикшеренү эшен суд рельсларына күчерүнең һич тә кирәге юк»*[8].

Шулай итеп, Совет властеның беренче көннәреннән үк «БАР»-ның тарихын өйрәнү максат итеп куелмаган, ә бары тик большевикларның халыклар белән көрәшү тәҗрибәсе генә алгы планга чыгарылган. Чынлыкта исә милли азатлык өчен көрәшкән зыялыларны эзәрлекләү өчен материал җыю максаты гына булган, дисәк тә ялгышмабыз. Гомумән алганда, тарихи әдәбиятта бары тик «буржуаз республика җимерелде», «националистическая буржуазия», «Забулачная республика», «Забулачка», «милләтчеләр җиңелде» кебек сүзләр генә языла. Бөтен бәла-казалар, тәртипсезлекләр, уңышсызлыклар алар өстенә аударыла. Икенче яктан, советлар, большевиклар фиркасе, аларның хәрәкәте, аерым шәхесләрнең эшләре мактала. Янәсе, бары тик алар аркасында гына Казанда 1918 елда кан түгелмәгән, шәһәрдә тәртип урнаштырылган. Татарстан җөмһүриятен оештыруда да алар гына мактала, ә «милләтчеләр» дип аталган татар зыялыларының изге эшләре исәпкә дә алынмый. Искә алынган очракта да яманлап кына телгә алына.

Инде СССР җимерелеп, суверен дәүләтләр дөньяга чыгып, үз тормышларын үзләре кайгырта, үзләренчә яши башлаган чорда узганыбызга кайтып, аны яңабаштан өйрәнү өчен мөмкинлекләр туды. Гаделсезлек хакимлек иткән дәвердә игелекле эш-гамәлләр юкка чыгарылды, күп кенә зыялыларыбыз харап ителде, чит илләргә китеп югалды, махсус каралтылып, тарих битләреннән сызып ташланды. Хәзер аларның якты исемнәре, мираслары халкыбызга кайтарыла. «Болак арты» вакыйгасы чагылдырылган документлар да дөньяга чыгарыла башлады. «Гасырлар авазы» (Эхо веков), «Мирас» журналлары һәм башка басмалар бу юнәлештә зур эшләр башкаралар.

«Болак арты республикасы» хәрәкәтендә катнашучыларның

язмышларын өйрәнүдә дә юл башы тәгаенләнде, дияргә мөмкин[9]. 80 нче еллар башына кадәр Ильяс Алкин, Газиз Монасыйпов, Галимҗан Шәрәф, Җиһангир Алкин, Әкрам Биглов һәм башкаларның исем-фамилияләрен искә алу да куркыныч иде.

Иртәме-соңмы дөреслек өскә чыга. Үткәнебез безнең өчен сабак булырга тиеш. Кыенлыклар белән очрашканда, бәйсезлек үрләренә күтәрелгәндә, бу сабаклар бик урынлыдыр. «Болак арты республикасы» ул нәрсә, аны кемнәр оештырган? Алар нинди максат белән эш иткәннәр һәм нинди гамәлләр кылганнар? Бу сорауларга кыска гына итеп җавап биреп булмый. Чөнки Болак артындагы вакыйгалар — башка вакыйгаларның нәтиҗәсе. Шул сәбәпле «Болак арты республикасы» барлыкка килгәнче булып узган хәлләргә, вакыйгаларга күз салу зарур.

* * *

XX гасыр башында җәелеп киткән милли азатлык хәрәкәте 1917 елдагы Февраль, Октябрь инкыйлаблары нәтиҗәсендә тагын да югарырак баскычларга күтәрелде. Милли хәрәкәтне җитәкли алырлык зыялылар да, оешмалар да бар иде. Халыкның билгеле бер өлеше һәм аның күп кенә зыялылары социализм идеяләре йогынтысыннан читтә кала алмадылар. Хәтта кайберләре социализмны Аллаһы Тәгалә кушуы белән эшләнә дип аңлаттылар. Кем дә кем социализмга, Советларга каршы — шул Аллаһы Тәгаләгә каршы, дип әйтүчеләр дә булды. Гайнан Вәисев, инкыйлабка бәя биреп: *«Бу инкыйлаб Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән үсә ... туганнар ... сез социаль реформаларны тормышка ашырыгыз, Совет хакимиятен төзегез. Әгәр дә сез социализмга каршы бара калсагыз, сез моның белән Ходай Тәгаләнең үзенә каршы барачаксыз»*, — диде[10]. Күрәсең, болары инде үзенә күрә бер агым, «Дөреслек һәм гаделлек» партиясе буларак хәрәкәт итеп, социализмны Ислам белән бәйләргә тырышалар. Социализмны гаделлек белән тиң итеп карау тагын бер фикергә — социализмны милли гаделлек чоры итеп карауга китерә. Моңа турыдан-туры, сукырларча ышанучылар үз-үзләренә һәм милли хәрәкәткә бик зур зыян китерәләр.

Шул ук вакытта социализмга карата башка төрле караштаторучылар да була. Әле революция алдыннан ук, бу төркемне искә алып, «Корылтай» гәзите: *«Без большевик та була алмыйбыз... социализм кертер өчен бездә белем дә, әзерлек тә җитәрлек түгел... Без әле «социализм» сүзен генә түгел, ә «республика» сүзен дә быел гына ишеттек, ә «капитал» сүзен аңлый гына башладык. Без социаль революцияне генә түгел, ә чын сәяси инкыйлабны аңламыйбыз, әгәр дә безнең арабызда большевиклар булса һәм алар үз идеяләрен таратсалар, алар безнең милләтебезгә зур зарар китерәчәкләр»*,— дип белдерә[11]. «Йолдыз» гәзите, берләшүнең кирәклеген хуплап: *«Безгә, мөселманнарга, классларга аерылуны онытырга кирәк, чөнки безнең ара-*

бызда чын буржуаларыбыз да юк... әлегә кадәр без бергә бардык, хәзер дә бергә барырга тиешбез»,— дип игълан итә[12]. *«Милләт һәм сыйныф аерылмалары милли берлеккә комачаулый алмыйлар»*, — дип яза «Корылтай» гәзите[13]. Болары, большевиклар шаукымына исермичә, үз фикерләрендә кала алган.

Әлбәттә, милли хәрәкәттә башка төрле рухтагы агымнар да була. Алар күбрәк, урыска каршы булып, *«булсын — дәүләт, булсын — Совет, бары тик урыс кына булмасын!»* дигән фикерне алга сөрә.

Ул елларда милли хәрәкәт тупланган бер йодрык булып көрәшә алмый, агымнарга таркала. Совет хакимияте ныгыган саен, аның иярченнәре дә арта, демократларның күпчелеге, төрле лозунгларга ышанып, Кызыл байрак астына баса, ә аларга иярмәгәннәре, үз фикерләрендә торганнары, инкыйлабтан соң акрын-акрын дәүләт органнарыннан читләштерелеп, бераз вакыт узгач, лагерьларга, төрмәләргә җибәрелә. Менә шул вакытта инде «милли берлек» туа башлый, дисәк тә була. Монда большевик та, вәиси дә, милләтче дә — барысы да бер камчы белән кыйнала һәм теге дөньяга озатыла.

1552 елдан соң бәйсезлек, милли дәүләтчелек өчен башланган көрәшнең тарихы бик бай һәм гыйбрәтле. Татар халкының дәүләтчелеге харап ителгән, теле, әдәбияты һәм тарихы юкка чыгу хәленә китереп җиткерелгән. Моның бер дәлиле — гарәп шрифтын латинга, ә соңгысын кириллица белән алмаштыру. Бу инде мәдәниятле халыкны әлифбасы да булмаган халыклар хәленә калдырырга тырышу иде. Галимҗан Шәрәф бу хакта И.Сталинга язган хатында: *«Хәрефләрне алыштыру мәсьәләсе төрки халыклар арасында гомуми саннары берничә миллион исәпләнгән грамоталы һәм ярым грамоталы булган һәркемгә бик якыннан кагыла. Хәреф алыштыру мәсьәләсе — бу уку һәм язу процессында яңа күнекмәләр тудыру дигән сүз, ә бу, бик күп энергия һәм матди чыгымнар тотып, өр-яңадан укырга-язарга өйрәтү була... Абстракт рәвештә фикер йөрткәндә, хәрефләр алыштыру язма культура мәсьәләсендә чынлыкта бер халыкны элек яки бүген дә әлифбасы булмаган өммәткә төшереп калдыру дигән сүз, чөнки яңа графикага күчү элеккеге язмадан һәм язу күнекмәләреннән бөтенләй баш тартуга бәрабәр...»* Коммунистларга һәм аларга ияреп бу эшне тизрәк башкарырга теләүчеләргә бәя биреп, Галимҗан Шәрәф үзенең хатында болай дәвам итә: *«Милли коммунистлар арасында күпмедер «латинчылар» булуы чын вазгыятьне билгеләми, чөнки аларның барысы да диярлек якыннанрак танышканда йә төзәлмәс карьерачылар, йә үз карашларына җавап бирә алмый торган сай акыллы халык булып чыга»*[15].

Гасыр башында милли дәүләтчелек мәсьәләсе төрле гәзитжурналларда, җыелыш-корылтайларда, түгәрәкләрдә, уртага салып, төрле яктан өйрәнелә. Монда дөньякүләм тәҗрибә дә исәпкә алына. 1915—1916 еллар дәвамында Петроград шәһәрендә

укучы татар егетләре Галимҗан Шәрәф җитәкчелегендәге «Татар учагы» исемле студентлар җәмгыятендә төрек-татарның киләчәген, аның мәдәният-агарту эшләрен мөзакәрә итеп, төп мәсьәлә — милли дәүләтчелек һәм аның формалары турында фикер алышалар. Бу хәрәкәттә Г.Исхакыйның да өлеше зур була. Яшьләр олылар белән киңәшеп эш итә. Әдәбиятны, тарихны өйрәнәләр. Яңа мәкаләләрне татар һәм урыс телләренә тәрҗемә итәләр. Җәмгыять эшчәнлеге яшьләрнең милли-сәяси фикерләвенә зур йогынты ясый. Түгәрәк җитәкчесе Галимҗан Шәрәф, революцияләрдән соң узган бөтен корылтайларда актив катнашып, милли дәүләтчелекнең тупраклы мөхтәрият (территориаль автономия) концепциясен, «Идел-Урал штаты»ның, Татарстан Республикасының демографик һәм җәгърафия карталарын төзи.

И.Алкин, Хәрби Шура оештырып, милли полклар булдыра. Габдулла һәм Гани Абызовлар, Җиһангир Алкин, Солтанбек Мамлеев һәм башкалар милли хәрәкәтнең алгы сафларында баралар. Әлбәттә, болар берсе дә очраклы хәл түгел. Реаль фикер йөртүчеләр буларак, милли азатлык көрәшчеләренең күпчелеге федерация идеясен яклый, унитаризмга каршы көрәшә. Соңрак федерация идеясен большевиклар һәм Совет хакимияте үз идеяләре итеп алга сөрә. Әлеге факт үзбилгеләнү лозунгысына һәм «автономияләштерү» сәясәтенә ышанууга өлеш кертә.

Билгеле булганча, 1917 елның 1—11 маенда Мәскәүдә Бөтенрусия мөселманнарының I съезды була. Ә июль аенда Казанда өч съезд уза: беренчесе — Бөтенрусия мөселман хәрбиләре, икенчесе — укытучылар, ә өченчесе — мөселман руханилары корылтае. Өч съезднын берләштерелгән мәҗлесендә милли-мәдәни мөхтәрият (культурно-национальная автономия) игълан ителә. Корылтай карарларын һәм милли-мәдәни мөхтәриятне тормышка ашыру нияте белән мөхтәрият һәйәте дә сайланып, аның әгъзаларыннан С.Максудига — экстерриториаль автономия, ә Галимҗан Шәрәфкә тупраклы автономия хакында докладлар әзерләү йөкләнә. Әлеге һәйәткә шулай ук И.Әхтәмов, Ә.Мөхетдинова, Ф.Кәримов, К.Кәримов, Н.Хәлфин сайлана. Аңа Милләт Мәҗлесен чакыру, соңгысын уздыру мәсьәләләре дә йөкләнә.

* * *

1917 елның 20 ноябрендә Уфа шәһәрендә Милләт Мәҗлесе җыела, ә 22 ноябрьдә аның беренче утырышы була. Мәскәү җыелышында көрәш федералистлар һәм унитаристлар арасында барса, Казан съездларында милли мөхтәрият өчен көрәш җәелсә, Уфада төркичеләр һәм тупракчылар арасында көрәш башлана.

Милләт Мәҗлесе иң элек С.Мамлеев чыгышын тыңлый. Ул Совет хакимияте тарафыннан Әхмәдбәк Цаликовның Наркомнацка эшкә чакырылуы хакында хәбәр итә һәм Мәҗлестән бу очракта ни эшләргә икәнлеген сорый. Наркомнацта эшләү тәкъдиме кире кагыла һәм җыелыш Совет хакимиятен гомумән кабул итми[16].

Башка корылтайларга караганда, Милләт Мәҗлесе дәүләтчелек мәсьәләсендә тагын да югарырак баскычка күтәрелә. Аның тарафыннан «Идел-Урал штаты» проекты кабул ителә. Проектны тормышка ашыру өчен Галимҗан Шәрәф рәислегендә һәйәт төзелә. Бу составка Г.Ибраһимов, С.Атнагулов, С.Енгаличев, Ф.Сәйфи, Н.Хәлфин, Ф.Мөхәммәдъяров, Ш.Әхмәдиев, А.Сатиковлар керә.

Тиздән штатны игълан итү теләге белән «Идел-Урал» һәйәте махсус вагонда Казанга кайта. Һәйәтнең беренче утырышында ук аның президиумы сайлана. Аның рәисе итеп И.Алкин, ә урынбасары итеп Галимҗан Шәрәф расланалар. Утырышта Галимҗан Шәрәфкә «Идел-Урал штаты»нда хакимият төзелеше турында доклад ясарга туры килә. Милләт Мәҗлесе карарлары белән чагыштырганда, ул үзенең чыгышына үзгәрешләр кертергә мәҗбүр була. Беренчедән, Галимҗан Шәрәф «Идел-Урал штаты»н федерация эчендә автономияле республика итеп төзергә тәкъдим итә. Икенчедән, аның фикеренчә, хакимият органнары совет оешмасы буенча сайланырга тиеш була. Өченчедән, ул һәр советны, милли составны искә алып сайлау ягында тора.

Озакка сузылган бәхәсләрдән соң күпчелек Галимҗан Шәрәф тәкъдимнәрен кабул итә. Хәер, Галимҗан Шәрәфнең әлеге тәкъдимнәрен Милләт Мәҗлесе карарларын ревизияләү дип карарга ашыкмаска кирәк. Чөнки ул большевиклар хакимияткә килгәннән соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эш итә, ничек кенә булса да «Идел-Урал штаты»н тормышка ашыру өстендә эшли. Әмма тиздән Уфа һәм Казан матбугаты аркылы Дәүләт Думасының элеккеге әгъзасы И.Әхтәмов имзасы белән Коллегия рәисе Галимҗан Шәрәфкә *«Гомумхалык сайлаган Милләт Мәҗлесе өстенлекләрен бозган өчен»* шелтә бирелә.

«Идел-Урал штаты» коллегиясенең планнарын тормышка ашыруда Казанда уздырылган II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съездының әһәмияте зур. Съезд 1918 елның 8 гыйнварында ачыла. Аның эше 3 мартка кадәр дәвам итә. Совет органнары, шәһәрдә коткы чыгарып, халыкта курку һәм ризасызлык уятырга тырышалар, мөселман гаскәриләренең беренче җыелышы алдыннан ук аның җитәкчеләрен (бигрәк тә И.Алкинны) кулга алырга ашкыналар. «Йолдыз» гәзите бу турыда: *«Ләкин мөселман гаскәриләре әүвәлдәге шикелле башка милләтләр кулы астында уенчык булырга теләмәделәр. Без үз язмышыбызны үзебез хәл кыйламыз. Сезнең безгә, теге эшне эшләмәгез, бу эшне эшләмәгез, дип әмер итәргә хакыгыз юк»,* — дип яза[17]. Шулай итеп, большевикларның съезд алдыннан мөселманнарны талаштырып, җитәкчеләрен кулга алу теләкләре тормышка ашмый. Съезд бердәм рәвештә И.Алкинны съездның рәисе итеп сайлап куя. Милләт рухы белән яшәгән күпчелек аңлый: мондый мөшкел заманда ыгы-зыгы юлына басарга ярамый. Съездга килгән төрле милләт вәкилләре дә, мөселманнарның көчен сизеп, моңа шатлануларын ачык итеп әйтәләр. Бер вәкил: *«Энеләрегез чу-*

ашлар үзләренең агалары булган сез мөселманнардан ярдәм көтә», — дип әйтә. Шул сүзләрне ишеткәннән соң, бөтен залда алкышлар яңгырый. Чирмеш һәм мордва вәкилләре дә: *«Сез, мөселманнар, безне онытмагыз»*,—дип белдерәләр. Аларның сүзләрен хуплап, съездның рәисе И.Алкин: *«Без үзебезнең яшь туганнарыбызны онытмабыз, һәрвакыт бергә эш кыйлырбыз»*, — ди. Аннан соң Казан Советы рәисе Я.Шейнкман, шәһәр Думасы исеменнән Иванов, Казан губернасы земствосы (җирле идарә системасы) вәкиле В.Вегер, 95 нче полк командиры Ә.Биглов, большевик К.Грасис һәм башкалар чыгыш ясый.

Совет хакимияте вәкилләренең һәм большевикларның II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съездына һәм «Идел-Урал штаты» проектына карата булган хәрәкәтләрен аңлау өчен аларның съезд ачылганда әйткән сүзләренә игътибар итик. Аларның икейөзлелеге монда бик ачык күренә.

Шейнкман үзенең чыгышында: *«Без буржуалар белән бер эш тә кылмыйбыз. Алар безгә баш исеннәр. Без мөселманнарга үзләре теләгән автономияне алырга каршы тормыйбыз. Казан Советы аңа каршы тормый, шулай ук Халык Комиссарлары Советы да һәр милләткә үз язмышын үзенә тапшырырга разый була... Шура самоопределениегә каршы килмәскә вәгъдә бирә»*,— ди. Бу фикерне Иванов та куәтли. Ул: *«Мин монда халыкның куәтле оешмасын күрәм. Мөселманнарның үз язмышларын үз кулларына алырга чын хаклары бар. Алар үзләренең сәяси җәһәттән өлгергәнлекләрен күрсәттеләр»*, — дип өсти. Моңа каршы К.Грасис болай ди: *«Без Русиядә федерацияле җөмһүрият булуны мәгъкуль күрәбез. Моннан соң хәрабәгә әйләнеп беткән Русиядә мөстәкыйль дәүләтләр һәм аерым җөмһүриятләр генә булыр. Безне халыкның ирегенә каршы торучылар диләр. Ул сүз дөрес түгел. Хәзерге көндә Русиядә хөкүмәтне Учредительное Собраниегә тапшыру мәгъкуль түгел. (Сызгыралар.) Сез шуралар хөкүмәтенә ярдәм итегез. Шуның аркылы гына без социализмга ирешербез!»*

95 нче мөселман полкы командиры Ә.Биглов съездга килгән халыкны, гомумән алганда, бөтен съездны саклау өчен үзләренең җаннарын да кызганмауларын белдерә. Башка утырышлар вакытында да мондый чыгышлар дәвам итә.

Менә шулай итеп, II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды үзенең эшен уңышлы гына башлап җибәрә һәм 4—5 сәгать чамасы И.Алкинның докладын тыңлый. Ә икенче мәҗлестә тәбрикләүләр дәвам итә. Анда мөселман социалистлары исеменнән М.Солтангалиев тә чыгыш ясап, ул түбәндәге карашын ассызыклый: *«Бөтен дөньядагы милләтләр арасында иң күп таптталган, изелгән милләтләр — мөселманнар һәм мөселман дәүләтедер. Мөселманнарга һәммә җиһангирларга каршы тору тиеш. Русия мөселманнары, кадетлар артыннан барган шикелле, меньшевиклар һәм вак социал-демократлар белән дә бергә бар-*

масыннар. Хәзер Учредительное Собрание җыелды... Инде мөселман гаскәриләре, Учредительное Собрание большевиклар программасын кабул итмәсә, аңа ярдәм итмәячәкләрен әйтсеннәр».

Польшадан Хансов һәм Перовский чыгыш ясап, *«мөселманнар үз эшләрен үзләре башкарырга тиеш»* дигән фикерне хуплыйлар. *«Әгәр дә сез мөселманлыгыгызны онытмыйча, шулай бер союз белән барсагыз, һич шөбһәсез, максатыгызга ирешерсез,*— ди поляк гаскәре комиссары Перовский.— *Әгәр дә ярдәм кирәк булса, без, поляклар, сезнең белән бергә булырбыз».* Социал-демократ интернационалистлар исеменнән В.Вегер: *«Безнең партия һәр җирдә милли хакимият ясалуын мәгъкуль күрә»,* — дип белдерә. Казан мөселманнары исеменнән сүз алучылар арасында Ш.Әхмәров та була.

II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съездында катнашучыларның зур күпчелеге милли программаны тормышка ашыруны көн тәртибенә куюны вакытлы дип саный.

Ни өчендер М.Сәгыйдуллин: *«Өч көн буена сәламләүләрне генә тыңладылар. Чыгышларның күбесе Совет хакимиятенә каршы иде. Котлау сүзе белән Казан Советы вәкиле Грасис чыгыш ясады. Аңа сөйләргә ирек бирмәделәр, сызгырдылар»,*— дип яза[18].

Бу тулысынча дөреслеккә туры килеп бетми. Көн тәртибендәге күп кенә мәсьәләләр тикшерелә. Гомумән алганда, әлеге съезд Совет хакимиятенә карата бернинди каршылыксыз, киресенчә, аның рухында башланып китә. Казан Советының астыртын рәвештә съездга, Хәрби Шурага каршы хәрәкәте фаш ителгәч кенә мөнәсәбәтләр үзгәрә, Совет хакимиятенә ышаныч бетә башлый. Шулай булса да, съездның җитәкчеләре, әле съезд тәмам булганнан соң да, милли дәүләтчелекне төзү өлкәсендә булачак «уңышлар»га ышаналар, өмет белән карыйлар.

Съездда ике фракция барлыкка килә: социалист-федералистлар һәм сул социалистлар. Һәр фракция башында сайлап куелган бюро эшли. Социалист-федералистлар фракциясенә Н.Еникеев, Җ.Алкин, Атнагулов, Байков, Рәмиев, Г.Монасыйпов, Терегулов һәм башкалар керә. Сул социалистлар фракциясенә К.Якубов, Миникаев, Юмагулов, Асфаганов, Җиһаншин һәм башкалар керә[19].

Сул социалистлар фракциясе Казан большевиклары белән берлектә милли хәрәкәтне тар-мар итү өчен барысын да эшли. Казан Советы, большевиклар уңышларга ирешәләр. Шулай да аларның мәкерле эшләренең барып чыкмаган очраклары да булгалый. Мәсәлән, Казан Советы астыртын рәвештә Подвойскийга телеграмма җибәрә. Анда *«Казанга киләчәк мөселман бригадасын коралсызландырып җибәрегез»* диелә. Хәрби Шура тарафдарлары бу телеграмманы эләктереп алалар. Менә шуннан соң инде съездның сулышы, барышы үзгәрә. Казан большевикларының, Совет әгъзаларының чыгышлары татарларны үзбилгеләнү-

ле тормышка ничек керешергә кирәклеген өйрәтү кебек кабул ителә. Г.Токымбетов турыдан-туры болай ди: *«Әгәр дә сез безне ничек итеп үзбилгеләнүне тормышка ашырырга өйрәтергә телисез икән, белегез: безнең миллионлап штыкларыбыз бар!»*

Чыннан да, Хәрби Шура ягында, миллионлап булмаса да, шактый хәрби көч булганы билгеле. Мөнәсәбәтләр көннән-көн кискенләшә бара. Ике як та моңа үз өлешен кертә.

Съездны оештыручыларга карата әле съезд алдыннан ук теш кайрап, аның җитәкчеләрен кулга алырга теләгән Совет хакимияте һәм II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды делегатларының аңа ияргән сул канаты, Мөселман социалистлары комитеты (МСК) һәм Совет каршындагы мөселман комиссариаты әгъзалары үзләренең сәяси оппонентларын җиңел генә кулга алу белән җиңәргә булалар. Әлеге элек Романовлар династиясе кулланган алым большевиклар тарафыннан, ә соңрак тоталитар режим тарафыннан киң кулланыла. Шулай итеп, И.Алкинны, Г.Токымбетовны, Й.Мозаффаровны һәм башкаларны кулга алу планы туа.

Хәзерге вакытта бу вакыйгаларга башкачарак бәя бирү юлы ачылды. Әлеге фактны һәм февраль ахырында урнашкан кискен эчке сәяси вазгыятьне тирәнрәк аңлау өчен тагын бер тарихи эпизодка игътибар итик.

* * *

«Йолдыз» гәзитендә урнаштырылган «28 февраль вакыйгалары» дип аталган мәкаләдә түбәндәге юллар бар: *«Иртәгесен, 28 февральдә, Казан мөселманнары мәйданга вә окружной хәрби комитет тарафына җыелдылар. Бу мәҗлестә кулга алынган кешеләрне азат итүләрен дәгъва кылырга карар кылынган. Әгәр дә азат кылынмасалар, бөтен Казан мөселманнары, мәхбүсләр янына барып, үзләре азат кылырга әзер торалар иде»*[20]. Бу вакытта Екатеринская урамында 5—10 меңләп мөселман җыелган, мөселман штабы мәхбүсләрне азат итүне сорап Советка вәкилләр дә җибәргән. Казанда яшәгән мөселман халкы арасында зур ризасызлык туа, шау-шу, тәртипсезлекләр башлана. Астыртын эш иткән көчләр, киеренкелекне тагын да көчәйтү теләге белән, Совет хакимиятенә каршы көрәшергә теләмәгән, битарафлык саклаган вәисиләргә каршы коткы таратуны дәвам итәләр.

Вәисиләрнең штабы Нариман урамындагы йортта урнашкан була. Оешманың җитәкчесе Гайнан Вәисев яңа төзеләчәк җөмһүриятнең нинди булырга тиешлеге турында уйлана. Аның төпмаксаты — булачак җөмһүриятне «Татарстан» дип түгел, «Болгарстан» дип игълан итү. Хәер, әлеге максат беренче тапкыр Гайнан Вәисев тарафыннан түгел, *вәисиләр хәрәкәтенә* нигез салган этисе Баһаветдин әл-Болгари (1810—1893) тарафыннан ук куелган иде.

«Дөреслек вә гаделлек» фиркасе җитәкчесе Гайнан Вәисев өчен төнге кулга алулар көтелмәгән күңелсез вакыйга була. Килеп туган вазгыятьтә нинди юлга басарга? Ул шул турыда уйла-

на. Бу хакта фикер алышырга килгән Хәрби Шураның төбәк комитеты вәкиле Садретдин Йосыпов та *«Сез бу очракта нәрсә эшләячәксез?»* дигән соравына аннан җавап көтә. Гайнан, озак уйланганнан соң, үз оешмасының мәсләген болай дип бәянли: *«Без, газилар, орыш-талаш сукмагына басу нигезендә түгел, ә бәлки Хак Тәгаләне, динебезне саклау җирлегендә берләшү турында хыялланган идек. Һәрхәлдә, без Советларга каршы көрәштә катнашмаячакбыз».*

Йосыпов киткәннән соң озак та үтми, Гайнан Вәисев янына Хәйретдин Вәлиев килә. Ул хәрби шурачыларны кулга алу сәбәбе аркасында фетнә күтәрелә башлаганын әйтә. Советка каршы көрәшергә теләмәгәнегез өчен сезгә карата да янаулар ишетелә, дип кисәтә. Аның сүзләрен раслап, йорт янына фетнәчеләр төркеме җыйнала, кычкырыш, хәтта ату тавышлары да яңгырый. Гайнан ярсыган халыкны тынычландырырга теләп тәрәзәсен ача һәм урамдагы төркемгә мөрәҗәгать итә: *«Милләттәшләр, карендәшләр! Кемнәрдер сезне хата юлга кертергә маташа. Тынычланыгыз, өйләрегезгә таралыгыз. Газилар сезне хак юлга чакыра. Мин хәзер үк Советка барам һәм кулга алынганнарны азат итү чарасын күрәчәкмен...»*

Гайнан сүзләрен әйтеп бетерергә өлгерми, берничә җирдән аңа төбәп атып җибәрәләр. Гайнан Вәисев күкрәген тотып диванга ава һәм берничә минуттан җан бирә. Фетнәчеләр йортка бәреп керәләр һәм штабның астын өскә китерәләр, ваталар, җимерәләр[21].

Мин ул вакытта Казанда укып йөргән студент этием Вәлиев Кәлимулла Миңнулла улының сөйләвен хәтергә төшерәм. *«Казан урамнарында мылтык өстерәп баручы кешеләрне, хәтта малайларны күрдем»*,— дип сөйләгән иде ул. Этием алардан: *«Бу нинди мылтыклылар соң?»* — дип сорагач, аңа: *«Менә Гайнан Вәисевнең складын тараттылар. Кем нәрсә бар, шуны ала»*,— дип җавап биргәннәр. Күрәсең, бу Гайнан Вәисевнең яшел гвардиячеләр өчен әзерләнгән корал складының шулай җимерелүе-таратылуы булгандыр. Башкача әйтүе кыен. Бу факт та ахыр чиктә Совет хакимияте өчен кулай, чөнки каршы чыгарлык тагын бер төркем коралсызландырыла, бетерелә. Патша хөкүмәте 50 елга якын көрәшеп тә *вәисиләр хәрәкәтен* җиңә алмый. Ә бу очракта бер көн эчендә бар да тар-мар ителә.

«Хак Тәгаләне, динебезне саклау җирлегендә берләшү турында хыялланган» мөселманнарның Советка яисә большевиклар фиркасенә нинди зыяны бар соң? Гайнанның башкалардан аерылып торган максаты — Ислам байрагы астында мөселман дәүләтен төзү. Ә мондый хәрәкәтнең куркыныч икәнен Милхлар, Грасислар аңламагандыр дип әйтеп буламы? Алар өчен бу хәрәкәт Совет властена таянып, «Идел-Урал штаты»н төзергә теләгән КУВШтан («Урал-Идел штаты» коллегиясе — Коллегия Урало-Волжского штата.— *Р.В.*), Ә.Биглов җитәкләгән Хәрби коллегиядән, И.Алкин җитәкчелек иткән Хәрби Шурадан һәм II Бө-

тенрусия мөселман хәрбиләре съездыннан да куркынычрак бит. Ни өчен соң әле алар атаклы төрки-мөселман хәрәкәте лидерын, дин әһелен атлы казаклар, кызыл гвардиячеләр, Казан Советы инкыйлабчылары белән бергә Кремльдә җирлиләр? «Знамя революции» гәзите купшы некрологлар яза. Социализмга юл тоткан сәясәткә, фиркаләргә Ислам диненең дә, исламчыларның үзләренең дә һәм аларның җитәкчеләренең дә кирәге юк. Гайнан Вәисевкә шундый «хөрмәт» күрсәтелгән икән, бу — чираттагы мәкер; ул милли хәрәкәтне таркатуга юнәлдерелгән. Рәсми хакимият милли дәүләт төзергә, әлеге ниятне тормышка ашырырга теләүчеләрнең бер йодрык булып каршы чыгуыннан шүрли. Күмү вакытында яңгыраган залп тавышлары еракларга ишетелсә дә, Гайнан Вәисев җитәкләгән хәрәкәт тиз арада Совет хакимияте тарафыннан тар-мар ителә.

Казан мөселманнары һәм мөселман хәрби штабы вәкилләре кулга алынганнарны иреккә чыгаруны таләп итәргә килгәч, Казан Советы карыша алмый, әмма алар алдына шартлар куя. Әлеге шартлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт. Беренчедән, бөтен мөселман оешмалары Советларның учредительный съездына кадәр «Идел-Урал штаты»н оештыру юнәлешендә бернинди чыгышлар вә хәрәкәтләр ясамаска. Икенчедән, Казандагы хакимият тулысынча һәм бары тик эшче, крестьян һәм солдатларның Казан Советы, Казан мөселман комиссариаты (Казан Советы каршындагы.— *Р.В.*) кулында гына тупланырга тиеш була. Башка барлык мөселман оешмалары бетереләләр. Мөселман комиссариатыннан гайре бер генә оешма да үзенең комиссарларын билгеләргә, вәкилләрен җибәрергә, фәрманнар бирергә хаклы түгел, диелә. Өченчедән, барлык хәрби көчләрнең мөселман эшләре буенча комиссариат карамагына күчүе күздә тотыла. Дүртенчедән, кулга алынганнарның мөселман социалистлары җаваплылыгында иреккә чыгарылуы тәкъдим ителә. Бишенчедән, таратылган, бетерелгән мөселман оешмаларының әгъзалары бар көчләрен Вәисевне үтерүчеләрне фаш итүгә юнәлдерергә, гаеплеләрне табарга булышырга, шулай ук Совет хакимиятенә каршы көрәштә катнашкан студентларны һәм офицерларны табып бирергә вәгъдә итәргә тиеш булалар.

Бу шартлар белән ризалашалар, чөнки килгән вәкилләр большевикларның тупас, кырыс гадәтләрен, аларның бернинди кануннар белән исәпләшмәвен беләләр. Халык әйтмешли, *«бүре оясында бүре булып уларга туры килә»*. Шулай эшлиләр дә. Мөселманнарның вакытлы революцион штабы рәисе Г.Монасыйпов, әгъзалардан Таһиров, Еникеев, Габдрәшитов, Исхаковлар шартнамәгә кул куялар. Нәтиҗәдә кулга алынганнар иреккә чыгарыла. «Йолдыз» һәм башка мөселман гәзитләре бу «килешү» белән үзләренең канәгать булмавын белдерәләр. Мәчетләрдә, митингларда бу хакта ачык итеп әйтелә. Кулга алулар тактик як-

тан большевикларга беркадәр вакыт отарга мөмкинлек бирә һәм II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды эшенә өстәмә кыенлыклар тудыра. Делегатларның бер өлеше беркадәр каушап кала, солдатларның күбесе демобилизациягә әләгү ягын карый. Әмма иң аянычы 1 мартта «Идел-Урал штаты» төзелүне игълан итүне өзү була.

Әлбәттә, хәрби корылтай җитәкчеләрен кулга алулар да, вәисиләр җитәкчесе Гайнанны үтерү дә үзара нык бәйләнгән һәм тирәнтен уйлап эшләнелгән мәкер, явыз коткы (провокация) буларак бәяләнергә тиеш. Беренче вакыйганы (кулга алуларны) Казан Советы, ревком оештырган. Ә икенчесен? Соңгы сорауга әлегә җавап юк. Шулай да, Гайнан Вәисевне үтерү турындагы җинаять эшенең бик тиз (1920 елда) «ябылуын» искә алсак, күңелдә икенче бер шөбһәле сорау туа: бу «эш»не ябарга нигә шулай ашыктылар икән? Болай итү кемнәр өчен файдалы булган соң? Киләчәктә яңа документлар табылган очракта, бәлки, моның да сере ачыкланыр дигән өметтә калабыз.

Ул вакытта килеп туган авыр хәлне аңлау өчен, әлеге вакыйгаларның нәкъ уртасында булып, соңыннан алар хакында истәлекләр язып калдырган М.Солтангалиев язмаларына игътибар итик. II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды җитәкчеләре кулга алынуны тулысынча хуплап, М.Солтангалиев Советлар хакимиятенең бу гамәлен болай аңлата: *«Съезд җитәкчеләре «Идел-Урал штаты» төзелү турында белдерергә карар иттеләр. Большевикларның Казан губерна комитетының ашыгыч киңәшмәсе җыелды. Анда мин һәм иптәш Сәетгалиев тә катнашты. «Нәрсә эшләргә?» дигән сорау куелды. Киңәшмәдә иптәш Шейнкман рәислек итте. Иптәш Сәетгалиев аларга республика төзелүне «игълан итәргә» мөмкинлек бирү ягында торды. Чөнки аның фикеренчә, бу кешеләр барыбер власть, җитәкчелек эшләрен башкара алмаячак. Мин киресенчә уйладым. Төгәл итеп әйткәндә, әгәр без «штат төзүне игълан итәргә» мөмкинлек бирсәк, анныары инде аны «төзәтергә» соң булачак, дидем. Мин түбәндәге фикерләрдән чыгып эш иттем: а) Татар дәүләтен игълан итү татар халкында милләтчеләр файдасына кискен борылыш ясавы мөмкин; б) без ул вакытта коралльı конфликт юлына баса алмый идек, безнең (*ягъни Советларның. — *Р.В.) Казанда кораллы көчләребез юк иде диярлек, ә Хәрби Шура татар солдатларының санын Казанда гына да 60—80 меңгә кадәр җиткерә ала иде. Менә шуңа күрә дә инде мин милләтчеләр тарафыннан «штатны» игълан иттермәскә һәм алдан кисәтү чарасы итеп хәрәкәтнең җитәкчеләрен кулга алуны тәкъдим иттем».*

Дөреслек күзлегеннән караганда, большевикларның һәм Казандагы Совет хакимияте әгъзаларының күпчелеге каршылыкны тыныч юл белән хәл итү өстендә эшлиләр. Грасис, Шелыхманов, Милх кебекләр әлеге күпчелеккә керми. Ә шулай да бу мәсь-

әләне тыныч юл белән хәл итүне бары тик большевиклар гына кулай күргән дип әйтү хата булыр иде.

Солтангалиевнең мондый тырышлыгы милли дәүләтчелек мәсьәләләрен башкачарак хәл итү өчен Казан Советы алдында яңа мөмкинлекләр ача. Шуны да истән чыгарырга ярамый: бу вакытта М.Солтангалиев — ревком, ревштаб әгъзасы, 1918 елның февраленнән апрель аена кадәр, ягъни «Болак арты республикасы» һәм «Идел-Урал штаты» белән көрәшнең хәлиткеч чорында, ул — Казан Совнаркомы әгъзасы да[22].

Большевиклар җитәкчелегендәге Совет хакимияте четерекле милли-сәяси мәсьәләләрне көч куллану юлы белән хәл итүне кулайрак күргән. Кызганычка каршы, Солтангалиев кебек талантлы «милли большевиклар» да үз милләттәшләренә карата башлыча шундый ук чаралар күрүне хуплаганнар. Танылган тарихчыбыз Мидхәт Мөхәррәмов II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды җитәкчеләрен кулга алуны Казан Советы оештыруын дәлилле итеп исбатлады[23].

Югарыда әйтелгәнчә, Хәрби Шура җитәкчеләре Казан Советы тарафыннан Мәскәүгә (Подвойскийга) җибәрелгән телеграмманы кулга төшерәләр. Анда Казанга килергә тиешле мөселман полкын юлда коралсызландыру кирәклеге әйтелгән була; янәсе, мөселман полкы коралланган килеш Казанга килеп төшсә, «милләтчеләр»нең хәрби куәте артачак, бу исә Совет хакимиятен куркыныч астына куячак. И.Алкин Казан Советының бу мәкерле коткысын II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съездында фаш итә. Нәтиҗәдә съезд әлеге телеграмманы юкка чыгарырга, аңа имза куйган Шелыхмановны эшеннән азат итәргә, Казан Советын яңадан сайларга, мөселман полкының имин килеш Казанга килеп җитүен тәэмин итәргә дигән карар кабул итә. Бу карарга хәтта съездның сул канатын тәшкил иткән татар социалистлары һәм большевиклары да кушылалар. Әмма карар тулысынча үтәлми: мөселман полкы имин килеш Казанга килеп җитсә дә, шәһәр Советына яңа сайлаулар уздырылмый, Шелыхманов та үз эшендә кала, аңа шелтә бирү белән чикләнәләр. Шулай да бу факт Совет белән көрәштә беренче җиңү буларак бәяләнерлек вакыйга була.

Шул ук вакытта Казан Советы милли хәрәкәтне таркату эшчәнлеген дәвам итә. Әлеге юнәлештә ул 1918 елның гыйнварында ук барлыкка килгән ЧК (чрезвычайная комиссия — гадәттән тыш комиссия) белән берлектә эш итә. ГубЧК колачын киң җәелдерә, Казан Советының тикшерү-юридик комиссиясе әгъзасы И.Фролов аеруча активлык күрсәтә. Ул шулай ук «Болак арты республикасы» белән көрәшү өчен төзелгән революцион штабта губЧК вәкиле булып тора[24]. ГубЧК яшертен рәвештә үз агентларын «Болак арты»на җибәреп, агитация эшләрен башлый.

Чекистлар шактый уңышка да ирешәләр. М.Хәсәнов дигән бәндә үзенең истәлекләрендә разведчик буларак, Болак артына

чыгып, дружинниклар арасында эш алып барганлыгы турында яза. Ул аларны Совет ягына чыгарга өнди, аларга губерна мөселман комиссариатының, Казан Советының адресларын калдыра[25].

Шул ук вакытта Казан Советы ашыгыч рәвештә Хәрби комиссариат төзү өстендә дә эшли. Әлеге гамәл, әлбәттә, Совет каршындагы хәрби коллегияне алмаштырып, бер яктан, иске армияне демобилизацияләү, ә икенче яктан, яңа көч — Кызыл Армия төзү максаты белән башкарыла. Нәтиҗәдә хәрби оешмалар, шул исәптән Хәрби Шура да, Мөселман хәрби коллегиясе дә һәм башкалар да бетерелеп, бары тик кызыл комиссариатлар гына калырга тиеш була[26].

Бу көннәрдә «Знамя революции» гәзите битләрендә Троцкийның һәм Подвойскийның мәкаләләре басыла. Аларда Советлар белән армия арасындагы элемтәләрне ныгыту турындагы мәсьәлә күтәрелә. II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды тарафыннан фаш ителеп, Советтан гына түгел, Казаннан ук куылырга тиеш булган И.Шелыхманов Казан губерна Советы хәрби комиссарларының берсе булып раслана[27]. Казанда Хәрби Комиссариат 3 марттан ук эшли, ә Ленин хәрби комиссариатлар турындагы декретка бары тик 8 апрельдә генә кул куя. Димәк, бу гамәл, «Болак арты республикасы»на һәм Хәрби Шурага каршы юнәлдерелеп, соңыннан бөтен илгә тарала.

«Болак арты республикасы» тирәсендәге вакыйгаларның кискенләшкән көннәрендә 95 нче мөселман полкы комитеты Үзәк мөселман комиссариатыннан яшерен анкета ала. Әлегә кадәр анкета үзе табылмаса да, аңа карата полк комитеты тарафыннан җибәрелгән җавап хаты тарихчыларга күптән мәгълүм. Моңарчы ул башкачарак бәяләнә иде. Әлеге документ белән бүгенге күзлектән чыгып танышу урынлы булыр.

«95 нче мөселман җәяүле гаскәр полкы комитетының Үзәк мөселман комиссариатына җибәрелгән Идел-Урал штатларының һәм Казандагы Болак арты республикасының бетерелү турындагы хәбәре.

18 май, 1918 ел.

95 нче җәяүле гаскәр полкының комитеты үзенә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында Сезнең 1918 елның 8 мартында 166 нчы номер белән җибәрелгән яшерен анкетагызга тиз арада гына җавап бирә алмады[28].

«Соң булса да уң булсын» дигән мәкальне истә тотып һәм хәбәрнең зур әһәмияткә ия булуын исәпкә алып, комитет беренче мөмкинлек булу белән үк үзен җавап бирергә тиеш дип санады. Казан хәрби округы буенча приказ нигезендә комитет мартның соңгы числоларында бетерелде.

Бу эшне башкаруны, ягъни Сезнең сорауларга җавап бирүне комитет тулысынча полк комитеты рәисе Әхтәмовка, секретаре Гатауллинга һәм комитет әгъзаларыннан Галимовка тапшырды.

Сезнең яшерен анкетагызга җавап буларак түбәндәгеләр хәбәр ителә.

Шушы елның март аеның беренче числоларында урындагы Совет боерыгы белән бетерелгән Хәрби Шураның дүрт әгъзасы кулга алынган иде. Икенче көнне сәгать 11 дә Печән базары мәйданында күп кеше катнашкан митинг булды. Анда катгый рәвештә кулга алынучыларны иреккә чыгаруны таләп итәргә дип карар чыгарылды. Митингтан соң ярсыган халык төркеме Вәисев штабына юнәлде, коралны бирүне таләп итте. Табигый ки, кире җавап алынды. Халык төркеме Вәисев штабына бәреп керергә теләде, ләкин Вәисевнең иптәшләре ата башлады. Мөселман округ комитеты һәм Хәрби Шура әгъзалары мөселман халкы арасында Вәисевкә каршы агитация башладылар. Шушы агитация нәтиҗәсендә берничә солдаттан һәм штатскийлардан торган коралы халык төркеме Вәисевкә каршы коралы хәрәкәт башлады, һәм шуннан соң штаб бүлмәләренең берсендә, урамнан мылтыктан аткан пуля тиеп, Вәисев үтерелде. Шул ук көнне сәгать 4 кә кадәр Вәисев штабы карамагындагы кораллар һәм патроннар гражданский халыкка таратылды. Шуның белән бер үк вакытта билгесез кешеләр Вакытлы инкыйлаби штаб төзеделәр. Әлеге штабны таныырга чакырган бик күп прокламация барлыкка килде. Болак артында яшәүче татар халкы аны танырга мәҗбүр булды... Шул ук вакытта 95 нче җәяүле гаскәр мөселман запас полкының ахуны Гатаулла Баһаветдинов, 95 нче полк атаманы Биглов һәм башка милләтчеләр демобилизацияләнмәгән (запаска җибәрелмәгән) мөселман солдатларын демонстратив рәвештә урындагы (җирле) Советны бетерү өчен крепостька барырга котырттылар. Моннан алда полк ахуны 95 нче җәяүле гаскәр запас полкы комитетыннан бу полк солдатларын митингка җыярга рөхсәт сорады. Полк комитеты бу үтенечкә тискәре җавап бирде. Оешып килә торган бу армияне тәэмин итү мөселман халкына йөкләнде. Шул максат белән байлардан да, ярлылардан да бертөрле түләү алынды. 95 нче полкта демобилизация бара иде, солдатлар арасында бернинди тәртип калмады, алар тулысынча үзләренең шәхси мәнфәгатьләре — үз эшләре белән мәшгуль иде. Болак арты мөселман революцион штабы оештырылганнан соң өч көн үткәч, ягъни 3 мартта төнге сәгать 1 дә 95 нче җәяүле гаскәр полкы комитеты президиумының ашыгыч утырышы булды, анда тиз арада солдатларны демобилизацияләү һәм демобилизациягә караган башка мәсьәләләр тикшерелде. Шул вакыт 250 гә якын кеше, коралы солдатлар һәм гражданскийлар, «Кулларыгызны күтәрегез!» дип команда бирделәр, телефон аппаратының трубкасын өзделәр һәм шуннан соң комитет президиумыннан полкның кораллары, ату кирәк-яраклары кайда икәнен күрсәтүне таләп иттеләр. Президиум

әгъзаларына селкенмәскә боерык бирелде. Безнең күкрәкләребезгә штыклар терәп, роталарга телефонограмма җибәрелде. Анда полк комитетының рөхсәтеннән башка роталар урнашкан биналарга бер генә агитаторны да кертмәскә диелгән телефонограмманы бөтен рота һәм командаларда укырга кушылды. Шулай итеп, агитаторларның 95 нче полкны котырту өмете уңышка ирешмәде. 95 нче полк солдатларын котырта алмагач, революцион штаб мөселман халкын тырышып коралландыра башлады, Болак арты урамнарының барысына да үзенең патрульләрен куйды. Демобилизацияләнеп кайтып баручы солдатларны урамнарда туктаттылар һәм алардан көчләп өс киемнәрен, коралларын, патроннарын һ.б. алдылар, ә үзләрен яңа оештырылган «армия» сафларына басарга көчләп мәҗбүр иттеләр. Мөселман кавалерия эскадроны тулысынча Болак арты ягында калды. 95 нче мөселман җәяүле гаскәр полкының мөселман офицерлары күпчелеге үз ихтыяры белән һәм бик аз өлеше үз теләкләренә каршы «инкыйлаби юл белән» мәхәлләләрдә район комиссарлары итеп билгеләнде. ... Президиумның бер әгъзасы — Кадыйров — корал складын күрсәтергә мәҗбүр булды. Шул ук төндә, 20 арбага төяп, мылтык һәм патроннарны, шулай ук телефон аппараты трубкасын һәм кулга алынган телефончы Ганиевне алып киттеләр. Бу комитет өчен көтелмәгән хәл иде. Президиум аптырашта калды. Комитет, рухын төшермичә, икенче көнне иртә белән бөтен булган хәл турында эшче, солдат һәм крестьян депутатларының Казан Советы каршындагы Мөселман комиссариатына хәбәр итте һәм шул ук көнне барлык калган кораллар һәм роталардан кабул ителгән сугыш кирәк-яраклары комиссариатка тапшырылды. Ул вакытта Мөселман комиссариаты бик яшь һәм көчсез диярлек булса да, Совет ярдәме һәм полк комитеты булышлыгы белән коралны алып китә алды. Болак арты штабы, 20 арба корал урлау белән генә чикләнмичә, тагын полкның берничә атын да алып китте. Соңрак алар мәхәлләләрдә буржуйларга таратылды. Чаналар, экипажлар (җиңел арбалар), сбруйлар шул ук юл белән шул ук штаб тарафыннан урланды. Бу соңгысы стройдан тыш хезмәт ротасы начальнигы Хәмзиннең Болак арты контрреволюцион штабына сатылуы белән аңлатыла. Аннан соң фуражны алып китә башладылар. Мөселман комиссариаты көннән-көн көчәя башлады. Полк комитеты аңарда үзенә ышанычлы таяныч тапты. Мөселман комиссариатына таянып, полк комитеты инде катгый рәвештә коралланган бандалар тарафыннан полк милкен урлауны тыйды.

Комитетның соңгы адымы Болак арты штабына ошамады: чөнки аларга буйсынган кавалерия эскадроны Болак арты штабында калды, ә ул, әйтергә кирәк, уң кул иде. Татарлар төрле өндәмәләр белән исергәннәр һәм нәрсәгәдер бик куанганнар

иде. Шат күңелләре кинәт кенә төште, суынды. Татар эшчеләре һәм, гомумән, хезмәт халкы Болак арты штабы эшчәнлегеннән үзләренең канәгать түгелләкләрен белдерә башлады. Алар штаб хәрәкәтләренең булдыксызлыгын һәм нигезсезлеген аңлый башладылар. 15 көн узганнан соң полк комитеты Мөселман комиссариаты рөхсәте белән Болак арты кавалеристлары, гомумән алганда, кораллы эшчеләр арасында агитация алып бара башлады. Кавалерия һәм армия сафларында энтузиазм бетә башлады. Болак артының кораллы көче әкрен генә эри иде. Ниһаять, яңа стиль буенча 27 мартта Казан шәһәренең татарлар яшәгән Болак арты өлешен матрослар һәм аларга ярдәмгә килгән мөселман кызылармеецлары әйләндереп алды. Урындагы Совет, Болак арты татар штабына ультиматум җибәреп, барлык коралны һәм ату кирәк-яракларын тапшыруны таләп итте. Ультиматумның срогы узганнан соң (көндезге 2 сәгатьтә), татарлар яши торган урамнарда пулеметлар чытырдый башлады, мылтыктан аткан тавышлар ишетелә иде. Җитди бәрелешләр булмады. Болак арты армиясе, кавалериясе үзләренең штаблары җитәкчелегендә бирелергә мәҗбүр булдылар. Шушы көнне тәртипсезлекләрне бетерү һәм элекке Болак арты контрреволюцион оешмаларының җиһазларын, кирәк-яракларын юк итү өчен «Шәһәрнең татар өлешенең Вакытлы революцион штабы» дип аталган вакытлы штаб оештырылды. Тентүләр, Болак арты армиясен бетерү башланды, кораллар, ату кирәк-яраклары тартып алынды һ.б. Бу эшне башкару барышында бер мөселман-кызылармеец яраланды, берникадәр вакыттан соң ул больницада үлде. Моннан тыш берникинди үтерү очраклары булмады.

Совет оешмалары эшчеләрне кыйнау һәм кан түгүне бөтенләй булдырмаска тырыштылар. Яшь мөселман комиссариаты Совет белән берлектә хәрәкәт итте һәм югарыда күрсәтелгән оешмаларның хәрәкәтендә бары тик тәртипсезлекләр генә күрде. 95 нче запастагы мөселман җәяүле гаскәр полкы комитетының мөнәсәбәте югарыда әйтелгәннәрдән килеп чыга. Финляндия полкының мөнәсәбәте дә шундый ук. Мөселман кавалерия эскадроны югарыда күрсәтелгән милли буржуаз-контрреволюцион оешмалар белән бергә хәрәкәт итте. Һәм башка милли оешмалар бу вакыйгаларга карата үзләрен битараф тоттылар. Мөселман гарнизон комитеты үзенең соңгы утырышында Советка һәм аның каршында оештырылган Мөселман комиссариатына булышлык күрсәтергә дип карар кабул итте. Яңа стиль буенча 27 мартта Совет һәм башка революцион оешмалар инициативасы белән Казанга матрослар килде һәм Казан вакыйгалары ахырына кадәр кан түгүсез беterелде. Шушы вакыттан бирле Казанда да һәм провинциядә дә хакимият Совет кулында. Хәзерге вакытта татарлар һәм

башкалар арасында килеп чыга торган барлык конфликтлар эшче, солдат һәм крестьян депутатларының Казан Советының Мөселман комиссариаты тарафыннан хәл ителә. Шулай итеп, Совет хакимияте тарафыннан барысы да тыныч кына җайлана.

95 нче мөселман җәяүле гаскәр полкының полк комитеты рәисе Әхтәмов[29]*.*
Секретарь[30]*».*

Югарыдагы юллардан күренгәнчә, беренчедән, Үзәк эшне Казан мөселман комиссариаты аша яшертен рәвештә алып бара.

Икенчедән, анкетага җавап бары тик 1918 елның 18 маенда гына җибәрелә. Ихтимал, март, апрель, хәтта май башларында да әле хәлләр кискен булып, вакыйгаларның кайсы якка үзгәрүен көтеп торырга туры килгән; Әхтәмов, Гатауллин, Галимов фамилияле хәрбиләрнең тиз арада җавап җибәрергә кыюлыгы җитмәгән.

Җавап хатыннан билгеле булганча, башка вакытлы революцион штаб төзелә, халык арасында прокламацияләр таратыла, митинглар уздырыла һәм нәтиҗәдә Болак артында яшәгән халык аларны кабул итә. «Мөселман кавалерия эскадроны» исә бөтенләе белән Болак артындагылар ягында була. Аңа Бәләбәй гарнизоныннан вәкил булып килгән гаскәри Нигъмәт Сәлимгәрәй улы Еникеев җитәкчелек итә.

Тарихи белешмә

Нигъмәт Сәлимгәрәй улы Еникеев 1893 елда Башкортстанның Бәләбәй өязе Яңа Каргалы авылында туа. 1918 елда II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съездында катнаша. Ул уң федералистлар фракциясен җитәкли. И.Рәмиев, И.Атнагулов, Я.Байков (Гали) тарафыннан М.Сәгыйдуллинга язылган хатта (19.01.1928) «бу фракциядә унлап кеше бар иде» диелә һәм анда Җиһангир Алкин, Госман Токымбетов, Йосыф Мозаффаров, Гатаулла Баһаветдинов, Газиз Монасыйпов күрсәтелеп, *«бу фракциядә Нигъмәтнең тәэсире бик зур иде һәм ул* (фракция) *аны* (Н.Еникеевне) *җаны-тәне белән яклый иде»* дигән сүзләр бар[31].

Кулга алынганчы, Н.Еникеев Омск хәрби училищесында бригада комиссары була. 1937 елның 21 декабрендә Омск НКВДсы тарафыннан кулга алынып, 1938 елның 4 декабренә кадәр тикшерүчеләр карамагында булып, нәтиҗәдә гаепсез дип табыла[32].

Ул сорау алулар вакытында: *«Мин 1918 елда II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съездында Бәләбәй гарнизоны делегаты буларак катнаштым. Бу съездда федералистлар фракциясе белән җитәкчелек иттем.*

Фракция җитәкчелеге татар-башкорт эсерларыннан торып, актив рәвештә федератив буржуаз-демократик автономия идеясен яклады», — ди.

Н.Еникеев шулай ук И.Алкин һәм башка офицерлар белән берлектә *«Болак арты республикасы»н төзүдә катнашуын әйтә. «Болак арты республикасы» территориясендә мин складлардагы коралларны тарату эшләрен оештырдым һәм Совет властена каршы көрәшү өчен кавалерия подразделениесе төзедем»,* — дип белдерә[33].

Ихтимал, яшерен анкетага җавап язучылар нәкъ менә шушы эскадрон хакында сүз алып барганнар.

«Идел-Урал штаты»н игълан итүне өзгәннән соң, 3 мартта төнлә сәгать 3 тә 250 коралллы кеше, 95 нче полк комитетының президиум утырышы вакытында килеп кереп, *«Кулларыгызны күтәрегез!»* дип, телефон трубкасын өзәләр, һәм 20 арбага винтовкалар һәм патроннар төяп алып китәләр, диелә. Шунысы кызык: әлеге гамәлне башкаручыларның бер өлеше штатский киемдә була. Бу фактны да, бернинди дәлилсез, милләтчеләргә сылтап килделәр. Сорау туа: ни өчен «Болак арты республикасы»н оештыручылар үзләре үк үзләренең коралын урларга тиеш булганнар соң? Бу сорауга җавап юк әле. Хәтта хат авторлары үзләре дә моңа җавап бирә алмаганнар.

«Болак арты республикасы» барлыкка килүгә нәрсә сәбәп булуы беркадәр ачыклана төште кебек. «Болак арты республикасы» барлыкка килүдә «милләтчеләр»нең гаебе булмый, моңа тулысынча «бәйнәлмиләлче» Совет тарафдарлары гаепле. Ачыграк итеп әйткәндә, үзләре үк күтәреп чыккан «милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы» шигареннән баш тарткан большевиклар коткысы нәтиҗәсендә туа «Болак арты республикасы».

Кулга алулардан соң хәзерге офицерлар йорты бинасында тантаналы рәвештә башланган II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды үзенең утырышларын Болак артында урнашкан 95 нче мөселман полкы казармаларында дәвам итәргә мәҗбүр була.

* * *

Янә 1918 елның март ае вакыйгаларына әйләнеп кайтыйк.

II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды делегатларын, «тәүбәгә»[34] килүләрен искә алып, төрмәдән чыгарылалар. ГалимҗанШәрәф 1937 елда сорау алулар вакытында бу турыда ачык итеп әйтә: *«Өч көн тоткында тотылганнан соң, алар азат ителделәр... Нәкъ менә шул вакыт Хәрби коллегия, инициативаны үз кулына алып, Советка каршы хәрәкәт итә башлады һәм «Болак арты республикасы»н игълан итте.*

«БАР» тарафыннан шактый эш эшләнде. Бөтен җирдә диярлек митинглар, җыелышлар уздырылды. Бик күп листовкалар

таратылды. Нәтиҗәдә шәһәрнең татарлар яшәгән өлеше «Болак арты республикасы»н үз республикасы итеп кабул итте.

«Болак арты республикасы» үзенең төп максаты итеп «Идел-Урал штаты»н гамәлгә ашыруны куйды».

Югарыда озак еллар дәвамында «Болак арты республикасы» барлыкка килү сәбәпләрен бәяләүдә берьяклылык хөкем сөрүе, аның бар гаебе «Идел-Урал штаты» һәйәтенә һәм аның «милләтче» җитәкчеләренә кайтарылып калдырылуы, чынбарлыкта исә хәлнең башкачарак булуы хакында әйтелгән иде инде. Мәгълүм булганча, ул вакытта Хәрби Шураны И.Алкин җитәкли. Шактый бәхәсләрдән соң «Идел-Урал штаты» һәйәте, полковник Биглов җитәкчелегендәге хәрби коллегия, Казан Советы башкарма комитеты белән бәйләнешкә кереп, «Идел-Урал штаты» буенча сөйләшүләр алып бара. Шәрәф сүзләренә караганда, һәйәт «Болак арты республикасы» белән Совет хакимияте арасында канлы бәрелешкә юл куймау өчен зур тырышлык куя, Советлар белән «БАР» арасында арадашчылык вазифасын Галимҗан Шәрәф үзе башкара. Әлбәттә, алып барылган сөйләшүләр нәтиҗәсез калмыйлар, мөселман полкларындагы солдатлар һәм офицерлар 25 көн буена сабырлык күрсәтәләр. Бүгенгә кадәр тарихта бу хәл большевикларның тырышлыгы нәтиҗәсе дип бәяләнде. Ә безнең фикеребезчә, ул көннәрдә ике арадагы киеренкелекнең кан коюга барып җитмәвендә беренче чиратта һәйәт җитәкчеләренең, бигрәк тә Галимҗан Шәрәфнең, Ильяс Алкинның, Газиз Монасыйповның тырышлыгы зур булса кирәк. Хәрби коллегия һәм аның җитәкчесе полковник Биглов та бу киеренке вазгыятьтә сабырлыкны саклауга үз өлешен керткәндер. Югыйсә биш меңнән артык мөселман офицерларының бер өлеше генә булса да Казан Советына каршы күтәрелсә һәм үз артыннан мөселман солдатларын да ияртсә, кан коюның котылгысыз булачагы бәхәссез. Ул гына да түгел. Советларга бу көннәрдә ышанычның йомшак булуын истә тотсак, «Болак арты республикасы»ның җиңүгә ирешүе дә ихтимал иде. Шунысы кызык: Казан Советы башкарма комитеты, «Идел-Урал штаты» һәйәте белән сөйләшүләр алып барганда, «Болак арты республикасы»на каршы буларак «Казан республикасы»н төзү мәсьәләсен күтәрә. Моны Советларның милләт мәнфәгатьләре өчен көрәшүчеләрнең һәр гамәленә карата нинди дә булса аңа каршы икенче бер төрле чара кылырга омтылулары белән генә аңлатырга мөмкин. Баксаң, мондый тактика сәяси вазгыятьне киеренкеләндерүгә генә хезмәт итә. Димәк, «Болак арты республикасы» барлыкка килүнең дә асыл сәбәпләрен «милләтчеләр»нең үҗәтлегеннән генә түгел, бәлки күпчелеге бөек мәмләкәтчел шовинистлардан һәм аларның җырын җырлаучылардан торган Совет җитәкчелегенең милли мәнфәгатьләрне исәпкә алырга теләмәүләреннән, шуңа күрә милләтпәрвәрләрнең һәр адымын сыйнфый дошманлык гамәлләре дип

бәяләүләреннән эзләргә кирәктер. Югыйсә бик сәер хәл туа: имеш, большевиклар партиясе, Совет хакимияте һәрвакыт дөрес юлдан гына барганнар, бары тик гаделлек гамәлләре генә кылганнар да, теге яки бу очракта килеп туган сәяси бәрелешләр барысы да «милләтчеләр»нең сыйнфый казынулары аркасында гына барлыкка килгән булып чыга. Әмма чынбарлыкта киресенчә булган очраклар да бик күп бит. Тарихчылар безнең үткән юлыбызны мондый берьяклы бәяләмәләрдән арындырырга, һәр сәяси вакыйганы объектив мәгълүматлар нигезендә яңача, гадел аңлатырга бурычлылар. Бары тик шул чакта гына тарихи гаделлек өстенлек алыр. «Контрреволюцион фетнә» дип бәяләнгән 1918 елгы февраль вакыйгалары вакытында да киеренкелекне тудыручылар «милләтчеләр» түгел, ә бәлки Казан Советы җитәкчелеге... Мәгълүм булганча, 1918 елның 28 февраленә каршы төндә Казанда, гомумән, татар-башкорт дөньясында, фаҗигале вакыйгалар башлана.

Шулай итеп, революциядән соң үзен таныта башлаган диктатура яңа үрләр яулый алган татар-башкорт демократиясенең буғазына ябыша. Хәрби һәм сәяси көчләр милләт өчен көрәшүче зыялылар каршында милли-мәдәни мөхтәриятне дөньяга чыгару юлында үтә алмаслык киртәләр куйдылар.

«Идел-Урал штаты»н тормышка ашыру өчен төзелгән коллегия Казан Советы, Мөселман социалистлары комитеты, Совет каршындагы Мөселман комиссариаты белән сөйләшүләр алып барганда, Галимҗан Шәрәф, Ильяс Алкин «Идел-Урал штаты»н тыныч юл белән хәл итәргә тырышалар. Әмма каршы як алдау юлына баса. Моны аңлау өчен «Казан республикасы»ның Казан Советына кертелгән комиссарлар исемлеген күрсәтү генә дә җитә, чөнки бу Совет — «Болак арты республикасы»на капма-каршы рәвештә төзелгән орган. Аның составында 15 кеше, шуларның икесе татар — Солтангалиев һәм Сәетгалиев. Икесе дә «Болак арты республикасы»на каршы. Ә калганнары — Мохов, Максимов, Фролов, Котляров, Скачков, Виноградов, Аносов, Шнуровский, Вегер һ.б. «Знамя революции» газетенә редактор итеп иң зәһәр шовинист К.Грасис куела. «Болак арты республикасы», «Идел-Урал», гомумән алганда, татар халкының дәүләтчелек мәсьәләсе көн тәртибенә куелганда, аның иң явыз дошман булып чыгуы мәгълүм.

Тарихчы Риф Хәйретдинов әйтүенә караганда, «Идел-Урал» һәйәте бу вакытта ике ут арасында кала. Бер яктан, аны «уңнар» тарафдарлары (Милләт Мәҗлесе) Советлар белән хезмәттәшлек итүдә гаепли. Ә икенче яктан, «БАР» куып таратылгач, авыр бәрелеш көннәре үткәннән соң, Галимҗан Шәрәф язуына караганда, «Идел-Урал штаты» коллегиясе һәм аның җитәкчеләре бу вакытта да Совет белән элемтәне өзмиләр. Арадашчылык ролен Галимҗан Шәрәф үз өстенә ала. Ул Революцион ко-

митет әгъзалары, шул исәптән хәрби коллегия рәисе Ә.Биглов белән очрашып сөйләшүне дәвам итә. Шушы сөйләшүләрнең берсендә ул: *«Безнең тарафтан канлы бәрелешүне булдырмаска бөтен көчне куярбыз, әмма Совет хакимияте «Идел-Урал штаты»н төзүгә ирек бирмәс, аларга ышанычым юк»* — ди. Шулай итеп, Милләт Мәҗлесендә «Идел-Урал штаты»н тормышка ашыру өчен төзелгән һәйәт белән II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды оештырган хәрби коллегия арасындагы мөнәсәбәтләр Казанда канлы бәрелешне булдырмауда төп рольне уйный. Әлеге ике оешма Казан вакыйгалары турында фикер алышып торалар. Әйтергә кирәк, бу фикер алышулар каршылыксыз гына, шома гына бармый.

Бу вакытта «Идел-Урал штаты» һәйәте әгъзалары, озак фикер алышулардан соң, күпчелек тавыш белән «Болак арты республикасы»на катнашмаска, тиз арада Совет органнары белән сөйләшүне дәвам итәргә булалар. Бу — Галимҗан Шәрәфнең һәм аның аркадашларының уйлап эшләнгән гамәлләре. Менә шушы сөйләшүләр нәтиҗәсендә «Казан республикасы» туа. Хәер, монда башка факторларның да тәэсире була. Әмма бу мәсьәлә махсус өйрәнелергә тиеш. «Казан республикасы»ның, Казан Совнаркомының әллә ни әһәмияте һәм абруе булмый; чөнки алар «Болак арты республикасы»на каршы уйлап чыгарылган атрибутлар гына. Казан Совнаркомы Үзәк белән, шул ук вакытта Уфа башкарма комитеты, бу мәсьәлә белән кызыксынган губерналарның башкарма комитетлары белән дә сөйләшүләрне дәвам итә. Бу хәл, әлбәттә, Казан Советы хакимиятенең үзлегеннән генә башкарган эше түгел. Монда Казан мөселман демократларының «Идел-Урал»ны дөньяга чыгару өчен бар көчләрен куеп көрәшүләренең дә тәэсире зур була. Монда без, Казан Совет хакимиятенең бик авыр хәлдә калуы сәбәпле, соңгысының «Идел-Урал штаты»н Советларга бәйләп игълан итәргә мәҗбүр булганлыгын күрәбез. Казан губерна советы тарафыннан кабул ителгән карарга игътибар итик:

«Совет «Урал-Идел республикасы»н оештыруга ашыгыч чаралар күрә, бу республика милли-пропорциональ (сыйнфый) нигездә Халык Комиссарлары Советы җитәкчелегендә оештырыла.

Президиумга Уфа һәм Оренбург советлары белән «Идел-Урал республикасы»н ашыгыч рәвештә игълан итү мәсьәләсе буенча бәйләнешкә керүне йөкләргә»[35].

Башка партияләрнең, демократиянең идеяләрен урлау большевикларга бернигә дә тормый. Бу алар өчен хас күренеш. Шулай итеп, моның Милләт Мәҗлесе һәм II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды гамәленә каршы инициативаны бары тик большевистик Советка гына беркетеп кую өчен эшләнгәне көн кебек ачык. Гомумән алганда, «Идел-Урал»га бары тик «советская» (һәм «республика») сүзен генә өстәп, хәтта 11 кешедән торган

яца коллегия дә төзелә. Әмма болар барысы да Милләт Мәҗлесен, «Идел-Урал» һәйәтен искә алмыйча эшләнә. Әйтелгәнчә, бу очракта Галимҗан Шәрәфнең эше Милләт Мәҗлесе җитәкчеләреннән берсе Ибниәмин Әхтәмов тарафыннан тәнкыйть ителә. Моны без анын кулы белән язылган һәм «Казан, «Идел-Урал» һәйәте рәисе Шәрәфкә» дип исемләнгән документтан күрәбез[36]. Эш шунда, Милләт Мәҗлесе һәм Милли Идарә белән җитәкчелек эшен Садри Максуди Ибниәмин Әхтәмовка ышанып тапшырган була, ул теге яки бу очракта ничек эш итү турында җентекләп язылган инструкция дә калдыра. Садри Максуди үзе Уфадан китә[37]. Әлеге язма Галимҗан Шәрәфкә, ихтимал, шул вакытта җибәрелгән. Чөнки беренче булып Ибниәмин Әхтәмов кул куйган. Укучылар игътибарына без әлеге документның тулы текстын тәкъдим итәбез.[38]

«Казан, Идел-Урал һәйәте[39] рәисе Шәрәфкә[40]

Сезнең 10 марттагы телеграммагызга җавап булып түбәндәге ике нотаны бәян итүне тиеш санаймыз. Һәйәт Милләт Мәҗлесе тарафыннан җәдвәле[41] мәгълүм булган вәкаләт белән сайланган. Бу вәкаләт буенча һәйәт үтәргә тиеш нәрсә фәкать Идел-Урал өлкәсе булачак йиргә кергән милләтләр вә партияләр вәкилләренең конференциясен җыю өчен кирәкле хәзерлек хезмәтләредер. Һәйәт фәкать өлкәнең чикләре, аның сәяси төзелеше хакында Милләт Мәҗлесе тарафыннан кабул ителгән нәрсәне конференциягә гарыз[42] итәргә дә вә шул хактагы докладларны Милләт Мәҗлесеннән вәкил буларак мөдафәгә[43] итәргә төгәл әйтелгән. Үз карашы белән генә берәр мәсьүлиятле карар кабул итәргә, бирелгән вәкаләтнең тышында берәр адым ясарга һәйәтнең хакы юктыр. Вә әлхаль:[44] 1) һәйәт, Милләт Мәҗлесе тарафыннан күздә тотылган конференцияне җыймыйча, өлкәне хәзер үк игълан итәргә уйлый; 2) өлкәнең Милләт Мәҗлесе тарафыннан тәгаен ителгән җәдвәлен баш-баштаклыклы сурәттә үзгәртә; 3) конференция җыюдан әүвәл, Урал-Идел Совет җөмһүриятенә керергә алдан карар биреп куеп, һәйәт, Милләт Мәҗлесенең өлкәнең сәяси төзелеше тугрысындагы карарын әсасыннан[45] җимерәдер; 4) үзен Совет платформасында тора торган мөәссәсә[46] итеп игълан итәрәк, һәйәт Милләт Мәҗлесе тарафыннан үзен сайлаганда һич күздә тотылмаган бер карарны бирәдер. Милләт Мәҗлесе карарларын болай бутауга каршы протест итеп, без һәйәтне үзенә бирелгән вәкаләт чигеннән чыкканга гына саир[47] түгел, бәлки Милләт Мәҗлесе тарафыннан үзенә йөкләтелгән вазифаларга каршы килә торган вә милләт өчен начар нәтиҗәләр тудыруы мөмкин булган хәрәкәтләре белән Милләт Мәҗлесенең инабәтен[48] сүи истигъмаль[49] иткәнгә санаймыз. Бу хәрәкәтләрнең агыр мәсьүлияте[50] бөтенләе белән, шөбһә юк, һәйәт өстенә төшәдер ки, ул Милләт Мәҗлесенең майдагы җыелышы вакытын-

да үзенең эшләренә хисап бирергә мәҗбүр булачактыр. Шуның белән бергә, рәсми мәсъулияттән башка, аннан җитдиерәк тарих хөкеме вә милләт алдында мәсъулият бар бит әле. Бу соңгы нәүгъ[51] *мәсъулиятне үз өстемезгә алырга теләмәгәнлектән, без һәйәтнең хәрәкәтләреннән үземезнең бер читтә торганлыгымызны игълан итәргә мәҗбүрмез, һәм бу хәрәкәтләрнең булуы мөмкин нәтиҗәләрен бөтене белән һәйәт өстенә йөкләтәмез.*

Милләт Мәҗлесе рәисе урынына
рәис могавине[52] *Ибниәмин Әхтәмов.*
Урта Русия һәм
Себер мөселман төрек-татарларының
Милли Идарәсе рәисе Садри Максудов.
Уфа. 1918 сәнә, 27 февраль[53]*».*

* * *

Үзәк тә йоклап ятмый. Казан большевикларына һәм алар хакимиятендәге Советка ярдәмгә ашыга. 1918 елның 22 мартында Татар-башкорт Совет Республикасы турындагы Декрет игълан ителә. Бу хакта «Йолдыз» гәзитендә түбәндәге хәбәр урнаштырыла: *«Казан Советы мөселманнарның Хәрби Шура илә хәрби съездга калган гаскәри оешмаларның таралуын дәгъва кыйла. Бу оешмалар таралмадылар, солых килешүен өмет итеп, эшләрен һаман дәвам иттеләр. Ләкин араларында мөзакәрәләр йөрсә дә, һаман солых килешә алмадылар. Мөселманнарның гаскәри оешмаларына ачу итеп, һәр көн Совет гаскәриләренең мөселман мәхәлләләрен тупка тоту ихтималлары бар иде. Шул рәвешчә яшәүгә дә дин вә милләт хәтере өчен казанлылар түзделәр.*

Совет мөселманнарны большевикларга вә Совет хөкүмәтенә каршы дип белә иде. Хәлбуки мөселманнарның максаты аларга каршы чыгу түгел иде. Мөселманнарның максаты — штат мәсьәләсенең хәл кылынуы илә дин укытуны мәнигъ кыйлмау иде. Бу мәсьәләләр 20 мартларда бер дәрәҗә хәл кыйлындылар. Пайтәхеттән татар-башкорт штаты булачак хакында телеграмм килде. Казан Советы хозурындагы комиссариат мөселман мәктәпләрендә дин укытуны мәнигъ кыйлынмаячагын игълан кылды»[54].

Татар-башкорт Совет Республикасының тормышка ашырылачагына ышанган мөселманнар, *«штат мәсьәләсе хәл кылынды», «мәктәптә дин укыту бетерелмәде», «монда да без уйлаганча булды»* дип алдандылар. Совет та максатына иреште, мөселманнар да морадына җитте дип алдандылар.

Үзәк тиздән Мөселман халык комиссариатын Татар-башкорт комиссариаты итеп үзгәртү мәсьәләсен дә алга куя. Менә шунда инде бер төркем Сталинга һәм аның яраннарына отставкага китү турында үтенеч бирә. Бу документта Г.Ибраһимовның, М.Вахитовның, Ш.Маннаповның, Ю.Ибраһимовның, И.Асәкәевнең,

М.Килдебәковның, М.Алиевларның имзалары бар. Әмма тиз арада Сталин аларны ризалаштыруга ирешә һәм алар, аның белән килешеп, үз вазифаларын үтәргә керешәләр. Сталин бу очракта үзен сәясәтче итеп, кирәк вакытта хәтта гафу итү-үтенү кебек адымга бара алу сәләтен күрсәтә. Тик төп юнәлеш — татарларны, башкортларны, чуашларны зәгыйфьләндерү эше алга барсын. Ә мондый сәясәтнең барлык Шәрык халыклары өчен дә ярап куюы ихтимал.

Кыскасы, авырлыклар, каршылыклар белән булса да Сталин тагын бер җиңүгә ирешә, чөнки бу этапта инде М.Вахитов, Г.Ибраһимов һәм аларның көрәштәшләре бөтен Русия мөселманнарының җитәкчеләре түгел, ә бары тик татар-башкорт халкының җитәкчеләренә генә әвереләләр. Әмма Сталин өчен әле бу җиңү юлының яртысы гына. Аның максаты — ТБСРны бөтенләй юкка чыгару. Шулай ук Татар-башкорт комиссариатын бетерү турында да уйлана ул. Менә монда инде сәясәтченең мәкере генә түгел, сабырлыгы да күренә. Ул ашыкмый. Аныңча юл дөрес, бары тик алда яткан зур һәм вак ташлардан котылырга гына кирәк. Аларны да үзе алып атмый, ахыр килеп үзләре үзләренә булышачаклар, ә кайберләрен хәтта җаваплырак эшләргә күтәрергә дә була. Чыннан да, хәлләр бик катлаулы була.

«Сталинның сәяси уеннары уңышлардан гына торган икән» дигән уй тумасын өчен тагын бер тарихи фактка күз салыйк. Революциядән соң, Милләт Мәҗлесе эшенә әзерләнгән көннәрдә, Сталин Хәрби Шураны бетерү хыялы белән янып йөри һәм, шуны тормышка ашыру өчен, ул Ә.Цаликовны Наркомнацка эшкә чакыра. Әгәр дә Ә.Цаликов аның тәкъдиме белән килешкән булса, Хәрби Шура гына түгел, башка милли оешмалар да юкка чыгарылган булырлар иде, әмма Ә.Цаликов аның тәкъдименнән баш тарта.

Кызганычка каршы, соңрак талантлы зыялыларыбыз М.Солтангалиев, М.Вахитовлар алдандылар. Алар да ТБСРның киләчәге булачагына чын күңелләреннән ышанып эшләделәр һәм нәтиҗәдә «Болак арты республикасы»н җимерүгә үз өлешләрен керттеләр. Мөселман үзәк комиссариаты рәисе М.Вахитов үзенең теләкләрен Х.Гайнуллинга, Һ.Маликовка һәм башкаларга җиткерә. Ул үзе дә Казанга килергә җыена. 1918 елның 18 мартында М.Вахитов Һ.Маликов белән сөйләшә.

М.Вахитов. Сезнең нинди сорауларыгыз бар? Бирегез.

Һ.Маликов. Мәскәүдән Казанга кайчанрак килергә уйлыйсыз?

М.Вахитов. Бик кирәк була калса, өч көннән чыгабыз.

Һ.Маликов. Хәлләр монда мөшкел, шулай булгач, сезнең килүегез хәлиткеч булачак. 400 дән дә ким булмаган кораллы көч белән килегез. Болак арты республикасының мөмкинлекләре менә мондый: мылтыклар белән коралланган 10 меңгә якын сугышчылар, 200 кавалерист, 15 пулемет, гранаталар бар. Без-

нең комиссариатның көче: 400 кызылармеец, 10 пулемет. Советның көче — 1мең кызылармеец, 1 агитбригада, 4 автобронևик, пулемет һәм винтовкалар.

М.Вахитов. Дошман яхшы оешканмы?

Һ.Маликов. Алай дип әйтмәс идем.

М.Вахитов. Мин сезгә разведканы көчәйтергә әмер бирәм. Язма һәм телдән агитацияне югары дәрәҗәгә күтәрегез. Бигрәк тә оештыру эшләрен көчәйтегез. Тиздән очрашуларга кадәр. Кирәк булса, телефонга чакырырмын[55].

Бу материалга аңлатмалар кирәкми. Соңыннан ТБСРның да гамәлгә кертелмәве, татарлар белән башкортларны аеру-бүлү сәясәте, Декретның бары тик вакыт отар өчен, каршылыкларны тирәнәйтү, киңәйтү өчен генә эшләнгән гамәл булуын күрсәтә.

Мөселман демократиясен гади бер агым гына яисә бер оешма дип кенә карау дөрес булмас иде. «Идел-Урал штаты» коллегиясе, «Идел-Урал» һәйәте, хәрби коллегия, Милләт Мәҗлесенә генә баш иючеләр (С.Максуди, М.Әхтәмов, Н.Хәлфин һ.б.) — барысы да «Идел-Урал штаты»н тормышка ашыру юлларын эзлиләр, ышанычларын югалтмыйлар. Советларга карата төрле карашта булсалар да, күпчелек «Идел-Урал штаты»н Советлар белән бәйләп төзергә ышаныч баглый. Казан Советының карары дөньяга чыккач та, Совет милли оешмалар белән эш итмәсә дә, Риф Хәйретдинов әйтмешли, «Идел-Урал штаты»на «ход» бирелә. Менә шуннан файдаланып, «Идел-Урал штаты» коллегиясенең җитәкчесе Галимҗан Шәрәф «Идел-Урал республикасы»на керергә тиешле өлкәләргә телеграммалар суга. 1918 елның 10 мартында Уфа Хәрби Шурасына җибәргән телеграммасында ул болай дип хәбәр итә:

«Идел-Урал штаты»нда автономияне тормышка ашыру буенча коллегия тиз вакыт эчендә Идел буе һәм Урал территориясен Русия Федератив Совет Республикасының автономияле өлеше дип игълан итәргә карар чыгарды. «Идел-Урал штаты»-на бөтен Башкортстан керә һәм аңа Казан шәһәре белән Казан губернасының мөселман өлеше кушыла. Штатта мөселман 55 процент тәшкил итә. Игълан ителгәннән соң милли-пропорциональ башлангычта учредительный (оештыру) съезды чакырыла»[56].

Шул ук вакытта II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съездында төзелгән Мөселман халык комиссариаты да эшен дәвам итә. Ул да, «Идел-Урал штаты» коллегиясе кебек, «Идел-Урал штаты»н Совет республикасы итеп игълан итүгә каршы килмичә, аны тормышка ашыруны, бары тик Советларны яңадан сайлап, махсус съезд җыюны гына алга сөрә. Март ахырларында Казанда «Идел-Урал өлкәсе» исемле гәзит чыга башлый. Аның беренче номеры 1918 елның 24 мартында дөнья күрә. Аның төп максаты — «Идел-Урал өлкә»сен тормышка ашырырга булышу. Мө-

селман халык комиссариатына 15 кеше сайлана. Анда Исмәгыйль Атнагулов, Исхак Алмаев, Габдулла Габдрәшитов, Фәхрелразый Басыйров, Әкрам Биглов, Әфтәхетдин Габдуллин, Сөләйман Ловчицкий, Гали Моракаев, Фатих Мөхәммәдъяров, Сөләйман Полторжицкий, Кәшшәф Терегулов, Адәм Якубовский, Әхмәтсолтан Таһировлар керә. Комиссариатның рәисе итеп Исмәгыйль Атнагулов, рәискә иптәшлеккә И.Кәрим, И.Алмаев, сәркатиплеккә Г.Габдрәшитов, К.Терегуловлар сайланалар. Комиссариат биш бүлектән тора. Чынлыкта аңа «Идел-Урал штаты»н тормышка ашыру эше йөкләнә. Комиссариат Екатерининская урамындагы Апанаев йортында урнаша.

Комиссариат *«Мөхтәрәм мөселман кардәшләр!»* дигән мөрәҗәгать кабул итә. Әлеге мөрәҗәгатьтә төп максатлар күрсәтелә[57].

«Идел-Урал өлкәсе» гәзитенең әлеге мөрәҗәгать басылган 24 март санында шулай ук Ф.Басыйровның «Төрки-татар демократиясенең таләпләре» исемле мәкаләсе дә урнаштырылган. Анда да шул ук фикер — «Идел-Урал»ны тормышка ашыру; бу өлкәгә кергән советларның составларын үзгәртү, чөнки алар составында төрки-татар демократлары юк диярлек дәрәҗәдә. Тиздән үтә актуаль таләп туа: Татар-башкорт җөмһүриятенә кергән советларның съездын, җир һәм милли составны искә алып, яңадан сайлаулар уздырырга. Советларны яңадан сайламый торып, съезд җыелган булса, бу съездны төрки-татар демократиясе мәҗлесе, органы итеп исәпләү мөмкин түгел.

Әмма болар барысы да яхшы теләкләр генә булып калалар, чөнки барысы да искечә эшләнә, советлар тарафыннан, төрки-татар демократиясенең таләпләрен искә алмыйча гына, «ленинчыл һәм сталинчыл милли сәясәт» тормышка ашырыла.

Мәгълүм булганча, Үзәк тарафыннан уйланылган Татар-башкорт Совет Республикасын төзү эшен И.Сталин үз кулында тота һәм бу гамәлләргә Галимҗан Шәрәфне дә тарта. Галимҗан Шәрәф язуына караганда, башта аны телеграфка чакырып, «Идел-Урал» чикләре турында информация алганнан соң берничә көн үткәч, И.Сталин тарафыннан кул куелган Татар-башкорт Совет Республикасы турында күрсәтмә игълан ителә. Апрель аенда Галимҗан Шәрәфне Наркомнацка чакыртып алалар. Ул анда 2—3 ай чамасы эшләп кайта.

1 марттан соң аска тәгәри башлаган милли хәрәкәт, Татар-башкорт Совет Республикасы турындагы күрсәтмә дөнья күргәч, бөтенләй диярлек тынып кала. Милли оешмалар үз эшләрен туктата башлыйлар. Беренчеләрдән булып «Идел-Урал штаты» коллегиясе эше туктап кала. *«Татар-башкорт Совет Республикасы турындагы күрсәтмә чыккач һәм аны төзү өчен махсус коллегия барлыкка килгәннән соң, безнең коллегия үз эшен туктатты»*, — ди Шәрәф.

Тиз арада II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды тарафыннан төзелгән Мөселман халык комиссариаты эшен туктатырга мәҗбүр була. Казан Советы каршындагы Мөселман комиссариаты һәм өлкә комитеты түбәндәге карарны игълан итә: *«Үзенең асылы белән контрреволюцион булган «Идел-Урал» өлкә комиссариаты вәкилләреннән һәм Совет комиссариатының кайбер әгъзаларыннан оешкан шәһәрнең татар өлешенең Революцион штабын юкка чыгарырга һәм яңа вакытлы Пролетар революцион штаб төзергә. Шәһәрнең Болак арты өлешендә контрреволюцион хәрәкәтне ахырынача бетерүне Мөселман эшләре буенча комиссариат шул Революцион штабка йөкли»*[58].

Милли оешмаларны, «Идел-Урал штаты»н, «Болак арты республикасы»н бетерүгә, кызганычка каршы, татар большевиклары М.Вахитов, М.Солтангалиев, С.Сәетгалиев, Я.Чанышев, Г.Касыймов, Х.Урманов, И.Галиев, С.Әхтәмов, К.Якубов һәм башкалар зур өлеш кертәләр.

Гасыр башында башланып, 1917—1918 елларда яңа үрләргә менә алган милли-мөселман хәрәкәте бүген генә түгел, үз заманында да шактый югары бәя ала алган.

М.Солтангалиев без югарыда искә алган хатының «Болак арты республикасы»на кагылышлы юлларында болай дип яза: *«Соңгы вакыйгаларның агымы безнең өчен куркыныч түгел иде. Бу вакыйгалардан соң оештырылган «Болак арты республикасы» да безнең өчен ул кадәр үк куркыныч булмады. Безгә оешкан рәвештә милли хәрәкәтнең калган өлешен бетерү мөмкинлеге туды. Үзәк тарафыннан Татар-башкорт Республикасын игълан итү безгә шурачылар белән көрәшергә һәм Кызыл Армияне, мөселман полкын оештыруда мораль куәт бирде. Мәскәүдән зур булмаган матрослар отряды китерттек, һәм шәһәрнең бездән бер айга якын аерылып торган татарлар өлеше — «Болак арты республикасы» — безнең хәрби частьларны анда керткәч, үзенең тимер батальоннары белән безгә сугышсыз бирелде»*[59].

Икенче бер мәкаләсендә, шул вакыйгаларга бәя биреп, ул болай ди: *«Шул замандагы эчке һәм тышкы хәлләрне искә алганда, без тәгаен әйтә алабыз: шурачыларның чыгышы, соңрак булган чехословаклар чыгышы тарафыннан тудырылган «Самарская учредилка»га һәм Колчакка караганда, Совет хакимиятенә күбрәк бәлаләр китергән булыр иде. Менә ни өчен без татар хезмәт ияләре тарихындагы бу моментны иң җаваплы чор дип карыйбыз. Чөнки аның нәтиҗәсе Совет властена каршы Идел өстендә барлыкка килгән күк күкрәүләрне тарату яисә мәсхәрәле һәм данлыксыз рәвештә артка чигенү булуы ихтимал иде. Татар социалистлары җитәкчелегендә без аларның барлык махинацияләрен бер сугуда җимердек»*[60].

Инде сүзне большевикларның оппонентларына бирик. Әле 1918 елда ук «Йолдыз», «Корылтай», «Безнең тавыш» гәзитләре, меньшевикларның «Рабочее дело» һәм башка басмалары чыгып килә. Аларда Совет хакимиятенең, Милли Мәҗлеснең, II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съездының материаллары басыла, «Болак арты республикасы»на карата булган мөнәсәбәтләр дә киң яктыртыла. Әлбәттә, соңрак күп кенә гәзитләр ябылып, бары тик большевистик басмалар гына дөнья күргәндә, элеге вакыйгалар турында бары тик «милләтчеләр», «Забулачка» дип, мәсхәрә итеп кенә яза башлыйлар.

ТБСР — Татар-башкорт Совет Республикасы төшенчәсе беренче карашка «Идел-Урал штаты»ннан әллә ни аерылмый кебек. Шул ук халыклар, шул ук территория. Әмма ТБСРның эчтәлегендә ике халыкны капма-каршы кую сизелә. Монда төрле фикерләрнең бер-берсенә каршы киләчәге көн кебек ачык. Мәгълүм булганча, И.Сталин да, В.Ленин үзе дә һәм җитәкчеләрнең башкалары да четерекле мәсьәләләрне чит куллар белән хәл итүне хуп күргәннәр. Бу очракта да, әйтелгәнчә, И.Сталин, М.Вахитов, М.Солтангалиев, хәтта партиясез, чынлыкта В.Ленинның милли сәясәтен кабул итмәгән Галимҗан Шәрәфне һәм башка татар зыялыларын махсус комиссиягә (ул аны *техник комиссия* дип атый) җыеп, аларның эшчәнлегеннән оста файдалана. Ул аларны төрле-төрле вәгъдә-тәкъдимнәр белән үз ягына аудара. Шундый тәкъдимнәрнең беренчесе — Татар-башкорт Совет Республикасын төзү.

Большевиклар хакимияте, И.Сталин киң фронтта һөҗүмгә күчәләр. Төп удар милли хәрәкәтнең социалист-федералистларына гына түгел, хәтта большевиклар арбасын төптән җигелеп тартып барган «суллар»га да кагыла. М.Солтангалиев белән М.Вахитов моны беренче булып татыйлар.

«Идел-Урал штаты»н төзү тормышка ашмыйча, үтәлмичә калды, чөнки большевиклар 28 март көнне, Мәскәүдән китерелгән хәрби көчләрдән файдаланып, «Болак арты республикасы»ның эшен туктаттылар. «Йолдыз» гәзите бу турыда: «*Шул рәвештә эш җайлана дип солых көтеп торганда, 28 мартта сәг. 4 ләрдә... мөселман штабы янына броневик килеп туктады, хәрбиләр мәхәлләләргә дә керәләр. Алар халыкка каравыл тору өчен таратылган коралларны җыялар. Моны, нигездә, матрослар башкардылар. Халык аларга каршылык күрсәтми, чөнки ТБСР күрсәтмәсе чыккач: «Советның максаты булды. Мөселманнар да үз морадларына ирештеләр», — дип уйладылар*», — дип язды[61].

Броневикка ияргән илледән артык матрос, Казан урамнары буйлап пулеметлардан ата-ата, базарларга килеп, халыкның котын ала. Авылдан килгән халык, әйберләрен ташлап, кайсы кая кача. Урамнарда беркем дә калмый. Капкалар бикләнә. Анда-

монда капка дөбердәтеп, төркем-төркем солдатлар һәм матрослар тентү ясап йөриләр.

Хәрби Шура һәм Мөселман халык комиссариаты әгъзалары кулга алына. Алардан Монасыйпов, Хәсәнов, Сыртланов, Г.Габдрәшитов, Полторжицкий һәм Габдуллин үзләре биреләләр. Ә берничә кеше кача. Тиздән корал җыю нияте белән Казан Советы өч кешедән торган штаб төзи. Аңа Ефремов, Солтангалиев һәм Севров керә.

Меньшевикларның «Рабочее дело» гәзите 28 март вакыйгаларын түбәндәгечә бәяли: *«Тагын пулеметлар, тагын кан кою. Бөек Русия демократиясенең балалары берсе берсенә ярсып ташлана»*[62].

Халыкны тынычландырырга тырышып сөйләгән мөрәҗәгатендә большевик Милх, мыскыллап, *«Болак арты республикасы»н бетерү бара»* дип шапырына. «Рабочее дело» гәзите, үзбилгеләнү мәсьәләсенә дә кагылып: *«Үзбилгеләнү бары тик большевиклар рецепты белән генә уздырылырга тиеш булып чыга, кем дә кем алар символын кабул итми һәм үзенең эчке тормышын үзе оештырырга тели, аңа анафема — пулеметлар»*, — дип яза. *«Безнең Казанда,* — дип дәвам итә шул ук «Рабочее дело», — *каршылык күптән туган иде. Мөселманнарның хәрәкәте акрынлап, тыныч кына үсте... Ул, татар пролетариатыннан һәм вак буржуаз демократиясеннән торган көчле хәрәкәт булып, шушы социаль нигезгә таяна иде. Булдыксыз Шейнкманнар, Грасислар, Милхлар һ.б. компанияләр тарафыннан урнаштырылган хулиганлык атмосферасы бик күп көчләрне милли хәрәкәткә китереп, аны бик көчәйтте. Хәрәкәтнең җитәкчеләре тарафыннан эшләнгән милли-мәдәни мөхтәрият проекты (шактый гына җитешсезлекләре булса да), гомумән алганда, милләтнең саф теләкләрен чагылдырып, шовинизмга каршы чыгып, күршеләр белән дустанә мөнәсәбәттә калуны таләп итә»*.

Үзенең хәрби көчләренә таянып, Хәрби Шура берничә тапкыр үз халкын бу оятсыз большевик тыкшынуларыннан якларга тырышып карады.

Хакимият коралсыз битарафларга тимәде — үз вакытын көтте. Хакимиятнең кайбер әфәнделәре инде күптән суеш чыгарырга теләделәр. Әмма, бәхеткә каршы, барысы да уңышсыз булды.

Эчке фронтта җиңүләр арткан саен, хакимиятнең кыюлыгы көчәя барды һәм, ниһаять, әйтелде: *«Үзбилгеләнү хокукы бары тик Советка гына бирелгән, ә милли оешмалар берсүзсез господин Грасисның «самоопределительный операцияләр»ен күзәтеп торырга тиешләр. Әнә шулай итеп, милли оешмаларга каршы ачыктан-ачык көрәш башланды. Татарлар ачык сугыш кырында көч сынашырга теләмәделәр һәм милли гаскәри частьларны*

һәм Шураны тарату Декретына буйсындылар. Шушы вакыттан башлап милли хәрәкәтне бастырылган дип санарга мөмкин»[63].

Бу мәкаләнең авторы — Айвенго. Әлегә бу псевдонимның кемнеке булуы мәгълүм түгел. Шунысы билгеле: автор, чын демократ буларак, хакимияткә килгән большевикларның гамәлләрен бик дөрес тасвирлаган. «Болак арты республикасы» нәрсә ул?» дигән сорауны турыдан-туры куймаса да, Айвенго: *«Мөселманнар, Болак артына чыгып, бары тик үз-үзләрен саклап калуны гына оештыра алдылар»*,— дип яза. Димәк, «Болак арты республикасы» ниндидер явыз ният белән тудырылган нәрсә түгел, ә бары тик чамадан тыш кыланган Совет хакимиятеннән һәм, сукыр тычкан кебек, аларга ияргән мөселман «суллар»ының явызлыгыннан читкәрәк китеп, хокукларны саклап калуга омтылыш икән.

«Болак арты республикасы» беркем өчен дә куркыныч тудырмыйча, аның асылы үз-үзен саклаудан гыйбарәт иде. *«Большевикларның бетмәс-төкәнмәс җинаятьләренә тагын берсе өстәлде. Бу эш халык исеменнән эшләнде. Килер бер заман, халык исемен файдаланып кан коюны һәм халыкларны берберсенә бәрелештерүләрнең эчке серен аңлап, аларны җирәнеп искә алырлар»*, — дип белдерә ул чордагы оппозицион матбугат[64].

Царизмны бәреп төшереп, революция сөреме белән исергән халыкның зур өлеше, большевикларның вәгъдәләренә ышанып, «социализм» сукмагыннан китте, кызыл байрак астына җыелды. Аның кая китереп чыгарганлыгын инде күпчелек аңлады, әмма узган заманны сагынучылар бүген дә күп әле. Бу хәл исә милли мәсьәләләрне чишү юлында хәзерге вакытта да зур комачаулык тудыра. Татарларга, янә көндәлек сәяси активлыктан үзаң этапларына күчеп, мөстәкыйльлекне тормышка ашыру юлын узарга туры килә!

Табигый сорау туа: 1918 елның февраль һәм март айларында сәяси киеренкелекне булдырмаска мөмкин идеме? Әлбәттә, бөтен мөмкинлекләр булган. Эш шунда ки, «милләтчеләр» белән большевиклар арасында ике төрле идарә шәкеле буенча кискен көрәш барган. Беренчеләре демократия юлын таләп итсәләр, икенчеләре диктатура урнаштыруны даулаган. Ә мәсьәләнең гадел хәл ителүе, ул чорның сәяси вазгыятен истә тотып, демократия белән диктатура гонсырларының (элементлар) бергә үрелеп кулланылуы нигезендә генә мөмкин иде. Әмма беренчеләренең җиңелүе мәсьәләне диктатура тарафдарлары файдасына хәл итүгә китерде, ул үсте, ныгыды. Моның фаҗигале нәтиҗәләрен бүген дә һәркайсыбыз татый әле. Шулай ук диктатура хакимиятенең мәңгелек була алмавы да ачыкланды. Моны тарих үзе исбат итте.

Инде, дөреслек өскә чыкты, дисәк тә ярый...

Ул чакларда кем ничек уйлаган соң? Г.Ибраһимов 1920 елның февралендә түбәндәгечә фикер йөрткән: «*Әллә нинди милли идарәләр, милли шуралар, хәрби шуралар тирәсендә әйләнеп, чех, Колчак вакытында татар революционерларын тоттырып йөргән күп ихлас күңелләр башларындагы иске буржуадан кергән чүп-чарларыннан сафландылар... Тик берничә гаҗиз бәндә генә әле һаман да Финляндия, Гөлҗә, Харбин татар буржуаларының нәҗес кулларыннан тамган хәбис бер тиеннәргә чукынып, Париж банкирларының бусагалары төбендә, рус монархларына койрык булып, адәм көлдереп йөриләр. Ләкин болар хәзер музейга куярлык кына: исәпли башласаң, алты бармаклы гарип кулның бармаклары сафына җитәрлек кенә булган өч игезәктер (Садри — Фуад, Закир — Гомәр, Баттал — Гаяз). Бу өч игезәктән башкалар: 1) иске тормышта ике төрле коллык кичергән эшче-крестьян хатыннарының алдагы гөруһлары; 2) хезмәт халкының азатлыгы кайда икәнен аңларлык булган мөгаллим-мөгаллимәләр, мөрәббия (тәрбияче) иптәшләр; 3) тарихның хәзерге дәверендә, хезмәт белән капиталның канлы, рәхимсез сугышы вакытында, кайсы якта булу мәсьәләсен эшче-крестьян гаммәсе ноктасыннан карап чишкән татар әдипләре, шагыйрьләре; 4) һәркайда, һәр заманда иң бөек әмәлләр белән янучы яшьләр, боларның алдагы гөруһлары, шул авыр, фаҗигале, канлы көрәш, рәхимсез диктатура аша тарих күгендә янып, саф азатлык өстәүче, күңелләрне үзенә тартып торган якты коммунизм кәгъбәсенә таба юл тоттылар*»[65].

Хәзер инде без дә үз фикеребезне әйтә алабыз. Уйлап карасаң, барысы да киресенчә бит. Болак артындагы милләтчеләр — азатлык өчен көрәшчеләр. Өч «игезәк» тә алар сафында. Алардан көлеп, тарих күгендә азатлык эзләп, коммунизм кәгъбәсенә юл тотучылар инкыйлабка, аның җитәкчеләренә ышанып ялгыштылар. Алар барысы да ГУЛАГта һәлак булдылар...

Тоталитар режимның корбаннарын, милли каһарманнарыбызны онытырга безнең хакыбыз юк. Бәйсез дәүләтебезне булдырып, аның нигез ташларына **бәйсезлек, ирек, гомумкилешү, тынычлык** сүзләре — безнең милләтебезнең изге теләкләре язылсын иде. Аларны аңлау, тормышка ашыру өчен, узган тарихыбыздан күренгәнчә, **үзаң, акыл, уяулык кына җитми, ә кыюлык та кирәк.** Бары тик боларның барысы да бергә булганда гына, аларга ия булган зыялы, эшче, крестьян, яше-карты «Ватан» дигән сүзнең төп серен, мәгънәсен аңлый, үзен-үзе җиңәргә, кирәк булса, үлемгә дә икеләнмичә барырга сәләтле була.

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] *Вәлиев Р.К.* Фаҗига.— Казан, 1996.— 20 б.

[2] *Валиди Дж.* У меня разногласия с Сов.властью // Эхо веков (Гасырлар авазы). — 1996 .— № 1/2. — С.167.

[3] Имкян — мөмкинлек.

[4] Яңа милли юл. — 1938. — № 1(116). — 5 — 11б. // Мирас. — 1993. — № 2. — 42 б. Гаяз Исхакый бераз ялгыша. Дөресрәге: 1918 елның 1 мартында.

[5] ЦХИДНИТ. — Ф.36. — Оп.1. — Ед.хр.126. — Л.1.

[6] Яртын — жирдән, тарафтан.

[7] *Камал Г.* Әсәрләр. 3 томда.— Казан, 1979.— Т. 2. — 341б. «Бер ел элек» шигыре беренче тапкыр «Декламацияләр»дә (1921) басылган. *«Казанда Болак арты җөмһүрияте бетерелү мөнәсәбәте белән язылган иде»* дигән искәрмәсе бар. Шигырь соңыннан «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Декламацияләр» (1954) китапларына да кертелгән.

[8] ЦХИДНИТ. — Ф.292. — Оп.1. — Ед.хр.328. — Л.21. Бу материалларны журналист Мәгъсүм Хәбибуллин тәкъдим иткән иде. Аңа зур рәхмәтемне белдерәм.

[9] *Вәлиев Р.К.* Фаҗига.— Казан, 1996; *Рәмиев З.* Тагын бер фаҗигале язмыш // Мирас. — 1996. — № 1/2. — 137 — 141б.; *Султанбеков Б.Ф.* Сталин и татарский след. — Казань, 1995; *Литвин А.Л.* Без права на мысль: Историки в эпоху Большого террора. — Казань, 1993; *Его же.* Запрет на жизнь. Сталинские репрессии в Татарстане. — Казань, 1993; *Сулима Л.О.* Падение правительства «правых» в Тат. республике // Татарстан. — 1994. — № 11/12; *Таһиров И.*Солтангалиев. Кем ул? // Казан утлары. —1989. — № 4.

[10] *Ваисов Г.* Знамение социализма и к чему оно приведет // Знамя революции. —1917. — 2 марта (17 февр.); *Валеев Р.К.* Революционное движение в Среднем Поволжье (июль—октябрь 1917 г.).—Казань, 1972.

[11] Корылтай. —1917. — 14 июль.

[12] Йолдыз. —1917. — 4 авг.

[13] Корылтай. —1917.—1 авг.

[14] *Вәлиев Р.К.* Фаҗига. — 32—34 б.

[15] Шунда ук. — 11—13 б.

[16] Йолдыз. — 1918. — 11 гыйн.

[17] Шунда ук.

[18] ЦХИДНИТ. — Ф.36. — Оп.1. — Ед.хр.451. — Л.53.

[19] Известия Всероссийского мусульманского Военного Шуро.— 1918. — № 10.

[20] Йолдыз. — 1918. — 29 февр.

[21] *Литвин А., Шәрәфетдинов Д.* Өзелгән дога // Татарстан хәбәрләре. — 1993. — 27 февр.

[22] Мирсаид Султан-Галеев М. Статьи, выступления, документы.— Казань, 1992. — С.421 — 422.

[23] *Мухаррямов М.И.* Октябрь и национальный вопрос в Татарии.— Казань, 1958. — С.145 — 148.

[24] В борьбе за счастье народное.— Казань, 1983. — С.304.

[25] За власть Советов. — Казань, 1960. — С.52.

[26] Знамя революции. — 1918. — 21 марта.

[27] Шунда ук. — 22 апр.

[28] Анкета Казандагы архивларда табылмады.

[29] ЦГАСА. — Ф.17. — Оп.1. — Д.125. — Л.17—18 об.; Образование ТАССР.— Казань, 1963.— С.61—65.

[30] Имза куелмаган.

[31] ЦХИДНИТ. — Ф.292. — Оп.1. — Ед.хр.328. — Л.74.

[32] Исповедь пережившего ад // Эхо веков (Гасырлар авазы). — 1996. — № 1/2. — С. 226—236

[33] ЦХИДНИТ. — Арх.120032. — Л.254—255.

[34] *Мухаррямов М.И.* Октябрь и национальный вопрос в Татарии.— Казань, 1958.— С.151—152.

[35] *Хайрутдинов Р.* Трудное возрождение. — Казань, 1992. — С.97.

[36] Бу документ белән безне таныштыруы өчен Марсель Әхмәтҗановка рәхмәтемне белдерәм.

[37] *Айда А.* Садри Максуди Арсал. — М., 1996. — С.115.

[38] Документ Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә Фатих Әмирхан фондында (16 ф., 3 тасв., 5 эш) саклана. Ул документның төп нөсхәсе булып тәзәтелгән, сызылган урыннары күренә. Гарәп хәрефләре белән шәмәхә карада язылган.

[39] «Идел-Урал» һәйәте — 1917 елның 22 июлендә төзелә. Аның әгъзалары: Садретдин Максуди, Ибниәмин Әхтәмов, Галимҗан Шәрәф, Әминә Мөхетдинова, Фатих Кәрими, Камил Кәрими, Нәҗип Хәлфин, Һади Атласи. Әгъзалыкка кандидатлар: Нәҗип Корбангалиев, Гаяз Исхакый, Габдулла Абызов, Гомәр Терегулов.

[40] Шәрәфкә — Галимҗан Шәрәфкә (1896—1950).

[41] Җ ә д в ә л е — графигы, эш вакыты.

[42] Г а р ы з — белдерү.

[43] М ө д а ф ә г а — саклану.

[44] В ә ә л х а л ь — һәм инде.

[45] Ә с а с ы н н а н — нигезеннән.

[46] М ө ә с с ә с ә — оешма.

[47] С а и р — башка, үзгә.

[48] И н а б ә т е н — ышанычын.

[49] С ү и и с т и г ъ м а л ь — урынсыз куллану.

[50] М ә с ь ү л и я т е — җаваплылыгы.

[51] Н ә ү г ъ — төр.

[52] М о г а в и н е — ярдәмчесе.

[53] Әлеге дата документның башында искә алынган телеграмма җибәрелү датасыннан элегрәк була. Димәк, бу документны язу төрле каршылыклар аша барган.

[54] Йолдыз. — 1918. — 19 апр.

[55] Борцы за счастье народное. — Казань, 1989. — С.72. Соңрак Һади Маликов Генштаб академиясендә эшли.

[56] Мирас. — 1997. — № 8, 10, 11.

[57] *«Мөхтәрәм мөселман кардәшләр!*

Идел-Урал өлкәсендә яшәүче төрек-татар балаларыннан гына мөрәккәб (гыйбарәт) булган II Мөселман хәрби корылтае Идел-Урал өлкәсен вөҗүдкә чыгару өчен унбиш кешедән мөрәккәб комиссариат сайлап калдырган иде. Безнең вазифаларыбыз:

1. Эшче халык һәм крестьяннар тарафыннан алынган бөек инкыйлабны саклау һәм Идел-Урал өлкәсендә зөһур (мәйданга чыккан) иткән гакселхәрәкәтчеләр (реакционерлар) белән көрәшү.

2. Тиз заманда милли әмәлләрен вөҗүдкә чыгару өчен Идел-Урал өлкәсендә яшәүче бөтен мөселман демократиясен оештыру.

3. Идел-Урал өлкәсен вөҗүдкә чыгаруны үзләренең вазифалары дип таныган оешмалар белән кулга-кул тотышып, шул өлкәне мөмкин кадәр тизлектә вөҗүдкә чыгару.

4. Идел-Урал өлкәсендә булган эшче һәм крестьян шураларын милли тәнасеб ысулында сайлату. Корылтай вәкилләре, кул көче белән көн күрүче халыкның мәнфәгатен күз алдында тотып, безгә дә шул эшче һәм крестьян халкының мөкаддәс теләкләрен җиренә җиткерергә боерды һәм ничә гасырлардан бирле золым хөкүмәт кул астында изелеп килгән дүрт миллионлык төрек-татар кавеме үзеннән золмәт (коллык) чылбырларын ыргытып, киң сулыш белән яшәсен өчен, ата-бабаларыбызның теләкләреннән булган Идел-Урал өлкәсен вөҗүдкә чыгарырга кушты. II Мөселман гаскәриләре корылтае тарафыннан сайланылган халык комиссариаты үзенең авыр һәм мөкаддәс

хезмәтенә керешү белән Идел-Урал өлкәсендә яшәүче, кул көче белән эш итүдә булган туганнарыбызны үзенә ярдәмгә чакыра вә аларга чын күңеленнән сәлам күндерә!

Яшәсен мөселман демократиясе! Аллаһы Хак аларга ярдәм итсен!

Исмәгыйль Атнагулов, Исхак Алмаев, Габдулла Габдрәшитов, Фәхрелразый Басыйров, Әкрам Биглов, Әфтәхетдин Габидуллин, Сөләйман Ловчицкий, Гали Моракаев, Фатих Мөхәммәдъяров, Сөләйман Полторжицкий, Кашшаф Терегулов, Адәм Якубовский, Әхмәтсолтан Таһиров.

Җомга, 15 март, 1918 сәнә».

Идел-Урал өлкәсе. — 1918. — № 1. — 24 март. (ЦГАИПДРТ, колл.газет, дело 25.)

[58] Знамя революции. — 1918. — 6 апр.; Образование Татарской АССР. — Казань, 1963. — С.43—44.

[59] Мирсаид Султан-Галеев М. Статьи, выступления, документы.— Казань, 1992. — С.425.

[60] Шунда ук.

[61] Йолдыз. —1918. — 19 апр.

[62] Рабочее дело. — 1918. — 30 марта.

[63] Шунда ук.

[64] Шунда ук.

[65] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр. — Казан, 1987. — Т. 7 — 167—168б.

ГАЕПСЕЗДӘН ГАЕПЛЕЛӘР...

Степановның бүген башы авыртып уянды. Март кояшы бөтен бүлмәне яктыртып тора. Шундый матур язның беренче көннәрендә мондый хәлдә калганы юк иде бит әле. Ул аяклары белән одеялын алып атты да, кроватеннан торып, кухняга чыкты. Монда җылырак иде.

Марина Григорьевна әле йоклый. *«Бүген дәресләре юк, күрәсең»* диеп, хатыны бүлмәсенең ишеген акрын гына япты. Ишек аз гына шыгырдап китте. «Инде уяттым, ахрысы, моны» фикере белән ул колагын ишеккә якынайтып тыңлап торды. «Уянмады» диеп, тиз генә кухняга кереп, чәйнеккә су тутырып утка куйгач, тагы кроватена килеп утырды. Аның, чыннан да, бүген кәефе начар иде шул. Күңеле болганып, башы авырта иде ОГПУның Татарстан буенча уполномоченные Степановның. Әллә нинди шөбһәле уйлар... имеш, кемнәрдер аңа телефоннан шалтыраталар, ишеккә кагалар, чакыралар, ә аның барасы килми. Уянып китсә, төш күреп ята икән. Соңгы вакытта йоклау тәртибе дә бозылды. Төнлә уянып йоклап китә алмас булды, ә йоклап киткәч, иртән торулары авырайды. Менә бүген хәтта будильник шалтыравын да ишетмәгән.

— Эш авырайганнан-авырая бит, — диде ул үз-үзенә. — Да... да... — дигәләп, ул, тәрәзә янына килеп, урамга күз салды. Анда каты буран иде. — Кара әле син, — диде ул, маңгаена учы белән сугып, — һава торышын сизә башлаганмын бит, шайтан алгыры.

Чыннан да, кырыгын да тутырмаган Степановның чәчләренә шактый чал төшкән иде шул. Соңгы вакытта колагында йә диңгез, йә кошлар сайрый. Менә шулай Степанов та авырая, салмагая башлаганын сизми дә калды.

Кичә дә бик мәшәкатьле эш булган иде шул. Ни әйтсәң дә, контрреволюцион оешманы фаш итү җиңел эш түгел. Тикшерүчеләр еш алмашынып торалар, эшли белмиләр. Бар белгәннәре кыйнау, сугу, куркыту — ә нәтиҗә юк. Шундый уйлар белән ул тиз генә салкын су белән битләрен сыпырып алгач, чәй белән бутербродларны гына капкалап, тиз генә урамга чыкты. Аны алырга килгән машина өй кырыенда күптән тора иде инде. Шофер Рәхим, аны күргә, җитез генә машинасын ишек төбенә үк китереп, ишеген ачып сәлам бирде.

— Добрый день, товарищ майор! — диде гадәттәгечә.

— Добрый, добрый, дорогой!

Степанов, машинаның утыргычына чумып, күзләрен йомды, үзе дә сизмәстән *«уф»* диеп, башыннан бүреген салды, чигәләрен ышкыды. Баш авыртуы бераз җиңеләйгән кебек булды.

Дзержинский урамына тиз килеп җиттеләр. Ишек төбендә диярлек Якубов белән очраштылар. Әйтерсең лә сүз куешып килгәннәр.

— Хәерле көн! — диде Якубов, Степановка кулын сузып. — Хәерле көн!

— Здравствуй, коллега, — диде официаль тон белән ОГПУ начальнигы Степанов.

Якубов, ишекне ачып, аны алга уздырды. Бу оешмада субординация дигән нәрсәне саклау — закон. Якубов моңа инде күптән күнгән иде. Шулай булса да алар, Степанов белән күп вакытларда бер фикердә булып, бергәләшеп эш итәләр иде. Берберең белән аралашып, аңлашып эшләүгә ни җитә. Моны Якубов та, Степанов та аңлыйлар, әмма соңгы сүз барыбер Степанов ягында. Моның сәбәпләре билгеле. Ул начальник, дәрәҗәсе дә зуррак. Аннан фамилиясе дә бит бөек халыкныкы... Бүген дә, кул биреп исәнләшкәч, Степанов кабинетына уздылар. Степановның кабинеты да зуррак, иркенрәк. Ике тәрәзә аша көн яктысы бүлмәне яктырта. Кирәк булса, тәрәзәләрне томалау өчен зур пәрдәләр дә бар. Степанов бүген дә, өстәле артына кереп утырганчы, гадәттәгечә тәрәзә пәрдәләрен тартыбрак куйды. Шулай да кояш яктысы аның өстәленә җитәрлек якты бирә иде. Утны кабызмыйча гына утырырга булдылар. Якубов үзе дә гел ут кабызып, бүлмәдәге бөтен лампочкаларның көчен сынаган кебек, якты ут белән эшли иде. Аның да күзләре көчен югалта башлаган иде инде. Хәер, аның күзләре яшьтән шулайрак иде инде.

«Әйдә, хуҗа ни тели, шулай булсын» кыяфәте белән Степанов биргән папкага күз салды. Ул яктыгарак якынаеп, кулларын сузыбрак укырга тотынган гына иде, Степанов, йөзен җыерып:

— Татар фашистлары гаепнамәсе, яхшылап укы, — диеп, ул, өстәлдәге графинадан ярты стакан чамасы су алып эчкәч, тәрәзә янына килеп, Черек күл ягын күзәтте. Ул, аптырап, Якубовка карамыйча гына: — Кара әле, бу безнең шеф Гарин түгелме соң? Кем белән гәпләшә «Черек күл» хуҗасы? — диеп кычкырыбрак әйткәнен үзе дә сизмәде, ахрысы.

— Ташла, — диде тыныч кына, гаепнамәне актаруын дәвам итеп, Якубов. Шулай да ул да түзмәде, өстәл артыннан торып, тәрәзә аша урамга күз салды. Чыннан да, анда Гарин табак битле берәүгә, кулларын болгый-болгый, нидер аңлатып маташа кебек иде. — Бу бит, кадерлем, өлкә комитеты секретаре Разумов.

— Да, — диде Степанов, уңайсызлана төшеп.

Ул арада Разумов белән Гарин кулга-кул исәнләшеп аерылып та киттеләр. Партия обкомы секретаре Разумов Осип Михайлович машинасына утырып юкка чыкты, ә Гарин тиз генә ОГПУның имән ишекләре артына чумды. Менә бүген көн шулай башланды...

— Ярый, — диде Степанов, янә өстәле артына үрмәләп, — ярый. Якубов, бир әле миңа папканы! Имзаңны куйдыңмы? — диде ул, соңгы битләргә күзен төшереп. — Все в порядке, менә монда синең имза булырга тиеш, — диде, йомшак тавыш белән.

Якубов ашыкмады. Әйтерсең лә ул бу кәгазьләрне беренче тапкыр гына күрә. Ул, папканы янә кулына алып, башта битләрен барлап чыкты. Барысы да урынында иде. Степановның имзасы инде куелган. *«Һе, һе»*, — диеп, тирли башлаган битләрен сыпырып, папканы ныграк кысты. Имза куюлары җиңел булса да, Якубов өчен бу бер авыр вазифа иде. Дөресен генә әйткәндә, куркаграк иде шул ул. Ата-бабадан калгандыр инде бу гадәт — һәрвакыт сак булу гадәте. Нишлисең, дәүләте дә бит «аларныкы» дигән фикер узды аның башыннан. Карт бабасының да сүзләре еш искә төшә — алар да шул фикердә. *«Имза ул — баш бәясе, улым»*, — ди торган иде Сәетгәрәй карт. Ул, куркаклардан булмаса да, *«Башта, улым, укы, тикшер, уйла, ә инде менә шуннан соң имза мәсьәләсен хәл итәрсең»*, — дия иде. Сәетгәрәй карт күпне күргән, әйтерсең лә университет бетергән бер юрист. Ул шушы уйлар белән тагы бер кат гаепнамәнең беренче битендә тукталып калды. Монда өстә сул яктарак *«Утверждаю полномочный представитель по Татарской АССР...»* диеп язылган.

Гарин әле кулын куймаган. Менә Якубов имзасын куйгач, инде ул да куячак. Менә шуннан соң инде бу документлар закон төсен алачаклар.

Битнең уртасында исә *«Обвинительное заключение по делу... контрреволюционной... повстанческой организации, именующейся... «ВСФП», вскрытой... на территории Татарской Республики»* диеп язылган. Шушы сүзләрне укыгач, Якубов үзе дә сискәнеп куйды. Ул изүләрен ычкындырып, кителен дә ачыбрак куйды. Гаепнамәне күрәсе килмәгән кыяфәт белән кәгазьләрне өстәл уртасынарак этеп куйды да кесәсеннән «Беломор» папиросы алды. Пачкасы әле ачылмаган иде. Беркадәр ул аны ачып маташты. Степанов дәшмәде. Ул тыныч кына Якубовны күзәтә. Кызык кеше бу татар егете. Ничек монда килеп эләккәндер бу кеше — кызганучан адәм.

— Яхшы ябыштырганнар, шайтан алгыры, — дип, пачканы ачкач, икесе дә мул итеп төтен чыгара башладылар. Тирән итеп берәр тапкыр суыргач та тәмәке исе таралып борын тишекләрен

кычыттырып җибәрде. Степановның башы авыртуы азаеп китте, ә Якубовка азрак гайрәт кереп киткән кебек булды, әмма гаепнамәне бер дә укыйсы килми иде шул.

— Ух, как надоело, — дип куйды ул, ишетелерлек итеп.

Ул өстәлдәге папканы янә үз ягына тартты. «Инде имзамны да куярмын» фикере белән соңгы битне ачса, андагы берничә фоторәсемгә күзе төште. Ул аларның барысын да яхшы белә — барысы да татарлар. Алай гына да түгел, татар зыялыларының асыллары. Ә бит берсенең дә гаепләре юк. Моны Степанов та, Якубов та яхшы беләләр. Ул янә карточкадагыларга игътибар итте.

Менә бусы, түбәтәйлесе, сакал-мыеклысы, зыялы Әхмәтһади Максудов. Имеш, ул шушы оешманың җитәкчесе. Сорау алу вакытларында ул Якубовта бары тик яхшы фикерләр генә уятты. Ул сорауларга төпле һәм ышанычлы итеп җаваплар бирде. Чын татар зыялысы: күп китаплар, мәкаләләр, дәреслекләр авторы. Озак еллар дәверендә «Йолдыз» гәзитенең мөхәррире. Сабыр, түземле, ә белеме әйтеп, язып бетерерлек түгел. «Безнең ОГПУда шундый кадрлар булса иде» дигән фикер узды аның башыннан. Менә шундый зыялылардан җыен солдафоннар-наданнар сорау ала бит, дошман итеп табалар, ә тапмаса — «ясыйлар». Әкәмәт, нәрсә белән бетәр икән бу безнең эшләр... Мәсәлән, икенче рәсемдә *«Алкин Рөстәм»* диелгән. Ә күпме соң бу әкияти Алкиннар? Кая карама, Алкин — бары да уңганнар, белемлеләр, курку белмәс татарлар. Сәетгәрәй Алкин, Ильяс Алкин, Җиһангир Алкин... Ниһаять, Рөстәм Алкин. Кара әле син аны, Рөстәмне, нинди яшь, матур күзләр, киң маңгай — акыл билгесе. Әйтерсең лә берни булмаган: йөзе тыныч, хәтта көлемсерәп карый дөньяга, ә менә бу олырак йөзлесе Мусин була инде. Үтәмешев белән Бигаевлар. Аларның йөзләрендә тирән борчылу, билгесезлек сизелә. Ә менә бусы Мостафин Мөхәммәд. Ул иреннәрен кыскан, әйтерсең лә түзем, сезне барыбер җиңәм, дип әйтер кебек. Фотоларны урынына куеп, гаепнамәгә тагы бер кат күз йөртеп чыкканнан соң, Якубов:

— Ярый, барысы да тәртиптә икән, — диде дә кызу хәрәкәтләр белән «Начальник 3-го отделения СПО» диелгән урынга имзасын куйды.

Тәртип шундый: начальник зуррак булган саен имзасын ахыргарак куя. Гаепнамә бөтенләй закон төсен алсын өчен, әле тагын икәү кул куясы икән. Берсе — Кущеев. Ул — ТАССР буенча СППО ПП ОГПУ начальнигы, ә аннан соң гына В.Гарин кул куяр... Якубов җәһәт кенә өстәл артыннан торып, чәчләрен төзәткәләп, кителенең төймәләрен төймәләп китәргә җыенган гына иде, ишекне киң итеп ачып, Степанов килеп керде.

— Булдырдыңмы? — диде ул, көр тавыш белән.

— Әлбәттә, — диде, аның күзләренә карап.

Степановның йөзе дә, күзләре дә әче катык ашаган песинеке кебек иде. Якубов моңа игътибар итмәде, әмма сүз куертмый гына:

— Ярый, мин үземдә булырмын, — диде, янә аның йөзенә күз ташлап. — Әгәр дә тегеләй-болай булса, мин үз урынымда булырмын.

— Ашыкма, Якубыч, ашыкма, син бит ашыга торганнардан түгел. Хәзер дә менә ашыкма. Утыр әле минем янымда. Көннәр буе кабинетта, үзең беләсең...

— Төрмәдә утыру түгел бит, — дип шаяртты Якубов.

— Анысы шулай, әмма утыртулары да бик җиңел түгел, үзең яхшы беләсең, ә? Күрдеңме менә бу татар «фашистлар»ын — бу бит липа, болар нинди дошман булсын да нинди фашистлар булсын ди, ә менә безнең служба синең белән миннән дошман табуны таләп итә. Син менә боларны аклап кара, агай-эне, тырышып кара. Акны — ак, диеп, синең үзеңне дә шушы протоколга кертеп, Себер җибәрәчәкләр бит. Шулай булгач, киләчәктә безнең үзебезнең дә каталажкага китүебез бик мөмкин, — диде ул, эштәшенә сынаулы караш ташлап.

Эштәшенең фикерләре шатландырса да, икенче яктан шөбһәле иде шул. Чыннан да, ни рәвештә тәмамланыр безнең бу хезмәтләребез. Безгә төшәчәк бит таякның авыр башы.

— Әйе, татар булу авыр бу дөньяда, — диде Якубов, Степановның сүзен бүлеп. — Авыр татарга...

— Ә башкаларга? — дип ярсыды Степанов.

— Синең списогыңда башкалар юк бит, — диде катгый рәвештә Якубов, — юк бит, бары тик татар зыялылары гына.

— Чыннан да, шулайрак кебек шул, — диде Степанов, аның фикеренә якынаеп. — Санап китсәң, башкаларга да эләгәчәк.

— Әлбәттә, — дип йомгаклады Якубов, — әлбәттә.

Мондый сөйләшүләр сирәк була. Бүген дә алар кинәт тынып калдылар. Икесе дә артыграк сөйләшеп җибәрделәр дисәк, дөрес булыр. Алар бер-берсен яхшы беләләр иде. Шуңа күрә артык борчылмадылар. Икесе дә гадәттәге хезмәткә керештеләр.

— Болар башка татар, дошманнар, — диде кырт кисеп Степанов. — Үзең беләсең — бер Максудов Әхмәтһади да ни тора. Глыба — дошман. Энесе Садри — эмигрант, Совет властеның дошманы, ә бит әле ул Милли парламентның рәисе, Дума депутаты, ә бүгенге көндә ул Төркиядә профессор... Без хуҗалар күпме канча эшлибез — мондагы «дошманнар»ны чит илдә яшәүче мөһаҗирләр белән бәйләп, зур машстаблы гаепнамәләр тудырабыз. Татар фашистлары капут, иптәш Якубов.

Якубов дәшмәде. Ул сул як күкрәген кысыбрак тотып торды. Йөрәге чәнчи иде, башлары әйләнеп китте. Ул бу сары чәчле

эштәшен үз күреп яшәде. Авыр минутларда аның белән киңәште, ә менә хәзер ни өчендер уйлар төрлечәрәк килеп чыкты. Степанов, кирәк булса, йөзен дә, фикерен дә тиз үзгәртә, ә Якубов мондый эшләрне эшли алмый иде шул. Чыннан да, әгәр бөтен эшләгән эшләрең дөрес булып чыкмасалар, гомерең шулай узса, ни кылырсың, агулы елан йоткан көчек кебек өреп йөрерсеңме?

— Ярар! Ярар, кайгырма! Безгә шулай үзгәрә дә белергә кирәк, тыңлап торулары да бар бит. Алай булса, менә мин сиңа бер анекдот сөйләп алыйм — безнең службага да кагыла.

Шулай бервакыт шәһәр кунакханәсенә берничә кеше килеп урнашканнар. Аларның берничәсе карта уйнарга керешкән. Әй уйныйлар икән болар. Бүлмәдә төтен, шау-шу. Йоклар вакыт җиткәч тә болар туктамаганнар, дәвам иткәннәр.

Авылдан килгән бер абзый:

— Егетләр, бәлкем, йокларга ятарсыз, миңа иртәрәк торырга кирәк, — дип караган.

Болар моннан көлгәннәр генә.

Абзый янә:

— Зинһар өчен, туктагыз, йокларга ятыгыз, — дип үгетләгән боларны.

— Деревня, спи спокойно, иначе... — дип куркыталар да икән әле.

— Ярый, — дигән абзый. — Менә сез монда сүгенәсез, шаулыйсыз, дәүләткә карата да тузга язмаган сүзләр әйтәсез, ә бит монда сезнең сүзләрегезне, японнар әйтмешли, шушы стеналар тыңлап торалар, — дип куркытып карагач та нәтиҗә булмаган.

Алар, уйнауларын дәвам итеп:

— Дядя, мы сами оттуда, — дигәннәр. Ха-ха-ха көлгәннәр. — Йокла, ә без монда...

Менә шуннан соң бу абзый хәйләгә керешә. Ул, тиз генә буфетка барып, андагы буфетчицага:

— Нәкъ 13 минуттан соң безнең бүлмәгә биш стакан чәй кертерсең, мә, акчасын да, — дип, бүлмәсенә кереп тә китә.

Карта уйнаучылар кызганнан-кызалар гына. Бүлмә һаман гөрли.

— Җәмәгать, — ди абзый, — соңгы тапкыр әйтәм: туктагыз! — Ниһаять, ул ачулы тавыш белән, түшәмгә карап: — Товарищ майор, через тринадцать минут принесите, пожалуйста, пять стаканов чая! — дигән.

Карта уйнаучылар тагы көлгәннәр моннан, әмма инде, ни булыр икән, дип, сәгатьләренә караштыргалыйлар икән.

Нәкъ унөч минут дигәндә, бүлмә ишеген ачып, буфетта эшләүче хатын биш стакан чәй керткән.

— Күрдегезме инде?! — дигән абзый, картежникларга карап. — Тагын нәрсә әйтим иптәш майорга?

Карта уйнаучылар башта ни әйтергә белми аптырап калганнар, ә аннан соң чәйләрен дә эчми йокларга ятканнар.

Ниһаять, бүлмәдә тынлык урнашкан. Авыл абзые, чәйләрне үзе эчеп, тирән йокыга киткән. Иртән уянып китсә, ул бүлмәдә берүзе генә калганын күреп гаҗәпләнгән. Тиз генә юынып, киенеп, теге буфетка барган һәм теге хатыннан:

— Минем бүлмәдәшләрем кая киттеләр икән соң? — дип сораган.

Теге хатын, көлеп:

— Аларның барысын да каталажкага озаттылар. Майорга сезнең шаяртуыгыз бик ошады, шуңа күрә сезгә тимәде, — ди икән.

Якубовка да анекдот ошады. Чыннан да, Степанов молодец! Ул рәхәтләнеп көлде. Степанов та аңа кушылды. Менә шулай эш көне башланды. Алда кулга алынганнар белән авыр эш көтә. Язасы, сызасылар, ялган протоколлар төзисе бар бит әле.

* * *

Гарин кем беләндер телефоннан сөйләшә иде. Йөзе борчулы, бик җитди. Ишек ачылуга, чыгып торыгыз, диеп әйтергә уйласа да, ул фикердән кире кайтып, кулы белән ишарә ясап, утырырга урын күрсәтте. Ул, телефоннан сөйләшүен дәвам итеп, эштәшен күзәтте. Бу урта буйлы, киң җилкәле Тамбов егетен ул пөхтә, ышанычлы коллега буларак ошата иде. Командировкага китсә, авырса да, аны үз урынына калдыра торган иде. Иң ошаган ягы — Кушеевның аз сүзле булуыдыр, мөгаен.

Кушеев, вакытсызрак кергәнлеген абайлап, кулындагы кәгазьләрен караштыргалап утыра башлады.

Ниһаять, Гарин, телефонын урынына куеп, алдындагы папкага ябышты. Әйтерсең лә монда ул берүзе генә утыра.

Кушеев, бераз кыюлана төшеп:

— Товарищ полковник, — дип әйтергә җыенган гына иде, Гарин, аңа карамыйча ук, җитди кыяфәт белән:

— Подождите, — дип, кулы белән ишарә ясап, укуын дәвам итте. Папканың соңгы битен карагач, ул: — Тыңлыйм, — диде. — Йә, нәрсә тагы, теге эш буенча материаллармы бу? — диде.

— Так точно, товарищ полковник! Можно идти, товарищ полковник?

— Да, да, можно.

Гаринның шатлыгы йөзенә чыккан иде. Кушеев чыгып китте.

Гарин папканы алган гына иде, тагы телефон шалтырады.

— Ишетәм, ишетәм, — диде ул, таныш тавышны абайлап.

Бу ТАССРның эчке эшләр комиссары Михайлов иде.

— Материаллар минем өстәлдә, әле генә керттеләр. — Ул алдында яткан папканы сыйпап куйды. — Монда бар да сез кушкан-

ча эшләнгән, иптәш комиссар, оешманың эшен кордон белән... — телефон шатыр-шотыр килде. Ишетелү начарайды. — Чит ил белән, кордон белән, — дип кычкырды Гарин, трубкага кереп китәрдәй булып... — кордон белән. Максудов Әхмәтһади һәм Алкиннар аша.

— Понял, — диде Михайлов. Телефон да шыгырдамый башлады. — Телефон линиягезне каратыгыз. Молодцы! Әбәт ашагач, миңа керерсез, — дип сүзен тәмамлады.

— Тыңлыйм, иптәш комиссар! — дип әйтеп тә өлгермәде Гарин, Михайлов трубканы куйды да.

Бигрәк тә каты кеше инде бу Михайлов. Гарин кешеләрне тиз абайлап ала торганнардан иде. Михайловны ул бик тиз аңлап алды. Службист, карьерист, бер йолдыз кисәге өчен эти-әнисен сатарга да булдыра торганнардан. Өстәгеләргә ошау өчен барысын да эшли. Аның кругозоры — тавык кругозоры, күрү горизонты да шулай ук бик тар һәм сыек. Моны Гарин күптән белә иде инде. Күпме эшләп, мондый хәшәрәтне күргәне булмады. Гарин үзе дә шундыйрак бер службист булганга, ул аны бик тиз белеп алган иде. Балыкчыны балыкчы еракган таныйдыр шул. Калганнары да шул «балыкчылар»дан ерак китмәгәннәр — барысы да бер калыптан. Ни әйтсәң дә, һәр профессиянең үз тәэсире бар. Әмма Михайлов барысыннан да явызлыгы, акылсызлыгы белән аерылып тора... Хәзер Казанда да, Рязаньда да бер тәртип — аз гына тайпылсаң, ризасызлык белдерсәң, танышларың, туганнарың чит илдә булсалар, сине эзәрлеклиләр, төрмә-лагерьларга озаталар.

Чыннан да, безнең тирә-якта гел дошман микәнни? Гарин, шикләнеп, ишеккә карады. Имән ишек нык ябылган иде.

— Так, так, — диде ул, яңадан гаепнамә папкасын актарып, — так... — Ул беркадәр гаҗәпсенеп тынып калды. Монда ул «Всесоюзная социалистическая фашистская партия», «Вооруженное свержение Советской власти» кебек җөмләләрне күрде. Бу нәкъ комиссар Михайлов теләгәнчә әүмәкләнгән эшләр бит... — Яхшы. Бик яхшы, — дип, дәртләнеп укый башлады Гарин.

Бу документның дөньяга килүендә аның да өлеше аз түгел иде шул. Шуңа күрә ул да куанды. Әнә шулай, туганкай, эшләсәң, менә дигән кешеләрдән дошман ясап була. Монда барысы да халык комиссары, ОГПУ хуҗасы Ягода кушканча эшләнгән. Чыннан да, оешманың җитәкчесе күренекле галим, татар зыялысы Әхмәтһади Максудов, калганнары да күренекле, билгеле әһелләр. Бу бит зур табыш следователь халкына. Әйе, зур табыш... Гарин — шактый дөнья күргән кеше, әмма мондый гаепнамәне беренче мәртәбә күрә иде шул. Фашистлар партиясе, имеш, коточкыч нәрсә бит бу. Шулай итеп, мондагы документлар аның күңелендә дә ниндидер сискәнү, бертөрле курку хисләрен уят-

ты. Калын бармаклары белән тырпаеп торган чәчләрен бер-ике сыпырып алгач, өстәл артыннан торып, тәрәзә янына килеп, «Черек күл» ягын күзәтте. Халык бу күлгә биргән исем очраклы түгелдер кебек тоелды аңа. «Череп барабыз түгелме икән соң без?» дигән фикер узды аның башыннан. Урамда салкын җил, әмма бу якта әлегә ышык, тыныч. Боз өстендә бала-чага мәш килә. Алар конькида, чанада шуалар. Олыраклар шуларны күзәтеп тәм таба... Гомумән алганда, тормыш гөрли, халык яши. Дзержинский урамында бер кеше дә күренми.

Монда кем килсен? Халык монда нинди учреждение булганын яхшы белә. Өч хәреф, ә калганын үзең беләсең инде. Алла сакласын бу тегермәнгә эләгүдән! ЧК, ә менә хәзер өч хәреф ГПУ...

Берничә мәртәбә телефон шалтырады, әмма Гарин урыныннан кузгалмады. Ул, урамга карап, тирән уйга чумган иде. Ул Лаврентий Бериянең бер киңәшмәдә дошман эзләүне, ничек эшләргә кирәклеге хакында күрсәтмәләр биргәнен хәтеренә китерде. Бу, аның аңлавынча, Сталинча дошманны табу методикасы иде. Гарин ул күрсәтмәләрне хәтердән бик тә яхшы белә: «Методы и практическая к.р. повстанческая деятельность организаций». Менә шушындагы күрсәтмәләргә таянып эшләнгән гаепнамә нәкъ аның өстәлендә ята хәзер. Ул, яңадан өстәле янына килеп басып, гаепнамәгә күз салды.

— Вот, вот так, так, — дип, үз-үзенә сөйләнеп, — менә безгә кирәк нәрсәләр, — диеп, тоткыннарның сорау алу вакытындагы күрсәтмәләрен дикъкать белән укырга кереште. — Ага, обвиняемый Тарасов... Нәрсә сөйли икән бу адәм актыгы?

Ул түбәндәге юлларга игътибар итте: «*Контрреволюцион оешманың Совет власте белән көрәшүенең төп методлары:*

1. Совет аппаратындагы бөтен тискәре моментларны файдаланып, аны яулап алырга.

2. Совет хакимиятенең, партиянең бөтен мероприятиеләренә саботаж ясап, колхозларны җимерергә.

3. Совет хакимияте белән канәгать түгелләрне файдаланып, Совет хакимияте белән көрәшү.

4. Кызыл Армия сафларына һәм уку йортларына кулак һәм «бывшийлар»ның балаларын урнаштырырга. Аларны ялган документлар белән тәэмин итеп алырга, махсус консультация бирергә. Чиста печатьле Совет органнары бланкларын урларга.

5. Халык арасында, листовкалар таратып, ачык көрәш кирәклеге, сугыш яки эшчеләр восстаниесе булачак кебек фикерләр таратырга.

6. Руханилар аркылы дини предрассудокларны файдаланып эшләргә».

Шул ук Тарасовның икенче бер күрсәтмәсендә: *«Безнең оешманың филиаллары Бохарада, Верхне-Удинскида, Уфада, Ленинградта, Харьковта, Донбасста, Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә дә барлыгын күрсәткән икән. Аның фикеренчә, Апанаев Әюп — Бохарада, Верхне-Удинскида — Иманаев, Уфада — Наркомземда эшләүче бертуган Мостафиннар, Дияров Ибраһим Харьков белән элемтәдә иде»*, — диелгән. Шушы юлларны укып алгач, Гарин тагы берничә биткә күз салды. Монда Иманаев Шәйхаттар, Мостафин Мөхәммәд, Файзуллин М., Рәхимов Мөхәммәд, Мостафина Суфияларның фамилияләрен карап, аларның да күрсәтмәләрен зур игътибар белән укуын дәвам итте. Күрсәтмәләрдән күренгәнчә, Рөстәм Алкин Төркиягә качуда гаепләнә. Имеш, ул Йосыф Акчурин янына махсус командировкага җибәрелгән. Ул, Батумига барып, Чорох аркылы Төркиягә качарга маташканда тотылган. Тентү вакытында Акчурага язылган хат табылмаган. Апанаев Әюпнең сүзләренә караганда, Бигаев Шакирның сәгать ремонтлау мастерское сәяси салонга әйләндерелеп, анда Совет власте белән көрәшү проблемалары карала. Гаепләнүче Шәмсетдиновның күрсәтмәләренә караганда, Мостафин Мөхәммәд, Шәмсетдинов Маликлар тиз арада коралллы восстаниегә чыгарга чакыралар, ә Әхмәтһади Максудов халыкара хәл турында сөйләшүне һәм ул кайсы илгә ышанырга булачагын әйтә. Вәлитов Шакир авыл хәлләренә кагылган материаллар бирә. Ул авыл халкының тормышын, колхозчыларның хәлләре хакында мәгълүмат бирә. Оешма әгъзасы Рәхимов Мөхәммәднең күрсәтмәсе Гарингa тагы ошый төште, чөнки ул турыдан-туры комиссар Михайлов таләпләренә туры килә иде бит. Ай-яй. Ул, кулларын ышкый-ышкый, текстка ябышты. Анда түбәндәге юллар ГПУшникның күңеленә хуш килә иде шул.

«Член организации Рахимов Мухаммед:

Сведения, собиравшиеся Тарджемановым и от других членов организации пересылались, по словам последнего, за границу в Турцию. Все эти сведения поступали непосредственно профессору Максудову Садри брату Гадыя Максудова и Шамгулову, происх. из г. Уфы, тот и другой проживают в столице Турции в Стамбуле»[1].

Иртә белән нәкъ шул хакта искәрткән иде бит комиссар Михайлов: эшне кордон белән бәйләгез, дип. Бәйләгәннәр бит. Ай да Якубов, ай да Степанов һәм Кушеев-Царевскийлар. Әйтерсең лә ОГПУ университетларын бетергәннәр — барысын да мач китергәннәр бит, ә. Исән булса шатланыр иде поп, Григорий Царевский кече лейтенант улы өчен. Алланың каһәре төшкере җаннар. Килер бер заман...

Татарстан Республикасы эчке эшләр комиссары Михайловның Шелудченкога язган хатында түбәндәге юллар бар: *«Това-*

рищ. Шелудченко! Грош цена будет, если не получим выход за кордон, в частности в Японию, в Германию... с этой публикой церемониться не следует. Взять от них все до единой капли, все внимание групповым делам с выходом в центр или за кордон. Займись мусульманским духовенством. Оно тесно связано с контрреволюционной организацией панисламистов «Идел-Урал» и т.п. формальностями.

Низовку немедленно изъять, причем увязывай в группу человек 150—200. Надо вычислить, вылизать все корни татарского национального фашизма. Надо нанести сокрушительный удар. Одиночек брать только в крайнем случае, не стоит последними загружаться... Дай указания начальнику РО, немедленно учесть лиц, подлежащих изъятию: татарских националистов-фашистов, контрреволюционное духовенство, карателей, поляков, латышей, повстанцев и повстанческих групп. Я думаю, что по линии только контрреволюционных националистических формирований мы должны взять 2—3 тысячи. Я буду просить 5—8 тысяч человек, так как работали мы слабо... Займись»[2].

Бу — эчке эшләр халык комиссары һәм аның урынбасары Шелудченколарның эшләү методикаларын яхшы чагылдыра торган күрсәтмәләр. Бу сәясәт Татарстанда гына түгел, бөтен СССР буенча алып барыла, чөнки аның төп инициаторлары — И. Сталин һәм Л.Берия. ОГПУ тарафыннан кулга алынганнарны Япония, Германия шпионнары итеп карау хәзер мәҗбүри. Степанов, Гарин, Царевский, Әхмәтов һәм барлык ГПУ следовательләре бу күрсәтмәләрне төп-төгәл итеп үтәүгә бөтен көчен куялар. Бу эшләр дә халык исеменнән эшләнә.

Аларның каты куллары аша күпме татар егетләре узып, каторгада, төрмәләрдә һәлак булдылар. Биш бертуган Шәрәфләр генә дә ни тора. «Партиясезләрнең генераль сәркатибе» диләр Галимҗан Шәрәфне халык телендә. Татар интеллигенциясе тарафыннан И.Сталинга, ҮКга язган барлык хатларны да ул яза, ул редакцияли һәм үзе дә И.Сталинга хат юллый. Ә «татар Бухарины» дигәне? Анысы Миңгәрәй Сәгыйдуллин. Ә Кәшшәф Мохтаров? Санап китсәң, 1939 елның гыйнварында 25 меңгә якын татарлар эш белән төзәтү лагерьларында иделәр бит инде...

«Эш» белән танышуны дәвам итеп, Гарин тагын Мәхмүт Шигаев, Филипп Тукмачев, Шәйхулла Шәйдуллин, Хәнәфи Гаффаров һ.б.ларның күрсәтмәләре белән таныште. Монда Сталинга карата террористик хәрәкәт һәм тагы әллә нинди кеше куркытырлык күрсәтмәләр бар иде. 1932 елның декабрь-гыйнвар айларында башкалар белән беррәттән Мөхәммәд Мостафиннан Штуден фамилияле следователь бертуктаусыз сорау ала һәм беркадәр уңышка да ирешә.

«Сорау: Сезнең к.р. оешмагызның исеме, атамасы бар идеме?

Җавап: 1928 елдан 1932 елга кадәр безнең оешманың исеме, атамасы юк иде. Әмма бу мәсьәлә хакында сөйләшүләр булып тордылар, бервакыт хәтта «Форд» дигән атама бирелгән иде (Фашистское общество Российских демократов). 1931 елда бер утырыш вакытында Бөтенрусия социалистик фашист партиясе (ВСФП) дип атарга булдык.

Сорау: Казаннан кала к.р. оешмагыз тагын кемнәр белән бәйләнештә тора?

Җавап: 1932 елның көзендә безнең оешма хакында хәбәрдар булган Сәгъдиев Габделхак Казаннан Мәскәүгә институтка укырга китте. Әле ул Казанда чагында ук мин аның белән, безнең оешмага матди ярдәм хакында сөйләшеп, аның йортын сату турында үйлашкан идек. Ул безгә матди ярдәм итү хакында каршы түгел иде.

Бер-ике айдан соң Тарасов Мәскәүгә китә. Аңа, Сәгъдиев белән сөйләшеп, матди ярдәм алуга күрсәтмә бирелә. Үзем 1930 елның августында отпускага Бохарага бардым. Бу баруда мин Урта Азиядә хәрәкәт итү һәм шулай ук чит ил белән бәйләнешкә керү, чит илгә чыгу мөмкинлекләрен ачыклауны хәл итәргә теләгән идем, әмма берни дә барып чыкмады. Казанга кире кайтып, оешманың программасын һәм уставын эшләргә булдым. (Программа хакында икенче юлы сөйләрмен. ВСФПның программасының соңгы редакциясен Алкин белән килешкән идек.) Программаны һәм уставны кабат карап чыккач, без башта оешманың әгъзаларына таратырга уйлаган идек, әмма конспирация өчен аларны юк иттек. Соңыннан мин Тарасов өчен кыскартылган вариантын язып биргән идем. Анда саклandымы-юкмы, мин белмим, чөнки мин аңа да аны юк итәргә кушкан идем».

3 гыйнвардагы күрсәтмәсендә ул Всесоюзная социалистическая фашистская партиянең программасы хакында түбәндәгеләргә туктала: *«В области правления Образование Демократической Республики на основе всеобщего избирательного права, путем тайного голосования, без каких-либо классовых ограничений. Диктатура пролетариата должна была заменена демократической формой правления.*

В области экономики наша программа признавала частную собственность...»

Ул тагы бу партиягә керә һәм партия әгъзаларының бурычлары хакында да шактый кызык күрсәтмәләр бирә: *«К.р. ВСФПның җитәкчесе мин үзем идем»*[3].

Гарин, тагы берничә битне игътибар белән укыгач, ул гаепнамәнең беренче битен ачкан гына иде, ишекне ачып, секретарь кыз башы белән күрше бүлмәгә ишарә ясады. Бу ишарә «сезне көтәләр, товарищ полковник» дигән сүз иде.

— Хәзер, хәзер, — диде дә гаепнамәнең сул як почмагына *«Утверждаю, полномочный представитель ОГПУ по Татарской республике»* дип язылган аз гына өстәрәк урынга кызу хәрәкәтләр белән «В.Гарин» диеп имзасын да куйды. Шунда ук 1933 елның 9 октябре иканлеген дә кәгазьгә төшерде. Менә шулай итеп, тагы бер ялган гаепнамә закон төсен алды. Ул йөздән артык татар зыялыларын, хезмәт ияләрен эшләреннән, гаиләләреннән, иректән, якты дөньядан — гомумән алганда, яшәүдән, фикер йөртүдән мәхрүм итте. Моның өчен ОГПУ следовательләре барын да эшләгәннәр, ә калганы бары тик вакыт мәсьәләсе белән генә бәйләнгән иде.

Гарин сәгатенә карады. Сәгать нәкъ берне күрсәтә иде. *«Тринадцать часов»*, — диде ул үз-үзенә. Ул ашыкмады. *«Начальство не опаздывает, а задерживается»*, — дияргә ярата иде ул күңеле күтәренке вакытта. Әйдә көтсеннәр. Бүген бары да әйбәт иде аның өчен, партия, дәүләт кушкан эш яхшы эшләнелгән. Димәк, азрак тәнәфес ясау комачауламас. Көзге каршына басып, чәчләрен кыска бармаклары белән укмаштырып, кулъяулыгы белән иреннәрен сөрткәч, тешләрен дә ыржайтып карагач, борыннарын ышкый-ышкый, кабинетыннан чыгып, җыелыш бүлмәсенә юнәлде.

* * *

Д.Кандыбин — Татарстан Республикасы буенча ОГПУның тулы хокуклы вәкиле — Казаннан китеп котылды. Ул башлаган эшләрне хәзер В.Гарин дәвам итә. Күрәсез, алмаш яхшы эшли, гаепсезләрне гаепли. Кандыбинны да Мәскәү ГПУшниклары үз иттеләр. Монда килеп эләгүнең төп сәбәбе — «халыклар атасы»-ның күрсәтмәләрен аңлап тормышка ашырудадыр. Югыйсә аны СССРның Югары суд коллегиясенең әгъзасы, хәрби юрист итеп куймаслар иде шул. Ул «Зур террор» чорында В.В.Ульрих, И.М.Зырянов, А.А.Батнер, А.А.Вышинскийлар белән Н.Бухаринның, хәтта Г.Ягоданың үзен дә җавапка тартты. Бу хәл 1938 елның 15 февралендә булды. Монда тагы Н. Н. Крестинский, Х.Г.Раковский, Х.Г.Чернов, М.А.Григоренко, Г.Ф.Зеленжский, И.А.Бессонов, А.Икрамов, Ф.Ходжаев, В.Ф.Шарингович, П.Т.Зубарев, П.П.Буланов, Л.Г.Левин, Д.Д.Плетнев, И.Н.Казаков, В.А.Максимов, Крючковлар Русия Җинаять кодексының 58-1а, 58-2, 58-7, 58-8, 58-9, 58-11 матдәләрендә каралган җинаятьләрдә гаепле дип табылганнар иде[4].

Репрессияләрнең көчәйгән чаклары нәкъ менә шушы В.Гарин кул куйган гаепнамә туган чорга туры килде бит. Гаепнамә артыннан гаепнамә туа торды. Әйтерсең лә адәм баласы шулай гаепләнү, мәсхәрә ителү өчен туган диярсең. Әкәмәт бит, аларның бөтен тормышлары дөрес булмаган икән. Кемнәр ясаган соң мондый нәтиҗәләрне? Чыннан да, архив папкаларын чыга-

нак буларак анализ ясый башласаң, ул папкаларда безнең өчен бик күп информация сакланып калган бит. Анда язылганнарның дөрес-дөрес түгеллеген аера белергә, следователь һәм кулга алынганнарның хәлләрен фотодокумент кебек карап булмаса да, аларның психологиясен, күңел төпләрен күрү авыр түгел. Тагы шуны да күз алдына китерми ярамый, бу 70—80 ел тузан җыеп яткан папкалар бүген дә безнең өчен куркынычлар. Бу битләрдә кан эзләре, күз яшьләре сакланып калган. Алар безне дә, күңелләребезне, фикерләребезне шул чорга алып китеп, авыр хәлдә калдыралар. Мин үзем дә, Галимҗан, Гыйльметдин, Борһан, Шәһер, Шиһаб Шәрәфләрнең «эшләр»ен карап, укып чыкканнан соң, бер ай чамасы авырып, алар белән сөйләшеп йөргән кебек булдым. Алай гына да түгел, алар миңа язу-сызу эшләремдә булышкан кебек булдылар. Бу ни дигән сүз буладыр. Бәлкем, бу психофактордыр, бу ягын без тарихчылар бөтенләй искә алмыйбыз бит. Материал байлыгы, охшаш тормыш рәвеше бер-беребез белән аңлашуны җиңеләйтте. Аларның тууына төрле факторлар да бик булышты. Шәрәфләр хакында миңа Сания Шәһеровна бик күп итеп сөйләгән иде. Шуңа күрә архив материаллары «терелеп», «тере» тел белән дә безнең мәгълүмати белемебезне дә киңәйтте.

«Кемнәр ясаган соң мондый нәтиҗәләрне?» дигән идек бит! Әлбәттә, ГПУ сержантлары, офицерлары, генераллары... Н.С.Хрущев «Шәхес культы һәм аның нәтиҗәләре» докладында (1956 ел, 25 февраль) болай дигән иде: *«...шушы съезд җыелу алдыннан берничә көн алда без Үзәк Комитет президиумына следователь Родосны чакырып сорау алдык. Ул — Косиор Чубарьләрдән сорау алган следователь. «Это — никчемный человек с куриным кругозором, в моральном отношении буквально выродок. И вот такой человек определял судьбу известных деятелей партии, определял политику в этих вопросах, потому что, доказывая их «преступность», он тем самым давал материал для крупных политических выводов... Он заявил: «Мне сказали, что Косиор и Чубарев являются врагами народа, поэтому я, как следователь, должен был вытащить из них признание, что они враги... я считал, что выполняю поручение партии»*[5].

Менә мондый следовательләр «Шахтинское дело», «Контрреволюционная трудовая крестьянская партия», «Академическое дело», «Русский социалистический союз», «Политический центр» һәм башка шундый «эшләр»не уйлап чыгардылар. Шундый эшләрнең берсен Казан Родосы — комиссар Михайлов җитәкчелегендәге бер группаның тавык кругозорлы следовательләре тудырдылар. Имеш, Татарстанда Бөтенсоюз фашистлар партиясе төзелгән. Шелудченко-Гарин компанияләре, татар зыялыларын каторгага җибәреп, гүр ияләре ясап, үзләре СССРны җимерүнең

чараларын әзерләделәр. Бу юлда безнең талантлы шәхесләребез корбан булдылар.

1933 елның 9 октябрендә бу эш тә суд тарафына тапшырылды.

Бу ялган гаепнамә «Контрреволюционная, повстанческая организация, именуюшейся «ВСФП» исемендә иде. Түбәндәрәк тагы шушы юллар язылган: *«Полномочным представителем ОГПУ ТАССР вскрыта и ликвидирована контреволюционная, повстанческого толка организация под названием «ВСФП», по своему существу являющяяся национальной к.р. организацией, ставившая целью: вооруженное свержение Советской власти и образование буржуазно-демократической республики на началах всеобщего избирательного права, путем тайного голосования без классовых ограничений, возникновение организации относится к 1928 году, организация сформировалась в Казани ТР из бывших активных деятелей национальных движений».*

Оешманың программасы түбәндәгедән гыйбарәт: 1) Буржуаз демократик республикасы төзү; 2) фабрика-заводларны үз хуҗаларына кайтарып бирү; 3) колхозларны тарату, совхозларны бетерү; 4) җиргә хосусый милекне торгызу; 5) иркле дин.

Шулай итеп, бу гаепнамә репрессияләрнең яңа этапка күтәрелгәнлеген күрсәтә. Әгәр дә 20 нче елларда «зарар китерүче» (вредитель Соввласти) модада булса, хәзер диверсия һәм шымчылык (шпионаж) кебек ярлыклар тагылып, эшне масштаблы итеп күрсәтергә юнәлеш алынган. Аның максаты — халыкны куркытып тору, җавапка тарту, өркетеп тору. Бу хакимият өчен бик тә уңайлы. Халык тыңлаучан: шапырынмый, күп сөйләнми, югарыдагыларның фикерен хуплап тора. Тәнкыйть дигән нәрсәләр бөтенләй диярлек юк. Булса, бик тиз гаепнамә төзелә... НКВД әһелләре И.Сталин, Г.Ягода, Ежов, Бериянең киңәшләре нигезендә күпме гаепнамәләр төзелгәнен әле тарихчылар гына түгел, архив хезмәтчеләре дә белеп җиткермиләрдер. Бу елларда Г.Ягода НКВД хезмәткәрләре белән уздырыла торган утырышларда И.Сталинның күрсәтмәләрен гел искә төшереп тора. Мәсәлән, Г.Ягода оператив работниклар алдындагы чыгышында И.Сталинның «Совет власте өчен иң куркыныч нәрсә — социалистик милекне урлап тарату, социалистик илнең нигезен җимерү, ә икенче куркыныч нәрсә — илдә фашистлар оешмасының барлыкка килүе» дигән фикерләрен ассызыклап әйтә. Шулай итеп, киң масштаблы гаепнамәләр ясалып, бик күп япон, немец, төрек һ.б. илләрнең «шпионнары» табыла, каторгаларга озатылалар. ГПУ Родослары, Гариннары, Царевскийлары, тавык солы арасындагы бодайларны чүпләгән кебек, илебезнең талантлы зыялыларыннан «халык дошманы» ясап, каторгаларга озаттылар.

Ягода тагы шуны искә төшерә: *«могут оживить и зашевелиться группы старых контрреволюционных оппозиционных элементов из троцкистов и правых уклонистов. Это, конечно, не страшно, но все это надо иметь в виду, если мы хотим покончить с этими элементами быстро и без особых жертв»*[6].

Гариннар казанында кайнатып өлгертелгән бу гаепнамә нәкъ юлбашчы кушканча, аның рецептлары белән өлгертелгән, сыйфатлы, масштаблы да. Алар, тырыша торгач, Татарстанны гаепнамәләр әзерләү полигонына әйләндергәннәр иде.

Чыннан да, алар бу к.р. оешманы 1917—1918 еллардагы вакыйгалар белән дә бәйләп дөрес эшлиләр, чөнки, болай эшләгәндә, «эш» бик күпләрне «дошман» ясарга мөмкинлек бирәчәк бит. 1918 елдагы мөселман хәрбиләре депутатларын, «Болак арты»нда туган 15 кешедән торган Мөселман халык комиссариатын, «Идел-Урал штаты» проекты авторларын, ә 20 нче елларда К.Мохтаров җитәкләгән Совнарком тарафыннан беренче Татарстан суверенитетын алга илтүчеләрне һәм башкаларны да бер ГПУ калыбына салып юк итү мөмкинлеге туды.

Менә бу гаепнамә дә, 109 кешене бу «эш» аркылы уздырып, 47 сен судка тапшыра. Калганнарының «эшләр»ен ОГПУ өчлеге хәл итә. Оешманың төп геройлары: Әхмәтһади Максудов,Мөхаммәдшакир Бигаев (Шакир Бигаев), Мөхәммәд Мостафин, Садыйк Мусин, Исмәгыйль Үтәмешев, Рөстәм Алкин[7].

Гаепнамәнең «Нәтиҗә бүлеге»ндә һәрберсенә кыскача характеристика һәм ни өчен гаепләнгәне күрсәтелгән. Анда *«На основании всего изложенного обвиняются:*

Максудов Ахмет-Гадый Низамутдинович, 1886 г. рождения, татарин, уроженец села Ташеу Дубъязского района ТР, житель г. Казани, сын муллы, с высшим образованием, бывший член ЦК партии «Мусульманский иттифак» и Центрального совета военно-повстанческой организации «Милли шуро», бывший член партии кадетов, женат, имеет дочь 12 лет, гр-н СССР.

В том, что:

Возглавлял к.р. повстанческую национально-социалистического толка организацию под наименованием «Всесоюзная социал-фашистская партия», ставившую своей целью свержение Сов.власти вооруженным путем.

Руководил практической к.р. деятельностью этой организации, осуществляя связь с закордоном.

Непосредственно руководил Дубъязской к.р. ячейкой организации, осуществившей в 1932 году повстанческое выступление.

В прошлом был связан с жандармской охранкой, т.е. в преступлении, предусмотренном ст. 58—11 УК.

Бигаев Мухамет-Шакир Закирович, 1883 г. рождения, татарин, уроженец и житель г. Казани ТР, имеет высшее образова-

ние (мусульманин), бывший владелец домов в Казани, Константинополе, Медине (Аравия), где проживал в дореволюционное время несколько лет. В последние годы имеет в г. Казани часовую мастерскую. Женат, имеет двух сыновей 8 и 18 лет и дочь 19 лет, гр-н СССР.

В том, что:

Руководил к.р. деятельностью организации, содержал конспиративную квартиру, где под его руководством обсуждались методы борьбы с Сов.властью вплоть до вооруженного выступления. Руководил к.р. деятельностью сельских к.р. ячеек и осуществлял связь с закордоном через агентуру и лично, путем нелегального перехода границы, содержал конспиративную квартиру организации, где производил вербовку и обрабатывал крестьян в организацию, т.е. в преступлении, предусмотренном ст. 58—11 УК.

Алкин Рустам, 1910 г. рождения, татарин, уроженец и житель г. Казани, сын помещика и чиновника министерства юстиции, образование — незаконченное среднее, исключен из ВЛКСМ, арестовывался за попытку нелегального перехода границы, два раза пытался перейти границу. Женат, детей не имеет. Гр-н СССР.

В том, что:

Состоял членом к.р. организации, имевшей своей целью вооруженное свержение Сов.власти. Участвовал в разработке программ и выпуске к.р. повстанческих воззваний. Осуществлял связь с быв. военным руководителем повстанческой организации «Милли шуро» — Алкиным Ильясом и с закордоном, неоднократно пытался перейти нелегально границу. Работая в сов.учреждениях, снабжал к.р. организацию бланками и печатью, т.е. в преступлении, предусмотренном ст. 58—11, 58—3 УК.

*Виновным себя не признал. Просил себя приговорить к расстрелу. (*Аңа ул вакытта бары тик 22 яшь иде. — *Р.В.)*

Мусин Садыйк, 1808 г. рождения, татарин, уроженец и житель г. Казани, окончил Галеевское медресе, панисламист, бывший член Казанской городской думы, член эсеровской партии «Мусульманский иттифак», во время Генуэзской конференции арестовывался как заложник, на иждивении никого нет, гр-н СССР. Его сын — беглый эмигрант. Находится за границей.

В том что:

Состоял членом к.р. организации, участвовал в нелегальных собраниях, где обсуждался вопрос о свержении Сов.власти, вел пораженческую агитацию, распространял провокационные слухи, т.е. преступлениях, предусмотренных ст. 58-10 и 11 УК.

Утямышев Исмагил Гарифович, 1862 г. рождения, татарин, уроженец дер. Норака Балтасинского района ТР, житель г. Ка

зани, грамотный, бывший владелец мыловаренного завода в г. Казани, бывший член партии правых эсеров, панисламист, бывший член Учредительного Собрания и член городской думы. Один из организаторов военно-повстанческой организации «Милли шуро», женат, имеет сыновей 21 года, 23 года, 33 года, дочерей 27 и 35 лет. Гр-н СССР.

В том, что:

Состоял членом к.р. организации, постоянно участвовал в собраниях в мастерской Бигиева и у руководителя к.р. организации Максудова Гадыя, где принимал активное участие в проработке вопросов, прорабатывались вопросы организации вооруженного выступления против Сов.власти, т.е. в преступлении, предусмотренном ст.58—11 УК.

Мустафин Мухаммед Абдуллович, 1909 г. рождения, татарин, со средним образованием, уроженец села ст. Тимошкино бывшей Ульяновской губ., житель г. Казани, сын доверенного известного пантюркиста, эмигранта Акчурина Юсуфа, племянник расстрелянного за руководство восстанием, организованным к.р. организацией «Милли шуро» муллы Апанаева Абдуллы, быв. члена ЦК Всероссийской партии мусульман.

В том, что:

Руководил к.р. деятельностью организации по линии молодежи, по линии вербовки в РККА, по линии подготовки складов для оружия, по линии экспроприации, руководил разъездной агентурой, организовал ряд филиалов к.р. организации в других городах СССР и к.р. ячейки в районах ТР. Являлся автором к.р. повстанческих возваний, прорабатывал план вооруженного свержения Сов.власти, принимал личное участие в хищении пишущих машин, а также чистых бланков в массовом количестве, коими снабжал сыновей буржуазии и занимался вербовкой людей в организацию, т.е. в преступлении, предусмотренном ст. 58—11, 58—3 УК.»[8]

Менә бу алты гаепләнүче оешманың җитәкчеләре дип каралганнар. Чыннан да, һәркайсы — милләтнең алтын бөртекләре. Алар берсе дә үзләренең гаепләрен танымадылар. Гаепнамәдә бу турыда *«виновным себя не признал»* дигән юллары сакланган. Алар барысы да «кеше сүзе», «үзләренең» генә күрсәтмәләре нигезендә гаепләнәләр. Болар гаепләү өчен дәлил була алмыйлар, чөнки алар көчләү, җәзалау юлы белән алыналар. Бу инде безгә мәгълүм. Шулай булуга карамастан алар барысы да җавапка тартылалар.

Следовательләрнең эш методикалары хакында да чыганаклар сакланган. Бу хөкемгә, җәзага тартылганнарның гаризаларында да яхшы күренә. Менә шундый документларның берсе — Томск шәһәренә ссылкага җибәрелгән фәнни хезмәткәр, һөнәре буенча юрист Шәйхаттар Иманаевның СССР ОГПУ коллегиясе-

нең рәисе Вышинскийга, И.Сталинга, М.И.Ульяновага җибәрергә әзерләнгән гаризасы. *«1933 елның февралендә,* — ди ул, — *следователь Степанов, өченче отдел хуҗасы Якубов һәм өч бертуган Царевскийлар, К... прокурор Кузнецов һәм башкалар физик көч, психик басым ясап һәм алдалап... мине үлем хәлендә... ялган протоколга кул куйдырттылар... Царевский миңа әйтте: «Берничә кешене атарбыз, ә сезне бүләкләрбез, күтәрербез»,* — диде. Моның өчен башкалар турында да ялган күрсәтмәләр бирү кирәк иде. Шәйхаттар Иманаевтан төрек, фарсы, әфган посоллары хакында ялган күрсәтмәләр бирүне таләп итәләр[9]. Соңрак кулга алынып, ГПУ тозагына эләккән Галимҗан Шәрәф тә: *«...әлеге беркетмәгә өч тәүлек буенча өзлексез сорау алулардан соң, 60 сәгатьтән артык басып торганнан соң, тикшерүче Әхмәтовның берничә тапкыр каты итеп йодрык белән сугуыннан һәм шул ук хәрәкәтләрне дәвам итәчәге белән янавыннан соң кул куйдым. Башка кешеләргә кагылган өлешенә шул ук тикшерүче йогынтысы нәтиҗәсендә кул куярга мәҗбүр булдым»,* — ди.

Моның өчен Гарин компаниясе, комиссар Михайлов аппараты барын да эшли. Алар оешманың үзәген Казанда ясап, аның филиалларын авылларда, Уфа, Бохара, Харьков, Баку, Сухуми, Ташкент, Сәмәрканд, Ашхабад һ.б. шәһәрләрдә «табалар». Шул маташулар аркасында Урта Азиядә дә «Урта Азия фашистлары партиясе» табыла. Бу турыда шул чорда нәшер ителгән «Кызыл Татарстан» гәзите хәбәр итә. Монда бу партиядән тыш тагы «Иттихаде төрек партиясе» дә булган дигән мәгълүмат бирелә. Бу партия дә, Казандагы ВСФП кебек үк, «СССРдагы бөтен республикалар белән бик нык бәйләнештә» дигән фикер уздырыла. Имеш, алар бер яктан яшьләрне «Иттихаде төрек»кә өндәсәләр, икенче яктан басмачыларга булышу сәясәтен алып баралар, диелә. Моңа «Туран автономиясе» дә килеп кушыла. «Кызыл Татарстан» гәзитенең язуына караганда, Урта Азия «фашистлары»ннан Әгъләм Заһретдинов, Ишан Хуҗахан, Мөнәвәр Гәрәй, Госман Тухталарны гаеплиләр. Туран әгъзаларыннан: Гобәйдулла Ходжаев (Хуҗаев), Насретдин Галимов, Сәеткулов, Михшановлар җавапка тартылалар. «Кызыл Татарстан» битләрендә тагы «Икейөзлелеккә каршы көрәш», «Контрреволюцион корткычлар оешмасы» һәм башка шундый яшертен оешмалар хакында мәкаләлер чыгарып, киң җәмәгатьчелекне үзләре әзерләгән гаепнамәләрнең очраклы түгел икәнлеген исбат итү өчен эшләнгәнлеге көн кебек ачык. Имеш, мондый оешмалар бездә генә түгел, бөтен ил буенча таралганнар.

Шулай итеп, гаепнамәне тормышка ашыруда урындагы административ органнар белән беррәттән вакытлы матбугат та үз өлешен кертә[10].

Җитәкчеләр өч категориягә бүленгәннәр. Беренчеләре — «Иттифак» фиркасенең элеккеге әгъзалары, икенчеләре Милли Шурадан, өченчеләре — татар буржуазиясе һәм мөселман фиркаләренең элеккеге әгъзалары...

Гаепнамәдән күренгәнчә, оешманың төп җитәкчесе булып Әхмәтһади Максудов торган була. Югары белемле, 15 ел дәверендә «Йолдыз» гәзитенең мөхәррире, бик күп мәкаләләр, дәреслекләр, китаплар авторы. Дәүләт Думасы депутаты Садри Максудовның туганы була. Ул, Гаспринский белән танышып, аңа охшарга тырышып, татар халкына бик күп изге эшләр эшләгән кеше. Әхмәтһади Максудов, аңа ияреп, җәдидчелекне алга сөрә һәм, Бакчасарайдан кайткач, үзе дә «Беренче укытучы», «Икенче укытучы» исеме астында яңа дәреслекләр нәшер итә. Соңрак ул «Төрек теленең грамматикасы»н, «Төрек теленең синтаксисы»н да язып, дөньяга чыгара. Менә шуңа күрәдер инде Г.Баттал: *«Әхмәтһади Максуди культура һәм педагогика өлкәсендә Казан төрекләре арасында гына түгел, ә бөтен төрки халыклар арасында да дан казанды»*, — дип язган.

«Йолдыз» гәзитенең мөхәррире буларак кылган эшләре генә дә аның исемен тарихка кертү өчен җитәрлек була. Озак еллар дәверендә тарихчылар, журналистлар, әдәбиятчылар «Йолдыз»ны йолдыз итеп түгел, ә бер зарарлы, куркыныч нәрсә сыйфатында искә алып, милләтчеләр, буржуаз матбугат итеп карап сүктеләр. Чынлыкта исә XX гасыр башын өйрәнү бу гәзитсез мөмкин дә түгел. Әхмәтһади Максудовның сүзләре белән әйткәндә, бу — чын милли гәзит, һәм гасыр башындагы вакыйгаларны, үзгәрешләрне бу гәзитне укымый торып аңлап бетереп булмыйдыр. Бик күп милли материаллар бары «Йолдыз» битләрендә генә дөнья күргәннәр. Шундыйлардан — II Мөселман хәрбиләре съезды (1918, февраль-март), Болак арты вакыйгалары. Бу материалларның архивларда сакланмаганлыгын искә алсаң, гәзитнең чыганак буларак әһәмияте тагы да арта, киңәя. Әле бүгенгә кадәр бу гәзиткә матбугатта тиешле бәя бирелмәгән. Бу — факт. Гарәп шрифты белән язылган, фарсы, төрек терминологияләре кулланылган «Йолдыз» язмаларын Гарин да, Якубов, Царевский-Степановлар да укып азапланмаганнар, чөнки бу планда да алар чеп-чи наданнар һәм аларга моның кирәге дә юк иде.

Г. Баттал-Таймасның *«Әхмәтһади Максуди бик сак эшли иде, кыю журналист түгел иде»* дигән сүзләре белән бик үк килешеп бетеп булмый, чөнки бу — Русия, монда төрле яктан уйлап эш итүнең файдалы икәнлегенә Батталның үз язмышы да бер дәлил бит. Талантлы педагог, гадел, сабыр мөхәррир-журналист үзенең кай илдә, кай җирдә икәнлеген онытмаганлыгын күрсәтәдер. Жандармерия әзәрлекләүләренең нәрсә белән беткәнлеге безгә дә мәгълүм бит. Кулга алулар, мәдрәсәләрне куып

таратулар, тентүләр, төрмәләргә ябу эшләрен патша дәүләте вакытында да бик яхшы, төгәл башкардылар. Татарстандагы вакыйгалар һәм, ниһаять, Совет хакимиятенең дә Әхмәтһадига мөнәсәбәте бу турыда сөйләмимени? Октябрь революциясеннән соң Максудовлар гына түгел, бөтен татар зыялылары авыр хәлдә калдылар. Милли гәзит-журналлар ябылдылар, алар урынына коммунистларның сәяси матбугаты туды. «Коммунистический путь», «Красная Татария», «Кызыл Татарстан» һәм башка сәяси органнар Әхмәтһади кебек күренекле зыялыларга бөтен нәшриятка юлны япты, дисәк тә ялгышмабыз. Алай гына да түгел, яшәү мөмкинлегеннән мәхрүм итте. Шулай булгач, әле ни өчен япь-яшь гаепсез татар егете Рөстәм Алкин: *«Мине атып үтерегез!»* — дисен соң? Өметен өзгән кешегә тагы ни кала. Г. Баттал-Таймаслар чорында, 1917—1918 елларда, бәлкем, чыннан да, кыюрак хәрәкәт кирәк булгандыр, чөнки бу чор әле демократия белән диктатураның көч сынашкан чагы. Әмма монда да бу кыюлыкны аннан түгел, ә II Мөселман хәрбиләре депутатларыннан гына таләп итеп буладыр, чөнки Казанда гына да Хәрби Шураның 25 меңлек гаскәриләре була. Алар, *«килешү көтеп»* («Йолдыз» гәзите сүзләре. — *Р.В.*), ниһаять, Болак артында төзелгән «Идел-Урал өлкәсе»н тормышка ашыра башлаган 15 кешедән торган Мөселман комиссариатын кулга алуга китереп җиткерәләр. Әлбәттә, алар кан коюны булдырмадылар, әмма диктатура алдады һәм демократияне җиңде. Күрәсең, монда сак булу гына түгел, көчле булу һәм аннан файдалана белү кирәк булгандыр. Шунысы кызык: боларның шулай икәнлеген дә без Әхмәтһади Максудов җитәкләгән «Йолдыз» гәзите аша беләбез. Ул үзен беркайчан да гаепле дип санамады. 70 елдан артык вакыт үткәч, без моны тагы бер тапкыр күреп, белеп шатландык. Әгәр Родос, Михайлов, Гариннар бүген безнең күңелләребездә нәфрәт тудырсалар, Ә.Максудов, Р.Алкин, Ш.Иманаев һәм башкалар белән без горурланабыз, аларга җырлар язабыз.

Гаепнамәгә карата нәтиҗәне прокуратура да ясый. Ул, аны дөрес дип табып, 1933 елның 7 октябрендә үзенең карарын кабул итә. 109 кешенең эше каралып, бу эш буенча 47 кеше гаепләнә. Шул ук елның 13 декабрендә ОГПУның суд коллегиясендә шушы 47 кешенең язмышлары хәл ителә[11]. Протоколдан күренгәнчә, Ә.Максудовны өч елга Вятка шәһәренә, М.Мостафин, Р.Алкин, М.Бигаевны өч елга ИТЛга, Ш.Иманаевны Көнбатыш Себергә өч елга, ә И.Үтәмешевне ике елга ИТЛга җибәрергә дигән карар кабул ителә.

Ялган гаепнамә үз вазифаларын үти. Тикшерүчеләр яңадан-яңа «эшләр» ясыйлар. 1934 елның беренче декабрендә, С.М.Киров үтерелгәннән соң, бу «эшләр» яңа үрләргә менеп, «Зур террорга» әверелеп, ил өстен кара болыт булып каплыйлар.

* * *

Гаепсезгә гаепләнгәннәрнең язмышы төрлечәрәк тәмамлана. Мәшһүр Ә.Максудов, өч ел урынына сигез ел утырып, туган иленә кайтып, шунда мәрхүм була[12]. М.Мостафин Казанга кайта. Р.Алкин 1935 елның 7 августында иреккә чыга һәм Сызраньга юнәлә. Калганнарының язмышлары безгә билгеле түгел.

Шушы гаепнамә нигезендә җавапка тартылганнар барысы да бүгенге көндә акландылар, чөнки аларның гаебен исбат итәрлек бернинди фактлар таба алмадылар.

1939 елның маенда Михайловны, Шелудченконы һәм Наркоматның тагын өч кешесен кулга алып, 1940 елның февралендә аталар. Шул ук елда Н.Ежов та үлә. Сталин һәм Дәүләт куркынычсызлыгы комиссары Берия Совет властен, компартияне һәм аның җитәкчеләрен акларга маташтылар. Әмма бу вакыйгалардан соң да илдә шул хәл дәвам итеп, репрессияләр тагы да куркыныч төс алалар. И.И.Курниковның Л.И.Брежневка язган хатында менә мондый юллар бар:

«А. Ф. Алемасов прибыл в Татарию на должность наркома внутренних дел 1937 года в июне—июле мес. на смену В. Гарину.

*..Алемасов с первых дней своей деятельности приступил к разгрому и физическому уничтожению (*республика кадрларын. *— Р.В.) В августе 1937 года Алемасов назначается Центральным Комитетом ВКП(б) первым секретарем Татарского обкома ВКП(б), на котором присутствовал Г. М. Маленков... вступив в должность первого секретаря... начал громить пачками кадры... Были арестованы все до единого члены бюро и кандидаты в члены бюро, все до единого заведующие, заместители, если не все, то почти все инструкторы обкома ВКП(б). Поголовно арестован Совнарком со всеми его наркомами и руководителями комиссии Совнаркома. Почти все секретари городских и сельских районных комитетов партии... директора заводов и фабрик, совхозов, МТС, комсомольские работники, работники профсоюза, очень много военных... Бесследно исчезли предсовнаркома Киям Абрамов, А. К. Лепа, Пожилов, Байчурин... и многие другие.»*[14].

Шулай итеп, террордан террорга барган ил «Зур террор» чорына керә.

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8233. — Д. 14611. — Т. 4. — С. 978—991.

[2] Письмо Михайлова Шелудченко // *Султанбеков Б.* Мирсаид Султангалиев. Судьба, Люди, Время. — Казань, 1991. — С. 204—205.

[3] Шунда ук.

[4] Генрих Ягода. Нарком внутренних дел СССР. Генеральный комиссар госбезопасности. Сб. документов. — Казань, 1997. — С. 241.

[5] О культе личности и его последствиях. Доклад первого секретаря ЦК КПСС Н.С.Хрущева. XX съезд КПСС. 25 февраля 1956 г. // Реабилитация, политические процессы 30—50-х годов. — М., 1991. — С. 41.

[6] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8233. — Д. 14611.

[7] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8233. — Д. 2-1461114. — Л. 968—970.

[8] Шунда ук. — 993, 995—998 б.

[9] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8233. — Д. 14611. — С. 65.

[10] Кызыл Татарстан. — 1930. — 17 авг., 26 сент.; — 1933. — 13 июль.

[11] ЦГАИПДРТ. — Ф. 8233. — Д. 2-1461114. — Кор. 200.

[12] Әхмәтһади Максудов, Вятка шәһәрендә срогын тутырганнан соң, янә 1938 елда кулга алынып җавапка тартыла. 70 яшенә җитеп, 1941 елны Казанда вафат була. Бу турыда Төркиядә «Общественное мнение» гәзитендә генә некролог чыга.

[13] *Султанбеков Б.* Мирсаид Султангалиев. Судьба, Люди, Время. — Казань, 1991. — С. 197—198.

ЭЧТӘЛЕК

Автордан
3
Гаепнамә, яисә «татар контрреволюциясе»
7
Өзелгән дога
49
«Милли тайпылыш»
103
Туры сүзле, баш бирмәс шәхес
153
Милләт һәм төрек-татар тарихы
165
Чын бәяне тарих үзе бирә
185
«Болак арты республикасы»
209
Гаепсездән гаепләләр...
247

Научно-популярное издание

Валеев Рамзи Калимович

ПРЕРВАННАЯ МОЛИТВА

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Фәнни-популяр басма

Вәлиев Рәмзи Кәлимович

ӨЗЕЛГӘН ДОГА

Мөхәррире *И.Ф.Сафин*
Рәссамы *И.Р.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
Ф.Р.Гыйсмәтуллина
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.03.2007. Форматы $60\times90^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 17,0 + вкл. 1,50. Шартлы буяу-оттиск 20,0.
Нәшер-хисап табагы 18,42 + вкл. 1,42. Тиражы 2000 д. Заказ С-107.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ. 420066.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

Вәлиев Рәмзи Кәлимулла улы 1937 елда Яшел Үзән районы Карашәм авылында туган. Тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирү тармагы мактаулы хезмәткәре, академик, Халыкара Кол Гали премиясе лауреаты. Россия, Татарстан тарихын һәм милләтара мөгамәләләрне өйрәнүче галим. 200 дән артык мәкалә һәм китаплар авторы.